


# Казан утлары

1.1988





Шиһабетдин Мәрҗани

(1818—1889)



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН
ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ
ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ
МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

1988

1

(783)

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА
ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

## *Бу санда*

ПРОЗА ҺӘМ ПОЭЗИЯ

Я. ЗӘНКИЕВ. Иртеш таңнары. *Роман* 3
Г. ЗӘЙНАШЕВА. Топольләр. *Шигырьләр* 86
Р. МӨХӘММӘДИЕВ. Урман карачкысы. *Хикәя* 90
Ш. МАННАПОВ. Җиргә сыенам. *Шигырьләр* 109
Я. ИГӘНӘЙ. Атыла йолдыз... *Шигырьләр* 114

ПУБЛИЦИСТИКА

З. МАНСУРОВ. «Гакълым берлә... кул талаша» 116

ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ

Р. С. ХӘМӘДИЕВ. Барыйк әле Минзәләгә! 125

БӘХӘСКӘ ЧАКЫРАБЫЗ

Р. МОСТАФИН, В. НУРУЛЛИН. Заман һәм шигырь 130

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

М. ВӘЛИЕВ. Киләчәккә кайту 135

УФАДА КУЛЬТУРАБЫЗ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

А. ТИМЕРГАЛИНА. «Сабах» китап кибете урнашкан бина 144
И. НУРУЛЛИН. Тукай Уфада 145

ШИҺАБЕТДИН МӘРҖАНИНЕҢ ТУУЫНА 170 ЕЛ

Я. АБДУЛЛИН. Философ һәм фикер иясе 146
Ш. МӘРҖАНИ. Казан һәм Болгар хәлләреннән файдаланылган хәбәрләр 154
Кызыклы хәлләр 170

ФӘТХИ БУРНАШНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

А. ӘХМӘДУЛЛИН. Кызыл чәчәкләр аңа 172
Ф. БУРНАШ. Илһам. *Пьесадан өзекләр* 174

АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВКА 60 ЯШЬ

Ил кайный, фикер көрәшә! 177

ШАМИЛ БИКЧУРИНГА 60 ЯШЬ

Р. ТӨХФӘТУЛЛИН. Геройлары белән кулга-кул 183

БОРЫНГЫ БОЛГАР ШӘҺӘРЛӘРЕ

Ф. ГАРИПОВА. Шәһре Болгар 186

Культура тормышы көндәлеге 189

Тышлыктагы сурәтләр 192

*Баш редактор*

**РЕНАТ ХАРИС**

*Редколлегия*

**МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ**

**ӘХӘТ ГАФФАР**

**МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ**

**АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ**

**МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ**

**МӘДИНӘ МАЛИКОВА**

**САЛИХ МАННАПОВ**
*(баш редактор урынбасары)*

**ТУФАН МИҢНУЛЛИН**

**ФЛҮН МУСИН**

**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ**

**РӘФЫЙК НӘФЫЙКОВ**

**НУРИХАН ФӘТТАХ**

**РИЗВАН ХӘМИД**

**НИЛ ЮЗИЕВ**

**АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН**

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

Роман Я. ЗАНКИЕВА «Зори Иртыша», рассказ Р. МУХАММАДИЕВА «Лесное пугало». Стихи Г. ЗАЙНАШЕВОЙ, Ш. МАННАПОВА, Я. ИГЭНЕЙ.
«Публицистика»: статья З. МАНСУРОВА; «Татарстан — родной мой край» — выступление первого секретаря Мензелинского райкома КПСС Р. С. ХАМАДЕЕВА.
Дискуссия «Время и поэзия». Беседа главного редактора Таткнигоиздата В. НУРУЛЛИНА и секретаря парторганизации Союза писателей ТАССР Р. МУСТАФИНА.
Статья М. ВАЛЕЕВА о творчестве М. Аглямова.
«Памятники татарской культуры в Уфе» — здание бывшего книжного магазина «Сабах».
К 170-летию татарского просветителя, ученого-энциклопедиста Ш. Марджани. Впервые публикуется его труд, переложенный на современный татарский язык «Сведения, привлеченные для истории Казани и Булгарии» и статья профессора Я. АБДУЛЛИНА о жизни и творчестве Ш. Марджани.
К 90-летию со дня рождения классика татарской драматургии Ф. Бурнаша — отрывки из его неопубликованной пьесы и статья А. АХМАДУЛЛИНА.
В номере отмечаются юбилеи известных писателей А. Гилязова и Ш. Бикчурина.
Новая рубрика: «Города древней Булгарии» — статья кандидата филологических наук Ф. ГАРИПОВОЙ.
Дневник культурной жизни.
На наших обложках — народные ювелирные изделия — футляр для книг XIV—XV вв. Дом литераторов в Казани.

Безнең адрес: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор —53-07-60,
баш редактор урынбасары — 53-07-09,
җаваплы секретарь —53-07-09,
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк —53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар —53-07-63.

*Җаваплы секретарь* Флүс ЛАТЫЙПОВ
Техник редактор *Р. Сөләйманова*. Корректорлар *Т. Сибгатуллина, Г. Салихҗанова.*

Производствога бирелде 10.11.1987 ел. Басарга кул куелды 06.1.1988 ел. ПФ 05001. Офсет ысулы белән басыла.
Кәгазь форматы 70 × 108[1]/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 66049. Заказ М-468. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1988 ел.

# ПРОЗА

**Якуб Зәнкиев**

# ИРТЕШ ТАҢНАРЫ

РОМАН

## Беренче кисәк

### I




елның августы. Мөхәммәт Уразаевның башын кая куярга белми исәнгерәп йөргән чагы. Сәүдә училищесын тәмамлаганда сөенечтән авызы ерылган иде. Мөкә байда хезмәт итә башлагач, сөмсере коелды, авызында сүзе калмаган кебек, иреннәре берегеп кысылдылар. Инде менә ничә көннәр, таң туса, өйдә җәнҗал-талаш — каенатасы Мөкә бер яктан, хатыны Миңлекалыш икенче яктан Мөхәммәтне йолыккалыйлар, сәүдә эшләрен үз кулына алып, байда управляющий булып калырга өндиләр. Мөкә карунның күн заводы, замш бияләй тегү мастерскойлары белән җитәкчелек итәргә кушалар. Барамы соң Мөхәммәт, заводтагы хәлләрне яхшы белә, укыган чакта эшчеләр янына кергәләп йөрде, белеш-танышлары җитәрлек, алар сөйләгәнне тыңлап ничә тапкыр кызып-ярсып киткән чаклары булды — күпләрнең соңгы канын имеп бетергән каһәрле урын ул болан, поши тиресен эшкә кертә торган завод!

Бүген уянды да, кичтән калган суык чәйне голт-голт йотып, аяк очларына басып кына урамга чыгып китте — каенатасы белән хатыны уянганчы күздән югалырга кирәк. Аптырап йөри торгач, губернатор йорты тирәсенә барып чыкты. Тобол каласының иң чиста, иң җыйнак, башка чакларда тын яткан мәйданы бүген гөр килә. Хәйран тамаша, халык җыелган, теге чаттан да, бу чаттан да ир-ат, хатын-кыз, бала-чага чабыша, барысы да җанланып сөйләшә-сөйләшә губернатор пулатының челтәрле балконына кул изәп күрсәтәләр. Мөхәммәт кысылып-ерып алгарак узды, күтәрелеп караса, исе китеп авызы ачык калды: ак пулатның икенче каты балконында Вакытлы хөкүмәт тарафыннан Тоболга сөрелгән Николай патша Романов басып тора. Янында императрица, ул бер дә исе китмәгән кыяфәт белән янәшәсенә баскан кызларына елмая-елмая нидер сөйли, җил кабарткан күпертмә итәген кулы белән сыпырып, җыештырып ала. Николай патша!..

---

*ЯКУБ ЗӘНКИЕВ (1917) — Иркутск шәһәрендә туган. 1942 елда үзе теләп Бөек Ватан сугышына китә, сугышны Прага шәһәрендә тәмамлый. РСФСРның атказанган укытучысы. РСФСР күләмендә персональ пенсионер. Тобол шәһәрендә яши. Журналда проза әсәре белән беренче тапкыр катнашуы.*

*Романның әдәби вариантын Аяз Гыйләҗев эшләде.*

Мөхәммәт янына елышкан курач кына бер адәм:

— Падишабыз аттан төшсә дә, ирдән төшмәскә ниятли бугай!— дип сүз катса да, ул эндәшмәде, кызыксынып алгарак узды. Николай патша да челтәргә якынрак килде, иелеп тузанын өреп җибәргәч, ап-ак пирчәткәле куллары белән балкон читенә килеп таянды. Елмаю билгесе булып уң як мыек очы бер югары күтәрелде, бер түбән төште. Балкон астына бала-чага, үсмерләр кереп тулган иде. Николай патша гәүдәсен турайтып олы кызы Ольгага ым какты. Чибәр кыз кулындагы нәни сумкасын ачты, тар учы белән көрәп вак акчалар чыгарды һәм аста кайнашкан малайшалай өстенә сибеп җибәрде. Көмеш, бакыр акчалар ашлык җилгәргәндәге бодай бөртекләре сыман җиргә сибелде. Ни булганын аңышмый аптырап торган бала-чаганы кысып, сытып якындагы ир-атлар акча җыярга тотындылар. Малайлар да исләренә килеп олыларның тез асларына чумдылар, аларның кулларын тешләделәр, кычкырып чинадылар, китте талаш, китте әүмәкләшү, җиң төпләре умырылды, бит-куллар канады... Менә кайда икән әле аның чын тамашасы!

Дүрт-биш шәһәр сукбае дугасыман кысык күзле, тыгыз нык гәүдәле унөч-ундүрт яшьләр чамасы авыл малаен үкертеп талый башладылар. Малай учларын чытырдатып йомып халык арасына чумарга чамалаган иде, арттан эләктергән ыштан төбе умырылып чыкты, тишекне капларга үрелгән кулны да сукбайларның берсе каерып тотты. Малай кулындагы таңкәләр җиргә чәчелде. Әмма малай житез икән, таңкәгә үрелгән сукбайлардан берсенең яңагына китереп кундырды, кырма башы белән икенчесенең корсагына бәрде...

Шушы ыгы-зыгыны күзәтеп торган җирән мыеклы офицер авыл малаен иңсәсеннән тотып алды һәм аның ай-ваена да карамастан өстерәп алып китә башлады.

Кәпәренеп, масаеп халыкның ызгыш-талашын елмаеп күзәтеп торган патша гаиләсенә ачуы кайнаган Мөхәммәт бу гаделсезлеккә юл куя алмады, көчле куллары белән халыкны икегә ярып малайга таба омтылды. Ул вакыйгага үзәгенә килеп җиткәндә малай белән офицер арасына Мөкә байның күн заводында сезонлы эшләүче Ялан авылы крестьяны Эссәт Фәтхуллин кереп баскан иде.

— Господин офицер,— диде Эссәт кыю гына.— Малайда гаеп юк, талаучылар әнә тегеләр...

Әллә балкондагыларны күрсәтте Эссәт, әллә теге кала сукбайларын, аның кыюлыгы офицерга бер дә ошамады, ул үзеннән ерак түгел генә басып торган ике солдатка:

— Җәнҗалчыларны кулга алырга!— дип акырды һәм Эссәт белән малайга күрсәтте. Малай кара йодрыклары белән битен уа-уа җылый иде.

Мөхәммәт поручикның җилкәсеннән эләктереп алганын сизми дә калды:

— Господин офицер, җилкәгездә кан!— диде ул.

— Нинди кан? Кайда?— дип офицер җилкәсен җыерып маташкан арада Мөхәммәт малайның кулыннан эләктерде дә халык арасына кереп югалды. Мәйданда күтәрелгән шау-шу аларны коткарып калды. Җыелган халык:

— Патша үзе, халык җыеп, этәч сугыштырып ята!

— Көпә-көндез кеше талыйлар, ә ул көлә!..

— Чү-чү, олуг падишаһыбызга тел тидермә!

— Минем өйдә хатын патша!..

— Ха-ха-ха...— дип тоташтан гөрли, кычкыра иде.

Офицер Мөхәммәт артыннан ташланам дигәндә генә мәйдан уртасында аяк астына артсыз урындык куеп бер кеше калыкты. Иске солдат киеменнән, сул җиңен яргаланган иске каешына тыгып куйган. Аның:

— Иптәшләр!— дигән беренче сүзе мәйданны яңгыратып үтте.

Аяз көнне дә зонтик күтәргән әфәнделәр, кара киемле курсантлар, авыр эштән суырылып кергән яңакларын сакал баскан эшчеләр, аркалары-

на биштәр-капчык аскан сала агайлары, патшадан аерылып, йөзләре белән сыңар куллы солдатка борылдылар. Бая патша турында үткен генә сүз кыстырган какча кеше бу юлы да Мөхәммәт янына килеп баскан булып чыкты, ул сул күзен кысып:

— Большевик! Белкин фамилиясе. Әлерәк кенә сугыштан кайтты! — дип пышылдады.

Халыкның игътибарын тулаем җыеп, мәйдан өстен тагын Белкинның ачы тавышы кисеп үтте:

— Күрегез, иптәшләр! Ишетегез! Герман фронтында кан кою дәвам итә! Эшчеләр байларга һаман бил бөгә! Ә сөрелгән патша губернатор пулатында кәеф-сафа корып ята! Житмәсә, ярлы халыкны мыскыл итә, җәберли! Чүплекләрдә казынырга мәҗбүр булган ятимнәрне сугыштыра! Без, большевиклар, канечкеч Николай патшаны үзе салдырган Тобол төрмәсенә күчерүне таләп итәбез! Сугыш туктатылсын! Эшчеләргә сигез сәгатьлек эш көне, крестьяннарга җир бирелсен!

Мәйданда халык дулкыны чайкалды, тыкрыктан озын штыклы мылтыкларын ике куллап тотып патша сакчылары йөгерешеп чыкты. «Таралыгыз, тарал!» — дигән сүзләр, команда тавышлары яңгырады. Баягы җирән поручик Канталыев, берничә солдатны ияртеп, кешеләрнең җилкәләренә мылтык түтәсе белән төртә-төртә Белкин баскан урынга таба китте. Моны абайлап өлгергән Эссәт әкә белән Уразаев кулга-кул тотынып күзен кан баскан офицерның юлын бүлделәр. Поручик акаеп кычкырды:

— Кит юлдан!

Озын солдатның штыгы Мөхәммәтнең яңагын сыдырып алды, икенче солдат аның кулына килеп ябышты.

— Җибәр! — диде ярсып Мөхәммәт. — Юкса, бездә дә кул бар!

— Иптәшләр! Егетләр! — дип шул тирәгә сарышкан эшчеләргә Эссәт әкә мөрәҗәгать итте. — Кайда ул Керенский әфәнде игълан иткән хөррият? Болар законны боза! Ник карап торасыз?! Ягез әле, күрсәтик күрмәгәннәрен!

Баядан бирле ачудан буылып торган эшчеләр төркеме дәррәү кузгалды, һавада сызгырып ташлар очты. Эшчеләр Белкинны уртага алып аны күздән югалттылар. Офицерның күзе гел Мөхәммәттә булган икән, ул аны эләктереп беләгеннән кысып алды. Ул арада Канталыев чинап Мөхәммәттән кулын ычкындырды һәм корт чаккандай ботына ябышты: баягы сала малае аның йомшак урынын тешләп алган икән... Форсаттан файдаланып Уразаев та читкә ыргылды, борылып караганда челтәрле балкон буш, ачык ишеккә эленгән ак пәрдәләр генә җилбер-җилбер килә иде. Капкадан чыгып килүче өстәмә көчне — солдатларны күреп җыелган халык урамнарга чаба-тарала башлады. Озак та үтмәде, губернатор йорты тирәсе бушап калды.

## 2

Яраланган, тырналган тәне-бите ут булып янып торса да Мөхәммәт өенә кайтырга ашыкмады, елга буена төшеп бит-күзен юды, таллар арасына кереп ятып ял итте. Өйгә караңгы төшкәч кенә кайтып керде. Күз тирәсе касмакланып канга каткан, битләре тырналып беткән ирен күреп Миңлекалыш сукранырга кереште.

— Тагын кан ялашып сугышып йөрдеңме? Чак күзеңне чыгармаганнар... Кем үзеңне болай бизәде?

— Сорама, хатын. — Мөхәммәт таллыкта ятып бераз тынычланган иде. — Булды бераз... Мин дә бурычлы булып калмадым.

Тоткасыннан бауга асылган җиз комганны чалшайтып су агыза-агыза ишек катында Мөхәммәт битен озаклап юды. Тасраеп аны көтеп

торган хатыны ягына борылып карыйсы килмәде аның. Тукмалган тәне һаман сызласа да, күңеле көр дип әйтерлек иде. Яхшы кешеләрне күрде, акыллы сүзләр ишетте. Күз алдыннан сыңар кул Белкинның шәүләсе китмәде, колагында аның тавышы яңгырады: «Без, большевиклар... тынычлык... ирек, җир даулыйбыз!»

Ул арада Миңлекалыш чәй өлгертте, булган нигъмәтләрен өстәлгә тезгәч, ире каршысына килеп утырды. Бик нык үпкәләгән тавыш белән:

— Кибеттә ишеттем, Мөкә байның кияве бәлшәвиклар ягында икән, урысларны яклап кеше кыйнап йөри башлаган дип сөйлиләр,— диде дә җыларга ук тотынды.

— Кибеттәге хатыннарның сүзе бетмәс,— диде Мөхәммәт ипи телемен авызыннан аермыйча.

— Ни җитми сиңа?— диде җылап туйгач Миңлекалыш.— Өстеңбашың бөтен, тамагың тук, улың үсеп килә. Әтинең бездән бүтән варислары юк. Йөз рәхәтләнеп майда!

Миңлекалыш түшенә таккан пар карбызын дерелдәтеп иренә таба иелә төште.

— Мин синең өчен куркам.

— Нәрсәдән куркасың?

— Падишага тел тидерүче имансыз урыслар арасында ирең чуала, диләр...

— Николашкага тел тидерергә дә ярамагач, нигә дип аны Себергә сөргәннәр? Ни өчен тәхетеннән күтәреп бәргәннәр?

Миңлекалыш куркуыннан агарып китте, ирен сүз белән генә җиңә алмаслыгына төшенде. Гомумән, Мөкә байның иркә кызы сүз белән эш итәргә күнекмәгән зат иде, ирен ул кешедән ишеткән хәбәрләргә таянып кына орышып маташты. Ул «урыс арасында имансызларга ияләшкән иренең маржалар янына китүеннән» генә курка иде. Мөхәммәт җилгә чыгып кергән арада аның башына гүзәл бер фикер килде. Ул савытсабаны да җыештырып тормады, каз мамыгыннан тутырылган ике дәү мендәрен күпертеп салды, әчке киемнәрен алыштырып өлгерде. Ире йокы бүлмәсенең бусагасыннан атлаганда ул түше ачык күлмәген тагын да ныграк ачып, караватта тыгыз балтырларын салындырып, чәч толымнарын сүтеп иңбашына таратып утыра иде.

Миңлекалыш иреннән биш яшькә олы булса да, әле үзенең нәфислеген җуймаган чибәр генә хатын. Хатынны кайнар куенына алгач, Мөхәммәтнең сызлаган, имгәнгән тәне эреп китте. Миңлекалыш бүген аеруча нәзакәтлелек күрсәтеп, мут хатыннарга хас булган бөтен осталыгын җигеп ирен назларга, иркәләргә кереште, тыны белән колак эченә өрә-өрә: «Тыңла әткәй әйткәнне, кер, заводларны кулыңа ал!»— дип пышылдады. Читкә тартылырга теләде Мөхәммәт, булдыра алмады, тыны буылды, ул, исәңгерәп, хатынның оста хәрәкәтләренә изрәп онытылды...

Иртән ашап-эчкәндә ул тагын үзенең элекке хәленә кайткан иде инде. Кырыс чыраен губернатор йорты мәйданында алган яралары тагын да кырысрак итеп күрсәтәләр, кашлар җимерелеп төшкән, иреннәр кысылган. Ул ашык-пошык кына ашады да тагын билгесез тарафка чыгып китте. Миңлекалыш тәмам аптырашка төште:

— Бозганнар! — диде дә үрсәләнеп җыларга кереште.— Бозганнар!

Назлы хатын ирен буталышлардан читләштерү өчен ниләр генә бирмәс иде! Аның уенча, Мөхәммәтнең юлында явыз кешеләр очрап аны сихерләгәннәр! Югыйсә башка якка каерылырлыкмы соң? Мөкә бай озакламас дөнья куяр, илдә барган чуалышлар үтәр-китәр, байның кибет тулы маллары аларга калыр, нигә рәхәтләнеп яшәмәскә?..

Миңлекалыш күршедәге диндар карчыкны чакырып кертте, коръән дә укытты, хәтем дә чыгартты. Ниләр генә кыланмады, ирен орышып та бакты, җылап та карады, сөю хисләрендә исерсен дип, бар булган назын эшкә җикте, тик алар бер-берсеннән һаман ерагая гына бардылар. Ул көткән тыныч көннәр килмәде. Моның тирән сәбәбе дә бар иде шул...

Мөхәммәт Уразаев ундүрт яшькә чыкканда авылга олы афәт ябырылды. Тиф кизүе ярты авылны кырып салды, аңа кушылып кара ачлык килеп житте. Мөхәммәтнең әти-әнисе бер көндә тифтан вафат булдылар. Башка туганнар юк, малай дөм ятим калды. Хужалыкта ат та, сыер да юк иде. Муенга киндер капчык асып, йорттан йортка хәер сорашырга гына калды.

Шулай бер көнне хәер сорап ишек төпләренә кереп баскан ябык малайга Ырсытдин бай игътибар итте. Ул аны баштанаяк сөзеп карап чыкты. «Ашатсаң-эчертсәң, бу ташбаш йомышка-юлга йөрергә яраклык икән лә!..»— дип уйлады да хатынына мөрәҗәгать итте:

— Әллә үзебездә калдырабызмы моны?— дип малайны күрсәтте. Иренә карышып өйрәнмәгән хатын:

— Үзең кара, әтисе,— дип куйды. Йомабикә байбичәгә малай ошады дип әйтеп булмый, мәгәр һәрдаим ирен тыңлаган булып, ул аны үз янына торган саен ныграк тарта иде.

Шул көннән башлап Мөхәммәт Ырсытдин байда яшәп калды.

Иң әүвәл чалгы пәке белән аның шырый-бырый төрле якка таралган чәчен кырып ташладылар, аннан эссе мунчада «әләлә-лә!»сен кычкыртып аркылы-торкылы ныгытып чаптылар, иске-москы киемнәреңн мичтә янды рып өр-яңа киемнәр киерттеләр.

Мөхәммәт, тамагы тук булгач, сөенде, хуҗаның күзенә генә карап торды, кушкан эшләрне яшен тизлеге белән башкарып чыкты. Атларга печән салды, солы бирде, хайваннарның астын чистартты, су ташыды, утын ярды, мунча якты. Тамакка таза иде, хуҗалар да ашауны кысмады, малай елдан-ел егәрләнде, үсте, ныгыды, егет булып җитте.

Иртеш катып, чана юлы төшкәч, Ырсытдин бай дүрт-биш йөк балык төяп Эшле базарына китә торган иде. Аннан арзан хакка бодай, ат-сыер тиреләре төяп кайта да Тобол купецларына илтеп сата. Шул йомышлары артыннан йөргәндә ул Тобол бае Мөкә сәүдәгәр белән танышты.

«Бай өйдә юкта ихатага күз-колак булырсың»,— дип, Мөхәммәтне тавык кетәге өстендәге бәләкәй генә өйдә яшәтәләр иде. Өй димәсәң хәтере калыр, дуга-ыңгырчак, камыт бөятләре, елымнар, җәтмәләр арасында аның тар гына агач караваты бар иде...

Быел да бай аңа йорт-җирне калдырып, «кара аны, уяу бул!» дип кисәтеп сәүдә эшләре белән китеп барды. Ихата арасындагы эшләрен иртәрәк бетереп, кичке чәйне эчкәннән соң, ул бай юклыгыннан кинәнеп, иркенләп караватына сузылып ятып күзен йомарга да өлгермәде, биклән мәгән ишек сак кына ачылды, ишекнең тоныk яктысында Йомабикә байбичә күренде. Ул бармагын иреннәренә куеп: «Тс-с! Бәбине уятырсың»,— дип пышылдады да якынрак килеп:

— Ялгызым куркам, әйдә, наныем минем янга!— дип чакырды.

Йомабикә байбичә ике ел дәвамында аны куеныннан чыгармады. Шул дәвердә егет тәнгә тулды, киң җилкәле, таза беләкле, типсә тимер өзәрдәй егеткә әверелде. Иген сукканда бодай тутырылган ике капчыкны ике култыгына йон төргәнгән күтәргәндәй кыстырып китүен Йомабикә байбичә махсус килеп, эчтән генә сокланып күзәтеп рәхәтләнә иде... Ырсытдин бай бер базардан икенчесенә еш чапканга, Мөхәммәтнең үз басуында урак урганын сизенми калды. Өченче елны йомгак һич уйламаганда сүтелеп китте. Шул язда якшәмбе базарына дип чыгып киткән Ырсытдин акчасын онытып калдырып, җәһәт кенә кире борылып кайтып керде һәм мыштым гына үз бүлмәсенә узды. Газиз хатыны Йомабикә ятагында ялчысы Мөхәммәтнең шәрә тәнен күргәч, ул чак кына акылдан язмады... Моңарчы да ялчысының кай чакларда артык кызарып китүен чамалап йөрер шикләнә башлаган бай, мәче тизлеге белән ташланып ялчысын ятактан умырып ыргытырга уйласа да, үзенең яшен чамалап тыелып кала алды, ачы итеп бер сүгенде дә тынды...

Аны-моны оныта торган жан түгел иде Ырсытдин. «Ни уйлап чыгарыр, нинди җәза!» — дип уйлап баш ватты Мөхәммәт. Әмма Ырсытдин аңа-моңа ашыкмады, базарга барып тормады, атларын тугарып ташлады да, көне буе диярлек ишегалдында йөрде. Кичке караңгылыкта Мөхәммәтнең кетәк өсте йортка кереп китүен сагалап торды да җайлап кына хатынын каптыртып алды. Кычкыртып ыштанын салдырды да камчы белән ярды... Эш моның белән генә бетмәде әле, мәкерле Ырсытдин былтырдан калган печән чүмәләләрен барлап кайтуны сылтау итеп, иптәшлеккә хатынын алып урман ягасына китте. Шомлы карурманга кереп, кеше күзеннән югалгач, атын сап-сары нарат кәүсәсенә китереп бәйләде. Аланчыкның бер читендәге чүмәләдәй кырмыска оясы күргәч, болай да коты алынган байбичә дер-дер калтырарга тотынды. Ырсытдин хатынын йолкып арбадан тартып төшерде дә кырмыска оясының өстенә атландырды. Нәзек билле, үткер тешле, эре җирән кырмыскалар дулап-чабышып хатын өстенә үрмәләделәр. Йомабикә байбичә үрле-кырлы сикерде, әмма ире куәтле куллары белән аның чәченнән урап тоткан иде, селкенергә дә ирек бирмәде...

Хатын башта ай-вайлады, үкерде, талкынды, хәле китеп башы бер якка кыегаеп төшкәч кенә, Ырсытдин хәләлен арба төбенә илтеп салды һәм юлда кайтканда бер генә сүз әйтте:

— Бераүгә авызыңны ачып сөйләсәң — үтерәм! Моннан болай азынсаң — әҗәл!..

Хәзер ялчысы Мөхәммәттән үч алырга кирәк иде. Озак уйлады мәкерле Ырсытдин, озак баш ватты, төннәрен йокысыз уздырды. Уйлый торгач бер фикергә килде. Мөхәммәтне чакырып алды.

— Мин сиңа бер яхшылык итмәкче булам,— диде ул күзләрен читкә тәгәрәтеп.— Миңа кылган яхшылыкларыңа әҗер булыр. Мин сине шәһәрдә сәүдә мәктәбенә урнаштырам дип килешенеп кайттым.

Егет аптырап калды. «Ничек алай? Сәүдә мәктәбенә?!»

— Русчам да такы-токы,— диде Мөхәммәт тотлыгып.— Укый алмам мин анда, бай абзый.

— Дустым Мөкә байда торырсың. Кирәк икән ул сиңа русча өйрәтергә кеше дә яллар...

— Уку өчен түләргә акчам да юк...

Бай әйткәннәр тәҗрибәсез егет Мөхәммәтнең башына сыймый иде. «Житмәсә хатыны белән өсләренә килеп чыкканнан соң?..»

— Акча сораучы юк синнән. Миндә дүрт ел хезмәт иттең. Укуыңа киткән чыгымнарның барын да үз өстемә алам. Җәй көннәрендә, бездә эш кызуында, кайтып аз-маз булышырсың. Укып бетереп, эшең җайга китсә, безнең яхшылыкны да онытмассың...

Бу урында Ырсытдин коп-коры күз төпләрен нык йомарланган йодрыклары белән сөртеп тә алды...

Байның йомшак җәеп катыга утыртканын Мөхәммәт соңрак, соңга калыбрак аңлады. Ике куянны атты Ырсытдин: шау-шусыз гына хатынын да үзенә калдырды, ялчыны да озын җәй көннәренә үзенә беркетте. Мөхәммәт «рәхмәт йөзеннән» яздан көзгәчә аңа бил бөкте, биш кешелек эшләде.

Авыл халкы аны-моны белми дә калды, ләкин Ырсытдин бай йортындагы хәлләрне илгә чәчеп сап-сары нәни кызчык туды. Ырсытдин үзе дә, хәләл хатыны Йомабикә дә дегет кебек кара чәчле, чуендай кара битле булганга, сары чәчле Мәүлиянең ялчылары Мөхәммәткә ошавын сукыр да күрерлек иде...

Мөхәммәт һич уйламаганда кызлы кеше булып китте, үзендә әти кеше хисләре уянуын тойды. Йомабикә дә аны чынлап торып ярата башлаган иде!.. Кышларын егет Ялан ягына качып-посып та кайткалап йөрде. Ләкин сабый балага сүз китермәс өчен Йомабикә янында озак юанмады, баланы күкрәгенә алып бер сөйде дә китеп барды. Укырга хирыслыгы бар иде, зирәклеге дә җитәрлек булып чыкты, яхшы укыды Мөхәммәт. Ул укыган

дәвердә Ырсытдиннең сәүдә эшләре тагын да киңрәк җәелеп китте, ул еш кына Тоболдагы дусты Мөкә байга килеп чыга, уртак эшләре дә булгалый, ераграк шәһәрләргә алар бергәләп сәфәр дә чыгып китәләр иде...

Мөхәммәт инде Мөкә байларда яшәп ятканда, байның Миңлекалыш исемле кызы җилдән бәбәй алып кайтты. Бик яшьтән урыс офицерлары белән якыннан дуслашып йөргән бу кызга көчли-көчли Мөхәммәтне өйләндерделәр. Бер байның мәкереннән котылам дигәндә генә Мөхәммәт икенче берәүнең — Мөкә шайтанның җәтмәсенә килеп капты. «Бала синнән!— дип куркыттылар аны Мөкә белән Ырсытдин.— Әгәр өйләнеп калмасаң, башыңны төрмәдә чертәчәкбез!». Бер мәртәбә дә күтәрелеп караганы юк иде Мөхәммәтнең Миңлекалышка, хәзер шуны үзенең хатыны итте, почык борынлы Шамилнең әтисе булды...

4

Октябрь революциясеннән соң да Тобол шәһәрендә Совет власте биш ай буена ныгый алмады. Шәһәр буржуазиясе, кадетлар, монархистлар властьны үз кулларыннан ычкындырмадылар. Унсигезенче елның апрелендә патшаны чит илгә качыру нияте белән монархистларның заговор әзерләве большевикларга мәгълүм булды.

Заговорны бастыруда Белкин группасына мөһим бурыч йөкләнгән иде: патшаны саклаучы иң актив монархистларны кулга алырга, качыруны булдырмый калырга!..

Эшче дружиналар төн уртасында губернатор йортын камап алдылар һәм аскы катка бәреп керә башладылар. Отряд җитез һәм бик сак хәрәкәт иткәнгә, куелган бурыч тиз үтәлде. Ләкин коралсызландырылган офицерлар арасында поручик Канталыев юк иде.

— Барлык бүлмәләрне, подвалларны тикшердегезме?— дип сорады Белкин Уразаевтан. (Әлегрәк исәнгерәп йөргән Уразаев, Мөкә байның сасы цехларына бармыйча, большевиклар арасына килеп кереп, эшче дружинага язылган иде).

— Юк, поручик чыгып ычкынган,— диде Мөхәммәт маңгай тирен сөртеп. Бүлмәдән-бүлмәгә чаба-чаба шактый алҗыган иде ул.

Үз тирәсенә күренекле монархистларны җыя башлаган патшаны тиз үк моннан күчерергә карар кылынды. Инде боз өстенә су чыга башлаган Иртеш аша патшаны көчле конвой астында Екатеринбург каласына озаттылар. Бу 1918 елның 25 апрель төне иде. Озак та үтмәде, Тоболга Колчак гаскәрләре керде, Уразаев эшче дружиналар белән урманга качты.

Миңлекалыш бер чакта да үз акылы белән яшәмәде, бала чакта әнисе сүзен тотты, үсә төшкәч әтисенең сүзеннән чыкмады, җитеп килгән кыз чагында аны күршеләрнең «җитез аяклы, ут табанлы кызлары» үз тәрбиясенә алды. Офицерлар йортына да күрше кызлары ияртеп барды. Офицерлар майлы күзле кызны бик тиз үз тәрбияләренә алдылар. «Дөнья фани, рәхәттә гизеп калырга кирәк!» — дип колак төбендә чикерткә булып сайрадылар һәм «рәхәтлекнең» барлык төрләрен тиз арада өйрәтеп, сендереп тә өлгерделәр. Иң кызыгы шул иде, кеше тәэсиреннән бер чыгып ычкынган Миңлекалыш үзенең элеккеге тәрбиячеләренә әйләнеп тә карамый иде. Аның акылы әнә шулай кулдан-кулга йөрде, җилдән бәбәй табып, Мөхәммәт кебек таза-сәламәт, чибәр кешегә кияүгә чыгу бәхетенә ирешкәч, ул беразга тынып-сабырланып калган иде. Әмма әтисенең сүзенә каршы төшеп, урыс-улак янында чуала башлаган иреннән ул тиз туйды. Бу вакытта аның бар акылы базар маржаларыннан ияреп кайта торган иде. Эше булса да, булмаса да базарга йөрергә ярата Миңлекалыш, һичкемнән оялмыйча сагыз чәйни, сагыз чәйнәгән арада ярты шәһәрнең гайбәтен чәйнәргә дә өлгерә. Революция елларын ул вакытлыча саташу дип кенә кабул итте. Базар әһелләренең телендә бары тик шул иде: «Үтә бу афәт, бетә, менә Колчак хәзрәтләре генә килсен!»

Килде Колчак, элеккеге рәхәтлекләр кире кайтты, рестораннар ачылды, урамда кая карама көяз офицерлар мыек сыпырып йөри, барышнялар туктаусыз танцыда. Ире Мөхәммәтнең чыгып югалуына башта бераз кәефе кырылып йөрсә дә, тора-бара моңа да күнекте Миңлекалыш, вак кәрәзле кара шәлен салып ыргытты да, бит-кашларын буяп, көязләнеп, тырт-тырт басып кына йөри башлады. Күршедәге ахирәт кызлары кайсы кая таралышканнар иде, бушап калган бүлмәләренә икеме, өчме офицер кереп урнашты, әнә шул кешеләр Миңлекалышның аяк адымнарын үзгәртәләр иде инде. Арада берсе, яшьрәк кенә поручик, аны күргән саен бөгелеп-сыгылып сәлам бирергә ашыга, аның матурлыгын мактап бер-ике салам кыстырып та уза. Бер тыңлый хатын — колагына керә, ике тыңлый — сүз күңеленә күчә, өченче тыңлаганда кашлар уйнап ала, күз үзеннән-үзе нидер вәгъдә итә. Офицер тәҗрибәле, яшь булса да каймакны мул ашаган, аннары Миңлекалышның кем икәнен, губернатор мәйданында сукбай-алабай малай аның чалбар төбен тешләп ертканда, малайны яклап алып калган Мөхәммәт Уразаевның хатыны булуын да яхшы белә! Канталыев бер атканда ике куянга гына риза түгел, өчәү кирәк аңа, дүртәү... Мөкәнең байлыгын да, Миңлекалышның бердәнбер варис икәнен дә белә поручик. Мөкәнең үзеннән дә, кызыннан да күп нәрсәләр өмет итә ул! Шуларга ирешсә, Мөхәммәттән үч тә алыначак!..

Миңлекалышка нәрсә — кочак ачык, юырттырып кереп китә аласың! Үсеп, тернәкләнә башлаган улы Шамилне күрше бүлмәгә кертеп йоклатты да тәрәзәне ачты. Тәрәзә каршысында Канталыев басып тора. Тәрәзәдән соң ишек ачылды, ишектән соң юрган, аннан кочак... Шамил йокыга китмәгән икән, ялан тәпи тып-тып басып килеп керде. Канталыев шәрә үкчәсе белән сабыйны тибеп очырды. Шамил үкси-үкси чыгып китсә дә Миңлекалыш тормады, баланы юатмады...

Икенче көнне, коймаклы чәй янында Шамил елый-елый әнисенең алдына менеп утырды һәм түрдәге Канталыевка карап:

— Әтиемә әйтәм! — дип янады.

Поручик көлеп куйды, Миңлекалыш:

— Синең әтиең безне ташлап качты, бүгеннән бу абзаң синең әтиең,— диде.

Чәйдән соң Канталыевның шпораларын чыңлатып уйнап утырган малай яңа әтисенә күнегә дә башлаган иде инде.

Күрше йорттан Канталыевның әйберләрен ике солдат ташып куйдылар, ул Мөке карунның яңа кияве булып, Тобол каласы байларында ашка-суга йөри дә башлады. Яңа иреннән Миңлекалыш бик канәгать иде. Офицер! Базар әһелләре хәзер аңа бөгелә-сыгыла сәлам бирәләр...

Ил өчен шактый дәһшәтле, караңгы бу көннәрдә Мөхәммәт Уразаев ничәмә-ничә елганы кичеп, кул-авылларны читләтеп узып кара урман уртасындагы Белкин отрядын эзләп тапты. Алар Белкин белән дусларча бик җылы күрештеләр. Көрәш юлы узган бу житез кеше Мөхәммәтнең мәхәббәтен бик тиз яулап алды. Белкин да аны яратты. Тәвәккәл, кушканны һәрчак җиренә җиткереп башкара, иптәшләре белән мөгамәләсе әйбәт, иң мөһиме күпне белергә тырыша. Белем ягы да бар. Лена вакыйгаларыннан соң Иртеш буена качып килеп большевистик агитация алып барган, революцион түгәрәкләр оештырган, сугышта үтны-суны кичеп сыңар кулын калдырып кайткан Иосиф Белкинның иң зур коралы ышаныч иде. Ул дошманның — Колчагы булсын, башкасы булсын,— җиңеләчәгенә, Россиядә бар халыклар өчен яңа тормыш туасына ышана, ышанычын башкаларга да йоктыра ала иде.

Уразаевны Шалашов командалыгындагы рус взводына беркеттеләр. Арада яше белән аерылып торган Шалашов себер кешеләречә таза, сәламәт һәм бик көчле иде. Шалашов белән дә килешенеп китте Мөхәммәт, аның яхшы сүзгә, тәмле телгә мохтаҗ икәнлеген отрядта тиз сизенделәр.

Блюхер дивизиясе составына кергән Белкин житәкчелегендәге отряд атна-ун көнлек әзерлектән соң һөҗүмгә күчәргә боерык алды. Алар

бер-бер артлы авылларны аклардан азат итә башладылар. Ай буе дәвам иткән каты сугышларда Мөхәммәт чыныгу юлларын үтте.

Октябрь кичләренең берсе. Озын марш үтеп Мөхәммәтләр полкы Иртеш елгасына килеп терәлде. Чигенүче дошман елга аръягында ныгып өлгергән инде. Отряд юлын шушы төн төсле кара елга кисмәсә, полк дошманны тар-мар итеп Тоболга бару юлында мөһим стратегик пункт булган Такыржан авылын алган булыр иде. Төш алдыннан күтәрелгән җил тагын да көчәйде. Иртеш кара дулкыннарын чайкап ургылып-ургылып ага. Паромнарны, барлык көймәләрне дошман үзе белән теге якка алып чыгып киткән иде. Уңга-сулга ашыгыч чапкан чапкыннар буш кул белән әйләнеп кайттылар. Елга камышлары арасыннан иске тагаракка охшаган ишкәксез көймәдән башка берни дә табылмады. Белкин тирәсенә командирлар җыелды. Уңай башланып киткән һөҗүмне туктатырга ярамый, дошман искәрмәгәндә елганы кичеп калырга кирәк иде.

— Ничек? — диде командирлардан берәү.— Шушы тәмугка керергәме?

— Шушы төн безгә ярдәмче булыр,— диде ышаныч белән Белкин. Уразаев белән Шалашовка теге як ярга чыгып паромны бу ярга күчерергә боерылды.

— Зур эш йөкләнә сезгә, иптәшләр, икеләнсәгез, әйтегез,— диде аларның аркасыннан кагып Белкин. Шалашов белән Уразаев бер-берсенә карашып кына алдылар...

— Без әзер...

— Уңыш телим. Сак булыгыз.

— Хушыгыз, иптәшләр...

Җил аларның кыска-кыска сүзләрен умырып-умырып алып китте.

Аларны балыкчыларга охшатып киендерделәр. Ишкәк урынына аннан-моннан ашыгыч юнылган такта кисәкләре тоттырдылар:

— Хәерле юлга...

Иртеш бөтерелеп-уралып ага, икесенең кулындагы такта кисәкләре туктаусыз хәрәкәттә торса да, көймә аларга буйсынмый, чайкала, менә авам, менә авам дип калтырана, әле борыны, әле койрыгы өскә чөелә. Агым аларны шактый түбәнгә алып китте, көймәне яр буендагы казыкка бәйләп, акрын гына өскә менә башладылар. Күзгә төртсәң күренмәслек караңгы, сәләмә киемнәр аша үтеп йөргән су җиле сөякләргә кадәр калтырата. Ургылып искән җил кеше авазларын китереп җиткерде, паром тирәсендә кемнәрдер мыдыр-мыдыр сөйләшәләр иде. «Дозор!» — дип пышылдады Шалашов, терсәге белән Мөхәммәткә төртеп. Йөрәкләр дөп-дөп тибә, авыз эче кипте, телләр аңкауга ябышты... Ни гаҗәп, Мөхәммәтнең аркасы тирләгән иде. Тавышлар ишетелми башлагач, алар тагын алга үрмәли башладылар, шуышып паромга барып җиттеләр. Паромны юан аркан белән баганага бәйләп куйганнар иде. Кармаланып барып таптылар, колакларын җилгә куеп тыңланып тордылар.

— Арканны кис! — диде Шалашов.— Очта йозаклы чылбыр.

— Син сакла!

Мөхәммәт кесәсеннән пычак чыгарып юан арканга ышкый гына башлаган иде, ике шәүлә, тавышсыз-тынсыз гына аларга якынлашты. Пычак Мөхәммәтнең такта ишкәк тотып кәкрәеп каткан бармакларына буйсынмады, аркан тиз генә бирешмәде, ул арада шәүләләр паромга килеп тә җиттеләр. Уразаев беренче булып килүчене чалып екты һәм дәү йодрыгы белән тегенең башына тондырды. Ул арада җил паромны тартып җибәрде, киселеп бетмәгән бау өзелеп чыкты. Икенче шәүлә:

— Фельдфебель, ни булды? Егылдыңмы? Суга бата күрмә! — дип кычкырды. Шалашов икенче шәүләгә ташланса да ул тайчанып өлгерде, акырып җибәрде, аткан тавыш яңгырады. Уразаев шәүләне арттан килеп кочаклап алган арада Шалашов паромны аягы белән тибеп агымгарак чыгарырга тырышты, паром беравык тирбәлеп торды да чалкан яткан дошман белән бергә Иртеш уртасына ага башлады. Көчле җил аны аръякка

куды. Бу ярда ыгы-зыгы барган арада паром караңгылык эчендә күздән дә югалды...

Аткан тавышка каравыл йортыннан бүселеп чыккан солдатлар разведчикларны камап алдылар. Алай да кулындагы пычагы белән Мөхәммәт бер-икесен яралап өлгерде...

Аткан тавышларны, Колчак солдатларының яраланып үкерүен, әлбәттә, теге як ярдагылар ишетми калмаганнардыр, дип юанды Шалашов.

Башта аларны бик каты ярдылар. Аннары штабка алып киттеләр. Штабта бүген дежурный офицер Канталыев иде. Шалашовны алып кергән солдат күкрәген бүлтәйтә төшеп:

— Ваше благородие! Ике лазутчик тоттык. Каты каршылык күрсәттеләр...— дип озаклап сөйләргә җыенган иде, Канталыев аны бүлдерде.

— Күрәм... Кыска сөйлә! — дип боерды.

— Фельдфебель... фельдфебель әфәнде...— дип сөйли башлаган солдатны ярты сүздә бүлеп, елмаеп, Шалашовка карады.

— Йә, голубчик,— диде ул,— ни йомыш белән бу якка чыктыгыз?

— Ваше благородие! — диде тынын җайлап алган Шалашов.— Балыкчылар без. Төн караңгы. Адаштык. Каршылык күрсәтмичә мөмкин түгел иде. Солдатларыгыз тоттылар да тиктомалдан тукмый башладылар.

— Әһә, балыкчылар?! Бармак белән балык тотучылар! — дип тагын елмайды Канталыев.

— Җәтмәләребез бар иде, көймәбез ауды да алары батып китте.

— Көймә аугач сез коры калдыгыз алайса?!

Канталыев Шалашовның беләгеннән эләктереп, чеметеп алды.

— Тентергә!

Тышкы киемнәрен алыштырсалар да, эчке күлмәк-ыштан үзләренеке калган иде, тентергә өйрәнгән бармаклар Шалашовның партбилетын «ә» дигәнче табып алдылар.

Канталыев билетны әйләндереп-әйләндереп карады да бөтәрләп Шалашовның борынына төртте:

— Җәтмәң шушымы, кызыл чучка?!

Аннары сүзсез генә разведчикның битен, башын төя башлады. Бераздан солдатларга:

— Ни карап торасыз? — дип кычкырды. Солдатлар алмаш-тилмәш Федорны яра башладылар. Бераздан ул аңын җуеп идәнгә егылды, аны сөйрәп чыгарып ташладылар. Шалашов бер сүз дә эндәшмәде. Чират Мөхәммәт Уразаевка житте, аны алып керделәр. Канлы кулларын чиста ак кулъяулыгына сөртеп маташкан офицер аны күргәч сөенеченнән көлеп үк җибәрде.

— Йа хода! Кемне күрәм мин! Иске танышым Мөхәммәт Уразаев! — Аннары ул конвойга җикеренде.— Ни карап торасыз? Чишегез кулларын. Бәйләгез яраларын!

Канталыевның кызыллар белән «мәзәк корырга» ятарканын белеп өлгергән солдатлар, тамаша көтеп, Мөхәммәт тирәсендә юри бөтергәләнеп йөри башладылар, яраларына май сөртеп, аркасыннан кактылар. Мөхәммәт шешенгән кулларын угалап Канталыевка карады: «Тагын нинди этлек уйлап чыгара бу?!»

— Ни хәлләрдә? — дип мөлаем елмайды офицер.

— Үзең күрәсең,— диде Мөхәммәт канын төкереп.

— Күрәм. Нык эләктергәннәр сиңа. Элеккеге вак-төякләрне хәтерләп үч алыр дип уйлый күрмә, юк! Мин андый вакчыл түгел. Син Мөкә бай кияве! Өеңдә сине йомшак тәнле хатының һәм улың көтә. Шулар хакына сине котылдырам мин. Тик бер шартым бар.

— Әйтеп кара,— диде Мөхәммәт.

— Менә бу, иптәшеңне әйтәм, кызыл чучканы үз кулың белән атып үтерәсең! — Канталыев өстәлдә бөгәрләнеп яткан партбилетка төртеп күрсәтте.— Аннары дүрт ягың кыйбла!

— Аның бер гаебе дә юк. Лутчы мине атыгыз! — диде Мөхәммәт, калтыранган тавыш белән.

— Безне өйрәтүче кирәкми, кемдә нинди гаеп барын беләбез! Яхшы, атмыйсың икән, үзебез дә ата алабыз. Тик син атты дигән даны таралыр.

— Мине дә атыгыз! — диде көчен җыеп Мөхәммәт.

Канталыев кашын җимереп чак кына уйлап торды, киң итеп елмайды да:

— Шалашовны атыгыз! Уразаев карап торсын! Мин аңа гомер бүләк итәм,— диде.

Мөхәммәт алгарак чыгып басты:

— Безне бергә атыгыз!

— Уразаевка тырнак белән дә чиртәсе булмагыз!

Мөхәммәт өстәлдәге пистолетка ташланды, әмма Канталыев сак иде,иңе белән аны этеп җибәрде дә, тагын да ягымлырак итеп елмаеп:

— Ашыкма, Уразаев. Минем дә яшисем килә. Сине дә яшәтәсем килә,— диде.

Шалашовны яр буенда аттылар. Аны атканда Уразаев ни үле, ни тере түгел иде. Аннан ул кинәт янындагы конвойны бәреп егып канга тузып яткан иптәшенә ташланды. Баш киемен салып ирләрчә тавышсыз гына үкседе...

— Ефрейтор Пермитин! — дип кычкырды поручик.— Уразаевны озатыгыз...

— Ничек? — диде әлегәчә Канталыевның яхшылыгына ышанмыйча торган Пермитин.— Ул фельдфебельне харап иткән!..

— Фельдфебельне харап иткән Шалашов атылды! Ә бу минем якын танышым, исән калсын. Озатыгыз аны!..

Шалашовсыз исән-сау кайткан Уразаевны нык шикә алып шунда ук карцерга ябып куйдылар. Соңы ни белән бетәр иде, бәхетенә каршы, аклар штабында кызылларның разведчигы эшләгән икән, ярдәм итә алмаса да ул Уразаевның сүзләрен ишетеп торган, аның хәбәре килеп ирешкән сәгатьтә үк Мөхәммәтне карцердан азат иттеләр. Тобол шәһәренә һөҗүм юлында да, шәһәрне азат иткәндә дә ул гел Белкин янында булырга тырышты. Егетнең аяусызлыгын, кырыс сүзлелеген, батырлыгын күреп аның йөрәгендә нинди ут-уч ялкыны ятканын Белкин тулысы белән аңлый иде. Шуңа күрә ул иң хәтәр, иң хәвефле урыннарга гел Уразаевны җибәрә торган булды. Һәм үкенмәде. Егет корычтай ныгыган иде инде...

## 5

Тобол шәһәре дүрт йөз җитмеш сигез көн Колчак кулында торды. Ул көннәрнең ачы хатирәсе булып урамнарда дар агачлары, җимерек йортлар, янган ихаталар, чүплекләрдә казынучы саргайган чырайлы бала-чагалар — ятимнәр калды.

Уразаев елдан артык шушы вакыт эчендә өеннән бернинди хәбәр дә алмады диярлек, ямьсез имеш-мимешләргә ул ышанмады. «дошманнар юри тарата!» дип уйлады. Инде командирдан рөхсәт алып, сакалмыегын ашык-пошык кырып, кич кырын үз йортына ашыкты. Мөкә бай йортына колчаклылар тимәгәндер дә, мәгәр гаиләсе ни хәлдә икән?..

Өйләренә якынлашканда алар йортына вак-төяк эшләрне башкарырга кергәләп йөргән таныш карчык очрады. Мөхәммәт моны яхшыга юрады һәм кычкырып ук сәлам бирде:

— Исән-сау гынамы, Майҗамал апа. Безнекеләр ни хәлдә?

Карчык авыз читен бөрештереп бер читкә тайпылды.

— Танымыйсыңмы әллә, Майҗамал апа?

Карчыкның авызы ачылмады.

— Шамил белән бер-бер хәл булдымы әллә?!

Ниһаять, Майҗамал телгә килде.

— Юк, улым, алай берни дә булмады. Шамилең дә исән-сау... Берни дә юк икән, нигә качты соң Майҗамал апа?! Мөхәммәт шик-шөбһәләргә уралып Мөкә бай йортының капкасын ачты. Капканы керүгә агач атка атланган Шамилен күреп алды. Малай карап-карап торды да әтисен таныды, кочагына атылды. Мөхәммәт улын (чит кешенеке булса да үзенеке кебек итеп сөйде!) үбеп алды, ике куллап югарыга чөйде.

— Офицер абый миңа тибеп җибәрде! — диде Шамил.

Мөхәммәт улын күтәреп текә баскычтан өскә менде, аягы белән тибеп ишекне ачты һәм катып калды: аркасын мичкә терәп хатыны Миңлекалыш басып тора, аның корсагы иягенә менеп җиткән, бите генә түгел, ике ияклэнә башлаган муены да тимгел-тимгел тутлаган иде...

Бер атлады хатынына таба Мөхәммәт, ике, хатынының эчкә суырылган бите буйлап тәгәрәгән яшь бөртекләрен күреп тукталды. Тукталды да тыелды. Улын идәнгә бастырды. Шамил ни әйтергә белмичә бер әтисенә, бер әнисенә карап тора иде... Түзмәде Мөхәммәт:

— Мин сине пычрак арасыннан аралап алдым. Ә син шул шакшыны минем битемә сыладың! Үтерәм!

Шамил кычкырып елап җибәрде. Миңлекалыш чүгеп төште, мүкәләп килеп иренең аякларын кочты.

— Булдыра алсаң, алла хакы өчен кичер мине,— дип елап ялварды...

Бүген көне буе Миңлекалыш капкасыннан күзен алмыйча «инде ни булыр икән?» дип кызыксынып күзәтеп торган Майҗамал әби, кычкырын Шамилен күтәргән Мөхәммәтнең эре-эре атлап өеннән чыгып китүен күргәч, канәгатьлек белән: «Эт саркытын арыслан ашамас»,— дип пышылдады.

## 6

Егерме беренче елның январь салкыннары тәрәзә пыялаларына катлы-катлы абага яфракларын ясап киткән. Губком членнары бүгенге эшләрен күптән тәмамлап өйләренә таралсалар да, Уразаев кайтырга ашыкмый, эш бүлмәсенең тәрәзә төбенә терсәкләре белән таянган да уйга чумган.

Миңлекалыш исенә төшкән саен аның уйлары икегә бүленеп китә: кызганыч та, чирканыч та. Бәбәй тапканда хатыны дөньядан китеп котылды. Ә Шамил әнисен гел-гел исенә төшерә, юк дигәндә дә аны телгә алып куя:

— Әнием кайчан кайта инде? — дип Мөхәммәтнең йөрәген өзгәли.

Телефон шалтырап аны сискәндереп куйды. Ул трубканы алды. Аның монда икәнен каян белгәннәр?

— Уразаев, минем янга кереп чыгыгыз әле,— диде Белкин.

— Хәзер, Иосиф Яковлевич.

Ул кергәндә, Белкин янында губернаның берничә җаваплы хезмәткәре бар иде, кул бирешеп күрештеләр. Башка чакта сөйләшергә яраткан Иосиф Яковлевич бүген сүзсез һәм борчулы уйчан иде. Бераз уйланып торганнан соң гына ул саңгырау тавыш белән сөйли башлады.

— Иптәшләр, губернаның көньяк районнарында кулаклар фетнәсе күтәрелү турында хәбәр алынды. Анда көчләр тигез түгел, безнекеләр аз, аларга ашыгыч ярдәм кирәк. Кем кулына мылтык тотарга сәләтле, иртәнге алтыга шушы урынга җыелырга.

Сүзнең беткәнен белдереп, Белкин урыныннан торды һәм чыгып баручыларга карап:

— Ә сез, иптәш Уразаев, калып торыгыз,— диде.

Ике-өч сүз белән ул Мөхәммәтнең хәлен сорашты һәм алар икесе

тиз генә бер карарга килделәр: Шамилне туган авылы Яланга илтеп куйгач, Мөхәммәт үз җае белән отрядны куып җитәргә тиеш!

* * *

Беренче этәчтән үк уянган Һади бабай салкын өйгә торасы килмичә озак уйланып ятты... Әле Колчак басып кергән елларда «җир бүләргә!» дип күтәрелеп чыккан улы Нәбиулланы тураклап ташлаулары күз алдына килде... Янында бөгәрләнеп яткан оныгының өстенә ертык чикмәнен тартыбрак куйды.

Таң аткач, түгәрәк кырпулы бүреген батырып киде, тунын биленнән тастымал белән буып, читекләре өстеннән киезката әлде. Эт тиресеннән тегелгән дәү бияләйләрен мич кырыннан эзләп алып ишегалдына чыкты. Башта ул көннең салкынлыгын чамалау өчен авызын бүлтәйтеп алды, аннан төкереп җибәрде. Төкерекнең җиргә төшкәнче үк бөтерелеп боз кисәгенә әверелүен күреп: «Кыш әле чигенергә уйламый да икән!» — дип, язның соңга калуына эче пошып мыгырданып куйды. Иртеш ягыннан искән ачы җил авыл урамы буйлап кар бөртекләрен таратып куа иде.

Көн яктырды, чыгып килгән кояш ертык болытлар өзелеп киткән арада, бер чите белән җир өстенә карарга да өлгерә, авыл артына ук килеп тезелгән кедр агачларын яктыртып ала. Кедр ботакларына калын-калын кар яткан. Алар селкенә дә алмыйлар, бу пәһлеван агачлар да себер кышы богавыннан котыла алмыйча азапланалар, ыңгырашалар кебек.

Бабай кар астында күмелеп калган чүмәләне агач сәнәк белән чукый башлады, бер-ике уч казып чыгаргач, сәнәк очына күтәргән печәнен абзарга таба алып китте. Хуҗасын сизеп эчтә Акбаш мөгрәде. Карт кинәт тукталды, күтәрелеп карады, аргы очтан авылга атлы казаклар ишелеп кереп килә иде. Бабай сәнәген читкә ыргытты, уң бияләен кашы өстенә куеп текәлеп карап катты. Качарга кирәк иде, югыйсә бәладән башаяк! Атлылар да аны абайлады, бер казак чаптырып килеп җитте, бит ялмасын бер якка каерып яман сүгенеп җибәрде:

— Кеше күргәнең юкмы әллә, чекерәйгәнсең! — дип акырды.— Теге тимер түбәле йорт кемнеке була?

— Минеке түгел инде,— диде карт рәнҗеп.— Үзең мөселман, үзең яман сүгенәсең.

— Юньләп җавап бирә белмәсәң, камчы да татырсың! — диде татар-казак.— Кем йорты?

— Кемнеке булсын... Рәхмәтулланыкы!

Казаклар кар туздырып узып киткәч, ул карга күмелгән сәнәген озак кына эзләде, «Кемнәр дисәң, фетнәчеләр булыр, башка түгел!» — дип уйлады. Рәхмәтулла йортына шулардан башка кем төшсен? Карун Рәхмәтулла диләр ич аны! Кыш уртасында бер йомарлам кар сорап ала алмассың!

Ихатадагы эшләрен барлап, тәһарәт алып намазлык өстенә генә утырган иде, ишектән чүмәлә хәтле суык иңртеп авыл пүнәтәе килеп керде. Өлкән улы Сәгъдетдин мичтә ут тергезеп йөри иде. Пүнәтәй шуңа эндәште:

— Сәгъдетдин әкә, авылга әлеге әфисәр килгән. Өй борынча йөреп ирләрне үз янына җыярга боерды. Соңлама, Канталыев акрын кыланганны яратмый!

— Канталыев? — дип кайтарып сорады Сәгъдетдин. Һади карт тетрәнеп китте: шуның боерыгын үтәп турактадылар ич инде аның төпчек улы Нәбиулланы!

Сәгъдетдин аптырашта калды, тиз-тиз киенеп йөгереп ишегалдына чыкты. Авылдашлары берән-сәрән Рәхмәтулла бай йортына таба атлыйлар, авылдан урманга уза торган тыкрыкта атлы казаклар йөреп тора-

лар... Качарга соң. Качып та кая бара аласың?! Февраль, кар иң күп яткан ай... Башын түбән иеп Сәгъдетдин дә чакырган җиргә барды. Анда ирләрнең һәммәсен көчләп фетнәчеләр армиясенә язалар иде. Халык беркадәр җыелгач, Канталыев сүз тотты.

— Без хәзерендә коммунистларсыз гына совет власте төзибез. Мөселман туганнар, алласызларны җәлләүсез кырырга кирәк. Аның өчен, тәңре хакы өчен безнең сафларга басыгыз! Бу изге алышта һәлак булганнарның урыны җәннәттә булыр!

Сәгъдетдиннең дә, бүтәннәрнең дә башы түбәнгәрәк иелде, бу дөньялыкта да, җәһәннәмдә дә Канталыев белән янәшә буласылары килми иде аларның.

— Үзегезне азатлык армиясенә кабул ителгән дип санагыз. Кемдә нинди корал бар — сәнәкме, сөңгеме, пычакмы, әлегә ярап торыр. Соңра коралны чит илдән китереп җиткерәчәкбез! Хыянәт итеп качарга теләгәннәргә хөкем бер — токмач кискәндәй турарбыз!

Ул арада ишектән ике бәләкәй малай килеп керде. Берсе хуҗаныкы иде, күренеп тора, керүгә бүреген бер якка, тунын икенче якка ыргытып: «Ипи бир!»— дип кычкырып җибәрде. Мич артыннан чыккан хатын аны җилтерәтеп кече якка алып кереп тә китте. Икенче малай, борынын тартып, җыелган кешеләргә бик аптырап карап бусага төбендә басып калды. Исемлек төзелеп бетеп, халык таралганчы шулай басып торды. Кеше сирәгәйгәч, Канталыев та малайны күреп алды, таныды, малай да аны танып өлгереп җәлт кенә чыгып сызды.

— Кем улы булды бу? — дип сорады Канталыев хуҗадан.

— Читтән кайткан бер нәмәрсә,— диде Рәхмәтулла.— Фәхриҗамал исемле тол хатында яши.

— Уразаев малае түгелме соң ул?

— Господин капитан, мин ул кадәресен белмим,— диде карун гаепле төс белән.

Ун минут үтәр-үтмәстә малайны Канталыев катына китереп җиткерделәр, малай мышык-мышык елый иде.

— Шамил ич син! — диде капитан йомшак тавыш белән.— Курыкма, мин сиңа тимим. Мәле, кәнфит, суырып җибәр.

Авызга кәнфит кергәч малайның иреннәре җәелеп китте. Капитан хуҗага карап:

— Рәхмәтулла абзый, бу егет Мөкә байның онысы. Бай үзе сәүдә юлында җан бирде. Без малайның әнисе мәрхүмә белән якыннар идек. Минемчә, аны биредә калдырырга кирәк. Сездә яшәп торсын.

— Баш өсте, господин капитан.

— Безнең кеше итеп тәрбияләрсең дип ышанам.

— Баш өсте...

— Ә хәзер, Шамил, әйт әле. Әтиең кайда?

— Белмим,— диде, кәнфитен лач-лоч авызында әүкәләп Шамил.

— Кая барам диде? Сине ул китергәндер ич? Моннан ары кая юл тотам диде?

— Белмим.

Канталыев Рәхмәтулланы бер читкәрәк чакырды:

— Бу теге сезнең Уразаев улы... Губкомда эшләгән кеше! Асыл кош! Малае артыннан авылга килми калмас... Әйбәт җим булачак бу маңка! Әгәр тота аласың икән... миннән бүләк!

— Тыңлыйм, господин капитан. Ә, әй, тукта... Ә Фәхриҗамал корткага ни диярбез?

— Тапкансың сүз! Бүген үк Нәбиулла артыннан озат! Һәм тиз тот: безне кызыллар эзәрлекләп килә!

Бу соңгы хәбәрне Канталыев карун Рәхмәтуллага гына белдерде. Аңа ияреп Ялан авылына кергән казаклар хәлне аңлыйлар иде, эшне тиз тоттылар. Колчакның үз кулыннан капитан дәрәҗәсе алган Канталыев соңарганнарны, соңга калганнарны яратмый иде! Карун Рәх-

мәтулланың әшнәләре кирәк кешеләрне күрсәтә тордылар: продразверстка отрядында йөргән Миргалине, Фәрижамал түтине акыртып-бакыртып Иртеш буена сөйрәп китерделәр дә бәкегә төртеп төшерделәр. Авылның ике коммунистын кар өсләп яланаяк байтак типкәләп йөрттеләр дә, хәлләре беткәч, юкә бау белән үз капкаларына аркылы асып киттеләр. Бу кансызлыкны күреп урамга дау күтәреп чыккан Эссәт әкәгә җәза уйлап таба алмадылар. «Азрак ятсын,' уйлап табарбыз!» — дип көлә-көлә аны яланөс салкын амбарга кертеп бикләделәр.

Кешеләр үзләре урамга чыгарга курыксалар да хәбәрләр өйдән-өйгә иреште, кешеләрнең күңелләре тетрәнде, тәннәре чымырдады. Эссәт әкәнең хатыны Шәмсеруй белән нәни кызы Сәрвәрне күрше Рокыя алып чыгып яшермәгән булса, аларның да гомере киселәсе иде, житез хатын казаклардан алда кереп өлгерде.

Төн уртасында, урамда тавышлар тынып, өйләрдә утлар сүнгәч, авылга Уразаев җитәкчелек иткән кызыллар отряды килеп керде. Тавышсыз-тынсыз гына керделәр дә, авыл очында сак юклыктан файдаланып иң әүвәл Һади карт йортына кагылдылар. Һади бабай Мөхәммәт Уразаевка авылдагы хәлне, ак казакларның кайсы йортларда тукталуын сөйләп бирде. «Карун Рәхмәтуллада аларның күпчелеге...»

Иң элек Рәхмәтулланың амбарын ачып катып-өшеп беткән Эссәт әкәне коткардылар. Ашыкканда ялгыш та җибәрделәр: өйне тоташ чолгап алмастан кинәт ишектән бәреп керделәр. Карун Рәхмәтулла йокыга китмәгән икән, мылтыгына ябышты, ата башлады һәм ике кызылармеецны яралады. Канталыев шушы буталыш мизгеленнән файдаланды, себерчә өй белән мунча тоташ салынган булу аңа ярдәм итте, башта ул мунчага кереп качты, аннан ындыр артына узды. Ындырда иярләнгән атлар печән чемченеп ял итә иде. Канталыев ике иптәше белән атка менеп качарга өлгерде. Рәхмәтулла өенә бәреп кергәч, патроннары беткән хуҗа, бәләкәй Шамилне йоклаган җиреннән әләктереп алды һәм:

— Бер адым атласагыз да мин аны суям! — дип акырды. Аның гәүдәсенә ышыкланып өй тәрәзәсен ватып чыгып йөгерде. Караңгыда атып караганнар иде, тидерә алмадылар. Шуннан бирле Канталыев та, карун Рәхмәтулла да суга төшкәндәй юкка чыктылар. Уразаев калтыранган куллары белән бәхетсез улын күкрәгенә кысып утырды. Шамил:

— Эт-ти, кайт-тың-мы? — дип кабатлый иде.

Шушы төннән, баш очында ялтыраган киң йөзле пычактан куркып, Шамил тотлыга башлады...

Ырсытдин авылга aклар керүен дә, аларның ни кылганын да ишетеп-белеп торды. Продразверстка вакытында дүрт йөк бодаен тартып алганнары өчен совет властен бер кабуда йотардай булса да фетнәгә катнашырга ашыкмады. Рәхмәтулла йортына чакыру килгәч, яңагын иске тире бияләй белән урады да, сырхауга сабышып урын өстендә ухылдап ятты. Ул фетнәчеләргә ышанып җитмәде. Сәнәк тә сөңге белән әллә ни кыра алмаячакларына төшенде. Икенче тапкыр чакыру килгәч, үзенең ялчысы Капушны баштанаяк коралландырып Канталыев катына җибәрде. Өр-яңа винтовка янына йөз илле патронны күргәч, капитан Ырсытдинне аяды, үзе бармаганнар шушы кадәр корал бирсен иде әле, дип уйлады...

Уразаев отряды таңга кадәр генә Ялан авылында булды. Көн ачылып, атлар, кызылармеецлар аз-маз ял иткәч Мөхәммәт үтерелгәннәрнең туганнары, якыннары йортына кереп кайгыларын уртаклашты да Шамилне Һади бабайларга тапшырып походка чыкты. Ялан тирәсендә генә түгел, Тобол төбәгенең башка авылларында да фетнә бастырылды, берничә ай үткәч фетнәчеләргә амнистия дә булды. Совет хөкүмәте фетнәгә катнашучыларның күбесен, кешелеклелек күрсәтеп, туган илләренә кайтарды, тыныч тормышта үз караларын юарга мөмкинлек бирде. Шул

исәптән Чырык Абдрахман, Капуш, Сәмук, тагын берничә кеше Яланга әйләнеп кайттылар. Ярлы, ялчы булып Ырсытдингә хезмәт иткән, гомергә хуҗасының җырын җырлаган ата фетнәче Капуш, авылда торып булмаслыгын белеп, каядыр читкә чыгып китте. Ул үзе белән Чырык Абдрахманны да чакырып караган иде, тегесе каршы төште: «Үлсәм дә туган авылымда калам, атам йорты — ак Мәскәү»,— дип кенә җибәрде.

Күбәүләр, амнистиядән соң байтак вакыт узгач, юл тузаннары басылгач, шыпырт-шыпырт кына, ындыр артлатып өйләренә әйләнеп кайттылар һәм, ярыкларга кысылган тараканнар кебек, төрлесе төрле җиргә кереп постылар...

## 7

Фетнә бастырылгач, Уразаев губкомда эшен дәвам итте.

Язгы гөрләвекләр челтерәп акканда, язгы җилләргә тирбәлеп Иртеш-Тура тирәләренә сайрар кошлар кайтканда, аның янына Ялан авылының комбед рәисе Эссәт әкә килеп керде. Ул тагын да ябыккан иде. Бәләкәйләнеп калган башы озын, арык муенында ничек болай туры басып тора торгандыр!? Керде, утырды, озак кына бер сүз дә дәшмәде. Эш күплектән гаҗиз Уразаевның авылга шактыйдан кайта алганы юк иде, Эссәт әкәне сораулар белән күмеп ташлады. Эссәт әкә ак казаклар кулыннан котылганнан бирле сүзгә тагын да саранланган иде.

...Шамилме? Һадиларда тора. Тотлыгуы кимеде диләр...

...Җыелышмы? Шәп үтте... Җир бүлгәндә гауга булмыймы соң?

...Симәнә кирәк, симәнә юк, чәчәргә орлык бетте...

...Орлыкмы? Белкин янына кереп киңәшергә кирәк, ансыз булмас...

Уразаев Эссәт әкәне Белкин янына алып керде...

* * *

Эссәт әкә, ун олау орлык алып кайтып ярлы-ябагайга тараткач, авылдагы шатлыкның иге-чиге булмады. Көне-төне аның исеменә рәхмәтләр яуды. Һади бабай, таң туса, иртәнге намаздан соң тәсбих төймәләрен тарта-тарта, аңа озын гомер теләде.

Күпләр зарыгып көткән көләч кояшы белән егерме беренче елның язы да килеп җитте. Исән-аман кыш чыгып кара җиргә аяк басу бәхетенә ирешкән кешеләр яз җитүгә чиксез куандылар. Кышкы афәтләрнең авыр хатирәсе белән кар астыннан рәт-рәт тезелгән яңа каберләр килеп чыкты... Иртешнең ярсып-үкереп агышында да алар бәке кырыена куллары белән ябышкан Миргали белән Фәхриҗамал түтине күрделәр. Әмма тормыш тукталып тормый, үзенекен итә, ни авыр хәсрәтләрне дә юдыра, кышкы кайгылар язын онытылалар, крестьянның кызу эш көннәре җитә. Кем ничек юнәтеп, актыккы мал-туарын сатып, кием-салымга алмаштырып тапкан чәчүлек орлыгын зур өметләр баглап җир күкрәгенә тапшырды. Ярлылар комитеты да байтак кешегә ярдәм күрсәткән иде, кырларны кысыр калдырмаска тырыштылар. Күзне иркәләп басулар яшәрде, Ялан авылы кешеләренең гәүдә тотышлары үзгәрде, урамда очраганда бер-берсенә сәламне кычкырыбрак бирә торган булдылар... Җәйгә керделәр. Адәм балаларының чыдамлыгын тагын бер кат сынап карыйм әле дигәндәй, кояш ай буе үзенең утлы укларын җиргә яудырды, куерып килгән уҗымнарны саргайтып, өтеп алды. Авыздан өзеп, бөртекләп җыйган бодай бөртекләре калкынып, иркенләп дулкынланырга да өлгермәделәр, тоташ куырылдылар. Җәй буена илгә бер бөртек яңгыр төшмәде. Иртеш төбәгенә шиксез үлем күләгәсен өстерәп ачлык ябырылды. Дизентерия, корсак тифы, чәчәк авыруы, ваба эпидемиясе йөзләрчә кешеләрне алып китте. Ялан зиратында кышын күмелгән шәһитләр янында ачлык тырнагына, чир кочагына эләккәннәрнең яңа каберләре тезелде.

Тайгада яшеренеп яткан банда калдыклары Саз ягы авылларында тагын калкынып чыктылар, авылларга һөҗүм ясап хәллерәк кешеләрнең соңгы телем икмәкләрен талап алдылар, сыер-сарыкларын урлап суйдылар. Губкомга таланган авыллар, ерткычларча үтерелгән совет активистлары турында әледән-әле хәбәрләр килә торды...

Нишләргә? Нурсыз күзләре ачтан эчкә баткан балаларга кайдан алып ипи сыныгы каптырырга? Кешеләрне ничек, нинди сүзләр белән рухландырырга? Бандалардан ничек котылырга? Укомда хәзер шушы сорауларга җавап таба алмыйча газапланалар... Телләрдә нибарысы бер сүз: «Икмәк!» «Икмәк!» «Икмәк!»

Авыл телендә бер сүз: «Яңгыр!» «Яңгыр!» «Яңгыр!»

Иң могтәбәр картлар мәчетләргә җыелып ялынып-ялварып тәңредән яңгыр сорадылар. Ир-атлар яңгыр теләп тәкъбир әйтә-әйтә урамнарны урадылар. Яшүсмерләр, бала-чага «карга боткасы» пешереп, һәр казык башына аз-маз ботка ягып каргаларны сыйлап та карадылар. Яумады яңгыр, күктә чекерәеп утлы шар тәгәрәде, җир өстендә тыгызланып куе, тузанлы рәшә тирбәлде. Иртеш суы гомердә булмаганча аска иңеп китте, агымы сүрәнләнде. Балыкка өмет итеп үсмерләр, житкән егетләр көне буе калкавычка күз текәп утырдылар, кич саен күз нуры түгеп, буш савытларын күтәреп кайттылар. Балык каядыр югалды, китте, чабагы да чиртмәде, балык тирән суны ярата, аска, төньякка, океанга агып китте алар...

Ялан авылы халкы юага иямәште. Чуртанлы суы кими торды, кимегән саен яңа яр ачылды, шул яңа ярда куерып юа үсеп чыкты. Августка кадәр юа белән корсак алдадылар. Чуртанлыда су кимегән саен җитез чуртаннарга көн бетте: үзле ләмдә чупырдап яткан бәләк-бәләк чуртаннарны сәнәк белән кадап та, корык[1] белән эләктереп тә ала башладылар.

Шул чагында яланлылар еракта, сазлыклар, урманнар уртасында утырган Шыкшырым күлен искә төшерделәр. «Шыкшырымда балык мыжлап үрчегән!»— дигән хәбәр Тоболга, Укомга да килеп җитте. Димәк, андагы балык белән яланлыларны гына түгел, башкаларны, балалар йортларын, больницаларны да тәэмин итеп булачак?

— Синә ышаныч,— диде Белкин Уразаевны озатып калганда.— Хәбәр чын булса, әйдә, халыкка балык ашатыйк!.. Азга гына булса да түздерик аларны... Башка урыннардан ярдәм килгәнче җан саклап кала алмаслармы?

Шыкшырым...

Юл рәтле чагында Яланнан Шыкшырымга ике-өч көндә барып җитеп була. Эссәт әкә әртиле, җиде көймә белән сазлы урыннарда ерма[2] ясап, этенә-төртенә бу араны җиде көндә үтте. Элек көймә керерлек вак-төяк күлләр сусыз калып, аларны вак камыш каплаган иде... Ниһаять, арып-талып, ачыгып, талчыгып, хәлсезләнеп, кулларны канатып, күл ярына барып егылдылар. Бер көн, бер төн тоташ йокладылар...

Күлне ылыслы куе урман урап алган. Шыкшырым нәни диңгез булып җәйрәп ята. Гомер буе балыкны Иртештән тотып өйрәнгән, елганың гадәтләрен бик яхшы белгән яланлылар башта аптырап калдылар. Күл өсте тып-тын, кап-кара һәм куркыныч иде... Икенче ягы күксел томан булып кына күренә. Яланлылар күл читенә басып аптырашып күзәтеп торганда уртага бер өер үрдәк очып килеп кунды. Киек кошларны күргәч алар кинәт җанландылар, бер-берсенә күрсәтеп, үрдәкләрне санарга тотындылар. Бер-бер артлы күлгә тагын кошлар кайтты, аларның санын алырлык кына түгел иде, арада чүрәкәйләр дә, батар үрдәкләр[3] дә күренгәли.

[1] Корык — кыл элмәк, ул таяк башына бәйләп куела.
[2] Ерма — русчасы резка, сазлыкта камыш кисеп ясалган көймә юлы.
[3] Батар үрдәк — казарка.

2*

Димәк, балык янәшәсендә үрдәк ауларга да җай булачак...

Җиң сызганып эшкә керештеләр. Мөхәммәт Уразаев әртил членнарына эшне бүлеп бирде. Берәүләр камыш читенә есе[1] куйдылар, икенчеләр күлгә чишмәләр килеп кушылган урыннарга тыуан [2] ясадылар, ау тектеләр, ауларны күлгә батыра башладылар. Каз зурлыгындагы батар үрдәкләр аерата сак иделәр, балыкчыларның күл читенә якынлашуын күрү белән алар аръякка, күксел томан белән өртелгән серле ярга йөзеп китәләр.

Мөхәммәт Уразаев тәкъдиме белән, тоткан балыкларны саклар өчен күл читләрендә зур-зур күрекләр ясадылар. Күрек — күлнең тын җирендә суга таяклар чәнчеп коршап алынган читән бура. Тоткан бер балыкны шунда камый барасың. Балык айлар буена шунда тере саклана. Уразаев партизаннар белән йөргән чакта бу эшне шактый нык өйрәнгән иде, алар кыш көне дә, сазлар каткач, күректәге балыкны җәтмә соскалар белән сосып алып, чаналарга төяп ташыганнар иде... Күп кешеләрне чирдән, ачлыктан коткарган иде ул чакта балык!.. Хәзер дә шулай итәргә кирәк, дип уйлады ул, күрекләрне кышка да яраклык итеп, тыгыз итеп үрдерде. «Әгәр кышка калсак»,— дип күлдән ерак түгел бер аланда бура бурап йорт салырга да керештеләр.

Икенче көнне таңнан торып ауларны тикшерделәр, еселәрдә кайнап торган балыкны күреп исләре китте, табан кереп тулган елымны бөтен әртил белән көчәнеп чак кына тартып чыгаргач, бөтенләй хәйран калдылар.

— Бу күлдә су бармы, әллә гел балык кына кереп тулганмы? — диде шаккатып Эссәт әкә.

Иң әүвәл корсаклары кап булганчы балык шулпасы ашадылар, «аш ашка — урыны башка!» дип иң симез табаннарны сайлап табада кыздырдылар... Аннан тотылган балыкларны күрекләргә җибәрделәр. Бер көн эчендә тотылган балык та күрекләрдә күзгә күренеп, су чәчрәтеп кайнап тора башлады.

Әртилнең эше тиз җайланды. Эссәт әкә дә, Мөхәммәт тә балык тоту осталары, алар елымны кайда салырга кирәген дә, кайчан алу файдалы булачагын да бик яхшы беләләр икән, белгәннәре ярап куйды.

Шулай өч-дүрт көн үтте, буралык агачларны аударып, иңнәренә бау уздырып, бауны бүрәнә башына бәйләп һай-һаулап кирәк кадәр агачларны аланга ташып та куйдылар. Балта тавышы көнозын тынмады, ак йомычкалар, тәмле ис таратып очып кына торды. «Бу ни хәл, кешеләр көнозын тын да тартмыйча ни кылалар?» — дип гаҗәпкә калган каз зурлыгы казаркалар күл өстендә әйләнгәләп йөрделәр...

Бер иртәдә көтелмәгән хәл булды... Иртәгесен зур өметләр белән күл ярына җыелсалар, ни күрсеннәр — бөтен күрекләр буш. Алар берничә урыннан ничек җитте шулай сүтелгәннәр һәм бар булган балык чыгып ычкынган. Барлык әртил буш күрекләргә карап катып калды. Мәет озаткандагы кебек тынлык урнашты.

Тотылган балыкны төяп бүген Яланга һәм Тоболга озатырга җыенганнар иде... Мөхәммәт улы Шамилнең нәни куллары белән тотып алып, бармакларын ялый-ялый балык ашап куанганын күз алдына китереп йөргән иде. Ач аналар, бала-чагалар өлешенә кем кергән?! Кем чыгарып җибәргән балыкны?

Елымнарны тикшерә башладылар: аларны судан чыгарып ерткалап кискәләп бетергәннәр булып чыкты. Еселәрне дә ватып-кырып бетергәннәр... Төнгә корып калдырган бер ауга дүрт кугый[3] үрдәкләре эләккән иде. Аларның йоннары нык, йолкынмый. Кугыйларның тиреләрен сыды-

---

[1] Есе — чыбыктан үрелгән балык тоту коралы, мурла.
[2] Тыуан — чыбык үрмә белән чишмәне яки күл култыгын бүлеп кую (балык тоту өчен).
[3] Кугый үрдәк — гагара, аның тиресеннән ясалган аяк киеме чыдам һәм үтә җиңел була.

рып алып киптерергә элделәр. (Соныннан алардан бөрмә дип аталган аяк киемнәре тектеләр).

Кем булыр?

— Карун Рәхмәтулла эше бу! — диде Эссәт әкә,— шуның этлеге...

Эш өр-яңадан башланды, көне буе, туралган елымнарны ямап, үреп иза чиктеләр, яңа күрекләр ясадылар. Чиратлашып төнлә-төнлә каравыл-ларга булдылар. Йортны да салкыннарга кадәр өлгертәсе бар иде. Уразаев байтак балык тотканнан соң Тоболга кайтып килде, төрле авыл-лардан тагын дүрт әртил оештырып Шыкшырым күленә һөҗүм баш-ладылар. Әртилләрнең берсе — сунарчылардан булып, алар шарт та шорт үрдәк, кугый ата башладылар. Үрдәк ите туп-туры шифаханәләргә, балалар йортына китә торды. Балыкның бер өлешен он, житен түбе, тозга алыштылар.

Уразаев житәкләгән әртилләр кар төшкәнче ике мең поттан артыграк балык тоттылар. «Мәнә сиңа урман-сазлар арасында качып яткан Шык-шырым күле! Тобол төбәгендәге авылларны ачлыктан саклап калган өчен синең исемеңне Туклык дип алыштырырга кирәк!» — дип шаярткан иде Уразаев...

Унике кешедән торган әртилне алты почмаклы таза бүрәнә йортта калдырганнар иде, бандит калдыклары ут төртеп йортны харап итте-ләр. Әртилчеләр бәрәкәтле күл буен калдырып кайтырга мәҗбүр бул-дылар...

Балыкны җибәрүчеләрне дә, ут төртүчеләрне дә әлегә тота алма-дылар, бандитлар һаман шул тирәдә Ялан авылы урманнарында качып яталар иде булса кирәк...

## 8

Тормыш мәшәкатьләренә уралып тагын сигез ел узып китте. Тор-мыш ел саен яңа сүз, яңа мәгънә алып килде Иртеш буйларына. Мөхәммәт Уразаев кебек белеме булганнарны гына түгел, аз-маз уку күргән, мәктәп узган активистларны да партия наданлык белән көрәш-кә озатты. Уразаев та бер айлык махсус курсны тәмамлап «укытучы» дигән таныклама тотып Ялан авылына, туган-үскән җиренә кайтып төште. Моңарчы өйләнмәде, ялгыз яшәде, башы эштән чыкмады, ялгыз икән-леген белеп аны ерак-ерак командировкаларга — Саз ягы авылларына йөрттеләр...

Ялгыз яшәп туйган иде Уразаев...

Ялан авылы да үзгәргән! Кәс түбәле алачыклар арасында ара-тирә тыгыз коймалар белән коршап алынган, челтәрле кәрнизле иха-талар да күзгә күренә башлаган. Коймалар артында тук маһмайлар һаулап кала. Шул йортларның берсе Уразаев күңеленә бигрәк тә якын иде. Анда Мөхәммәтнең ваемсыз яшьлеге узган...

Иртеш буендагы татар авылларының нигезен Күчем хан мирзалары салган. Ялан авылы өчен урын сайлаган акыллы мирза: «Киез йорт-ларны салкын җилләрдән, төньяктан сузылып үткән биек тау — Уба ышыклар, көньяктан иң затлы балыкларга бай Иртеш елгасы ага — шуннан ризыкланырсыз, авылны ярып узган чишмәдән татлы су эчеп рәхәтләнерсез»,— дигән, имеш... Шулай дигән дә авыл уртасына беренче казыкны китереп каккан... Шул казык тамыр җибәргән, тармакланып җимеш агачына әверелгән. Руслар әле дә шушы урынны авыл түгел — күчмә халыклардагы кебек Юрты дип атап йөртәләр, ягъни Ялан йорты.

Тыштан караганда мунчага охшаган Эссәт Фәтхуллин йорты эчтән ару гына җыештырылган булып чыкты. Колач җәеп дустын бер кочак-лыйсы килсә дә, кырып юганнан соң басарга куркынычка әйләнгән сап-сары кедр такталарыннан җәелгән идәнгә басарга кыймый үрә катып торды, тамагындагы төерне көчкә йотып җибәреп:

— Исәнме, Эссәт дус! — диде.

Эссәт аны кочаклап ук алды:

— Кайттыңмы? Бөтенләйгәме? — дип сорады.

— Ишеткән идеңме?

— Ишеттек. Кайта, диделәр. Мөгаллим булып эшләр, диделәр. Ышанмадык.

Гимнастеркасының төсен тәмам кояш суырып алган, күн фуражка, иске галифе чалбар кигән, партия эшлеклесе булып танылган Уразаевның авылда эшкә урнашырга теләвен Эссәт аңлап җиткермәде.

— Әллә тагын нәләт төшкере берәр банда-мазар кузгаламы? — дип сорады ул ары-бире хәл алышкач.

Җавап урынына Мөхәммәт түгәрәк мөһер сугылган кәгазь кисәген сузды. Һаман ышанып бетмәде Эссәт Фәтхуллин, керфекләрен тиз-тиз биетеп:

— Әллә берәр шуйган[1] кылып куйдыңмы? — дип сорады.

— Ник алай дисең?

Эссәт җавап итеп бармагы белән югарыдан түбәнгә шуып китүне ымлады. Мөхәммәт аңлап көлеп җибәрде:

— Юк, брат, һичнинди тәгәрәү-нитү булмады, авылыбызга кайтасым килде. Бары шул гына. Улымны да сагындым.

Эссәт әкә казанлык янында маташкан хатыны тирәсендә очып йөри башлады, таганны җайлап утыртырга булышты, җилтерәп барып җиз комганга су салды, сандыктан чиста сөлге тартып чыгарды. Ул арада Эссәт әкәнең кызы Сәрвәр Һади бабайларга йөгереп барып Шамилне алып килде. Ата белән ул бер-берсенә ятсынып карап тордылар...

Үскән Шамил, буйга нык ук калкынган. Сирәк күрештеләр алар бу елларда, сигез ел дәвамында Мөхәммәтнең ял иткәне юк диярлек, улын үз янына калага алдырырга ниятләгән чаклары да булды, бик еш командировкаларда йөрүен уйлап ул уеннан кире кайтты, баланы чит-ят кулларда калдырырга туры киләчәк иде. Ә авылда исә, ерак булса да, туганнары бар, дуслары, якыннары, алар берсе дә баланы чит итмәгәннәр, катыгын-сөтен илтеп, өс-башын карап торганнар. Җай чыкканда Мөхәммәт тә улына кирәк-яракны, кышын-җәен кием-салымны җибәргәләп торды. Сирәк кайтты, сирәк, анда да бик азга гына күрешкәләп тордылар, бер-берсен ятсынсалар да гаҗәп түгел...

Мөхәммәт сикереп торып улын каршылады, кочакларгамы, юкмы дип аптырап калды, малай чак кына читләшә, гаҗәпләнгән һәм нигәдер курка да иде, ахрысы.

— Әтиең әнә бөтенләйгә кайткан, Шамил,— диде сөенеп Эссәт әкә.

Ул арада Шәмсеруй җиңги табын әзерләде, ягымлы, моңлы тавыш белән кунакларны табынга чакырды:

— Ягез әле, кунаклар, табынга рәхим итегез! Хуш килдегез! Иртәшебез биргән нигъмәтләрдән — кәреш[2] белән тогысыннан[3] авыз итегез. Менә монысы шомырт бәлешe, монысы баланнан — Сәрвәрем белән бергә җыйдык. Әйдә, тартынма, улым, аша.

Сүзе юньләп чыкмаса да, уйнап ачыккан малайның күзе ут булып яна башлады, ул өстәлдәге кисәк-кисәк балыкны ашап куйды, кыздырылган шаңгә белән ике-өч чынаяк чәй эчте. Мөхәммәт тә тәмле ризыкларны сагынган икән, бераздан табын өсте ялт итте.

Мөхәммәт Уразаев соңрак та кайта ала иде, әмма ул Белкинны соңгы атналарда гел тыкырдатып торды, «Иртәрәк кайтыйм мин, авыл белән таныша торыйм, балачагым узган як бит, сагындырган»,— дип

---

[1] Шуйган — шуклык, зарар.
[2] Кәреш — чөгә, стерлядь.
[3] Тогы — осетр балыгы.

кат-кат кабатлады. Сагынган иде Яланын Мөхәммәт, улын сагынган иде...

Ә Ялан?.. Аның язмышы гади бер язмыш кына түгел ләбаса!

Башта ятимлек... Әгәр ятимлек измәсә, ачлык-ялангачлык рухын сындырмаса, ул Ырсытдиннең байбичәсенә буйсынып торыр идеме? Азгын байбичәне өреп кенә чыгарган булыр иде тавык кетәгеннән!.. Әгәр иртәгәге көн ятимне көтеп-сагалап торган кара язмыш булмаса, ул Мөкә бай кармагына барып кабар идеме... Ялланда үз кызы бар — ана ул «кызым!» дип эндәшә алмый... Янында улы бар, ул «әтием!» дип мөлдерәтеп аңа карап тора, ә чынлыкта исә ул аның каны түгел... Менә язмыш диген! Нинди четерекле яклары бар аның! «Чит кеше баласы!» — дип ташлап китеп кара Шамилне... Һаман тотлыга бичара, табындагы ипи телеменә үрелгәндә дә уң ягы тартышып-тартышып китә... Үз янына иртәрәк алдырасы калган?... Эх, тормыш дулкыннары байтак кагып йөртте шул Мөхәммәтне, нигезен корып бер урында ныгып китә алмады...

Әнә шул теләк, нигезен корып ныгу теләге алып кайтмадымы аны Ялланга?.. Гәрчә үз нигезе — ярлы-ябага нигезе күптән җимерелгән, йорт ишелеп черегән... Каралты-кура калмаган. Яланда кайда яшәргә дә, кемдә торырга? Хәзер улы белән яшәр өчен аларга бер куыш кирәк.

Дөнья хәлләрен сөйләшеп, ерак-еракларда гизә-гизә утырганнан соң Эссәт әкә белән алар киңәшеп алдылар.

— Кәрим Мөхлисәсенә урнашу мәслихәт булыр,— диде Эссәт Фәтхуллин, авыл советы рәисе.— Йорты тузган булса да, янгыр үтми, беләм. Эштән кайтуына әби пешеренеп-төшереп тә тора алыр, кул-аягында егәре бар әле аның. Сүзе ягымлы, карашы мөлаем карчык. Хәер, бер кызы бар, мәгәр ул читтә укый. Кайтса әнисе белән бер бүлмәдә торыр. Фелшер кыз ташпулат сорамас бит әле?..

Шәмсеруй җиңгигә тәмле ризыклары өчен рәхмәт әйтеп, килгән шәптә кыздырып калыйк, дип Мөхлисәләргә киттеләр. Әби аларны ягымлы каршылады:

— Мөгаллим булып кайткансың икән, Мөхәммәт... Ырсытдингә рәхмәт әйт! Ул сине укытты, ул чыгарды олы юлга. Бала укытуның ни икәнен үземнән беләм... Инде менә безнең ярлы-ябагай ихатасы ошар микән? Мәрхүм этиләре вафатыннан соң йорт-курага кул тидерә алганыбыз юк. Еллар бик авыр килде лә!— диде дә, няк астыннан ук бәйләгән иске яулыгы белән күз тирәсен сөртеп алды.

Шамил:

— Безнең өебез шушы буламы, эти?— дип сорады.

Аның шатлыгы йөзенә чыккан иде, сөенеченнән тотлыгуы да кимегән төсле булды.

Әбинең сүзен раслагандай, кыегаеп егылырга житешкән җил капка бер ачылып, бер ябылып ямьсез шыгырдап алды. Шамилгә бу шыгырдау шулкадәр ошады ки, ул ике куллап җил капкага ябышты да, аны арлы-бирле йөртә, кычкырып көлә башлады.

— Ни барына риза булырбыз, Мөхлисә әби. Менә минем тиктормас егетем генә теңкәгезгә тимәсә инде?..— диде Мөхәммәт, Шамилен иңләп кенә капка тирәсеннән этәреп.

— Бала белән йортка шатлык керә, балалы йортта гайбәт булмый, ошатсагыз, әйдәгез, хуш килегез. Мин ятимәгә дә бер юаныч булырсыз! Ир-ат юкка кичләрен шыксыз була. Әлгәрәге елларны урманнан качкынмазар чыкмасын дип гел куркып яшәлде...

Эссәт әкә:

— Аларның тамырын корыттык!— дип авызын ерды. Мөхәммәтнең йөзеннән ашыгыч күләгә йөгереп узды:

— Тамырлары ук корыдымы икән?— дип сорады ул баскыч такталарын шыгырдатып мена-мена. «Төзәтергә кирәк боларны, Шамил белән бергәләп!»— дип уйлады ул. Эссәт әкә, нечкә хисле кеше, ата белән

баланы ялгыз калдырырга кирәклеген аңлап, саубуллашып китеп тә барды. Алар иртәнчәк Иртеш буенда аккорт яуганын караганда очрашырга сүз куештылар.

Шамил куларага керә дә башлаган икән инде, ул Иртештән су алып менде, Мөхәммәт җиңнәрен, чалбар балакларын сызганып идән юарга тотынды, Мөхлисә әби үзе дә яшәреп киткәндәй булды. Самавыр куйды, бар булган ризыгы белән кунакларны сыйлады. Ишегалдын себереп кергәндә кичке караңгылык иңде, алар аталы-уллы кочаклашып әбинең чип-чиста идәненә җәелгән ятак өстендә озак кына сөйләшеп яттылар...

* * *

Һәр ел саен җәй уртасында, салкынча төндә, Иртештә аккорт ява... Аккорт ява башлагач, елга өстендә тоташ куе томан күтәрелгән төсле була.

Аккорт дигәннәре энә карагына охшаган бөҗәк ул. Төсе ак, канаты кара булганга аны «аккорт» дип атаганнар. Руслар «метляк» диләр. Аккорт Иртеш төбендәге зәңгәр ләмдә яши, үсә һәм йомырка салып калдыра. Ел да русларның петрау көне җитәр чакларда таң яралганда су өстенә йөз меңнәрчә, миллионлаган күбәләкләр чыгып лепер-лепер оча башлый. Аккорт яуган мәлдә күбәлək канатларыннан су өсте гүләп тора. Кортларның ишлелегеннән Иртеш өстен куе болыт каплагандай була. Кояш күтәрелә башладымы, ул күбәләкләрнең канатлары җепшеп, аккортлар су өстенә егылып төшәләр... Гомерләре нибарысы ике-өч сәгать чамасы гына. Дулкын кагып кортларны ярларга ташлый, күбәләкләр кырдам[1] булып өеләләр. Теләсән, соскы белән җыйна да ал! Су ярына җыйналган аккортларны балыкчылар чиләкләп җыеп каес[2]-ларга тутырып алып кайтып киптерәләр. Аккорт җимләсәң, кәреш шәп каба! Элек шулай иде! Аккорт яуганын карарга бөтен авыл төшә! Бәлки Мөхәммәтнең ашыгып кайтуының бер сәбәбе шулдыр әле — аккорт яуган таңда авылдашларын бергә күрәсе килгәндер аның?!

Юл кайтып арылганмы, әллә улының тигез сулышын бүләсе килмәдеме, Мөхәммәт тиешле вакытта уяна алмады. Аларны Мөхлисә әби уятты:

— Торыгыз, тор, оланнар! Иртештә аккорт ява башлаган!

Шамилнең дә йокысы сак икән, әтисе торып чалбар каешының аелын шылтыратуы булды, ул да күзләрен ачты, кайда ятуын аңлый алмыйча ят кешегә карап ятты. Ак күлмәк-ыштаннан ул әтисен танымады. Мөхәммәт аның ябык гәүдәсен кочып күтәреп алды һәм:

— Торыйк, улым, Иртешкә төшик!— диде.

Киенделәр, ашыгып елга буена юнәлделәр. Ә Иртеш әнә-ә генә, елга өстендә эре-эре бөртекле кар яуган сыман, г-ө-өжж иткән сәер тавыш колакларны яра. Елга буенда олылар, карчык-корчык күп, бала-чаганы әйткән дә юк, алар кычкыралар, абына-сөртенә чабалар, егылып төшкән күбәләкләрне учларына җыялар. Ашыгып аккан Иртеш күбәләкләрнең күбесен йотып үзе белән алып китә, яр буена кагып чыгарганнары да байтак, яланлылар аккортларны кушучлап каесларга тутыралар. Чыгар алдыннан гына Мөхлисә әби Мөхәммәткә дә такта чиләк тоттырган иде, алар да Шамил белән икәүләп тиз арада кортларны җыеп тутырдылар.

Яшьрәкләр Мөхәммәтне танымыйлар, ят кешегә сәерсенеп карыйлар, олылар бер-берсеннән ишетеп аның белән күрешергә киләләр, сәламләшү, гаҗәпләнү, хуплау тавышлары янгырый.

— Кайттыңмы?..

---

[1] Кырдам — покос итеп өелгән печән.

[2] Каес — тырыс, туздан тегелгән биштәр, аркага асып йөртәләр.

— Озаккамы?

— Ә без аккорт яуганын көтеп монда кундык... Караңгыда ук төшкәли башладылар, аннан китте, китте! Яңгыр кебекява!..

Кояш чыгып тәртә буе күтәрелгәч, Иртеш буйлары ямьләнеп ачылып китте. Аның бу төбәктәге һәр бормасы, һәр тугае таныш Мөхәммәткә, таныш һәм якын., якын һәм кадерле. Уйласаң, күпме күргән бу Себер елгасы!.. Киртләч ярларына бәрелә-бәрелә ул челт-челт тавыш чыгарып, үткән заманнар хакында сөйли кебек. Һәркемгә бәхет, озын гомер, игелек тели сыман. «Хуш килдегез, Мөхәммәт Уразаев!»— дип эндәшә кебек...

Бурлакларның ачы тире тамган ярлар... Колчак явызлыгыннан, Ермак һәм Күчем яуларыннан заманында кызыл төскә кергән елга гасырлар буена ятимнәрнең моң-зарын тыңлаган. Легендар Блюхер аның ширбәттәй суын эчеп көч җыйнаган. Даһи Менделеев аның йомшак дулкыннарында тирбәнеп үскән. Сихерле Иртеш буйларында Ершовның «Канатлы ат»ы дөньяга чабып чыгып киткән. Ямьле елга таллары арасында Алябьев күңелендә сихерле «Сандугач» яңгыраган...

Әнә теге борылышта егерме беренче елның февралендә зур бәке чапканнар иде. Бәке тирәсендә ыгы-зыгы: «Бетерәбез!» «Батырабыз!» «Юк, мин риза түгел!— диде чал Иртеш,—«Мин дөньяга игелек, тереклек бирә килдем, нигә мине болай рәнҗетәсез?!»

Шул вакыйгаларның шаһиты Мөхәммәт исән, ярда басып тора. Ә Иртеш ага да ага...

Кемдер сыздырып гармун уйный, аккорт ява — үзенә күрә бер бәйрәм, яланлылар бергә җыелган... Бергә чакта күңелләр берегә, якынлаша... Иртеш буе аланында кинәт гармун тавышы яңгырый башлый. Елга ага, моң ага, хатирәләр ага... Яшьләр җырлый. Бу моңны Иртеш дулкыннары ятлап алып ерак-еракларга салкын Боз океанына кадәр алып баралардыр төсле...

Ямьле Иртеш буйларында
Тавышым калсын билгегә.
Уйларымда, җырларымда
Йөрәгемдә син генә.
  Суга салсаң су күтәрмәс
  Бер мыскал тимерләрне.
  Кайтарып алыйм дисәң, юк,
  Үткән яшь гомерләрне...

Елга гына түгел, җыр да Мөхәммәт Уразаевның күңелен әллә кайларга алып китә. «Әйе,— дип кабатлый ул җырга ияреп,— яшь гомерләрне кире кайтарып алырмын, димә... Үтте, китте...» Җиргә яңа буын туган, яңа кешеләр. Әнә, алар, кырмыскалар кебек, Иртеш буен тутырып уйныйлар. Шамил дә алар арасына барып катнашкан. Ул да көлә, ул да шат. Көлмәс иде — этисе янында. Шатланмас иде — этисе кайткан. Этисе мөгаллим аның, зур кеше... Мөгаллим...

## 9

Мөхәммәт Уразаевның Яланга кайтып төпләнүенә иң нык шатланган кеше Эссәт Фәтхуллин булгандыр. Әллә Шамилме?

— Булды бездә бер мөгаллим, Саз ягыннан килгән иде. Әхәт атлы. Җәй буе эт сугарып йөрде, мәктәбе утынсыз калды. Эчте дә эчте мөгаллимебез, самогон да эчте, аракысын да ким куймады, күзенә ни күренсә шуны эчте... «Совет мөгаллимнәре әнә шундый була ул!»— дип күзгә төртеп күрсәтә башладылар.

Мөхәммәт Уразаев авыл советы рәисенең бу сүзләрен күңеленә салып куйды. «Совет мөгаллиме»... Димәк, аның нинди булуы авыл өчен дә, совет рәисе өчен дә ифрат мөһим икән.

Укучылар белән беренче очрашыр көн якынлашкан саен аның дулкынлануы арта төште. Өй борынча йөреп, уку яшендәге балаларны

барлап, Тоболдан акбур, дәфтәр ише нәрсәләр алып кайтып куйгач бер никадәр тынычланган иде, дәрескә барып кергәндә инде күпме дөнья күргән, халык алдында ничәмә-ничә тапкыр чыгыш ясап өйрәнгән мөгаллим Уразаевның аркасына салкын тир йөгергән иде.

«Мәктәп шул көнне ачыла, укулар фәлән сәгатьтә башлана»,— дип йорт саен әйтеп, кисәтеп чыкса да, беренче көнге сабакка нибарысы җиде бала килгән иде. Алар иң арттагы парталарга өчәрләп-өчәрләп кысылышып утырганнар, җиденче бала ялгыз утырырга шүрләп аларга сыенып тора иде. Мөхәммәт балаларны икешәрләп утыртып чыкты, алай да бер парта артында өчәү калдылар, берәү дә ялгыз утырырга базмады. Арада олыраклар да бар, нәниләр дә, күпчелек бер чама, бер елгы балалар булып чыкты. Кемнәр барын дәфтәрдәге исемлеге аша тикшереп чыкканнан соң да Уразаевның каушавы кимемәде әле. Бер айлык курсларда укып ишеткән «укыту методлары, кагыйдәләр» берьюлы баштан очып чыгып беттеләр. Һәм ул полк алдында чыгыш ясаган олы командир сыман көр, нык тавыш белән дөнья революциясе, шушы революциядә пролетариатның роле турында сөйләргә тотынды. Аның исәбенчә, дөнья революциясе боларны ифрат нык кызыксындырырга тиеш иде! Нинди генә аудитория алдында чыгыш ясамасын, моңарчы ул гел уңышка ирешә иде. Буш диярлек класста аның тавышы гөрелдәп, яңгырап торды. Балалар башта гаҗәпләнеп, күзләрен шарайтып утырдылар-утырдылар да, күнектеләр, терсәкләр хәрәкәтләнде, бер-берсенә карашып алдылар да сүз каттылар, ярты сәгать үтәр үтмәстә Мөхәммәт үзенең ялкынлы дәресенең нәтиҗәсен күрде: Шамил белән Сәлимә бер-берсенә иңнәрен терәп борын сызгырталар, йоклап киткәннәр. Ырсыттиннең малае Ташкәй бер кулы белән муенын кашый, икенче кулының имән бармагы төбенә хәтле борын тишегенә кереп киткән, рәхәтлектән аның да күзләре йомылган...

Мөхәммәтнең тавышы салулап барды-барды да, түбән төшеп, бөтенләй тuktады. Класс тынды. Тынлык шактый вакыт дәвам иткәннән соң озын чикмән кигән бер малай чебиләре сибелгән кап-кара кулын югары сузды.

— Йә, бала, ни әйтергә телисең?— диде мөгаллим үз уйларыннан чак арынып.

— Әхәт абый безгә әкият сөйли торган иде!— Башка балалар да чак кына җанландылар.— Абый, сез, «Йом-йом йомгагым, йомарланды йомагым, куй көтүче әбекәм...»— дип башланган әкиятне беләсезме? Әхәт абый вәт шәп йомаклар өя торган иде!

— Акыллым, син миңа буржуйның ни икәнен аңлыйсыңмы?

Теге малай Мөхәммәтне аптырашта калдырып чинап көлеп җибәрде, башка укучылар да аңа кушылып көлә башладылар.

— Аны белмәскә мин җүләр түгел лә!

Мөхәммәтнең күзе шакмак булды. Әхәт, исерекбаш булса да, дөнья буржуазиясенең этлекләрен, кан эчүче сыйныф булуын балаларга сеңдереп өлгергәнме әллә?

— Безнең авылда, абый,— дип дәвам итте чая малай,— Карун Рәхмәтулланың аттан биек, кап-корсаклы үгезе бар. Мөгезләре тимер сәнәк кебек. Кем очраса сөзә дә ега. Шуны бездә «Буржуй» дип йөртәләр. Син шуны әйтәсеңме?..

Бу малай шәһәр урамында көз буе әнисе белән чынаяклап карлыган сатып чаяланган, телен үткерләгән Маннур булып чыкты...

Тәнәфестә чакта Мөхәммәтнең аптыраулы башында яңа бер фикер өлгерде: нигә дәресне туган җир белән, үзләре яшәгән өлкә белән таныштырудан башламаска? Ул үз-үзен әрләп, хәтер сандыгыннан балаларга яраклы бер-бер риваять эзләде, маңгаен учлап тәрәзә кашагасына терәлеп торды. Эзли торгач тапты...

— Балалар,— дип башлады ул сүзен. Тавышы да артык яңгырамыйча ягымлы гына чыкты шикелле.— Сез әле белмисездер, Тобол

шәһәренә житәрәк Иртеш елгасының уң як ярында Козгын авылы бар иде... Элек әнә шул урындагы таучыкта — Бицек-торада Күчем ханның айдай матур йөзле Сүзге исемле яшь бикәче яшәгән, имеш. Сүзге зифа буйлы, шомырт кара күзле, йомшак күңелле булган, ди. (Бу урында Мөхәммәт көрсенеп куйды — балаларга мондый ваклыкларны сөйләргә педагогика рөхсәт итәме икән!? Беткән баш беткән!) Тиңе булмаган бу сылуны Күчем хан Казаннан алып кайткан ди. Ул Казан ханы Моратның кызы булган, имеш. Гүзәллеге белән күпләрне шаккатырган, сылулыгы иртәнге таң нурына тиң булган Сүзге казакъ солтанының кызы булган диючеләр дә бар... Күчем хан яшь бикәченә сарай салыр өчен Сүзге-тора дип аталган калкулык өйдергән. Крепостьта Сүзгене йөзләрчә кол кызлар караганнар, аны ят күздән саклаганнар. Санайлы укчылар көне-төне күз йоммаганнар. Мәгәр Сүзге һаман ачык йөзле, тәмле телле, юмарт күңелле булып калган.

Кояш урман өстенә калыкты исә кол кызлар Сүзгене чишмәгә юындырырга алып төшкәннәр, аның йомшак тәнен тырышып юганнар, хуш исле майлар белән сылаганнар. Озын, кара чәчләрен алтын тарак белән тарап, асылташлардан ясалган чулпылар кыстырып үргәннәр. Нәфис муенына кыйммәтле муенсалар, бармакларына Бохара йөзекләре, ап-ак беләкләренә алтын беләзекләр кигерткәннәр. Ялтырак алкалар такканнар. Эссе көннәрдә Сүзге Иртештә йөзәргә яраткан. Битенә ак пәрдә каплап, баш очына ефәк чатыр корып ишкәкче яшь егетләргә тик карап бара икән көймәдә ул. Качып китмәсеннәр өчен ишкәкче егетләрне көймәгә тимер чылбырлар белән бәйләп куялар икән. Сүзге кол егетләрен бик кызганган, Күчемнән аларны бәйләмәскә сорап үтенгән. Яшь бикәчнең соравын үтәп, Күчем хан көннәрдән бер көнне ишкәкче егетләрне бәйсез генә Иртешкә чыгарган. Елга уртасына житкәч, көчле агым көймәне төрле якка чайкый башлаганда Сүзге кол егетләргә кычкырган: «Качыгыз, качып котылыгыз!» — дигән... Егетләр Сүзге ялгызы үләр дип качмаганнар. Хан бикәче ялынып-ялварып сорагач кына берәм-берәм суга сикергәннәр... Сүзге ишкәкләргә үзе утырган, чак кына көймәсе аумаган. Ишә-ишә ул ярга якынлашкан... Моны күзәтеп торган Күчем бик нык ачуланган, колларны эзәрлекләргә сакчылар жибәргән. Мәгәр елгыр егетләр йөзеп-качып өлгергәннәр... Күчем хан Сүзгене бик нык ратканга аны гафу иткән. Шул көннән башлап Сүзге дә ямьсез Күчем ханны ярата башлаган икән.

1582 елның 26 октябрендә Ермак үз отряды белән Күчемнең башкаласы Искерне сугышып ала. Күчем кача. Күчемнең жиңелүен горур хатын бик авыр кичерә. Сүзге-торага һөжүм башлангач, Сүзге калкансөнге тотып үзе сугышка чыга, сугыш белән житәкчелек итә. Өч атна каты сугыш бара. Күп гаскәр кырыла. Сүзге-торада азык бетә, су калмый. Сүзге яшь хатыннарга хас булмаган кыю бер адым ясый. Ике яктан да кан коюны туктатыр өчен ул: «Әгәр Ермакның атаманы крепостьны саклаучыларны әсир итмичә ирекә жибәрсә, без каршылыксыз биреләбез», — дигән тәкъдим белән парламентер жибәрә. Руслар аның шартына риза булалар. Тыңгысыз авыр төн үтә. Берзаман киң ачылган крепость капкасыннан исән калган сугышчылар, коллар, бала-чага тышка атылып чыга башлаган. Сүз куешу нигезендә, казаклар аларны рәт-рәт тезелеп ирекә озата торганнар. Сүзге крепостьның иң биек урынына басып күзәтеп торган. Барлык халык чыгып беткәч, крепость эченә казаклар кергән. Карасалар, Сүзге бая басып торган урынында юк! Ул яшәгән бүлмәләр дә буш икән. Бераздан мәгърур кедр агачы төбендә аунап яткан канлы гәүдәне күргәннәр. Кулында пычак, гәүдәсе буйлап кан саркыла икән... Үз башы бәрабәренә сугышчыларын, халкын саклап калган Сүзгене бик олылап Иртеш буена жырлаганнәр. Бу нәни крепостьның горур хуҗасы Сүзгегә хөрмәт йөзеннән аның үле гәүдәсен каберенә кадәр казакларның атаманы үзе күтәреп барган. Казак-

лар башларыннан авыр шлемнарын салып бу сылуны соңгы юлга озатканнар...

Аңладылармы аны балалар, юкмы?

Йөзләренә караганда аңладылар, кемдер көрсенеп куйды, ә Сәлимә елап ук җибәрде...

Беренче уку көненең дәресләре шуның белән тәмамланды. Дәрестән кайткач ашык-пошык кына ашап алып Мөхәммәт йортлар буенча йөрергә чыгып китте.

## 10

Һади бабайның оныгы Йосыф та дәрескә килмәде.

Бу йортка Мөхәммәтнең рәхмәте аерата зур: нинди кыен чакларда, йорттагы һәр кашык исәптә чакта алар Шамилне карап, өс-башын юыштырып, ашатып-эчертеп тоттылар... Һади бабайларның капкасыннан кергәндә аның күз төпләре ирексездән дымланды... Һади карт белән аның улы Сәгъдетдин балага якты чырай да күрсәтсеннәр ди... Өйдә бит үги ана! Йосыфның әнкәсе үги, ул җиде яшькә җиткәч әнисе үлеп китте. Сәгъдетдин йортка үги ана төшерде. Ачлык елны барлык туганнары үлеп беткәч, шулар исәбендә ире дә дөнья куйгач, Гыйззәтбану түти, авылдашларына ияреп туып-үскән төбәге Тәтеш өязеннән бәхет һәм ризык эзләп бәрәкәтле тук Себер ягына чыгып киткән. Сәгъдетдин белән кавышканда аңа инде утыз биш яшьләр чамасы булса да Себер калачы, Себер балыгы ашап тулышып киткән бу хатынның ике бите алма кебек кызарып-янып торган була, эштә чыныккан гәүдәсе таза, нык, аяклары гөбе-гөбе юан иде... Бәрәңге борыны астында шырпы-шырпы төкләр тырпаеп тора, йөреше дә, торышы да, тавышы да ирләргә тартым иде. Бер кычкырып җибәрсә, баш бирмәс сыерлар шым булалар... Үз-үзен якларлык булмаса, ятим хатын үз өен ташлап озын сәфәргә, җиде ят арасына чыгып китәме соң?! Сәгъдетдин исә, хатынының нәкъ киресе буларак, юаш холыклы, аз сүзле, басымчак бер кеше иде. Телне генә түгел, буйны да җәлләп биргән аңа ходай. Янәшә бассалар, хатынының култык астына керә дә бетә, җәлпәгрәк зур борыны гына күренеп кала.

Ничарадан бичара бу йортка килен булып төшкән Гыйззәтбану түти атна-ун көн узар-узмас зарланырга керешә: өйне яратмады — «тәбәнәк» диде. Ишек бәләкәй — «сандык капкачы». Җитмәсә чак элә-геп тора, ике куллап тотынсаң, каерылып та чыгачак!..

Җил булып керде килен, давыл булып түргә узды. Һади карт арт чүмечен кашып, боегып үзалдына: «Киленнең тәртәсе кыска булырга охшый!» — дип көрсенде. Йосыфның әнисен — тәмле телле, өй эчендә бизәк-күбәләк булып очып йөргән киленен сагынып еламсырап алды...

Мөхәммәт кычкырып сәлам бирде. Сәламен алмадылар. Һади бабай почмакта бик бирелеп намаз укый. Сәгъдетдин эштә иде. Ул арада кече яктан ике буш чиләк шалтыратып Гыйззәтбану түти килеп чыкты. Чыгуы булды, күк күкрәтте:

— Йосыф дим, сары урыс, нишләп почмакта каттың? Юньсез, булышмыйсың да ичмасам, чукынган тәре! Акбаш туймыйча кайткан, сөтен тибеп түктерде, хәерсез! — дип үтә әчкелтем сүзләрен сибә башлады. «Мондый телле хатынга, ай-һай, сыер сөтен бирер микән?» — дип уйлап алды Мөхәммәт һәм шунда гына Йосыфны күрде. Чыннан да, малай почмакка кереп сеңгән дә кымшанмыйча тик басып тора, бабасының намаз тәмамлаганын көтәме?

Өй эче үтә фәкыйрь, идән буйлап шар тәгәрәтеп җибәрсәң дә ул барып орыныр нәрсә юк, өстәл дә бүкән урындыклар... Шушы шәрәлек, почмакта шым гына торган, тәнендә бер чеметем ите булмаган арык

малай Мөхәммәтнең тәнен чымырдатып алды. Ничек сыйды икән аның Шамиле бу йортка, ничек яшәде? Ничек җан асрады...

— Нинди мәктәп?— дип җикеренде Гыйззәтбану мөгаллимгә.— Кулга шук, телгә явыз. Сүз тыңламый. Бушка ипи чертеп тик йөри. Аңа мәктәп түгел, сыек чыбык кирәк!... Андый балалар сука артыннан йөриләр, ә ул юньсез эт сугарудан бушамый. Җитмәсә сыер кебек тыгына, мәчкәй. Акбаш та бер, ул да бер!

Буш чиләкләрен почмакка кертеп ыргытып, җил тегермәне хәтле гәүдәсе белән бөтен өйне тутырып пыр тузган хатын итәге белән Һади бабайга да җил тидереп китте. Аның ак чалмасын чак кына бәреп төшермәде. Моңарчы үзен сүккәндә шым да итмәгән малай чәчрәп килеп чыкты:

— Тимә олатайга!

Явызлыкка каршы баш күтәргән малайга карап Мөхәммәтнең исе китте. Ул арада Сәгъдетдин кайтып керде, ишек катында чалбар тузаннарын кагып торды да ике кулын Мөхәммәткә сузды. Моңарчы давыл булып тузгыган хатын ире кайткач бераз сабырланды, аның җен кагылган күңеле тынмаганны дөбер-дөбер атлап йөрүе генә белдерә иде. Һади бабай да намаздан торып утырды. Сөйләшә киттеләр, шактый әңгәмәләрдән соң хуҗалар Йосыфны мәктәпкә йөртергә риза булып калдылар.

Сәгъдетдин Мөхәммәтне озата чыкты. «Хатының, ай-һай, явыз икән!»— дип турыдан-туры әйтергә базмады Мөхәммәт, сүзен җайга китереп кенә:

— Сезгә рәхмәтем чиксез инде, Сәгъдетдин, баламны ничә еллар карадыгыз!— диде. Сәгъдетдин, чебен куган төсле, кулларын гына селкеде.

— Куйчы, Мөхәммәт, аның ние бар? Йосыф белән бергә үстеләр шунда...

— Алай да...

— Менә теге вакытта син отрядың белән кайтып җитеп фетнәчеләрнең арт сабагын укытмаган булсаң... Мине, юашны, алар няртеп китәләр иде... Соңын уйлап бак син аның, соңын! Фетнәчеләргә әле дә көн булмаячак икән дип сөйлиләр...

Сәгъдетдиннең тавышы шыпыртланды, ул Мөхәммәткә таба иелә төшеп:

— Аларны авыллардан сөрәчәкләр ди, имеш, хакмы бу сүз?

— Ишеткәнем юк,— диде аптырап Мөхәммәт.

Алар сагаешып калдылар. Мөхәммәт Ырсытдиннәргә таба китте. Сәгъдетдиннең соңгы сүзләре аны хафага салган иде...

## 11

Ырсытдин йорты янына җитәрәк Мөхәммәт сөрлегеп туктап калды, күңелендә яшьлек хатирәләре терелеп янарды. Аның бу йортта үсмерчагы — кабатланмас кадерле еллар үткән. Монда аның Мәүлиясе яши. Кызы туганнан бирле аны кулына алып бер тапкыр да чынлап сөя алганы булмады. Ярамый. Күпме ачы уйлар кичерде ул шушы бала язмышын уйлап! Уйлары һәрчак ике канатлы — бер канаты Шамил булса, икенчесе — Мәүлия. Бер канаты алга тарта, икенчесе артка сөйри...

Теге чакта Ырсытдин тотып алганнан соң, Мөхәммәт шәһәрдә яшәгәндә урамда Йомабикә очрап: «Тартып ал мине шул аждаһа яныннан!»— дип ялынган иде... Мөхәммәт «әллә риза булыргамы?» дип уйлап та алды, инде эш кызып килгәндә генә Йомабикә, бай тормышын ташлап хәерче Мөхәммәткә яр булырга ризалашмады... Аннары аның Ташкәе бар, ул олыгайды...

Сирәк-мирәк кайткалаган чакларда Мөхәммәт Мәүлияне очратка-

лый, иелеп аны кочып аласы килә, «Кызым, җан җимешем!»— дип әйтердәй була. Ярамый...

Мәүлия бүген укырга килмәде. Килешенү буенча, ул да туганы Ташкәй белән мәктәпкә йөрергә тиеш. Өйгә керергәме, юкмы, дип икеләнеп торган Мөхәммәт кинәт ныклы дәртләнеп авыр капканы киереп ачты. Капка шыгырдавына эт авазы кушылды, көлтә хәтле койрыгын сөйрәп келәт алдыннан алабай һау-һаулап килеп чыкты. Хуҗасы Ырсытдин болдырга чыгып тамак төбе белән бер кычкыргач кына тынды эт, ырлый-ырлый оясына кереп ятты.

Монда бар нәрсә Мөхәммәткә таныш, күп нәрсәгә аның кулы тигән. Аның эзе төшмәгән бер почмак та юк бу биек койма белән коршап алынган ихатада. Эт кенә яңа, эт кенә ят!..

Ырсытдин дә үзгәрмәгән диярлек. Төксе чырай, ачуланамы ул, шатланамы — һич белерлек түгел. Чәбәләнеп беткән эре бөртекле кашлар җыерылган, аскы ирен бәлшәеп алгарак чыгып тора. Кысык чем-кара күзләр һаман элеккечә усал елтырыйлар... Һәммәсе искечә! Мөхәммәтнең яшьлегенә кара тап булып яткан теге кетәк тә исән хәтта...

Ул арада Ырсытдин, болдырдан төшеп, йөнтәс, кыска бармаклы куллары белән Мөхәммәтнең кулларын эләктереп алды һәм мәңге ычкындырмастай ныгытып кысты.

— Танымый да торам, үзебезнең Мөхәммәт икән ләбаса! Әйдә, әйдә рәхим ит.— Үзе ялт кына тәрәзәгә борылып карады, тәрәзәдә хатын-кыз шәүләсе чагылып узды. Өйгә керделәр. Өйдә җиһазлар арткан, идәнгә келәмнәр, озын ялбыр йонлы аю тиресе җәелгән. Матчадан идәнгә кадәр зур көзге сузылган, ярты потлы маятнигы арлы-бирле тирбәлгән стена сәгате күз явын алып тора, бөтен җирдә житешлек, байлык күзгә бәрелеп тора. Утырыштылар. Сүз әле бер, әле икенче якка сикерде. Ырсытдин Мөхәммәткә, мөгаллим хуҗага сынап-сынап карап алды. Йомабикә кереп тавышсыз-тынсыз гына табын әзерли башлады, өстәл ашъяулыгы җәйгәндә ул Мөхәммәт каршысына чыкты һәм ирексездән аларның күз карашлары очрашты. Йомабикәнең маңгаена сырлар тәгәрәшкән, бите куе кершән яккандагы кебек кып-кызыл, ике аяк өстенә өченчесе басып килә, хәрәкәтләре салмакланган, күзләре генә элеккечә майланып, чакырып торалар, нәзек иреннәре кыймыл-кыймыл килеп хәрәкәтләнеп кемнедер, каядыр өндиләр кебек. Чәчен нәзек кенә тасма белән үреп аркасына салган нәни Мәүлия килеп чыгып әнкәсенә булыша башлады, Йомабикә аның аркасыннан кагып куйгач, Ырсытдин көзге миләш капкан кебек чыраен сытты. Теге чакта Йомабикә серне берәүгә дә ачмады, авыл арасына хәбәр таралмады, Ырсытдин нәселендә сары чәчле, ак йөзле кешеләр мул булганга, Мәүлияне ерак бабаларының берсенә охшаттылар...

— Тач Атыш әкә булган бу!— диештеләр.

Чынлыкта, серне алар өчәвесе беләләр.

Ырсытдин белән Мөхәммәтнең әңгәмәсе җайлана гына дигәндә, ишек кинәт җилләнеп ачылып китте һәм аннан бар көченә ямьсез тавыш белән улап Ташкәй атылып килеп керде. Барлык гаиләнең коты чыгып аңа ябырылды:

— Ут чыкканмы әллә?

— Борының ник канаган?

— Кайсы явызы болай имгәтте?

Әткә-әнкәсенең иркәләү тавышларын ишеткәч, Ташкәй тагын да ныграк акыра башлады, күзеннән яшь, танавыннан беш акты.

— Йә, рәтләп сөйлә!— диде кызып Ырсытдин.

— Әнәкәй Маннур кыйнады,— диде малай ярсып.

Ырсытдиннең шеш кабаклары тагын да ныграк аска салынды:

— Шунда аның авызын җимерергә җегәрең җитмәдеме? Өйгә акырып кайтканчы тигәннең касыгына тубык белән бир, йодрык белән бавырын төй, кан саусын! дип ничә тапкыр өйрәттем?

— Сугарсың аңа... Алар икәү. Йосыф белән. Уйный идек...
— Үзең хәрәмләшкәнсеңдер әле,— дип чәрелдәде Мәүлия.

Ташкәй аны-моны әйтеп тормады, күз яшенә манчылган кара йодрыгы белән кызчыкка берне китереп тондырды. Мәүлия бер якта елый, Ташкәй икенче якта үкерә, китте тавыш, китте елаш...

Елаш кинәт тукталды, башкача игътибар итүче булмагач, малай тынды. Табын әзерләнеп бетте, хуҗа зур, бизәкле чынаякларга күздән тутырып, саргылт көмешкә койды.

— Әйдә, Мөхәммәт, исән-аман очрашу хөрмәтенә берәрне тотыйк,— диде хуҗа, чокырның сабыннан түгел, корсагыннан ике куллап эләктереп.— Аш булсын!

Хуҗа кунагының чынаяк чокырына үрелгәнен дә көтмәде, чөмереп куйды. Уразаев эчемлектән катгый рәвештә баш тартты. Авызына алганы бар, дус-иш очраганда, бер-икене каплап та куярга кулыннан килә, мәгәр монда, Яланда?! Эчкече мөгаллим Әхәтнең даны сеңеп бетмәгәндә? Бер почмактан күз елтыратып Ташкәй карап торганда?.. Юк, юк...

— Мәүлияне мәктәпкә йөртергә кирәк, Ырсытдин агай!

Хуҗа тиз генә җавап бирмәде, чокырын төбенә хәтле чөмереп бетерде, ысланган кәреш балыгы кисәге каерып алды һәм чапырдатып, ләззәтләнеп чәйнәргә керешге.

— Кыз балага ни нәрсәгә аңа мәктәп?— диде ул бераздан.— Әнә, казан, өчаяк янында әнкәсе өйрәтсен.

— Заман башка хәзер, Ырсытдин агай, укымыйча ярамый.

— Заман?— дип гаҗәпләнде хуҗа.— Заман үзгәрә дә куя ул, аны һич аңламассың... Менә син кайчандыр минем ялчым идең, ә хәзер мөгаллим! Коммунистмы?

— Беләсең бит, Ырсытдин агай.

Хуҗа артык күп сөйләшеп ташладым дигән сыман тагын бер чынаякны тутырып эчте, ияк очы кызарды, гәүдәсе алгарак иелә төште. Гүя ул, иелеп, өстәл астыннан нидер эзли иде кебек...

— Карап карарбыз,— диде, ниһаять, хуҗа кеше.— Мужыт мәктәбенә дә йөртербез.

— Ерак туганыгыз Капуш исәнме?— дип сорады һич көтмәгәндә Мөхәммәт. Бөтенләй башка нәрсә турында уйлап утыра иде, Капуш исеме каян теленә килгәндер.

— Ә, Капушны әйтәсеңме?— диде үзгәреп Ырсытдин.— Аның авылдан азып-тузып чыгып китүенә ни гомер үтеп китте! Һич хәбәр-хәтере булмады. Үлгән икән дип тә сөйләделәр. Үлгәндер, үлгәндер.

Актив фетнәче Капушны телгә алуны өнәмәде Ырсытдин, тагын да ныграк кырысланды, сүз кылдый-былдый йөри башлады.

Мөхәммәт ризык капмады да диярлек, бер бавырсакның читен сындырып алды да тик шуны авызында әүкәләп йөртте. Эчемлек тә шул килеш мөлдерәп чынаяк чокырында утырып калды. Озатырга да чыкмады Ырсытдин. Майлы кулларын чалбар төбенә ышкый-ышкый, тәрәзәдән карап, Мөхәммәтнең иплəп кенә болдырдан төшүен, туп-туры атлап, гәүдәсен төз тотып капкага якынлашуын карап торды. Эт тә бу юлы өрмәде, ул да кунакның бугазына сикерергә әзерләнгән сыман сузылып кына аның янәшәсеннән барып, капкага кадәр озатты.

Алар капка бигенә икесе ике яктан берьюлы килеп тотындылар,— ишегалдыннан Мөхәммәт, урам яктан Чырык Абдрахман. Теге якта кеше барын абайламыйча икесе дә капканы үзләренә тарткалап тордылар, мәсьәләне аңлап, Мөхәммәт көлеп җибәрде.

— Сез икәнсез, Абдрахман абзый.
— Кем дип белгән идең?
— Берәрсе шукланамы әллә димен.
— Безнең шукланыр чак узган,— диде дә Чырык Абдрахман яратмыйча башын чайкады, яратмавын яшереп маташмады. Мөхәммәт, тай-

пылып, аңа юл бирде, һәркем үз юлында булды. Алай да, бераз киткәч, Мөхәммәт борылып карады, бер-берсенә ышанып, капканы япмаганнар икән, борылып килеп, ишегалдына күз төшерсә... аны абалап каршылаган алабай Чырыкның аякларына сырпаланып йөри, иркәләнеп, аның күзләренә карап бара.

Чырык Абдрахман керүен күргән балалар күз ачып йомганчы юкка чыктылар. Ырсытдин яңа килгән кунакның сәламен исе китмичә генә кабул итте дә. Йомабикәгә борылып:

— Әйдә, карчык, самавырыңны яңартып җибәр,— диде. Хатыны самавырны күтәреп чыгып киткәч,— без дә монда яңарта торыйк,— дип, сыңар күзен кысты.

Кунак иң әүвәл ашыкмыйча гына кәвешләрен чишеп, ишек төбенә куйды, аннан кырпулы бүреген, копшыр[1] тунын чишеп, стенадагы юан чөйгә элде. Якындагы урындыкка утырып, ашыгып-ашыгып мыдыр-мыдыр нидер укынды да куе йон баскан битен җиңел генә сыпырып фатиха бирде. Аннары гына мул табынга күз ташлады.

— Дәрәҗәле кунак кабул иткәнсең дисәм...

Ырсытдин әле генә Йомабикә чыгып киткән якка төксе генә бер карап алды да чыра очы белән теш арасында казынып:

— Куйчы... Кунак дип, үзебезнең ялчыбыз Мөхәммәт кагылган иде. Мөгаллим булып кайткан икән ул!

Сүз арасында үзеннән-үзе эшләнде, Ырсытдин Мөхәммәттән калган чокырны үзенә тартты, кунагына баягы кебек үк итеп чырылдатып мөлдерәмә тулы саргылт сыеклыкны койды. Сүзсез генә эчеп бетерделәр, Абдрахман «тагын ни әйтерсең, ни яңалыгың бар?» дигән сыман хуҗага карап торды. Ырсытдин дәшмәде, чынаяк чокырларын лып тутырып эчәргә салды. Чырык ике учы белән чокыр өстен каплап саңгырау гына:

— Җитте,— диде,— сүз бар.

— Һәр нәрсә җае белән, ботка пешә мае белән. Эч! Әнә, коммунист корсагына ярамады. Безгә шәт, килешер! Әхәт мөгаллим дә башта шулай кыландырып йөргән иде, ә?!

— Әхәт башка камырдан әвәләгән иде. Пәри башка, җен башка...

— Бусын да кулга ияләндерербез!

— Ай-һай...

Чырык, җитди сүзе бар икәнен тагын бер кат сиздереп, башын чайкады. Ул арада башмакларын чожтырдатып Йомабикә самавыр кертте, чәй ясады, «ни боерасың?» дигән кебек иренә карады.

— Чыгып тор,— дип җикеренде Ырсытдин.

Абдрахман да кыстатып тормады, чи килеш коштабакка туралган кәрештән олы гына бер кисәк алды да чәйнәргә тотынды, бармак араларыннан, ирен читеннән балык каны агып чыкты.

— Уразаевтан куркып яшәргә калдымы әллә безгә? — дип сорады Ырсытдин.

— Куркырга димим...— Абдрахман тагын бер кисәк балыкны кабып йотты.— Син менә Эссәт Фәтхуллинны Тобол-торага чакырып алуларын беләсеңме? Ишеттеңме?

— Юк.

— Ник чакырганнар аны?

— Анысын да белмим.

— Кулакларны раскулачивать итәчәкләр. Син әллә Уразаевны балалар укытырга җибәргәннәр дип беләсеңме?.. Дурак. Йә, сал әле берне.

— Салган, эчеп куй.

Абдрахман эчеп җибәрде дә бераз уйга чумыпмы, тыңланыпмы, тәрәзәгә карап торды. Эт өргән тавыш килде. Ырсытдин торып тәрәзәгә карады.

— Беркем дә юк!

— Яланда байтак кешеләрне авылдан куачаклар. Һәм шуның

[1] Копшыр — үз размеры булмаган киң тун.

башында Эссәт белән Уразаев булачак. Шуның өчен җибәргәннәр аны безгә, юкабаш!

— Булмас ла! — диде Ырсытдин. Аркасына суык йөгерде, касыгын кату алды.— Булмастыр? Син гел безне куркытып киләсең.

— Менә авылда коммунистлар көч алып бара. Үзең уйлап бак: Гафур мулла шул кадәр мал-туарын тиктомалга ташлап качтымы? Колхоз дип тиктомалга авыз күтәреп сөйләшеп йөриләрме? Әхәт мөгаллимне күтәреп атып, Уразаевны тикмәгә монда җибәрделәрме? Өеңне тикшерделәрме? Як-ягына карандымы?

— Каранды шикелле,— Ырсытдин стена көзгесендә үз шәүләсен күреп куркып китте.— Күзәтергә кергәнме?

— Туп-туры Эссәткә бара да мал-мөлкәтеңне санап күрсәтә.

— Ачуым килмәгәе, авызың сүздән бушамый, сүзең сүзгә охшамый, йөрисең юкны бушка сугып. Тьфу! — дип, Ырсытдин идәнгә лачкылдатып төкергәнен сизми дә калды.

Бу Чырык Абдрахманның сүзенә ышанырга да ярамый, бер юньле эш килештергән бәндә түгел! Ата-анасы ясаклылар[1] нәселеннән, җир-сулары күп булган. Кыр-болыннарын үзләре эшкәртмәгән, сартларга арендага биреп, шуның килеренә туенып яшәгәннәр. Җир белән сәүдә иткәннәр. Эт ялкавы булып, тик ятып, аракы эчеп гомер үткәргәннәр. Җир-сулары күп, ләкин хуҗалыкларында ишәк зурлыгындагы ала биядән башка мал-туар булмаган. Абдрахман буйга җиткәч, атасы аңа өч дисәтинә җир бүлеп биргән һәм сарт нәселеннән Гөлҗамал исемле ярлы кызын алып биргән. Чырык, өйләнсә дә, ипкә килмәгән, кесәсеннән шешә төшмәгән. Хуҗалыкны тырыш Гөлҗамал үзе алып барган. Кеше-кара сүз тидерсә, «Бичәгә ике камыт кигертә белер өчен дә егет булырга кирәк!» — дип кенә җибәргән Чырык. Бер көнне шулай исереп канауда аунап ятканда, Сарбае килеп, тегенең авызын ялап тора икән. Яшьләр Чырыкның сөйләшеп ятуын ишетеп, кем белән гәпләшә икән бу дип, килеп карасалар... «Гөлҗамал! — ди икән Чырык этенә.— Ыспайлап үпче, кеше бичәләре төсле үбә дә белмисең!»

Менә шундый кеше Ырсытдин янына килеп акыл өйрәтә!.. Алай да күңеленә шик салды кунак! Мөхәммәтнең юкны бар итеп йомыш тапкан булып килеп керүен башыннан ахырынача күз алдыннан уздырды һәм кинәт...

— Әйтәм җирле Капуш турында сорашып маташа!

— Менә, менә! — дип сөенде Чырык һәм бу юлы шешәгә ике куллап тотынып чынаягына эчемлекне үзе койды.

— Ниемә кирәк булган аңа Капуш! Киткән, беткән. Тот Иртеш өстендәге дулкынны!

— Шул шул!

Нигә кәпәренә бу Чырык? Ырсытдинне өркетеп сыйланып чыгарга гына кергәнме? Әллә үз иртәгәсеннән куркамы? Фетнәчеләргә кереп киткәнен бөтен авыл белә ич... Ырсытдин сак иде, ул чакта Капушны озатып котыла белде...

— Безнең торада Уразайны белүчеләр күп икән! Колчак Тоболны алганда байтак коммунистлар белән ул да эләккән булган. Бүтәннәрне бер очтан атып бетергәннәр, ә Уразай котылып калган. Бер бөртек мамыгын да коймаганнар тегенең. Колчакка Уразай ниемә кирәк булган дип уйлыйсың? Үз товарищларын сатканга чыгарганнар аны өтерманнан! Менә шуны аңладыңмы?..

— Уразай булмаса, Ялангa башка берәүсе килмәс дисеңме?

— Яланны аннан башка берәү дә яхшылап белми. Уразайны юк итәргә кирәк, юлдан алып ыргытырга!

Ырсытдиннең сүнә башлаган күзләре очкынланып киттеләр. Нигә бу

[1] Ясаклы татарлар — патшага ясак түләүче. Җир биләгән, солдат хезмәтенә алынмый торган татарлар.

козырьдан файдаланмаска? Уразаевның койрыгына басып, Эссәтне дә шуңа бәйләп куйсаң... «Рәхмәтулла агай да борчыла иде, урманга аңа да хәбәр итеп куйсаң...» Тик Ырсытдин Рәхмәтулла белән Капушның бергә урманнарда качып йөрүен, ара-тирә хәбәр алышып та, очрашып та торуын белдермәде... Ышанып бетми ул Чырыкка! Китергән хәбәрен дә кешеләргә үзе житкерсен! Һәм ул шунда ук җаен эзләп тапты. Гафур мулла авылдан чыгып югалганнан бирле аның вазифасын өлешчә Чырык Абдрахман үтәп килә иде.

— Корбаң гаетен син укыйсыңдыр бит?— дип сорады Ырсытдин.

— Как же! — дип масайды Чырык.

— Вәгазь сөйләгәндә, җаен туры китереп, шушы хәбәрне уртага сал! Коммунистлар арасында Колчак койрыклары да бар диген...

— Әйтермен дә!— диде мие томалана башлаган Чырык.

— Соткы тарата икән дип бәйләнерлек булмасын.

Шулай дип үгетли-үгетли, кулына ярты тоттырып, Ырсытдин Чырык Абдрахманны озатып чыгарып җибәрде.

Эш арасында Йомабикәнең Мөхәммәткә күз ташлап алуларын Ырсытдин сизеп-күреп утырган иде. Уразаев ишекне япкач ук, тавыш-гауга чыгарырга иде исәбе, Чырык кереп, аның уйларын башка юнәлешкә алып китте. Йомабикәне күрүгә, уйлары яңадан монда кайтып төйнәлделәр, ул:

— Син, карабат, тагын күзләреңне майландыра башладыңмы? Инде эшне өр-яңадан башларга ниятме? Ялан урманында кырмыска түмгәге бетмәгән!

— Әткәсе, миңа кешегә карарга да ярамыймыни?

Тик тормаган тел бәла китерә, диләр. Йомабикәнең сүзе Ырсытдинне кыздырып ук җибәрде.

— Беләм мин син сөйрәлчекнең ничек каравын!

Ырсытдиннең көнчелеге килгәндә, күген болыт каплый, күк күкрәми дә калмый, бичәсе моны бик яхшы үзләштергән, дәшмәде, чәй белән мавыккан булып кыланды. Әмма тел астына ачы су йөгергән иде, чәйнең тәмен тапмады. Ире тагын котырып китмәсә генә ярар иде. Ә Мөхәммәт яшь чагындагыдан да матурланган, көрәйгән, асыл бер ир булган... Аның яшертен генә елмаюы Ырсытдиннең сизгер карашыннан кача алмады, ул:

— Гаебең булмаса, нәрсәгә дип чүлмәктәй кызардың? Тагын кычытынасыңмы, кабыргаңны санап кына калмам, берәм-берәм аерып алып бирермен, карабат!

Эшнең бик начар борылыш алганын күреп, Йомабикә агарынды.

— Әстәгыйфирулла, бу ни кылануың, карт?

Алар бер-берсенә күптәннән «карт, карчык» дип эндәшсәләр дә, бу юлы Ырсытдин бәйдән ычкынды.

— Сиңа яшь кирәкме, канчык? Өстерәлчек!

Һәм ул яшьләрдән дә болайрак сикереп бичәсенең чәченнән эләктереп алды да янтыгын төяргә тотынды. Йомабикә ыңгырашкан тавышка Мәүлия белән Ташкәй атылып керделәр һәм әниләренең ике ягына асылынып, берсе еларга, икенчесе уларга тотындылар.

## 12

Бу айсыз төндә күккә сибелеп киткән көмеш тәңкәләрнең җемелдәвенә карап сокланып, көндезге каршылыклы кичерешләр тәэсирендә акрын гына атлап өйгә якынлашканда, Уразаев үзара сатулашкан ике тавышны ишетеп ирексездән туктап калды. Себер шивәсе сизелсә дә, бу яшь тавышлар шәһәрчә, татарча, Казаннар сөйләшкән кебек бәхәсләшәләр иде.

— Шәүкәт дим...— Бусы хатын-кыз тавышы.

— Төн караңгы. Куркырсың...— Бусы калын ир тавышы.

— Өйгә егет кеше ияртеп кайтыйммы мин?

— Мин сине сагынып көткән булам тагын.

— Иртәгә очрашырбыз.

— Сания, ихлас әйтәм, сагындым.

Егет сагынганын нинди хәрәкәт белән белдерергә тырышкандыр, кыз үпкәләде, тавышы җәберсенеп чыкты.

— Кешечә кылан, Шәүкәт. Иртәгә очрашырбыз. Шунда аңлашырбыз, ярыймы.

— Аз гына тор инде.

— Хәзергә хуш булдык!

Шушы көннәрдә Саниянең укуын тәмамлап кайтырга тиешлеге турында Мөхәммәт Мөхлисә ападан ишеткән иде инде. Ул нәүмизләнеп басып калган егет яныннан сүзсез генә узып китте һәм бара-бара адымнарын акрынайтты. Бер җир буе узгач, Сания дә туктап калган иде. Мөхәммәт аның янына барып җитте һәм кызның җиргә куйган чемоданын алырга теләп кулын сузды:

— Сез Санияме?— дип сорады ул.— Чемоданыгызны алыйм әле.

— Ни хикмәт бу?— диде ярым ачуланып Сания.— Ялан авылында кавалерлар бигрәк вежливый булып бетканнәр.

Мөхәммәт чемоданны тотып өлгергән иде инде.

— Анда вак-төяк кенә...

— Барыбер. Караңгы, алда чокырлар бар, сакланыгыз.

Сания үзе белән баручының шәүләсен генә күрә, ул аннан буйга шактый биек, туры гәүдәле ят бер ир. Тавышына караганда бик яшь тә булмаска тиеш, шулай ук артык карт та түгел шикелле. Кем булыр бу вежливый кавалер?..

Кыек капка янына килеп җиткәч, Сания, аптырап, юлдашына карады: әллә өйгә үк озатмакчы инде бу сәер кеше? Каравын карады, юлдан чыгып китүе булды, капка баганасы өчен яңа казылган чокырга аягы чумып та китте.

— Әнекәчем, беттем!— дип кычкырды ул.

Мөхәммәт, кабаланып, чемоданны җиргә куйды, ике куллап кызны тарта башлады. Кулларының көчле, нык икәнен кыз аңлап алды, чокырдан чыкты һәм егылып китәм дигәндә, коткаручысының муеныннан кочарга туры килде. Йөзләре бик якын килсә дә ул Мөхәммәт Уразаевны танымады, Мөхәммәт авылда чакта Сания бик яшь иде әле, белсә дә, онытырлык вакыт узган инде.

Уразаевны фатирга кертү хакындагы хат Саниягә барып кермәгән иде, Мөхәммәтнең иңенә таянып болдырга кадәр килеп җиткәч, ул, исенә килеп:

— Рәхмәт сезгә, хәзер үзем дә керә алам,— диде.

Мөхәммәт, көлемсерәп, ишекне ачты, Саниянең канәгатьсезлегенә каршы, алар бер ачылган ишектән өйгә керделәр.

— Әнкәем, җаным, сагындым!— диде кыз.

Мөхлисә әби шәм яктысында җеп эрли иде, киндерагачын[1] бер читкә этәреп калкынды. Кызы нигә якынрак килми соң? Саниягә тагын Мөхәммәтнең иңсәсенә таянырга туры килде.

— Аягыңа ни булды, кызым? Хәвеф-хәтәргә юлыктыңмы?— дип өзгәләнде ана.

— Төзәлер!— дип җавап бирде Мөхәммәт кыз өчен.— Шулай да тикшерергә кирәк, чатнаган-мазар булмасын тагын.

Мөхлисә әби кыска-кыска гына аңлатып Мөхәммәт белән Санияне таныштырды, чоланнан аю мае алып кереп, Саниянең аягын сыларга җыена башлады.

— Шешкән түгелме, күрче, кызым!? Менә көтелмәгән җәфа...

— Мин гаепле,— диде Уразаев.— Баганаларны утыртырга бүген кул җитмәде...

---

[1] Киндерагач — идәннән матчага терәтеп куйган таяк, киндер, йон эрләү өчен җайланма.

Ана белән кызны ялгыз калдырырга кирәклеген аңлаган Мөхәммәт улы Шамил янына чоланга чыгып ятты. Аны озак кына йокы алмады. Өй эченнән Саниянең ягымлы тавышы агылып торды. Аяк бәласе белән алар әллә ни сөйләшә алмадылар, Мөхәммәт кызга юньләп, текәлеп карый да алмады. Шулай да күрде: кыяфәтенә караганда, кыз комсомолка иде — өстендә каеш белән кысып буылган яшел гимнастерка, биле нәзек, күкрәкләре йомрыланып калкып чыккан. Матур коңгырт күзләрендә гадилек балкый...

Мөхәммәт, кичтән йоклый алмый ятса да, иртән караңгылы-яктылыда уянды. Гәүдәсе җиңел, йөрәге чаптар атныкы кебек ашкынып тибә, күңел нидер көтә, эзләнә иде. Чыкты, капка баганаларын уенчык итеп уйнатып кына йөртте, кулындагы көрәккә күз иярмәде, балчык ишелеп, агып торды. Мөхлисә әби, торып чыккач, үз күзләренә үзе ышанмады: элекке череп кыйшаеп беткән баганалар урынына таза, нык наратлар кереп утырган. Җил-давылга бирешмәс юан баганага капка тимер күгәннәр белән беркетелгән. Шакылдаган тавышлар колагына чагылган иде әбинең, әмма алар аналы-кызлы таңга чаклы сөйләшеп, куанышып ятканга тавышка да исе китмәде Мөхлисәнең, әле уянгач та суйлакланып, иренеп ятты. Чыкса... менә сиңа мә! И, Сания куаныр инде! Кешеләрдән оялып, күршеләреннән читенсенеп йөри иде Мөхлисә әби!.. Түзмәде, өйгә кереп китте, Сания белән Шамилне уятып алып чыкканда, Мөхәммәт соңгы йомычкаларны тимер таска тутырып, багана төпләрендәге балчыкларны тигезләп йөри иде.

— Күрегезче, балалар!— диде ул куанып.— Яңа капкалы булганбыз бит!

Иртәнге кояш нурларында Сания тагын да матуррак булып күренде. Кыз да үсмер улы булган ялгызак иргә кызыксынып һәм бераз гаҗәпләнеп карады: шундый гәүдәсе, буе-сыны, һөнәре була торып, нигә өйләнми икән Уразаев?!

Чәй янында дүртәүләшеп тормыш хәлләрен сөйләшеп утырдылар, Саниянең шатлыгын уртаклаштылар. Укып, туган авылыңа, әниең янына фельдшер булып кайт әле! Яланнан гына түгел, тирә-як татар авылларыннан беренче медицина белгече!..

Сания кайткач, монда яшәүнең читен булачагын, фатирга башка кешегә күчәргә туры киләчәген Мөхәммәт читләтеп кенә әбекәйгә сиздергән иде, Мөхлисә әбигә бу сүз бер дә ошамады, ул кайнар самавырыннан да ныграк кызып китте.

— Сания ир-атсыз булмыни ул? Хуҗалыкта ир-атсыз буламы? Син булмасаң, җимерек җилкапка белән тагын күпме интегер идек менә?! — дип тезеп киткәч, Сания дә әнисенең сүзен куәтләгәч, улы Шамил дә сүзгә катышып: «Әти, Мөхлисә әбиләрдә генә торыйк инде!» — дип ялынгач, күчүне әлегә кичектереп торырга булдылар. «Алда күз күрер!»— дип уйлады Мөхәммәт.

Тормыш шулай башланды: иртән торып ашап-эчәләр дә, Уразаев, китаплар тутырылган сумкасын тотып, улын ияртеп, мәктәпкә чыгып китә. Сания авыл советы бүлеп биргән бүлмәсенә ашыга. Атна чамасы шулай яшәгәч, Уразаевка төннәрен дә дәрес әзерләргә кирәк була башлагач, ул күчәргә дип ныклы карарга килде. Мәктәпнең бер башы буш тора иде. Аңа булдыра алган кадәр ремонт ясап, мичен сүтеп, яңадан чыгарып, Уразаев шунда күчте. Ике кеше күчүгә бер дә ризалашмадылар: Мөхлисә әби белән Шамил. Сания аерып бер сүз дә эндәшмәде. Уразаевлар әйберләрен күтәреп яңа урынга килгәндә, ул да ирде.

Моңарчы, Уразаев барында, Саниялар йортына аяк басарга базмаган Ялан егете Шәүкәт өй бушап калган кичне үк кич утырырга килеп житте. Мөхлисә әбине юатырлык кына ниндидер сәбәп тә тапкан булды, имеш, эче авыртып тора икән... Беләкләре уйнап торган егетнең хәйләсе көн кебек ачык булса да, әби аны-моны сиздермәде, «тиздән тагын ялгыз калырмын ахрысы» дип моңсуланып уйлап кына куйды.

«Сания кайтып эшли башлаган икән!»— дигән хәбәр авылда таралса да, атна буе медпунктка берәү дә кереп карамады... дисәк тә ялган булмас. Булды, кергәләделәр, Шәүкәт кагылып үтте, башка егетләр дә берәмберәм дә, икәүләшеп тә кергәләп чыктылар, кичке уенга чакырдылар. «Гыйшык чиренә дәва буламы ул?»— дип йөдәтеп бетерделәр, күз кыстылар. Берәүсенең дә «авырыйм» дип зарланганы булмады. Сания белә: чирләсәләр, яланлылар, гадәттә, әлеге дә баягы Абдрахман янына бара, ул догалар укып, өшкереп озата, кайчагында урман авызыннан, тау ягасыннан, болыннан җыйган үләннәрен дә биреп җибәрә...

«Әллә Ялан авылында чир-чор беткәнме?»— дип, бик аптырап, ул өй борынча йөри башлады, иң әүвәл йөкле хатыннарның санын белде, аларны аерым бер дәфтәргә теркәде, «Пунктка килеп йөрегез»,— дип үгетләде. Күпләр көлделәр, күпләре ачыктан-ачык: «Дуктырдан башка да бәби таба торган идек әле»,— дип, бармаячакларын әйтеп үк чыгардылар...

Атна үтте. «Әллә Мөхәммәт абый янына кереп киңәшеп чыгыйммы?»— дип пошынып уйлап утырганда пунктка, ут кабынгандай ашыгып, җил-давыл булып, Гыйззәтбану апа килеп керде. Керде дә башы белән матчаны терәтеп, бер аягын алга чыгарып басып, көр тавыш белән сөйләргә тотынды:

— Күгәрченем димме сиңа, былбылым димме, сине уку бетереп кайткан, чирләрне дәвалый, диләр. Дөресме?

— Дөрес!

Гыйззәтбану апа икенче аягын алгарак чыгарып, кызга бер адым якынрак килде. Сания куркып урындыгын читкәрәк этәрде.

— Әле генә Сәгъдетдин абзыең аттан егылып имгәнеп куйды, наныем. Бик үрсәләнә. Йөгер безгә, бер-бер ярдәмең булмасмы.

— Кай төше имгәнгән соң? Ярасы зурмы? Кан киткәнме?

Сораштырган арада Сания кирәк булырдай инструментларын тутыра башлады. Тагын бер атлады апа һәм Сания чак кына аның ике боты арасында кысылып калмады.

— Зурмы дип, карамадым. Аю кебек үкерә мәгәр. Ярасы юктыр, ярасы булса, ул телсез калыр иде.

— Нигә?

— Каннан курка ул! Тавык та бугазлый алмый инде бичара. Әтәч бугазлауны да үзем башкарам, кешегә сиздермичә генә сарыкны да суям. «Кан күрсәм, башым әйләнә»,— ди. Ачуым да килмәгәе, ат өстендә утыра алмагач, ни пычагыма чалбар киеп йөри?

— Аты холыксыз булгандыр инде.

Сания ишеккә аркылы таяк салды да Гыйззәтбануга ияреп урамга чыкты. Чаба гына апа, өлгерә алмый Сания аның артыннан, житмәсә беркөн чокырга төшкәннән бирле аягы да авырткалап тора. Утырганда сиздермәгән иде, хәзер сызлапмы сызлый... Укыган китапларыннан «аттан егылу» фактын исенә төшерергә тырышып карады, хәтергә берни килмәде... һади бабайлар йортына житкәндә, Санияне курку хисе биләгән иде. Биләсә дә сиздерергә ярамый, аны беренче авыруы көтә, беренче ярасы...

Алар килеп кергәндә, өй тутырып кеше җыелган иде, хатын-кыз — кызыксынып, ир-ат — эш юклыктан, бала-чага хатын-кызга ияреп кәмит карарга кереп тулганнар.

Түрдә сәкедә уфылдап Сәгъдетдин ята, йөзе киндер кебек агарган, иреннәре күгәргән. Сания башта аның имгәнгән урыннарын капшап чыкты. Нечә күз аның йомшак бармакларына ияреп йөрде. Берәүләр кызыксынып, икенчеләр жәлләп, өченчеләр: «Ни кыла алыр икән бу кызыкай?»— дип мыскыллап күзәттеләр. Үз җилкәсендә аларның кайнар тынын тоеп читенсенсә дә, Сания сүз әйтмәде, карасыннар, күрсеннәр, ышансын-

нар, ул барыбер үзенекен эшләр, терелтер, ярдәм итәр.

Сәгъдетдиннең иңбашы эчкә суырылып кергән. Анатомия билгеләре буенча я каймыгу, я сыну галәмәте. Тәҗрибәсез кешегә каймыгуны сынудан анык аерып белү кыен. Каймыккан булса, сөякне урынына кертергә кирәк. Инде сынганны каймыккан дип тарта башласаң, төзәлмәслек бәла туу бар. Сак булырга кирәк.

— Сынган,— диде берәү.

— Каймыккан,— диде икенчесе.

— Валлаһи, сынган бу! — дип сүз кушты өченче берәү.

— Хафиз әкә сынганда сыер тизәге изеп сала!

— Чырык Абдрахман имли, төзәлә дә китә.

— Чырыкны дәшәргә кирәк!

Сания тикшереп чыгып, ни әйтергә белми торды да ышаныч белән:

— Сәгъдетдин абзыйны шәһәр больницасына хирургка илтергә кирәк,— диде. Кемдер артта хихылдап көлеп җибәрде. Җыелганнардан бер баш өстен булып басып торган Гыйззәтбану түти күк күкрәтеп:

— Хирур-мирурларың ни эшләтә алыр бу бичараны?— дип сорады.

— Күрсәтергә кирәк,— дип кабатлады Сания.

— Әй, аппагым, түшәк өстендә чак ятканын күрмисеңмени? Кырык чакрымлы сикәлтәле юлдан ничек үтсен ди ул? Үләчәк ул юлда, калмаячак. Инде, наныем, белмим, укыганым карга куарга да ярамый дип әйт тә, әлләниләр сүләп, безнең башны катырып йөрмә. Хәзер Абдрахман абзыйны алып кайтам!— дип пырылдап чыгып та китте.

Чалгысы ташка эләкте кызның, тигез җирдә абынды. Җыелганнар барысы да аннан көләләрдер кебек тоелды. Һәм шунда ук ул ап-ачык итеп ялгыз булуның, ялгыз эшләүнең читенлеген аңлап алды. Күз алдына нигәдер Мөхәммәт Уразаев килде. Әгәр ул янда булса, акыллы сүзе яки сабыр күз карашы белән аңа каушамаска кушар иде, егәр өстәр иде. Йосыфны Ырсытдингә йөгерттеләр. «Ул да дөнья күргән кеше, килсен»,— диделәр.

Чырык Абдрахман бик көттереп, ялындырып, күпереп килеп керде. Халыкның шактый күп җыйналганын күреп сөенде (дөресен әйткәндә, Сәгъдетдиннең кулы каймыгуын да, фельдшер кызның аңа ярдәмгә ашыгуын да авыл арасында ул тараткан иде. «Кәмит күрәсегез килсә, барыгыз!»— дип өндәп йөргән иде Чырык!).

Керде. Ашыкмыйча гына сәке янына үтте. Кемдер ашыгып аңа урындык сузды. Утырды. Шактый утыргач кына әрвахлар рухына дога укыды. Аннан, елмаеп, Саниягә күтәрелеп карады.

— Сания кызыбыз да монда икән, бәрәкалла. Гыйззәтбану, шундый укымышлы врачлар барында, кеше көлдереп, нигә мине чакырдыгыз? Юкка кузгаткансың безне, килен (ишектән кыптырдап Ырсытдин дә килеп керде). Нәрсә, Сания кызым, абзаң бик каты имгәнгәнме? Әле ярый сине укытып кайтарганнар. Нишләр идек без бичаралар? Егылып үләр идек.

Җилнең кай якка борылганын искәреп өлгергән Ырсытдин, җылаган тавышлар чыгарып, аны куәтләде:

— Ие, ие... Эшләребез харап иде!

— Инде нишләргә ниятлисең, кызым? Әйт акыллы сүзеңне!

— Әйт, әйт,— дип тәкрарлады Ырсытдин.

— Кичекмәстән хирургка күрсәтергә кирәк.

— Шулай укмыни?— дип сузды Чырык.— Яле без дә карап карыйк алайса.— Ул Сәгъдетдиннең ай-ваена куймыйча имгәнгән кулны ары-бирле каерып карады, сөякләргә басып капшап чыкты.

Иренең баш очында чүмәлә булып утырган Гыйззәтбану каркылдап алды:

— Йә, ничек, Абдрахман абзый?

— Хәле авыр,— диде Чырык. Моны ишетеп, Сәгъдетдин тагын да катырак ыңгырашты. Аның маңгаена кулын куйган Ырсытдин бик җитди итеп:

— Үлә бит, үлә. Әнә, маңгае да суына башлаган!— диде.

Сания шул чакта гына аларның үзеннән көләргә җыенуларын аңлап алды. Тик ничек итеп хәлне җиңеләйтергә? Нишләтергә?..

Гыйззәтбану ындыр табагы хәтле алъяпкычы белән күз кырыйларын сөртте, каш-керфекләре онга буялып калды.

— Өйдә генә терелтеп булмасмы? Хәле шулай ук өметсезмени?— диде ул да йомшап.— Бәлки, бер җаен табарсың? Сәдакасеннән тормас идек.

— Булмый,— диде Абдрахман кистереп,— әнә, ишетәсеңме, духтырыбыз нәрсә ди? Кешегә яхшылык кылам дип башымны төрмәдә чертәсем килми. Ачуланма, Гыйззәтбану килен. Намысым саф калсын, дим. Авылдагы кайберәүләр сыман кара эшләремне яшереп йөрмим.

— Бар бездә андыйлар, бар,— дип куәтләде аны Ырсытдин.

— Кулын саклап калыйк дисәк, больницага озатырга кирәк,— дип кабатлады Сания.

— Тыңлама аны, Абдрахман абзый, белгәнеңне эшлә!

— Юк, килен, им-том белән шөгыльләнә дип, Уразаев белән Эссәт ишетеп калсалар, көн күрсәтмәсләр. Үзләрен белмәсләр... Башымны ашарлар! Алар шуны көтә дә!

— Менә икмәк: әгәр берәрсенә сине җәберләргә бирсәм, ходай орсын!— Гыйззәтбану икмәк күтәрде.

— Тәвәккәлләп тотынып карыйкмы әллә, Ырсытдин яшьтәш?— диде Чырык. Аның күзләре канәгатьлек белән яналар иде.— Булмаса, ходайга тапшырыйк.

Абдрахман бик җитди кыланып башта догасын укыды. Дога тавышына Гыйззәтбану елый ук башлады. Иң өсләре, күкрәкләре җир тетрәгәндәге бәләкәй таулар кебек калтырадылар.

Чырык Абдрахман халыкка ишеккә табарак күчәргә боерды, ике җиңен дә әйбәтләп сызганды, «ыһ» та «ыһ» килеп яткан Сәгъдетдиннең култык астына йон оеклы аягын китереп терәде, авыруның кулын Ырсытдин белән бергә эләктереп алып, тарта башладылар. Сәгъдетдиннең акыруын Иртешнең теге як авыллары да ишеткәндер. Гыйззәтбану, сикереп торып, башы белән түшәмне тишеп чыгара язды, түбәсе таш кабак хәтле кабарып чыкты. Бала-чага куркынып этешә-төртешә өйалдына бүселеп чыкты. Авыруның иңбаш сөяге «шылт» итеп купкан урынына кереп утырды. Сәгъдетдин дә «уф» дип киң бер сулыш алды. Бераздан җиңеләеп су сорады. Күзен ачты. Су эчәргә торып утырды.

Кулы хуҗасының теләгенә буйсына — күтәрелә дә, төшә дә башлады. Әле генә үләргә яткан кешенең аякларын салындырып, сәкедән төшәргә маташуын күргәч, кешеләрнең исе китте, алар Абдрахманга куркып карадылар: «Изге җан! Изге адәм!»— дип пышылдады арттан берәү.

Сәгъдетдин өчен эчтән куанса да, Саниянең хәле мөшкел иде. Ул ничек чыгып киткәнен дә, медпунктына кайтып егылганын да хәтерләмәде. Бетте, дип уйлады ул көенеп, моннан ары берәү дә Санияне санга сукмас. Каян җаен китереп борынына чиртте әле бу Чырык?.. Тәвәккәлләп тотынса, Сания дә кулны урынына утырта ала иде бит!

Хәбәр, әлбәттә, сәгате-минуты белән авылга таралып өлгерде. Чырык Абдрахман белән Ырсытдин, Гыйззәтбану түтинең симез каз бойын кимереп, түрдә утырганда, Сания медпунктның ак җәймә каплаган, әле беркем дә утырып карамаган кушеткасына йөзтүбән авып, ачы күз яше түгә иде.

Икенче көнне, белепме-белмичәме, пунктка Шәүкәт килеп керде. Кызның юаш кына башын иеп утыруын үзенчә юрады, аяк очларына гына басып, Саниянең артына килеп басты, ике кулы белән күзен каплады. Дәшми Сания, кымшанмый да, берзаман бармак араларыннан күз яше ага башлагач кына Шәүкәт кызның хәлен күрде. Күрде, аңламады.

— Иртештә су ташый торган чак түгел!— дип шаяртырга маташты.

— Иртештә кайчан су ташый соң?— дип кырысланды Сания.

— Беләсең ич!

— Аны белмәгән кеше юк, кеше күңеле кайчан тулып ташыганны аңласаң икән син.

— Сания!
— Аңламыйсың, аңламыйсың!
— Син ул мине аңламыйсың һәм аңларга да теләмисең!
Сүз ялганмады, Шәүкәт, үзенең «көтелгән кунак» түгеллеген сизенеп, озакламый чыгып та китте.
Ике көннән соң да медпунктка беркем дә «чирлим» дип килмәде. Ә ишеттерделәр: бизгәк авыруы белән хасталанган Гайникамал кортканы Чырык Абдрахман караган да, Гайникамал кичә урам себеркесе кочаклап чүплектә салкында яткан, бүген, авыруы көчәеп киткәч, Чырык тәкъдиме белән аны үлгән елан кочаклатып йоклатканнар. «Хәле гел аруланды!»— дип сөйлиләр икән...
Ары сугылды Сания, бире бәрелде, барып, әбинең хәлен белер иде, ишектән үк кертмәсләр дип курыкты!..
Шулай бәргәләнеп йөргәндә, аның янына Мөхәммәт Уразаев керде. Сәлам алыштылар. Мөхәммәт, урындык тартып, тәрәзәгә күзен атып утырган Сания янына килеп утырды. Сания, яшьле күзләрен яшерер өчен, аның кулына капланды һәм ике куллап муенын кочаклап алды.
— И Мөхәммәт абый, Мөхәммәт абый!
— Чү, чү, Сания!
— Соң, нишлим? «Корыган сазга сукыр кәҗә, таш мәчеткә агач мулла дигәндәй, Мөхлисә кызы да доктор булган!»— дип көлеп сөйлиләр бит.
Мөхәммәт йомшак кына итеп тамагын кырды, елмаеп:
— Сөйләсәләр!— диде.— Сөйләсеннәр.
— Ышанмыйлар бит, шуңа сөйлиләр.
— Миңа ышандылармы? Беренче көнне дәрескә бер уч бала килде. Атна-ун көн классны җыя алмадым.
— Ә сез нишләдегез? Ничек эшли алдыгыз? Ничек башладыгыз?
Мөхәммәт көлеп үк җибәрде:
— Ә мин аларга Сүзге ханша турында риваять сөйләдем. Икенче көнне балаларым кушуч булды, аннан тагын арта тордылар. Бер-берсенә: «Әй, анда мөгаллим йомак арты йомак сөйли икән!— дип хәбәр җиткерделәр.
— Авыл халкын җыеп, мин дә әкият сөйләп күрсәтиммени?
Мөхәммәт маңгаен җыерып уйланып утырды.
— Сиңа, Сания, могҗиза күрсәтергә кирәк.
— Могҗиза?!
— Әйе... Авыллар караңгы... Кешеләрнең күңелләре якты булса да, әлегә аңа дин пәрдәсе, ырым-шырымнар пәрдәсе корылган. Чырык Абдрахман тарата хәбәрләрне, беләм... Нигә таратмасын? Дәүләтша әкә корткасы Гайникамалны бизгәк хастасыннан коткарам дип бер сарык бәрәннәрен алып киткәнме? Киткән!
— Могҗиза ясый алмыйм шул,— диде Сания үртәлеп.
— Карап карарбыз,— дип хәйләкәр елмайды Уразаев.
...Икенче көнне таң белән Эссәт Фәтхуллин Чырык Абдрахманнарга барып керде. Балык аулары хәстәрләп ихатада йөргән Чырыкның тез буыннары калтыранды, чырае көл төсенә керде.
— Абдрахман,— диде Эссәт көч-хәл белән эчен уып,— ярдәм ит, үләм.
— Ни булды, Эссәт әкә?
— Төне буе улап чыктым, синең катыңа килергә яхшысынмадым. Эчемнең авыртмаган җире юк, уңнан да сызлый, сулдан да авырта, өстән дә талый, астан да йолыккалый.
Чырык сөенергә дә, сөенмәскә дә белмәде: чынын сөйлиме соң бу Эссәт?.. «Им-том итмә!»— дип, очраган саен кисәтеп килгән совет рәисе үзе тәгәрәп килгәнме? Чын булырга охшый, Эссәтнең авыз читләрендә күбек, төсе калмаган, ике кулы белән эчен кысып тоткан, күзеннән нур качкан. Хәзер шунда, ишегалдында ятып җан бирер диярсең! Абдрахман башын чөеп, тирә-якка карады, артистлар тамашачы алдында гына чын

хәлгә керә алган кебек. Чырык Абдрахманы да дәвалау вакытын, дәвалау чараларын халык алдында башкарырга ярата иде. Иске шаманнардан калган идеме аның бу гадәте, тамашачылар барында гына ул кызып, үзгәреп бетә, уйный, кылана, ышандыра... Ә монда беркем юк. Хатыны да карап тормый ичмасам!.. Эссәт аның саен ныграк ыңгыраша, дугадай бөгелеп, авызыннан көч-хәл белән ялыну сүзләрен чыгара.

— Синең кул шифалы диләр... Коткар...

Өйгә алып керде Абдрахман Эссәтне, түренә яткырды, өс-башын салдырып, күлмәген чишеп, ябык корсагын уып-уып карады, белгән догаларын укыды.

— Ничек?— дип сорады ул өметләнеп.

— Хуже!— дип ыңгырашты Эссәт.

Тиз-тиз генә самавыр куеп, матчага кыстырган тузанлы үләннәрен ваклап кайнар суга салды, тондырды, сөзде, нидер мыдырдап Эссәткә эчертте. Үлек төсе ныграк керә барган рәиснең сулышы өзек-өзек була башлады.

— Ничек?

— Үләм...

Хәзер Абдрахманның хәле китте: әгәр рәис аның сәкесенә ятып җан бирсә... Авыл арасында моны яшереп кала алмассың... Берәр җиргә гәүдәсен илтеп ташлар иде, аның монда таба килүен, мөгаен, күреп калганнардыр. Семьясына да «Абдрахман катына барам»,— дип әйтеп киткәндер... Менә бәла! Менә җәфа!.. Үләр, торадан докторлар килеп, алып китеп ярып карарлар, эчennән Абдрахманның Ялан кешеләре корсагына яраган үләннәре килеп чыгар... Элек рәхәт иде ичмаса... Туа, куаналар. Үлә икән, «язмыш» диләр, «алла үзе бирде, үзе алды», диләр. Чырык Абдрахманга хәтта күрше авыллардан килеп йөриләр иде. Ярлы-ябага гына түгел, урта хәлләләр дә килә, муллаларны да дәвалаганы бар аның, бер чакны хәтта Казаннан кунакка килгән хаҗины да терелтеп җибәрде. Бу коммунист дигәннәренең йөрәге уң якта булып, җаннары әллә икенче төрлеме?

Чырык чоланнан савыты белән бал алып кереп, ярты чокыр бал, яртысына җылымса су салып эчертеп карады. Эссәт сыңар күзен ача төшеп: «Тагын бер чокыр ясап бир әле монысын, җиңеләя төште кебек»,— диде. Абдрахман сөенеп чокыр тутырып диярлек бал тутырды, эчертте. Эчеп тә бетерде Эссәт, тәгәрәп капланып та китте:

— Үләм!..

Көн яктырды, урамда мал-туар куучы, кычкырып сөйләшүче адәмнәр күренде. Һәм гомердә бер тапкыр да врачка күренмәгән, «Докторга күренү безнең мөселман халкына гөнаһ!»— дип тәкрарлап килгән имче Абдрахман, көпә-көндез, җитәкләп, култык астыннан күтәреп Эссәт Фәтхуллинны медпунктка алып килде. Алдан ук әзерләнеп торган Сания аны ак җәймә каплаган кушеткага яткырды, температурасын үлчәде, тимер чүкеч белән тезенә суккалады һәм:

— Әгәр ун минут килми торсагыз, үләсе икәнсез, Эссәт әка!— дип, дару эчертеп, су йоттырды. Ун минут хәлсез ятканнан соң Эссәтнең башта бер күзе, аннан көттерреп кенә, икенчесе ачылды, торып утырды, бал ашап туйган икән, байларча кикереп җибәрде.

Абдрахман сөенеченнән нишләргә белмәде: «Котылдым, бәладән котылдым!»— дип укына-укына, өенә кайтып китте.

«Яңа кайткан дуктырның кулы бик шифалы икән»,— дигән хәбәр дә шул көнне үк авыл арасына таралды. Җиделе лампа кабызган пунктта кичен, ак җәймәләр белән капланган кушеткага утырып бер кеше эчен уа-уа көлә иде. Сизенгәнсездер, бу кеше — мөгаллим Мөхәммәт Уразаев булып, кыз белән килешеп, Чырык янына Эссәтне ул җибәргән иде, рәис белән репетицияләрне дә ул ясаган иде.

— Мөхәммәт абый! — диде кыз, Уразаев көлеп туйгач.

— Нәрсә, акыллым?

— Әле ярый сез булдыгыз! Рәхмәт сезгә!

Мөхәммәт җавап урынына аның ике кулын кысты һәм үзенә таба тартты. Кыз тайчанмады, үзе дә якынрак килде һәм Мөхәммәт абыйсының — «коткаручысының» ике битеннән үбеп тә алды.

Озакламый Өннә апа белән Туктасын әкәнең уртанчы кызлары Сәлимә кинәт авырып китте. Укшыды, коса башлады, температурасы күтәрелде. Ашыгыч рәвештә мәктәпкә Саниянe чакырып алдылар. Ул килгәндә, Өннә дә, Туктасын да бала янында иделәр. Бу юлы Сания диагнозны тиз һәм кискен рәвештә куйды.

— Сәлимәдә сукыр эчәгесе авыруы. Аны кичекмәстән торага озатабыз! Операция кирәк! — диде.

Соңгы сүзләрен әйткәндә, ул ышаныч белән Уразаевка карады. «Операция» дигәнне ишеткәч, Өннә апа кычкырып елый ук башлады һәм иренең чачакланган иске чикмәненең җиңеннән тарткалады:

— Кызыңны туракларга җыеналар, ишет. Юк, ирек бирмәм! — дип тәтелдәргә тотынган иде, ире, ирлеген сиздереп:

— Шыңшыма, больницага илтәбез диләр сиңа! — дип, аны бүлдерде. Сәлимәне Тоболга илттеләр, операциясе уңышлы узып, ун көн дигәндә, кызчык сәламәтләнеп, көлеп-шаярып әйләнеп тә кайтты. Бу хәл дә Саниянең абруен нык күтәрде, хәзер хатын-кызлар гына түгел, ир-атлар да, андый-мондый хәл булганда, турыдан аның ишеген шакыйлар иде...

## 14

Егерме беренче ел дәвамында тайга урманнарында хөкем кылып йөргән бандалар тар-мар ителгәч, кулак коткысына бирелеп, фетнәчеләргә, сәнәкчеләргә кушылып киткән ярлы-ябага, байтак вакыт урманнарда качып-посып йөргәннән соң, берәм-берәм авылларына кайтылар да песием булып кына яши башладылар. Совет власте аларның гөнаһларын кичерде, власть вәкилләре аларның кайтып керүләренә игътибар да итмәгән төслерәк кыландылар: «Кайттыңмы?» «Кайттым». Тавыш түбән, күзләр җирдә, тез буыннары дер-дер... «Яхшы иткәнсең». «Рәхмәт». «Күптән кирәк иде». Тирән көрсенү. Үкенү. Кыйналу, курку. Гаиләләрдә шатлык, авылларда сөенеч. Урманга барырга, ауга чыгарга куркалар иде... Хәзер тынычлык килә, чын тормыш кайта...

Фетнә башында торып җитәкчелек иткән, куллары гына түгел, күңелләре дә каралган башлыкларның байтагысы закон алдында тиешле җәзасын алды, кайберләре исә төрле ярык-тишекләргә кереп яшеренде, көнгә чыкмас, күзгә күренмәс булдылар. Карун Рәхмәтулла, үзе кебек берничә ерткычны ияртеп, болан үтеп керә алмаслык тыгыз тайганы ерып чыкты һәм очсыз-кырыйсыз сазлар аша узып, гомердә адәм басмаган утраучыкка барып урнашты. Шунда үрдәк-кош, балык мыж килеп кайнап торган күл буенда качкыннар землянка кордылар. Урманнан кешмал[1], тиен, ас, пошый аулап көн күрә башладылар. Саздагы торнакүз[2] не кышын-җәен көрәп җыйсаң да бетәрлек түгел иде. Качкыннарны шырпы, тоз, икмәк юклыгы гына җәфалады. Тора-бара анысын да таба башладылар. Бер-ике елдан нарталар җайладылар, эт үрчеттеләр. Шуларны җигеп, ялган документлар ясап, кешмал тиреләрен төяп, Урал якларына ерак сәфәрләргә чыгып киттеләр. Кайда мал алмашып, кайда урлап, кайда талап үз кирәк-яракларын юнәттеләр. ГПУ кешеләре аларның барлыгын белсәләр дә, тиз генә эзләренә төшә алмадылар. Рәхмәтулла үз кешеләрен нык тотты һәм саксыз адымнар ясамады. Канталыев та алар арасында иде. Берзаман ул зарыга башлады, ябыкты, ашаудан калды. Тәмам күк ял усал бүрегә әйләнде. «Әллә җанын кыеп ыргытыргамы?..»— дип тә уйлады Рәхмәтулла, кеше үтереп туйган күңеле Канталыевны җәлләде, документлар юнәтеп, аны еракка озаттылар. Ул

[1] Кешмал — соболь.
[2] Торнакүз — мүк җиләге.

Урта Азия якларына барып чыгып, сарык тиресе ябынып, чыраен битлек белән каплап, совет органнарында эшләде. Беренче булып кул күтәрде, эшкә иң алдан килде, иң арттан китте, заемга да иң күп язылган кеше шул иде...

Кыйшык Капуш гел-гел Рәхмәтуллага буйсынып яшәргә теләмәде, башта бил бөгеп, ул кушкан җиргә барып йөрсә дә, соңра баш бирмәде: иптәшләре янынннан качты. Биш этне, нартаны алып качты. Авылга якынлашканын белгәч, нартасын яшереп, этләрен бугазлап, тирән чокырга күмде. Саз ягы авылларының берсенә барып, тол хатынга йортка керде, күп вакытын ялгызы — йә күлдә балык тотып, йә урманда поши эзәрлекләп үткәрде...

Әле күптән түгел генә ул аудa бер пошины яралады. Поши, канлы эз калдырып, ешлыкка кереп калды. Капуш мондый ризыкны кулдан ычкындырамы соң, мал кадерен белә, җанварны эзәрлекләп, шактый озак барды. Төн җитте. Иртән тагын поши эзенә төште. Капушның хәле калмады, әмма комсызлыгы аны һаман алга куды. «Менә җитәм, менә җитәм!»— дип бара торгач, ул Кара елга ягына килеп чыкты. Борынына төтен исе килеп бәрелде. «Кемнәр булса да булыр»,— дип тәвәккәлләп, төтен исе килгән якка барды, хәле беткән иде, карыны ач иде, кайнар чәй йотып хәл аласы да килде...

Күзгә күренмәслек урында салынган алачыкка якынлашканда, аны һау-һаулап этләр каршылады... Учак янында ул эзәрлекләп килгән пошиның мөгезе генә тәгәрәп ята иде... Учак өстендәге корымлы казанда богыр-богыр ит пешә.

Сунарчылар белән күрешим дип, алачыкка барып керсә, түрдә тирләп-пешеп, Карун Рәхмәтулла чәй эчеп утыра. Йөрәге жу итеп китте Капушның, мылтыгын сул кулдан уңга күчерде. Теле бетеп, ни әйтергә белми аптырап торганда, ике ягыннан ике мылтык көпшәсе сузылды. Рәхмәтулла сакчыларына чыгып торырга ишарә ясады.

— Иске дус белән очрашуга кем шатланмас? — диде ул ясалма елмаеп.— Әллә сотник Рәхмәтулланы дус дип санамыйсыңмы хәзер?

Кара тун кигән, бөтен битен бөдрә йон баскан сотник аңа, акылын җуеп, кышын да тайга җимереп йөргән аю-шатунны хәтерләтте. Рәхмәтулланың шәфкатьсезлеген белгәнгә: «Әҗәлкәем шушы икән!»— дип уйлады Капуш...

— Азатлык армиясе десятнигы Капуш! Мин сине җәннәттә хур кызларын кочып ятасыңдыр дип уйлаган идем. Этләр, нарта урлап качкан кешене ходай хәзрәтләре туп-туры оҗмахка керткәндер дип белдем... Иске дусларны оныттың дамы? Коммунистларны байтак кырдың, урының оҗмахлы булыр!

Чәй түгел, самогон эчеп утырган икән Рәхмәтулла, күзләре калайланды, сүзләренең рәте-чираты югалды. Мондый хәлдә аның катында булу тагын да куркынычрак иде. «Бер аякны җиргә, икенчесен бөгелгән агачка бәйләп урталай өзәчәкләр!»— дип уйлады Капуш.

Һәм аның дуамал башында бер фикер туды:

— Ваше благородие, без кечкенә кешеләр, җәннәттәге урынны олырак чиннарга бирергә дә риза! — дип, мылтыгын Рәхмәтуллага төзәде.

— Смирно! — дип акырды сотник.— Симез бичә куенында күгәреп ятып, тәртипне онытып бетергәнсең! Яңадан исеңә төшерер өчен сине стенага терәргәме, әллә ГПУга озатыргамы? Иртештә бәкегә коммунистларны ничек тутыруың турында сөйләп бирерсең!

— Ул чагында сотникка да алтын тәре бирмәсләр! «Батырыгыз!»— дип кем кычкырган да «Бетерегез!»— дип кем боерган?

Сүзсез генә Капуш артына килеп баскан ике бәндә җалт итеп аның мылтыгын каерып алдылар.

— Йә, нишлибез? — диде Рәхмәтулла.

— Господин сотник...

— Сөйлә, Капуш, сөйлә.

— Мин сезгә ни зарар кылдым?

— Ни файда китерден? Ул бичә кочып ятсын, ә монда... Сөттән ак, судан пакь булып күренәсең киләме? Качып язмышыңнан котылырга теләдеңме, азатлык армиясе десятнигы Капуш?

Рәхмәтулланың байтактан яңа кеше күргәне юк иде. Капуш та яңа ук түгел, алай да ул тегеннән, авылдан килгән... Анда яшәгән! Ишеткән! Нидер күргән! Белгән... Ашаган-эчкән, хатынын кочкан... Ә монда... Карун Рәхмәтулла... Сотник Рәхмәтулла черкиләргә азык булып ничә еллар интеккәндә, ул анда...

«Чыннан да асып куяргамы әллә үзен?»— дип уйлады Рәхмәтулла. «Миңа да, иптәшләргә дә күңелле тамаша булыр иде. Бүтәннәргә сабак булсын өчен учакка бәйләп салып кыздырыргамы әллә дуңгызны?»

Бер минуттан Рәхмәтулланың кызуы сүрелә төште, ул байтактан үзләре катнашкан эшнең өметсез икәненә ышана башлаган, бу нигезле шик-шөбһәләрен соңгы юлдашларыннан тырышып-тырышып яшереп килә иде. Капуш хәзер аның тозагында. Теләсә ул аны куырып ашый, теләсә асып куя ала, һәммәсе аның иркендә. Соңгы айларда гына түгел, еллар буе сотникка үз иркен күрсәтергә җай чыкмый тора иде. Моңарчы язмыш аларның һәммәсенә хуҗа булып торса, бүген ул Капушның язмышына хуҗа. Тулысынча хуҗа. Берәүнең язмышына хуҗа булып алу — Рәхмәтулла өчен бәйрәм, тантана...

Ул сүзсез генә Капушка эчемлек салып бирде... Фу, сасы...

— Безгә Ялан белән элемтә кирәк,— диде ул кинәт.— Барасыңмы?

— Господин сотник, кемнең үзе теләп буар елан авызына кергәне бар?

— Алайса, элемтәче итеп кемне тәкъдим итәсең?

— Нигә сезгә элемтәче? — дип сорады Капуш кыеп.

— Минем анда башкарасы эшләрем калган,— диде Карун.

— Хәзер ау вакыты. Сунарчылар һәммәсе урманда.

— Кем? — диде бәбәген терәп Рәхмәтулла.

— Сәмукны очрата алсам гына инде...

— Очрату гына түгел, аны элемтәче булырга мәҗбүр дә итәсең. Син теге, сугышта чакта, эләккән бер чүпрәкне капчыкка тутырып, үлекләрнең малын җыеп йөргән Сәмукны әйтәсең инде?

— Шуны.

«Уйлаган алга килә»,— диләр. Ялан ягына тартылып өч көн йөрдеме икән, Капуш, Сәмукны очратып, Рәхмәтуллалар алачыгына алып кайтты. Теге пошиның яртысын аңа бирделәр. Куш көпшәле «Зауер» мылтыгын бүләк иттеләр, итәген патрон белән тутырдылар. Рәхмәтулла үз иценнән салып аңа тун да бирде. Болар өчен Сәмук туган анасын да сатып җибәрергә әзер кеше иде.

Башта ул авыл хәлләрен бәйнә-бәйнә тезеп чыкты. Аның һәр сүзен ике кеше — Карун Рәхмәтулла белән Капуш йотылып тыңладылар. Хәзер дәүләткә икмәк тапшыру кызу рәвештә бара икән. Планы тулмаган өчен Сәмукның үзен дә авыл советына ике тапкыр чакырганнар.

— Рәисе кем?

— Һаман шул Эссәт Фәтхуллин.

Капуш белән Рәхмәтулла теш шыгырдаттылар.

— Ырсытдин ни хәлдә?

— Аңа да каты задание бирелде. Аны авылдан сөрәләр икән дигән хәбәрләр бар.

— Ә минем йорт?

— Аны мәктәп иттеләр. Бер башында мөгаллим яши.

— Кем?

— Мөхәммәт Уразаев.

Рәхмәтулла белән Капуш ыңгырашып алдылар.

— Колхоз оештыралар.

— Анысы ни-нәрсә тагын?

— Бөтен нәрсә уртак була икән. Җир-сулар, урманнар, диләр. Бу юлы алачыктагылар һәммәсе улап куйды.
— Ай-һай!..
— Эссәтне колхозга баш итеп куймакчылар.
— Ә халык ни әйтә, халык?
— Крестьяннар сагаеп нидер көтәләр. Күпчелек сыкрана, атларны уртак итәселәре килми. Фәтхуллин белән Уразаев бутый хәзерге дөньяны!
— Тереләй суялар, валлаһи! — диде сотник Рәхмәтулла, аның каты тешләүдән иреннәре кан иде.— Нишләтәләр, ә?!
Калын тактадан балта белән юнып кына ясаган авыр өстәл өстендә аның йодрыгы биеде.
— Җитте! — диде ул.— Сасы алачыкларда сигез ел яшеренеп яттык, бет симерттек! Күптән эшкә керешергә вакыт. Менә шул хәл — колхоз төзү безгә булыш итәчәк. Кемнең үз малын уртак итәсе килсен? Уртак малны эт җыймас! Сәмук!
— Мин нишли алам?
— Чебен җаның өчен курыкмасаң — икмәк тапшыру планын өзә аласыз. Икенчедән, Ырсытдин агайны ничек тә авылда калдырырга кирәк. Ай, кирәк! Ул монда яшәсен. Монда! Уразаев белән бетле баш Эссәтне күздән ычкындырмаска! Кая бару-кайтуларын безгә хәбәр итеп торырга. Без бүгеннән Яланга якынрак урманга күчәбез. Сәмук, безне сатарга уйласаң — беттең. Безгә хәзер адәм башы — ике тиен бер акча. Йомшак урының белән очлы казыкка утыртырбыз. Арзанга да төшәрсең, тәмле дә булыр әҗәлең.
Сотник, бу урынга җиткәч, Капушка да бер карап алды.
— Саксызлык белән эләгә калсаң... син безне белмисең, без — сине. Надан мин диген, аңгыра, диген... Юкка калтырама, Капуш. Шәп көннәр килә! Крестьянны колхозга куа башлагач, совет власте үзеннән-үзе таркалачак. Без Рәчәйдә — крестьян дәүләтендә яшибез. Барысы да яхшы булачак. Сәмук, курыкма: яхшы эш күрсәтсәң, онытмабыз, буш итмәбез. Аңлашылдымы, әфәнделәр?
Аңлашылмаган кая!
— Ә мин, господин сотник? — дип сорады Капуш.
— Син әлегә монда калып торасың.
Бу юлы Капуш тешләрен шыгырдатты, сотник Рәхмәтулла ишетмәслек итеп кенә шыгырдатты.

## 15

Ялан авылы кешеләре сыерларын җәй көне генә көтүлектә йөртәләр. Кырдан игеннәр җыелып алынды исә, хайваннарга кыр капкалары ачыла, аларны ирекка җибәрәләр. Һади бабайларның Акбашы — авылда иң качкын, иң тәртипсез, иң усал сыер. Капка ачылмый торса, җимереп тә чыга алган бу юньсез мал, күзгә кергәч, бөтенләй азынып китә. Ул гизгән басу-кырларның читенә чыга алмассың! Йөри-йөри Акбаш, мичкәдәй корсагын шыплап тутырса, җайлы бер урынга ята да күшии бирә, өйгә кайту турында уйлап та карамый.
Йосыфка эш өстәлде, дәрестән кайтып, аннан-моннан гына капкалый да Акбашны эзләргә чыгып йөгерә. Һәркөнне яңа сукмак салган бу юньсезне тиз генә табармын димә, интегә малай, җәфа чигә, караңгыда чыбыклый-чыбыклый Акбашны алып кайтып яба да дәрес карарга да көче калмастан урын өстенә ава.
Себердә октябрь ае гел яңгырлы була, бүген дә куе төтенгә охшаган авыр болытлар тау башындагы агачларга тияр-тимәс тирбәлеп түбәннән уза торалар. Авыл урамнары кара боламыктай балчык белән тушәлгән, җайсызрак бассаң — итекләреңне тартып чыгара алмассың. Ул ындыр артлатып урманга барып керде. Саргайган абагаларга кунган тамчылар аның чалбар тезләрен сыгып алырлык чылаттылар. Тал-тирәк

ләргә сарган тамчылар шыбырдашып якасына коелдылар, чиркандырып, өшетеп, калак сөякләренә, аркага үттеләр. Ары чабып, бире йөгереп узган малайның кайнар арка тире, суык яңгыр белән бергә кушылып, бөтен киемнәре лычкылдык су булды. Ул:

— Акбаш! Акбаш! — дип инәлеп Мишән түбе дигән урманга атлавын дәвам итте, соңгы кичләрдә юньсез Акбаш шунда утлап йөргәли иде.

Урман авызында бик тиз караңгы төште, күз бәйләнә башлады. Чунайдан Юкәле утравына күчкәндә, түмгәктән аягы таеп китеп итек кунычы боздай салкын саз суын сосып алды. Туңудан тешләре тешкә тиеп биеште. Барды да барды малай, «Акбаш, Акбаш!»— дип чакырганы көчсезләнгәннән-көчсезләнде, сискәндереп, вак-төяк урман җәнлекләре кыштырдап чабып узды. Барды, барды — үзе үткән эзләргә кире төште. Бу аның адашу галәмәте иде. Төнге салкын кырау куна башлады, уң итегенең черек табаны төпкә эләгеп каерылып төшеп калды. Тишек оектан бармаклар килеп чыкты. Туктап хәл алырга, юлны эзләргә кирәк иде. Ләкин күзләре зур ачылса да, берни күрмәс булган үсмер малай чапты да чапты, маңгае белән дәү кедр кәүсәсенә килеп бәрелгәч кенә «әлә-лә!» дип еламсырап туктап калды. Кедрның ботаклары өч яклап җиргә кадәр салынып төшкән иде. Малай эчкәрәк узды, аска йомшак яфраклар түшәлгән, эчендә кипкән үләннәр сыгылып өелгән. Коры, җылырак урын. Йосыф инде төнгә калуын, юлны табалмаслыгын ачык аңлаган иде. Итекләрен салып ташлап, аякларын аска бөкләп утырды, аркасын агачка терәде. Башта аяклары берни тоймаган иде, тора-бара алар кыза, сызлый башлады. Ул авыраеп янтая барды, тәнен оетып, сәер бер җылылык йөгерде һәм ул тәмле йокыга талды.

Байтак йоклаганмы, белмәде, кемдер берәүнең коры чыбыклар сындырып узуы колагына кереп сискәнеп уянды. Тишеккә түшәлгән үләннәр арасыннан сыек яктылык сирпеп керә башлаган иде. Ул саклык белән генә өскә күз ташлады һәм шул мәлдә телсез калды. Аннан ун адым чамасы ераклыкта гына зур бер аю ята иде. Йөнтәс җәнлек, кабыргасына төшкән сүрән кояш нурларына рәхәтләнеп, йоклый иде бугай. Менә ул башын чайкап алды, Йосыфның хәле китте, аяккуллары калтыраргa тотынды...

Һади бабасы аңа берчакны:

— Йосыф улым, үсәрсең, сунарчы булырсың, ауга йөрерсең, аюлардан курыкма,— дип өйрәткән иде.— Элек-электән безнең як хатыннары ятим калган аю балаларын имезеп үстерә торган булганнар. Синең ерак, бик ерак әбиең Сәкинә дә адашкан ятим аю бәбиен үз имчәгеннән имезеп терелткән. Караган. Аю баласы исәйгәч, аны урманга җибәргәндә колагына тукыган: «Син инде минем балам булдың — минем җиде буыныма тимә!»— дигән... Син — Сәкинә әбинең бишенче буыны. Аюлар сине онытмаганнардыр...

Аю йокламый икән, тик ята, кайчакта кеше төсле итеп кулы белән колак артын кашып ала, учын ялый, иркәләнеп аунагандай итә. Аю өненә кергән ләбаса Йосыф! Шуның өнендә йоклаган. Әгәр Сәкинә әбисе колагына теге сүзне әйтмәгән булса, бу тау кадәр җәнлек аны өнендә тыныч кына йоклатыр идеме? Кереп, сыртына бер генә кундырыр иде. Һәм Йосыф тын алырга да куркып артына чигенә башлады. Кедрның ул яктагы ботаклары тыгызлап үрелгән, беркаян чыгар урын юк иде, ул ботакларны аергаларга тотынды, ботакларның берсе шартлап сынды, тавышка аю торып басты, йөнтәс башын сузып иснәнә башлады, үкереп куйды... Бу тавыш Йосыфка сигнал булды, ул йомылып кына чыкты да тишек итекләрен кедр төбендә калдырып, җан-фәрманга торып чапты...

* * *

Аю аны эзәрлекләмәде. Нигә, нилектән?

Тайга хуҗасының гадәте сәер, тормышы серле. Әгәр аны рәнҗет-

мәсәң, ул сиңа тими. Атсаң, яраласаң — аюдан рәхим-шәфкать көтмә...

Чапты да чапты Йосыф, ниһаять, аюның үзе артыннан килмәвенә ышангач, авылны эзләп табу чарасына кереште. Биек кенә кедр агачына менеп, тирә-якны карамакчы булды. Менәр өчен җайлырак, куе ботаклы агачка шактый менгәч, аның күзе урман сукмагыннан җәһәтҗәһәт атлап килүче бер кешене аерып алды. Сәмук әкә ич бу! Малай агач башыннан ничек төшкәнен дә сизми калды, корсагы, ертык чалбар тишекләреннән боты сыдырылып канап бетте. Агач төбенә шапылдап егылып килеп төште, сикереп торды, җан авазы белән:

— Сәмук әкә! Сәмук әкә! — дип кычкырды.

Юк. Тавыш та, өн дә юк. Күпереп торган койрыгын кәкрәйтеп тиен генә ботактан-ботакка сикереп, төймә күзләре белән Йосыфка карап алды, «Ни тилереп йөри бу бала монда?»— дип уйладымы әллә? «Күземә күренгәндер!»— дип юрады малай, шулай да Сәмук әкә күренгән якка таба барырга булды. Төнлә кырау төшкән иде, ялан тәпиләре аша узып, суык бөтен тәненә йөгерде.

Мөхәммәт абыйсының сүзләре хәтеренә төште: тыгыз, озын ылыслар кедрның көньягында булырга тиеш, дигән иде ул. «Бөтен нәрсә яктыга, кояшка тартыла!» «Агач ботаклары көньякта тыгыз булалар, киселгән агач төбенең боҗралары киңрәк, кырмыска оясы җәенкерәк була». Мөхәммәт абыйсының сүзләре аңга килеп ирешкәч, ул бераз тынычланып калды. Очраган агачларның ботакларын аралап-аралап карады. Әһә, көньяк монда. Авыл да шунда булырга тиеш. Ул ялан тәпиләре белән суык ылысларны изә-изә җәһәтрәк атлап бара башлады, бераздан урман сирәгәйде, агач төпләре, аунап яткан каен һәм нарат ботаклары ешрак очрый иде. Аның эченә җылы керде. Усак ботаклары арасыннан кылый куян атылып чыкты, Йосыф шатланып кычкырып җибәрде:

— Һәй, һәй!

Гайбәтче саесканнар: «Йосыф килә! Йосыф килә!»— дип хәбәр тараттылар. Гайбәт тыңларга яраткан кызыл төлке дә, көлтә койрыгын болгый-болгый, аның юлын аркылы кисеп узды. Эт өргән, каз каңгылдашкан тавышлар килеп ишетелде. Урман читеннән иң әүвәл авыл зираты күренде. Әнисе вафат булгач, аңа, нәни малайга, кабер өстенә бер уч туфрак салдырганнары Йосыфның исенә килеп төште дә авызы җәелеп китте, күзеннән яшь бөртекләре коелды. Зиратка якынайгач, ул тыела алмыйча үксергә кереште. «Әнием-бәгырем,— дип үкседе малай,— син исән булсаң, мине кичкә каршы сыер эзләргә чыгарып җибәрмәсләр дә иде. Туңдым... Аюдан курыктым...»— дия-дия иңәлде малай.

Эче тәмам бушанганчы елады, эч серләрен әнисенә түгеп бетергәч кенә азрак тынычланды. Иртәнге кояш нурлары әнкәсе баш очындагы яшь каенга төште. Агач, бөгелә-сыгыла, аны озатып калды... Йосыфның әнкәсе шушы ак каенга әверелгән кебек тоелды.

Мөхәммәт Уразаев барлык мәктәп балаларын туплап, авыл кешеләрен җыеп, тыкрыктан чыгып барганда, Шамил чабып килеп җитте:

— Йосыф кайта! Үзем күрдем! Йосыф табылды!

* * *

Өйдә Йосыфны күтәреп тилмергән Һади бабай саран күз яшен сөртеп алды да оныгын куенына яшерде. Боз булып каткан аяк-кулларын җылытты. Үги әнкәсе дә бик шатланды, чуенда тиз-тиз су җылытып аны агач мичкәгә тутырды, Йосыфка шунда керергә кушты. Малайның үги әнкәсе алдында бер тапкыр да чишенгәне юк иде, ул авырыксынып кына күлмәк-ыштанын салды, әнкәсе Йосыфны мунчалалап катkat ышкый-ышкый, су алыштыра-алыштыра озаклап юды. Кайнар сөт,

мичтән чыккан хуш исле арыш ипие белән туйганчы сыйлады.

Ләкин бу йорттагы шатлык озакка бармады. Бер-ике сәгать үтүгә, Йосыфның битләре, колак яфраклары тимгел-тимгел комач төсенә керделәр, ул хәлсезләнеп аяктан егылды. Малайны дәваларга кемне чакырырга дигәндә бәхәс сузылмады, ашыгыч кына Санияне алып килделәр. Төрле яктан тыңлап карагач, Сания сискәндерерлек сүзен әйтте:

— Йосыфның үпкәсе шешкән булырга тиеш!

Укучысының бик каты чирләвен ишетеп, Мөхәммәт Уразаев та килеп житте. Сания малайга банка салырга гына әзерләнгән иде. Уразаевның килеп житүе ярады, ул утлы чыраны тотып торды, өйдәгеләрнең һушы таралып чыра тотарлык та хәле калмаган иде. Һади бабай, күз яшьләрен чак тыеп, почмакта утыра, Гыйззәтбану бер чыга, бер керә, малайны шулай соң чыгарып жибәргәне өчен үзен-үзе битәрли. Сәгъдетдин дә тамам аптырашка калган иде.

Уразаев Саниянең колагына якынрак иелеп сорады:

— Бер-бер ярдәм кирәкмиме, Сания?

Сания кәгазь кисәгенә язды: «Үпкә ялкынсынуына каршы яңа дару чыкты, ул бездә юк. Шуны юнәтә алмассызмы?»

Рецептны кулына тотып, «тырышып карармын!» дигәч, Уразаев чыгып китте. Ишегалдында исәрләнеп йөргән Гыйззәтбануга:

— Терелер, нык малай ул безнең Йосыф! — дип әйтеп узды.

Йосыф төне буе бертуктаусыз саташты.

— Олатай, ул әнә почмакта тора... Тешли, тешли! Коткар, олатай! — дип бабасының муенына сарылды. Сания малайга йөрәк даруы, елывыт[1] чәе эчерткән иде, малай башыннан аягынача манма су булды. Беразга тынычланып йоклап китә дә тагын эсселәп, саташып уяна, торып утыра.

— Әнием, мин куркам! — Ул арык куллары белән Гыйззәтбануның муенын кочып алды.— Әнием, нигә мине ялгызымны урманга жибәрдең? Маннур да, Ташкәй дә ялгыз йөрмиләр. Әнием, мин урманга барырга куркам. Анда аю бар! Әнием, кил инде!

Чакыра, янәшәсендәге әнкәсен чакыра бала, аннан тагын тынсызөнсез кала. Мондый тынлык минутларында Саниянең куркуы тагын да арта. «Әгәр бала үлеп китсә?» — дип борчыла. Андый минутларда Гыйззәтбану Саниянең үзен юата башлый:

— Эченә салкын кергән баламның, юеш үткән. Уза ул, Сания, артыгын янып көймә. Терелер, боерган булса. Барысы да тәңре кулында...

Һади бабай Йосыф яныннан бер әйләнеп китә дә тагын намазлыгы өстендә ойый, ул ялынып-ялварып тәңресеннән бер нәрсәне сорый: «Алма жанын минем бәләкәч улымның... Гомерен озын ит, ходаем!..»

Мөхәммәт Уразаев ат чаптырып кына торага барып, тиешле даруларны алып килде. Һәм кайту юлында сәер бер хәлгә юлыкты...

Ялан урманының уртасына житәрәк ул менгән кола бия колакларын уйнатып, шигәеп, атламын акрынайтып кырын-кырын карап бара башлады. Мөхәммәт тә шиккә төште, бияне туктатып, өзәңгегә басып, юлның ике ягын да күзәтеп, тыңланып торды. Һәм аның үткер күзләре юл читенә үк килеп, калын кедр агачы артына поскан ике шәүләне аерып алды. Шәүләләр дә үрә катып юлны, аны күзәтәләр иде сыман. Эндәшергә дә уйлады Мөхәммәт, үзенең коралсыз икәнен дә, ашыгырга тиеш булуын да уйлап юртып китте.

Бу очрашуга алай исе дә китмәгән иде аның, кайтып, малайга дарулар эчертеп, үзе дә йорт хужалары һәм Сания белән чәйләргә утыргач, Сания мәзәк кенә бер сүз әйтеп куйды.

— Саташты да инде, балакаем!.. Әллә ниләр сөйләп бетерде...«Аюдан качып барганда, мин тайгада Сәмук әкәне күрдем,— диде.— Ул барды-барды да аюга әйләнде»,— ди...

— Сәмук?— Мөхәммәтнең маңгаена китереп суктылармыни, ул үз

[1] Елывыт — мәтрүшкә, «жылы ут — үлән» сүзеннән алынган.

соравына үзе гаҗәпләнеп, урман юлын, агач артына посып калган ике шәүләне, шуларның берсе бик тә Сәмукка охшаган икәнен исенә төшерде...

* * *

Гаҗәптер, Йосыф авырган дәвердә кырыс Гыйззәтбану түтинең хатын-кыз булarak яңа тойгылары уянды. Үги улына карашы көннән-көн үзгәрә, җылына барды. Әүвәлге иреннән дә бала күрергә өлгермәгән, Сәгъдетдин абзый белән дә байтак гомер кичереп, балага узмаган пәһлеван хатынның кай җирендәдер посып яткан боз эреде, ул токымсыз калуына моңарчы әчтән генә көенә, яна иде, хәзер янында Йосыф барлыгын тоеп сөенде, ана булу бәхетен тойды. Һәрбер хатынга хас булган табигый матур бер хыял: имиләрен бәбинең тешсез, мамыклы авызына каптырып, иреннәрен чәпелдәтеп суыртып яту ләззәтен тату, ир бала табып, хан бикәчләредәй түрдә иркәләнеп яту бәхетенә ирешү теләге Гыйззәтбану түтидә зөфаф кичәсеннән бүгенге көнгә кадәр сүнмичә-сүрелмичә яшәп килде. Чит балага карата ана булу хисе берчакта да уяна алмас, Йосыфны яратмыйм, яратмам да дип уйлый иде ул.

Йосыф кайнар куллары белән аны кочып, «әнием!» дип өзгәләнә-өзгәләнә, әҗәл белән тарткалашып ятканда, ул моңарчы татымаган ят хис кичерде. Башта ул үзе дә аңлап бетермәде: ни булды соң әле? Ни үзгәрде?.. Бәлки Йосыф үз әнкәсен юксынып кына әйткәндер ул назлы-әче сүзләрен? «Әнием!» дип өзгәләнде бит сабый... Юк, юк, ул аңында иде бит, күрде, «Әнием!» дип, кайнар куллары белән аның муенына сарылды... Моңарчы күрсәткән салкынлыгы өчен бала аны гаепли, «Әбием әкиятләрендәге үги ана сыман син мине ялгызымны карурманга кудың... Үлсәм, сиңа мәңге үкенече булыр! Сиңа ризалыксыз китәм!»— дип әйтә кебек тоелды. Үзенең ерак балачагын, әнкәсенең туктаусыз назлавын исенә төшерде... Һади бабайның ходасына кычкырып-кычкырып эндәшүенә кушылып, ул да почмакка кереп утырды һәм күз яшьләрен сөртә-сөртә: «Йа, аллам, үзең кичер. Бу нарасыйга ярдәм ит, түземлек бир!»— дип сыкрап теләк теләде.

Йосыф сихәтләнә төшкәч, сандык төбендә озак вакытлар яткан ике шакмак шикәрен һәм бер чуклы кәнфитен казып чыгарды...

Үги ананың мөнәсәбәтен бала сизмиме соң?! Йосыф Гыйззәтбану әнкәсенең күзенә карарга тырышты, ул аның күзләрендә туып, арта барган җылылыкны ап-ачык күрде, аның тизрәк тереләсе, аякка басасы, көчле-егәрле буласы килде. Элегрәк үги әнкәсенә үч итеп ул эштә дә ялкауланды, суга барса, юлда яртысын түгеп, чиләген тулыр-тулмас алып кайтты, утынны да, берәм-берәм кертеп, юри өйне суытты... Хәзер ул аларның берсен дә эшләмәс, әнкәсе ни кушса, җиренә җиткереп эшләр иде...

Бүген мәктәптән кайтышлый аның янына Шамил белән Мәүлия кереп чыктылар. Әллә ни сөйләшмәсәләр дә, Йосыфның күңеле күтәрелде, Шамилгә бер шакмак шикәрен, Мәүлиягә чуклы кәнфитен бирде. Тегеләр алмый торгач:

— Әнием бирде,— дип мактанды.— Мин ашадым инде!..

Моны күреп, ишетеп торган Гыйззәтбану түти, иптәшләре чыгып киткәнне генә көтеп торды, ишек ябылуга, Йосыфны кочаклап алды, «Улым, улым, балам!»— дип, озак кына сөйде...

## 16

Яңа уку елында балалар буйга калкып төшкәннәр иде. Шамил, Йосыфлар соңгы елларын Ялан мәктәбендә укыйлар. Алар инде пионерлар. Тәнәфесләрдә Шамил гел Мәүлия тирәсендә бөтерелә башлады.

Моны күргән Уразаевның йөрәге жу итеп китте. Әгәр ике арада мәхәббәт кабынып китсә?.. Үз улы булып саналган Шамилдә аның каны түгел, Ырсытдин кызы Мәүлиядә Мөхәммәтнең үз каны ага, кыз үскән саен, ул анда үз чалымнарын ачыграк күрә. Тормыш үзгәрә тора, Ялан мәктәбенә, курслар тәмамлап, икенче бер укытучы килде, Мәдинә исемле Казан кызы, ул түбән сыйныфларда укыта, зуррак балалар элеккечә Мөхәммәт кулында... Күз мәшәкатьләр белән килде. Рәхмәтулла карунның калай түбәсе бик искергән булып чыкты, яңгыр яуды исә, идәннәр су белән тула, түбәгә дә, ишек-тәрәзәләргә дә кичектергесез ремонт уздырырга кирәк. Райбашкарма складында калай барлыгын ишетеп, Уразаев туп-туры РИК председателе Саламатов янына китте. Саламатов белән алар күптәннән, партизан отрядында чакта ук аз-маз танышлар иде. Шул танышлыкка да исәп тотып, Уразаев рәис бүлмәсенә кыю гына барып керде. Саламатовны танымады, калынайган, өс-баш энәдән-җептән генә чыккан; купшы, калын мыек үстереп җибәргән, тавышны бөердән генә чыгарып сөйләшә. Башта ул Уразаевны танымаган булып маташты. Аңлатып биргәч кенә:

— Ә-ә, бик яхшы. Ни йомыш? — дип сорады.

Тавышын ишетүгә үк өмете кимегән Уразаев гозерен әйтеп бирде.

— Калай юк,— диде Саламатов.

— Бар ич, иптәш Саламатов.

— Безнең мәктәпләрдән дә мөһимрәк тишек-тошыкларыбыз бар,— диде Саламатов киреләнеп.

— Беләм, калай складта ике ел ята икән.

— Ятса соң?!

— Тагын ике ел ятып череп бетәр дим...

— Сез, иптәш Уразаев,— диде кинәт кызып Саламатов,— әлегә ревизор да, тикшерүче дә түгел. Үз хуҗалыгыбызга үзебез хуҗа, сез безнең эшкә тыгылмагыз.

— Мин коммунист! — диде Уразаев та, тавышын бераз күтәреп.— Бөтен җиргә тыгылырга хакым бар!

Мондый ук сүзне көтмәгән иде Саламатов, беравык тынсыз калды, аннан җан-фәрманга Уразаевны сүгә башлады. «Оппортунист! — диде,— районның хуҗалык планнарына аяк чаласың»,— дип ычкындырды.

— Мин конференциягә доклад әзерлим,— диде ул актыктан.— Синең белән утырырга вакытым юк.

— Калай алмыйча, мин моннан чыкмыйм,— дип карышты Уразаев.

— Мин милициягә шалтыратам!

— Ә мин райкомга!

— Бу кадәр үзсүзле татар булырсың икән! — диде Саламатов һәм складка шалтыратты...

Түбәсе ябылган, ишек-тәрәзәләре ныклап каралган мәктәп көндез генә балалар иркендә, кичләрен анда клуб, яшьләр җыела, өлкәннәр өчен наданлыкка каршы көрәш кичәләре уздыралар, спектакльләр куялар.

Авылда олы үзгәрешләр башланган чор! Тоташтан коллективлашу, кулакларны сыйныф буларак бетерү турында ил буенча сүз бара... Бер кичне бик гаугалы актив утырышы булды. Анда Сәлим байны һәм Ырсытдинне раскулачивать итеп авылдан куу турында сүз барды...

— Куарга! — диде күпчелек.

— Россиядән кулакларны Себергә куалар, ә без кая куыйк?! — диде азчылык.

— Барыбер авылда калдырырга ярамый аларны! — диде күпчелек.

— Калсалар ни зыян? — диде азчылык.

Эссәт Фәтхуллинны шушы арада гына яңа төзелгән колхоз рәисе итеп сайлаганнар, авылның юаш кына бер кешесе Дәүләтша әкәне авыл советына хуҗа иткәннәр иде. «Колхоз — яңалык, син — авылда житәкче булган кеше, колхозны син житәклә!»— дигәннәр иде Эссәткә.

«Кулакларны сыйныф буларак бетерергә!» — дип, район жыелышларында кул күтәргән, шушы өндәмәне яклап кулы талганчы алкышлаган Эссәт тә бүгенге актив утырышында икеләнеп калды. Кулакларны сөрергә кирәк, анысы шиксез, тик менә үз авылың кешеләре — Сәлим бай белән Ырсытдингә эш килеп терәлгәч, эш авырланып китте. Хатыннары, балалары бар аларның... Сәлим бай заманында череп баеган кеше иде, ялчылар тотты, сәүдә итте, ашады-эчте, типтерде, мәгәр совет власте елларында тавыш-тыны чыкканы юк, Ырсытдин дә Рәхмәтулла фетнәсе кузгалгач кушылмады, аннан соң да әллә ни зыян-кыян күрсәткәне юк... Бер яктан караганда шулай, икенче яктан уйлаганда, аларны акларлык сәбәпләр дә юк түгел...

Һич көтмәгәндә Уразаев та бик нык икеләнеп калды...

Күпчелек хаклы: Ырсытдин — кулак. Йортына керсәң, мал-мөлкәте ерып чыгарлык түгел. Эшләп табылган малмы әллә? Мөхәммәтнең дә хәләл көче кергән ул байлыкка. Шулай. Ә икенче яктан килгәндә — Ырсытдин бай Мөхәммәтне ачлык тырнагыннан т. ртып алды, киендерде, ашатты... Укырга җибәрде! Гаиләсенә ямьсезлек эшләгәннән соң... Әйе, Мөкә бай белән килешенеп, аның азгын кызына кияү итеп җибәрде... Монда мәрхәмәт белән явызлык бергә кушылган иде кушылуын... Әмма Мөхәммәт ак белән караны аера башлаган икән, кирәк чагында дөрес юлда була белгән икән, моңа аның сәүдә училищесында укуы ярдәм итмәдемени?!

Мәктәп-клубтан чыккач та ул өенә керергә ашыкмады, урамга чыкты, арлы-бирле бер максатсыз йөренеп килде. Урамда шактый әче җил булса да, тирләп, ак мамык шарфын чишеп, кулына тотты. Уйлар тозагына эләккән күңеле тиз генә суына да, бушана да алмады. Ул кайтып кергәндә Шамил инде йоклаган, өстәлдә кукәй кабыклары, салкын чәй утырып калган иде. Мөхәммәт озаклап, һаман авыр уйлардан арына алмыйча чишенде, Шамилнең өстен карап килде, почмакны эш бүлмәсеннән аерып торган чуар пәрдәне тартыбрак япты... Кулларын кушырып, башын учларына салды, урындыкка ярым ятып, караңгы күзле тәрәзәгә карады... Йокымсыраган да кебек булды, шул арада кемдер тәрәзәгә чиртте. Мөхәммәт, сискәнеп китеп, тирләгән, дымлы пыялага якынайды, маңгаен терәп бераз көтеп торды. Чиртү тагын кабатланды. Ул, ашыгып, ишеккә килде һәм гаҗәпләнүдән чак кына егылып китмәде. Ишектән, Мәүлияне җитәкләп, Йомабикә килеп керде. Йомабикә шакмаклы шәлен ныгытып ураган, күзләре чак кына күренеп тора, Мәүлиянең исә бите ачык, уң битендә миндәр җөе эзләре, аны уятып алып чыгып киткәннәре күренеп тора. Мөхәммәт ашыгып аларга урындык тәкъдим итте:

— Өй җылы, чишенегез, Йомабикә түти,— диде. Соңгы вакытларда гадәтләнгәнчә ул Ырсытдин бичәсенә «түти» дип эндәшә иде.

— Без идек әле бу,— диде Йомабикә, шәлен чишә-чишә. Аның җилдә, салкында кызарган йөзе сүрән ут яктысында Мөхәммәткә матур, акыллы булып күренде.

— Ни хәлләрегез бар? — диде Мөхәммәт, шактый озак дәвам иткән авыр тынлыкны бозып. Мәүлия дә әнкәсенә карап яулыгын чишеп җибәрде, калыная башлаган саргылт толымнары, Мөхәммәтнең күзен кисеп, күренеп калдылар...

— Безнең хәлне синнән сорарга кирәктер,— диде Йомабикә, Уразаевка карамаска тырышып.

— Нигә?

— Беләсеңдер ич?

Мәүлия әнисенә таба авышты да ап-ачык итеп:

— Әнием, минем йокым килә,— дип инәлде.

— Хәзер, кызым, хәзер. Мөгаллим абыең белән сөйләшәсе бар...

«Мөгаллим абыең» белән дигән сүзгә,бәлки, Йомабикә әллә ни мәгънә дә салмагандыр, әмма ул сүз Уразаевны тагын да ныграк сискәндереп



4*

җибәрде, ул Ырсытдин хатынының төнлә шулай йөрүенең серенә төшенгән иде диярлек.

— Авылдан куарга иткәннәр икән безне,— диде Йомабикә, кызының авырайган башын тезенә алып.— Кусыннар. Без китәрбез. Ә балалар? Минә бу нарасыйның ни гаебе бар? Ташкайнең?..

— Сине монда ирең җибәрдеме?

— Үзем килдем.

— Ә ул кайда?

— Ул өйдә юк. Әгәр синең катыңа килүемне белсә, ирем муенымны борачак. Мәктәп ягына караган өчен дә җанымны алырга әзер... Ярый, Ырсытдиннең гаебе дә булсын, ди. Риза. Балалар... Алар нишләр?...

— Кайда да тормыш бер.

— Монда без яшәгән, торыр җиребез, ашар ризыгыбыз бар... Ә анда ни булыр? «Куылып килгән кешеләр» дигән дан белән кайда да урын тар булыр...

Уразаев Йомабикәнең зирәклегенә таң калды. Әллә берәрсе өйрәтеп җибәргәнме бу бичәне дип куркып калды...

— Нишләргә соң, Йомабикә түти?

Бу юлы «түти» сүзе ирексездән ияреп чыкты.

— Белмим,— диде Ырсытдин хатыны.— Минем башка сүзем юк. Үзең уйла.

Ул энисенең тез өстенә башын куеп йокыга киткән кызчыкка ишарәләде...

Кызын көч-хәл белән уятып алып чыгып китте Йомабикә, Мөхәммәтне тагын да авыррак уйлар чоңгылында калдырды... Мөхәммәт янына килергә кем кушкан аңа? Кем киңәш иткән? Мәүлиянең кем кызы икәнен белүчеләр бармы әллә авылда? Әгәр хәзер Ырсытдинне яклап тавыш бирсә, аңа яңа гаеп ташламаслармы?.. «Йомабикә бичә сүзен сүз итеп кенә яклыйсың син Ырсытдинне!»— димәсләрме?

Йомабикә: «Ырсытдин өйдә юк!»— дип хак сүз әйткән иде. Ялан авылында беркем дә, шул исәптән Йомабикә дә иренең кайдалыгын белми иде. Әгәр Уразаев бу төндә аның кайдалыгын белсә, «Ырсытдин чын кулак ук түгел!» — дип тавыш күтәреп маташмас иде...


Рәхмәтулла тамагы ач бөркет шикелле көне-төне Ялан авылын күзәтә ала иде хәзер. Теге чакта Сәмукка тапшырылган бүләкләр, аннан соңра бирелгән кешмал тиреләре Сәмукны тәмам Рәхмәтулланың тугры ялчысына әйләндерделәр. Ул авыл хәлләрен атна саен диярлек бандага җиткерә торды. Күз күргән сунарчылар моңарчы гел ялкауланып яшәгән, күп вакытта коры кул белән йөреп кайткан Сәмукның вак-төяк җәнлек кенә түгел, кешмал да атып алып кайтуына гаҗәпләнә башладылар. Йосыфның сүзен һәрчак хәтерендә тоткан Мөхәммәт берчакны аларның өйләренә барып керде.

— Сунарның серен белә башладыңмы әллә син, Сәмук? — дип сорады. Сәмук, куркып тез аслары калтыраса да, сер бирмәскә тырышты, өр-яңа дип әйтерлек мылтыгын (Рәхмәтулла бүләге!) Уразаевка сузып:

— Сер юк, эш мылтыкта,— диде.

Уразаев мылтыкны әйләндереп-әйләндереп карады, мылтык аның шиген генә арттырды. Әмма «күк капусы ачылган» сунарчыны гаепләрлек дәлиле юк иде аңың...

Рәхмәтулла урманда качып ятса да, дөнья хәлләре белән таныш диярлек иде, урманда төрле кеше очраштырып тора, арада Сәмук кебек гомаалары бар, шулай янәшәсендә укыган, университет күргән элекке офицерлар килеп чыга, алар инде тел яшереп тормыйлар, белгән-белмәгәннәрен чыгарып салырга ашыгалар, совет властен сүгәләр, каргыйлар, аның якын киләчәктә тар-мар киләсен, таркаласын юрап сөйлиләр.



*Тимергалина рәсеме.*

Ишетә Рәхмәтулла, күрә, белә, уйлый, вакыты чиксез, көн дә уйлый, төн дә уйлый... Совет властеның көннән-көн ныгыганын да белми түгел, колхозлар да оешып килә, крестьяннар бу яңалыкны кабып йотты, анда-санда ишетелеп калган вак-төяк каршылыкларны исәпкә алмаганда, якын-тирә авылларда ныгып ук килә шул колхоз дигәннәре... Рәхмәтулланы соңгы вакытларда төп бер уй борчый: дөрес сайладылармы алар көрәш юлын? Дөрес яшиләрме?.. Әгәр совет власте таркалмаса? Илгә-кырга колхозлар хуҗа булып калса?.. Шушы икеләнүләрдән котылыр өчен, ул вак-төяк җиңү тантаналарын юксына башлады. Сәмук, «Ырсытдинне авылдан куарга җыеналар»,— дигән хәбәрне җиткергәч, ул бөтен көче белән аны Яланда калдыру ягын кайгырта башлады. Совет власте белән көрәш турында да уйламый хәзер Рәхмәтулла, аның читен, авыр икәнен белә... Колхозларны таркатырга да кулыннан килмәслеген чамалый, анысы да җиңел эш түгел. Әмма нәни генә, бәләкәй генә җиңү ясый ала ич ул! Бөтен авыл коммунистлары, активлары җыелышып Ырсытдинне авылдан куарга җыеналар. Ә Рәхмәтулла моңа каршы төшә... Һәм теләгенә ирешә: Ырсытдинне Яланда калдыра! Ялан активларының күзенә шырпы булып кадалып яшәсен әле Ырсытдин! Ул авылда чакта Рәхмәтуллага да рәхәт, әле кечтек кенә булса да өмет кала... Өмет! Төрле яклардан өмете киселгәндә, Рәхмәтуллага шушы бәләкәй генә җиңү дә җитә!

Һәм ул аны урманга чакырып алды.

Икәүдән-икәү генә очраштылар.

— Йә,— диде Рәхмәтулла урманда ятып күгәргән тавыш белән.— Ни исәп тотасың?

— Власть миндә түгел. Власть миңа каршы,— диде Ырсытдин.

— Ә син нык тор, китмә.

— ГПУ белән озата башласалар, китми ни хәлең булыр?

— Җаен тап.

— Юк, Рәхмәтулла, монда калып булмас. Эссәт белән Уразаев каныгалар.

— Ә син аларны юк ит, дөньяда яшәтмә.

— Әйтергә ансат... Болай читкә генә куалар, ул чагында ләхеткә кертерләр. Минем яшисем килә. Бала-чагаларымны үстерәсем килә.

Рәхмәтулла белән Ырсытдин уйга калдылар, төрле юлларны эзләп баш ваттылар. Иң ахырдан Рәхмәтулла:

— Китсәң, үз теләгең белән чыгып ычкынырга тырыш. Җиңелеп калма! — дип киңәш бирде...

Уразаев, идарә члены буларак, Эссәт әкәнең урынбасары итеп тә сайланган иде. Эссәт әкә ераграк юлга чыкты исә, «Таң» колхозының мөһере һәм вак-төяк эшләре аңарда кала. Шундый бер чакта идарәгә мыштым гына Ырсытдин килеп керде. Үз иреге белән читкә китәргә нияте барлыгын белдерде һәм тиешле документлар сорады. Уразаев, бу адымның җитдилеген тулаем аңласа да, Ырсытдиннең үтенечен канәгатьләндерде. Әллә Йомабикә бичәнең ялваруы күңелен нечкәрттеме, ни булса булды, Ырсытдин идарәдән үзенә кирәкле документларны тутырып алды һәм шул ук кичне бөтен гаиләсе белән Обдорск шәһәренә күчеп китте. Озатырга чыккан авылдашлары белән саубуллашканда, Ырсытдин Сәмукка ым какты һәм: «Тегендә хәбәр ит, үз теләгем белән китәм!»— дип пышылдады...

Бу вакыйгадан соң Уразаевка тынгы бетте. Иң әүвәл аны РИКка чакырып Саламатов пешерде, «Кулак калдыгы, сатлык җан!»— дип канына төште һәм эшне ГПУга җиткерде. ГПУ ашыгыч рәвештә «Уразаев эше» белән шөгыльләнә башлады.

Рәхмәтулла куанычыннан нишләргә белмәде, яхшы хәбәрләр китергән Сәмукка тагын бүләк яуды, бүләккә өстәп яңа киңәшләр бирде банда башлыгы, нишләргә кирәклеген аңлатты...

Уразаевның Ырсытдин гаиләсе белән булган мөнәсәбәтләрен бер

Белкин гына нигезле белә иде, аның тәкъдиме белән Мөхәммәткә каты шелтә белдереп, партия сафларында калдырдылар... Сәмук монысын Рәхмәтуллага җиткерергә ашыкмады, аңа кадәр берәр «файдалы эш» күрсәтеп каласы килде...

Яланда ялгыз хуҗалык секторы икмәк тапшыру планын үтәмәгәч, авыл советы члены Сәгъдетдин абзыйны утырышка чакырып житәрлек пешекләделәр. Шәһәрдән килгән ач яңаклы, күзлекле вәкил: «Өч көн срок сиңа, ничек итсәң ит — планны тутыр, эшче сыйныфка икмәк кирәк!»— дип янап китеп барды. Бу мәсьәләдә йомшаклык күрсәткән авыл советы рәисен ике елга утыртып ук куйдылар...

Вәкилгә җиңел, әйтте дә китеп барды. Ә монда... Менә Сәмукның ниен аласың? Юеш борынлы биш баласыннан һәм ертык күлмәгенең тишек-ертыкларын каплап мич артында поскан хатыныннан башка нәрсәсе бар?

Алай да башын кашып, икенче көнне Сәгъдетдин Сәмук янына да сугылды.

— Икмәгеңне ничек түләрсең? — диде ул.

Хуҗа, бик эре кыланып, икмәк тапшыру квитанцияләрен авыл советы членының күзенә китереп терәде. Бу бәндәнең бер бөртек тә игене булмавын белгән Сәгъдетдин хуҗага шаккатып карады.

— Кабердән кубарылган әрвахка караган кебек карап торма,— диде Сәмук.

— Иген каян алдың?

— Төшә маллар егет кулына! — дип җибәрде һаваланып Сәмук.

— Ничек? Каян юнәттең? — дип кат-кат сораса да, Сәмук, танавын чөеп, Сәгъдетдингә серен ачмады. Актыктан гына, сәгать чамасы ялындырганнан соң:

— Мине сатмасаң, план үтәүнең серен ачам,— диде.

Сәгъдетдингә коръән күтәреп ант итәргә туры килде.

— Глубинкада приемщик балык ярата,— диде Сәмук.— Кәреш, тогы, акбалык — барысы да аңа таба шәп йөзә! Квитанция яза да бирә. Кирәк кешеләргә шуны ишеттер. Үзеңне советта сукканнар дип ишеттем. Бүтән сүзем юк. Сине җәлләп кенә әйтүем. Мин иртәгә ауга чыгып китәм...

Эчкерсез Сәгъдетдин Сәмукка чын күңеленнән рәхмәт укыды...

Эх, белсә иде ул моның төбендә нәрсә ятканын!

Сәмук китергән хәбәр Рәхмәтулла йөрәгенә сары май булып ягылды...

Әле аңа кадәр...

Әле аңа кадәр Сәмукның тагын бер «ашыгыч эше» бар иде Яланда. Ул ерак кардәше Шәүкәтне эзләп тапты. Хәл-әхвәл сорашты, сүзне гадәттәгедән кыска тотып, Саниягә китереп җиткерде.

— Я, энекәш, туеңны кайчан үткәрәбез?

— Нинди туй, Сәмук әкә?

Көтелмәгән сүз башлануга Шәүкәт уңайсызланып китте.

— Саниябез соң! — диде көлеп Сәмук.— Эреп пешкән җиләктәй гуй. Хәбәр җирдә ятмый. Әйбәт кыз. Тик кара, авыз ачып калып кызны ычкындырып җибәрә күрмә. Ныграк ябыш! Авылда синнән дәстүен егет юк. Аны корыйлап йөрүчеләр бар.

— Кем?

— Уразаев аның тирәсендә бертуктамый юргалый. Оялмый да ичмасам, карт башы белән...

Шәүкәт аптырап тынып калды. Әйе, Уразаев белән Сания арасында «нидер бар» дигән хәбәр авыл арасына чыккан иде. Мәгәр Шәүкәт моңарчы ул хәбәргә аерым игътибар бирмәде: авылда гел нидер сөйлиләр инде!

— Син кызның тыркылдавына карама! — дип дәвам итте Сәмук.— Алар һәрчак шулай кыланган булалар. Ул ярамый аларга, бу килешми.

Үзең үйлап бак, кыз синең муенга килеп асылмас! Себер татар кызлары: «Сине яратам!»— дип акырып йөрмиләр. Җаен табып йомышын бетер дә куй... Аннан үзе сиңа тагылып йөри башлар.

— Әллә ни сөйлисең син, Сәмук әкә! — диде тәмам аптырап Шәүкәт.

— Мөхлисә кортка белән сөйләштем, ул риза! — дип, төрле яктан җөйләп куйды Сәмук...

Бусы да Рәхмәтулла боерыгы иде: «Уразаевны төрле яктан чәлмәргә тырыш, кая килеп капканын да сизми калсын!»

«Уразаев белән Сания арасында нидер бар!»— дигән хәбәр урманга, бандитлар шайкасына да килеп ишетелгән иде инде...

## 17

«Нидер бар!»— дип гөрли авыл халкы...

«Нидер бар!»— дип, бандит Рәхмәтулланың колагына да барып керә һәм аның җенен чыгара.

«Нидер бар!»— дип, Саниянең әнисе Мөхлисә әби дә ишетә һәм «кызны әзерләргә бик вакыт, бик вакыт!» дип юк җирдән бар итеп мендәр-ястыкларын, чаршау-ашъяулыкларын хәстәрли башлый...

Сания үзе дә моңарчы беленмәгән ләззәтле тойгыларга уралып яши... Әлбәттә, әнисе әйткәндәй, аңа «башлы-күзле» булып китәргә вакыт. Эшли, эш урыны әйбәт, Ялан халкы аңа ияләнеп килә, яраталар да шикелле. Чырык Абдрахман да ярты чакрымнан сәлам бирә, сыкрапнитеп китсә, хәзер үк пунктка йөгереп килә. Дөрес, аның үз клиентлары да җитәрлек: карчык-корчык, карт-коры күбрәк аның янына килә, аңа ышана...

Мөхәммәт Уразаев та күптәннән сәер халәттә яши, Сания белән очрашканнан бирле җан тынычлыгы югалды мөгаллимнең!.. Ул җилбәзәк үсмер сыман гыйшык утында «дөрләп яна башлады». Ун ел ялгызы яшәгән чорда хатын-кыз очратмады түгел Уразаев, чибәрләре дә, телчәннәре дә булгалады гомер сукмагында, үзләре килеп сүз каттылар, кеше аша сүз житкерделәр, кичен-кичен чәйгә чакыручылар да, дәртләренә тәкать калмагач, тол ирнең тәрәзәсенә кагылучылар да булмады түгел. Уй булды, фикер туды, тик бер хатын-кызга да моңарчы ныклы хис кабынганы юк иде. Бу гап-гади кызның йөрәк түренә үк үтеп керүен чигә чәчләренә беренче көмеш җепләр йөгергән ир сизми дә калды. Гыйшык китмәскә килде... «Сания, мин сине өзелеп сөям!»— дип талпынган чаклары да булды. Ләкин акылы бу уйга аркылы төште: Уразаевның тәкъдимен кире кагарга кызның сәбәпләре җитәрлек. Монда, саксызлык күрсәтеп, барыр юлыңны кисеп, кайтыр юлыңдагы күперне җимерергә ярамый. Саксыз әйтелгән бер сүз, саксыз ясалган бер хәрәкәт ике арага упкын ясарга мөмкин...

Йөрәк белән акыл бәхәсләшә. Төннәрен йөрәк җиңгән кебек була да, көндезләрен, кеше арасында, яшәештә, мәшәкатьләр дулкынында акыл өскә чыга. «Тиле, кая үрмәлисең?!»— дип, йөрәкне тыя, нәфескә аркылы төшә, уйларны чикли.

Кич. Алар бүген икесе дә монда, мәктәптә. Мөхәммәт олы кешеләр белән ликбез дәресен алып бара, яшьләр арасында Сания лекция укый. Дәресен тәмамлап, Мөхәммәт аны көтә, дәфтәрләр тикшерә. Саниянең дә эше тәмам. Яшьләр теләр-теләмәс кенә таралалар... Сания чәчен рәтләп, пальтосын киям дигәндә, мәктәп ишегендә Шәүкәтнең башы күренде. Аның сулышы кабынган, йөзе кызарган, ул бусаганы үтеп бетмәстән ямьсез хәбәр салды.

— Сания, Мөхлисә әби чирләп кинәт егылган! Әйдә тизрәк!

Кыз аны-моны ачыклап тормады, чыкты да чапты. Бу хәбәр Уразаевның аңына барып җиткәндә, алар күздән югалган иде. Ул аптырап шинеленә ябышты, җиңен кия алмыйча маза чикте. Кемдер шинель җиңен чәлмәштереп, тыгыз төен белән бәйләп куйган иде. Яшьләр ара-

сыннан кайсысы шулай ямьсез шукланды икән? Ул киенеп, тирләп-пешеп Санияләргә барып кергәндә, Мөхлисә әби, бер кайгысыз кичке аш хәстәрләп йөри иде...

— Мөхлисә әби, үттемени? Шөкер! — Уразаев киң сулыш алып, елмаеп ук җибәрде.

— Кем үтте, улым?

— Сезне зыян тотып егылды дигәннәр иде. Сания кайда?

— Ай аллам, берни булганы да юк. Сания кайда дип, эшеннән кайтмады...

Мөхлисә әбине юатырга кирәк иде кирәген, әмма Мөхәммәт кичегергә ярамаганын, кызның начар бер нәрсәгә тарыганын аңлады. Җиннәрне дә чияләндереп юкка гына бәйләп китмәгәннәр булып чыгамы?.. Ары чапты Мөхәммәт, бире йөгерде, күз аллары караңгылана башлаганда аңа Йосыф белән Маннур очрадылар.

— Абый, абый... анда Ырсытдиннең мунчасында... Сания апа...

Чабып бара башлаган Уразаев, үзенә ияргән малайларга:

— Эссәт әкәгез килсен! — дип кычкырырга өлгерде.

Мунча ишек алдына килеп җиткәндә, аны аяктан чалып ектылар. Партизанда йөргәндә егылырга да, торырга да, торгач, дошманны ничек-ничек чөеп ыргытырга да өйрәнгән Уразаев борыны белән җиргә якынайды да терсәкләре белән шуып барды һәм ә дигәнче җирдән калкынды. Аңа аяк чалган егет шунда ук һавага очып менде һәм Уразаевның иңе аша узып әллә кая барып сөрлекте. Моны күреп торган икенче егет читән-киртәләрне шатыр-шотыр сындыра-сындыра тиз үк моннан ычкыну җаен карады.

Ырсытдиннең күптән ягылмаган мунча алдыннан кабер исе, тирән баз исе килә иде. Мөхәммәт ишеккә терәлгән юан казыкны итек очы белән тибеп очырды да ишекне каерып ачты. Караңгыда ул әүмәкләшкән Шәүкәт белән Санияне күреп алды. Шәүкәт Сәмук әкәсенең киңәше белән «йомышын йомышларга» ниятләгән, шуның белән кызны үзенә ябыштырып калдырырга уйлаган иде.

— Кабахәт, тимә кызга! — дип үкерде Уразаев.

Битләре тырналган Шәүкәт, кызны ычкындырып, Уразаев каршысына чыкты.

— Монда сиңа ни кирәк? — диде ул Мөхәммәтнең үзеннән дә катырак кычкырып.

Баягы шәүләләр дә ерак китмәгән икән, алар шунда ук ике егеткә әверелеп килеп керделәр. Мунчада дүртәүләшеп әүмәкләшә башладылар. Ярый әле Мөхәммәт буйга барысыннан да озын, янында Сания, ура гына егетләрне. Үзенә дә эләккәли, Шәүкәт тә төшеп калганнардан түгел, ямый гына мөгаллимгә! Бәрелеш кызып җиткәндә, Мөхәммәт, мунча сәкесен каерып тотып, егетләрне төя башлаганда, Эссәт әкәнең калын тавышы яңгырады:

— Туктагыз, юньсезләр! Төрмәдә черергә телисезме? Совет заманында нишләп йөриләр бит, юньсезләр!

Барысы да тынып калдылар. Мөхәммәт, Санияне житәкләп, урамга алып чыкты, озакламый Эссәт тә алар янына килеп житте. Кыз урлаучылар, эссе мунча ташына салган су кебек юкка чыктылар. Сания Мөхәммәтнең күгәргән, шешкән күз кабакларын тотып-тотып карады, бераздан өчәүләшеп, урамны яңгыратып көлә башладылар. Алар янына килеп житкән Йосыф белән Маннур да яңгыратып көлеп җибәрделәр...

Эссәт әкәне яраттылар. Бар икән үзендә дә сәләт! Җәйге кәккүк төннәрендә кояш белән бергә күтәрелгән кеше басу-кырларны әйләнеп чыгарга өлгерә, кайда нинди эш тералеп калса, кичтән бирелгән нәрәт начар үтәлсә, чарасын күреп, анда ярдәмләшеп, монда булышып, көн үткәнен сизми дә кала. Эшли-эшли, авылдашлары Эссәт Фәтхуллинның яхшы ягын да, ярамаган яклар: н да танып өлгерделәр.

Яхшыга яхшы була белгән председатель яманнарга аяусыз, артыгы белән дорфа да булгалый иде.

Бер егет әвенгә көлтәгә барганда ятып йоклаган, атның аркалыгы чишелгән, менә йөри икән урылмаган җирдә башак кыркып!.. Бәхетсезгә вакытсыз дигәндәй, көлтәләргә яңгыр тамчылары куна башлаган, төньяктан кубарылып болыт калыккан.

Элеп тә алган йоклаган егетне Эссәт арбадан, селкеп тә салган. Малай белән пар булып эшләүче Гобәйбә — тол хатын: «Тәнемә кылчык тулды, бик кычыта!»— дип, култык астын кашый-кашый мунча керергә кайтып киткән икән. Мондый эш өстендә көпә-көндез мунча кереп йөрүче түтигә дә эләккән! Чабып барып та кергән Эссәт, мунча ишеген ачып та җибәргән.

—Кылны урталай ярыр чакта, мунча кереп йөрергә кортладыңмы әллә?

Гобәйбә дә таш астыннан чыккан, гомере буе тол яшәп шомарып беткән, рәисне күрүгә тегене куалап чыгарган да кайнар сулы чиләген өстенә тондырган... Шәрә тән килеш рәисне урам буйлап куа да киткән, башта гарьләнгән Эссәт: «Шушы юньсез бичәгә ник бәйләндем икән?»— дип үкенә-үкенә идарәгә кадәр йөгергән икән...

Шундый кызу эш өстендә якындагы кедр урманында янгын чыгып берничә агач яна башлагач, янгынчылардан берәү рәис янына йөгереп килгән.

— Юк! — дигән Эссәт әкә,— мондагы янгын зуррак. Бүген дәүләткә планны үтәп бетерәбез! Бер кешемне дә җибәрә алмыйм!

Ярый әле, аның артыннан ук ындыр табагына Уразаев килеп житә, салам өючеләрдән ни булганын сорашып белешкәч, болай ди:

— Иптәшләр, Эссәт әкә Фәтхуллин баягы боерыгын үзгәртте, барыгыз да янгын сүндерергә ашыгыгыз! — дип, колхозчыларны янгын сүндерешергә җибәрә. Ындыр табагын сакларга бары тик Чырык Абдрахман гына кала, Уразаев үзе дә атка менеп куе төтен ургыган урынга чаба.

Хисапчы Шәехов янында отчетлар белән иза чиккәннән соң Эссәт әкә ындыр табагына килсә, җилгәргән бодай көшеле өстендә бозаулар йөреп ята, ә Чырык Абдрахман күләгәгә кергән дә, тынлыктан файдаланып борынын сызгырта...

— Бу нинди вредительство!? — дигән тавышка Чырык сикереп торса, аны-моны абайлаганчы рәис моны сугып та ега.— Кешеләр кайда?

— Ут сүндерергә киттеләр.

— Кем кушты?

— Үзең кушкансың ич. Мөгаллим Уразаев шулай дип килеп әйтте.

Янгыннан да болайрак кызган Фәтхуллин урманга таба чаба башлаганда «янгынчылар» булып узган афәтне җиңүләре турында берберсенә мактанышып сөйли-сөйли кайтып та киләләр. Эссәт әкә Уразаевның якасыннан эләктереп тә ала.

— Мин ни кушкан идем?

— «Янгын сүндерергә барсыннар!»— дидең.

— Кайчан?

— Идарәдә. Шәехов алдында.

Эссәт әкә Уразаевның шулкадәр ышанып әйткән сүзләренә таң кала, «Әллә ашыгычлык белән шулай әйттем микән?»— дип бик нык аптырый.

Ул арада, ындыр табагына кайтып эш башлаганда, алар янына РИК председателе Саламатов килеп житә, тарантасыннан сикереп төшеп, рәиснең кулын ике куллап кыса.

— Молодец, Фәтхуллин,— ди.— Утка куәт алырга ирек бирмәгәнсең! Кедрачтан игенгә, игеннәрдән складка күчәчәк иде ул! Өч мең пот бодай әрәм була иде...

Уразаев: «Эссәт әкә ни әйтер икән?»— дип кызыксынып тыңласа,

Фәтхуллинның мыегы да селкенми, РИК рәисенең күзенә керердәй булып:
— А как же, без эшләсәк эшлибез инде аны! — дип чатнатып тора. Алай гынамы соң, форсаттан файдаланып, икмәк илтешергә күрше тирәдән атлар җибәрсеннәр дип тә килешеп ала...
Менә шундый кеше иде инде «Таң» колхозының рәисе Эссәт Фәтхуллин, кабынып та китә, «партизанлыгы» өстенлек ала, юаш та була беләә. Теге көндә, Сания белән Мөхәммәтне ярсыган егетләрдән аралап алгач, атна чамасы Уразаевның канына төште. «Әйдә, утыртып куйыйк теге этәчләрне, казна икмәген ашасалар, акыллары арта төшәр!» — диде.
Егетләрне судка бирергә риза булмады Мөхәммәт, бу хәбәрнең авыл арасында таралуын теләмәгән иде, таралмый каламы соң, егетләр үзләре үк «мөгаллимнең аркасын кашыдык!» — дип мактанышып йөргәннәр. Вәт чукынган малайлар!..

## 18

Асламчы килгән урамга,
Асыл алыйк юрганга...

Мөхлисә әби, көн туса, шушы җырны көйләп йөри. Ялгыз калганда гына түгел, кеше арасына чыкканда да, чишмә янында да, онытылып, шуны җырлап җибәрә. Ишетеп калганнар төпченеп тормыйлар, кызлы йортның гадәтен беләләр, канаты ныгыдымы, очып китәргә вакыт, очып китә икән — татарлар кызны зур әзерлек белән кияүгә озаталар. Урын-җир, мендәр-юрган, кызның кием-салымы еллар буе җыела, туплана, бизәкле сандыкка тула бара. Элек Яланның хәллерәк кешеләре кыз белән җир дә бирә торган булганнар, андый чакта кызның әтисе болай дип әйтә икән: «Ат бирсәм — азар, тун бирсәм — тузар, җир бирсәм — мәңгелек булыр»...
Кызын мунчага алып кереп мәсхәрә итәргә җыенуларын ишетеп, Мөхлисә әби үтә хафаланды, тамактан калды, өч-дүрт көн кеше арасына чыгарга кыенсынып йөрде. Ни әйтсәң дә «алдан намусың барсын, артыннан үзеңияр!»
Әле ярый балалар күреп калган да Мөхәммәт Уразаевка әйтеп өлгергәннәр, әле ярый авылның абруйлы кешесе Эссәт әкә килеп өлгергән, харап итәселәр икән баланы... Мөхлисә әби «Каргап кайтыймчы, бәддогамны белдеримче!» — дип кызып, Шәүкәтләрнең өенә дә бармакчы иде, Сания җибәрмәде. «Ярар, ахыры әйбәт булсын дип кенә телә, әни!» — диде.
Ахыры... Нинди булыр әле аның ахыры...
Шәүкәткә бирергә каршы да түгел иде Мөхлисә әби, егетне ошатып йөри иде, болай чорсызлангач, исемен ишетә алмас хәлгә килде... Кызын Мөхәммәт Уразаев белән чуала, диләр. Мөхәммәт әйбәт кеше, ипле, ягымлы, тәмле телле. Эшкә кулы килә. Мәгәр аның да кыеш-мыешлары җитәрлек... Уразаевның Ырсытдин хатыны куенында калач ашаганын белмиләр кебек тә, кая ул, ут бар җирдә төтен чыкмыйча каламы, ишетелде, раслап пичәт басучы булмаса да авыл арасында сүз йөрде... Шуның өстенә үсеп килә торган улы бар... Бала өстенә барган ананың рәхәт күргәне бармы? Әнә, Гыйззәтбану Сәгъдетдиннең улын яратмыйча күпме интекте...
Алай да, авыл арасында күләгәле сүзләр куерганчы, кызны тапшырып куйганда яхшы буласы иде дә... Һәм карчык, шуларны уйлый да, үзе дә сизмәстән бер үк җырны суза башлый:

Асламчы килгән урамга,
Асыл алыйк юрганга...

Мөхәммәт бүген ныклы бер карарга килеп уянды: «Барам да

әйтеп салам!» Барса, Сания эш урынында юк, ишегенә «Хаста янына киттем» дип, кечкенә генә язу да элеп калдырган. Мөхәммәт киләсен сизенгәнме әллә? Көткәнме?!

Уразаев, кызны көтеп алырга ниятләп, йорт нигезенә килеп утырды һәм кесәсенә тыгылды. Ул һәрвакыт кесәсендә үткен пәке йөртә, ялгызы калганда, эче пошканда пәкесен чыгарып, кулына эләккән таякмы, тактамы, шуның ише нәрсәләрне юна торган иде. Башта аны-моны уйламыйча гына юныштыра башлый, юна-юна агачы йә кеше башына, йә берәр хайванга охшап китә, Уразаевның кызыксынуы арта, җан тынычлыгы иңә... Медпункт нигезенә утырып кесәсенә тыгылса, пәке анда юк, иртән кесәсенә салганын яхшы хәтерли, пәке мәктәптә калган булса кирәк!.. Көтте, көтте, Сания кайтып җитмәде, Уразаев кайтышлый мәктәпкә сугылды. Пәке — истәлек, Белкинның бүләге иде. Кадерле бүләк! Юлда хәтеренә төште, пәкене класста кесәсеннән алып өстәлгә куйган иде бит ул!

Кызу-кызу атлап керсә, пәке көндез куйган урында юк. Кем алыр?.. Пәкенең укытучыныкы икәнен беләләр, бер генә тапкыр күрсәтмәде ич ул аны балаларга!

Ул көндез мәктәптән чыгып киткәндә класс бүлмәсендә бер Йосыф кына калган иде. Мөхәммәт буш мәктәптә башын тотып шактый утырды... Йосыф шук малай, тик аңа «пәкемне бир!» дип турыдан-туры әйтеп булмый ич инде! Бәлки, Йосыф алмагандыр? Алуы да ихтимал, шуклыгы бар малайның, бик бар!

Пәке югалуын Мөхәммәт беркемгә дә әйтмәде, алган кеше үзе китереп бирер дип ышанып көтте. Өмет артыннан башына ару гына бер фикер килде...

Иртән ул класска килеп кергәндә балалар стена газетасы тирәсендә укмашканнар иде. Маннур, чыңгырдап торган әче тавыш белән «Укытучы рәхмәте» дигән мәкаләне кычкырып укып тора. «Мөхәммәт абый граждannар сугышы истәлеге итеп йөрткән пәкесен югалтып куйган иде. Йосыф аны табып, абыйга китереп бирде. Абый аңа чын күңелдән рәхмәтен белдерде».

Кич белән, Уразаев дәфтәрләр тикшереп утырганда, сак кына ишек кактылар. Ишетсә дә, беразга ишетмәмешкә салышкан Мөхәммәт, эченнән генә куанып:

— Ярый, рәхим итегез! — дип эндәште.

Кыюсыз гына атлап Йосыф килеп керде.

— Мин... абый... пәкене китердем...— диде малай һәм тамак төбенә нидер тыгылып, туктап калды.

Җиңен күзенә китерде, җиңе ертык малайның, беләге ябык.

— Табып китергәнеңә зур рәхмәт, Йосыф! — дигәнне ишеткәч, малайның йөзе ачылып китте. Чыланган күзләрендә нур балкыды. Ул җиңеләеп өенә җилдерде...

Мөхәммәт, Йосыф өчен сөенеп, Шамиле янына айдай балкып кайтты, ул да тырышып-тырышып хисап чишеп утыра, дәресен әзерли. Кыскасы, һәр яктан тормыш көйләнә, балалар белән арадашлык ныгый иде.

Бу минутларда Мөхлисә карчык белән Сания арасында Мөхәммәткә бик нык кагылышлы әңгәмә бара иде. Әңгәмәнең төбе — җыеп кына әйткәндә — бер дә Уразаев файдасына түгел...

Сания яшереп тормады, Уразаевта күңеле барын әнисенә туп-туры әйтеп салды. Мөхлисә әби җавапны ашыгып бирмәде, күтәрелеп тә бәрелмәде, кызмады да, кызын үз янына утырырга чакырып, салмак кына сөйләп алып китте.

Әле аңа кадәр...

Көндез, Сания囗 эштә чагында, истә-оста югында Мөхлисәләргә Чырык Абдрахман килеп керде. Ишек катына басып кына калмады, түргә үк узды, мыштырдап дога укыды, битен сыпырып алды...

— Туйлар кайчан инде, Мөхлисә? — диде Чырык, сакалын кашып.

— Нинди туй? — Мөхлисә ялт итеп яулыгы белән бер күзен каплады.
— Мин башка авылдан килмәдем, шөкер, һаман шушы Ялан авылы кешесе. Син яратмасаң да бөтен авыл миңа тартыла... Хәбәр яралса, иң әүвәл, миңа килеп ирешә. Бәлки, мин синең файдага йөримдер. Кызыңны бәладән тартып алырга җыенамдыр? Ә син борын җыерасың. Килешми, кем, Мөхлисә.
Чырыкның ялганчы икәнен дә белә, ышанмаска кирәген дә аңлый Мөхлисә, әмма бүген сүз аның кызы турында, Саниянең киләчәге турында бара. Сүз авыр, хәбәр күңелсез булырга охшаса да, Чырыкны тыңламыйча ярамый.
— Сөйлә, Абдрахман әкә,— диде ул көрсенеп.
— Уразай начар адәм түгел. Акча эшли! Тормышы бар!.. Мәгәр аның белеме юк. Мөгаллим булып мәңге эшли алмас... Җитмәсә...— Ул иреннәрен ялап Мөхлисәгә таба иелә төште.— Хәбәрләр йөри... Теге чакта Колчакның шымчысы булган икән ул! Йөз кешене төрмәгә тыккannар, туксан тугызын чыгарып атканнар, бер Уразай исән калган! Һаман тикшерәләр икән аны, төбенә төшеп җитә алганнары гына юк...
Чәй эчмәде Чырык, озак утырмады, әмма ананың күңелен утка ыргытып чыгып китте. Җитмәсә Саниясе дә шул кичне, әнисе шундый янып-көеп йөргәндә сүз башлады.
— Әни,— диде ул үзенә генә хас йомшак-татлы тавыш белән.— Син ни әйтерсең? Миңа кияүгә чыгарга бик вакыт.
— Уразаевкамы? — дип сорады Мөхлисә, ни өчендер, мөгаллимне фамилиясе белән атап.
— Аңа.
— Асла ризалыгым юк! — диде кистереп Мөхлисә.
— Нигә? — дип сорады гаҗәпләнгән кыз.
Һәм ана, үзеннән дә бераз өстәп, бераз арттырып, Чырык сөйләгәннәрне елый-елый кызына җиткерде. Аныңча, Мөхәммәт Уразаев дөньяда иң кара, иң куркыныч кеше, аны менә-менә тагын төрмәгә алып китәргә тиешләр, алып китәргә тиеш кешеләр әнә генә, ындыр артында булып чыкты...
Сания хафага калды. Иртәгәсе көнне, дәресләрдән соң Уразаев мәктәпкә килгәч, белгән-ишеткәннәрен түкми-чәчми аңа сөйләп бирде.
— Дөресме? — дип сорады.
— Дөрес икән, мин укытучы булып эшли алыр идемме? Чирегенә хак булса да мине партиядә тотарлар идеме?
Кыз, әнисен тыңласа да, Уразаевка ныграк ышана иде. Әмма бүген генә өйләнешү-кавышу турында сүз булуы мөмкин түгеллеген икесе дә сизделәр.
Кыш узды, яз үткәнен дә сизми калдылар. Иртештә су ташыды. Урманнар, яланнар яшелләнде. Җәй көне Уразаев Төмәнгә бер айлык укытучылар курсына барып кайтты. Һава алыштыру, бераз яңа җир, яңа кешеләр күрү кирәк иде аңа. Иң сөенечлесе шул булды, үзе белән партизаннар отрядында сугышып йөргән ике иптәшен очратты. Алар да тора-бара укытучы булып киткәннәр. Кордашлар, көрәштәшләр арасында сүз җитәрлек иде. Иптәшләре Мөхәммәтне кызыктырдылар — икесе дә гаилә корып, пыр тузып бала үстереп яталар икән.
Китеп торуның тагын бер ягына игътибар итте ул. Сания белән булган мөнәсәбәтләрне ачыклау өчен кирәк иде бу! Аеры тору — йә кушылдыра, йә араны ерагайта.
Мөхәммәт Саниядән башка яши алмавына тагын бер кат инанды.
Сания дә күп нәрсәләрне ачыклады. Ул нәкъ әнә шул — яндыра, көйдерә торган, шатландыра-көлдерә торган, мәхәббәт дип аталган зәхмәткә тап булган икән! Мөхәммәт абыйсы киткәннән бирле дөнья китек, авыл элекке ямен җуйган. Иртеш шыксыз, ярлары котсыз, күк сүрән, аш тәмсез иде. Кыз көннәрне генә түгел, сәгать-минутларны саный башлады.

Уразаев Түмәндә чакта тагын бер хәл булып алды. Казан каласыннан килгән укытучы Мәдинә авыл халкы белән аралашып китә алмады, Себер татарлары телен яратмады, күз керфекләренә гел яшь эленеп йөрде, сагынды, саргайды, «Мине моннан җибәрегез, зинһар!»— дип районга да, өлкәгә дә хат арты хат җибәреп торды. Ниһаять, аңа туган ягына кайтырга рөхсәт иттеләр. Беркем белән дә ныклап аралашмаган, берәүнең дә күңелендә җылы урын тапмаган бу курач кыз көннәрнең берендә эреп югалды. Аның урынына Айсетдин исемле егетне җибәрделәр. Шушы як кешесе, Ялутор ягыннан, педтехникумны уңышлы тәмамлаган, әзерлекле, белемле, шуның өстенә бераз һавалырак та егет. Фырт киенеп йөри, эссе көннәрдә дә муеныннан галстугы төшми, аягында кап-кара шиблетлар... Килүгә яшьләр арасына кереп китте, лекцияләр укыштырды, кичке уеннарга да баш булып алды. Кара шиблет үкчәләре белән Иртеш болынының яшел чирәмен таптап-тыпырдап байтак кызларны йокысыз калдырды. Кызлар бу купшы егеткә карап йотылдылар. Тик егетнең күзе беренче мизгелдә үк Сания ягына төште... Бу хәбәр авылда тиз таралды. Шәүкәт белән аның иптәшләре бу хәбәргә канат куеп очырттылар.

Чырык Абдрахман, маңгаен җыерып, учларын бер-берсенә ышкыды һәм Айсетдинне чәйгә чакырып, тамырын тотмакчы булды.

— Безнең авыл ошыймы соң яшь мөгаллимгә?— диде ул әүвәл башлап.

— Ярыйсы болай... Уразаев абыйны гына күрә алган юк, аны да әйбәт кеше дип сөйлиләр.

Сүз нәкъ Чырык көткән юнәлештә башланып китте.

— Бер ай курсларда алганын селкеп йөри-йөри коеп бетерде инде! Аннан калмады, мунчада сугышып бетте... Белем саерак! Зав итеп сине куячаклар. Шулайдыр бит?

Айсетдин, Чырык әйткән белән тулаем килешсә дә, теле башканы әйтте:

— Уразаев тәҗрибәле, олы кеше. Миңа болай да бик ярый!

— Олысын олы да... Барысын да аңа бирмә инде син!

— Аңлап бетермәдем, Абдрахман әкә.

— Соң, авылыбызның кура җиләге кебек кызын шул карт алашага биреп куймыйк инде!— Сүзне эредән башлап куйгач, Чырык, гадәтенчә кыска гына тыныш ясап алды, кәпәчен уңгарак этеп, чуалган сакалын тырнап куйды.— Яшең җиткән икән, энем. Вакытлы өйләнеп кую мәслихәт. Бездә нәкъ синдәй егетне көтеп торган кыз бар. Яшь чакта шуның урагын урып рәхәтен күреп калу кирәк!..

Абдрахман карт Айсетдиннең бөтен эч серен белә диярсең!

«Дөнья күргән кеше, күңеле яхшылык тели торган карт!»— дип уйлады Айсетдин, кунактан кайтып барышлый. Чәй арасында, очраклы гына бер шешә аракы да табынга менеп утырды. Айсетдин бик кыстатып кына бер чынаякны каплап та куйган иде...

Икенче көнне үк медпунктка барып житте.

Көне буе шунда чуалды. Кичен Санияләрнең өйләренә килде. Кызның кырыслыгын, үз итмәвен чамаласа да, Чырык Абдрахманның сүзләре аңа гайрәт өстәгән иде. «Вакытында урагын урырга кирәк бу бичәнең!»— дип уйлады, үз-үзенә бик ышанып Ялутор егете.

Сания күрешүдән баш тартты, очрашырга риза булмады, егет әрсезләнеп килеп керде исә, эш тапкан булып пункттан чыгып китте. Аның күңеле зарыгып-зарыгып Уразаевны көтә, җаны аның тизрәк кайтып житүен тели иде. Ә Айсетдин, гөнаһ шомлыгына каршы, Мөхлисә апага ошады да калды!

— Егетнең асылы, укыган, чибәр, яшь. Тагын ни кирәк сиңа?— дип сайрады ана.

Килә, үз өенә кергәндәй кыю атлап керә Айсетдин, Саниянең каршысына барып утыра.

Бүген дә шулай булды...

Кирәк-яракларын җыештырып «Ашыгыч барасы җирем бар!»— дип ишеккә юнәлгәндә генә урамда ниндидер шау-шу купты. Кемдер ачулана, кемдер кычкырып елый иде. Айсетдин Саниягә ияреп урамга чыкты. Ачуланучысы Хафиз әкә икән, елаучысы Рокыя малае Маннур. Хафиз әкә малайның колагын умырып тоткан да акрын гына урам буйлап килә. Пункт тирәсенә җитәрәк, Айсетдин белән Санияне күреп, икесе дә тукталдылар.

— Әһә, бик әйбәт!— диде Хафиз әкә.— Яшь мөгаллим дә монда икән. Менә күр, укучыгыз булыр бу малай!

— Нишләгән ул?

Маннур тагын да ныграк елый башлады...

Елауның нәрсә икәнен байтактан үзләштергән тәҗрибәле малай иде инде Маннур! Моннан берничә ел элек, әнкәсе белән ике кәрҗин карлыган җыеп алар шәһәргә бардылар. Көянтәләрен алмаш-тилмәш иңнәрдә йөртеп икенче көнне генә, арып-талып шәһәргә килеп керсәләр, чир-чор таралган булганга яшелчә җимеш сатуны катгый рәвештә тыйганнар икән. Аны-моны белмәгән ана белән бала җәелеп торып, мактый-мактый карлыган сатарга керешкәннәр. Табигый буларак, аларны милиционер эләктереп алган, кәрҗиннәре белән идарәгә үк иртеп кергән. Юньләп русча да белмәгән ана аптырап ни эшләргә белмәгән. Сөйләп карый — аңламыйлар. «Акча юк, акча кирәк!»— дип зарлана, аңламыйлар. Шуннан ул шыпырт кына Маннурга еларга кушкан.

— Елап кара, катырак кычкыр!— дигән.

Болай да сытылырга торган малайга шул гына кирәк тә, ул идарәне генә түгел, урамны, урамны гына түгел, бөтен шәһәрне сасытып акырырга керешкән. Аңлатып-аңлатып та аңламаган, зарланып-зарланып та шәфкать күрсәтмәгән милицияләр малай акыра башлагач кул селкегәннәр һәм ике кәрҗинне дә тоттырып куып чыгарганнар...

Шуннан бирле Маннур бер нәрсәгә оста — берәрсе кагылды исә авызын карлыгач оясы хәтле ача да мә, тотына акырырга!..

Хафиз әкә дә малайны җибәрергә тора, шул дәрәҗәгә килеп житкән иде. Айсетдиннең, яшь укытучының гына моңа һич исе китмәде, ул Сания яныннан кузгалып малай тирәсенә барып житте һәм икенче колагыннан эләктереп алды. Хафиз әкә малайны ычкындырды, әмма Айсетдин колакны каерып, төптән үк умырып тоткан иде. Маннур чынлап торып үксергә тотынды.

— Мин сезгә Уразаев кына булмам! Сызган сызыктан йөртермен! Мин сезне биетермен! Карак!..

Аның бу сүзләрен ишетеп Сания генә түгел, Хафиз әкә дә таң калды. Маннур исә, бераз читкәрәк китеп, колагын уа-уа үкседе.

— Ялгыш кына барып кергәнмен аларның бакчасына...

— Ә кыярлар?

— Кыярлар да ялгыш кына минем кесәгә килеп кергән.

— Әле син алаймы?— диде малайга таба юри омтылып Айсетдин,— карак кына түгел, алдакчы да икәнсең син!

— Шәһәрдә милиция дә миңа ышанды,— дип сукранды малай,— ә син ышанмыйсың. Үзе укытучы...

— Уразаев абый исемен бик тиз сата башлагансыз сез,— диде Сания егетне әрләп.— Әдәпсезлек түгелме бу?

Шушы секундтан ул егетне бөтенләй күралмас булды...

Мөхәммәт курслардан дүрт көн алдан китте. Тобол коммунистларының җитәкчесе, аның күптәнге дусты Белкин кинәт үлде. Мөхәммәт аның җеназасына кайтуны намус эше дип санады...

Зираттан чыкканда аны мәгариф бүлеге мөдире куып җитте.

— Иптәш Уразаев,— диде ул.— Бу хакта сүз кузгату хәзер уңайсыз... Алай да, авылга кайтып киткәнче минем янга кереп чыгыгыз әле. Мәсәлән, иртәгә. Килештекме?..

Уразаев Яланга кайтырга бик нык ашкынса да (Сания, Шамил — сагындырдылар!) ул Тоболда төн куныл калды. Иртәгесен мөдир катына керсә, мөдир күзгә күренеп хафаланып аның алдына бер кәгазь ташлады.

«...безнең авыл халкыннан көлепме, Яланга әкәмәт начар укытучы җибәргәнсез. Ул адәм ышанмаслык эшләр эшли, яшь кызлар артыннан сөйрәлә, яшьләрне ызгыштыра, сугыштыра. Аны бездә беркем дә яратмый, аның Колчак шымчысы икәнен бөтен кеше дә белә. Коммунист иптәшләрен сатып кына әсирлектән котылган Уразаев ничек ирektә йөри ала соң? Нигә исән калган ул? Колчак аның кайсы ягын яраткан?.. Авылның кулагы, сөрелергә тиешле Ырсытдин Котлыбаевка авылдан качарга ярдәм итте, аңа ялган документлар әзерләп бирде. Бу эше өчен аңа байтак алтын тәңкәләр яуган, дип сөйлиләр.

Уразаевның махсус белеме юк, тәрбияви эштә гел хата җибәрә, балаларны мәктәпкә җибәреп булмый. Мәктәптә тәртип юк, укучылар урлаша, алдаша башладылар. Тиз арада аны бездән сөрмәсәгез, балаларны бозып бетерәчәк. Андый мөгаллим безгә кирәкми».

Сыздин-быздин куелган имзага карап Уразаев озак кына уйланып утырды.

— Ни әйтә аласыз, иптәш Уразаев?— диде мөдир, сынап карап.

— Ни әйтим? Сез яңа кеше. Ә бу кәгазь, район оешмаларын шөбһәгә салып байтактан йөри инде. ГПУга кереп чыкты. Прокурорда булды. Райком да бу сүзләр белән таныш...

— Без моңа чара күрергә тиеш, иптәш Уразаев.

Бу юлы мөдир «иптәш» сүзен теләр-теләмәсрәк, теш арасыннан гына чыгарып әйтте.

— Райкомда тикшерделәр. Анда мәрхүм Белкинның аңлатмасы саклана. Минем ничек-ничек акларга әсир төшүемне дә, бу яланы Канталыев таратканын да ул бик яхшылап аңлатып биргән иде. Кызыксынсагыз, карый аласыз...

Мөдир кызыксына торган яшь кеше иде, ул райкомга шунда ук барып җитте, тик Уразаев кәгазьләре арасында Белкинның аңлатмасы юк иде. Язманың булуын райкомда да хәтерлиләр, «Бар иде андый кәгазь»,— диләр.

Икенче секретарь җитәкчелегендә абруйлы комиссия төзелде, аның составына мәгариф инспекторы да кертелде.

Белемен күтәреп, ачылып, ныгып кайтырга дип киткән Мөхәммәт Уразаев... Ялан авылына гайбәт тулы кәгазь, шул кәгазьдәге кара юлларны ачыкларга ниятләгән куркыныч комиссия әгъзаларын ияртеп кайтты.

— Ни булды әле алай?— дип сорады пошынып Эссәт Фәтхуллин.

Уразаев иңбашларын гына сикертте.

Аны әчкерсез сөенеп, шатланып, оча-оча кочаклап улы Шамил генә каршылады, башкалар һәммәсе дә каш астыннан гына карыйлар кебек тоелды. Ул үзенең адымнары авыраюын беренче мәртәбә сизде. Иңбашларын әлеккечә күтәреп йөреп китмәкче була, ике-өч атлауга авыр уйлар аны басалар, күз үзеннән-үзе җиргә таба тәгәри...

Комиссия членнары иң әлек ындыр табагына бардылар. Анда яшьләр ашлык җилгәрәләр. Бер якта көлтә таратып ташлаганнар, анда «трат-та-тат» дигән күңелле тавышлар чыгарып чабагачлар бии. Бер кыз: «Шәүкәт, чабагачыма юри сугасың!».— дип чырылдап кычкырып җибәрә. (Шәүкәт монда, кызлар арасында!) «Ә—ә, син әле алаймы? Әләкләшәсеңме?!»

Шәүкәт аны-моны кылырга өлгерми, кызлар аны урап алалар да хуш исле бодай саламы белән күмеп тә ташлыйлар. Шәүкәт: «Булыш, кырыкмаса кырык кыз дустыңны иләп ята!»— дип иптәшенә кычкыра. Иптәше Булат, иләмсез озын торыклы, какча егет, кырык кызны кочагына сыйдырып, аларны Шәүкәт тирәсеннән сөзеп ала. Шәүкәт атылып

килеп житеп кызларның берсен — Булатның күзе төшеп йөргән, кысык күзле, чем кара чәчле, тыгыз таза гәүдәле кызны биленнән эләктереп алды да, алар көпшәк салам эченә чумып та киттеләр. Ун-унбиш секунд узгач, сап-сары шәлгә төренгәндәй, Мәүлихәнең башы калыкты, ул нәни, әмма таза йодрыклары белән егетнең җилкәсен төя башлады.

— Чабагач та кирәкми Мәүлихәгә!— диештеләр өлкәнрәкләр. Алар, төенчекләрен чишеп, аннан ипи кыерчыклары, пешкән күкәй, сөт чыгарып тамак ялгарга утырганнар иде.

Ниһаять, Булат белән Шәүкәт тә калкындылар. Шәүкәт икенче бер кызга, Шәгъбикәгә күз атып алды да, күз карашы Мәүлихәгә тукталды. Булат кесәсеннән тарак чыгарып, Мәүлихәгә сузды.

— Әллә безнең өчен кордылар инде болар спектакльне?— диде секретарь үз юлдашларына һәм яшьләргә якынрак килде.— Егетләр, сездә кыйгач кашлар күп икән, күзгә туйлар күтеләдер?!

— Шәүкәт белән Булат урынында булсам, бу кура җиләкләрен кабып кына йотар идем!— дип тамак кырды Хафиз әкә.

— Булыр! Туйлар да булыр!— диде Булат белән Шәүкәт беравыздан.

Мәүлихә, ут кебек кыз, башын чайкады:

— Белмәем, белмәем, иптәш, егетләребез бик шәләүләр[1], кыз куенында йоклауның ни икәнен белмиләр булыр мескеннәр!

— Ачуландырсаң, бүген үк урлыйм үзеңне!

— Шәүкәт әйтәме моны? Авызына капкан май кисәген дә төшереп җибәргән егет?

Егетнең Саниягә өйләнә алмавына ишарә иде. Шәүкәт кызарынды-бүртенде, бер уч салам алып Мәүлихәгә таба ыргытты.

Әссәт Фәтхуллин килгән кунакларга Шәүкәт, Сания, Мөхәммәтнең уртак вакыйгаларын сөйләп өлгергән иде инде, ындыр табагына кагылырга да ул кинәш итте. «Яшьләрнең үзара сөйләшүеннән дә эшнең кай тирәдә булуын аңларсыз үзегез!»— диде. «Сания артыннан йөреп Шәүкәтнең авызы пеште, Уразаевка үчле булып калды, ул язган булуы да бик ихтимал»,— дип өстәде.

Комиссия членнары да Чырык Абдрахманны беләләр икән, арадан берәү:

— Монда аларның хикмәтле кешеләре бар. Шуңа кагылыйк,— дип тәкъдим ясады.

— Кай ягы белән хикмәтле?— дип сорады секретарь.

— Мең дә берне белә,— дип ачыклады башкалар.

Комиссия членнары килеп кергәндә Чырык Абдрахман сәкегә җәелгән егән[2] өстендә аякларын бөкләп кысыр чәй эчеп утыра иде. Керүчеләрнең тышкы кыяфәтеннән үк тикмәгә йөрмәүләрен шәйләп, аның чырае агарынып китте. Чынаягын тиз-тиз куеп учын сакал очына тидереп алды да, калкынам дигәндә чак кына самавырны аудармады. Кыйшайган самавырдан егәнгә кайнар су акты. «Нәрсәгә шулай курка?»— дип уйлап алды секретарь.

Керүчеләрнең үзен тикшерергә килмәүләрен, Мөхәммәт Уразаевның тамырын тотарга йөрүләрен белгәч кенә Абдрахманның тавышы да, үзүзен тотышы да ныгайды. Комиссия членнары берәмләп тә, бергәләп тә аның кылларын тартып-тартып карадылар, әмма Чырык ачылып китәргә ашыкмады, нягын селкеп: «белмим», «юк», «күрмәдем» дигән сүзләрдән ары китмәде. Кич халыкның клубка җыеласын ишеткәч:

— Сүз шунда булыр инде, халык хөкемен әйтер!— дип куйды.

Район вәкилләре капкадан чыгып китүгә үк Чырык Абдрахман ашыгып кына өс-башына киде һәм ындыр артлатып кына сүз сыярдай

[1] Шәләү — булдыксыз.
[2] Егән — камыштан тукылган палас.

кешеләргә ашыкты. «Бүген Уразай егылачак!— дип уйлады ул сөенеп.— Бүген аның башын ашарга килгәннәр! Хәзер йоклап калмаска, башны җәтрәк табакка салырга кирәк!»

Берәүләргә кагылды, икенчеләргә сугылды, кемгә вәгъдә бирде, кемгә янады, куркытты, кайнар көлгә төшкән корт сыман бөгәрләнде, ул житешеп клубка барып кергәндә халык шыгрым тулы иде инде. Районнан килгәннәр арасында Эссәт Фәтхуллин белән Уразаев та утыра. Соңгы вакытларда авылча киенеп йөрсә дә, бүген кояшта уңган гимнастеркасын кигән, йөзе борчулы, ишек ачылган саен, кемнедер өметләнеп көткән кебек, шул якка карый. Халык өстәлгән саен аның борчылуы да арта кебек...

Күбесенчә ата-аналар, өлкәннәр килгән иде, соңга табарак инде утырыр түгел, басып торырга да урын калмагач, бер төркем егет-кызларны иярتеп Шәүкәт килеп керде.

Иң әүвәл Уразаевка сүз бирделәр. Ул сүз бирерләр дип уйламаган да иде, аягүрә баскач беравык аптырап залга карап торды. Аннан иплəп кенә үзенең беренче адымнарын, ничек эшли башлавын кыска-кыска гына итеп сөйләп алды, кыенлыкларга аз-маз тукталды...

Шул вакытта аның күз карашы иң алда утырган яшь бер кешегә төште. Ят кеше үткер күзләрен кыса төшеп аны үтәли тишеп чыгардай карап утыра иде. Күз карашлары очрашкан саен Уразаевның аркасы чемер-чемер итеп китте, тәне карулашты, сүзләре чыкмас булды, ул ни сөйләргә кирәген дә онытып урынына утырды. Маңгаен кульяулыгы белән сөртеп Эссәткә карады. «Кем бу?»— дип сорады ул ят кешегә ишарәләп. «Айсетдин, Мәдинә урынына килгән мөгаллим!»— дип пышылдады тегесе.

Эзләгән кешесен таба алмады Мөхәммәт, залда ул көткән Сания юк иде. Бик күп күзләр аңа таныш, ләкин аның күңеленә якты нур өстәрлек кеше бүген килмәгән. Уразаевның хурлыкка калуын күрергә теләмәгәнме? Аннары нигә бу Айсетдин дигән яңа укытучы аңа шулай дошманнарча карый? Ни белә ул Мөхәммәт турында? Гайбәтләргә ышанып аны дошман дип, хыянәтче дип уйлыймы? Әллә шулай уйларга нигезе, дәлиле бармы? Үзен күреп өлгермәсә дә, комиссия членнарының яңа укытучы янына кереп чыкканын аңа ирештерделәр ич инде? Кемгә карарга да белмәде Мөхәммәт, уң якта, тәрәзә янына кысылышкан укучыларын күргәч кенә әченә җылы йөгерде. Шамиле, Йосыф, Сәлимә... Тагын кем соң бу? Таныш күзләр! Ташкәй ич бу! Каян, кайчан кайткан? Үсеп, тартылып киткән... Тукта! Үз исемен райкомның икенче секретареннан ишетеп, Уразаев исенә килде.

—...кәгазьдә Уразаев өстенә байтак гаепләр язылган. Сез хәзер шуларны ачыкларга тиеш. «Яшьләрне боза», дигәннәр. «Мәктәптә тәртип начар», «Укучыларның дәресләргә йөрисе килми»... һәм башкалар, һәм башкалар. Йә, сөйләгез.

Моңарчы аннан-моннан җыелган эскәмияләр шыгырдап, һәркем үз күршесе белән сүз алышкалап утыра иде, зал тынды, муеннар алга сузылып, киңәйгән колак тишекләре һәр яңа сүзне тотып алырга әзерләнеп зурайдылар... Эссәт Фәтхуллин:

— Ягез, сүзегез юкмы әллә?— диярга мәҗбүр булды.

Аның бу өндәвеннән зал тагын да тынып, куырылып калды. Һәм кинәт бөтен почмакларга ишетелерлек булып яшь кенә тавыш яңгырады:

— Мөхәммәт абый әйбәт!

Арттагы рәтләрдәге муеннар тагын да озынайды, алдагылар борылдылар. Тавыш тагын бер тапкыр:

— Яхшы мөгаллим!— дип кабатлады.

Ташкәй! Ырсытдин малае! Качып киткән кешенең улы. Комиссия членнары тирәсенә Сәмук килеп җитте, халыкны ера-ера, күпләрнең аягына баса-баса килде:

— Күрдегезме, Уразайны кем яклый?.. Ник яклаганын да беләбез! Кулак Ырсытдингә авылдан качарга ярдәм итте! Үзе кайта алмагач, малаен монда җибәргән! Беләбез Уразайның кем икәнен! Үзе Колчак ялчысы, яклаган адәмнәре кулаклар! Балаларны кыйный, кызларны аздыра. Авылдашлар, ник авызыгызны йомып утырасыз?!

Абдрахман да җиңеләеп китте: «Молодец, Сәмук!»

Аннары үзе сүз сорады. Күзләр хәзер аңа текәлделәр.

— Инде килсәк Уразайның гөнаһларына,— диде ул вәкарь белән тамагын кыра-кыра,— аларны тавык чүпләп тә бетерерлек түгел. Хатын-кызлар белән уйнадымы? Уйнады! Авыл белә, әйтмиләр генә! Яшь кызларны аздырдымы? Аздырды! Олы коммунистларга яшь кызларны кочарга дигән закун бармы әллә?!

Хафиз әкә түзмәде, урыннан кычкырды:

— Абдрахман, син Гобәйбә буйдакны ничек итеп өшкерүенне дә сөйлә! Мунча артында дим...

Гөр итеп көлешеп алдылар. Чырык сүзен дәвам итәргә теләп авызын ачкан иде, аңа сөйләргә ирек бирмәделәр. Уртак тавыш купты, аннан да моннан да куллар күтәрелде... Эссәт кулы белән өстәлгә сугып карады, секретарь да торып халыкны тәртипкә чакырды, әмма сүз буасы ерылган, беркемне дә туктатыр әмәл юк, телләр коргаксыган, кешеләр сүз дулкыны артыннан ияреп китеп тәртипне дә, чиратны да онытканнар иде...

Халыкның хәтере чиксез икән, әй! Һәммәсен искә алдылар!..

Мөхәммәтнең ачтан үләргә җитеп хәер эстәвен дә, Ырсытдинда ялчы булып интеккәнен дә, сәнәкче-фетнәчеләр гомуми мобилизация ясаган булып авыл ирләрен советка каршы котыртканда, командасы белән килеп җитеп, Канталыевны авылдан куып да телгә алдылар. Балалар укыта башлагач бер тиен акча сорамыйча хәләл көчен түгеп мәктәп түбәсе ябуын да, кара такталарны, парталарны үз кулы белән ясавын да, чирле балаларга колхоз аша ярдәм оештыруын да, хәтта тол хатын Мөхлисә кортканың капкасын яңартуын да яхшы сүз белән, рәхмәтләр өсти-өсти телгә алдылар. Секретарь халыкны тыярга тырыша, Сәмук нидер чәрелди, Чырык Абдрахман арык йодрыкларын йомарлап бер сикереп тора, бер утыра, ә Эссәт әкә көлә, кулын изәп тагын да ныграк сөйләргә чакыра, «Һай, әттәгенәсе! Әйт шуны, калдырма берсен дә!»— дигән сүзләр белән залдагыларны дәртләндерә иде. Халык бер кызса, тиз генә сүрелә белми. Хаксызлык белән очрашса халык тиз кыза, һәм аңа каршы килеп кара син! Башта тәртип урнаштырырга тырышып караган секретарь да кулын селкеп урынына утырды, роно инспекторы халык сөйләгәннәрне бөртекләп яза башлаган иде, тора-бара анын очлы ияге тагын да очлыланып куен дәфтәренә тия язды, ул да каләм-карасын ташлап, онытылып, залны күзәтә башлады. Мөхәммәт Уразаевны яклап әйткән сүзләрне «ур-ра» кычкырып каршылап утыручы укучылар азакка таба тагын да ныграк җанланганнар иде... Ташкәйнең күзләре ут булып яна, Шамил җылый, Сәлимә белән Маннур бер-берсен уздырып кул чабалар, Йосыф чыдый алмыйча биеп-биеп тә җибәрә иде... Хафиз әкә мактый Уразаевны, Туктасын мактый, Маһитап җиңги күкләргә чөя, хәтта йөз яшьлек, авызында теше һәм сүзе калмаганга иреннәренә мәңгелеккә челем кыстырып куйган Чәләкә әкә дә сикереп-сикереп куя, сүзе булмагач челемен генә селкетә...

Тавышлар бераз тына төшкәч, Сәлимәнең әтисе Туктасын әкә сүз сорады:

— Абдрахман әкә монда кешегә яла ягып пычрак сыларга кереште. Килешми, Абдрахман әкә, Ялан кешесенә алай ялганлау килешми. Монда чит кешеләр утыра, кунаклар, гөнаһсыз кеше турында аларның яман уйлавы бар. Без Уразайның нинди агач җимеше икәнен беләбез, тамыры үзебездә. Уразайга кушып ефәктәй саф кызыбызга, Саниягә дә сүз житкердең... Алай сөйләргә синең ни хакың бар? Азгын каенана киленнең намуслы булуына берчакта да ышанмый. Син шул каенана сыңары

булдыңмы, Абдрахман әкә?! Син аурак[1] башың белән кеше хөкем итәсең. Ярамый!

— Ә син гомергә авыш агач булдың!— диде явызланып Чырык.— Билең тик тормады синең! Колчак әсирлегеннән ничек котылуын аңлатсын!

— Ул хакта Белкин иптәшнең аңлатмасы бар,— диде Уразаев. Комиссия членнары язуның югалганын белсәләр дә, әлегә сүзгә керешергә яхшысынмадылар.

Зал тагын мыжлап китте, уңайга яңгыраган сүзләр арасында, кирегә сөйләп, җилгә каршы барырга маташучылар да очрады. Һәм кинәт зал тынып, сагаеп калды. Ишеккә сөялеп торган яшьләрне ерып клубка Сания килеп керде. Чәләкәнең төпчек килене бәбәйгә кысталып авырып киткән дә ул озаклап шуның янында мәшәкатьләнгән икән. Юк, Сания ишек катында гына тукталып калмады, һаман-һаман алгарак узды, кайнарланган, бит-маңгайларын тир бизәгән кешеләр тайпылып аңа юл саптылар, ул комиссия членнары янына ук килеп җитте. «Сания, безнең дуктыр!»— дип пышылдады Эссәт әкә секретарьга иелеп.

Мөхлисә апа башта клубка бармаска теләгән иде. Чырык Абдрахман коткы таратып йөргәндә аның бусагасына да кагылды. «Райуннан Уразаевны тикшерергә комиссия килде, килми калма, була бүген бер әкәмәт! Тиресен тунап алалар бүген егетнең!»— дип, канына тоз салып чыкты. Һушы таралган карчык бер мәлгә Уразаевка каза килүен теләде, кызын иләс-миләсләндереп йөргәне өчен җәзасын татысын, дип теләк теләде. Җыелышка да соңга калып кына килде, эчкә кермәде, ачык ишек янында ишегалдында басып калды, Шәүкәт белән Булатның сүзләре ачык ишетелеп тора иде аңа. Залдагы һәр сүзгә үзләренчә мәгънә биреп торган яшьләргә ачуы чыга башлады Мөхлисәнең. «Бираләр кирәген карт төлкенең!»— дип куанышуларын ишеткәч, аптырап, башы авыртып, чигәләре сулкылдап Санияне эзләп китте. «Абдрахман Чырык «Уразаевны райуннан ристовать итәргә килгәннәр»,— диде. Рас икән, хәзер мәктәпкә җыелып аны хөкем кылалар»,— дип елый-елый сөйләде.

Чәләкә әкәнең килене бәбәйдән котылып, җиңел сулап куйган мәл иде, Сания халатын салып әнкәсенә тоттырды, бит-кулын юып, клубка ашыкты. Ярты юлда тукталды, борылып өенә керде, сандык төбенә салып куйган комсомол формасын тартып чыгарды. Гимнастерка киеп, билен каеш белән буды, болай да матур күкрәге тагын да калкыбрак, нәзек билне дә, зифа буен да ачыграк итеп күрсәтте. Кыска киселгән чәчләрен учлап җыеп фуражкасы астына кертте, кара юбкасын юлда рәтләп, хром итеген аяусыз шыгырдатып мәктәпкә чапты...

Комиссар кыяфәтле кызга авылдашлары теләп юл бирделәр...

Хатын-кызлар рәтеннән (Себер татарларынча, Ялан кешеләре клубкамазар җыелганда хатын-кызлар бер якка, ирләр икенче якка утырышканнар иде!) кемдер аһ итте:

— Сания-я!..

Сания комиссия членнары утырышкан өстәл янына ук килде һәм, бер сүз дә дәшеп тормастан, Уразаевның муенын кочып алды. Хатын-кызлар сафы аһ итте, ирләр ягыннан кемдер, Сания узганда телен шартлатып: «Имиләренә сандугач кунарлык булган моның!»— дип тәтелди башлаган иде, хәзер, Уразаев янына килеп баскач, ысылдап аны да тыйдылар... Гомуми тынлык бер минут кына дәвам итте дә бөтен зал кинәт кул чаба башлады. Алкышлар тынгач, Сания иелеп халыкка рәхмәт укыды һәм чатнап торган ачык тавыш белән болай диде:

— Шушы кеше исемен миңа янәшә куеп гаеп ташлыйлар. Алайса, белегез: мин аны гомерлеккә яраттым һәм берәүгә дә бирмәячәкмен!

Күз төпләре дымланган Эссәт Фәтхуллин райком секретарена карап кулларын җәеп җибәрде: менә, күрдегезме, янәсе!..

Халык тагын дөбердәтеп кул чаба, аяк тибә, шатланып кычкыра

---

[1] Аурак — тинтәк.

башлады. Егетләр ишек катында авызын ачып шаккатып торган Шәүкәтне этеп-төртеп залдан чыгардылар.

Сания Уразаевны житәкләп тагын да тыгызланган халыкны ырыперып залдан алып чыгып китте.

Боз бер кузгалсамы!..

Шәүкәт һәммәсенә үч итеп, беркем дә көтмәгәндә, үзенең якын дусты Булатның сөйгән кызы, җиңел холыклы Мәүлихәгә өйләнде. Янәсе, күрсеннәр, Шәүкәт тә төшеп калганнардан түгел — кеше ярын тартып ала! Менә диган егете булган Мәүлихәне көпә-көндез килен итеп төшерделәр! Байтак салып, кызып киткәч, Шәүкәт дус егетләрен кочаклап елаган, имеш. Һәм: «Белегез, күрегез, әгәр теләсәм, Мәүлихәне бүгеннән ташлыйм да иртәгә үк Шәгъбикәгә өйләнәм! Ялангдагы һәр кызны яр итә алам үземә!»

Шәгъбикә Шәүкәтне яратып, якын итеп, ышанып йөргән икән. Ышанган да алданган... Ачы сүзләрне аңа да җиткерделәр, кыз атна-ун көн елады да үз иркеннән Булат янына барды: «Кушылыйк без, мин сиңа тугры хатын булырмын!» — диде.

Шәгъбикә төннәрен — Шәүкәтне, Булат Мәүлихәне уйлап үткәрде. Җилем белән дә берекми торган ике таш кисәге булды аларның тормышлары. Кеше арасында орышып-талашып яшәмәсәләр дә, тормышлары суык, яткан мендәрләре салкын иде.

Уразаевка: «Эшлә, тырыш!» — диделәр саубуллашканда комиссия членнары. Сания белән Мөхәммәт аларны рәхмәт әйтеп, Шамил белән Мөхлисә кортка сөенеп озатсалар, Ялан авылында йодрыкларын җиң эченә яшергән адәмнәр дә житәрлек иде. Чырык Абдрахман белән Сәмук җиргә төкеренделәр, кемдер карганды, Айсетдиннең, яшь мөгаллимнең күз карашы нәфрәт белән тулы иде.

## 19

Аланда учак яна. Юаш учак — качкыннар учагы. Алар тайганың әллә кай төшендә булса да, ничәмә-ничә еллар качып йөргән карун Рәхмәтулла сагая бела, өйрәнде. Инде сакалы агарды, башындагы чәче сирәкләнде, ә ул һаман шул Тобол төбәген ташлап кача алмый. Янында да нибарысы дүрт кеше калды. Дүртнең берсе — Капуш. Ул да бүген качар иде, Рәхмәтулланың боерыгы нык: «Күздән ычкындырмагыз, әгәр качарга ниятләсә, шунда ук чучка урынына бугазлап ыргытыгыз!»

Рәхмәтулла юлдашларын күзәтә, алар Капушны сагалыйлар.

Сәмук сирәк килә хәзер. «Авылдан чыгып йөрү куркыныч», — ди. Куркынычмы, түгелме, кем тикшереп караган аныысын, авылдан чыгып йөрү ничектер, мәгәр урман авызына бару да куркыныч хәзер. Колхозчылар берәм-берәм түгел, эшкә унарлап чыгалар, кая карама — кыр тулы кеше була, бала-чагасына кадәр шунда урала! Берәрсе күрә калса, бетте баш. Әнә, Илтер авылыннан узган атнада бер тана урлап суйганнар иде, милиция әле атка менеп, әле арбага төялеп көндез дә, кичләрен дә урман юлларын урады. Белә Рәхмәтулла, тәҗрибәсе ай-һай зур: олы юллар кисешкән урман авызларында сак тора. Яшерен сак!

— Ваше благородие!

Хәзер аңа шулай дип бары Капуш кына эндәшә. Башкалар аның авылда тагылган кушаматы «Карун»ны онытып, «Бүре» дип кенә йөртәләр. Чыннан да, күк ял бүре гадәтләре бар хәзер Рәхмәтуллада! Ничәмә-ничә чакрым җир үтеп, яңгырда чыланып, хәлсезләнеп алачыкларына кайтып егылсалар да, йокысы сак. Каравылга куелган юлдашы күзен йомуга, Рәхмәтулла сикереп торып йокычыны уңлы-суллы яңаклый башлый... Бүредәй усал, ерткыч! Мал суйганда җылы канын эчәргә ярата, калай кружкага тутырып ала да чүмереп кенә җибәрә.

— Кан эчкәнгә картаймыйсың син! — ди аңа ачуланганда Капуш. — Ә минем бөтен буыннарым сызлый, сызлый! Җибәр син мине моннан,

Рәхмәтулла! Мин олыгайдым. Авылга кайтып, Хәернисаның җылы корсагына җилкәмне куеп йоклыйсым килә.
— Җилкәң бетле бит!
— Мунча кереп бетен коярмын!
— Кеше күзенә ничек күренерсең? Кайда булдым диярсең?
— Ауда йөрдем, диярмен...
— Ха-ха-ха!— Рәхмәтулла көлә, аңа ияреп ике юлдашы да шаркылдый, тора-бара Капуш та көләргә тотына. Көлүен көлә, авызы гына гаҗәпкә калырлык: әллә көлә, әллә үксеп елый...
— Кайтарып җибәр син мине, Рәхмәтулла. Ваше благородие!
— Бар, кайт...
Капуш дәшми, качарга ниятләп урманга кереп югалган иптәшләрен бик тиз эзләп тапты моңарчы Рәхмәтулла, тәүлек дигәндә эзләренә төште. Төште дә кулларын бәйләп алып кайтты. Бер тәүлек алачык янында тотты. Аннан яшь, нәзек каүсәле нык агачны җиргә кадәр бөгәргә боерды. Тоткынның бер аягы, бер кулын җиргә, икенчесен агач очына ныгытып бәйләделәр дә тартылып торган каүсәне ычкындырып җибәрделәр... Иңрәп кычкырган үлем авазын бары Рәхмәтулла гына елмаеп тыңлады. «Бүре» диләрме? Дисеннәр. Шулай кирәк. Карун иде, дан алды, рәхәт яшәде. «Бүре» булды, рәхәт яши. Дөнья бер үзгәрмәсә бер үзгәрер...
Китап, газета, кәгазьләр кулга төшкәндә ул хәзер аларга ябырылып ташлана, укый, ятлап бетерә, үзенә-үзе җавап эзли: кая таба барыр бу дөнья?
Ә Капуш юаш учакка утын өстәргә куркып һаман шыңшый.
— Өемә кайтарып җибәр син мине, Рәхмәтулла! Гомер буе рәхмәт укыр идем...
Ә Рәхмәтулла газетага йотылган, кәгазьләр актара. Боларын аңа Сәмук китереп биргән иде.. «Уразайның мәктәбеннән алдым, авыл тарихын җыя башлаган!»— диде ул тешен ыржайтып.
Кызык кеше Сәмук, итне пешәр-пешмәс ашарга ярата, умырып ике кулы белән тота да вак-вак үткер тешләрен батыра, кан чәчрәп чыга, ә ул рәхәтләнеп, күзләрен йомып мырлый-мырлый ашый.
— Тәмле ашыйсыз...
— Тәмлене яратсаң монда көч...
— Ә юк...— Сәмукның күзләрендә курку.
Юк, Сәмук монда килмәсен, ул Ялан авылы белән элемтә, ышанычлы элемтә. Киек-җәнлекне җәлләми аннан Рәхмәтулла, бүләкне мул ядыра. Тик Сәмук та сирәк килә хәзер, күп вакытта буш кул белән килә...
Капуш, өметен өзеп, үз-үзенә сөйләнә башлый. Яшь чагындарак ишеткән вакыйгаларны кырыкмаса-кырык тапкыр сөйләгән булса да сөйли, белә— Рәхмәтулла андый йомакларны, әкиятләрне ярата.
Бәек авылыннан Корман бабай сөйләде, ат чабышында катнашкан икән. Менгән аты ябага тай — төссез булган икән. Әй көлә икән җыелган халык, әй мыскыллыйлар икән Корман картны. Ул чагында яшь булган инде ул булуын... Чабышка китеп барганда авылдан берәү: «Бу ат барлык чабышкыларның тизәген җыеп килсен өчен койрыгына китән[1] капчык тагып җибәрү кирәк»,— ди икән. Корманның үлеп ачуы килгән. «Менгән иясе дә кәмшәк нәмә икән, егылып үлмәсен тагын, янтыгына ике мендәр бәйләү тиеш!»— дигән икенчесе... Корман ярлы булган, көлүчеләр байлар икән. Ябага тай чабышкыларны узып киткән. Шаккатып атны унбиш метр ефәккә төргәннәр. Тай елык-елык килеп тора икән...
Рәхмәтулланың күзләре кәгазьдә булса да колагы җил ягында, җил Капуш ягыннан исә...
— Безнең якларда әүвәле Гафур исемле ат карагы яшәгән. Бер вакытны ул Голышман ягыннан чаптар урлап кайта. Эзәрлекләп куа

[1] Китән — киндер.

килүләрен чамалап, чаптарны тиз генә сарайга бикли дә үзе намазлык өстенә утыра. Ат урлаткан урыслар бастырып киләләр. Өйдә утырган Фәттах абзый урысларга намазны бозарга ярамаганын әйтә. Гафур намазлык өстендә килеш уңга-сулга борыла да: «Әссәламегаләйкем вә рәхмәтулла!»— диясе урынга: «Әссәламегаләйкем вә Фәттахулла, авызыңны ачып утырма, атны шылдыр, аллаһе әкбәр!»— дип догасын дәвам итә. Ул озаклап тәсбих тарткан арада, жиз комганын тоткан Фәттах сарайдан атны читкә алып чыгып өлгерә. Шулай котылып кала Гафур карак...

Капуш сөйли, җил ягыннан торып сөйли, тик бүген Рәхмәтуллага һич ничек тә ярый алмый, кәгазьләр өстенә йотылган. Укый, сынык каләм очы белән нидер тырнап та куя... Капуш өметсезләнеп кире борылып ятса, монда утлы күмерләр чәчрәгән икән, ул яралы киек кебек үкереп җибәрә. Анда да күтәрелеп карамады Рәхмәтулла.

1887 ел переписе буенча Ялан авылында 92 төтен булган. Бохаралылар 142 кеше, жирле татарлар 87, күчеп килгән татарлар 209 кеше булган (белә Рәхмәтулла, аның бабасы да җирле себер татары, бабаларының бабалары Күчем белән бергә Ермакка каршы сугышып йөргәннәр). Тобол төбәгендә бохаралылар 3284 кеше булып, күчеп килгән татарлар 1088, ә җирле себер татарлары 15918 җан булган. Себерлеләр күпчелек. Байлар — алардан. Сәүдәгәрләр дә алардан. Мөкә бай кебекләре завод-мастерскойлар да тоткан. Казан татарлары ярлы-ябагай, бае күчеп киләмени аның! Бае Казанда да рәхәт яши, Мәкәрҗә ярминкәсенә бара, Эрбеткә, Бохарага...

Хәзерендә дә күпчелек — себер татарлары...

Капуш: «Рәхмәтулла тыңламый да, ишетми дә»,— дип сукранса да, тыңлап-ишетеп яткан икән... Әнә бит Гафур карак та чаптарларны урыс ягыннан урлаган, урыс кешеләрен көлкегә калдырган... Тату чаклары булган халыкларның, талашып алган вакытлары булган... Хәзер дә талаштырып булмыймы соң аларны? Талаштырып, сугыштырып, болгатып?! Болганчык күлдә чуртанга рәхәт! Тымызык күлне корт баса. Нишләргә соң?

Сәмук: «Фәлән көнгә икмәк тапшырып бетерәбез, план үтәлә!»— дигән иде...

Планны өзәргә кирәк...

Кем өзә ала моны? Ничек итеп?..

Капуш... Утлы күмергә авып тәне пешкән Капушка бер генә күз салды Рәхмәтулла, тегесе шуны абайлап сикереп торды.

— Ваше благородие!

— Өйгә кайтасың киләме?

— Килә!

— Хатыныңның янтыгына терәлеп ятасың килә инде?

Җавап урынына Капуш бүре булып улый... Эренләгән күз төпләреннән болганчык су тамчылары бүленеп чыга...

— Ялан авылының бодай кырына ут салсаң, хатының янына кайтырга рөхсәт бирәм.

Капушның чәчләре кыймыл-кыймыл килә: ут салырга?

— Ничек?

— Уйлап тап. Яшен яшьнәтәсеңме, зилзилә кубарасыңмы — анысы синең эш, иген янарга тиеш! Бүген көн уңай, җил бар!

Алар икесе дә бүрек колакчыннарын кыйгайтып (җәен дә, кышын да башларында колакчын бүрек аларның!), колакларын көнгә куеп тыңлаадылар: агач башларыннан җил йөгерә, агач ботакларында җил шаулый... Капуш Рәхмәтулланың төтен, ылыс исе килгән тезләрен кочаклый:

— Агаем, атам бул. Кушма андый яман эш!

— Алайса — киттем юк.

— Барам!— Тәвәккәллек Капушның эренле күзләрендә ут булып кабына...

Теге көнне кедр урманына утны Капуш салды. Ут, агачтан-агачка күчеп, бодай кырына, арыш басуына таралырга тиеш иде... Яланлылар, янгынчылар утка сикерергә ирек бирмәделәр, ут байтак агачларны ялмады да тынды, җил дә басылды.

Ут салганнан соң Капуш Рәхмәтуллалар янына кайтмады. «Кушканнарын үтәдем, мин хәзер иректе кош!»— дип уйлады Капуш, уравыч юллар узып, Саз ягына юнәлде, өч тәүлек дигәндә, таң беленеп килгәндә, йортка кергән хатынының кечкенә тәрәзәсенә чиртте. Кеше-кара булыр дип тә курыкмады, тәвәккәллеге аңа көч биргән, йөрәген кабарткан иде.

— Кайларда йөрдең син югалып?— диде бичәсе.

— Дәшмә, бичә,— диде Капуш өйалдында гына чишенеп.— Мунча як.

Мунчадан соң бавырсак белән ике самавыр чәй эчкәннән соң, Капуш хатынына һушын җыярга ирек бирмәде, таң яралганда кайткан иде, кичке шәфәкъ чамасында, өй тәрәзәләрен такта белән кадаклап, бердәнбер кәҗәне бичәсенең әнкәсенә илтеп, сакларга кушып, сәфәр чыгып китте. Рәхмәтулланың кулы гына түгел, теле дә озын! Янында Сәмук, ул теләсә кемне сукыр бер тиенгә сата ала, авыл арасында «Утны Капуш салган!»— дигән хәбәр таратса... Уттан ерак, судан сак, яманнан читтә бул, дигәннәр борынгылар.

Капуш бер генә нәрсә яшерә алган иде Рәхмәтулладан: талап, урлап җыйган байтак акчасы бар иде аның, ут салганнан соң йөз яшәр кедр төбеннән чери башлаган китән капчыгын алып, саклык белән генә куенына кыстырды. Сәфәргә сәрмаясез чыгарга ярамый. Буш кул белән капка кага алмыйсың бу дөньяда!..

Мең бәла, җиде сагыш, ун каргыш белән Урта Азия шәһәрләренең берсенә барып эшкә урнашты Капуш... Йорт сатып алды, «Себер ягының һавасы килешми!»—дип, күршеләренә үз хәлләрен сөйләде. «Әйе, әйе, бездә дә колхозлар оешты, мин дә әйбәт кенә эшли, яши башлаган идем,— дип, күзен җиргә төшереп, түшен уды, сырхауландым, зыянлы булдым!»

Вакыты җитеп хәрби учетка басарга дип курка-курка гына барып керсә... Капуш егылып китә язды! Борыны өстенә нәзек алтын кысалы күзлек элгән Канталыев утыра иде бүлмә түрендә.

Алар, бер-берсенә карашып, телсез калдылар...

## 20

Әйткән идек — Саниянең чаялыгын, кыюлыгын күреп, Шәүкәт шаккатты, Булат гаҗәпләнде, Мәүлихә белән Шәгъбикә кияүгә чыктылар, һәммәсе хәрәкәткә килде...

Саниянең чаялыгына, кыюлыгына иң нык гаҗәпләнгән кеше Мөхәммәт Уразаев үзе иде. Уразаев өчен кыен вакытта, исеменә кара тап ягылырга торганда, гайбәтләргә, имеш-мимешләргә чик куеп, Сания аны «Үз ярым, үз сайлаганым!»— дип атады һәм гомерен-гомергә бәйләде. Берәүләр Уразаевның кадалып төшкәнен көтеп торганда, аны этеп-төртеп һәлакәткә илтергә маташканда, Сания кулын бирде, аны упкыннан тартып алды.

Дөрес, залда авылдашларының аңа теләктәш булуын, яратуларын, балаларны әйбәт тәрбия иткәне өчен рәхмәтле булуларын күрү үзе дә аңа көч биргән, аның җанын тынычландырган иде. Ул: «Күңелең саф булу, яшәешең якты булу кеше өчен нинди зур бәхет!»— дип, күңеленнән генә тәкрарлап та утырган иде. Шуның өчен ул, инде Санияне яр иткәч, күңелен аңа тулаем ачарга ният итте. Арада кер калмасын, шикшөбһәләр юылсын... Мөхәммәтнең авыр тормыш юлында кыек атлап куйган чаклары булмадымыни?.. Ырсытдин кызы булып исәпләнеп йөргән Мәүлия, аның кызы түгелмени? Һәм ул һич читләтеп тормастан,

кайтып, беравык әл-хәл алгач ук Саниясенә үз ялгышларын ачып салырга кереште. «Мәүлия» исеме чыгуга ук, Сания бармаклары белән аның авызын каплады:

— Кирәкми, Мөхәммәт абый...

— Абый?

— Кирәкми, җаным, мин барын да беләм.

— Ничек?

— Мин генә түгел, аны авылда бик күп кеше белә.

— Һич уйлаганым юк иде.

— Чырык Абдрахманның колагына кергән сүз мең авызга барып ирешә ич.

— Анысы шулай...

Тагын да ныграк гаҗәпләнде Мөхәммәт Уразаев: Сания барын да белгән хәлдә аны үз янына тартып алган!.. Каян, ни өчен килде аңа мондый тиңсез бәхет?!

Шул мизгелдән башлап Уразаевның да тыныч оя корып, рәхәтләнеп гомер сөрер чаклары җитте. Арып-талып эштән кайтуыңны өзелеп көтеп торыр кешең бар. Иртәрәк кайтсаң, син аны өзелеп көтеп аласың... Җылы сүз, якты йөз белән озатып куяр һәм каршы чыгып алыр иркәң бар. Өс-башың һәрчак чиста, өстәлеңдә тәмле аш. Шуның өстенә бердәнбер улың, ярым үксез яшәп интеккән улыңның э н к ә с е бар...

Бу гаиләдә һәр тумыш көн шатлыклы бәйрәм төсен алды. Җиһазга ярлы гына булган Мөхлисә әби йорты күңелле шау-шуга тулды. Киң күңелле Саниягә Шамил элек тә гел тартылып тора иде, хәзер ана тагын да ныграк иялә́ште. Һәм ана мәхәббәте бүләк иткәне өчен аны әчкерсез сафлык белән яратты.

Уразаевка соңлап килгән бу бәхет чиксез кыйммәт һәм кадерле иде. Мөхлисә әби дә, баштагы көннәрдә яшертен-яшертен генә көрсенеп алгаласа да, балаларның бәхетен күреп, ул да бу сөенечне уртак итте, яшәреп киткәндәй булды, кәшимир яулыгын элеккечә ияк астыннан түгел, түбәгә чөеп бәйли башлады.

Шулай атна узды, ун көн. Сания иртәнге чәйне әзерләгән арада Мөхәммәт газета караштырып утыра иде, күзе бер мәкаләгә төште. Күрше район комсомолецы Петр Лосевны тракторда пар сөргәндә урманнан чыккан бандитлар урыныннан тартып төшергәннәр дә өстенә керосин сибеп ут төрткәннәр... Үзләре качып киткәннәр!

— Сания, кара әле! Могҗиза! Петрны үлде дип уйлаганнар, ә ул исән, исән!..

— Нәрсә булган? Кем исән?

— Петр Лосев исән! Бандитлар аны үтерергә теләгәннәр... Һм-м... Күрче син аларны! Бандитлар өчесе дә кәләпүштән, татарлар иде, диелгән... Һәм шуларның берсе Ялан авылыннан Рәхмәтулла Дәүләтбаев булырга тиеш, дип тә өстәгәннәр. Димәк, ул да исән?!

Петр Лосевны, рус егетен, рус тракторчысын Рәхмәтулла Дәүләтбаев яндырырга теләгән икән, монда мәсьәлә көн кебек ачык. Рус белән татарны сугыштырырга теләгән, ызгыштырырга маташкан, дип уйлады Мөхәммәт Уразаев... Һәм ялгышмады.

Шул кичне үк Ялан клубында халык тагын җыелды. Газетадагы мәкаләне кычкырып укып чыкканнан соң, тетрәнеп калган яланлылар явыз Рәхмәтуллаларга, урманнарда посып яткан бандитларга үз нәфрәтләрен белдерделәр һәм Петр Лосевка саулык-сәламәтлек теләп хат җибәрергә булдылар...

Бу эшне дә Мөхәммәт Уразаев башлап йөрде.

* * *

Айсетдиннең Уразаев белән әле капма-каршы килгәне юк диярлек, башын аска иеп, шыпырт кына йөргән бу кулага кешенең эчендәге

уйларын ул үзе генә белә иде. Үзенә дә кайбер чакта кайбер нәрсәләр ачылып җитми иде егетнең!.. Мәсәлән, нигә беренче көннән, исемен ишетүгә үк яратмый башлады ул Уразаевны?

«Яхшы, бик яхшы» билгеләре чекерәеп торган дипломын РОНО мөдире алдына китереп салгач, ул үзен шәһәрдә, һич югында зуррак, затлырак авылда калдырырлар дип ышанган иде. Тигәнгә тиен башы, тимәгәнгә куян башы дигәндәй, аның кайбер иптәшләрен, һич көтмәгәндә, җидееллык мәктәпләргә билгеләделәр. Ә аңа, педагогик кагыйдәләрне сүзен-сүзгә ятлап өйрәнгән хәтерле укытучыга, нибарысы беренче һәм өченче класс борчалары гына тәкъдим иттеләр. Карышыр иде, эшне карышудан башлауны яхшысынмады Айсетдин.

Мөдир ишеге төбендә чират көтеп торган иптәшләре сораша башлагач, «Утыра шунда чалбар төбе туздырып бер күзле бүкән!» — дип, кызу-кызу атлап чыгып китте. Аның мондый холкын моңарчы күрмәгән иптәшләре аптырап калдылар.

Яланга килгәч тә Айсетдиннең тегермәне гел кирегә әйләнә башлады. Санияне күргәч үк аның күңеленә җылылык инде. Техникумда чагында йөргән кызлары булгалады аның, әмма егет чын мәхәббәтне берчакта да татымады, андый бәхеткә ирешмәде. Таныште, аерылышты, кабынды да сүрелде. Кызлары түгел, ул үзе аларны ташлады. Җанынны биреп яратмаган хатын — муендагы тәре кебек гел комачаулый, дип кабатлады ул кемнәндер ишеткән сүзне.

Айсетдиннең һәр нәрсәсе урынында, төскә-биткә дә төшеп калганнардан түгел, шулар өстенә дипломлы педагог!

Санияне беренче очраткач та: «Менә минем язмышым кайда яшәп ята икән! Ялан авылына сөрелүнең бүләге шушы икән», — дип уйлады егет һәм шул секундтан Санияне үзенеке дип исәпләп йөри башлады. Аныңча, бу авылда аның белән ярышырлык ир-егет тә, аның юлына каршы төшәрлек кеше дә юк иде кебек. Караңгы авылда әнисе белән яшәп яткан ятимә кызга тагын кем кирәк?

Һич көтмәгәндә кыз аның кулын кире какты, сүзләрен санга сукмады, юньләп күз дә төшермәде. Гел «яхшы» билгеләре генә тезелгән дипломны кулына да тотып карамады... Шулар өстенә, курслардан Мөхәммәт Уразаев кайтып төште. Чигә чәчләренә беренче чал йөгергән, иңе калынайган, адымы салмакланган ир — янында үсмер малае да булган бәхетсез кеше — чибәр, коңгырт күзләренә ямь тулган яшь кызны үзенә караткы да куйды. «Инде бетә! Инде язмышы кыл өстендә!» — дип өметләнеп көтеп торганда, аны үзенә ир итте.

Аның Уразаевтан өстен чыгасы килде, нәфесе котырды, бавыры тулып ташыды, бер сүз, ярты ишарә белән Уразаевны егып саласы, аста калдырасы килде. Бер үк вакытта аны җиңүнең ансат булмасын аңлады. Гомер-гомергә монда яшәп, Уразаевның алдын-артын бик яхшы белгән Чырык Абдрахманнар да әллә ни кыра алмаганны, Уразаевны егып салу Айсетдингә дә җиңел булмаячак. Әмма җиңәргә кирәк, җиңәргә!..

Иң беренче чиратта мәктәптә мөдирлекне үз кулыңа алырга. Кызлар ир-атның тоткан урынына, дәрәҗәсенә игътибар итми кала алалармы?

Сания ир хатыны булгач, Айсетдин: «Беткәнмени бу дөньяда кызлар? Аннан да чибәррәген туры китерермен!» — дип юаныргa тырышып караса да, булмады, кыз онытылмады. Күңелендә кабынган чаткы бу юлы пыскып сүнәргә ашыкмады.

Урамда, мәктәптә, кичәләрдә очрашканда, ул, һич тайчанмыйча, Саниягә карап уза яки карап тора башлады. Аның эрсезләнеп үзенә текәлгәнен күреп, моны Мөхәммәт тә күрәдер дип уйлап, Сания бик нык борчыла иде. Һәм ул бер очрашканда Айсетдингә әйтә куйды:

— Сез миңа алай карамагыз, зинһар, Айсетдин иптәш.

— Нигә?

— Мин ир хатыны. Бездә, Себер татарларында хатын иргә тугры була.

Айсетдин яшь хатынның сүзен ишетми, аның комачтай кызарынып киткән чибәр йөзенә карый. Сания аңа карата бөтенләй ваемсыз булса, күзгә-күз очрашканда, нигә шулай кабынып китә соң? Бу тикмәгә түгел, дип уйлый аның әрсез күңеле. Хәзер очрашкан саен азына бара Айсетдин, таррак урында туры килсәләр, аңа иңнәре белән кагылып уза, күзен майландырып төче елмая, аның чибәрлеген мактап йомшак сүзләр яудыра. «Мактау сүзләренә кайсы хатынның каршы тора алганы бар? Йомшак тел — хатыннарның җәймәсен ача»,— дип белә Айсетдин. Моңарчы шулай иде, моңарчы тәмле теле аңа бик күп ишекләрне ачты, бик күп җылы кочак бүләк итте. Дөрес, ул Санияне бер минутлык яры итәргә теләми, аны гомерлек яры, хатыны итәсе килә Айсетдиннең. Буш сүзгә дә баш биргән хатын кирәкми аңа, андый зания[1] Айсетдиннең үзенә дә тансык түгел, занияләр бер кичкә генә кадерле...

Сания нык булган саен, егетнең өмете дә, әрсезлеге дә арта төште. «Яшь мөгаллим Уразаевның хатыны белән чирттерә икән!»— дигән хәбәрне авылда беренче булып Чырык Абдрахман әйтте. Бу хәбәр Сәмук аркылы Бүре Рәхмәтуллага да барып ишетелде...

## 21

Ташкәй теге чакта, ерак кардәшләренә кунакка кайткач, «Хат язармын!»— дип, Йосыфка вәгъдә бирсә дә язмады. Ырсытдин язмаска кушты аңа, «Язма, оныт шул Яланны!»— диде. Малайны кунакка әнкәсе Йомабикә җибәргән иде. Кунактан кайткач, ул рәттән берничә көн улыннан Ялан хәлләрен сорашты, төпченде, белеште. Ташкәй аз сүзле иде шул, клубта булганнарны өч-дүрт сүз белән йомгаклады да куйды. Ә Йомабикәнең бик күпне, барысын да беләсе килә иде ерак ят калада...

Йосыфлар быел Мөхәммәт абыйдан соңгы елларын укыйлар. Өч кыш буена алар бер юлдан, бер сукмактан бардылар. Яңа елларны каршыладылар, Октябрь бәйрәмендә, саф-саф тезелеп, урамнан икеөч тапкыр «урра!» кычкырып үттеләр. Күңелле бәйрәмнәр иде алары, әмма Йосыфның иң яраткан бәйрәме — 8 Март! Быел да алар бәйрәмгә озак әзерләнделәр. Рәсем дәресләрендә, төсле кәгазьләр кисеп, әниләренә, әбиләренә котлау сүзләре яздылар. Пионерлар, кызыл галстуклар тагып, бәйрәм почтасын — кыңгыраулар тагылган, чәчәкләр, ал тасмалар белән бизәлгән чанага утырып йорттан-йортка таратып йөрделәр.

Йосыф күңелендәге иң җылы, иң кадерле сүзләрне Гыйззәтбану апага — үз әнисенә язды. Иң яңгыравыклы тавышлы Маннур котлау сүзләрен шытырдатып укып биргәч, пионерлар бердәм кул чапкач, Гыйззәтбану түти тыела алмыйча елап утырды. Маннурдан соң Сәлимә сүз алды, ул Мөхәммәт абыйның Йосыфның әнкәсенә язган рәхмәт хатын укып чыкты. «Кадерле Гыйззәтбану түти! Сезне бәйрәм белән чын күңелдән котлыйм! Улыгыз Йосыфның укуда, үз-үзен тотышта көннәнкөн уңышларга ирешүен әйтеп, Сезне шатландырасы килә. Аның күңеле ана нуры белән яктыртылган, ана җылысы белән җылытылган. Рәхмәт Сезгә, кадерле Ана!»

Кичен клубта әниләргә багышланган җырлар җырланды, бүләкләр тапшырылды. Бүләкләрне колхоз идарәсе исеменнән Эссәт Фәтхуллин тапшырып торды. Саниягә дә бүләк эләкте — Шамилдән, кедр һәм нарат күркәләреннән эшләнгән матур песнәк. Сөенде Сания, куанычы йөзенә чыкты.

Әле кайчан гына Сигезенче Март бәйрәме турында Ялан хатынкызлары бөтенләй белми иделәр, ә бүген, җылымса яз җилләре искән кичтә, Иртеш уянып маташканда алар, күңелле гәпләшә-гәпләшә, өйләренә таралалар. Күңелле кичәләрне бик нык яратса да, Санияләргә кайтырга вакыт: өйдә аларны тормыш җимешләре Фаягөл көтә.

---

[1] Зания — уйнашчы хатын (гарәпчә).

Сания, бүләгең куеп торып, пальтосына үрелде, йөзеннән елмаю сүрелмәде, киенә башлады. Сәдәфләрен төймәләгәндә, кесәсендә ят бер әйбер барлыгын тойды.

— Әллә син миңа сюрприз әзерләгәнсең инде?— диде ул Мөхәммәткә карап.

— Нигә?

— Кесәмдә нидер бар!

— Яле, яле...

Кесәдән нәни генә серле төен килеп чыкты. Юлда кайтканда ук сүтә башладылар, кат-кат кәгазьләргә, чүпрәкләргә уралган шырпы тартмасы килеп чыкты. Тартманы өйгә кергәч кенә ачтылар. Тартманың ике башыннан ике кара җеп үткәрелгән, ике энәнең очы эчкә каратып куелган. Җепкә кырык төен төйнәлгән.

Әле генә бәйрәм тантанасы белән балкыган яшь ананың йөзе кинәт сүрелеп китте, болыт каплады. Тәнен калтырау алды. Мөхәммәт тә аңлады, Саниянең кесәсендәге «бүләк» бозым галәмәте иде. Гадәттә, егет белән кызның яки ир белән хатынның арасын бозу өчен Иртеш ягында шулай итәләр. Кара җептә кырык төен — янәсе аларның татулыгы кырык көндә өзелә, имеш!..

Кем кыландырыр моны, кайсы явызы?

Аларны сискәндереп, нәни Фаягөл чырылдап елап уянды...

Нинди кара көч кара җепле энә белән аларның йөрәгенә кадарга җыена?

Ул арада, нәни кызчыкны күтәреп, Мөхлисә килеп чыкты.

— Ашат, кызым. Нәниемнең мәм-мәм итәсе бик килә...

Моңарчы мондый сүзләр, сабыеның ачыгып торуы аны чиксез сөендерә иде, бу юлы ул баланы шомланып кына кулына алды. Мөхәммәт тә пошаманга төшкән иде.

Иртәгәсен Уразаев белән Фәтхуллин, ат җигеп, шәһәргә, партактив җыелышына барырга тиешләр иде. «Язгы сулар кузгалып, юллар өзелгәнче бер җыеп алыргадыр ниятләре!»— диде Фәтхуллин Мөхәммәткә. Мәктәптә дүрт классны да Айсетдин алып калды.

Иртәнчәк идарә йорты яныннан кузгалырга дип торганда гына ахылдап чана янына Сания килеп җитте. Аны күргәч, Мөхәммәтнең йөрәге жу итеп китте. «Тагын күңелсезлек бармы әллә?»

— Өннә апа яныннан килешем,— диде Сания.— Бәбәй таба алмыйча интегә. Шәһәргә алып бармыйча ярамас. Үзем озата китәм.

— Фаягөлне нишләтәбез?— диде Мөхәммәт борчылып.

— Сымракка[1] өйрәнә торсын, әбисе карар,— диде Сания.

Ике айлык бәбине әбисе янында калдырып, озын юлга чыгарга ниятләгән хатынына Мөхәммәт төксерәк карадымы, Сания аңа иелә төшеп:

— Башка чара юк, җаным. Сезгә ышанып утыртып та җибәрер идем, юлда бәбили башласа, нишләрсез?— дип аңлатып бирде.

— Да, дела,— дип куйды Эссәт әкә.

Өннә апаны, битен куе тут баскан, йокысызлыктан күз тирәләре күгелҗем төскә кергән хатынны корама юрганга төреп чанага сузып салдылар. Эт тиресеннән тегелгән олы толып якасы астыннан очлаеп калган борыны гына күренде. Эссәт әкә бераз читкәрәк, Мөхәммәт белән Сания исә Өннә түтинең аяк очына кысылышып утырдылар. Эссәт әкә чөңгереп куюга, Карун Рәхмәтулланың җирәнә җәһәт кенә кузгалып та китте. Юл шома, көн әйбәт, җилсез, юрттылар да юрттылар, калага житкәндә аттан күбекләр тама иде.

Киңәшмә беткәндә, Сания аларны коридорда көтеп тора иде инде.

— Йә, ничек?— дип сорадылар Мөхәммәт белән Эссәт әкә.

— Улы бар!— дип авызын ерды Сания.

---

[1] Сымрак — имезлек.

Инде чыгабыз да кузгалабыз дип торганда Мөхәммәтне РОНО мөдире туктатты.

— Сез беразга калып торыгыз әле. Сөйләшәсе мәһим сүзләр бар,— диде ул. Ир белән хатын бер-берсенә караштылар.

— Безгә ашыгырга кирәк иде бит,— диде Уразаев уңайсызланып кына һәм ашыгуның сәбәбен аңлатып бирде.

— Алайса сез иртәгә генә китәрсез,— диде мөдир.— Безнең сүз сузылыр әле. Тәҗрибәгез белән танышасы да бар.

Эссәт әкә дә ашыга иде, ул җир бүлегенә кереп белеште, ун олау сыйфатлы симәнә бирмәкчеләр, аны иртәгәдән ташып куярга кирәк икән.

— Нишлибез?— диде Мөхәммәт икесенә дә карап.

— Калып тор,— диде Эссәт әкә.

— Әйе, калып тор, җаным,— диде Сания.

Мөхәммәт хатынының мамык шәлен маңгаена табарак төшереп, толыбының якасын күтәреп, сыер тиресеннән эшләнгән тукмактай зур төймәләрен эре-эре элмәкләргә каптырды да алсуланган бит алмасыннан үбеп саубуллашты.

— Хәерле юл сезгә!— диде ул.

— Иртәгә мин ат белән берәр малайны җибәрермен,— диде Эссәт әкә. Саубуллаштылар.

Җирән көнозынына ял итеп өлгергән, тамагы тук, талагы гөр-гөр килеп тора, юрта гына! Сания сөт тулып ташыган имиләренең сызлавына түзә алмыйча боргаланып кайта, толып якасын кайтарып, көнгә карый. Тиздән караңгы да төшәчәк, юл ерак, урык-сурык кына йөргән болытлар бергә укмашып, җир өстенә ярма кар коя башладылар. Буран күтәрелмәсә ярар иде. Эссәт әкә дә борчылып кайта, кар явып, юлны басып китсә, иртәгә бу юлдан ничек узасы булыр?!

Күбек кедрачының куе урынына житкәндә Эссәт әкә урманнан бер шәүләнең юлга чыгуын күреп сагаеп калды. Алай да булмады, арттан: «Тукта, чучка! Стой!»— дигән боерык яңгырады. Ул тавышны Эссәт әкә бик ачык таныды... Димәк, ансат кына, атны чаптырып кына котылып булмаячак... Хәзер бер пуля — һәм ат авып та төшәчәк... Туктарга кушалар икән, туктамый хәлең юк. Ул кысып тоткан дилбегәсен чанага ташлады һәм сузылып ятып өлгергән Саниягә эндәште:

— Сания, банда! Мин тоткарлыйм, син башыңны күтәрмә!— дип, чанадан сикереп төште. Ат кушаяклап чаба башлаган иде, юлдагы кешене тәртә башы белән юл читенә аударды. Шунда ук аткан тавышлар яңгырады. Эссәт әкә карга капланып, куеныннан наганын чыгарды һәм гөрселдәтеп атып җибәрде. Кара-каршы атыш китте.

Ат чапты да чапты, Сания куркуыннан һушын җуйган иде. Җирән аргамак мәктәп янына килеп туктады. Аны иң беренче булып Шамил абайлады.

Айсетдин фатирына китмәгән иде әле, Шамил аның янына атылып керде.

— Анда... чанада... Сания апа... һушсыз!— дип кычкырды ул.

Айсетдин атны бар куәтенә Мөхлисә әби йортына алып китте, жыелып өлгергән кешеләр яшь хатынны күтәреп өйгә кerttеләр. Сания авырлык белән генә күзен ачты, кызын эзләде. Нидер әйтергә дип талпынды. Бер-ике йотым су эчкәч кенә хәл җыеп әйтте:

— Күбек чикләвегендә банда! Анда Эссәт әкә! Ашыгыгыз!

Яшьләр чыгып чапты. Кем нәрсә туры килсә шуның белән кораланды. Бардылар, ләкин караңгы буранлы төндә бернәрсә дә таба алмыйча нәүмизләнеп кайттылар. Икенче көнне генә Эссәт әкәнең танымаслык булып гарипләнгән гәүдәсен кибәндәй җәелеп үскән карт кедр агачы төбеннән табып алдылар. Эссәт әкәнең күз урыннарына ап-ак кар кереп тулган иде...

Авылны кара кайгы басты. Хәбәрне ишетүгә, Яланга кайтып жит-

кән Мөхәммәт Уразаев картлар төсле бөкрәеп калды. Чигәсенең аклыгы артты. Шул кайгылы көннәрдә Саниянең сөте качты. Эссәт әкәнең хатыны Шәмсеруй апа түшәккә егылды. Ул көннәрдә мәрхүмнең кызы Сәрвәрнең күз яше кипкән чак аз булгандыр.

Нигә кеше бу дөньядан киткәч кенә аның кылган яхшылыкларын кайта-кайта уйланасың икән? Күршеләре Раукыя апа мәрхүмнең изге гамәлләрен күз алдыннан кат-кат үткәрде. Комбедта эшләгән елларында Эссәт Фәтхуллин Раукыя апаны сыерлы итте.

Истә-оста югында ике мөгезе дә аска таба бөгелеп килгән кола сыерны җитәкләп килен кергән бу! Авызы ерык, тирләгән.

— Менә,— ди,— Раукыя, кыш чыгарсың, авызың сөт-каймакка тук булыр. Балаларың хакына!

Раукыя каушады, ирennәре мелт-мелт килә, авызыннан сүз чыкмый. Аның кыенсынганын күреп, Эссәт әкәнең кәефе тагын да күтәрелде.

— Ал, ал,— диде ул мөгезгә бәйләгән бауны Раукыяга тоттырып,— сәвит власты бирә, тартынма! Үзебез яулап алган власть!

* * *

Тикшерү башланганда, төнге буран җинаятьчеләрнең эзләрен күмеп киткән иде. Ерткычларча мәсхәрәләнгән Эссәт Фәтхуллинның тәсен тану кыен иде. Кургаш ук баш түбәсен каерып алып киткән... Икенче ук, аркасыннан үтеп кереп сөяккә кадалган иде. Арттан атканнар да икенче тапкыр терәп диярлек маңгайга төбәгәннәр диде тикшерүчеләр. Мөгаен җинаятьчеләр Эссәт әкә белгән адәмнәр булгандыр? Фаҗига урынын җентекләп тикшергәч, укучы дәфтәреннән ертып алынган һәм янып бетмәгән пыж табылды. Шул кәгазь кисәге аннары тикшерүчене мәктәп бусагасына алып килде. Алар Мөхәммәт Уразаев белән бергәләп кәгазьне кат-кат тикшерделәр, җыелган барлык дәфтәрләр, ертылган битләр белән кушып карадылар.

«Беребез сары чәчле, беребез»...— дип башланып киткән кәгазь кисәге Йосыфның дәфтәр битеннән ертылып алынган булып чыкты. Куркудан ак киндергә әйләнгән Йосыфтан тикшерүче Уразаев алдында сорау алды. «Минем дәфтәр»,— диде үсмер малай. «Дәфтәремне ят кеше кулына биреп торганым юк»,— дип раслады.

Букчада һәркөн малайга ияреп мәктәпкә килеп-китеп йөргән дәфтәрдән бу кисәкне кем умырып-ертып алган? Патронга кем төя-төя тутырган?.. Моңа җавап юк иде, шул сәбәпле авыл арасында чыш-пыш хәбәрләр таралды. Сәгъдетдин абзый белән Гыйззәтбану түти кеше арасына чыгалмас булдылар. Алардан күрмәкче, Йосыф та ике-өч көн мәктәпкә бармыйча калган иде, кичкырын тузынып Мөхәммәт Уразаев килеп җитте. «Дошманнар этлегенә баш биреп, җыйнаулашып өйдә ятасызмы?— диде ул, хәл-әхвәл сорашып та тормастан.— Җинаятьчеләр шуны гына көтә дә! Безнең барыбызның да дошманлашып бетүебез зарур аларга!»

Улының дәфтәр бите китергән бәла онытылып та бетмәде, Сәгъдетдин өстенә икенче кайгы төште... Икенче кайгыга ияреп, беренче бәла өр-яңадан калкып чыкты. Тикшерү оешмаларына кемдер: «Эссәт Фәтхуллинны үтерүче Сәгъдетдин генә! Моны бөтен авыл раслый ала. Фәтхуллинны үтергән минутларда Сәгъдетдин шул урманда булган!»— дип раслап язып җибәргән...

Әйе, Сәгъдетдин фаҗига урыныннан ерак та булмаган, аткан тавышны да ишеткән... Элек аяк кагып, аның һәр сүзенә ышанып утырган тикшерүче бу юлы үтә кырысланган, каты-каты сораулар белән аннан дөреслекне таләп итә иде.

— Атыш тавышын ишеткәч тә нигә авылга чапмадың? Нигә ишеткәннәреңне берәүгә дә кайтып әйтмәдең? Гаебең булмаса, син боларны яшереп торыр идеңмени?

Ни әйтсен Сәгъдетдин,— юаш җан, кул аркасына кунган черкине дә җәлләп өреп төшергән басынкы кеше — үзен ничек акласын?..

— Эссәтнеме?.. Ни сөйлисез сез? Чәчәремә орлык бирде. Йорт тоткасы итеп ат бирде... Авылның бер байгышын кешегә санап, авыл советына тәкъдим итте. Шундый җан дустыма корал күтәрәмме мин? Гомеремдә бер тапкыр мылтык тотып караганың бармы, дип сорагыз. Кем бутый моны?..

Егылган өстенә йодрык — шул көннәрдә икмәк тапшыру җинаяте ачылып, йөзе кара Бәдри, үзе эләккәч, башкаларны батырырга керешә.

— Сәгъдетдин котыртты! Күбәүләрне җинаятькә шул димләде!— дип күрсәтте. Бөтен бәлане аның өстенә аударып, үзе корыда калырга маташты.

Эссәт Фәтхуллин эше буенча Сәгъдетдинне гаепләрлек дәлилләр юк иде югын, әмма икмәк тапшыруда аны гаепләп чыгучылар авылда берничә булып чыкты. Бәдри, Сәмук: «Безне авыл советы члены Сәгъдетдин Сакин котыртты, чөгә, тогы балыгы ташып икмәк тапшыру квитанцияләре алдык»,— дип күрсәттеләр.

Сәгъдетдинне кулга алдылар.

Гыйззәтбану белән Йосыф, житәкләшеп, аны авыл очына кадәр озата бардылар.

Судта дәүләт гаепләүчесе:

— Совет власте вәкиле буларак, гражданин Сакин җинаятьне алдан кисәтергә тиеш иде. Ә ул дошманнарга ярдәм иткән. Ул совет власте нигезенә балта чабучы корткыч!— дип чыгыш ясады, актыктан аңа иң югары җәза таләп итте.

Судта Мөхәммәт Уразаев та чыгыш ясады.

— Төп тамыры ярлы нәселеннән булган, намус белән гомер кичергән кешенең андый җинаятькә катнашуына авыл халкы ышанмый. Мин дә ышанмыйм, ышана да алмыйм!..

Мөхәммәт судка Һади бабай белән килгән иде, ул Һади карт янына, алдагы рәткә утырып тирләгән маңгаен сөртергә дә өлгермәде, артта тыгызланып торган кешеләр арасыннан бер тавыш яңгырады:

— Ә синең үзеңә кем ышана соң?

Залдагылар барысы да тавышка борылып карадылар, кулындагы кепкасын бөтерә-бөтерә Чырык Абдрахман калкынып маташа икән.

— Үзең кем соң син? Авыл халкы исеменнән сүз әйтергә хакың бармы? Синең үзеңнең дә койрык бозда... Эссәт Фәтхуллин үтерелгәндә, Сәгъдетдин кайда иде? Ту-ты, дәшмисең? Син ул чакта да аны яклап калдың, җәмәгать исеменнән сөйләдең... Тотасың да «Сәмук!»— дисең. Икенең берендә миңа бәйләнәсең! Бөтен авыл белә: Эссәтне юк иткәндә, без халык күз алдында идек! Нигә гел җинаятьчеләрне яклау юлына бастың син, Мөхәммәт Уразаев?!

Мөхәммәтнең дәлилләре җитәрлек булмады, Сәгъдетдин Сакинны төрмәгә ябып куйдылар.

## 22

Уйламаганда, көтмәгәндә, бер ел эчендә Мөхәммәт Уразаев ялгыз калды. Күңеленә гел җылы бөркеп торган Эссәт Фәтхуллин гүргә вакытсыз инде, ә Сәгъдетдин Сакинны хаксызга рәшәткә артына яшереп куйдылар. Мондый чакта ир кеше ялгызлыкны бик авыр кичерә, кая барып бәрелергә белми, мондый чакта кавырсыны йомшак ирләр йә бер-бер җүләрлек эшләп ташлый, йә эчәргә сабыша. Булды, Мөхәммәтнең тузынып китеп Чырык Абдрахман белән Сәмукның якасыннан алып селкеп саласы килгән чаклары булды. Саниягә карап, үсеп тернәкләнеп килгән кызына карап тыелып калды. Булды Мөхәммәтнең дә аракы диңгезенә чумып «әйдә, беткән баш беткән!» дип әйтергә омтылган чаклары булды, мәктәптә Йосыфлар, Маннурлар, Шамилләр белән

очрашканда томалана башлаган зиһене кинәт ачылып китте: «Менә кемнәр өчен яшәргә кирәк, менә шушы балалар өчен үзеңне саклау тиеш!»— диде теле...

Күбек кедрачындагы фаҗигадән соң «Таң» колхозы байтак вакыт председательсез яшәде. Әллә Эссәт Фәтхуллинның хәтерен саклап бирәү дә бу эшкә алынмыйчарак торды. Ниһаять, Чырык Абдрахман, аның яраннары ярты төнгә кадәр даулашып утыргач үз араларыннан йомыкый гына бер бәндәне колхоз башлыгы итеп сайлап куйдылар. Мөхәммәтнең, башкаларның искәртеп әйткән сүзләре шау-шу арасында күмелеп калды. Шуннан... китте, китте генә! Фәтхуллин рәткә салган эшләр кинәт сүтелә башлады. Язгы чәчүгә әзерлек өзелде. Иреннәрен салындырган арык атлар, «без сабанны ничек тартырбыз?» дип кайгыргандай, тырпайган кабыргаларын сүлпән кояш нурларында җылытып басып торалар, катырак җил иссә, чүт кенә аумый аякланып калалар. Азык җитми! Булганы әрәм-шәрәм ителә, бар чагында бүредәй, юк чагында шүредәй! Ни хикмәттер, Эссәт барында чиләк-чиләк сөт биргән мулҗиленле кола сыерлар (себер ягы токымы!) иртән савымчылар килүгә эчләре күбеп анда-монда тәгәрәшеп яталар, күзләре акайган. Аларны ашык-пошык суеп иткә тапшыралар... Чәчүлек орлык салынган амбарның түбәсе каерылып, буралар өстенә әрсез буран кар кертеп тутырган да, җылы көннәрне гел җепшеп бодай түмгәк-түмгәк күгәреп укмашкан... Җансыз орлыкны җиргә салудан ни файда? Кайбер колхозчылар арасында аерым хуҗалыкка кире кайту турында сүз йөри башлады. «Таң» колхозы әгъзалары тагын мәктәпкә җыйналдылар.

Төнтек Мәхмүтҗанны рәислектән алырга, дигәндә халык бердәм диярлек иде. Мәхмүтҗанның кылган гамәлләре аның булдыксызлыгында шик калдырмады. Мәгәр «Председатель итеп кемне куябыз?»— дигән сорау алга килеп баскач, залдагылар икегә бүленделәр, авызларына шайтан төкергән хатын-кызлар ягы бертавыштан: «Чырык Абдрахман рәис булсын!»— дип кычкыра. Ирләр шаккатып аларга каршы төшәләр: «Чырык председатель булса, ай кителеп Кызлар убасына төшәр!»— диләр. Хатын-кызлар әллә юри, әллә берәрсе котыртып куйган, чәрелдәпме-чәрелдиләр. Залда шайтан туе байтак дәвам иткәннән соң җыелышны алып баручы Туктасынның тамагы карлыккач, сүзне Мөхәммәт Уразаев алды.

— Күптән түгел генә большевиклар партиясе члены итеп алынган Хафиз әкәне председательлеккә тәкъдим итәм,— диде ул нык тавышы белән залның чыр-чуын басып.

Авыл арасында Мөхәммәтнең абруе зур иде, мөгаллимнең сүзен аяк астына салып ташламадылар, залдагылар Хафиз әкәне сайлау ягына авыша башладылар. Ул арада мәктәп-клуб ишеге ачылды, аннары күз-башлары тонган биш-алты үсмер бала килеп керде.

— Ут!— дип кычкырдылар алар.— Янып утыра!

— Нинди ут?— дип сорады түрдән Туктасын.

— Зират өстендә ут яна!— диде алгарак чыгып Йосыф.

— Күрдек!— дип куәтләде аны Шамил.

— Ут әтием кабере өстендә!— диде Сәрвәр.

Зал тынып калды, балаларны уртагарак чакырып алдылар.

— Иплән кенә сөйләп бирегез,— диде Уразаев.

Балалар Эссәт әкәнең каберен язын ничек-ничек карау турында сүз кузгатканнар да, чәчәкләр белән бизәргә килешенеп хәзердән үк әзерлекне башларга дип, авыл очындагы зиратка таба киткәннәр. Зират коймасы буена барып җитеп карасалар, ни күрсеннәр, Эссәт әкә кабере өстендә дулый-дулый ут янып утыра!

Залдагылар аһ иттеләр. Карчык-корчык укынып аягүрә басты, ирләр кашларын кушып уйга калдылар. Арттан кемдер: «Коммунистлар шулай тәмугъта яналар!»— дип кычкырып салды. Нәкъ шул вакытта гына лампаның уты кимеде, филтә күмерләнеп пелт-пелт итеп торды да

сүнде. «Нигә сүнде бу лампа?» — дип уйлады Мөхәммәт хафаланып, кичкырын гына керосинны тутырып салган иде ләбаса... Куыгын Сания чистартып әзерләде, лампаның тулылыгына ул да игътибар иткән иде. Карангылыкта калган халык тагын да ныграк шомланып акырыша-талаша башлады.

— Хафиз әкә дә бәлшәвик! Ул да тәмугта яначак! — дип гөрләде хатын-кыз ягы. Ирләр дә аларга кушылып, сөзгәк сыерлар сыман мөгрәштеләр. Ишек янындагыларны кыса башладылар, талаш көчәйде, бүселеп урамга чыктылар. Кемдер: «Әйдәгез зиратка!» — дип чакырды. Кузгалдылар. Киттеләр. Барсалар зират өстендә тып-тын, ут-мазар юк, алай да Эссәт кабере тирәсендә тирән-тирән эзләр ярылып ята, кәрәзләнә башлаган шәмәхә кар өстендә кара сөрем шәйләнә...

Ул көнне җыелышны дәвам иттерү мөмкин түгел иде, икенче көнне кешеләрне өй борынча чакырып йөреп, көч-хәл белән клубка җыеп бик авырлык белән генә Хафиз әкәне «Таң» колхозына председатель иттеләр.

Теше төшеп беткән Мәгыйшә карчык:

— Яхшылыкка булмас бу... Хафизны сайлаганда зираттан ходай ымы күренгән, йә үтерерләр, йә үзе әҗәлен табар! — дип юраган.

Зиратта күренгән ут балалар арасында да төрле сүзләр тудырды. Икенче көнне беренче дәрескә кергән Айсетдинне сораулар белән күмеп ташладылар.

— Тәмуг бармы, абый? Бу дөнья чынмы?

— Әбиләр биргән бөти җен-пәридән саклыймы?

— Кешеләр каян яралганнар?

Дистәләрчә яуган бу шөбһәле сораулар үзенең дә дөнья төзелеше турындагы карашы ныгып җитмәгән Айсетдиннең җанын кыйдылар. Ул башта ык-мык килеп маташты да, «Үсә төшкәч үзегез аңларсыз!» — дип, җавап бирүдән котылмакчы булды. Әмма зират өстендәге утны үз күзләре белән күргән Йосыф, Маннурларны алай гына туктатырлык түгел иде. Айсетдин дәрес башлап карый, балалар тагын шул серле түгәрәккә кайталар: «Ничек тә ничек?» «Нигә дә нигә!» Класс өченче көнге җыелышка охшап калды. Балаларның кызыксынуы артканнан арты, Айсетдиннең котыруы көчәйгәннән көчәйде. Дәрес җан көйдергеч нәрсәгә әйләнде. Типсә тимер өзәрлек таза егет шушы бот буе нәрсәләрне җиңә алмасын инде!

Теле белән җавап биреп классны тыя алмагач, Айсетдин кызып китеп кулына ирек бирә башлады: Сәрвәрнең чәчен тартты, сорауларны аерата күп яудырган Йосыфның ипи шүрлегенә менеп төште.

— Җитте сезгә юк-бар җен-пәриләр белән саташырга! — дип акырды ул.

Бер мәлгә тынычлана төшкән класс бераздан тагын җанлана төште, уртада кемдер өзеп-өзеп сызгыра иде. Айсетдин сүздән туктауга сызгыру да бүленде. Ул авызын ачып сүз әйтүгә тагын сызгыра башлыйлар. Берәү генә түгел, икәү сызгыра, өчәү! Айсетдин дәресне бүлеп Уразаев янына чабып керде.

— Зиратта бернинди дә ут-мазар булмаган! Акылларына җиңеллек килгән Йосыф белән Маннур уйлап чыгарган аны. Шул юньсезләр авылны тузгыткан. Ялган хәбәр таратканнары өчен аларны мәктәптән куарга кирәк! — диде ул, үз сүзләренә үзе буылабуыла.

— Шулай укмы? — Уразаев төбәп карады.

— Сез кемгә ышанасыз? Шул шпаналаргамы, әллә миңамы?

— Айсетдин, син педтехникумга үзең теләп кердеңме?

Мондый киеренке минутта Айсетдин хезмәттәшеннән мондый сорауны һич тә көтмәгән иде.

— Бу нинди кирәксез сорау алу? — диде ул кызарынып.

— Беләсем килә, — диде Уразаев сабыр гына.

— Белми торыгыз әле.

— Механик яки инженер булу турында уйлап караганың юкмы, Айсетдин? Свердловскида институт бар, Омскида. Педагог буларак сиңа иң кирәкле бер сыйфат җитми.

— Нинди сыйфат?

— Түземлелек, сабырлык.

— Түзем булам дип Йосыф кебек башкисәрне муеныма менгереп атландырыйммы? Сез башка эшне булдыра алмыйсыз, дипломыгыз юк, шуңа күрә балалар ни кыланса, шуңа түзәргә мәҗбүр!..

Мөхәммәт сабырлыкка өндәгәндә дә сабыр булырга кирәген чамалап, сүзне ярты юлда өзде, югыйсә сүз ташкыны әллә кайларга кереп китәчәк иде. Айсетдиннең йогышсыз кыланышы нәтиҗәсе буларак, иртәгесен Йосыф, Маннур, Сәрвәр, Сәлимәләрнең парталары буш иде...

Уразаев янына зар белән Гыйззәтбану апа килде.

— Әткәсе төрмәдә. Бабасы авырып ята, хаста. Баланың күңеле болай да сынык, җитмәсә мөгаллим аны тукмап кайтарган...

Нидер эшләргә, балаларның күңеле кайта башлаган мәктәпкә яңадан тартырга кирәк иде. Мөхәммәт чарасыз калып утырганда аңа ярдәмгә тугры Саниясе килде.

Иртәгесен Сания киңәше белән мәктәп линейкага тезелде. Мөхәммәт абыйлары саф алдына чыгып баскач, барлык күзләр аңа төбәлде. Нидер сизенгән Айсетдин учын-учка ышкып бер читкәрәк барып басты.

— Кадерле балалар!— диде Уразаев.— Дүрт аяклы ат та сөртенә, диләр. Хак сүз. Йосыф, Сәрвәр! Айсетдин абыегыз сезнең алда гафу үтенүне миңа тапшырды... Ул хаталык кылганына бик нык үкенә. Алда мондый хәл яңадан кабатланмас!

Балалар елмаешып бер-берсенә караштылар. Айсетдин йодрыкларын йомарлап шашып калган иде.

* * *

Зираттагы ут вакыйгасыннан соң атна-ун көн чамасы үткәч, Шамил белән Йосыф кичкырын Мөхәммәт янына чабып килеп җиттеләр. Танаулары ярылырдай ташкан, сулышлары капкан — авызларыннан кайнар пар бөркелә. Икесе беравыздан:

— Зиратта... Эссәт әкә каберендә сөяк кеше басып тора, башы да, аяк-куллары да бар!— диделәр.

Ышаныргамы, ышанмаскамы?! Айсетдин балаларны пыр туздырып куа башлады. Ул да Мөхәммәт янында иде.

— Юк белән баш катырып йөрмәгез! — диде ул әрләп.

Мөхәммәт ашыгыч отчет белән утыра, иртәгесен РОНОга барырга кирәк иде. Айсетдин сүзләре аны бер мизгелгә икеләндерде.

— Әллә карап кайтасыңмы, эшем бик тыгыз иде!— диде ул Айсетдингә.

— Йөрим ди әбиләр әкиятенә ышанып!

Юньле карарга килгәнче караңгы төште, шик-шөбһәләргә уралып өйләренә таралыштылар. Иртәгесен кичәге урында бер нәрсә дә юк, Эссәт әкәнең кабере тирәсен тирән-тирән эзләр генә чуарлаган иде.

Хәбәр тиз таралды, авыл тирән куркуга төште. Күрше авылларга хәбәр китеп, алардан Яланга «тикшерүчеләр» килгәли башлады.

Кичкә таба авыл урамнары бушап калды, кунакка йөрешүләр тукталды, әнгер-меңгердә әби-чәбиләр бисмиллаларын кат-кат укып, ишек-капкаларның келәләрен төшерәләр, ир-ат корулы мылтыгын янына алып йокыга ята... Бала-чаганың муенына кызыл галстуклар белән бергә, бөтиләр элене...

Авылга сихри курку салган явызны тотмый торып, үгет-нәсихәт ярдәмендә яки әңгәмә-фәлән белән ышандыру мөмкин түгел иде.

Уразаев ышанычлы кешеләр белән киңәшкәннән соң, укучыларны һәм пионерларны әзерләп, «Тәмуг» операциясе уздырырга булды. Серле һәм кискен эш итеп кенә дошманның битлеген салдырып, максатын ачыклап булачак...

Яшерен эшкә иң әүвәл Хафиз әкә тартылды, ул өч көн алдан «Җомга кичендә җыелыш булачак»,— дип белдерү элдерде. Үзе куш көбәкле мылтыгын тоз белән корып баш очына куйды. Тагын бер тапкыр халыкны шаккатырырга теләсә, дошман яланлылар бергә җыелган кичтән файдаланырга тиеш иде.

Актырнагын кочаклап койма артына посып яткан Йосыф, Эссәт әкә кабере өстендә чытырдап янгын күтәрелүгә, сискәнеп калкынды һәм чак кына эшне бозып ташламады, телен тешләп авазын бүлде... Икенче якта Хафиз әкә сакта иде, ул калкынып атып та җибәрде. Кайсыдыр:

— Кача! Тайгага кача!— дип кычкырып җибәрде. Актырнакның муенына тагылган бауны ике куллап тотып, алга ыргылган этен көчкә тыеп Хафиз әкә янына Йосыф чабып чыкты. Кабер өстенә ут салган карачкы томырылып эрәмәлеккә кереп югалды.

— Танып булмады явызны!— дип сукранды Хафиз әкә.

— Җибәрегез этне!— диде Уразаев.

— Актырнак!— дия-дия Йосыф бауны чиште.— Өс-с!

Эт ашыкмыйча гына карны иснәп бөтерелеп алды һәм яшь хуҗасы күрсәткән якка чабарга тотынды, аннан да, моннан да килеп чыккан бала-чагалар, зурлар һау-һаулап аның артыннан йомылдылар.

Эт качып баручыны юан кедр төбендәрәк куып җитте һәм арттан җилкәсенә сикерде. Ул арада булмады шырпы күкерте белән корылган тимер, бакыр көпшәле «наган»нарын шартлата-шартлата балалар да килеп җитте. Актырнак яман ырлый-ырлый җиргә йөзе белән капланып яткан кешенең чабуын тарта иде. Кеше борылып уң кулы белән эткә селтәнде һәм Йосыф... Сәмукны танып алды.

— Сәмук?!— «Әкә» димәде малай, олылап әйтергә теле әйләнмәде, яшь хуҗасының якында икәнен тоеп, Актырнак тагын да аяусызланыбрак Сәмукны йолыккаларга тотынды. Ул арада әлсерәп-пешеп Уразаев, Хафиз әкә һәм башкалар килеп җитте. Килеп җиткәне бере туктый да, ярым алка ясап, мөртәт бәндәне урый бирә.

— Сәмук бу!— дип аңлатты Йосыф.

Җыелганнар гаҗәпләнеп ахылдап куйды.

— Сәмук?!— диде яткан бәндәнең бөкересенә төрткәләп Хафиз әкә.— Җир бит! Ата-бабалар рухыннан көлеп, авылыбызның яманатын таратып, әрвахларын мыскыллап йөргән мөртәт син икәнсең! Тор!

Этне көч-хәл белән читкәрәк алып киткәч кенә Сәмук торып басты, битен пычрак юеш җиңе белән каплап үксергә кереште.

Җинаятьчене тентеделәр, кесәсеннән бер кап шыршы һәм коры каен тузы кисәкләре чыкты. Җыйнаулашып зират янына кайттылар, дегет катыш керосин чиләктә янып бетеп килә иде инде.

— Йомшак җире белән утлы чиләккә утыртыйк үзен!— диде кызып Хафиз әкә.

— Әйдә, әйдә!— дип куәтләделәр балалар. Җыелганнарның уртак теләген хуплаган сыман, Актырнак та абалап өрә башлады.

— Төрмәдә чертермен!— дип чәрелдәде Сәмук.— Тереләй утта яндырган өчен сиңа да якты көн булмас!

— Бөтенләй яндырмыйм, кайбер җирләреңне генә өтеп алам!— диде сабырсызланып Хафиз әкә.

— Шаяру җитеп торсын, Хафиз әкә,— диде Уразаев.— Сәмук хәзер үк скелетны табып бирсен, каян алганын әйтсен. Берсен дә яшермәсен!

Хафиз әкә белән Уразаев алдында тел яшереп маташса да, районнан килгән тикшерүче аны бик тиз ипкә китерде. Сәмук Иртеш дулкыннары актарып ярдан чыгарган сөякләрне җыештырып алуын да, Эссәт

әкә кабере өстенә ничә тапкыр ут кабызуын да сөйләп бирде. Ул закон алдында тиешле җәзасын алды. Җәза карарына артык исе китмәде аның, иң мөһиме — Карун Рәхмәтулла белән бәйләнеше тагын күләгәдә күмелеп калды... Кара эшләрнең башында торган атаманны язмыш тагын аяды.

## 23

Капуш китеп югалганнан соң Рәхмәтулланың башка юлдашлары да озак тормадылар, атаманнан куркып-калтырап яшәсәләр дә, берәмберәм китеп беттеләр. Рәхмәтулла аларны тоткарларга да тырышмады, өмете өзелгән, күңеле төшенке иде аның хәзер. Якса учакны яга, якмаса салкын җирдә кырын ятып авыр уйларга күмелә. Ни уйласа да уйларының очы юк, көчәнеп-көчәнеп очын тапса, уйлары барыбер караңгы килеш, яшәгән җире сыман дымлы-сөремле килеш кала. Колхозлар таралып бетәр дип көтте ул, көткәне килмәде. Руслар-татарлар сугышып яши башлар дип өметләнде ул, өметләнгәне алга чыкмады. Тормыш үз юлын алып акрын гына рәтләнә, шәһәр-авылларда бер җайга кереп бара иде. Сазлы күл ярларында, кедрач куелыкларында яшәсә дә, Рәхмәтулла үзгәрешләрне сизә, тоя, белә иде. Әйе, юлдашлары аны берәм-берәм ташладылар, алар кая китте, ничек яшиләр хәзер, Рәхмәтулла кызыксынып тормады. Хәзер аңа барыбер иде, дөнья сүрән, өметләр өзелгән, юллар киселгән. Узганнарга кайту юк, киләчәктә аңа урын әзерләнмәгән. Иртәгәсе көне ни аяныч булып тоелса да, ул елга якын урманда ялгызы яшәде... Эссәт Фәтхуллинны да ул атып үтерде. Ул чагында аның янында ике иптәше бар иде әле. Сәмук та сирәк-мирәк очрашырга килеп чыккалый, хәбәрләр йөртә иде, ул да югалды.

Бер ел япа-ялгызы яшәде Рәхмәтулла. Кыш чыкты, язны үткәрде, көзгә керде. Гәүдәсе бөкерәйде, күз кырыйлары эренләп касмакландылар, тәне каралды... Көзге кырпак төшеп, елга-күл читләренә беренче күңелле боз челтәре ятканда, ул яңа туган айга карап бер аланда озак ятты. Учагына чи утын салган иде, ул ачы сөрем чыгарып чыртлыйчыртлый янса да аның күшеккән тәненә җылы бирмәде. Озак уйланды Рәхмәтулла, учак сүнде, ай урагын кедрач куелыгы йотты, бөтен тәне бәргәләнә-бәргәләнә калтырый башлады... Таңга кадәр изаланды Карун, ипкә ирешә алмады, ахыр чиктә бер карарга килеп, күмелгән алтын тәңкәләрен казып алды, тун итәген кайтарып, бөрмәләп акчаларын шунда текте, ике мылтыгының берсен үзе генә белерлек куышка яшереп куйды, икенчесен иңенә алды. Чуен-чүлмәкләрен, тимер чиләген дә, вактөяк тормыш кирәк- яракларын да әйбәтләп төреп, чүпрәкләр белән чолгап кайсын кая урнаштырды, алачыгын иште, мул коелган яфрак белән томалап күмде. Алан уртасына басып тирә-ягына бер карады да тирән итеп көрсенеп төньякка юл алды. Кышка каршы рәтле кеше юлны җылы якка, көньякка сайлар иде, әмма Рәхмәтулла җылылыкны онытып бара иде, аңа ялгызлык булсын да, тамагы туйсын. Башкасы кирәкми. Ул төньяктарак, Саз тирәсе авылларында үзе сыярлык кына куыш табасына ышана иде. Капуш сөйләгәннәр дә хәтерендә, болай да чамалый, ул якларда качыйм дигән кешегә урманның кочагы киң!

Башта кунарга гына калды, бер-ике көн ауга чыгып югалып торды да тагын әйләнеп кайтты Карун Рәхмәтулла. Бер күзенә ак төшеп каплаган, төп кебек юантык, табак битле марҗа аны сөенеп каршылады, сүзгә саран иде, берни сорашмады, төпченмәде, ашыгып-ашыгып караңгылы-яктылыда кичке аш әзерләде, ашыгып-ашыгып Рәхмәтуллага карамаска тырышып сәкедә урынын җәйде. Түшәме тәбәнәк иде толның — бөкерәйсә Рәхмәтулланың башы ботаклы каралган тактага барып терәлә, ишегә тар — кергәндә Рәхмәтулла янтаеп кына уза ала. Шул кирәк Рәхмәтуллага, ялгызлык кирәк, ялгызлык! Ак күзле хатын-

нап башта шикләнеп йөргән иде, ай, ай ярым китә, кайта йөргәннән соң ул аны сынады, сынагач ышанды, хәтта ничектер якын итте. Саз ягы урманнары киеккә бай, күлләрендә балык мыжлап тора, Рәхмәтулла һәр эшнең әмәлен яхшы белә, бер чакта да коры кул белән кайтмый, такта-токталардан әтмәлләгән өйалды почмагында акбалык чүмәлә булып өелеп тора. Теләсәң чи килеш аша, теләсәң өреле куе шулпа пешер. Хатын күрер-күзгә котсыз булса да, ярыйсы ук уңган иде, Рәхмәтулланың өс-башын юнәтте, тәнендәге шеш төпләрен аю мае сөртеп дәвалады, сорашмады, белешмәде, исемен дә Яңа ел алдыннан гына белде бугай.

— Хикмәтулла мин,— диде ир.

Якындагы күлнең исеме дә бик сәер — Чүпле күл. Авыл йортлары анда-санда, бер-берсеннән шактый еракта урнашканга, тол хатынның өенә аяк баскан кеше дә юк. Авылдан чыктың исә мөлдерәмә сазлык башланып китә. Беренче тапкыр бу сазлыкка аяк баскан кешенең буыннары калтырый башлый. Сазда дерелди башласаң, сиңа нәреп, ун-унбиш метрда, тирә-якта мүк тирбәлә...

Ә мүклектә торнакүз! Аны соскак белән сосып җыялар.

Рәхмәтулла бу урынны яратты. Чүпле күлнең аръягында куе кедр урманы башлана.

Былтыр кедр чикләвеге бик уңды. Рәхмәтулла иртән ауларын карап чыга да ашап-эчкәч, көймәдә күл аръягына чыгып китә. Көндезен дүртбиш капчык чикләвек күркәсе җыеп кайта. Аны алачыгының түбәсенә киптерергә куя, бер өлешен җиргә күмеп сагыздан арындыра. Хатыны аның ни көткәнен, ни теләгәнен сыңар күз карашыннан ук аңлап ала. Гөбе-гөбе ботлары ачылып киткән очракларда Рәхмәтулла бер генә ым кага, хатын кысан ишектән керә-керә чишенә башлый. Яратмый көтәргә Рәхмәтулла, яратмый!..

Бер көнне ул бай табыш белән күз бәйләнә башлагач кына алачык йортына кайтып керде. Этләрен якындагы нарат төбенә бәйләде, мылтыгын аучылар гадәте буенча тышта, стенага элеп калдырды. Алачык түбәсеннән чикләвек күркәләренең җиргә коелып-коелып төшүен күрсә дә, фикере таркау иде, моның сәбәбен ачыклап тормады, җил булгандыр, дип уйлап алды. Ул кайтып керүгә хатын казан асты, аш салды. Табан балыгыннан пешкән шулпа өстәлгә килеп тә утырды, ишегалдындагы этләр чамасыз һаулап өрергә дә керештеләр. Рәхмәтулла кашыгын ташлап ишеккә атылды, ботаклы такталга баш түбәсе тиеп сыдырылды, ишекне ачып җибәрсә, ни күзләре белән күрсен — ишектә дәү җирән аю!.. Рәхмәтулла күренүгә әлеге чакырылмаган кунак арт аякларына басып ишекне каптырып та алды һәм урыныннан кубарып ыргытты. Аны этләр шулай ярсыткан икән!

*Дәвамы бар*



*Шагыйрә Гөлшат Зәйнашева исеме укучыларыбызга яхшы таныш: аның сүзләренә Татарстан һәм Башкортстан композиторлары тарафыннан күп җырлар язылган, һәм бу җырлар — алар арасында «Туган җирем — Татарстан» (А. Ключарев музыкасы), «Китмә, сандугач» (Р. Яхин музыкасы), «Менәргә иде Урал тауларына» (М. Мозаффаров музыкасы) кебек җырлар бар — халыкта чын мәгънәсендә киң яңгыраш алдылар. Шулай ук укучылар аны драма әсәрләре авторы буларак та беләләр.*

*1962 елдан КПСС члены, 1969 елдан СССР Язучылар союзы әгъзасы Гөлшат Хисам кызы Зәйнашева 1928 елның 13 январенда Татарстан АССРның хәзерге Сарман районы Иске Теләнче авылында туган. Балачагы Минзәлә районы Югары Тәкермән авылында уза, шунда — башлангыч, Хуҗамәт авылында җидееллык мәктәпне, аннары Минзәлә педагогия училищесын тәмамлый. 1945—1949 елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый; аны тәмамлагач, Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясендә редактор, радиокомитетта музыкаль тапшырулар редакторы, Татарстан язучыларының Г. Тукай исемендәге клубы директоры булып эшли. 1973—1983 елларда исә ул Татарстан китап нәшриятында кадрлар инспекторы вазифасын башкара. Беренче шигырьләре, җырлары, эстрада өчен пьесалары илленче елларда көндәлек матбугатта һәм «Күңелле сәхнә», «Мәктәп сәхнәсе», «Эстрада», «Клуб сәхнәсе» кебек күмәк җыентыкларда басыла. 1958 елда «Тыңларсыңмы җырларымны» исемле беренче китабы дөнья күрә; шул ук елда аның «Рамай» пьесасы халык театрлары сәхнәсендә куела. Бүгенге көндә Г. Зәйнашева — дистәдән артык китап (шигырьләр, җырлар, пьесалар, балалар өчен әсәрләр) авторы.*

*Шагыйрә 60 яшен иҗади дәрт белән янып, яңа әсәрләр язып каршылый. Күркәм юбилее белән котлап, без бу санда аның бер бәйләм шигырь, җырларын укучылар игътибарына тәкъдим итәбез.*

# Гөлшат Зәйнашева

## Топольләр

Кайттым туган якларыма
Сезне сагынып, топольләр.
Кирәкми миңа, кирәкми
Сез булмаган ят илләр.

Мине дә сагынган кебек,
Шаулыйсыз, топольләрем.
Күңлем туйганчы тыңладым
Яфраклар лепердәвен.

Яфраклар ни сөйли икән,
Беләсе иде, топольләр.
Мәңге кире кайтмас өчен,
Сызылып үтә бу көннәр.

Айкаласыз, чайкаласыз,
Шаулыйсыз, топольләрем.
Беләсез, күрәсез мәллә
Бөтен дөнья хәлләрен?!.

Давыл килсә, топольләрем,
Кире борасыз кебек.
Илне саклап афәтләрдән,
Сакта торасыз кебек.

## Идел суы ага торыр

Идел суы ага торыр,
Алысларга бара торыр.
Кылыч тотып килсә дошман,
Идел-суга бата торыр.

Идел суы ага торыр,
Дулкыннарын кага торыр.
Өлкән җиңги углан тапты,
Безнең нәсел арта торыр.

Идел суы ага торыр,
Җилкән-көймә бара торыр.
Идел кичкән ир-егетләр
Чын дусларны таба торыр.

## Тургай гөле

*Хәсән Туфан истәлегенә*

Иртә язда кайткан тургай кебек,
Кар астыннан чыккан гөлләргә
Тургай гөлләре бу, диеп, Туфан
Ярата иде сулар сибәргә.

Шагыйрь китте, ул юк инде мәңге,
Тынып калды Аккош күлләре.
Туфан үзе тургай иде диеп,
Сагына аны зәңгәр гөлләре.

Тургай гөле зәңгәр чәчәк атып,
Зәңгәр таң нурында коена.
Тургай кебек очып кайтыр ул, дип,
Көтә аны җәйләр буена.

Оя корган гөлләр арасына,
Сандугачмы, сабан-тургаймы?..
Сабан тургайлары сайраганда,
Эзли гөлләр Туфан-тургайны!..

## Исеңә төшәрмен

Сызып ташлап мине хәтереңнән,
Оныттым дип гомер итәрсең.
Очрый калсам әгәр урамнарда,
Күрмәмешкә салышып китәрсең.

Ә мин син йөрисе юл буенда
Гөлләр булып үрелеп үсәрмен.
Я бер моңлы җырга әверелеп,
Көн дә синең исеңә төшәрмен.

Яшьлек хатабыздыр язмышыбыз,
Ник яшибез аңа буйсынып?..
Үтәр гомер — соңгы сулышкача,
Бер-беребезне яшерен юксынып.

Сызып ташлап мине хәтереңнән,
Оныттым дип гомер итәрсең.
Хәтерең белән түгел, бәгырең белән
Барыбер мине һаман көтәрсең.

## Үткән гомер турында

Таныш сукмагымны югалттым мин,
Юлсыз җирдә йөрдем юл ярып.
Таныш сукмак бәлки табылыр да,
Үткәннәрне булмый кайтарып.

Үткәннәрем минем яшьлек булган,
Яшьлек киткән зәңгәр юл алып.
Атылып сүнгән йолдыз кебек анда,
Сөйгән ярым калган югалып.

Үтмә, гомер, димим, үтсен әйдә,
Үтсен әйдә йөрәк тынмагач.
Үткән гомерем миңа кирәк түгел,
Яшьлек ярым кайтыр булмагач.

## Язгы таңда

Язгы таңда йөрдем тау астында,
Тау битләре кардан арчылган.
Гөрләвекләр тавышын тыңлап тордым,
Табигатьнең теле ачылган.

Тынгысыз соң язгы гөрләвекләр,—
Юл юк җирдә үзенә юл таба.
Челтер-челтер нидер сөйли-сөйли,
Тау астына йөгереп югала.

Кошлар сайрый, кошлар чөкердәшә,
Ни куаныч икән кошларда?..
Әзер алар томшыклары белән
Оя корып көн-төн эшләргә.

Язын кошлар яңа тормыш башлый,—
Һәр яз саен шулай яңадан...
Исем китеп карап йөрим ялгыз,
Мин көнләшәм ахры алардан.

Яңабаштан, өр-яңадан башлап,
Яшисе иде кошлар шикелле:
Кош түгел лә, кеше булып кешенең
Моңа хакы бардыр бит инде?!

Бу уема каршы фикер әйтеп,
Телгә килде шунда биек тау:
«Мин дә менә, гасырларны узып,
Мәңге яшәр идем исән-сау! —

Һәр нәрсәнең башы һәм ахыры бар,
Ташлар тиккә таудан ташланмый.
Бернәрсә дә ләкин кабатланмый,
Яңабаштан гомер башланмый!..» —

Диде, моңаеп тау, сулар, ярсып,
Тәгәрәткән ташлар тавышыннан...
Таулар, ташлар белән бер серләштем,—
Табигатьнең теле ачылган.

## Очратсам да башканы

Таңда сүнсә, кич кабына
Күк йөзендә йолдызлар.
Йолдыз янар, минем йөрәк
Гел сине сагынып сызлар.

Очратсам да башканы мин,
Гел сине сагына күңел.
Йолдызларга тиң булса да,
Син түгел ул, син түгел.

Күк йөзендә йолдызлар күп,
Ай бер ялгызы яна.
Йолдыз түгел, ай кебек син!
Берәү генә дөньяда!..

## Көмеш балдак

Алтын түгел, көмеш балдак кидем,
Борынгыдан калган саф көмеш.
Саф көмештәй гүзәл яшьлек үтте,
Синсез үтте — нинди үкенеч!..

Алтын түгел, көмеш балдак кидем,
Сызыла, сызыла көмеш балдагым.
Балдак кебек сызылып, өзелеп яшим
Бу гомеркәйләрнең калганын.

Алтын түгел, көмеш балдак кидем,
Борынгыдан калган саф көмеш.
Син оныттың, ә мин мәңге саклыйм
Мәхәббәтебезне саф килеш!..

## Мәхәббәтең алда әле

Ялгыз күгәрчен шикелле,
Йөрисең син урамнарда.
Туктап калып юл бирәсең,
Парлы-парлы узганнарга.
    Башкаеңны кайгыларга салма әле, салма әле,
    Мәхәббәтең синең алда әле, алда әле...
Гашыйк булдың яшьлегеңдә
Бирәүгә син яшерен генә.
Еллар үтте бер-бер артлы,
Ул хис сүнде әкрен генә.
    Башкаеңны кайгыларга салма әле, салма әле,
    Мәхәббәтең синең алда әле, алда әле...
Гашыйк булу — сөю түгел,
Сөю — утка ташлаган ул.
Мәхәббәтең бер очрар,
Әле сине тапмаган ул.
    Башкаеңны кайгыларга салма әле, салма әле,
    Мәхәббәтең синең алда әле, алда әле...



**Ринат Мөхәммәдиев**

# УРМАН КАРАЧКЫСЫ

хикәя



Бүреген артка чөя төшеп, маңгаена бәреп чыккан тирне сөртеп алды Нургаяз. Ниһаять, иркенләп суларга да була. Менә ничә көн инде иртәдән кичкә кадәр кулыннан төшмәгән балтасына карап куйды ул. Баш бармаклары белән кагылгандай итеп, аның үткенлеген чамалады. «Алай да балта чыдый, балта түзә әле,— дип уйлап куйды ул.— Бер атна эчендә ун меңнән артык чыршы кисеп озатты ич. Үзе үстергән агачларга үзе балта чапты... Нишлисең, махсус үстерелгән агачлар булгач, башка чараң юк. Бәйрәм хакына... Яңа ел хакына... Шул чыршылар әйләнәсендә уйнап бәйрәм итәчәк шәһәрдәге сабыйлар хакына кисте... Быел ун мең. Киләсе елга ун мең. Алга таба да шулай — барысы да уйланылган, планда каралган. Әнә ич, рәт-рәт булып, килер яңа елларны көтеп чиратка баскан чыршылары. Имин еллар гына булсын, чыршыга килеп терәлмәс»...— дип тәгәлләде уйларын.

Тәгәлләвен тәгәлләде, әмма күңелендә күптән йөргән бер теләге бар иде бит әле аның: өй түренә ямь-яшел чыршы кертеп урнаштыру. Гомерендә бер генә тапкыр булса да яңа елны җылы өй түрендә утырган чыршы янәшәсендә каршы алу. Елы да гадәти генә түгел — алтмышынчы яңа елы. Күптән карап торган, хәстәрләп килгән чыршысы да бар.

Ныклы бер фикергә килеп, тәвәккәл адымнар белән көрт ерып шул чыршыга төбәп китте Нургаяз. Иңбашына ак шәл салган сабыр туташ сыман, әнә, үзе дә аны көтеп тора. Бәйрәм күлмәгедәй киң ябалдашлары ап-ак кар өстенә сыгылып-сыгылып төшкән. Чыршының төбенә кай тарафтан килергә дә белгән юк, куе тармаклы киң ябалдашлар белән уратып алынган.

Әллә нәрсә булды, бөтенләй чарасызланып калды бит әле ул. Балтасы да үтмәсләнгән, чыршы төбен дә табарлык түгел. Шуның өстенә, кары да тирән тагы. Быелга калып торсынмы соң әллә... Киләсе елга тәвәккәлләр, боерган булса. Кар да болай күп яумас... Көне дә әнә чалт аяз, кызганмый ничек кул күтәрергә кирәк... Чү, алсулана барган кояш нурлары да, аның чыршысы ботакларына уралып, кар бөртекләре белән уйный-шаяра түгелме соң?

Ныклы бер фикергә килеп, ул кулындагы балтаны җәтрәк бил каешына кыстырды. Һәм, иркен сулап, кытыршыланып беткән уч төпләрен бер-берсенә ышкып алгач, көрт ерып, кайтырга чыкты. Юлдан түгел, турыдан гына, ерак түгел агып яткан салкын чишмә аша кайтырга ниятләгән иде ул.

Кышын урман шәрәләнеп кала, диләр. Бу хакта Нургаязның да ишеткәне бар. Урман читләп машинада узган кешегә бу, бәлки, чынлап та шулай тоеладыр. Әмма Нургаяз өчен түгел... Кышкы урман үзе бер мөстәкыйль дөнья булып яши, иркен сулыш ала, бушап калмый, кырыкмаса-кырык төрле җәнлек һәм кош-кортлары белән көндәлек мәшәкатьләргә чума. Кар өстендәге эзләр, агач башыннан коелган учлам-учлам кар, корыган ботак кисәкләре, усак кайрыларындагы теш тамгалары — һәркайсы кышкы урманның талгын тормышы турында сөйли.

Дөньясын онытып, шул хактагы уйларга бирелеп барганда, кинәт аның каршысына кабаланып чапкан куян килеп чыкты. Әллә куркудан югалып калды — колакларын торгызган ап-ак куян текәлеп диярлек аңа карап тора. Нургаяз үзе дә, ирексездән, атларга-атламаска белми торган урынында катып калды. Гомер булмаган хәл — куян белән карашлары очрашты аларның. Ул — куянга, куян аңа күзләрен мөлдерәтеп карап тора иде, әйтерсең, магнитланганнар. Араларында күп булса алты-җиде адым ара булгандыр, артык түгел. Тын да алырга уңайсызланып, керфек какмый карап торды Нургаяз. «Куянның күзләре кылый диләр — ялган»,— дигән уй йөгереп узды аның күңеленнән. Ә куян, аның саен күзләрен зуррак ачып, текәлгән көе тик басып тора. «Куян куркак диләр — бусы да ялган»,— монысы инде үзеннән-үзе килде аның уена. Күңелен шом, ниндидер сәер шом баса башлады урманчының. Гаҗәп: ул калтырана башлаган иде. Ләкин суыктан түгел. Бу көтелмәгән сәер очрашу һәм талгынлык, урман эчендә ялгыз куян белән күзгә-күз карашып тору тагын күпме дәвам иткән булыр иде — әйтү кыен. Куян түгел, бүре яисә кабан дуңгызы белән шулай очрашканда да куркуның ни икәнлеген белмәгән, урманда гомер кичергән урманчы түзмәде, үзен биләп алган шомнан тизрәк арынырга теләгәндәй, карашын бер мизгелгә генә читкә тайпылдырды. Куян да моны шундук сизде һәм ул да уңга-сулга күзләрен йөгертеп алды, әмма кымшану, колакларын кыймылдату — уенда да юк. Урманчыны сыный, аны аңларга тели, әллә ни дә булса аңлатырга омтыла идеме соң ул үзенең бу әрсезлеге белән? Теле генә юк, әгәр теле булса, куян һич кенә дә мәгънәсез сүз әйтмәгән булыр иде шул мизгелдә...

Нургаяз, башкача булдыра алмыйм дигәндәй, сак кына алга омтылып алды. Серле тынлыкны югалту өчен шул җитә дә калды. Куянның борын тишекләре киң ачылып, колаклары тагын да тырпая төште, һәм ул шундук, тирән кар өстеннән бата-чума сикергәләп, күздән югалды. Ә икенче яктагы куелыкта кинәт корган куак шартлап сынды... Хикмәт менә нидә икән! Агачлар артында кире борылырга мәҗбүр булган төлкенең ялкын теледәй койрыгы гына шәйләнеп калды.

Берничә адым атлауга, тагын өр-яңа эзләргә юлыкты ул. Ана поши, бозавын ияртеп, салкын чишмәгә таба үткән. Эзләренә әле бәс кунарга да өлгермәгән. Кар тирән. Кар ерып йөрүләр бераүгә дә җиңел түгел мондый кышта...

Ниһаять, ул салкын чишмә читенә килеп чыкты. Чишмә аръягындагы зур алан читендә аның ялгыз йорты урнашкан. Салкын чишмә — бу урманның мактанычы. Халык телендә аны Силингер дип йөртәләр.

Силингер... Бу чишмәгә ни өчен нәкъ менә шундый исем тагылганын ачык кына белүче юк. Шулай да Нургаязның бабасы элекке елларда моны үзенчә гөманлап аңлата торган булган, диләр. Имеш, бу тере су тирә-юньдәге калын урманның җаны. Нинди генә буран һәм чатнама суыклар булмасын, аны бервакытта да кар-боз капламый. Бу чишмәнең урманны кыл урталай бүлеп, ничек кабаланып акканын күзәтеп, тыңлап торсаң, исең-акылың китәр: бер дә харап шаулап, гөрләп ага ул. Урманның, андагы һәммә тереклек һәм агачларның теле, имеш, бу чишмә. Гөр килеп ага, берөзлексез сөйләнеп ага.

Силингердән пар бөркелеп тора. Кышларын гел шулай. Атналар буе күзачкысыз буран булып та, аның кар астында күмелеп калганы

юк. Өрәңгеләр шартлап ярылган, имәннәр түзмәгән суыкларда да аны боз капламады. Бүрсет суы һәм гайрәтле Кама калын боз катламы астында калганда да Силингер, җылы пар бөркеп, тик шаулап агып ятуын белә. Ә җәйләрен суы тешне сындырырлык салкын була үзенең, андый салкын суны тирә-якта табарлык түгел. Менә шундый чишмә ул Силингер! Йөзьяшәр нарат тамырлары төбеннән бәреп чыга да ашыгып-кабаланып йөгерергә керешә. Көн йөгерә, ай йөгерә, ел йөгерә шулай. Барыр юлында аңар ком-таш арасыннан кайнап торган яңа чишмәләр кушылып җегәр өстиләр. Саегуны, ару-талуны белми йөгерә Силингер.

Гомере шушы су читендә узды Нургаязның. Ул шушында, аучы кышлагында туган. Унҗиде яше тулыр-тулмастан сугышка чыгып китте һәм дүрт ел буе ут эчендә Европаны аркылыга гизеп, шушында кайтып та төште. Өйләнде. Уллар үстерде. Инде менә бер ялгызы яшәп калды. Шулай да Силингердән, урманыннан аерылмады. Гомеренең соңгы сәгатен дә ул шушында, Силингердә каршылар. Мәңгегә шушында калыр...

Бу юлы да Силингер яныннан тыныч кына атлап үтә алмады ул. Онытылып-онытылып, су агышын тыңлап торды. Әйтерсең лә су түгел, гомер шулай ага. Җәен дә шул аваз, көзен дә, кышын да шул ук аваз. Әмма елның һәр фасылында үзенә бер ямь таба, үзенә бер кабатланмас моң шәйли торган иде ул монда. Җанга якын, күңелгә ятышлы ул моң бары монда гына ишетелә. Җил исә, урман шавы кушыла аңарга, таң беленсә — кошлар сайравы, чикерткә авазы, күке тавышы, тукран тукылдавы... Боларның һәркайсы, чишмә агышына кушылып, моңга әверелә монда. Шуңадыр инде: бер ялгызың калып, Силингердәге авазларга колак салсаң, күңел мөлдерәп тула, тамакка төер тыгыла. Күңелдәге хис һәм тойгылар тоташ ташкынга әверелер дәрәҗәгә житә. Урмандагы һәммә тереклекне, агачларны, үләннәрне берәм-берәм сыйпап-сөеп узасы килә шундый чакларда, кешеләргә изгелек, табигатькә игелек кенә кыласы килә...

Менә бүген тагын, сабый чакларындагыдай онытылып, чишмә авазына колак салып тора Нургаяз. Беренче кат монда килеп чыгуы диярсең... Башка һичнинди аваз да ишетелми. Агачлар шавы да, кошлар сайравы да, чикерткә авазы да. Силингернең, кабалана-кабалана, нидер аңлатырга омтылгандай сөйләнүе генә... Беләктәге арыганлык, аяктагы талу онытылды. Ә күңелдә — үзе рәхәт, үзе моңсу, аңлатуы түгел, үзенә дә аңлау җиңел булмаган бер халәт. «Ун мең... чыршы»,— дип куйды ул үзе дә абайламастан. Ун мең! Әйтергә генә җиңел. Силингер буенда тамыр җәеп, якты зәңгәр күккә омтылган нарасыйлар иде ич алар. Чишмә дә шуңа моңланамы соң әллә бүген? Ун мең төп чыршы... Шулкадәрле гаиләгә бәйрәм шатлыгы иңгәндер бүген. Чыршы кисү җиңелдән түгел, ә кешеләргә бәйрәм шатлыгы озату — башка.

Бил каешына кыстырылган балтаны алып, кар көртенә сөяп куйды Нургаяз, аннан, бүреген салып, балта сабына элде. Салкын чишмә яныннан үтеп тә аның суын татымый узу, тәнеңә гайрәт индерми китү мөмкинме соң... Аякларын җәя төшеп, ул Силингернең ике як ярына басты һәм суга үрелде. Бармакларын, уч төпләрен өтеп алды су, тәндәге оеп киткән бөтен күзәнәкләрен кинәт уятып җибәрде. Шул рәхәтлекне тоеп, берара торгач кына кушуч тутырып алган суны иреннәренә китерде Нургаяз. Арыган иде. Йотлыгып-йотлыгып эчәсе килә иде аның. Әмма авызына капкан суны йота алмады, тамагыннан үтмәде су. Кинәт тетрәнеп куйды ул. Күккә ашкан биек нарат очларыннан ак бәс коелды. Кабаланып тагын суга үрелде... Ялгышмаган! Юк ялгышмаган икән — чишмә суыннан кан тәме, кайнар кан исе аңкып тора иде...

Өйалды ишеген тырный-тырный тышта эт өргән авазга уянып китте Нургаяз. Нигә өрә икән ул? Нигә шулай ярсый?.. Кешегә ул алай ук өрмәс, бер-бер кыргый җанвар килеп чыктымы икән? «Юлдаш! Юлдаш.

нигә өрәсең?..» — дип дәшәсе килде аның. Әмма иреннәре ачылмады, тавышы чыкмады. Өй эче янә тынычланып калды. Кипкән иреннәрен чылатырга теләп, авыз эчендә адашкан телен табарга, кыймылдатырга итте ул. Әмма барып чыкмады. Әллә иреннәре кымшанмады, әллә теле аңкаудан аерыла алмады. Бөтен тәне оеган, күз кабаклары авырайган. Ул тагын онытылып торды.

...Бу юлы инде аны ат кешнәгән аваз сискәндерде. Аның бахбае кешни иде. Ашарына салынмаган... Эчәсе дә киләдер. Тик менә Нургаязның күзләре генә ачылырга теләми. Күз кабакларына нәрсә шулай баса — керфекләре шулай авырайганмы? Нигә ачылмый соң әле аның күзләре? Болай изрәп яту ярамас, җитәр! Өрә-өрә, әнә, анда Юлдашның тавышы да беткән, өйалды ишеген тырный-тырный чиный. Этне газапларга ярамас, елый ич, бичара... Торырга... Чыгарга... Юлдашны тынычландырырга кирәк! Тик менә күзләрне, күзләрне генә ничек ачарга соң?.. Ул янә изрәп йокыга талды.

...Бер мизгел уздымы, бер тәүлекме — хәтерләми. Дөп-дөп ишек каккан, юк, ялгыша ахрысы, капка дөбердәткән тавышка уянып китте ул бу юлы. Башын күтәрә төшеп, сагаеп, тыңларга итенде — баш идәннән күтәрелмәде. Ә капканы аның саен һаман дөбердәтәләр. Тукта, капкамы соң бу, әллә... Капкада бик юк ич. Ишекме? Ишектә дә элгеч юк. Нәрсә булыр, идәнне дөбердәтәләр дисәң... Булмаганны! Өстәвенә колак шаулый, чигә кыса. Әллә йөрәге тибәме соң шулай! Күкрәк читлеген ватарга теләп әллә йөрәге шулай ярсынамы? Юлдаш ни дип өрүдән туктады икән тагы? Атның да тавышы-тыны юк. Бер-бер хәл булмагандыр, исәннәрдер ич?.. Болай яту ярамас, торырга кирәк, торырга. Ачыкканнардыр...

Кымшанып, кулларына таянырга ниятләде ул. Ләкин буйсынмады, аны тыңламады куллары. Ә чигәне нидер кыса, чигәне һаман җибәрергә теләми.

Ул да түгел, колак төбендә үк ачы итеп сызгырган аваз ишетелә башлады. Бусы инде таныш аваз, аңа яхшы таныш аваз. Кырык дүртнең көзендә, Балтик буенда, окоп өстенә бомбалар шулай сызгырып ява торган иде. «Юк,— диде ул үз-үзенә әмер биргәндәй итеп,— бирешмәячәк. Аны бомба булып бомба ала алмады ич ул чакларда. Окоп өстеннән фашист танклары үткәндә дә аны сыта, таптый алмадылар. Инде хәзер үз өендә, үзенең туган нигезендә, Силингер буенда бирешергә тиешме ул? Юк!..» Ыңгырашу катыш кычкырырга ук керешкән иде инде ул: «Юк! Юк, бирешмәячәк...»

Шунда ук кымшанырга омтылды, әмма иңбашын яшен ташы телеп узгандай булды кинәт. Тагын кымшанырга итте, тагын чәнчеп алды. Юк, ул барыбер бирешмәячәк! Уч төпләрен киң җәеп, нәрсәгә дә булса таянып этенергә ниятләде. Куллар буйсынмады. Үзенең кайда икәнлеген абайлап алды — өйдә, үз идәнендә йөзтүбән ята икән ләбаса. Тупса белән янәшәдә ята. Ишектән кергән дә идәнгә чүгәләгән булып чыга, димәк... Ә шулай да тезләнергә кирәк, аякларына басарга...

Яра сул якта икән, ул кулга таяну турында уйларга да ярамый. Нургаяз иң элек уңга табарак янтаерга тырышты. Бу тикле хәлсезләнсә хәлсезләнер икән кеше... Ә барыбер хәрәкәтләнергә кирәк. Оеган тәнне уятырга, күзләрне ачарга, ничек кенә булса да аякланырга, аякланырга аңа хәзер. Юкса соң булуы бар... Уң кулы белән капшана торгач, ишек тоткасын тапты. Хәзер инде бөтен егәрне бер йодрыкка төйнәргә генә кала.

Аякларына басып, ишек борысына сөялгәч, җентекләп өй эчен күзәтеп чыкты. Өйдә бар да элеккечә. Идәнгә агып укмашкан кан төерләрен искә алмаганда, берни артмаган, берни кимемәгән... Әйе, стена сәгате туктаган икән әле тагы. Гере өсталгә төшеп терәлгән...

Ишекне ачып, өйалдына чыккач, бер тын күз аллары караңгыланып торды аның. Туктап хәл алгач, караңгыда куллары белән капшана-

капшана, болдырга юнәлде. Ул баскан саен сыгылып куйган өйалды идәне суыктан сыкранып-сыкранып калды. Болдырда исә аны Юлдашы каршы алды. Хуҗасын күрү шатлыгыннан эт ни эшләргә белмәде. Әле алгы аяклары белән аның түшенә сикерде, кулларын, бармак очларын ялады. Әле, кабат дүртаяклап, аның бер алдына, бер артына төшеп, койрыгын болгый-болгый, арлы-бирле йөренергә кереште.

Кич житеп килә икән инде... Тик кайсы кич? Ул өйгә кайтып егылганга бер тәүлек булганмы, әллә соң бары да күз ачып-йомган арада булып уздымы? Култыксага кунган яңа кар бөртекләрен учына җыеп, бит һәм маңгаен, колакларын, чигәләрен уарга кереште. Шунда гына күз алдында эленеп торган караңгылык бераз тарала төшкәндәй булды.

Вакыт байтак узган булса кирәк инде. Ишегалдына шактый калын булып яңа кар төшкән. Болдыр төбендә генә кар тапталган иде — Юлдаш күпме гомер ишек тоткасын саклаган дигән сүз иде бу.

Һәр адым, һәр хәрәкәт йөрәк өзгеч авырту белән генә бирелде. Шулай да, иң элек этнең ашарына бирде, аннан, култык астына печән кыстырып, бахбаеның хәлен белеп килде. Иреннәрен җиңелчә генә җилфердәтеп, кешнәү авазы белән каршылады аны ат. Печәнгә үрелмәде, хуҗасының күзләренә текәлеп торды. Хәлең ничек, озак югалып тордың, бер-бер хәл булдымы әллә, дигән сыман сагаеп карый иде ат. «Хайван диген син аларны,— дип уйлап куйды Нургаяз күңеленнән.— Эте булсын, аты булсын, җаныңа керергә әзер булып торалар...»

Лапас яныннан кире әйләнеп килгәндә, күз аллары караңгыланып китте. Ул, болдыр култыксасына тотынып, баскыч өстенә килеп утырды. Бармак очларына боз кисәге алып тагын чигәсенә китерде. Йомылырга җай көтеп кенә торган күзләренә ирек куймау иде теләге. Шулай да күз кабаклары бернигә карамый авырая, аяклары оерга итә башлады аның. Үз-үзен торырга мәҗбүр итүдән башка чара юк икән. Иплә генә атлап, капкага таба китте ул. Каршында караеп торган урман һәм тынлык. Әйе, тынлык, шылт иткән аваз да ишетелми тирә-юньдә. Бу ни була, нигә мондый тынлык соң?..

Кинәт сискәнеп куйды ул, гәүдәсен яшен ташы урталай ярып үткәндәй булды. Нинди тынлык? Ә Силингер?!. Сабырсызланып, башыннан бүреген салып колак салды урманчы: ялгыша... Ялгыша икән ләбаса. Силингернең гөрләп аккан тавышы әнә ничек ишетелеп тора. Җил ялгыштырган, җил генә бутаган аны. Силингер... Әнә, ничек ага, мыдыр-мыдыр килеп, урман белән серләшә ул шулай. Нургаязны утка сала яздың ич, Силингер. Тавышың ишетелми торгач, ни эшләргә белми югалып торды ул әнә. Башка алай итмә, зинһар шаяра күрмә, Силингер. Их, Силингер, Силингер...

Өйгә кереп, буш чиләк алып чыкты Нургаяз һәм, иске сукмакка яңа эз салып, Силингергә төбәп китте. Яр читендә үскән алмалар, иелә төшеп, чишмә суында толымнарын чайкаган шушы борылыш аеруча кадерле аңарга. Монда аның яшьлеге хатирәләре, монда мәрхүмә хатыны Нурлыбикәнең эзләре. Шул алмалардай сыгылмалы чаклары бар иде бит аларның да. Алмә тармакларын аралап, икәү янәшә, йөзтүбән ятып су эчкән чаклары әле кайчан гына! Йотлыгып-йотлыгып, шул чишмә суын эчкәч тә көне буе эшләп арыганнары онытылыр иде. Дәрт тулган күкрәген су өстеннән күтәрмәс борын ук шаярырга керешер иде Нургаяз.

— Әбәү, Нурлыбикә, иренең туңган, өшегән ләбаса,— дияр иде.

— Туңмый соң, Силингернең суы салкын ич,— дип елмаер һәм зәңгәр күзләрен тутырып бер тын карап торгач, чарасыздан аңа таба ымсынып тартылып куяр иде Нурлыбикә.

— Җылытыйм булмаса, өшесә, ни хәл итәрбез,— дип, хатынының биленнән кысып, үзенә тартыр, аннан җәт кенә күтәреп, элмә күләгәсенә алып кереп китәр иде Нургаяз.

— И-и, урман карачкысы, оялмыйсынмы... Кояш та баемаган ич...— дияр иде Нурлыбикә, тулышкан хисләрен яшерә алмыйча, күзләрен йома төшеп.

Менә тагын шул әлмәлек читендә тора Нургаяз. Чишмәгә үрелгән әлмә чыбыклары карга төртелеп күмелеп калган. Яшь чакларындагы кебек йөзтүбән ятып, иреннәре, яңаклары белән суга, Силингернең йөгерек дулкыннарына кагыласы килде Нургаязның шул минутта. Ләкин бу мөмкинме соң? Чиләк белән үрелгәндә дә тез буыннары сыгылып-сыгылып куйды түгелме соң?.. Ә шулай да йөзе белән, һич югы маңгай читен куеп кагыласы килде аның Силингергә. Сабыйларча үзсүзлелек белән ул кар өстенә сузылып ятты һәм, бер як иңбашы чәнчеп-чәнчеп авыртуга да карамастан, яланбаш килеш чишмәгә үрелергә азаплана башлады. Кар өстендә аунаса аунады, әмма үзенекен итте. Иң элек, су өстенә алмаш-тилмәш яңакларын куеп, аның гөрләвенә озак кына колак салып торды. «Бирешмә, Нургаяз, бирешмә... Миңа да җиңел түгел, минем дә юлыма аркылы төшүче аз булмады, әмма юлымнан тайпылмадым. Без әле яшәргә тиеш... Урман хакына...»— дия сыман иде аның колак төбендә генә гөрләп аккан чишмә.

Хәлсезләнгән башы чишмә өстендә салынып калган иде инде аның. «Әчәргә дә кайтырга кирәк сиңа»,— дип янә пышылдады Силингер. Комсызланып, иреннәрен суга тидерде ул. Әмма ни хикмәт, бу юлы да су тамагыннан үтмәде аның. Судан әле һаман кан тәме аңкып тора иде. «Икебез дә яралы, бәгырьләребездән кан саркый. Түз, Нургаяз, шулай да түз!..»— дип аваз бирде, көч бирде аңар чишмә. Ул күзләрен ачты, һәм көпшәк кар өстеннән шуа-шуа артка чигенде.

Сулы чиләген кар өстенә куеп, озак кына капка баганасына сөялеп торганын хәтерли ул тагы үзенең. Ә колагына берөзлексез Силингернең челтерәп акканы ишетелеп торды. Нинди көч, нинди җегәр яшәтә икән сине, Силингер?.. Агасың да, агасың... Нургаяз да, әнә, синең кебек үк көр күңел, таза рух белән гомер кичерде. Синең кебек үк мәңге-мәңге яшәр, ару-талчыгу турында һичкайчан уйлап та карамас кебек иде. Их, Силингер, Силингер... Син әле озак, бик озак агарга тиеш... Тик Нургаяз гына менә... Әллә картая да инде? Ай нурларыннан оялган сыман күзләрен читкә борды ул. Һәм шунда өй каршындагы яңа яуган кар өстендә эзләр — кеше эзләре булуын абайлап алды. Аның түр яктагы тәрәзәләре каршында шулай таптану кемгә кирәк булган? Нигезгә өелгән кар өстенә менеп тәрәзәгә каплану кемгә кирәк булган? Кемне эзләгән, нәрсә күзәткәннәр аннан? Кем булыр? Ни өчен яшеренеп, кача-поса күзәтергә аның өен? Капка һәм өй ишеге бикле түгел ич, нигә?... Өр-яңа эзләр!

Өйгә кереп, урын өстендә тагы күпме яткандыр, ул хәтерләми. Өзелеп-өзелеп, уң як иңбашы сулкылдауга түзә алмыйча уянып китте Нургаяз. Өй эче күптән дөм караңгылыкка чумган иде инде. Тышта җил чыккан. Кер киптерү өчен эленгән тимер чыбыкны шап-шоп капкага китереп бәрә иде җил. Өйгә салкын төшкән. Ягарга вакыт җиткәнне белгертергә теләгәндәй, ачы итеп морҗа сызгыра. Түзгәч-түзгәч, иртәгә кадәр түзәргә туры килә инде. Тик менә вакыт күпме икән? Кайсы көн булыр — утыз береме? Яңа елны, алтмышынчы яңа елын бер дә болай каршы алырга җыенмаган иде дә бит...

Утыз бере булса, ул озаткан чыршыларда күптән ут кабызганнар булса кирәк. Бәрәм-бәрәм хәтеренә кереп калган чыршыларын күз алдына китерде ул. Шәһәр өйләренә урман исе, ылыс исе таратып, түрдә утыралар бугай, ә... Очларына кызыл йолдыз эленгәндер әле үзләренең. Тирәләрендә әйлән-бәйлән уйнап сабыйлар йөгерешә микән?.. Менә бит ул үстергән чыршылар! Күпме кешегә бәйрәм шатлыгы китерә алар бүген...

Ә карашы өй түрендәге шәрә почмакка текәлгән үзенең. Анда чыршы урнаштырырга ниятләгән иде дә бит... Хәерлегә булсын инде, быелга өлгерә алмады...

Чыршы дигәннән, сугыш беткән елны ул Мәскәү аша кайтты. Берничә сәгать кенә вакыты бар иде аның. Вокзалдан туп-туры Кызыл мәйданга китте. Сокланганы Кремль манаралары булды. Хәйран калды ул аларны күреп — Кремль манаралары Силингердә үскән мәһабәт чыршыларны хәтерләттеләр. Туган ягын, урманын сагынган иде шул ул. Очларына йолдыз куеп чыксаң, белләһи, боларның кайсы чыршы, кайсы Кремль манарасы икәнне аера алмый икеләнеп калырсың.

Нурлыбикәсе исән чакта: «Син — Мәскәүне күргән кеше, сөйлә әле Мәскәү турында...»,— дип йөдәтә торган иде аны. Үзе сөйләгәнгә үзе үк хәйран калып, урмандагы мәһабәт чыршыларны хәтерләткән Кремль хакында сөйләргә тотынып иде ул. Исе китеп, тел шартлатып тыңлар иде аны Нурлыбикә. «Булмастыр ла, ул тикле манараны аны төзергә кирәк бит. Борчак сибүеңдер, син — урман карачкысы — гел шулай инде, арттырып сөйлисең»,— дип, ышанырга-ышанмаска белми торыр иде. Ә үзенең шул хакта гел тыңлыйсы гына килеп торыр иде. Әлегедәй хәтерендә менә, аңа табарак елыша төшер иде дә: «Сөйлә әле, тагы бер тапкыр сөйлә әле шул Мәскәү турында»,— дип, колакны кытыкларга керешер иде. Ул тагын шул Силингердәге чыршыларны хәтерләткән манаралар турында аңлатырга керешә... Гомер дигәнең бер дә генә узмас кебек иде.

Нигә моңсулана башлады соң әле ул?!. Вакыты андый түгел ич. Иңбашындагы яраны да хәстәрләми булмас. Калак сөяге астына кереп оялаган ядрә... Хәер, ядрә генәме икән, бәйрәмне пошига ата торган чыпчык башы тикле кургаш кисәге белән каршы алу ярамас. Атка менеп, авылга юнәлергәме соң әллә? Әмма шундук ул үз-үзенә каршы төште. Бәйрәм каршы алганда кеше борчып йөрү яхшы түгел. Анда төшеп күренсәң, бөтен авыл аякка басачак... «Кайда? Ничек? Кем?» — диярләр. Бу сораулардан ул хәтта менә хәзер дә калтыранып куйды. Юк-юк, ул андыйга бармаячак! Үзе... Ничек кенә булмасын, үзе ерып чыгар. Яңа ел каршылаганда, кемнеңдер гаиләсенә борчу китерәсе килми аның. Торырга, бер-бер хәстәрен күрергә кирәк.

Үзе күңеленнән шулай дип кабатлады, ә үзенең кымшанырлык та әмәле юк. Канны байтак югалткан, күрәмсең, егәр чамалы. Шулай да күңеленең ерак бер почмагыннан килгән әмергә буйсынырга мәҗбүр итте ул үзен, аякларын берәм-берәм караваттан идәнгә шудырды. Караңгы өйдә капшана-капшана шырпы, лампа табып ут кабызды. Телогрейка сәдәпләрен ычкындырырга керешә. Өстендәге киемнәр яра турында бер-беренә аерып алгысыз булып ябышып каткан иде. Башка чара булмаганнан, тешләрне кысып булса да түзәргә генә кала. Телогрейка артыннан пинҗәк салынды, аннан канга укмашып каткан күлмәген умырып алды Нургаяз. Өйалдына чыгып, чиләк белән бозлы су алып керде, нәни генә шешәгә салынган спиртын чыгарды. Калак сөягенә барып терәлгән кургаш «бочка»га келәшчә очы белән үрелгәнен дә яхшы хәтерли әле. Яраны аралап, аны келәшчәгә эләктерергә азапланганын да хәтерли. Әмма шуннан ары... Ул аңын җуеп, йөзтүбән капланган.

— Нургаяз абый, тор... Нургаяз абый, дим... Нургаяз абый, ни булды? Уян, әйдә, яраңны бәйлик, яраңны, дим...

Төш күрә иде ахры. Төшендә аны шулай үз итеп кемдер уятырга тели. Ул ишетә-ишетүен, әмма күзләрен ача алмый, мәрткә киткән кеше сыман йоклыйсы, бары тик йоклыйсы гына килә аның.

— Нургаяз абый, дим... Торыйк әйдә, кан эчендә ятасың ич. Торыйк, яраңны бәйлик.

Кем соң бу? Кем каныкты аңар шулай? Кем аның йокысын бүлә? Кем аңар тынычлап йокларга ирек бирми? Яраланган имеш... Нинди сүз ул? Аны пуля аламыни? Сугыштан бер ярасыз кайткан Нургаяз-

нымы? Юк, фашист булып фашист тидерә алмады аңар. Төзәп аттылар, әмма тимәде.

— Нургаяз абый, дим. Аптечкаң кая? Аптечкаң, даруларың...— дип дер селкетteләр аны һаман.

— Ә-э,— диде ул, ишетелер-ишетелмәс карлыккан аваз чыгарып. «Сукыр чебеннән дә болайрак булдың, нигә каныгасың? Кем син?»— дип тә әйтәсе килгән иде. Әмма болары күңелендә калды, иреннәре кыймылдамады.

Калай чүмеч белән су китерделәр аңа, Силингер суы... Шуны йотып алгач, тәненә җан кергәндәй булды. Исән кулы белән, минме соң бу дигәндәй, башта маңгаен, аннан берәм-берәм яңакларын сыпырып алды һәм сакал баскан иягендә тукталып калды.

— Аптечкаң бармы, дим, Нургаяз абый?

Шунда гына, моның төш түгел, өн икәнлеген абайлап, күзләрен ачты урманчы. Колакчыннары төшерелгән бүрекле ир-ат тора икән каршысында. Томан элпәсе артындагыдай тоелды ул аңа элек, фокусын көйләми төшерелгән рәсемдәге кебек. Әмма тора-бара күз алдында эленеп торган томан таралып, кешенең йөзе аермачык шәйләнә үк башлады.

— Бинтың бармы?. Марля... Марля дим,— дип дәште ул, Нургаязның маңгаена көрәктәй зур, салкын уч төбен куеп.

Түрдәге өстәлгә таба ымлады Нургаяз, аның дару-фәләннәре шунда тора иде. Файдаланганы юк-югын, шулай да бер тартма тулы тегесе-монысы ята анда. Шәһәрдән сирәк-мирәк кайткан чакта уллары, киленнәре төяп кайта, олыгайган кешегә кирәге чыгар дип алып кайталар.

— Хәзер, яраңны бәйлим дә авылга алып китәм,— дип сөйләнәсөйләнә, өстәл тартмасында актарынырга кереште теге кеше.

Юлаучыны танырга теләп, башын калкытты Нургаяз. Башында төлке бүрек, өстендә кайры тун, аякларында киез итек — җылы киенгән үзе. Гәүдәгә калку күренә. Берәр каян кайтып килешли кагылгандыр, Бүрсетнеке булса кирәк...

— Хәзер, Нургаяз абый. Синең монда безнең авыл аптекасыннан баерак икән. Болай булгач, каныңның тамчысын да җиргә төшермибез бүтән.

— Бәтәч,— дип куйды урманчы, үзенә таба борылгач та юлаучыны танып алып.— Бу синмени әле, энем.

Юлаучы дигәне аның кордашы Куян Гыйнияте малае Марсель икән ләбаса. Бүрсетнекеләр. Мал врачлыгына укып кайткан кече малае, колхозда эшли. Әйтәм аны, даруларның рәтен белгәндәй сөйләнеп маташа.

— Безне ат духтыры диләр диюен, шулай да менә диган итеп бәйлибез аны, Нургаяз абый,— дип эшкә тотынды Марсель, бүрек һәм туннарын җәһәт кенә урындыкка салып аткач.

Аның кыланышыннан көләсе килде Нургаязның, әмма кагылмас борын ук сызланырга, чәнчергә тотынган яра күзләрен йомарга мәҗбүр итте.

Тагы бер тын черем итеп алынган икән. Ул уянганда, чарт-чорт килеп, мичтә утын яна иде инде. Өй эченә имән һәм каен тузы исе чыккан. Каршы як стенага мич алдыннан кызыл шәүлә төшә, ул гөлт итеп бер яктырып китә, бер сүрәнләнеп кала. «Юлаучыга рәхмәт инде,— дип уйлап куйды Нургаяз,— әнә ничек, өйгә тәмамысы җан кереп киткән. Ә үзе кайда икән соң ул?» Өстәл артында, мич тирәсендә күренми. Яткан көе генә күзләре белән өй эчен айкады ул. Ә егет, башын уч төпләренә салып, ишек тупсасы өстендә тын гына утыра икән.

Башын калкытып, Нургаязның ишеккә таба үрелүеннән караватшыгырдадымы, әллә очраклы рәвештә күреп алды егет, ул шундук аягүрә торып басты.

— Нәрсә, Нургаяз абый, уяндыңмы? Ну, йоклап та күрсәттең үзең,— дип, карават каршысына килде ул.— Менә, яраңны бәйләдем. Дәү нәрсә белән бәргәннәр, тирән киткән...

— Зыянлы түгел, баш исән булсын,— дип куйды урманчы, җавапсыз каласы килмичә.

— Хәзер, бераз хәл алабыз да аннары авылга,— диде егет, баскан урынында таптана-таптана.

Нургаяз башын күтәрде. Үзен кайгырткан егетнең йөзенә текәлеп карыйсы килде ахрысы. Ә ул борчулы кыяфәт белән инде ишекле-түрле үк йөрергә керешкән иде.

— Ат капка төбендә, Нургаяз абый. Толып — чанада... Бер сәгать тә үтмәс, юыртып төшеп җитәбез аны.

— Мин беркая да барырга җыенмыйм ич.

— Ничек?— дип, сораулы карашын төбәп, аның баш очында ук туктап калды егет.— Ничек? Сезгә кичекмәстән авылга кайтырга кирәк. Врачка...

— Булдыргансың ич инде. Әнә ничек, актан киендерен куйгансың,— дип, сул ягына ымлап, шаяргандай иткән булды Нургаяз.

— Уравын урадым да бит... Ярасы тирән, канны күп югалткансыз.

— Кан табылыр, орлыгы Бохарада түгелдер әле,— дип, үзенең артык исе китмәгәнлеген белдерергә тырышты ул һаман.

Егет бер тын дәшми торды. Уйлана иде, күрәмсең.

— Яңа ел каршыларга ашыгасыңдыр?— дип сорап куйды Нургаяз, егетнең дәшмәвен үзенчә гөманлап.

Егет җәт кенә сәгатенә күз төшереп куйды. Әмма Яңа ел хакында ләм-мим.

— Кан гына түгел шул... Ядрәсе тирән киткән, таба алмадым...

Уңга-сулга күз төшереп алды Нургаяз, келәшчә белән кургашынны күрмәгән, димәк. Кая куйды икән соң ул аларны? Ирексездән юрган астыннан сыңар кулы һәм аяк очлары белән капшанырга кереште — тәненнән алынган кургаш кисәге, каядыр, шул тирәдә булырга тиеш иде аның исәбе буенча. Тапмады, күрәмсең, телогрейка кесәсенә салынгандыр. Аны, әнә, чөйгә үк илтеп элгән кунак.

Егет, тынгысызланып, тагын ишекле-түрле йөрергә кереште.

Нургаяз аны тынычландырырга ашыкты.

— Ә мин аны үзем, келәшчә белән колагыннан тартып...— дип, аңлатырга керешкән иде, егет аны тыңлап та тормады, кулын гына селтәде, шаярып торыр чакмы, дип әйтүе иде булса кирәк.

— Син, улым, вакытыңны юкка уздырма инде. Яшь кеше син, Яңа ел ич... Йөргән кызың да булмый калмас. Бар, кайт, югалтканнардыр үзеңне.

— Ә син, Нургаяз ага, син нишләрсең,— дип, борчуыннан арына алмый, тагы сәгатенә күз ташлап алды егет.— Яңа елга тикле ике сәгать чамасы бар әле. Әйдә, киттек авылга.

— Бар, улым, бар,— дип, булдыра алганча ягымлы итеп дәште Нургаяз.— Мин монда гына инде... Яңа ел килгәндә урманны да ялгыз калдыру килешмәс.

Егет, стена сәгатенең герен күтәреп, дөресләп җибәрде. Дәшмитынмый гына мичкә тагы берничә кисәк утын өстәде. Һәм капылт кына янәшәдә торган аркасыз урындыкка килеп утырды. Караватка таба иелә төшеп тирән сулыш алды.

— Нургаяз ага, шушыңарчы сорамый да торам икән, ни булды соң, сөйлә?! Кем атты үзеңә? Ничек алай килеп чыкты?

Чынлап та, егет аның белән ни булганын белми икән ич әле. Кара инде, күпме гомер бергә әвәрә килеп, ул хакта ләм-мим сүз чыкмаган. Нургаязның үзенә үк сәер тоелды бу.

— Сөйләсәң — сүз, төртсәң — күз, дигәндәй, булды инде. Булды...— дип кенә куйды ул, үзалдына уйлануын дәвам итеп.

— Юк, Нургаяз ага, мин белергә тиеш. Әйтегез, кем атты?— Егет тагын тирән сулыш алды һәм кыюлана төшеп башын күтәрде.— Мин белергә тиеш. Кемнең кулы күтәрелде сезгә?

— Ярар ла, ташла шуны, башка берчакны сөйләрмен.

— Юк, Нургаяз ага, хәзер үк сөйлисең. Мин чәй куеп киләм, күмер төшкәндер... Болай калдыру ярыймы соң,— дип, капылт кына урыныннан сикереп торып, өстәл өстендә утырган җиз самавырга барып тотынды. Аның һәр хәрәкәтеннән: «Әйтегез генә, кемнең кулы күтәрелде, өзгәләп атачакмын үзен»,— дигән омтылыш сизелеп тора иде. Өзгәләр дә, ике уйлап тора торганга охшамаган, әнә самавырга су салганын, кыскыч белән аның торбасына утлы күмер тутырганын гына карап тору да җитә. Нәфрәтләнүе тышка бәреп чыккан.

Егет янә урындыкка килеп утырды.

— Чәй дә өлгерер... Сөйлә, Нургаяз ага, сөйләгез...— диде ул, икеләнергә урын калдырмаслык итеп.

Каршы килер чара калмаган иде шул. Әнә ничек өзгәләнеп сорый, тыңламый буламы соң? Шуның өстенә әле «Нургаяз ага» дип олылап, ил агаларына дәшкәндәй мөрәҗәгать итә башлады. Нургаязның әле үзенә шулай дип дәшүчене очратканы юк иде моңарчы, авыл кешесе бит андый сүзләрне эзләп маташмый сиңа. Ә бу егет башка, күренеп тора, укыган һәм культуралы... Каян башлыйм икән, дигән сыман, бертын уйга калып торды Нургаяз.

— Үткән көнне кичкә таба булган хәл бу...

— Үткән көнне...— дип, гаҗәпләнүен белдереп баш чайкап куйды егет.— Шушы хәлдә тәүлектән артык монда ятасыңмы?— һәм иреннәрен турсайтып, кат-кат иңбашларын җыерып-куырып алды. «Аңлый алмыйм, ничек шул гомер кеше түзәргә мөмкин»,— дия сыман иде ул.

Баш астындагы мендәрен сыңар кул белән үзенәрәк тартып куйды Нургаяз. Һәм, хәтеренә төшерергә теләп, түшәмгә текәлгән күзләрен кыса төште. Башыннан кичкәннәр әле аның үзе өчен дә бигүк аңлашылып, ачыкланып бетмәгән сыман иде. Матур гына, ипле генә барган җирдән әнә бит ничек килеп чыкты. Кем уйлаган...

— Бүген утыз бере дисең ич... Әйе, үткән көнне,— дип, тын гына, ипле генә сөйләргә кереште Нургаяз.— Кулларымны сузып, Силингергә үреллдем. Эчеп туярлык, күреп күңелең булырлык кынамыни безнең Силингер. Беләсең ич үзең дә...

Шунда егеткә күз төшереп алды ул. Аның да Силингер хакындагы сүзләр белән килешкәнлеген, ул матурлыкны күз алдына китереп сокланып утырганлыгын тоясы килә иде. Һич булмаса, «әйе» дигән сүз ишетәсе яисә үзе белән килешеп баш кагучыны күрәсе...

Егет өчен, күрәмсең, артык әһәмиятле түгел иде бу кадәресе. Тыңлаганлыгын белгертеп: «Шуннан»,— дип кенә куйды ул. Нургаяз янә түшәмдәге үз ноктасын табып сөйләргә кереште:

— Кушуч су чумырып алып, иреннәремә китергән идем... Эчә алмадым. Эчәргә өлгермәдем. Берни аңыша алмый тордым башта — суда ят тәм бар. Силингер суы ич, ә тәме аныкы түгел. Авызга капкан суны кире чыгардым. Тамактан үтмәде. Кан тәме килә иде, җылы, кайнар кан тәме килә иде судан... Ничек итеп, бер кулга балта, икенчесенә бүрекне эләктереп алганымны һәм су агышына каршы менеп йөгергәнемне сизми дә калдым.

Күңел дигәнең сизгер ич ул. Ниндидер хәвеф, бәла-каза булуын әллә каян сизеп торам. Гел юктан, бөтен гәүдәне җилтерәткәндәй, йөрәк дөп-дөп кагарга кереште. Тирән кар ерып, һаман ашыгуым, кабалануымны беләм. Башы да эшләп житкерми бит — аның шундый чакта: өйгә сугылып, ау чаңгысын элеп кенә килергә булган да бит. Атлаган саен бил тиңентен карга бата-чума баруның ни икәнен беләсең... Җитмәсә, гомер булмаган хәл — сулышны кыса башлады. Тик шунысы гаҗәп: Силингернең ни аргы ягында, ни биргесендә кеше түгел, куян эзе дә күренми. Соңгы борылышка да менеп життем — ул-бу күренми, ишетелми кебек. Тынычланып киткәндәй булдым: әллә соң дим, ялгыштыммы, тоелды гына микән әллә дим? Шулай була күрсә

икән, дим. Ә ireннән һаман әле теге кан тәме китми йөдәтә. Күңел барыбер тынычланмас, чишмәнең чыккан җиренә үк барып килми ярамас дип, йөзьяшәр наратка төбәп киттем...

Туктап торды Нургаяз, бер тын хәл алды. Мич каршындагы калай өстендә пар бөркеп утырган самавырга күз салып, кибешкән ирennәрен тел очы белән чылатып куйды. Әмма бер ноктага текәлеп утырган егет моны абайламады. Ул онытылып тыңлый иде.

— Чишмәнең кайнап бәреп торган урынына җитәр-җитмәс туктап калдым, аяклар атламас булып торды бертын. Күзләремә ышанырга-ышанмаска белмим: уязлыкта поши бозавы ята. Әле суынырга да өлгермәгән, бичара, өстенә сибелгән кар эреп, шуннан җылы пар бөркелеп тора. Бозауның башы Силингергә үк авып төшкән. Ак кар өстенә сузылып ятып, чишмәдән су чөмереп тора икән диярсең, борын очы хәтта су читенә тиеп үк тора...— Күңеле нечкәрүдәнме, ул сөйләвеннән тукталып алды. Күзләрен яшерергә теләп, башын стенага табан борды, борынын тартып алды. Бугазында пешкәк сыман арлы-бирле йөгерергә тотынган төерне юрган белән капларга итте. Әмма тел очында буылып торган сүзләрен тыеп кала алмады.— Канатлары каерып ташланган кыр казы инде менә, нәкъ кыр казы. Атып екканнар да чалып ук киткәннәр. Ап-ак карның көпшәк бәгырен телеп, ерганак булып аккан аның каны. Силингергә аккан. Чишмә ничек түзде икән? Чишмә, Силингер!...

Мичкә ташланган соңгы утыннар янып күмергә әйләнде булса кирәк, стенага төшеп торган ялкын телләре уйнаудан туктаган иде инде. Сүрелә барган күмернең алсу-кызыл шәүләсе алыштырган иде инде аны. Ә самавыр һаман шаулап кайнап утыра. Мине онытттыгыз дигәндәй, шылтыр-шылтыр килеп, капкачның ике ягында пар чыгу өчен куелган нәни түбәтәйләр байтактан сикерешә иде. Әмма мич тә, самавыр да онытылган иде инде, искә алучы булмады үзләрен.

— Шуннан? — дип сабырсызланып куйды егет, мин алга таба тыңларга әзер дигән сыман. Бу тарихны тизрәк тулысы белән күз алдына китерәсе килә, шуңа сөйләүченең туктап-туктап торуы ошап бетми кебек иде аңарга.— Шуннан ни булды, Нургаяз ага?

— Кулымнан икмәк кисәкләре ашап үскән бозау иде ич ул. Кешегә тәмам ияләшеп беткән иде. Сузылган кулны күрсә, әнисен әллә кайда калдырып, башын чайкый-чайкый чабып килә торган иде яныма. Шул, кешеләрдән курыкмавы житкән дә инде бичараның башына... Су эчү өчен Силингергә төшүләре булган. Сусауларын бары тик шунда гына баса торганнар иде. Менә бит ничек, язмыш юк диген син. Җаны да Силингердә сүнеп, Силингергә аккан...

— Шуннан, Нургаяз ага, шуннан?

Егетнең кабалануы урманчыны сискәндереп үк җибәрде бу юлы. Сабырлыгын җуеп, вакыйгаларның алга таба ничек дәвам иткәнлеген ишетергә ашыга иде ул. «Яшьләр шул, аларга синең поши бозавың ни дә, Силингерең ни — әллә бар, әллә юк,— дип уйлап куйды Нургаяз, кәефе кырылып.— Артыграк балавыз сыга башлады бугай, чынлап та. Сөйләргә кирәк, вакыйгалардан читләшми генә сөйләргә».

— Әнисе белән булганнар. Поши баласын әйтәм. Башка чара калмагач, ана поши качкан. Анысына да атып караганнар, күрәмсең, тидерә алмаганнар. Шуңа бозау өстенә аннан-моннан гына кар сибеп, анасын куа киткәннәр. Ит күп кирәк булган инде, бер бозау гына аз тоелган. Чаңгы эзләре ярылып ята, икәү булганнар. Ә мылтыклары берәү генә булырга охшый. Тәҗрибә яклары да, браконьерларныкын әйтәм, чамалы булган. Чөнки гильзаларын да җыя белмәгәннәр. Бозауны алырга килгәч җыештырырга булганнардыр. Әнә, кесәдә яталар, уналтылы. Андый мылтык бу тирәдә ике-өч кенә кешедә.

— Ә бәлки,— дип, кабаланып сүзне бүлдерде егет,— безнең якныкы булмагандыр алар. Шәһәрнекеләр дә өзелеп тормый. Сиңа да атканнар әнә. Авыл кешесе алай итмәс иде...

— Безнекеләр,— диде Нургаяз, икеләнергә урын калдырмаслык итеп.— Бар хикмәт тә шунда шул, безнекеләр! Шәһәр тикле шәһәрдән ике кешегә бер мылтык тотып килмиләр. Ә тагы...— дип мәгънәле генә тукталып алды ул.

— Тагы нәрсә?

— Гильзага тутырылган кәгазь кисәкләре калган. Татарча гәжит... Үзебезнең районныкы.

— Районы да зур шул әле аның,— дип көрсенеп куйды егет, гаепләләрне табу җиңел генә түгел икән әле дигәндәй.

— Бүрсетнекеләр. Үзебезнең авыл. Аякларындагы чаңгыларның берсе үзем ясаган өрәңге чаңгы. Бер күрүдән танып алдым, үз кулым ич.

— Ә-ә,— дип сузып куйды егет. Урманчы аңар икеләнер урын калдырмаган иде шул. Һәм шундук, гаҗәпсенүенең көйсезрәк чыгуыннан уңайсызланып, шаяртып та алды үзе.— Син теге Шерлок Холмстан да болайрак икәнсең бит, Нургаяз абый.

— Анысын күргәнем юк, белмим,— дип сөйләвен дәвам итте Нургаяз.— Тик минә чаңгыда була торып та, пошины куып житә алмаганнар. Күкрәк белән шуып барса барган тирән кар өстеннән, әмма тоттырмаган тегеләргә. Чытырманлыкларга кереп ураган-ураган да, үзләрен тәмам адаштырып качкан.

Артларыннан барып тотарга иде дә үзләрен, аякта чаңгы булмавы гына минә... Мин аргы якка чыгып тормадым, бата-чума кайтырга чыктым. Кары да бит аның быел, җәяү йөрерлек кенәмени. Умарталык аланына җиткәндә, тәмам хәлдән тайган идем инде. Анда минем кышка әзерләнгән печән кибәннәре тора. Пошиларның яраткан җире иде. Кайры кимереп кенә бармый бит эш, шунда килеп, алар печәннән авыз итә, төннәрен кибән ышыгына ятып ял итә торганнар иде. Бераз хәл алыйм дип, кибән читенә чүгәләвем генә булды, ишетәм: кемдер еш-еш сулап якынлашып килә. Торып басарга өлгермәдем, агачлар артыннан чабулап поши килеп чыкты. Мине күргәч тә иң элек, сискәнеп, башын борды. Әмма кире борылып чапмады, таныды. Һәм, гомер булмаган хәл: иплә генә адымнар белән яныма ук килеп басты. Әйтәм ич, бозавы ияләшсә дә, үзе сагая, читләбрәк йөри иде ул минем тирәдән. Ә бу юлы әнә ничек... Икәүдән-икәү генә печән кибәннәре арасындагы ышыкта торып калдык. Үзе манма тиргә баткан, тәненнән кайнар пар бөркелә. Түшенә һәм муеннарына, шөлдер сыман булып, исәпсез-хисапсыз боз кисәкләре ябышкан. Борын тишекләре галәмәт олы булып киерелгән, сулыш алган саен, самавыр диярсең, ике багана булып пар бәреп чыга үзләреннән. Кешегә сөйләсәң, кеше ышанмас минә, бер заман күзләрен текәде бу миңа. Ә алардан, мөлдерәп-мөлдерәп, кайнар тамчылар тәгәрәшә. Күз читләреннән сыгылып чыгалар да ике як яңагы буйлап түбән йөгерешәләр. Аналар елаганын күргәнең бар микән?.. Һич аермасы юк инде минә, нарасыен югалткан аналар гына шулай елый. Син күзләрен, күзләрен генә күрсәң иде аның... Беләсеңме, күпме сагыш, күпме хәсрәт сыйган иде ул күзләргә?!

Күңеле тулышып, бер тын сөйләвеннән туктап торды урманчы. Әмма бу юлы күзләрен яшермәде, сабырлыгын җыеп булса да түзде. Күңелендәге нәфрәт хисләрен генә яшерә алмады, кысылган иреннәр, йомарланган кул һәм карашына бәреп чыккан кырыслыкны яшерү җиңелмени?!

Егет дәшмәде. Ашыктырмады да. Үзенең тыңлап бетерергә әзер булуын белгертеп, тик утырды. Өй эчендә сәгать теленең әрле-бирле йөргән авазы гына ишетелеп торды. Каршы як стенага төшкән утлы күмер шәүләләре дә, сүрәнләнә барып, юкка чыккан иде инде. Самавырның да гайрәте басылган. Матчадагы кадакка эленгән керосин лампасы гына әледән-әле куык эчендә мелт-мелт итеп җан биреп ала.

— Иңне-иңгә терәп, поши белән тагы күпме шулай янәшә басып

торылгандыр, белмим. Көтмәгәндә, ул нидәндер сискәнеп, кинәт тартылып куйды. Аның тәненнән электр тогы сыман йөгереп узган калтырану миңа да күчте. Тынгысызланып, кузгала башлады ана поши. Ә мин, аерылышырга һәм аны шул хәлендә җибәрергә теләмичә, муенына кулым салган көе пошига иярдем. Ул да түгел, кибән ышыгыннан чыгып килгән җирдән, күз иярмәс тизлек белән башын югары чөйде поши, арт аякларына чүгә төшеп кире чигенде. Ә мин аны-моны уйларга, хәл кылырга өлгерә алмадым... Колак төбендәге шартлау авазы... Ут көлтәсе... һәм иңбашым... Башка берни хәтерләмим.

Нургаяз сөйләүдән туктады. Егет тә дәшмәде, ни дияргә белми утыруында булды.

— Менә шул,— дип куйды Нургаяз, сөйләвен тәмамлаганны белгертеп.

Бер тын тагы дәшүче булмады. Бу юлы инде тынлыкны егет бүлдерде.

— Башка берни дә хәтерләмисеңме? — дип сорап куйды ул капылт кына.

— Юк, хәтерләмим.

— Кем атканын танымадыңмы?

— Кая танийсың... Ул хәлдә.

— Берни ишетмәдең дәме?

Нургаяз, гаҗәпсенеп, егеткә текәлде. Барысы да ачык, аңлашыла ич инде. Нигә дип төпченергә тагы? Нинди сүзләр, нәрсә ишетергә тиеш иде соң ул? Дәшер сүз тапмыйча, башын гына чайкап куйды ул.

Бер урында хәрәкәтсез утырудан егет йончыган иде, күрәмсең, тирән сулыш алып, урыныннан торды. Барып, мич капкачын ачты һәм кулына кисәү агачы алып, күмерләрен актаргалады.

— Мичне ябам,— диде ул ипле генә,— күмерләре сүрелә дә башлаган инде.

Үрелеп бер-бер артлы ике юшкәне дә япкач, самавырны өстәл өстенә китереп куйды. Чәйнеккә су агызып, аны самавыр түбәсенә утыртты.

— Хәзер, Нургаяз ага, чәй эчеп җибәрәбез,— диде егет, үзенең тәвәккәл хәрәкәтләре белән өйгә җан кертергә омтылгандай, тавышын күтәрә төшеп.— Аннары авылга. Туп-туры врач өенә алып барам үзеңне... Балың бардыр ич. Нургаяз ага, алып керимме?

Егеткә җавап кайтаручы булмады. Ул тиз генә карават янына борылып килде. Урманчы йокыга талган иде инде.

Әллә йоклады, әллә саташып кына ятты Нургаяз. Әллә төш күрде, әллә каядыр баш миенең ерактагы бер күзәнәгенә кереп калган өндәге сүзләрне хәтерләде:

Ул йомшак кар-түшәк өстенә егылган, имеш... Аңлы-аңсыз изрәп ята. Колак төбендә кемнәрнеңдер сөйләшкән авазлары.

— Кеше-кара күренмиме? — ди бер тавыш.

— Әлегә юк, күренми,— ди икенчесе.

— Табанны вакытында ялтыраткан хәерле... Ал мылтыгыңны, элдертик.

— Син нәрсә?! Ә ул, аны нишләтәбез?

— Әйдә диләр сиңа, тизрәк!

— Ничек була инде... Ничек тизрәк?..

— Акылыңа кил, аңа ярдәм итеп буламы-юкмы хәзер. Урман карачкысы өчен төрмәдә черисең киләме? Әйдә, диләр!

— Син нәрсә?!

— Үзеңә кара... Мин атмадым, мин җавап бирәсе түгел,— дип, китәргә димләгәне, күрәмсең, кузгала ук башлаган иде булса кирәк.

— Син нәрсә? Син нәрсә! Ярасын булса да бәйлик, күрмисеңме...

— Күзең чыкмагандыр, сул якка тигән. Анда ни барын беләсеңдер?!

— Син нәрсә?!

— «Син нәрсә, син нәрсә?» имеш... Нәрсә бозык пластинка төсле сөйләнәсең... Табанны ялтыратыйк, ычкындык, дим!

Чаңгы табаннарының карга ышкылып аваз бирүе колакка керде. Бераздан, ераклаша барып, алары да ишетелмәс булды.

Төш булмады бу. Юк, төш түгел! Ул ярым уяу, йоклый алмый саташып ята икән ич ул. Чигә төбендәге аваз — чаңгы табаннарыннан түгел, башы авырта, башы шулай чыңлый-сызгыра икән аның.

— Менә уяндың да, Нургаяз ага, мин чәй әзерләдем,— дип елмаеп, балкып дәште аңар егет.— Запаслы яшисең икән ич, син, мин монда әллә нәрсәләр таптым әле.

Рәхим итәсез, дигәнне аңлатып, ул өстәлгә ымлады. Келәттән алып керелгән бал-май, киптерелгән урман сыйлары, төрле тәм-том белән тулган иде өстәл өсте.

— Булдыргансың, егет икәнсең,— дип, аңарга кушылып елмаерга итте урманчы да.

— Яңа ел житеп килә, Нургаяз ага, торасыңмы соң, шунда гына китеримме?..

— Кирәкми, торам. Торырга кирәк! Яңа ел ич аны урын өстендә каршы алу әйбәт булмас...

Кипкән жиләк, мәтрүшкә һәм бөтнек салып пешерелгән чәй эчтеләр алар. Маңгайларына тир бәреп чыкты, бит очларына алсулык йөгерде. Өйгә дә жылы төшкән иде инде. Егет, свитерын салып, урындык артына элде. Нургаяз да изүләрен ачып жибәрде. Жиңелрәк булып киткән иде аларның һәр икесенә, шулай да әле эчке киеренкелек тә таралып бетмәгән. Талгын тынлык урнашып алды. Ләкин бу юлы ул озакка сузылмады. Алар икесе берьюлы кинәт сискәнеп куйдылар: баш очларындагы сәгатьнең күкесе, тәрәзеннән башын тыгып, кычкырырга керешкән иде. Башларын күтәреп карарга кыймый тордылар, югалып калдылар алар бер мизгелгә. Күке тавышын санадылар... Ун. Унбер... Унике! Нургаязның хәтта кулындагы чынаягы төшеп китә язды.

— Унике дә тулган,— диде ул, дулкынлануын һәм жиңелчә калтырануын яшерә алмыйча.

— Яңа ел белән! — дип, аягүрә торып басты егет. Һәм житез генә ишек чатына барып, тун кесәсеннән ялт кына бер ярты тартып чыгарды.— Минем монда бер акбашлы егетем дә бар иде,— дип, өстәлгә дә китереп утыртты ул аны. Аннан, тиз генә бөкесен ачып, ике стаканга койды.

— Ул нәрсә белән дуслык юк, кирәкми,— дип, стакан белән үзе арасына кулын аркылы куйды урманчы.— Мин чәй белән генә... Әйдә, котлы булсын Яңа ел!

Бәйрәм хөрмәтенә тагы тынлык урнашып алды. Теләсә-теләмәсәләр дә һәр икесе елмайгандай иттеләр, бер-берененең күңелләрен күтәрделәр.

— Шампанский булмады шул... Кем белгән бит аны,— дип үзенең уңайсызлануын белгертеп алды егет.— Әллә дим, Нургаяз ага, тәвәккәллибезме соң, Яңа ел хөрмәтенә дим.

— Шампанские дә, шайтанские дә кирәкми. Аллага шөкер! — диде урманчы артык кысташуга урын калдырмаслык итеп.

— Син нәрсә?! Ничек була инде бу, Нургаяз ага? — дип, кулындагы кырлы стаканны күтәрергә-күтәрмәскә белми тартынып торды егет.

— Миңа, әнә, куе итеп тагын берне ясап бирсәң, шул бик житкән.

— Син нәрсә? Урманчы ич син, Нургаяз ага... Монда, саф һавада, бер стаканнан гына ни булсын. Авыртуларың да басылып китәр иде.

Егетнең әле рәхәтләнеп кыстарга иде исәбе. Әмма, Нургаяз уйламаган-көтмәгән жирдән кызып китте, күңелендәгеен турыдан әйтеп салды.

— Урманчы...— диде ул, иреннәрен турсайта төшеп.— Урманчыны

кем дип беләсез соң сез?! Агач төбе саен аракы эчеп, пошн ите белән авыз итеп, умарталык аланында бот күтәреп эшсез ятучы дипме? Акланма, шулай уйлыйсыз. Урман сезгә нәрсә? Байлык — и все! Урман — бүрәнә. Урман — утын. Урман — печән. Урман — җиләк-җимеш... И все, тегесе-монысы дигәндәй... Туктатма да, акланма да, әйтә башлагач, бетерим. Синә димим, күпләр шулай уйлаганын беләм. Чыдасын, өлгерсен генә урман, барысы да алырга менә. Бирергә түгел! Инде менә хәзер ит кирәк булган. Малны да асрап торасы юк икән, менден дә атып төштең. И все! Бер кышлык ит! Әнә ич, ничек җиңел икән... Ата-бабаның шуңа башы җитмәгән. Яшьләр акыллы хәзер, акыллы яшьләр үсеп җитте...

— Тукта әле, Нургаяз ага. Син нәрсә?! — дип, бүлдерергә күптән җай көтеп торган егет кушылды сүзгә.— Юкка кызасың. Әйдә, тынычланыйк. Төрле кеше бардыр. Яшьләр арасында да төрлесе бар. Нигә дип әле, менә хәзер һәм миңа әйтәсең син боларның барысын?

Нургаязның дулкынлануы йөзенә чыкты. Ачык изүеннән күренеп торган муенында хәтта тимгел-тимгел кызыл таплар пәйда булды аның. Ләкин ул үзенең шулай вакытсызрак кызып китүен, эченә җыелып килгәннәрне бер селтәнүдә чыгарырга керешкәнлеген дә сиземмәмәде түгел. Тынычланырга теләүдән, теләр-теләмәс булса да иреннәренә чәй китерде ул. Шулай да ярты юлда өзелеп калган фикерен тәмамламый калмады.

— Ә беләсеңме син,— дип дәвам итте ул, иппе һәм әчкерсез сөйләшүгә күчеп.— Иң авыр елларда, ашарга ризык булмаган чакларда да урманга мылтык күтәреп йөрмәде халык. Кычыткан ашады, черек бәрәңге күмәче пешерде, бөре җыйды. Әмма пошиларга кул сузмады.


Яңа ел хөрмәтенә дип, кулында күпме гомер тотып торган стаканны нишләтергә белми, икеләнеп калды егет. Шулай да, тәвәккәллеге житмәде ахры, ялгызың ничек эчеп утырырга кирәк дигәндәй, бераздан аны читкә үк этеп куйды.

— Шулай дисең инде, Нургаяз ага...— дип сузды ул, тел очына килгән соравын ничек һәм ни рәвешле бирергә белми аптыраган кеше сыман.— Ярар, куеп торыйк, әйдә, сөйлә әле... Соңыннан ничек булды соң, соңыннан? Умарталык яныннан ничек кайттың? Кем алып кайтты үзеңне?

— Минем Юлдашым бар ич, Юлдаш исемле этем.— Гел уйламаган җирдән шунда күңеле нечкәреп алды урманчының, җылы хатирәләргә бирелүдән күзләренә якты нур йөгерде.— Ярсып эт өргән тавышка, колак төбемдә этнең кайнар сулышын тоюдан аңга килгәнмен. Бәйдә тотмыйм ич мин аны, үзе эзләп тапкан. Тирә-ягымны таптап такырайтып бетергән иде инде. Якадан өстерәп, өйгә алып кайтырга азапланган, әнә, телогрейканың карарлыгын калдырмаган, чәйнәп ташлаган кебек.— Этенең шул кыланышларын күз алына китереп, ул ирексездән горурлану катыш елмаеп ук җибәрде.— Өйгә кайтып җиткәнче, бер адым читкә тайпылмады үземнән. Каза килгәнен каян белгән диген, менә бит хикмәт. Эт кенә диген син аны шуннан соң. Кешеләр калдырып киткән, ә эт өйгә таба өстерәпме өстерәп маташа. Гаҗәпләнерсең дә...

— Бәлки, ул кешеләр сине күрмәгәндер?.. Пошига тидерә алмагач, шуны куа киткәннәрдер тагы. Сиңа дип атмаганнар ич инде,— дип урманчының кешеләргә булган ышанычын якларга керешә егет бер үҗәтлек белән.

— Бәлки, шулайдыр,— дип, үзенең карышмавын белгертте урманчы.— Бәлки... Шулай да мин бит үзем дә мылтык тоткан кеше әле... Нинди генә игътибарсыз, мәнсез кеше дә аткан ядрәсенең кая барып тиюенә битараф булмый, кызыксына. Бушка очырса да, кайсы якка каерган дип, агачлардан ядрә эзе эзләп йөрисең әле аны. Фашист



А. Тимергалина рәсеме.

солдаты түгел ич, алар гына автоматны кендеккә кадәр төшереп, арлы-бирле атып йөрделәр.

Дөнья күргән кешенең сүзләреннән гыйбрәт алып, баш кагып тыңлады егет.

— Әйбәт булмаган, билгеле... Шулай ташлап китүләрен әйтәм, әйбәт булмаган.

— Гомер кичеп, кешегә зыян китергәнем булмады дисәм дә ялган булмас. Үземне дә хөрмәт итәләр кебек иде.

— Шулаен шулайдыр да, әнә ич, ташлап киткәннәр дисең...

— Китүен киткәннәр... Ташлап китеп, җаннары тынычлангандыр дисеңме әллә?

— Ярый да бит эт килеп коткарган. Кар өстендә өшеп тә үләргә мөмкин.

— Миңа — урман карачкысына — ни булсын соң,— дип шаяруга бормакчы иде Нургаяз. Тик шундук ул ниятеннән кире кайтты, шаярырлык идемени соң аның хәле?

— Син нәрсә?! — дип, аны егет тә урынлы кисәтеп алды.

— Дөнья бу, улым. Ә дөньяда кылган игелек югалмый. Эт булмаса, шул ук поши булса да кире әйләнеп килгән булыр иде. Ничек итсә итәр, өшеп үләргә ирек бирмәс иде. Кабан дуңгызы, бүре булса да... Табигатьнең тәртибе шундый аның, үзенә игелек кылганны бер җанвар да онытмый. Иң кыргый һәм ерткыч дигәннәре дә.

— Кеше дә табигатьтән ич, әнә, ташлап киткәннәр дисең?

— Кешеләр...— дип, уйланып калды Нургаяз.— Кем белә, ә бәлки кеше исемен күтәрерлекләре булмагандыр. Ни аллага, ни муллага дигәндәй, азмыни...

— Барыбер кешеләр ич инде.

— Ә беләсеңме, никадәрле генә каты бәгырьле булмасын, андыйларның да кешелеге уяна ул бер. Бәлки, аларны әйтәм, үзләре үк кире әйләнеп кайткан булырлар иде әле. Бәладә калдырмаган булырлар иде ялгыз урман карачкысын.

Егет кинәт сискәнеп үк куйды. Нургаязның үзе турында шулай сөйләшүенә риза түгел иде булса кирәк.

— Нургаяз ага, әйтмә әле шул «урман карачкысы» дигәнне. Хет син әйтмә,— дип, беренче тапкыр тавышын күтәрде егет.

— Нәрсә булган, урман карачкысы дисеннәр соң, ни гаебе бар?!

Һәм үзе дә көтмәгәндә, аның күңеленә күптән булып узган, онытылган хатирәләр килде. Олы улы чыгарган кушамат ич ул. Сабый чакта «Әтиең кем?» — дип сораган кешегә, «урман каравылчысы» диясе урынга «урман карачкысы» дип җавап биреп, килгән-киткән кунакларны шул көлдерә торган иде. Шуннан тагылып калган кушамат. Бу кушаматы белән аңар гомер буе үз итеп, яратып кына дәштеләр.

Аңлашылды дигәнне аңлатып баш кагып алгач, өзелеп торган әңгәмәне тагы егет дәвам итте.

— Кайтмаганнар... Ташлап калдырганнар, әнә.

— Исләренә төшәр әле бер, барыбер.

— Төшсә ярый да... Уйланмыйча гына яшәүчеләр дә җиткән.

— Уйланмыйча яшәү... Яшәмичә уйлау... Белмим, буламы икән?!

Бу хакта сөйләшәсе дә килми иде урманчының.

— Кая әле, бераз хәл алыйм булмаса,— дип, өстәл артыннан иплә генә торды да, караваты өстенә барып ауды Нургаяз. Йончыганлыгы йөзенә чыккан иде аның. Шулай да сүзне үзе дәвам итте ул: — Ә бит минем үземнең дә абзарда атым бар. Чыгып, сарай капкасын ачсам, янәшәмә үзе килеп басачак. Нинди генә хәлдә дә исән-аман авылга алып төшәчәк.

Бу ни әйтергә тели тагы дигәндәй, кинәт борылып карады егет.

— Мин алай итмәдем,— диде урманчы, эчке бер канәгатьлек кичереп.

— Ә нигә?

— Төшсәң, врачка барырга кирәк. Врач милиция чакыртачак. Китә шуннан, китә әйләнеп... Минем аркада кемнеңдер өтермәгә барып керүен теләмим. Аның бит әле ата-анасы, туган-тумачасы да бар дигәндәй, беләсеңме, күпме кешенең тынычлыгы качачак?!

— Үзеңә аткан кешенеме... Шуны кызганасыңмы? — дип гаҗәпсенде, аңлый алмады егет.

— Миңа атканмы, пошигамы?.. Пошиның бозавын чалып киткәннәрме? Хикмәт андамыни? Барысы да бер үк кыргыйлык ич!

— Ә син шуларны кызгандым дисең?

— Кыргыйлыкларын түгел, кешелекләрен кызгандым. Кеше ич...

— Юк, Нургаяз ага, булмый болай,— дип сикереп торды егет.— Хәзер үк авылга! Врачка күрсәтергә кирәк үзеңне. Әйдә, киендерәм дә...

Икеләнер урын калдырмаска тырышып, ул урманчыга киемнәр хәстәрләргә үк кереште, гел урынсызга каударланды, өй буенча арлыбирле йөренә башлады.

— Син нәрсә?! Анда ниндидер подонокларны кызганам дип...

— Тукта, ашыкма әле, энем.

— Юк-юк, сөйләмисең дә, тыңламыйм да. Син нәрсә, Нургаяз ага?! Күпме кан югалткансың... Шуның өстенә тәнеңдә чыпчык башы кадәрле ядрә йөртергәме? Юк, ике уйлап торды юк! Хәзер үк авылга. Шаяра торган вакытмыни?! Син нәрсә!

— Ашыкма әле син, тукта, утыр әле килеп менә монда,— дип урманчы үзе белән янәшәдә урын күрсәтте егеткә. Һәм булдыра алган кадәр тыныч итеп янә аңлатырга кереште: — Әйттем ич инде, анда төшсәк, врач дидем. Врачтан милициягә... Ә бит кеше кадәр кешегә аткан өчен берәүнең дә башыннан сыйпамаслар.

— Кулсыз каласың киләме? — дип сорап куйды егет, бераз басыла төшеп.

«Кургаш кисәгенең алынганлыгы хакында әйтергәме икән әллә?» — дип, икеләнеп калды шунда Нургаяз. Тәвәккәл егет, моннан ансыз котылу мөмкин булырмы... Шулай да, ниндидер эчке бер тойгы аңарга бераз сабыр итәргә киңәш итте.

— Кем, Марсель диден бит әле... Бераз хәл алыйк башта, ашыкмыйк. Мондый чакта алдын-артын уйламый эш итми ярамас. Бәлки әле үзләре дә менеп җитәр, гафу сорарлар. Табигать каршындагы корткычлыкларын танып, бише белән кайтарырга вәгъдә бирерләр... Ашыкмыйк, бераз сабыр итик.

— Син нәрсә?! Кешеме соң син, әллә?.. Үз гомерең кыл өстендә торганда, шундый нәрсәләр турында уйлыйлармы,— дип, ни әйтергә белмичә, уч төпләре белән чигәләрен кысты егет. Бераздан йодрыкланган куллары белән тез өсләренә китереп сукты, иреннәрен чәйнәде.

— Кеше булмый, кем булыйм соң? — дип көлемсерәп куйды урманчы.— Гади бер карт, әйттем ич, урман карачкысы...

— Булды, Нургаяз ага, шаярып утырыр ара юк. Җитәр! Болай да соң булмагае,— дип урыныннан сикереп торды егет.— Нәрсәләр киясең, кая, ниләр китерим?

...Киенеп, ишегалдына чыктылар. Чиный-чиный, койрыгын болгап, каршыларына Юлдаш чабып килде. Урманчының әле бер, әле икенче ягына чыгып сырпаланырга кереште, теле белән аның кулларын яларга итенде.

— Себерә башлаган ахры,— диде Нургаяз, өй кыегының чит-читләреннән як-якка аккош канаты сыман сибелеп торган кар тузаннарына игътибар итеп.

— Зыянлы түгел... Юл ачылган, ат шәп минем,— дип, күн белән тышланган тире бияләйләрен киеп, бер-беренә суккалап куйды егет.

Капканы ачып тышка чыктылар. Хуҗасы артыннан чыгарга омтылган этнең борын төбендә генә шапылдап ябылды капка. Кешеләр күренүгә куангандай, җигүле килеш ни гомер капка төбендә торган ат, авызлык тимерләрен шалтыратып, башын чайкап алды.

— Әйдә, чана түреннән урнаш, Нургаяз ага,— диде егет, капка тимеренә бәйләнгән дилбегәне чишәргә керешеп.— Толыпка төренеп утырырсың, толып яңа.

Күкрәк киереп сулыш алды Нургаяз. Урман һавасы, ылыс һәм кар исе сулыш юлларын кытыклап үтте. Баш очында зәңгәр караңгылыкка барып тоташкан наратлар шавы эленеп тора. Бары тик төннәрен һәм Силингер урманында гына ишетергә мөмкин булган киң сулышлы, шом катыш бәйсезлек авазы бу. Шул шау эчендә, зур оркестр уйнаганда әледән-әле сизелер-сизелмәс кенә тоемланып күңелнең нечкә кылларына кагылып узган скрипка сыман, чишмә челтерәве ишетелеп-ишетелеп ала. Әнә ич, нинди мәһабәт табигать кочагында, нинди урманда яши ул! Үзеннең шул урманга кирәклегеңне аңлауга ни җитә...

— Нургаяз ага,— дип дәште егет, аны уйларыннан бүлеп. Кузгалабызмы инде, дигәнне аңлатырга теләде булса кирәк. Атын күптән кайтыр юлга борып куйган иде инде ул.

— Мин төшеп тормам инде,— диде урманчы тыныч кына. Һәм бөтенләй көтмәгәндә, кесәсеннән кунак малайга бер уч чикләвек чыгарып биргәндәй, гильзаларны алып егеткә сузды.— Мә, үзенә булсын. Ал...

Кулыннан дилбегә төшеп китте егетнең. Дәшәргә сүз, кымшанырга җай таба алмый торган җирендә катып калды ул. Шулай да гильзаларны алмый булдыра алмады.

— Ә кулың, андагы кургаш кисәге? — дип дәшәргә көч тапты ул, күзләрен зур ачып бер тын текәлеп торганнан соң.

— Мә, кирәге чыгар, ал анысын да.

Икенче кесәсеннән тартып чыгарган кургаш кисәген дә егеткә тоттыргач, безнең сөйләшер сүз бетте дигәндәй, кырт борылып, Силингергә илтүче сукмак буйлап ипле генә атлап китте урманчы. Бүтәнчә кире борылмады.

Тынлык урнашты. Байтакка сузылды бугай ул тынлык. Ә бераздан бөтен тирә-юньне ачынып кычкырган аваз сискәндереп җибәрде:

— Ә миңа, миңа нәрсә була соң?.. Миңа ничек яшәргә?..

*Казан*
*Январь-февраль, 1986*



*Шамил Маннапов шигъриятебезгә алтмышынчы еллар башында солдат хезмәтен, яшьлек омтылышларын, студентлар тормышын чагылдырган шигырьләре белән килеп керде. Туган җир, туган туфрак, әниләр һәм тынычлыкны яклаучы гади кешеләр турында язды ул. Халыкта матур яңгыраш алган «Солдатта булган диләр», «Керфегеңә тамармын мин», «Рәхмәт сиңа» кебек җырлар да шагыйрьнең төп иҗат юнәлешеннән аерылгысыз иде.*

*1979 елдан СССР Язучылар союзы әгъзасы, КПСС члены Шамил Мәгъйзъ улы Маннапов 1938 елның 1 январенда Татарстан АССРның Әлки районы Татар Мулла авылында туган. 1957 елда Алпар урта мәктәбен тәмамлагач, туган авылында эшли, аннары Совет Армиясендә хезмәт итә. 1960—1965 елларда В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Университеттан соң «Татарстан яшьләре» газетасында әдәби хезмәткәр, пропаганда бүлеге мөдире, аннары, 1977 елда Горький шәһәрендәге ике еллык югары партия мәктәбен тәмамлагач, «Социалистик Татарстан» газетасында әдәбият-сәнгать бүлегендә өлкән корреспондент булып эшли. Хәзерге көндә ул — Татарстан китап нәшриятының политик әдәбият редакциясендә редактор.*

*Ш. Маннапов шигырьләре башта көндәлек матбугатта басыла; 1967 елда исә «Беренче карлыгачлар» сериясендә «Яшьтәшләрем» исемле беренче җыентыгы дөнья күрә. Хәзер ул алты шигырь җыентыгы һәм «Әти урманы» исемле проза китабы авторы. 1982 елда Мәскәүдә «Современник» нәшриятында шагыйрьнең «Возвращение» исемле русча китабы дөнья күрде. Ш. Маннапов шулай ук әдәби тәнкыйть, публицистика һәм тәрҗемә өлкәсендә дә эшли.*

*Илле яшен шагыйрь яңа шигырьләр язып каршылай.*

# Шамил Маннапов

## ҖИРГӘ СЫЕНАМ

Ник яшәргә кыен, димсең, миңа,
Тормышлар мул, тыныч заманда? —
Ышанычым кими бара сыман
Тыныч буласына һаман да:
«Тынычлык!» — дип оран сала дөнья,
Ә кораллар һаман күбрәк итеп,
Дәһшәтлерәк итеп ясала.
Иртән Кояш имин чыгармы?! — дип,
Борчу ала кичтән ятканда.

Нигә кайберәүләр карый әле
Каеру ягын үзенә күбрәкне?
Ничек карыйм күзенә намусымның —
«Ышаныч!..» — дип типкән йөрәкнең?!

Таш арты таш кителә сыман һәркөн
Ышаныч атлы гүзәл кыядан.
Йомшакларны тормыш суы юа,
Каты хисләр кала хыялга.
Бер-берең изгелекләр кылу
Борынгыдан калган лабаса...
Аһ, ышанмау!
Син яхшылык итсәң —
«Нигә?..» — дигән сорау алмашка.
Җаның кебек күргән газиз кешең
Яра ясый синең җаныңа!
Җир имин дә әлегә,
Тик йөрәкләр,
Тик йөрәкләр менә ярыла.
«Кинәт үлде!..» — дигән хәтәр хәбәр
Ишетелә бик еш эфирдан.
Сизәм: кыен — мине гөл итәр, дип,
Кешене бар иткән бу Җиргә.
Мин Җир белән бергә борчыламын,
Җир — зур, Җир — нык, беләм...
Ә йөрәк? —
Ул нибары йодрык кадәр генә,
Курку ала аны көчлерәк.
Җир үзе дә кайнар хисләр тулы
Йөрәк шикеллерәк — Галәмдә.
Җиргә «инфаркт булмый» икән, димәк,
Таяныч бар әле адәмгә.
Җир таяныч эзли Кешесеннән,—
Тудыргандыр аны шуңарга.—
Карап баккан аны миллион еллар...
Адәм кимсеткәндә
Кыен аңа, кыен чыдарга.

Мин йөрәгем белән Җиргә сыенам,
Китмәсен, дим кинәт ярылып.
Вулкан-хисләр тулы Җир-йөрәктә
Әле ышаныч, ныклык бар кебек...

## Кара йорт сагышы

монолог

*Петрищево авылында партизан кыз Зоя Космодемьянскаядан сорау алган өй саклана. Ул тоташ кара төстә.*

«Мине салган оста әйткән иде:
— Иң матур өй булыр авылыгызда!
Ни өчен соң күпме елдан бирле
Кешеләр миңа кырын карап уза?

Тәрәз-күзләремнән ага яшьләр —
Һич аңламыйм: ни гаебем минем?
Мин үземдә бәхетле пар яшәр
Һәм сабыйлар туар дигән идем.

Керде фашист каерып ишек-бикне,
Үз тәртибен алып, таләпләрен.
Хуҗамны ул әсир-тоткын итте,
Мыскыллады гореф-гадәтләрен.

Шуңа үч шырпысын сызган кызны
Тотып керде бер көн ул урамнан,
Идән сайгакларым сыкрап торды
Ерткычларча кызны кыйнаулардан...

Еллар узгач һәйкәл булып кайтты —
Ак мәрмәргә төреп утлы җанын.
Сәламемне никтер алмады ул,
Әллә таныды, әллә танымады...

...Аның утларыннан янган булсам,
Бу сагышны күрмәс иде башлар.
«Кара йорт!» дип кырын карамагыз,
Гаебем юк минем, авылдашлар...

Үзем кара, ләкин уем якты,
Кара коелам бары тик дошманга.
Бар диләр бит «Яңа сугыш!» диеп,
Саташучы кайбер Ак йортлар да...

Мин эчемә йотып сагышларны,
Каһәр генә сукса иде, диеп,
Фашизмны каргыйм, сугышларны,
Нәфрәтемнән шулай кара көеп...»

*1987. Мәскәү — Петрищево.*

Балачактан яшьлек кырларына
Йөгерә-йөгерә чыгып барганда,
Әллә ничек кенә очраштык та
Авыл читендәге таңнарда,
Дулкынланып торган яшь арышлар
Арасында качыш уйнадык.
Баш өстендә — тургай...
Шул вакытлар
Узмас дипме әллә уйладык,
Кыймадык без хәтта бер-беребезнең
Күзләренә текәп карарга...

Ә шулай да синең елмаюың
Сызылып китә
Сызылып кына аткан таңнарда.
Толымнарың — арыш кырындагы
Җилдә тибрәп торган бер учма,
Хуш исләре иләс-миләс итә,
Тотсаң, үзе — сыяр бер учка.

Ә күзләрең — авылыбыз күге,—
Болыты да, аяз чагы да
Газиз җанга: чагыла сыман анда
Җырлап торган тургайлары да.
Елмайганда шомырт чәчкәседәй
Балкып куя ап-ак тешләрең.
Иреңеңдә — (әле дә тоям кебек) —
Яңа гына сауган сөт тәме...
Уйлыйм кайчак: нигә шулкадәрле
Онытылмаска кергән күңелгә?
Яшьлек мәхәббәте була ахры
Туган якның үзе төсендә...

Яшьлек мәхәббәте...
Ул — синеке,
Туган якта калсаң әгәр дә.
Читкә китсәң, кала икән бары
Гомер буе сагынып яшәргә.

## Урман шавы

Колагымда һаман урман шавы,
Бер шаулый да урман, бер тына,
Вакыт-вакыт куя ыңгырашып
Тәненә чапкан балта тавышына.

Эссе чакта урман куены җиләс,
Салкыннарда — бирә җылылык.
Урман булса, коры җилләр тимәс,
Урман юкта — җанда корылык.

...Арфа итеп кояш нурларын,
Бабайлардан калган моңлы җырны
Күңелләргә сала урманым.

Ә рәхимсез балта һаман кисә
Агачларның сайлап асылын.
Балтаның бит аның йөрәге юк,
Тимер башның нинди акылы?

Илсакчылар өчен калкан булган
Белоруссия урманнарының
Туганыдай безнең бу урманнар,
Җырлары да уртак, таныймын.

Сугыш елларының суыгыннан
Туңдыртмыйча безне саклады.
Тик бирәү дә ул чак агачларны
(Ат койрыгына таккан комиссардай...)
Тракторга тагып кайтмады.

Уңны-сулны балта белмәгәнгә
Бу урманның җыры кайгылы.
Искәртә ул, гүя, балта башлы
Бәндәләрнең әле барлыгын...

## Кадерен бел

*Кайчандыр үзем хезмәт иткән*
*хәрби частька килгәч уйлану.*

Бөтен нәрсә газиз һәм үз монда:
шул ук урман, шул ук казарма.
Тик солдатлар, командирлар гына
таныш түгел — яшьләр, тазалар.

Заманында без дә шундый идек,
хуҗалары идек урманның.
Хезмәтебез тутырдык та киттек...
Сизелмәде еллар узганы.

Дистә еллар...
Эх, беркатлы күңел,
элеккечә һаман күрмәкче,
элек постта торган урыннарда
хуҗа булып үзен сизмәкче.

«Юк, ярамый!
Булган үзгәрешләр,
Яңалыклар сиңа сер инде...»
Элек үзең хуҗа урыннарда
тыйнак кунак булып йөр инде.

Монда хәзер мине таныса да
урман бабай таный торгандыр.
Ләкин аннан бирле урманда да
ничә буын алышынгандыр...

Тик шулай да танымыйча калмас
серем уртаклашкан каеннар.
Сез бит мине яшел шәл бөркәнеп,
озатып калган идегез авылга...

Ул вакытта айлап түгел, көнләп
санадык без солдат хезмәтен.
Инде менә, гимнастерка кигән
егетләрдән йөрим көнләшеп.

Әй, кайда сез, бер аяктан атлап,
җырлаучылар поход җырларын?
Күз кырыем белән булса да бер
күримче дип яшьлек елларым,
килгән идем. Ләкин сез булмагач,
боектым мин ятим шикелле.

Шул вакытта урман юлларында
җанга таныш җырлар ишетелде...

Безнең яшьлек киткән бүгенгенең
ышанычлы нигезен салышып.
Бүгенгеләр эше — киләчәкнең
нигезләре булып калышлы...

Мин аңладым: әнә шуңа икән
каты таләп куйган Ил безгә —
Ил-йортыбыз ныклы булсын дисәң,
нык булырга тиеш нигезләр...

Күңелдәге сагыш —
Мин бит монда
кунак кына, дигән уйлардан...
Кадерен бел Җирдә яшәвеңнең —
үзең шунда хуҗа булганда!

*Май, 1987. Мәскәү — Дорохово.*

Бик җырлыйсым килгән иде, бик тә,
Чирмешәндә боз кузгалган кичтә,
Җырламадым. Уйламадым һич тә
Калыр диеп болай үкенечкә.

Оялумы, тартынумы — тынсыз,
Ялгыз гына басып тордым, җырсыз...
Җырла, егет, җырла, синең шунсыз
Күңлеңдәген ничек белсен ул кыз.

Колак салып тыңлагандыр ничә,—
Чирмешәндә гөрләп бозлар китә.
Ә мин киттем, имеш, сер бирмичә,—
Шул кич калды гомер үкенечкә.

Куып тотты аның хаты мине:
«Мин тормышка, дигән, чыктым инде,
Мәхәббәтем миңа җырлап килде,
Сихерләде алкын күңелемне...»

Чирмешәннең кузгалгандай бозы,
Актарылып-ташып чыкты моңым! —
Инде шушы җырланмаган җырым
Гомер буе яңгырый, гомер буе...

Сүзең була торып, имеш, тартын,—
Сөйгәнеңне ятлар тартып алсын...
Җырла, шагыйрь, җырла, синең тавышың
Ишетерлек булсын сөйгән халкың...





*Шагыйрь, 1982 елдан СССР Язучылар союзы әгъзасы Ямаш Игәнәй (Ананий Нестерович Малов) 1938 елның 10 январенда Татарстан АССРның Сарман районы Ләке авылында туган. 1955 елда — Сарман урта мәктәбен, 1958 елда Лубян урман техникумын тәмамлый; 1958—1960 елларда Совет Армиясендә хезмәт итә. Армиядән кайткач, Рантамак, һәм Азалак мәктәпләрендә балалар укыта һәм читтән торып Казан дәүләт университетының журналистика бүлегендә белем алгач, Баулы һәм Мамадыш — район, аннары Яр Чаллы шәһәре газеталары редакцияләрендә эшли, Татарстан Язучылар союзының Яр Чаллы оешмасында җаваплы секретарь вазифасын башкара. КПСС члены.*

*Шигырьләре белән башта көндәлек матбугатта катнаша. 1981 елда аның «Сәфәр чыгам» исемле беренче мөстәкыйль китабы дөнья күрде. Хәзер Я. Игәнәй — дүрт шигырь китабы авторы.*

*Илле яшен котлап, укучыларыбыз игътибарына шагыйрьнең берничә яңа шигырен тәкъдим итәбез.*

## Ямаш Игәнәй

### Атыла йолдыз...

Берние дә юк шикелле, югыйсә —
Атыла йолдыз. Юлы сызылып кала.
Ә син минә шуны кабатлап кара...

Ботагыннан өзелеп,
Алма төште нибары —
Зыңлап куйды Җир шары...

### Диңгез

*Тереклек диңгездән башланган.*

Гипотеза.

Офыкка сыенган, серле
Җан иясе күк диңгез.
Бар сыман анда кодрәтле
Нииндидер яшерен көч.

Ул серле көчнең асылын
Аңлый алмабыздыр һич.
Юкса бу бөек җисемнең
Кисәге — үзебез ич!..

●

Көн аша, я төн аша — узар юлың.
Бар — таныш, таныш түгел шомлы урын...

Тайгакта егылмыйм, имгәнмим, дисәң —
Ал таяк, армас, хәлдән таймас борын.

Көн димә, саклан хәвефтән, хәтәрдән,
Ут кабыз, караңгыга калмас борын...

●

Кырказ тавышы камыш булып шыткан күлдә,
Сандугачның җыры чәчәк аткан гөлдә.
Каян килә тылсымлы көй-аһәң, дисәм —
Сөю булып сарылгансың син күңелгә...

## Серле көзге

Серләрен күзләр
Сөйли көзгегә,
Көзгеләр — күзгә,
Диделәр безгә.

Баксам көзгеңә
Белим дип сереңң —
Кучте күземә...
Сурәтең синең.

●

Яраткан да адәм затын бу Табигать,
Аңа кодрәтле көч, бөек Акыл биргән.
Хәзер әҗәле алдыннан, кан калтырап,
Мәрхәмәтен көтә аның, дүрт күз белән...

●

— Табигатьнең иң асыл хәзинәсен
Яшергәнсеңдер күңелең түренә.
Йөзләреңдә серле балкыш аллана,
Күзләреңнән җем-җем нурлар түгелә.

— Ялгышмадың, зирәк егет,— диде кыз,
Серем ачам сиңа ихлас күңелдән.
Әйе, минем йөрәгемнең түренә
Зур хәзинә — мәхәббәтем күмелгән!..

# ПУБЛИЦИСТИКА

## Зиннур Мансуров

# «ГАКЪЛЫМ БЕРЛӘ ... КУЛ ТАЛАША»

### БЕР ЧИКТӘН ИКЕНЧЕ ЧИККӘ ТАШЛАНУЛАР КИРӘКСЕЗГӘ КҮПМЕ ЯШӘҮ КӨЧЕН АЛА

Аналгезия... Кешенең авыртуны тою сәләтен югалтуы медицина фәнендә әнә шулай дип атала. Авыртуны тоймау... Әлеге гаять куркыныч авыру, туры мәгънәсендә алсак, гавами күренешләр рәтенә керми. Шулай булуы хәерле. Бу төшенчәгә символик күзлектән карап, рухи-әхлакый яктан фикер йөрткәндә исә... Рухи сызлану тойгысын югалту, кызганычка каршы, хәвефләндерер дәрәҗәдә таралыш алды. Монысы хәтәррәк авыру. Мең тармаклы чир! Бюрократлыкның хроник рәвеш алуы да шушы рухи аналгезиягә бәйләнмәгәнме? Кешелеклелек сыйфатларының саега төшүе җанның сызлана алмавыннан килмиме? Көнделәге әхлакый башлангычның ярлылана башлавы һәм туфрактагы бәрәкәтле катламның кимүе... Хәтта алар арасында да бәйләнеш бардыр төсле! Янсә менә бүгенге бәхетле тыныч тормышта ятим балаларның арта баруын гына алыйк. Картлар интернаты күбәя. Бу күңелсез күренешнең эчке сәбәпләре әрнүләрне тоймас төстә тупасланудан түгелме соң?! Төрле мисаллар китерергә була. Кешелеклелек дәрәҗәсен билгеләүче өлгеләрдән берсе олуг икмәккә мөнәсәбәт мәсьәләсенә тукталыйк.

...Кыш бик иртә килгән ел иде. Туй күлмәген яшьли кигән кыз төсле моңаючы табигатьнең аянычлы шундый бер манзарасы хәтердә һаман яңарып тора. Уңышы җыелмаган совхоз басуы! Район үзәгенең борын төбендә... Ап-ак кардан тырпаеп торучы алтынсу башаклар саргылт камышлардан күпкә сагышлырак була икән. Күпкә...

Нәрсә булды безгә? Йөрәкләрне чәнчү алмыймы? Күңел чаңы нигә дәшми?.. Элек башак җыю гадәте бар иде. Балачак елларында үземнең дә башак җыйганымны хәтерлим. Ә мондый мөмкинлектән файдаланырга була ич. Басу артык зурдан түгел. Укучы балаларны тартырга мөмкин. Уртакка эшләүне дә беләбез югыйсә. Башакның яртысы — совхозга, яртысы — җыючыга бирелсә... Юк. Мондый күнегелмәгән чишелешкә кайсыбер җитәкчеләр каршы. Үземә дә булмасын, кешегә дә... Аларга шулай яхшырак. (Бәя төшерергә теләмәүче тәкәббер фермерларның җиләк-җимешне чүплеккә түгүләре хәтергә килә.) Колхозчы хуҗалыклары язын саламга мохтаҗлык кичергәндә, әнә шулай, сөреләсе басуда «артып» калган эскертләр яндырыла. Хәтта игеннәр дә кар астында кала. Вөҗдан газапламыйдыр безне...

Шунысы аңлашылмый: шәхси хуҗалыкка бөтенләй башка караш. Уңышы җыелмыйча калган бәрәңге бакчасын күргәнегез бармы? Колхоз басуына исә эчебез пошмый. (Күпме җир алмасының туфракта калуын инде әйтеп тә торасы килми.) Күмәк хуҗалык карамагындагы җирләр (гомумән алганда, социалистик милек) ничектер хуҗасызга әйләнә башлады. Ялланып эшләүчеләрне хәтерләтүче битараф көнлекчеләр күбәйде. Коллектив подряд ысулы, бәлки, чын хуҗаларны тудырыр?! Ышаныч — шуларда. Әмма авыл хуҗалыгында колач җәюче әлеге прогрессив алымның асылы «шабашникларча» акча каерып алуга гына кайтып калмасын иде. Монда икенче чиккә ташлану күңелсез нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. Үзебезнең хәләл совет акчасы океан артыныкына охшап китмәсен...

Сызлану тойгысын югалту... Мондый аномаль күренешне берьяклы аңлатып булмый. Сәбәпләр күп төрле. Шуларның берсе, минемчә, ачык төсмерләнә. Җәмгыятьтә үзебезнең әһәмиятебезне аңлау — үзаң тотрыксызлана төште шикелле. Аеруча соңгы берничә дистә елда. Уртак мәнфәгатьләргә мөнәсәбәтнең кайвакыт «аңсызрак» булуы, хезмәт интузиазмы төшенчәсенең курсы сизелерлек төшү, һәрнәрсә белән килешүчән-

лек, күндәмлек, роботтай сукырларча «үтәүче»гә әверелү, социаль ваемсызлык, гражданлык кайгыртуын кечерәйтеп аңлау, үзеңне илдә реаль хуҗа итеп тоймау... Үзаңыбызны шактый дәвамлы торгынлыкка менә шундый сәбәпләр китергәндер. Әле бу сәбәпләрне тудырган «беренчел» сәбәпләр дә бар. Шуларның иң җитдие: һәрбер эшнең үзәген билгеләүче идея һәм интерес берлеге какшый төште. Кайчак кешене шәхси мәнфәгатьләренә туры килмәүче идеяне гамәлгә ашырырга мәҗбүр итү... Әлеге гайре табигый хәл социаль гаделлек принцибының бозылуына, соңгы исәптә, хезмәт ияләренең гомум җәмәгать эше белән кызыксынуын киметүгә китерде. КПСС Үзәк Комитетының январь (1987) Пленумында ассызыклап әйтелгәнчә, идеянең интерестан аерылуы нәтиҗәсендә кешеләрнең хезмәт һәм социаль активлыгы кимеде, дисциплина һәм тәртип начарайды, рухсызлык һәм скептиклык чире көчәйде.

«Мин — бәләкәй кеше...» Искәрткәнегез бардыр: соңгы вакытта үзләрен «бәләкәй кеше» итеп санаучылар күбәйде. Гаять күңелсез «арту». Үзләренең иңнәренә җаваплылык алырга теләмәүче мондый затлар, билгеле, җәмәгать эшләре белән җитәкчелек итүдән читтә торалар. һәм «политикадан читтә»... Тәрәккыятнең һәркем эше булуы мондый «бәләкәй кешеләр»не кызыксындырмый. Ялгыш адымнар ясаган чакта исә андыйларның җавабы һәрчак әзер: «начальство гаепле!..» Алар гынамы икән?! Бу уңайдан хуҗалык итүдә үзидарә, үзфинанслау һәм тотылган чыгымнарны каплау кебек яңа тәртипкә күчүнең үзаңны тирәнәйтүгә, хезмәт һәм социаль активлыкны көчәйтүгә китерүенә ышаныч зур.

Кайбер яңа идеяләрнең тиешле экономик җирлеге булмау, тормыш агышының объектив нигезен тоеп җиткермәү, хуҗалык итүдә алдан күрү сәләтен җитәрлек файдаланмау, әйе, кешеләр аңындагы күп кенә асыл сыйфатларның тәссезләнүенә, фикерләүнең күпмедер дәрәҗәдә «катып калуы»на, хәрәкәт ориентирларын буташтыруга этәрде. Безне бер чиктән икенче чиккә ташлану кебек хәлне бетергеч яман өянәк даими эзәрлекли башлады. Үзендә капма-каршылыкларны сыйдыручы кешеләр күбәйде. Тайпылышсыз характерлар кими төште. Сәбәпләр, әйткәнебезчә, күп төрле. Мәктәпләрдә җәмгыять белемен укытуның схоластик рәвеш алуы да фикерләү торгынлыгын китереп чыгаручы сәбәпләрнең берсенә әверелгәндер. һәм югары уку йортларында философия фәнен үзләштерүдәге догмачылык чалымнары да... Илнең килачәктәге хуҗаларын болай тәрбияләргә ярамый!

Яшь буында югары философик культура тәрбияләү өлкәсендәге формализм турында уйланганда, Казан дәүләт медицина институты студенты Ю. Батрасовның ачынып сөйләве хәтергә килә: «Комсомол сафына аяк баскан чакта миннән Советлар Союзы флагының нинди төстә булуын сорадылар (?!)» Бүгенге көндә факультет комсомол оешмасын җитәкләүче егет әлеге сорауны эчке сызлану белән искә ала. Шаккаткыч формальлек. Ленин комсомолының дәрәҗәсен төшерү. Кешелек сыйфатларын кимсетү... (Без университетта зачет яисә имтихан биргән чакта исә, укыганлыкны тикшерү максатыннан, өйрәнергә тиешле китап тышлыгының төсен сорыйлар иде.)

Фикри торгынлык чире белән авыручы кеше, әйтканебезчә, бер чиктән икенче чиккә ташланучан була. Артыбызга борылып карыйк әле: күпме кичердек мондый тайпылышларны! Каршылыкларны җиңеп бару юлында хәлне бетергеч күпме бәргәләнүләр! Аеруча соңгы берничә дистә еллар эчендә... Бер чиктән икенче чиккә ташлану социаль бәлагә әйләнеп китте күк. Алтмышынчы еллар башын искә төшерегез. Илленче еллар уртасында уңышлы башланган үзгәртеп корулар әлеге дә баягы икенче чиккә ташлану шаукымына очрады. Авыл тормышын алыйк. Колхозчының каралтыкурасы кысылды, шәхси мал-туар кыскартылды. Әле дә истә: күпләп йорт куяннары үрчеткән еллар иде. Миндәй малайлар өчен гөнаһсыз озын колаклардан аерылу шактый авыр булды. Йорт-җир. Борынгылар юкка шулай атамагандыр. Җирсез йорт буламы? Мал-туарсыз каралты-кура?! Халык тормышын нечкәләп өйрәнгән мәгърифәтче галимебез К. Насыйриның йорт-җир турындагы этнографик хезмәтен укыйсы килеп китә: «Күп кешеләр бар, урта гына хәлле булса да, тавык-чебеш, каз-үрдәк, күркә кебек нәрсәләрне асрыйлар, сыер һәм кәҗә асрыйлар. Һич мөселман катыксыз аш ашамас, ашка катык салып ашар. Чәйне сөт белән эчкән кеше бик сирәк булыр; әмма катыклы ашны күбрәк яраталар. Шуның өчен күп кешедә сыер бар. Хәтта фәкыйррәк булса, кәҗә асрый, сөте-катыгы өчен...»

Табигый яшәеш агышын нигезләнеп җитмәгән ясалма чаралар белән үзгәртергә омтылу, гадәттә, алга таба хәрәкәт итүне тоткарлый торган күңелсез нәтиҗәләр китереп чыгара. Сала бай булса, кала бай була... Халык тарафыннан гасырлар дәвамында юкка ителгән «политэкономия» моңарчы безнең колагыбызга әнә шулай такрарлап килде. Шәхси хуҗалыкларда мал-туар тавышы ишетелми башлау исә әлеге табигый бәйләнешнең күпмедер бозылуына китерде. Авыл табынының саегуы бөтен ил табынына тәэсир итте. Саладагы туганнарга күчтәнәч итеп, каладан ит-май ташый башладык. Шешәле катык та алып кайтабыз... Искә төшерү оят. Тормыштан нигезен тапмаган идея

шаукымының галәмәте. Әгәр шәхси хуҗалыклар Азык-төлек программасын балдамайда йөзеп каршыласа, хәл башкача булыр иде.

Йорт-җир... Бөтен барлыгым белән авыл баласы буларак, шушы төшенчәгә киңрәк тукталып китәсе килә. Авылның камил йорты нинди булырга тиеш? Каралты-курасы? Әлеге сораулар безне күптәннән борчый. Төрле «модельләр» тәкъдим ителде. Тәҗрибәләр ясап карадык. Ялгышларның иң-иң аянычлысы, минемчә, йортны җирдән аерудадыр. Берничә катлы йортлар салып, авылны биеккә үстерергә омтылдык. Колхозчы югары күтәрелгәндә, газиз җиреннән ераклаша башлады. Физик яктан гына түгел, социаль мәгънәдә ерагая төште. Җиргә алай өстән карарга өйрәнмәгән колхозчы бәрәкәтле тарту көченең кими баруын тойды. Авылда күпкатлы йорт, шулай итеп, тамыр җибәрә алмады. Авыл йорты. Идән астында — туфрак, түшәм өстендә — туфрак. Авыл кешесе ике яктан да туфрак җылысын тоеп яши. Баштанаяк... Менә шундый «типовой йорт». Билгесез халык архитекторлары аны гасырлар буена камилләштергән. Вакытлар сынавын үткән әлеге «проект»ны ансат кына сызып ташларга мөмкинме? Бер читтән икенчесенә ташлану түгелме бу?

Авылда күпкатлы йортлар салу, әйе, җир хуҗаларының күңеленә ятмады. Шаукым узып китте. Әмма авыл яңарудан туктамый. Соңгы вакытта салына башлаган, хуҗалык итәр өчен бөтен уңайлыклары булган «утар»лар авыл йортларының гасырлардан килгән классик үрнәгенә якынрак торалар. Ишектән чыгуга, җиргә басасың. Тәрбияви яктан да гаять уңайлы. Баскыч төбеннән үк урам башланмый. Кул арасына керә башлаган балаларны каралтыда үз төрле эш көтеп тора. Гасыр ахырына кадәрге чорны колачлаган илкүләм төзелеш планында авыл йортларының нәкъ менә шундый төрдәгесе үзәккә алына. Өйләрнең бары биш процентын гына (башлыча шәһәр читендә) күпкатлы итеп салу күздә тотыла. Госпланда шулай каралган. Киләчәкне истә тоткан мондый чишелеш халык ихтыяҗларына каршы килми шикелле. Узгандагы ялгышлар да искә алынган. Әмма әлеге проектка да каршы чыгучылар очрый. Авыл кешесен «җирле йорт»ка бәйләүне, имеш, әлегә дөрес карарга санап булмый. Хезмәт ияләрендә җиргә мәхәббәт, кайберәүләр фикеренчә, колхоз кырларында тәрбияләнергә тиеш. Зур җиргә мәхәббәт кайдан башлана соң? Беренче тапкыр тәпи баскан туган йорт нигезеннән түгелме? Ниндидер тискәре үҗәтлек белән йортны җирдән аерырга омтылабыз. Янәдән икенче чиккә ташлану. Ялгышларны ник кабатларга? Саланың бай булуы шактый дәрәҗәдә шәхси хуҗалык җиренә дә бәйләнгән. Шуны онытa күрмик!

Җир шарының күпмедер сутый өлешенә хуҗа булу... «Алпавытлык»ны уятмый ул авыл кешеләрендә. Юк! Авыл йорты янындагы шушы җирне безгә кече колхоз басуы итеп күрә белергә кирәк. Алай гына да түгел әле. Зур җир башы булып саналучы йорт кишәрлеге авыл кешесе өчен әйтеп бетергесез әһәмияткә ия. Җир хуҗасы аны үзе белә. Нинди йортта яшәргә кирәклеген дә ул өйрәтүчегә караганда яхшырак аңлый. Без сораштырып тормыйбыз шул. Киңәшмибез. Һәм шактый идеялар җирлексез булып чыга. Шуларны көчләп тагарга тырышабыз. Йорт яны участогы белән бергә, туган нигез тамырлары да киселә. Колхозчының авырткан җиренә кагылабыз. Калага кунакка килеп киткән чакта да ул биек йортлар «изүе»ннән тәмам гаҗизләнә. Авылга ташпулатлар кирәкме? Бит хәзер бөтен бер авылны сыйдырырлык күпкатлы йортлар төзеп була торган чак. Шундыйларын төзергәдер?!

Кайчак шулай да уйлап куясың: бездә авыл тормышын «тамырдан» үзгәртеп кору белән калада туып үскән белгечләр күбрәк шөгыльләнә башлады бугай. Нигә әле авыл дөньясын нечкәләп аңламаган «урбанист» колхозчыга яңа йорт проекты эшләп бирергә тиеш?! Авыл организмын тирәнтен белми торган кешеләр даирәсенең мондый очракта катгый фикер үткәрергә хакы юк. Төп сүзне авылда туып үскән белгечләр әйтергә тиеш. Авыл халкы. Икенче чиккә ташланудан килеп чыккан ялгышлар, минемчә, мәсьәләне тирәнтен белүчеләр белән исәпләшмәүдән киләдер. Югарыдан көчләп тагу, әнә шулай, җирле мөстәкыйльлекне киметтә. Сукыр күндәмлек тамыр җәйдә. Җирлексез күрсәтмәләрне карышмыйча үтәп, кечкенә авылларның тамырын корыттык. Суның кадере, чишмә корыгач беленә. Арыш кыры уртасында зиратлар гына утырып калгач, ике кулыбыз белән башны тотып: «Аһ!» — иттек. Әмма соң иде инде.

Киңәшле эш таркалмас. Моны безгә халык үзе тукып тора. Борын заманнардан бирле. Әмма соңгы берничә дистә еллар дәвамында халык белән киңәшмәү очраклары шактый булды. Авыл хуҗалыгының аерым «форпост»лары булып күзалланган кечкенә авылларны планлы рәвештә юкка чыгару белән мавыгуны гына алыйк. Кечкенә авылларда яшәүчеләрнең үзләреннән сорадыкмы «перспективасыз» нигезне алыштыру турында? Тарихи яшәү рәвешенә кагылышлы әлеге җитди проектны бөтен халык тикшерүенә куярга мөмкин булгандыр югыйсә. Киңәшеп тормадык. Шушындый санлашмау очраклары гадәткә әйләнә башлады. Халыкның үзеннән сорамыйча гына зур-зур шәһәр исемнәрен алыштырабыз. Хәтта милли башкала исемен. (Зөһрә йолдыздагы

сүнгән янартау авызына исем кушмыйбыз лабаса.) Барыбыз да шаһит. «Хезмәт иярләре соравы буенча» Ижевск шәһәрен башкача атадык һәм халык үтенече белән әүвәлге исемен кире кайтардык. Монысын ничек аңларга? Халык исеме белән алай уйнамаска иде.

Төньяк елгаларын көньякка бору проектына бәйле озакка сузылган волокитаны искә төшереп узыйк. Табигатьне «төзәтергә» керешкәнче, халыктан ризалык соралдымы? Шундый коточкыч мәгънәсез проект Госпланда «халык визасы»ннан башка кабул ителгән. Җир хуҗасын санга сукмау бу. Күзаллап бетерә алмаслык күңелсез нәтиҗәләргә китерәчәк шушы шикле идеягә каршы көрәшеп, күпме акыл иясенең файдалы эшкә тотылырга тиешле никадәр көче сарыф ителде. Авыртмас башка тимер таяк булган әлеге проблема әдипләр тарафыннан аеруча авыртулы төстә кабул ителде. Хәтта совет язучылары съездының карарында да ул җитди мәсьәләләр рәтендә чагылыш тапты. Җәмәгатьчелек тарафыннан тәкрарланган фикер дәүләтебезнең реаль көченә әверелде. Татарстан башкаласы читендәге гүзәл урыннарның берсендә «озонлы һава яратучан» биохимзавод төзүне кире кагу да хәзерге яңа шартларда халык сүзенең нинди көчкә ия булуын шактый ачык күрсәтә. Җибәрелгән ялгышны без таный башладык. Әмма мондый савыгу әлегә акрын бара. Эшне сукырларча хәл итәргә күнеккән кешеләрне, кызганычка каршы, каннарына сеңгән гадәттән ансат кына ваз кичтереп булмый. Фикерләүдәге догматизм тамырлары тирәнгә китеп өлгергән. Һәм гамәлләребездәге инерция дә шактый дәвамлы шул.

Җир җимертеп эшләү... Халкыбыз телендә яши торган әлеге тәгъбирнең кайвакыт туры мәгънәсе турында уйлап куясың. Тимер адымнар белән алга барып, газиз җирне шактый җимерергә өлгердек. Күпме сөрүлекләрнең «астын өскә» әйләндерүебезне исәгезгә төшереп торасы килми. Үзегез дә беләсез. Туфрак структурасын бозулар күбәйде. (Күпләр авызыннан ишеткән мондый сүзләрне, юк, агач сабаннар заманын сагынудан әйтмим.) Җиргә сеңеп барган агулы химикатлар тавы безгә киләчәктә нинди «җимешләр» бүләк итәр? Алла белсен! Һаман икенче чиккә ташлану шаукымы. Техника куллануда да чамасыз кыланабыз. Хәтта бәрәңге бакчасын да «корыч айгырлар» сөрә. Туфракны һаман тыгызлыйбыз. Дөньяны тимер басты. Хуҗасызлык хөкем сөргән колхоз-совхозлар нинди дә тимерлеккә әверелде. Кайбер авыл урамнарында гербарийга өзәрлек чирәм табып булмый. Тимер тапкан тилмермәс дип, борынгылар әйткән әйтүен. Әмма уйлап эш итмәгән очракта тимерле кеше дә тилмерергә мөмкин. Тимер бәдәнле бәндәләр тимерагачларны корыта ала. Тимер чыдамлылыгы төшенчәсе табигатькә килешеп бетми. Илаһи җирнең дә түземе чикле.

«Кызыклы» бер күзәтү. Татарстан авылларының берсендә көзнең көчле җиле ялгыз тирәктәге карга оясын җиргә очыртып төшерә. Җентекләп караучылар табыла: болар үзләренең ояларын, янәсе, нәрсәдән ясыйлар икән? Тал чыбыгы, әрем сабагы, каз мамыгы һәм... Нәрсә дип уйлыйсыз? Алюминий, тимер, бакыр, кургаш чыбыклар!

Әллә көләргә, әллә еларга?! Менә шундый хәл. Уйланган кешенең үзәге өзелерлек...

Миңа ике елдан артык «җир чите»ндә — Ерак Көнчыгышта яшәп алырга туры килде. Сопкаларда адашкан чакларым булгалады. Дерсу Узала иле! Мондагы табигатькә соклнудан туймадым... Тайгада яралы бер эт күрүем хәтердә. Кыланышы шундук гаҗәпсенү уятты. Соңыннан юлдашларым аңлатты. Айкунеги ашап савыгыр өчен килгән икән әлеге этебез. Качып килгән. Урман суганының дәвалау көчен сизеп. Уйландырды. Туган якның сөрелгән болыннары искә төште. Җаныбызга шифа булган бихисап чәчәкле болыннар! Миллион еллар буена баеган табигать аптекасы! Ниндидер вандаллык белән шуны җимереп ташладык. Җирләрне миллиорацияләү эшендә икенче чиккә авыштык. Аумакайлык күрсәттек. Күңелсез нәтиҗәләрен күзалламадык. Халыктан фикер сораучы булмады. «Гакълым берлә... кул талаша»... Бөек Тукаебызның шундый шигъри сүзләре хәтергә килә. Акыл белән кулның талашуы — яшәештә һәрчак кирәкле шәйдер. Әмма мондый файдалы талашу соңгы елларда кими төште. Акыл белән эшләү җитми. Кул өлгеррәк. Балакай авыллар тамырына икеләнмичә балта чабыла. Болыннар сөрелә. Аннары безнең халыкта шундый сәер гадәт тә бар: без бит уйланып җитмәгән күрсәтмәне дә «арттырып» үтибез, һәм кайвакыт мәгънәсезләрен дә. Болын белән дә шулай булды. Инициативалы эшләп, булдыклылык күрсәттек. Кыска вакытка гына караган ихтыяҗ өчен... Мондый очраклар шактый. Илдә табигый байлыклар чагыштыргысыз дәрәҗәдә мул. Шуларны эзлекле төстә ишәйтәбезме? Әлеге байлыкларны туздыру хисабына яшәмибезме икән?! Болай уйлыйсы килми. Әмма ялгышларыбыз байтак. Тере табигать организмына кулларын күтәрүчеләр күп. Гетеның искәртүен хәтерлик: «Табигать үзе белән шаярырга юл куймый... Табигать һәрчак хаклы, кеше генә ялгыша...»

Бернича еллар элек Курган өлкәсендә булган чакта мин Мальцевча туфрак эшкәртү ысулын шактый нечкәләп аңладым. Дөресрәк әйткәндә, хуҗалар төшендерде. Әлеге алымның асылы, баксаң, гади генә икән. Халык агрономиясенең мәкальгә әверелгән кагыйдәсе хәтергә килде: җир ертканны ярата. Һәркемгә мәгълүм шигъри юллар да аермачык булып искә төште: «...Абый белән бергәләшеп, кара җирне Сука белән ертып-ертып йөргәннәрем...» Шушы алым рәсми төстә танылганчы, кырык елдан артык вакыт узган! Болыннарны сөрдерү исә бер селтәнүдә башкарылган. Акыл белән кул талашуы алай ук озак булмаган. Мондый сәерлек кайдан килә? Игенчедә җирнең хуҗасын күреп җиткермәүдәнме? Авыл хуҗалыгында мөстәкыйльлекне кысуданмы? Агрономнарны читтән өйрәтергә остардык. Җирнең үзеннән чыккан агрокультурага ныграк ышанырга кирәк югыйсә. Гомеркәйләрен җиргә багышлаганнарга... Алар игенчелек фәнен тупас бозмыйлар ич. (Инде боза калган очракта, әлбәттә, өстән катнашу таләп итеlә.) Икенче чиккә ташлануларны җиребез күпме кичерде! Кукуруз «бизгәге»... Җәй буена карга кудым кукуруз басуыннан, дип, ихластан җырлап йөргән чаклар бар иде. «Кәгъбә бодае»н айга мендереп чәчәргә хыялландык. Әлеге дә баягы агулы химикатларга ябырылу. Баш ватып торасы юк. Терәклеккә яңый башлаган әлеге «химик корал»ны инде хәзер катгый тыярга вакыт җиткәндер?! Биологик чиста икмәк үстерергә... Гербицидтан ваз кичкән хуҗалыклар илебездә инде шактый исәпләнә. Бу уңайдан халык академигы Т. Мальцевның искәртүе борчылу уятучы чаңдай шомлы яңгырый: «Агулы химикатлар белән мавыгу, минем уйлавымча — шул ук алкоголизм. Кайчандыр бюджет кереме өчен халыкны эчәргә өйрәттек, монда да шулай: агымдагы елның уңышы өчен генә туфракны, бөтен табигатьне агулау юлына басабыз. Агротехника буенча эшләп җиткермибез — акыл ушәнлеге һәм бәлтерәгәнлек күрсәтәбез».

Аныкка таңык булу, икенче төрле әйткәндә, көч түкми яшәү... Авылларда булгалаган чакта шундый сүзләрне ишеткәлим. Мондый дәгъвалы фикерләр, гадәттә, алдынгырак хуҗалыкларда әйтелә. Хикмәт — шунда: рентабельсез хуҗалыклар җитештергән продукция, мәгълүм булганча, дәүләткә чагыштырмача югарырак хакка сатыла. Өстәмә түләү рәвешендәге шундый льгота артта калган колхоз яки совхозны тизрәк аякка бастырыр өчен бирелә. Вакытлы чара. Әмма мондый ярдәм үзен аклыймы? Кистереп әйтү кыенрак. Дәүләт җилкәсеннән төшкән хуҗалыкларны, әлбәттә, күрмәмешкә салышып үтәргә ярамый. Ә зыянга эшләүчеләрнең артуын ничек итеп аңлатырга соң? Илебезнең кайбер төбәкләрендә шундыйрак хәл күзәтелә. (Чиләбе өлкәсендә ишеткән борчылулы сөйләүләр хәтердә.) Колхоз яки совхоз зыянга эшли, баш белгечләр өзлексез премия ала! Мондый парадокслар юкмы? Бурычка күмелеп яшәүнең рәхәтен белүчеләр шактый. Андыйларны вексель куркытмый. Катгый төстә таләп куймыйбыз. Артта калган хуҗалык җитештергән продукциягә өстәмә рәвештә түләүнең, уңай якларыннан битәр, зыян китерүче тискәре асылы күзгә ныграк ташлана төсле. Мондый экономик алым ничә еллар инде хезмәткә сәламәт булмаган караш тәрбияләп килә. Тулы көченә эшләмәүчеләр җиңел яшәргә өйрәнә, гаделсезлекне тойган тырышлар хезмәттән бизә. Менә нинди әхлакый зыян! Шушындый камил булмаган шартларда яшьләрнең яңа буынын үстерәбез. Бер якка чалулау нәтиҗәсе түгелме бу?! Хуҗалык итүнең яңа принципларына күчү, әлбәттә, мондый каршылыкларга инде урын калдырмастыр.

Берчак шәһәр урамы буйлап барганда, гадәти чүп савытына күзем төште. Пингвин рәвешендә ясалган. Уйга калдым. Гөнаһсыз кошкайны нәрсәгә әйләндергәнбез! Авызына чүп тыгылган... «Көнкүреш сәнгате үрнәге»ндә, баксаң, матурлыкның киресе гәүдәләнә. Бу эстетизм түгелме соң? Кем уйлап тапкан аны? Совет кешесеме? Яныннан үтеп китүче пингвиндай балаларга әлеге зәвыксызлык нинди әхлак сеңдерә? Менә шундый яман тәрбия ничә еллар дәвам итә! Әһәмиятсез дип уйламагыз. Зур уйларга этәрүче гыйбрәтле ваклык бу. Дөнья корамадан тора. Икенче чиккә ташланулар юлларыбызда күпме очрый! Вaклары һәм эреләре...

«Пролетариат язучысы... тормыштагы бөтен тайпылышларны аңлап, бөек төзелешнең һәрбер винтын карап, күреп үтәргә тиешле». Һ. Такташ революцион үзгәртеп корулар заманы язучысында шушындый мөһим сыйфатны күрергә омтылган. Бөтен тайпылышларны аңлап!.. Бу бурычның бүгенгәчә искергәне юк. Тик тормыштагы бөтен тайпылышларны аңлатып бирә алабызмы соң? Алдан күрүчәнлек сәләтебез бармы? Кисәтү авазы көчле чыгамы? Кулыбызны йөрәккә куеп әйтә алмыйбыз шикелле. Үзебезнең хуҗалыкта да тайпылышлар җитәрлек. Иҗатыбыз методын аңлатуда да бар икенче чиккә ташланулар. Һәм башка мәсьәләләр буенча да... Тема актуальлеген аңлауда, мәсәлән, берьяклы хөкемнәр күпме? Аерым әсәрләрне бәяләүдә? Соңгысына киңрәк тукталыйк.

Әсәрне бәяләү... Шушы уңайдан алтмышынчы еллар башында иҗат ителгән «Рәшә» (Ә. Еники) һәм «Өч аршын җир» (А. Гыйләҗев) повестьлары тирәсендә кузгалып алган мәгълүм шау-шу беренче булып хәтергә килә. Кайбер тәнкыйтьчеләр тарафыннан штыкка алынган әлеге әсәрләргә, белгәнебезчә, китап рәвешендә чыгу хокукын яулап алу җиңел булмады. Икенчесе андый хокукка үзебездә түгел, илебез башкаласы нәшриятларының берсендә ирешә. Моңа кадәр «Дружба народов»та басылып, журналның еллык премиясенә лаек булды. Урау юллар белән кайтты. Халык тарафыннан «егылып» укылган «Мәхәббәт сагышы» повесте дә (Ш. Хөсәенов) еллар үткәч кенә, китап рәвешен алды.

Шушы урында «Рәшә» белән «Өч аршын җир»гә яңадан кайтыйк. Инде хәзер әлеге әсәрләрнең яшәүчәнлегенә шикләнеп караучылар юктыр, чөнки аларның вакыт сынавын уңышлы үтүе һәркемгә мәгълүм. Повестьларны берьяклы тәнкыйтьтән вакыт үзе «реабилитацияләде». Бүгенге үзгәртеп корулар чорында алар икенче сулышларын алдылар шикелле. (Сәхнәдә яши башлауларын әйтеп тә торасы килми.) Теге чакта исә... Мәкаләләрнең исемнәренә генә игътибар итегезче: «Кояшлы язны рәшә капламасын», «Замандаш белән очрашу барып чыкмаган» һ. б. Гадәттәгечә тоелмаучы әлеге әсәрләр, гади генә итеп әйтсәк, «типиксызлык статьясы», «чынбарлыкның объектив дөреслеген чагылдырудан читтә торган очраклы ситуацияләрнең шактый урын алуы» белән гаепләнде.

Һәркемгә дә яхшы мәгълүм булган әлеге әсәрләрдә, әйтегезче, чынбарлыктан читтә торган очраклы моментлар чагылыш тапканмы? «Рәшә» повестеның үзәк образы Зөфәргә якын дусты мондый сүзләр әйтә: «Бел, мин синең шикелле акчага табынмыйм, минем өчен чүп ул, әмма ләкин шул чүп кесәмдә кыштырдамаса, мин кеше түгел. Минем белемем дә, дипломым да, партбилетым да — бернәрсәм дә юк. Бары акча гына миңа тигезлек, батырлык, хокук бирә. Бәс шулай икән, яшәсен галантерея сәүдәсе!» Типларны барлыкка китерә алмаслык үзенчәлекме? Язучы сурәтләгән елларда андыйлар азрак иде әле. Художниклык нәкъ менә шунда да күренә! Бәхетне байлыкта гына күргән үземче бәндәләрнең үрчиячәген язучыбыз шактый еллар аша алдан күреп кисәтте. Контрольсез «сул» экономиканың чәчәк атачагын куркыныч яралгы хәленнән үк күрәзәләде. Чаң сукты. Без хәзер хезмәтсез керемнәргә каршы, махсус карар кабул итеп, илкүләм көрәш ачтык. Исебезгә төшереп, уйлап карыйк. Тормышыбызның социаль ягы әлеге әсәрдә күрсәтелмәганме? Язучыны социаль фактордан читләшүдә гаепләп буламы? Яшәештә барлыкка килгән күренешнең социаль-драматик асылы, аның тормыштагы төп нигезләр белән эчке бәйләнеше... Повестьта шушы ачкыч күренмиме?

Утыз еллап элек иҗат ителгән «Саз чәчәге» дә «чынбарлыкны бозып күрсәтүче» эстетизм әсәрләре ратенә кертелде. Югыйсә язучы гаять яман күренешнең тамыр җәячәген безгә бирничә дистә еллар алдан күрәзәләп бирде. Повестьның үзәк фикере, хәтерлисездер, башламда ук сиздертелә: «...Былтыр көз булып үткән район партия конференциясендә делегатлар райкомның икенче секретаре Шакир Мостафинны «тәгәрәттеләр»... Конференция барышында коммунистлар аңа бик җитди гаепләр ташладылар: халыктан аерылдың, халык кайгысыннан бигрәк, үз кайгыңны күбрәк кайгыртасың, кыскасы, обывательгә әйләнеп барасың диделәр. Мондый гаепләүләрнең нәтиҗәсе бер — коммунистларның ышанычын югалту булырга тиеш иде. Куркыныч хәл иде бу җитәкче кеше өчен...»

Очраклы моментлар, имеш, очраклы ситуацияләр. Мал җанлы обывательләр, янәсе, безнең тормышта аз. Кайвакыт чиребезне шулкадәр яшерергә тырышабыз. Наркомания шаукымын да күрмәмешкә салыштык. Күзебезне ачыбрак карасак... Үзәк матбугатта чыккан кайбер мәкаләләр расланынча, хәтта фәхешлек статистикасы туып маташа икән. Җәмгыятьнең сәламәт организмына елышучы шул яман чирләргә без нигә күрәзәчеләрчә алдан ук хөкем карары чыгара алмыйбыз?! Тормышта аерым очраклылыклар да тенденциягә әйләнеп киткәли. Күренешнең тамырын күзаллап җиткермибез. Өлгереп килүче тормыш каршылыкларының асылын ачуда реаль иҗат мөмкинлекләре әлегә тулы файдаланылмый. Ниндидер «чикләгечкә» күнегүме? Алданрак барырга омтылучыны исә кайвакыт өнәп бетермибез. Нигә? Хәзерге тәнкыйтьнең перспектив фикерләү сәләте тоныклана төштеме? Шулайдыр. Инде һәркемгә мәгълүм күренешләргә берьяклы аңлатма бирү белән чикләнүчедән вакытны узып язылган әсәрләр турында төгәл нәтиҗәләр чыгаруны көтеп булмый. Әсәрдә үткәрелә торган аерым тенденцияне иҗтимагый процесслар җирлегендә өйрәнеп, язучының талант көчен бөтен зурлыгында ачып бирергә омтылучылар сирәк. Зурны кечерәйтеп аңлатучылар шактый. Яхшы әсәрне ялгышын табар өчен генә укып чыгучылар да очрашып тора. Бездә югыйсә һәр дүрт-биш язучыга бер тәнкыйтьче яки әдәбият белгече туры килә. Бер-береңне үстерү өчен менә дигән мөмкинлек! Әмма әдәби язмышыңда алыштыргысыз таяныч була алган, гомер буе рәхмәт укырлык тәнкыйтьчене табуы кыен. Бу уңайдан Ә. Еникине аңларга була. Күптән түгел басылып чыккан

истәлекләрендә ул борчылдыра торган гыйбрәтле мисал китерә: «...Башта уйлар күп, күңелдә ышаныч аз, нәрсәгә тотынырга да белмим. Ахырда, якын дустым Хәбибрахманга барып, зарымны сөйләдем. Ул, әдәбияттан читтә торса да, заманны бик яхшы аңлый иде...»

Әсәрне тере организм итеп караучылар арабызда нигә шулай аз икән?! Гел стереотипларда тәрбияләнүебезднеме бу?! Тормыш әдәби теорияләр буенча бармый лабаса. Яшәеш калыпларга сыймый. Талант зурлыгы бәхәссез булган әдипне нигә «прокруст ятагы»на сузып салырга? Тәнкыйтьтә кайчан бетәр догмачылык? Социалистик иҗат принциплары асылын нигә шулкадәр тарайтып аңлыйбыз? Үзебезнең сайлыкны күрсәтәбез, өстәвенә, икенче чиккә ташланабыз. Типиклык төшенчәсен аңлауда, күргәнебезчә, перспектив фикерләү җитенкерәми. Мондый формаль логика калыплары белән тикшереп караган очракта, әйтик, «Ахырзаман» («Плаха») кебек казанышларны бөтенләй юкка чыгарып ташларга мөмкин. Тискәре типларны үзәккәрәк алып язылган яхшы әсәрләрнең тулаем уңай әһәмияттен, гомумән, соңгы дөрес бәя бирүнең җаваплылыгын әлегә бөтен тирәнлегендә аңлап бетермибез. Шушы хакта уйланган чакта М. Танк инануы хәтергә килә: «Бәяләү мәсьәләсендә мин саграк булырга тырышам, чөнки әдәбият һәм сәнгать тарихы хөкем ителгәннәрнең еш кына үзләренең судьяларыннан һәм аларның трибуналларыннан озаграк яшәгәнлекләрен күрсәтә».

Җәмгыятьнең алга баруына каршылык күрсәтүче бөтен нәрсәне фаш итү, билгеле булганча, КПСС Программасында һәртөрле сәнгатькярнең мөһим бурычларыннан берсе итеп күрсәтелгән. һәрбер яхшы әсәр, элеккерәк атама белән әйткәндә, «инкыйлабчы» булырга тиеш. Югарыда телгә алынган повестьларны әнә шундыйлар рәтенә, вакытны узып киткән әсәрләр җөмләсенә кертергә мөмкиндер. Үзебезгә тәнкыйтьчел бәяне без шундый язучылардан алабыз. Тәнкыйтьчел иҗатлар аркылы хәтта политикабызны тикшерәбез. Әдәбиятның конъюнктурага бирешмәүче вәкилләре, гомумән алганда, җәмгыятьне үзгәртеп корыларга әзерләште. Бездә дә бар алар. Югарыда телгә алынган «гаугалы» әсәрләрнең авторлары Ә. Еники белән А. Гыйләҗев, мәсәлән, җәмәгатьчелек намусын яхшы мәгънәдә тынычсызлап торган әдипләр рәтенә кермиме? Үз-үзен аямаучы М. Зариповның һөҗүмчән публицистик әсәрләре?! Язучының шактый еллар дәвамында үҗәтлек белән үткәрелгән идеяләре бүгенге көндә бара торган илкүләм үзгәрешләрдә чагылыш тапмыймы? Драматург Д. Вәлиев әсәрләрен күзаллагыз... Күптән түгел генә үзебезнең сатирик мирас белән янә танышып чыгарга туры килде. «Үзгәрмәс» С. Баттал белән Г. Афзалыбызга сокландым. Батулланы да укыдым. Шактый еллар элек иҗат ителгән сатира үрнәкләре бүгенге шартларда язылган яңа әсәрләр кебек яңгырый!.. Мондый мисалларны китерүне, әлбәттә, дәвам итәргә буладыр. Әмма ике йөзләп язучыбызның барысын да әлеге исемлеккә кертү мөмкин түгел. Теләсәк тә булмый...

Бүгенге үзгәртеп корулар чорында, минем тоюымча, шундый берьяклы караш сизелә: һәрбер каләм иясе, имеш, **тамырдан** үзгәрергә тиеш. Тамырдан үзгәрү... Зурдан кубып әйтелгән әлеге таләп, әйтик, Еники кебек фидакяр әдипләргә кагыламы? Язучының тайпылышсыз акылы иман яңартуга мохтаҗмы? Айтматов тамырдан үзгәрсә, аны иртәгә укырлармы? Олуг талантлар, гомумән, метаморфоза кичерәме? Бәхәсләшергә дә мөмкиндер. Дөньяга караш мәсьәләсендә, әлбәттә, төзәтмәләр инкяр ителми. Бүгенге үзгәртеп кору шартларында талантка яңа мөмкинлекләр ачыла. Камилләшүдән туктамаган талантка!.. Халтурачыларга?! Тамырдан үзгәрү исә менә кемнәргә кирәк. Әмма аларның «төзәлүенә» өметләнү чираттагы беркатлылык күрсәтү генә. Алхимиктан алтын көтмиләр. Уртакул каләм иясенең күренекле әсәр язуы шикле. Ышанычның зурысы, димәк, талантлы язучыларда! Ничек кенә сәер кабул ителмәсен, үзәктә һаман алар булырга тиеш! Болай әйтүнең сәбәбе шулдыр: кагылып йөртелгән талантлар байтак. Югыйсә һәрбер талант иясенә, Ленинча әйткәндә, «булышлык күрсәтеп торырга кирәк». Ә реаль тормыш шартларында, дөресен әйтик, һәрдаим алай булмый шул. Ярдәм итәсе урында, киресенчә, таяк тыккан очраклар шактый. Мисал китереп тормыйк. Үзебез дә беләбез. «Инде булышлыкларын көтмибез, ичмасам, комачауламасыннар иде...» Гаҗәпләнмик: шундый уфтанулы сүзләрне дә ишетергә туры килгәли... Әдәби хуҗалыгыбыз эшчәнлеген, димәк, тамырдан үзгәртү кирәк! Монысы бик тә зарур. Илкүләм тамырдан үзгәртү кирәк. Иҗат союзларының моральпсихологик климаты инде күптәннән заманча сафландыруга мохтаҗ. Оештыру-иҗат эшчәнлеген дә тәрләндерү таләп ителә. Барлык иҗат көчләрен тыгызрак туплау сорала. Әһәмиятле мәсьәләләрне чишкән чакта кайчак бердәм фикерлелек җитенкерәми. Берәр төрле сафландыргыч сөйләшү оештырып булмыймы икән?! «Язучы. Шәхес. Культура»... Көндәлек матбугат битләрендә, әлеге факторларны үзәккә алып, фикерләшергә мөмкиндер югыйсә. Кайвакытта дискуссия темаларын файдалылыктан чыгып сайламыйбыз. Савыктыргыч сөйләшү, минемчә, күптән өлгерде. Югыйсә кайбер кеше-

леклелек сыйфатлары «антикварлык» рәвешен ала башлады. Өлкән буын вәкилләре сирәгәйгән саен, бездә илгәзәклек саега бара төсле. Күңел тарлыгы эчне пошыра. Тел очыннан бал тамызучы, күңелендә сумала кайнатучылар күп. Иҗатташыбыз уңышы өчен ихлас сөенә белмибез. Эчкерсез ярдәмчеллекне үземчелек кысрыклый. Үзара яну җитми. Шушы урында мәрхәмәтсез паралич белән богауланган Ф. Әмирханның «үлемнән качып кергән» Г. Тукайга эчке эндәшүе ишетелгәндәй була: «— Мә, Тукай, ал минем таза үпкәләремнең берсен, берәр үпкә белән дә дөньяда торырбыз әле...» Мондый мөнәсәбәтне аңлатырга сүзләр таба алмыйм.

Туфаныбыз еракта сәяхәт итеп йөргән чакта дуслары аның беренче китабын төзеп чыгаралар. Автор үзе белми дә кала. Без әлеге классик мисалны җае килгән саен искә алабыз, әмма үзара мөнәсәбәт мәсьәләсенә бәйләнешле асылын аңлап җиткермибез күк. Хәзер игелеклелек максаты белән «урлап» чыгару очраклары бармы? Мондый сорау куелышы күпләрдә елмаю уятадыр. Шундыйрак очрак, хәер, тагын кабатланган. Егерме еллап элек Рәшит Әхмәтҗановның беренче шигъри җыентыгын, үзе армиядә чакта, Әлмәттән Г. Ахунов белән Ә. Маликов китап нәшриятына төзеп тапшырган. Мондый «сәер» очраклар бүтән булмады бугай...

Көндәлек тормышта очрый торган кайбер әхлаксызлык күренешләре турында сүз чыкса, минем бер иптәшем Тукайча турылык белән әйтелгән мондый сүзләр кабатлый: «Көнчелек, үчлек белән тулган татарлык, Төяп илтеп Мәкәрҗәгә сатарлык...» Мондый кискенлек белән әйтү, дип каршы төшәм мин, бүгенге көндә ярап бетмәс. Туган халкыңны, дим, яратырга кирәк. Шундый җавап ишетәм: «Шагыйрь әлеге катгый дәгъвасын үлеп ярату белән белдергән. Һәм мин дә... Яратуымнан гына кабатлыйм». Шагыйрь сүзләрен бүгенгегә бәйләп искә төшерү, барыбер, күңелдә әллә нинди уңайсыз хисләр кузгата. Һәм уйландыра да. Менә шушы юнәлештә үзгәрү кирәк безгә. Үзара мөнәсәбәтләрдә тамырдан үзгәрү. Әдәби хуҗалыкны «талантларга уңай рәвештә» үзгәртеп кору... Яхшы әсәрләр тудыру өчен өстәмә мөмкинлекләр шунда түгелме? Халтурачыларның үзгәргәнен көтеп, тагын берьяклылыкка ташланмыйк. Ә талантлар бездә җитәрлек бит!

Икенче чиккә ташлану... Ниндиләренә генә бирелмәгәнбез! Тема актуальлеген аңлауда да берьяклылык күрсәтеп алдык. КамАЗ турында язарга тырыштык. Тәзелеш елъязмасына охшаш төссез әсәрләр ишәйде. Хәзер АЭСка, КамТЗга чират җитте. Халыкның хезмәт батырлыгы һәйкәлләрен, әлбәттә, сәнгатьтә мәңгеләштереп калдырырга бурычлыбыз. Әмма нигә әле мондый социаль заказларның икенчерәк пландагы мәгънәсенә ныграк басым ясала? Чакыруны берьяклы аңлыйбыз һәм берьяклы тормышка ашырабыз. Кеше рухы проблемалары (сәнгатьнең төп проблемалары!) игътибардан читтәрәк кала. Күп кенә очракта әсәрләребездә гәүдәләндерелгән кеше үзен характеры булмаган роботтай хис итә... Иҗат эшендә тема, сүз дә юк, зур әһәмияткә ия. Әмма барысы да талантка бәйле. Чын сәнгать әсәре, хрестоматиядә әйтелгәнчә, һәрчак актуаль була.

Кайчак шулай да уйлап куясың: бер чиктән икенче чиккә ташлану безнең гомерлек «юлдаш»ка әйләнде, ахры. Ниятләгән һәрбер эшебез шуннан башлана шикелле. Эчкечелеккә каршы көрәш җәелдердек. Икенче чик шаукымының нәтиҗәсе инде сиздертә дә башлады. Административ чаралар белән артык дәрәҗәдә мавыгудан яман чир эчкә куыла. Тыюга ныграк басым ясау — җиңелрәк юлдан бару түгелме? Гасырлар буена өйрәнелгән гадәтне кинәттән юкка чыгарып булмый. Гадәтне бәреп чыгару, ай-һай, җиңел эштән саналмый. Тәрбия программасы кирәк! Сәламәт буын тәрбияләү бурычын без аеруча игътибарда тотарга тиешбез.

Бәргәләнүләр... Милли мәктәпләрнең кыскаруы да берьяклылык шаукымыннан килә. Татар теле белән, янәсе, ерак барып булмый. Шулай уйлаучы ата-аналар күбәеп китте. Менә шундыйларның «инициативасы» нәтиҗәсендә, сыңар канатлы балалар үсә. Берьяклы фикер йөрткән ата-аналарга әдәбият сөюче Г. Хәмидуллинның мондый сүзләрен ишеттерәсе килә: «Ә менә безнең Якуб Чанышев мәдрәсәдә укып та генерал-лейтенант булган бит!..»

Туган тел варисларының кимүе, билгеле, башка сәбәпләргә дә бәйле. Үзебез дә гаепле. Заманга гына сылтамыйк! Совет халкының интернациональ ныклыгы милли телләрнең үзьяшәешлегеннән тора! Телсез халык булмый. Теле барның юлы бар. Моңа берьяклы карамаска кирәк.

Халык язмышы турында фикер йөртү, әлбәттә, берьяклы гына булырга тиеш түгел. Шуңа күрә дә ул халык язмышы. Ялгышлар да булгалый. Эшләмәгән кеше генә ялгышмый. Башлап юл салучылар чалуларга да мөмкин. Каршылыклар да җитәрлек. Тормышыбызда калкып чыккан киртәләрне, дөресен әйтик, әһәмиятсезгә са-

наган чаклар булгалады. Аларны уңышлар да каплап китколәде. Каршылыклар асылын тирәнтен өйрәнмәдек. Яшәеш куйган проблемаларга кул селтәүчеләр күбәеп китте. Язучылар арасында да... Теге вакытта кечкенә авылларны бетерүгә каршы катгый төстә дәлилле ризасызлык белдерелмәде. Арба ватылгач, юл күрсәтүче күп булыр. Инде эш узгач, әйе, чәчрәнүләр күп булды. Әле хәзер дә дәвам итә. Барыр юлыбыздагы һәртөрле чалуларны без еректан күрергә бурычлы югыйсә. Тискәре тенденцияләрнең көчәю куркынычын вакытында тәнкыйтьчел бәяләү, Ленинча әйткәндә, «ялгышны төзәтү чараларын игътибар белән тикшерү» кирәк. (Җәмгыять белеме дә тормышка якынайсын.) Бу җәһәттән демократиянең һәрьяклы үсеше үзаңны камилләштерүдә бинаһая мөмкинлекләр ача. Катлаулы проблемаларны халык белән бергә өйрәнү, бик акрын булса да, даимилек төсен алучы гадәткә әверелә башлады. Илкүләм киңәшүнең зарурлыгына инандык. Хәбәрдарлык нәтиҗәсен күреп торабыз. Халык фикеренә, стратегиябезне билгеләшүче коллектив акылга, ярыш шартларында, күрелмәгән киңлекләр ачылды. Әөек халык таланты чиксез ачышларга сәләтле ул.

Шәһәр урамнары буйлап хәрәкәт итүче машиналарның элегрәк сигнал бирешкәнен һәркем хәтерли. Урам тулы тавыш иде. Сигнал бирү тыелды. Колаклар иллә рәхәтләнде! Үзара шау булдырмыйча да хәрәкәтләнеп була икән. Тәҗрибә шуны күрсәтте. Шушындый кирәксез шау-шулар башыбызны күпме миңгерәтә! Тел тегермәнен файдасызга тартучылар, кысыр тавыктай кытаклаучылар күп. Әйткәнен иңендә күтәрергә сәләтсез телдәрләрнең «перестройка» төшенчәсен таушалдыруына ирек бирмик! Күп сүзнең, борынгылар әйтмешли, хатасы күп. Күпсүзлелек акылны үшәнләндерә. Фикерләү торгынлыгына бирелү куркыныч гамьсезлеккә китерә. Мисалын хәтсез күрдек. Сүзебез илнекенә берексен. Уйлап сүз әйтик, уйлап эш итик. Хәлне бетерә торган тайпылулар мөмкин кадәр азрак булсын.

Шушы уйлануларыма нокта куяр алдыннан Тукайны искә төшереп үтәсе килә:

Уңга, сулга аумыйм, һәнүз алга барам,
Юлда манигъ[1] күрсәм, тибәм дә аударам...

[1] Манигъ — каршылык, киртә.

**Р. С. Хәмәдиев,**
КПССның Минзәлә райкомы беренче секретаре

# БАРЫЙК ӘЛЕ МИНЗӘЛӘГӘ!

Безнең Минзәлә өч ягыннан су белән чикләнгән ярымутрауга урнашкан. Түбән Кама ГЭСы төзелгәннән соң борынгы Чулман, тынгысыз Ык һәм салмак агышлы Минзәлә елгалары кушылып, бер ярыннан икенче яры күренмәгән биниһая олы сулык хасил булды. Аның дулкыннары шәһәр кырыннан ук дугайланып сузылган бетон ярларга, причалларга бәрелеп чупылдый.

Игелекле табигать Татарстанның төньяк-көнчыгышындагы бу шәһәрне беркайчан да мәрхәмәтеннән мәхрүм итмәгән. Җәй көннәрендә ул куе яшеллеккә, шау чәчәккә күмелә. Рәсми кәгазьләр раславынча, аңа 1584—1586 елларда нигез салынган. Оренбург губернасының белешмәлек-китабында да бу хакта шулай диелә. Ләкин Минзәләдән нибары унике-унөч чакрым ераклыктагы Дәвек авылы янында алып барылган тикшеренүләр исә кешеләрнең бу якларда безнең эрага кадәр үк яшәгәнлеге турында сөйли. Болгар дәүләте чорыннан калган кабер ташлары һәм тарихи истәлекләр, күп санлы риваятьләр дә Минзәлә шәһәре урнашкан җирдә бик борынгы заманнарда ук утрак тормышта яшәүчеләр көн иткәнлеген раслый.

Элек-электән матур һәм бай булган бу яклар. Менә шуңа күрә дә анда яшәүчеләр үзләренә яу белән килгән дошманның һөҗүмнәрен кире кагу өчен аяусыз көрәш алып барганнар. Ык һәм Минзәлә сулары арасындагы әлеге җирләргә князь Одоевский тарафыннан җибәрелгән гаскәриләр килеп утырган. Алар елга буендагы иң биек урыннарны сайлап алганнар. Төньяктан аларны — мул сулы Ык, ә көнчыгыштан биек һәм текә ярлы Минзәлә елгалары саклаган. Кыскасы, хәзерге Минзәлә хәрби күзлектән чыгып караганда, әһәмиятле пункт буларак та үсә, күтәрелә башлаган. 1781 елның 23 декабрендә, рәсми рәвештә, Минзәләгә шәһәр статусы бирелә. Унсигезенче-унтугызынчы йөзләрдә ул бик акрын үскән. 1836 елда шәһәрдә 4969 кеше исәпләнгән. Унтугызынчы йөз ахрына бу сан 6526 кешегә җиткән. Анда алты чиркәү, хатын-кызлар монастыре, авыл хуҗалыгы мәктәбе, хатын-кызлар гимназиясе, дүрт класслы училище, монастырь каршында хатын-кызлар мәктәбе, 60 урынлы больница, аптека, 4 врач, 6 фельдшер һәм 1 акушерка булган, сыра-бал кайнату, спирт куу, патока, шырпы, кирпеч заводлары эшләгән.

Шәһәр аша сәүдә юллары узган. Агыйдел һәм Кама елгаларында Әҗәкүл, Дербышка, Курья, Чаллы пристаньнары үсеп чыккан. Тора-бара Минзәлә өязе сәүдә өлкәсендә бөтен Россиядә күренекле урынны яулап алган. Шәһәрнең үскәннән-үсә баруы анда уздырыла торган ярминкәләр белән турыдан-туры бәйләнгән.

Уңайлы урынга урнашкан булуы Минзәләдә атаклы ярминкәләр үткәрүгә мөмкинлек бирә. Бирегә Казан, Мәскәү, Архангельск, Әстерхан, Нижний Новгород, Иваново-Вознесенск, Уфа, Оренбург, Пермь, Тула шәһәрләреннән, Украинадан, Себердән, Урта Азиядән, хәтта Ираннан кәрваннар агыла. Шәһәр мәйданнары һәм урамнарының күбесе шунда сатылган товарларның исемнәре белән аталган. Урман урамы, Ат һәм Печән мәйданнарының исеме әнә шулай барлыкка килгән. Төбәктә базар элемтәләре үскәч, Алабуга, Мамадыш, Буа, Минзәлә сәүдәгәрләре Идел-Кама су юлыннан тагын да тулырак файдалана башлыйлар һәм үзләренең капиталларын әйләнешкә киннән-кин күбрәк кертәләр. Ярминкәләр елга өч тапкыр уздырыла. Аларда нигездә тукыма, чәй, шикәр, күн, иләнгән сарык тиресе, май, бал, терлек белән сату итәләр. Узган гасырның сиксәненче еллары башында анда сатылган товарның күләме 10 миллион сум тәшкил итә.

Минзәлә бары тик ярминкә белән генә дан тоткан дип әйтү һич тә дөрес булмас иде. 1773 ел ахырларында Емельян Пугачев күтәрелеше турындагы хәбәрләр бөтен Идел буен һәм Кама аръягын иңли. Крестьяннар зур-зур төркемнәр булып баш күтәрүчеләргә килеп кушылалар. Минзәлә өязендә төзелгән пугачевчылар отрядына Әбҗәлил

Сөләйманов җитәкчелек итә. Шулай итеп өяз крестьяннары Пугачев восстаниесендә актив катнашалар.

Бу якларны патша властьлары тикмәгә генә «тынгысыз төбәк» дип атамыйлар. Владимир Ульянов катнашында Казан университетында узган сходкада катнашучылар арасында якташлары — университет һәм ветеринария институты студентлары — М. Дударь, А. Колесников, В. Касаткин, Н. Шемаев, А. Борецкийлар булуы белән минзәләлеләр бик хаклы горурланалар, профессиональ революционерлар — бертуган Иван, Эразм һәм Михаил Кадомцевлар, 1897-1899 елларда Казанда укып, аннары өч ел дәвамында Минзәләдә яшәгән һәм яшерен революцион эш алып барган, РСДРПның II съезды делегаты, искрачы Герасим Михайлович Мишенев истәлеген изге итеп саклыйлар.

1908 елда Минзәлә халкын бер зур вакыйга таң калдыра. Шәһәр төрмәсеннән РСДРПның Уфа сугышчан дружинасы членнары Михаил Кадомцев һәм Иван Головкин качалар. Качу планы әлеге сугышчан дружина членнары тарафыннан әзерләнә. Аны гамәлгә ашырганда Михаилның әнисенә гаять җаваплы эш тапшырыла. Ул РСДРП(б)ның Уфа комитеты тапшыруы буенча төрмәгә бомба һәм корал алып керә. Шулар белән бергә улы Михаилга йоклаткыч дару, акча һәм тимер кисә торган пычкы да бирә. «Ана» романын язганда, Максим Горький шушы вакыйгаларны да файдалангандыр, мөгаен. Чөнки ул чакта Иван Кадомцев Италиядә Капри утравында М. Горький янында яшәгән. Туганының язмышы белән кызыксынган язучыга ул Михаилның һәм әнисенең хатларын биреп тора. Әлеге хатлар хәзер Мәскәүдә Горький музеенда саклана.

Бертуган Кадомцевларның революцион эшчәнлеге «Зур Совет энциклопедиясе»ндә дә яктыртыла. Алар турында журналист И. Кашиц «Кыен таң» дигән повесть иҗат итә. Минзәлә урамнарының берсе хәзер Кадомцевлар исемен йөртә.

1917 елның 14 ноябрендә Минзәлә шәһәрендә крестьяннар, фронтовиклар һәм хәрби гарнизон солдатлары катнашында манифестация үткәрелә. «Бөтен власть Советларга!» дигән плакатлар күтәреп урам әйләнгәннән соң ревком бинасында Совет власте игълан ителә. Матвеевка, Иске Тамбовка, Николаевка һәм башка авылларда крестьяннар алпавытларның икмәкләрен, малларын тартып алалар, йортларын яндыралар. Күп тә үтми, Минзәлә ревкомы тарафыннан оештырылган халык комиссарлары советы һәм җир бүлекләре алпавыт җирләрен җәмәгатьләштерү эшен үткәрәләр. Декабрьдә Советларның беренче өяз съезды чакырыла.

Гражданнар сугышы елларында Минзәлә бернichә мәртәбә кулдан-кулга күчә. 1919 елның маенда гына ул тулысынча азат ителә. Акгвардиячеләрне тар-мар иткән гаскәрләрне соңыннан Советлар Союзы маршалы дәрәҗәсенә күтәрелгән В. И. Чуйков җитәкли. Революция елларында Минзәлә фронтка 8 мең партизан, 10 мең солдат бирә.

Октябрь революциясе җиңгәннән соң, В. И. Ленинның «Икмәк өчен көрәш — социализм өчен көрәш ул!» дигән тарихи чакыруына җавап итеп, 1919 елның 1 августыннан 1920 елның 1 августына чаклы өяздә 2 миллион 614 мең 220 пот икмәк, 1 мең тонна ит, май, яшелчә һәм төрле авыл хуҗалыгы продуктлары җыела.

Кайнап торган вакыйгалар өяз большевикларын көннән-көн чыныктыра бара. Бу вакытта оешмада нибары 12-15 ләп кенә коммунист исәпләнә. Ләкин аз санлы булуга карамастан, алар массаларны оештыралар, җир турында Ленин декретын тормышка ашыруга керешәләр, эре җир биләүчеләргә, революция дошманнарына каршы аяусыз көрәшәләр. 1918 елның язында куркусыз коммунист, оста оештыручы һәм оратор Миңнегәрәй Әхмәтшин һәм Николай Лямин инициативасы белән РСДРП(б)ның өяз комитеты оештырыла. Биредә Минзәлә өязенең хәрби комиссары Николай Лямин турында берике сүз әйтеп үтәсе килә. 1919 елда ул Хәрби академиягә укырга керә. Башка укучылар белән бергә аны да Урта Азиягә, басмачылар хәрәкәтен бастырырга җибәрәләр. Соңыннан Лямин Украина хәрби округының 7 нче корпусында штаб начальнигы була, Ленинградта Хәрби академиядә укыта.

Революция өчен кыю көрәшчеләр Г. Мельников, А. Железкин, С. Хөснетдинов һәм башкалар иң кыен вакытларда да югалып калмыйлар. Алар җитәкчелегендә минзәләләр Колчакка каршы фронтка дүрт отряд оештырып җибәрәләр, соңыннан алар бердәм коммунистик батальонга берләшәләр һәм Гражданнар сугышының легендар герое В. М. Азин җитәкчелегендәге 28 нче «тимер дивизия»нең 40 нчы полкы составына керәләр.

Өязнең үзендә дә тыныч булмый. Кулаклар һәм авыл байлары Совет властена каршы фетнә күтәрәләр. Бу аяусыз көрәштә яшь чекист, коммунист Михаил Степанович Головин һәм аның иптәшләре батырларча һәлак була. Хәзер Минзәлә урамнарының байтагы революция каһарманнарының исемнәрен йөртә.

Минзәлә коммунистлары һәм совет органнары җитәкчеләре Мәскәү белән, Ленинның үзе белән элемтә тоталар. Өяз ревкомы исеменнән Халык Комиссарлары Советына җибәрелгән телеграммаларның берсендә, мәсәлән, 1918 елда акгвардиячеләрдән чистартылган авылларның барысында да авыл Советлары, ярлылар комитетлары төзелүе һәм

хезмәт Ияләренең Совет властен хуплаулары турында әйтелә. Ленинга җибәрелгән икенче бер телеграммада икмәк хәзерләүнең торышы турында хәбәр ителә.

Владимир Ильич Ленин үзе дә бу төбәктә икмәк хәзерләү, сал агызу кебек эшләрнең торышы белән даими кызыксынып тора. Менә 1918 елның 18 июнендә җибәрелгән телеграмма:

«Минзәлә Советы председателенә.

Үзегез киптереп куйган салларны да, шулай ук Иделнең түбән ягына дәүләтнеке һәм дәүләтнеке булмаган такта яру заводларына барырга тиешле барлык башка салларны да шунда ук ирекле үткәреп җибәрергә. Бер генә очракта да бер генә төрле дә налоглар һәм салымнар алмагыз. Бу эш белән тоткарлык Совет Республикасына зур зыян китерә, моның өчен сез революцион суд алдында каты җавап бирәчәксез. Үтәлеш турында Халык Комиссарлары Советына телефон буенча хәбәр итегез.

Совнарком председателе Ленин.

Совнарком эшләре белән идарә итүче Владимир Бонч-Бруевич».

Егерменче-утызынчы елларда, башка барлык урыннардагы кебек үк, Минзәлә авылларында да социалистик үзгәртеп корулар, авыл хуҗалыгын яңача оештыру өчен көрәш башлана. 1929 елның ноябрендә Иҫке Красный Бор һәм Иске Мажын авыллары крестьяннарыннан колхозга алуны сорап күп санлы гаризалар керә. Шул ук көннәрдә Кузкәй волостендагы дистәләрчә авыллар күмәк хуҗалыкка оеша. 1930 елда инде тоташ колхозлашу башлана. Районга 30 трактор, 1 автомашина кайтарыла. Беренче МТС 1931 елда оештырыла. Ленинның кооперативлаштыру планын үтәү юлында район коммунистлары һәм активистлары В. Кривов, М. Вәлиәхмәтов, П. Рылов, Ф. Гурьянов, А. Березин кебекләр бөтен көчләрен һәм сәләтләрен биреп эшлиләр. Г. Батыршин, П. Новиков кебек фидакарьләр шул юлда корбан булалар.

Күмәк хуҗалыкның уңышлары озак көттерми: сугыш алды елларында районның уникe хуҗалыгы Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы күргәзмәсендә катнаша, ә Бөек Ватан сугышы елларында район дәүләткә 3 миллион 838 830 пот ашлык тапшыра.

Районда киң колач белән культура революциясе җәелдерелә. Беренче бишьеллыклар чорында дистәләрчә яңа мәктәп биналары, клублар, китапханәләр, уку өйләре төзелә, үзешчән сәнгать түгәрәкләре оештырыла, авылга радио кертелә, кинофильмнар күрсәтелә башлый. Районда яшәүче милләтләрнең барысы да үз телләрендә укырга мөмкинлек ала.

Кешеләрнең тормыш-көнкүреше елдан-ел яхшыра, матурлана, аң-белем дәрәҗәләре күтәрелә. Исемнәре халык теленнән төшмәгән кыр батырлары үсеп чыга. 1935 елда колхозчы-ударникларның Икенче Бөтенсоюз съездына делегат булып ат караучы Галимулла Юсупов катнаша. Мәскәүдән кайтышлый ук ул Әгерҗе районы колхоз председательләре киңәшмәсендә колхозларның үрнәк уставы турында чыгыш ясый. Шул ук елны «Кызыл Йолдыз» колхозы бригадиры комсомолка Рәхимә Нуриева яшь ударникларның Бөтенсоюз киңәшмәсенә делегат итеп җибәрелә (әлеге киңәшмәдә Татарстаннан нибары ике вәкил катнаша). Ил һәм халык алдында зур абруй казанган хатын-кызларыбыздан Зөһрә Закирова — РСФСР Верховный Советына, Фаизә Хәкимова Татарстан АССР Верховный Советына депутат итеп сайланалар.

Район хезмәт ияләренең киләчәккә планнары тагын да матуррак була, тик фашист илбасарларның изге җиребезгә хыянәтчел төстә басып керүе барлык матур уй-теләкләрне челпәрәмә китерә.

Бөек Ватан сугышы елларында минзәләлеләрдән унөч меңгә якын кеше хәрәкәттәге армиягә алына. Дошманга каршы батырларча, арсланнарча сугышалар алар. Менә 3 нче Белоруссия фронты политидарәсенең Татарстан сугышчыларының батырлыгы турындагы белешмәдән берничә юл: «Татарстан АССРның Минзәлә шәһәрендә туган, батарея командиры, партия члены, өлкән лейтенант Моратов Сабир Әхмәтҗан улы 1941 елның июль аеннан бирле фронтта. Дошманны тар-мар итүдә батырлык һәм ныклык үрнәкләре күрсәтә. Торак пункт өчен барган сугышларның берсендә танклар һәм үзйөрешле орудиеләр ярдәмендә немецлар дүрт тапкыр контратакага күтәрелделәр. Сабир Моратов пушкалардан туры наводка белән ут ачарга приказ бирде. Нәтиҗәдә немецларның ике танкы, берничә дистә солдаты һәм офицеры юк ителде. Бу сугышта күрсәткән кыюлыгы өчен Моратов I дәрәҗә Ватан Сугышы ордены белән бүләкләнде».

Якташларыбыздан биш кешегә — генерал-полковник В. Н. Гордов, капитан С. М. Тапиков, укчы рота командиры Г. М. Һадимөхәммәтов, лейтенант В. Г. Вәҗетдинов һәм сержант Ф. Г. Галиевкә Советлар Союзы Герое исеме бирелде. 2500 сугышчы илебез орденнары һәм медальләре белән бүләкләнде.

Ул авыр чорда хатын-кызлар, сугышка киткән ирләрен һәм туганнарын алыштырып, фидакарь хезмәт үрнәкләре күрсәттеләр. Тракторчы М. Никитина олы хезмәтләре өчен Ленин ордены белән бүләкләнде. Тракторчылардан М. Федорова, М. Попова, Л. Юсупова, агроном Н. Сөләйманова, Н. Әһлиуллиналарның тырышлыгына бөтен район сокланды. 1943 ел башында районыбыз республикага болай дип хәбәр итте: «Район колхозчылары-

ның шәхси запасыннан Кызыл Армия фондына 6000 пот ашлык җыелды. Самолет төзелешенә — миллион сумнан артыграк, танк колоннасы төзелешенә 2 миллион 250 мең сум акча тупланды. Акча җыю дәвам итә. «Кызыл Йолдыз» колхозы члены Хаҗи Әхмәтов самолет төзүгә бер үзе 100 мең сум акча бирде. Аның адресына Кызыл Армия Верховный Башкомандующиеның рәхмәте килде.

Сугыштан соң район хуҗалыгы кызу темплар белән үсә башлады. Минзәләнең һәм авылларның йөзе сизелерлек үзгәрде. Сугыштан соңгы 15 ел эчендә генә дә 1500 дән артык эшче һәм колхозчы өй туе үткәрде, шәһәрдә торак мәйданы алты мең квадрат метрга диярлек артты, урамнар асфальтланды, яңа парк һәм бакчалар барлыкка килде, һәйкәлләр калыкты.

Халык мәгарифе, культура, сәламәтлек саклау өлкәсендәге уңышларыбыз да сокланырлык. Районда 18 урта, 5 сигезьеллык һәм 24 башлангыч мәктәп бар. Балалар өчен 32 бакча һәм ясле эшли. Педагогия, медицина училищеларында, совхоз-техникумда, ике һөнәр училищесында, автомобиль мәктәбендә белем алырга мөмкин. Педагогия һәм медицина училищелары үзләренең ярты гасырлык юбилейларын үткәрделәр. Илле ел дәвамында педучилище 5260 укытучы һәм тәрбияче хәзерләп чыгарган. Алар үзләренә белем биргән укытучылардан Н. Котляровская, Я. Котляровский, В. Марченко, С. Гобәйдуллина, Я. Һадиев, Н. Тәлдәева, Э. Тәлдәев, В. Һадиев һәм башкаларның исемнәрен һәрвакыт зур ихтирам белән телгә алалар.

Минзәлә медицина училищесы ел саен 140-150 белгеч хәзерли. Ярты гасыр дәвамында биредә 7 меңнән артык белгеч укып чыккан.

Киләсе елда Минзәлә совхоз-техникумы үзенең йөз еллыгын бәйрәм итәчәк. Хәзер ул зоотехник-оештыручылар, агрономнар, умартачы-техниклар, бухгалтерлар әзерли. Ел саен 500 кеше анә шул белгечлекләргә ия була.

Районда һәм шәһәрдә формасы ягыннан милли, эчтәлеге белән социалистик культура үскәннән-үсә. Революциягә кадәр Минзәләнең үзендә бер халык йорты, бер китапханә булып, ул китапханәдә 10 мең данә китап исәпләнгән, аңа 300 кеше йөргән. Хәзер бездә 33 филиалы булган үзәкләштерелгән китапханәләр системасы, район Культура сарае, 17 авыл Культура йорты, 33 клуб, музыка мәктәбе, 17 культура-спорт комплексы эшли. Берничә колхозның үз тынлы оркестры, җыр һәм бию ансамбле бар. Н. П. Петров җитәкчелегендәге «Энтузиаст» киностудиясенә халык коллективы исеме бирелде, ул — үзешчән киносөючеләрнең Бөтенроссия смотры лауреаты. Культура төзелеше буенча районга берничә тапкыр КПСС өлкә комитеты һәм ТАССР Министрлар Советының күчмә Кызыл байрагы тапшырылды.

Театр сәнгате остасы, Г. Тукай исемендәге республика дәүләт премиясе лауреаты С. Өметбаев җитәкчелегендә оештырылган Минзәлә татар дәүләт драма театры хезмәт ияләрен коммунистик рухта тәрбияләүдә зур роль уйный. Театр бөтен Татарстан, Идел буе республикалары һәм өлкәләре тамашачыларына да хезмәт күрсәтә, Уралга, Себергә, Урта Азия республикаларына, Казахстанга һәм илнең башка районнарына гастрольләргә чыга. Бу коллективта РСФСРның атказанган һәм Татарстанның халык артисты Ә. Фәсхетдинов, ТАССРның халык артистлары Җ. Җиһаншин, М. Зәйнуллин, Ә. Җиһаншин, И. Бәдриева, ТАССРның атказанган артистлары М. Мостафин, Р. Мәрдеханов, Ә. Фәттахова, Ф. Зәйнетдинова, Р. Муллин, Ф. Бәдриев, А. Богатырев, И. Фәхретдинов, В. Нигъмәтуллина кебек сәхнә осталары үсеп чыкты.

1941 елда Минзәлә педучилищесында оештырылган хәрби-политик курсларда Муса Җәлил укыган. Аның сугышның башлангыч чорында язылган шигырьләре беренче тапкыр Минзәлә район газетасы битләрендә басылган.

Патриот-шагыйрь истәлеген мәңгеләштереп, училище бинасына мемориаль такта куелды. Анда Муса Җәлил музее ачылды. Шәһәрнең бер урамы һәм мәйданы, районыбызның бер колхозы шагыйрь исемен йөртә. Минзәлә урамнары шулай ук Муса Җәлилнең көрәштәше, аның язмышын тигез бүлешкән Абдулла Алишнең кайнар эзләрен саклый. Утызынчы елларда ул монда мелиоратор булып эшли, үзенең күп кенә шигырьләрен, мәкаләләрен бастыра.

Минзәлә — иҗат көчләренә бай төбәк. СССР Язучылар союзы членнарыннан хәзерге көндә Мәскәүдә яшәүче Валентин Ерашев, Вячеслав Шугаев, Иркутск шәһәрендә торып иҗат итүче Роман Солнцев (Ренат Суфиев), арабыздан бик иртә киткән Газиз Мөхәммәтшин, укучылар күңеленә матур-матур шигырьләре һәм поэмалары белән үтеп кергән һәм республикабызның Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясенә лаек булган Марс Шабаев, шагыйрьләрдән Рәшит Гәрәй, Гөлшат Зәйнашева, Фәннур Сафин, Салисә Гәрәева, прозаик һәм драматург Габделхәй Сабитов шушы районда туып үскәннәр.

Минзәләләләр үзләренең якташлары, күренекле хирург, СССР Медицина Фәннәре Академиясе академигы, Ленин премиясе лауреаты, медицина хезмәте генерал-лейтенанты Владимир Николаевич Шамов, СССР Фәннәр академиясе академигы, Польша Фәннәр академиясе члены, Германия Демократик Республикасы Авыл хуҗалыгы акаде-

миясе член-корреспонденты Иван Владимирович Тюрин, медицина фәннәре докторы И. Ф. Харитонов, медицина фәннәре кандидаты, Татарстанның атказанган врачы, Минзәлә шәһәренең почетлы гражданы Э. Н. Огнева, Башкорт опера театры солисты Петр Михайлович Токарев, Мәскәүдә һәм Ленинградта яшәүче бертуган рәссамнар Вадим һәм Вячеслав Аксеновлар белән бик хаклы рәвештә горурланалар.

Соңгы егерме биш-утыз ел эчендә районда промышленность зур үсеш алды. 1959 елда Минзәлә нефтьчеләр шәһәре булып әверелде. Нефтьчеләр коллективында Социалистик Хезмәт Герое Ф. М. Шәрәфетдинов, Ленин ордены кавалерлары А. И. Мигачев, Т. М. Ильясов, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены кавалеры Н. Н. Киреев, Р. З. Хәбриев, А. Я. Павлов һәм башка бик күп уңганнар эшли. Идарә бөтенсоюз социалистик ярышында даими рәвештә алдынгы урыннарны яулый, берничә мәртәбә Нефть промышленносте министрлыгының һәм тармак профсоюзлары Үзәк Комитетының күчмә Кызыл Байрагына лаек булды. Ул хәзер Көнбатыш Себер нефтен үзләштерүдә катнаша, ел саен Төмән җирендә 1 миллион 150 мең метрдан артык тау токымы бораулый. КПСС членнары Т. Ильясов һәм М. Әгъләмов җитәкчелек иткән бригадалар бишьеллыкның ике еллык планын 1987 елның май аенда ук үтәделәр.

Авыл хезмәтчәннәре дә сынатмый. Экономиканы үзгәртеп кору һәм яңарыш колач җәя. Партоешмаларның игътибарын беренче чиратта кадрлар белән эшләүгә, кеше факторына юнәлдердек. Фермаларда хезмәт һәм ял шартларын яхшыртуга, алдынгы тәҗрибәне киң куллануга, хезмәтне коллектив подряд нигезендә оештыруга, сменалы эшкә күчүгә игътибар артты. Терлекчелек йортларында ашханәләр, буфетлар ачыла, профилакторийлар булдырыла. Болар барысы да алда торган бурычларны хәл итүгә уңай йогынты ясады. Терлекчелектә специальләшү югары баскычка күтәрелде. Әгәр моннан ике ел элек районда һәр сыердан елга 3500 килограмм сөт саву турында сүз кузгатсаң, моңа беркем дә ышанмас иде. Ә хәзер нәкъ менә шул турыда сүз йөртәбез. Чөнки адымнарыбыз ышанычлы. Өчмеңчеләр саны 136 кешегә җитте, алты савымчыбыз — дүртмеңче. Дүртмеңчеләргә хәзер утыздан артык кандидат бар.

Сөт мәсьәләсенә озаклап тукталуыбызның сәбәбе шул: элегрәк ул безнең иң кыен тармак иде. Хәзер исә аны иң алдынгы тармаклар рәтенә бастырырга омтылабыз.

Авыл хуҗалыгын туктаусыз үсеш юлыннан алып бару өчен хәл итәсе мәсьәләләр күп әле. Коллективларда хезмәтне бригада һәм гаилә подряды нигезендә оештыруны тәгәллисе бар. Кайбер фермаларда эшне механикалаштыру дәрәҗәсе түбән. Авылларда төзелешне нык җанландыру сорала. Шулай булмаганда, кадрлар мәсьәләсендә кыенлык кичерәчәкбез. Күршедәге төзелешләр, бигрәк тә КамАЗ төбәге эшче көчне үзенә күп алды. Хәзер исә авылларда эшче көчне саклау һәм арттыру таләп ителә. Моның өчен беренче чиратта яшәү һәм эш шартларын яхшыртырга тиешбез.

Район хезмәтчәннәре хуҗалыкның һәр тармагында зур бурычлар куеп, хезмәт традицияләрен лаеклы дәвам итәргә омтылып яши.

# ЗАМАН ҺӘМ ШИГЫРЬ

*Шигърият — кеше күңеленең иң кайнар хисләре елъязмасы булган шигърият — бүген ни хәлдә? Соңгы елларда басылып чыккан шигъри әсәрләрне укучылар ничек кабул итә? Замандашыбызның шигъриятькә карата нинди таләпләре бар?*

*Менә шундый бик күп сорауларга җавап эзләү максаты белән журналыбыз битләрендә «Заман һәм шигырь» дигән сөйләшү башлап җибәрәбез. Аны тәнкыйтьче* **Рафаэль Мостафин** *белән Татарстан китап нәшриятының* **баш редакторы, язучы Вакыйф Нуруллин** *әңгәмәсе ача.*

*Әлбәттә, бәхәс уртасына салынган мәсьәлә бу әңгәмәдә күзгатылган фикерләр белән генә чикләнми. Шуңа күрә, моннан соң сүз алучы укучылар, шагыйрьләр, тәнкыйтьчеләр «Заман һәм шигырь» темасын тагын да киңрәк һәм тирәнрәк итеп ачарга тырышсыннар, үзләрен борчыган уйларын язсыннар иде.*

*Журналыбыз битләрендә барачак бәхәскә рәхим итегез!*

РАФАЭЛЬ МОСТАФИН. Язучылар союзының партия оешмасы секретаре итеп сайлап куелганнан соң миңа әшебездәге күп кенә «авырткан урыннар» белән якыннан очрашырга туры килә башлады. Тулаем оешмабыз тормышындагы үткен проблемалар белән һәм аерым язучылар язмышындагы игътибар сорый торган мәсьәләләр белән... Вакыйф Нуруллович, менә Сез безнең язучыларны партбюрога күбрәк нинди проблемалар белән мөрәҗәгать итәләр дип уйлыйсыз?

ВАКЫЙФ НУРУЛЛИН. Монда инде уйлап та торасы юк, мин Сезгә шунда ук әйтә алам. Алар күбрәк нәшрияттан зарланып киләләрдер. Хәтта әле ничегрәк зарланганнарын да әйтә алам. Биш табак күләмендә китап чыгарган авторлар үзләренә ун табак бирүне сорыйлар. Ә китаплары моңа кадәр йомшак тышлык белән чыккан язучылар инде каты тышлык һәм яхшыртылган басма таләп итәләр... Бүген нәшриятка үзенең кульязмасын китереп тапшырган автор исә китабының өч елдан түгел, ә иртәгә үк басылып чыгуын тели...

Р. М. Әйе, нигездә Сез дөрес уйлыйсыз. Тагын Сезгә өстәп шуны гына әйтергә мөмкин: беренче китапларның дөньяга чыкканчы бик озак төрле кулларда йөрүенә дә еш зарланалар. Чынлап та, яшь автор җыентыгын эшләп бетергәннән алып китапның халык кулына килеп әләгүенә кадәр 5—6 ел гомер үтүне нормаль хәл дип санап буламыни? Бу әле эш әйбәт кенә барганда шулай. Ә яшь кеше өчен 5—6 ел вакыт ул нәрсә дигән сүз? Ул бит үзенә гаять озак булып тоелган бу чор эчендә борчылудан әллә ниләр эшләп ташларга мөмкин, әдәбияттан гомумән китеп барырга да мөмкин... Аннан соң яшьләребезнең күпләре әсәр төгәлләнгәннән соң, каләмне бер якка куеп, төрле инстанцияләргә чабарга да мәҗбүр була. Үзенең иҗади гомеренең иң яхшы елларын ул шулай әрәм итә, китабын үткәрү өчен йөри. Биредә мин Язучылар союзыннан китап нәшриятына һәм аннан кире союзга кайткан, ике арада бик озак йөргән байтак кына кульязмаларны мисал итеп китерә алыр идем... Әнә шуларның барысы турында да Сезнең белән бергәләп уйлансак иде.

В. Н. Тик, әйдәгез, башта ук бер бик мөһим нәрсәне ачыклап китик. Безнең нәшрият ел саен уртача ун-унбиш яшь авторның китапларын бастырып килә. Минемчә, бу аз түгел. Хәтта тик әдәби әсәрләр бастыру белән генә шөгыльләнә торган үзәк нәшриятлар да бу кадәр кешенең беренче китапларын чыгармый.

Р. М. Анысы бәлки шулайдыр. Ләкин менә әлеге авторлар чыннан да яшьләрме соң алар?

В. Н. Сез беләсез бит инде, әдәбиятка яше дә, карты да — барысы бердәй гашыйк. Бу очракта алар, авторлар буларак, безнең өчен барысы да яшьләр. Гәрчә алар

арасында инде чәчләре агарганнары булса да. Без бит Сезнең белән әнә шул беренче китап чыгаручылар һәм чыгарырга йөрүчеләр хакында сүз алып барабыз. Һәм бу җәһәттән мин Сезгә алдан ук шуны әйтеп китәргә телим: яшь авторларның беренче китаплары, әгәр алар сәнгатьчә эшләнешләре ягыннан җитлеккән булсалар, нәшриятта, Сез әйткәнчә, биш-алты ел ятмый, ә өч ел эчендә, бик күп булса, дүрт ел дигәндә басылып чыга. Мин аңлыйм, үз китабының дөнья күрүен көткән авторга өч-дүрт ел гомер дә аз түгел, әлбәттә. Ләкин, ышаныгыз, кулъязмаларның китап булып чыкканчы шулай озак тоткарлануы һич тә нәшриятның яшьләргә игътибарсыз булуыннан түгел, ә илебездәге барлык нәшриятларда да эшнең шулай куелышыннан килә.

Р. М. Ә ул эшнең куелышы кешеләргә бәйле түгелмени соң?

В. Н. Кешеләргә, әлбәттә, бәйле. Ләкин бу очракта ул сезнең белән безнең ихтыярдан тормый... Ә инде яшь авторларның кулъязмаларына килсәк, кызганычка каршы, аларның бишәр-алтышар ел басыла алмыйча торганнары да булгалый. Ләкин, кабатлап әйтәм, нәшрият хезмәткәрләренең игътибары җитмәгәннән түгел моның сәбәбе. Сез, әлбәттә, үзегез дә яхшы беләсез: Язучылар союзының иҗат секцияләре тәкъдименнән башка, нәшрият авторларның беренче китапларын планга кертми. Һәм болай эшләүне без дөрес дип саныйбыз: язучылар җәмәгатьчелеге үз араларына кемнәр килергә омтылганын белеп торырга тиеш. Беренче китабын чыгарырга җыенган авторларга алар үзләренең таләпчән сүзләрен әйтергә, бары тик киләчәктә перспективалы булганнарына гына үзләренең фатихаларын бирергә тиешләр.

Р. М. Шулай, әлбәттә. Ләкин иҗат секцияләрендә әсәрләре тикшерелү һәм уңай бәя алу белән яшь язучының мәшәкате бетми, ә башлана гына бит кайчакларда.

В. Н. Ләкин бит моңа да еш кына шул ук иҗат секцияләре сәбәпче була. Алар, яшь авторның тикшерелгән китабы өчен ни матди, ни әхлакый җаваплы булмаганлыктан, әле нәшриятта йөрү процессында китап эшләнеп бетәр, тиешле дәрәҗәгә җиткерелер дигән өмет белән еш кына очракларда әсәрләргә тиешенчә таләпчән карамыйлар һәм урта кулдан түбән кулъязмаларны да китап итеп чыгарырга тәкъдим итәләр. Менә ни өчен без үзебезгә килгән кулъязмаларны өр-яңадан рецензиягә бирәбез. Күп очракта ул әсәр тиешенчә эшләнеп бетмәгән була һәм без аларны авторларына эшләп бетерергә кайтарабыз. Бу хәл берничә мәртәбә дә кабатланырга мөмкин. Үзе катнашмаган бик күпләр күрми торган бу эш озак вакытны ала, күп көч таләп итә. Шуның аркасында кулъязма дөньяга чыкканчы берничә ел вакыт үтә.

Р. М. Шулаен ул бәлки шулайдыр да... Ләкин бит яшьләр менә нәрсәдән зарланалар: күп мәртәбәләр тикшерелгән, тиешле дәрәҗәгә җиткерелгән кулъязмалар чират көтеп ятканда, алардан йомшаграк булган икенче бер әсәрләр ниндидер юллар табалар һәм басылып та чыгалар. Иҗат секцияләре белми дә кала. Хәтта әле кайчакларда аларның фикере теге китапларны чыгармау ягында була.

В. Н. Бу җитди гаепләү, алайса әйдәгез, фактларга күчик. Сез конкрет кемне күздә тотасыз?

Р. М. Мәсәлән, Лениногорскида яшәүче Рамазан Байтимеровны. Аның «әсәрләре» турындагы әдәби җәмәгатьчелек фикерен сез үзегез дә яхшы беләсез. Р. Байтимеров — союз члены түгел һәм, минем белүемчә, аның кулъязмаларының иҗат секцияләрендә тикшерелгәне дә юк. Ләкин, шуңа да карамастан, соңгы биш ел эчендә ул үзенең өч җыентыгын бастырып чыгарды: «Туган ягым» (1982), «Җырларым — солдатларым» (1983) һәм «Канатларым» (1986). Китап исемнәре үзләре генә дә ни тора! Ә шәп тышлыкларга кызыгып алган укучыны китап эчендә ни көтә дисез? Шигъри сүзнең бәясе төшү әнә шуннан башлана түгелме соң инде?

В. Н. Конкрет мисалыгыз өчен рәхмәт... Ләкин бирeдә аерым очрак. Авыр очрак... Эш шунда — автор чынлап та игътибарга лаек кеше.

Р. М. Ә бирeдә поэзиянең ни катнашы бар соң?

В. Н. Сабыр итегез, әле мин фикеремне әйтеп бетермәдем... Ул бит үзенең танышлыгын һәм дуслыгын файдаланып бик күп язучыларны, бигрәк тә хөрмәтлеләрен һәм холкы белән йомшаграк әдипләрне йөреп чыга, үзе хакында кыска гына булса да, аллә ни мактамыйча гына булса да, фикер язып бирүләрен сорый. Һәм безнең күп кенә хөрмәтле әдипләребез аның элеккеге хезмәтләрен искә төшереп, бай тормыш тәҗрибәсен әйтеп язалар... Әле бәлки Сезнең үзегезнең дә аның турында язганыгыз булгандыр?

Р. М. Мин тискәре фикер язган идем!

В. Н. Кызганычка каршы, барысы да Сезнең кебек түгел шул. Үзләре турында үзләре әнә шулай уңай фикерләр җыялар да, Р. Байтимеров кебекләр иң югары инстанцияләргә яза башлыйлар, йөри башлыйлар. Ә бит бүтәннәр андый югары оешмаларга иң-иң кыен чакта гына бара! Шуннан соң инде безгә шылтыраталар: игътибарлырак була алмыйсызмы, диләр, чыннан да игътибарга лаек кеше бит, диләр.

Әле бу хәзерге демократия һәм ачыклык заманында шулай. Ә берничә ел элек эшләр башкачарак иде. Китап нәшрияты директорына югары оешмалардан шылтыраталар һәм ул шунда ук редакторны чакыра да: «Ничә табак күләм сорый соң ул анда? — ди.— Уникене?! Кара нинди әрсез! Ләкин шулай да, бер өч-дүрт табак сайлап алырга булмыймы соң? Фәлән шагыйрьгә бирегез, ярдәм итеп, кулъязмасын әзерләшсен. Шуның белән бәлки котылырбыз...» Ләкин бөтен бәла дә әнә шунда шул! Теге әрсез авторлар моның белән генә һич тә канәгатьләнмиләр. Бер китаплары чыккач, аяк терәп, мин язучы дип, тагын кулъязмаларын тотып нәшриятка киләләр. Гадәттә аларның икенче китаплары беренчеләреннән кайтыш була. Чөнки алар, үзләрен инде язучы санап, беренче китапларына керми калган чиле-пешле әйберләрен дә алып киләләр. Минем сүзгә ышанмасагыз, архив документларын карый аласыз. Шуның ише очраклар бездә аз түгел.

Р. М. Аңлавын аңлыйм да мин моны, ләкин килешәсе килми. Мондый мәсьәләдә йомшаклык күрсәтү — шулай ук гаепләнергә тиеш бит! Ләкин, әйдәгез, сөйләшүебезнең төп темасына әйләнеп кайтыйк. Гадәти шартларда яшь авторның китабын бастырып чыгаруга нәрсәләр комачаулый?

В. Н. Сез республикабыз районнарында еш буласыз. Анда йөргән чагында китап кибетләренә керәсездер. Һәм китап кибетләрендә өелеп яткан шигырь китапларын, әлбәттә, күрәсездер. Алар — беркемгә дә билгесез авторларның беренче, икенче, өченче китаплары. Китап сатучы оешмалар андый китапларны бастырып чыгаруга куллары белән каршы торалар — укучы аларны алмый диләр...

Р. М. Ә аларның укучы исеменнән сөйләргә хаклары бармы соң?

В. Н. Бар. Чөнки китапларны алар сата. Алар заказыннан башка нәшрият бер генә китап та чыгара алмый.

Р. М. Китапка гадәти товар дип кенә карарга ярамый бит инде! Барыннан да элек ул — рухи азык. Ул — идеология бит...

В. Н. Сезнең белән тулысынча килешәм. Ләкин китап та, сәүдә челтәренә чыккач, билгеле бер дәрәҗәдә товарга әверелә. Ә товар сатылмыйча ятарга тиеш түгел. Шуңа күрә без аны алучылар, ягъни бу очракта китап укучылар фикерен исәпкә алмыйча булдыра алмыйбыз.

Р. М. Ә менә ул фикерне белмәсәләр һәм хәтта бөтенләй өйрәнмәсәләр дә — ул чагында ни эшләргә?

В. Н. Бу инде икенче мәсьәлә. Ә ныклап уйлаганда, әлеге мәсьәләгә язучылар үзләре дә игътибар итәргә тиешләр иде, аның белән шөгыльләнергә тиешләр иде... Ләкин мин әйтә башлаган фикеремне дәвам итим әле. Сатып алучы беренче китапка, бигрәк тә шигырь китабына, салкынрак карый. Аз тиражлы бәләкәй китаплар типография өчен дә кулай түгел — эше бик күп, кереме бик аз. Безнең яшьләр исә үз китаплары өчен нинди тырышлык куелганын бөтенләй белмиләр дә.

Р. М. Әгәр шулай уйлаучыларга иярсәк, без бит беренче шигырь китапларын бөтенләй басмаска тиеш булабыз. Әйе, дөрес, алар — беренче шигырь китаплары — еш кына очракларда йомшак та, «кытыршы» да булалар. Ләкин бит Твардовский да, Хәким дә, Туфан да беренче китаплардан башлаганнар. Андый китаплар булмаса — әдәбият та үсмәячәк, күтәрелмәячәк. Бөтенесе тукталачак...

В. Н. Мәсьәләне алай ук драмалаштырмыйк әле. Сез атаган шагыйрьләрнең инде беренче китаплары ук бүтәннәрнекеннән яхшы якка нык аерылып торган. Ә бу очракта исә сүз чиле-пешле әсәрләр агымына каршы ничек итеп киртә куя алу хакында бара... Сезнең менә яшь авторның беренче китабын басып чыгару күпмегә төшкәнне уйлаганыгыз бармы?

Р. М. Күпмегә төшә инде?

В. Н. Әнә шундый һәрбер китап безнең нәшриятка якынча ике-өч мең зыян китерә.

Р. М. Ә конкретрак әйтеп булмыймы соң?

В. Н. Алайса, әйдәгез, исәпләп карыйк. Бигрәк тә хәзерге чорда, продукциянең үзен-үзе аклавы заман таләбе булып торганда, бу мөһим. Әйтик, 1986 елда без яшь шагыйрь Ю. Макаровның «Круг» дигән китабын чыгардык. Китапның күләме 1,9 табак, бәясе 20 тиен тора. Йомшак тышлык белән чыккан. Тиражы 1200 данә.

Бу китап дөнья күрсен өчен түбәндәге чыгымнар тотыла: авторга гонорар түләнә, китап рәссамнар тарафыннан бизәлә, аларга түләнә, нәшрият һәм типография чыгымнары тотыла, кәгазь бәясе өстәлә... Кыскасы, безнең телдә шаярып кына «профсоюз билеты» дип йөртелә торган бу юка гына китапчык өчен нәшрият 2 мең сум акча тотты. Ә аны сатудан керем бары тик 180 сум булды. Биредә инде, шәт, артык аңлатып тору кирәкмидер?

Р. М. Ә шулай да, минемчә, бу очрак бик үк типик түгел шикелле. Әлбәттә, «профсоюз билеты» тибындагы басмаларның авторга да, укучыга да берниндн шатлык

китермәве белән дә, экономик яктан файда бирмәве турындагы фикерегез белән дә килешәм. Шуңа күрә бит инде язучыларның һәр җыелышында диярлек китапны күбрәк тираж белән һәм калынрак итеп чыгару турында сүз бара. Хәтта беренче китапларны да!

В. Н. Калынрак итеп, күбрәк тираж белән, дисез сез. Бу — барлык язучыларга хас хыял. Ләкин бит китапның үзен-үзе аклавы аның ничә данә тираж белән чыгуыннан тора. Ә тиражны, кабатлап әйтәм, без билгеләмибез, китап сәүдәсе белән шөгыльләнүчеләр билгели. Безнең нәшриятта, мәсәлән, иң популяр шагыйрьләрнең китапларына да өч-дүрт меңнән артык тираж җыйналмый. Мин инде беренче китаплар турында әйтеп тә тормыйм. Аларга кайчак бер мең тираж да җыйналмый.

Хәтта шагыйрьләребезнең иң яхшы әсәрләрен туплап «Шигырь китапханәсе» сериясеннән дөнья күргән җыентыклар да дәүләтебезгә һәркайсы ун-унике меңгә төшә... Менә сез китапка гадәти товарга караган кебек карамаска кирәк, дисез. Барыннан да бигрәк ул — идеология, дисез. Күп кенә бүтән язучылар да шулай диләр. Барысы да дөрес. Китап ул — тәрбияче дә, совет кешеләренең дөньяга карашын формалаштыручы да. Ләкин бит идеологиянең тәэсир көче зур булырга тиеш. Ул кешеләрне үз артыннан ияртергә тиеш. Бу очракта мин укучыларны күздә тотам. Ә укылмый да, алынмый да яткан китап, гафу итегез, нинди идеология була ала соң инде ул?! Яшерен-батырын түгел, кайчагында бит бер генә мең тираж белән чыккан китап та тарала алмыйча ята һәм мондый очракта, икенче китапларын чыгару өчен, яшь авторлар сатылмый яткан китапларны үзләре алырга мәҗбүрләр. Чөнки бер китабың сатуда ятса, икенчесен планга кертеп булмый!

Р. М. Ә сезнеңчә ни өчен шулай килеп чыга икән соң?

В. Н. Аның сәбәпләре байтак инде. Ләкин башта мин китап тиражлары хакындагы сүземне бетерим әле. Әйтеп узганыбызча, аларны китап сатучы оешмалар билгели. Урыннардагы китап кибетләреннән һәм укучылардан килгән заказлар буенча билгели. Бәхәсләшмим, ул оешмалар һәр вакытта да, һәр китапка да, бигрәк тә яшь авторларга карата, тиешенчә игътибарлы булып бетә алмыйлардыр. Күп чагында безнең сатучыларыбыз язучыларны белми дә бит әле. Әнә шуңа күрә алар китапларга заказ биргәндә бик тә сак эш итәләр... Минемчә, безгә бирелә Язучылар союзының иҗат секцияләре фикеренә дә колак салырга кирәк түгел микән? Әлбәттә, аларга китапны басарга тәкъдим итү җиңелрәк. Әлбәттә, китапны халыкка таратуы басарга тәкъдим итүгә караганда кыенрак эш. Әле бит тагын шунысы да бар: тәкъдим иткән кеше һәрчак — яхшылык эшләүче булып кала. Ләкин... Ләкин без нәшриятның мөмкинлекләре чамасыз зур түгеллеген дә онытмасак иде шул.

Р. М. Мондый ситуациядән чыгу өчен Сез нинди юл тәкъдим итәсез соң?

В. Н. Иң элек, Язучылар союзының һәм аның секцияләренең яшьләргә карата
таләпчәнлеген бик нык арттырырга кирәк. Союз членнарын сан ягыннан үстерү
белән артык мавыгырга ярамый. Чын мәгънәсендә талантлы булган каләм ияләре
белән ныклабрак, җитдирәк итеп эшләргә кирәк. Ел саен союзга унар кеше кабул
итүне дөрес дия алмыйм. Сер түгел, аларның кайберләрен идарә әгъзалары идарәнең
союзга кабул итү утырышы вакытында гына күрә бит. Яшьләрнең союз тормышында
актив катнашуы, иҗат секцияләре эшендә һәм башка эшләрдә катнашуы да бер
дә артык булмас иде. Ул вакытта инде аларның иҗади мөмкинлекләрен дә, граж-
данлык сыйфатларын да төгәлрәк ачыклау мөмкин булыр иде.

Һәм тагын бер нәрсә. Әйдәгез әле без исәп белән яшәргә өйрәник, исәп-хисапны
онытмыйк! Теге яки бу китап җәмгыятькә нинди файда китерә, нәрсә бирә? Уку-
чыларга ни бирә? Һәм әнә шул китапны чыгару дәүләткә күпмегә төшә? Боларны
исәпләп карау мәсьәләгә байтак кына ачыклык кертә бит... Материаль өлкәдә генә
түгел, рухи яктан караганда да күп нәрсә ачыклана.

Р. М. Берничә ел элек мин «Литературная газета» битендә шундый бер тәкъдим
язып чыккан идем: беренче китапларны хәзергедән күбрәк чыгарырга, ләкин алар
өчен авторларга гонорар түләмәскә!

В. Н. Ә яшьләр үзләре Сезнең тәкъдимне ничек кабул иттеләр соң?

Р. М. Төрлесе төрлечә кабул итте. Бик кискен фикер әйтүчеләр дә булды. Яшь
авторларның хокукларын чикләүдә һәм хәтта аларны «таларга теләү»дә дә гаепләделәр.
Бу тәкъдимне тыныч кына кабул итүчеләр дә булды... Ә менә берәү «Книжное
обозрение» журналы буенча шуны исәплап чыгарган — безнең илдә елына 500 дән
артык беренче китап басыла икән. Аларга киткән чыгым ил буенча караганда миллион
сумга җыела икән! Каләм сынап караган өчен миллион сум... Бирелә бит әле мәсь-
әләнең икенче ягы да бар... Без үзебезнең яшьләребезне кеше җилкәсендә яшәргә
өйрәтмибезме соң? Ярар, беренче китап өчен алар акчаны аванс буларак та ал-
сыннар, ди. Ләкин бит бик күпләр ул авансны гомер буе кире кайтармыйлар. Әле
алай гына да түгел: китап чыгарган саен аларның дәүләткә китергән зыяннары
арта гына бара. Шушындый хәлдә нәшрият ничек итеп бәлмичә яши ала соң?

В. Н. Шөкер, безне классиклар коткарып килә. Аларга гонорар түлисе юк.

Р. М. Әйе шул, минем дә ишеткәнем бар иде. Муса Җәлил шигырьләрен бер мәртәбә бастырып чыгару да унлап яшь шагыйрь китабы ясаган чыгымны капларга җитә икән... Ләкин менә Сез үзегез гонорар түләмичә бастыру фикеренә ничек карыйсыз?

В. Н. Түлаем алганда, уңай. Әмма биредә әле бик күп нәрсәне уйлап бетерәсе, җәмәгатьчелек белән киңәшәсе бар — алагаем кизәнеп кенә эшне хәл итеп булмый. Әйтик, кемгә түләргә, ә кемгә түләми калдырырга — бусы да четерекле нәрсә... Аннан соң, Язучылар союзы члены булу әдәбияттагы уртакуллыктан саклап кала аламы? Ә бәлки авторлык гонорарларының да шкаласын үзгәртергәдер? Әйтик, без хәзер шигырь китабының авторына һәр юл өчен бер сумнан ким түли алмыйбыз. Әсәрләре моңа тартып җиткермәгәнне белсәк тә, киметә алмыйбыз. Ә нигә кайбер очракларда авторга юлына 30 яки 50 тиеннән түләмәскә?

Р. М. Ләкин без шунысын да онытмасак иде — шагыйрь кеше нинди генә түзем булса да, аның көн итәсе, ашыйсы, киенәсе бар бит әле... Бик күбесенең гаиләсе, балалары бар...

В. Н. Миңа калса, без еш кына очракларда шигырь сөючеләр белән, үзешчән иҗатчылар белән профессиональ поэзияне бутыйбыз шикелле. Ә алар бит — төрле әйберләр, принципта аерыла торган әйберләр. Әсәрләргә түләгәндә дә менә бу аерма сизелергә тиеш. Әле хәзер без куллана торган түләү тәртибе, кызганычка каршы, бу ике төрле иҗатны тигезли. Китаплары халыкка чынлап та кирәкле шагыйрь белән шигырь сөюченең хезмәтен тигезләп куя ул.

Р. М. Ләкин шулай да — яшь авторларның китабын күбрәк һәм яхшырак итеп чыгару буенча нинди чаралар күрергә мөмкин соң?

В. Н. Элегрәк сынап каралган ысулга — яшь авторларның китапларын бергә туплап чыгаруга яңадан кайтмакчы булабыз. Аларны бер тышлык эчендә туплап чыгаруны гамәлгә кертергә исәплибез.

Р. М. Элегрәк мондый алымны сынап карап, укучылар сатып алмаганга күрә баш тартканнар иде түгелме соң? Без бит китапны конкрет күз алдына китерәбез, аерым бер авторныкы итеп. Күмәк җыентыкларга карата укучыда ниндидер бер шикләнү бар...

В. Н. Анысы дөрес, болай эшләүнең начар яклары да юк түгел. Ләкин уңай ягын да күрми ярамый. Болай иткәндә без кыен сатыла торган кече форматлы китаплардан котылабыз. Ун-унбиш табак күләмендәге китапны каты тышлык белән һәм яхшы итеп бизәп чыгарырга мөмкин. Андый китапка китапханә киштәләрендә дә урын табылачак, чөнки ул озак саклана... Ә иң мөһиме, бу ысул берьюлы ун-унбиш авторның иҗаты белән укучыны оператив таныштыру мөмкинлеге тудырачак.

Әмма беренче китапларның тиражы һәм таралуы, барыннан да бигрәк, аларның авторларына бәйле. Аларның халыкка билгеле булуына, популярлыгына бәйле.

Р. М. Ләкин халыкка билгеле булу өчен аларга иң элек әсәрләрен бастырырга кирәк.

В. Н. Бик дөрес әйтәсез. Әсәрең басылмыйча популярлашу мөмкин түгел. Ләкин бит әсәрләрне китап итеп кенә бастырырга димәгән. Башта аларны газета-журналларда бастырып, радио һәм телевидение аша сөйләп тә пропагандаларга була. Һәм шулай эшләргә кирәк тә, минемчә. Югыйсә вакытлы матбугатта өч-дүрт шигырь бастырып, шуннан соң дүрт-биш табак шигырь күтәреп, нәшриятка килүче яшь авторлар да аз түгел бит.

Р. М. СССР һәм РСФСР язучыларының соңгы съездларында беренче китапларны, бигрәк тә беренче шигъри җыентыкларны, ротапринт ысулы белән һәм 300—500 данәдә генә бастырырга кирәк дигән тәкъдимнәр дә әйтелде. Болар инде сынау өчен чыгарылган басмалар булачак һәм, әлбәттә, аларга гонорар да түләнмәячәк. Мондый китапларның тиражы автор үз җыентыгын танылган шагыйрьләргә, тәнкыйтьчеләргә, газета-журнал редакцияләренә һәм инде билгеле дус-ишләренә җибәрә алсын өчен шулай аз куела. Әгәр инде әлеге китап уңай бәя ала икән, аннан соң аны гадәти юл белән дә бастырырга мөмкин... Бу тәкъдимнәргә Сез ничегрәк карыйсыз?

В. Н. Болай эшләүдә дә мәгънә бар. Ләкин мондый китапны чын мәгънәсендә китап дип атавы кыен инде аны. Бу шул ук кульязма дигән сүз бит, бары күбәйтелгән генә. Шуңа күрә әлеге тәкъдим турыдан-туры нәшриятка кагылмыйдыр. Мондый очракларда, минемчә, Язучылар союзына типографияләр белән бәйләнешкә керә алу һәм кульязмаларны күбәйтә алу хокукы бирергә кирәк.

Р. М. Кыскасы, без сөйләшкән бу мәсьәлә әдәбиятыбызның киләчәген билгели торган җитди мәсьәлә, шуңа күрә аны уңай якка хәл итү өчен төрле-төрле юллар эзләргә кирәк.

# ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

## Мансур Вәлиев

# КИЛӘЧӘККӘ КАЙТУ

*Онытма, Европа,*
*Бу минем илем —*
*Яртысы Азиядә, яртысы синдә;*
*Димәк, Европа, Татарстанның*
*Яртысы Азиядә, яртысы синдә;*
*Димәк, Европа, минем өемнең*
*Яртысы Азиядә, яртысы синдә;*
*Димәк, Европа, минем миемнең*
*Яртысы Азиядә, яртысы синдә...*

Мөдәррис Әгъләмовның яңа китабын («Киләчәккә кайту». Шигырьләр, балладалар, поэмалар. Казан, 1987) ачып җибәргән һәм әнә шундый сискәндергеч кәчкә ия булган юллардан башланып киткән поэмасы безнең Татарстан кешеләренең генә түгел, ә бәлки күңелләре һәм уй-хисләре белән дөнья өчен борчылып яшәүче миллионнарның да рухи халәтен чагылдыра. Ишетәсез, тоясыз микән — үзенең югары культурасы һәм купшы яңа модалары белән, бик күп бөек ачышлары һәм даһи укымышлылары белән мактанырга, горурланырга ярата торган Европага әлеге юлларда безнең шагыйребез нинди кырыс тонда эндәшә:

— Онытма, Европа!

Әмма без, бүгенге кешеләр, бу кырыслыкның сәбәбен бик яхшы беләбез. Европа егерменче гасырда гына да ике олы кырылышны — ике дөнья сугышын кабызып җибәрде. Шуның аркасында дистәләгән миллион халыкның җаны кыелды, чәчәктәй гомере өзелде! Җир йөзендә моннан да зуррак җинаятьнең булуы мөмкинме?! Безнең уйлавыбызча һәм шагыйрь фикеренчә, бүген Европа барыннан да элек нә шул турыда уйларга тиеш!

М. Әгъләмовның яңа китабы шулай итеп башта ук заманыбызның иң хәвефле кичерешләре эченә алып кереп китә. Җыентыкны ачып җибәргән әлеге поэма да гомум билгеле булган дежур сүзләр сөйләүче публицистик әсәр генә түгел. Европа белән ялкынлы сөйләшүгә шагыйрьнең авылдашы Шәйхинең дә, Шәрифәнең дә язмышлары килеп тоташа. «Үтерелгән бу кыз бала — ул минем сеңелем», «Үтерелгән бу ана — югары оч Миңнеш...»

Европаның бүгенге кешеләре дә поэманы укучыга реаль күзаллана: «Париж урамыннан атлап килүче Француз егете, ул әлмәк Безнең өстә... Без синең белән көрештек Татарстан башкаласы Казанда, айлы кичтә», «Чех кызы, исәнме! Фучикны тудырган Мәһабәт халыкның Бер кызы — Казанда Сәхнәдә калыктың...»

Әйе, Мөдәррис Әгъләмов поэзиясе дигән дәрьяның агымы сине бик тиз үзенә ияртә. Үзенә ияртә дә китаптагы тәэсирле шигырьләр, мавыктыргыч балладалар, драматик эчтәлекле поэмалар белән очраштыра. Аларда халык тормышы, кешеләр яшәеше киң һәм үзенчәлекле шигъри чагылыш таба. Китаптагы әсәрләрдә куплаган кешеләр гомерен алып киткән олы даулар да, алардан соң мәңгегә күз яшьле булып калган тол хатыннар да, ятим балалар да яши:

*Ә аның шикелле илемдә*
*Меңләгән хатыннар үләндер.*
*Онытма, кешелек,*
*Ул минем*
*Әнием иде бит,*
*Бердәнбер!*

Биредә тагын ирләр һәм хатын-кыз мәхәббәтенең, егет һәм кызлар мәхәббәтенең күп төрле төсмерләре дә: «Йортка кертү... Ярага тоз салган Шушы әче сүзләр өченме? Сөеп яшәмичә, үз иреңне Төнлә чыгып эзләр өченме?»

Монда шулай ук ир-атларның һәм хатын-кызларның һәркайсыныкы аерым трагедия дәрәҗәсенә күтәрелгән бәхетсезлеге дә: «— Акча салып, хатлар язып тордым, Шуның белән гөнаһ сипләгән. Балалардан оялырга иде, Балалардан... нәрсә җитмәгән?»

Әсәрләрдә бүгенге япь-яшь җаннарның үзара мөнәсәбәтләреннән туган тетрәндергеч халәтләр дә бар: «Сорама — ник болай, ник алай? Ярып бак җанымны урталай. Ярып бак, курыкма, эчкә кер! Тапмассың син анда шик-мәкер».

Һәм китапта халыкларның бөек уллары турында — Володя Ульянов, Тукай, Акмулла, Җәлил, Туфан турында шигъри уйланулар да: «Син ул булып кара», «Тукайдан хатлар», «Ут», «Акмулла арбасы», «Шагыйрьне озату» h. б. әсәрләр.

Китапта урын алган поэзия әсәрләрендә халык яшәешенең мәгънәле күренешләре белән очрашасың, аларны бөтен рухың белән кичерәсең. Әнә шул очрашулар вакытында шагыйрь иҗатының бер зур үзенчәлегенә дә игътибар итә барасың. Ул үз шигъриятендә тормышны үткәнгә, бүгенгегә һәм киләчәккә бүлмичә — аны бер итеп, бербөтен итеп карый. Күренешләр, вакыйгалар кайчан гына һәм кайда гына булсалар да, шагыйрь аларны бер үк яшәешнең чагылышы итеп күз алдына китерә. Укучы алдында чорларга, дәверләргә бүленмәгән зур бер тормыш җанлана. Гүяки төрле чорларның төрле кешеләре безнең алда бер тормыш кичерәләр, көрәш һәм уй-хис белән тулы бер гомер үткәрәләр.

*Давыллары хәтта берсен-берсе*
*Сүндермичә барган ялганып;*
*Әнә шулай Моабитка җиткән*
*Тукайлардан төшеп калган ут.*

«Ут» исемле шигырьдә әнә шулай бер-берсенә тоташкан давыллар бербөтенлекне, бер үк процессның дәвам итүен чагылдыра. Ягъни патша Россиясе чорында якты идеал өчен көрәшкән Тукайның һәм фашистлар тоткынлыгында кешелек ныклыгы күрсәткән Җәлилнең көрәшләре — асылда бер күренеш, дигән фикер үткәрә шагыйрь.

Инде без аңларга теләгән әлеге сыйфатны тагын да ачыграк күзаллау өчен авторның Володя Ульяновка багышланган «Син ул булып кара» шигыренә мөрәҗәгать итик.

*Һәр яшь кеше үз дигәнчә бара,*
*Үз дигәнчә якты юл сала...*
*Син ул булып юлга чыгып кара*
*Тик бер генә тапкыр булса да.*
*...Егерменче гасыр бетеп бара,*
*Килер гасырга мин ышанам,*
*Бүген миңа б а р ы п  җ и т ү  к и р ә к,*
*К а й т у  к и р ә к Кокушкинодан...*

«Бүген миңа барып **җитү** кирәк» — шигъриятнең образлы теле белән әйтелгән бу сүзләр нинди мәгънә **бирә**? Кинәт чыккан буран аркасында Кокушкинога бара алмыйча торуын гына әйтергә телиме биредә автор? Бары тик шуны гынамы?

Һичшиксез, иң беренче, иң гади мәгънә биредә әнә шул — юлга чыга алмый тору: «Аты да юк хәзер. Чор атлары — Бульдозерлар әнә юл сала». Ләкин без әлеге шигырьне укый-укый бик яхшы итеп аңлый, төшенә барабыз: бу әсәр зуррак нәрсә турында, кешенең олырак сәфәре — рухи сәфәре турында. Әсәрнең исеме дә әнә шуңа ымлый, «син ул булып кара» ди.

Димәк, биредә бүгенге яшь кешенең һәм гомумән безнең замандашыбызның Ульяновка таба юл тотуы хакында сүз бара. Тормышта, яшәештә аның сыман була алу хакында сүз бара.

Ә инде шигырьнең моннан соң килгән юлы «Кайту кирәк Кокушкинодан» хәзер безгә шактый җиңел аңлашыла. Биредә инде сүз Ульяновка барып җитә алган, ягъни халыкка һәм партиягә үзен аның кебек фидакарьләрчә, тулысынча багышлый алган кешенең бүгенге чор эшләренә тотынуы, аларны тормышка ашыра башлавы хакында бара.

Күрәсезме, «бару» һәм «кайту» сүзләре аша, бер шигырь аша шагыйрь төрле чорларны, төрле кешеләрне ничек оста тоташтырды. Гүя алар барысы бер заман, бер дәвер кешеләре! Гүя без бүген яшь Ульянов белән бер елларда яшибез!

Әйткәнебезчә, монда Мөдәррис Әгъләмов иҗатына аеруча хас булган бер үзенчәлек, бер сыйфат зур роль уйный. Шагыйрь биредә сәнгать көченең чорлар һәм

еллар каршында искерми, тоныкланмый торган дәрәҗәсенә ирешә. Ул кеше күңелендәге искә төшерү, уйлану һәм киләчәк турында хыялланулы — кыскасы, төрле вакыт яссылыкларын бер шигъри давыл итеп туплый. Элегрәк без күреп үткән «Ут» шигырендәге сыман, дөресрәге аннан да ныграк укмашкан, берләшкән хәрәкәт, процесс барлыкка килә.

Мондый бербөтенлек тойгысы кешеләр тормышында, социаль реальлектә генә чагылмый. Шагыйрь аны бөтен тереклектә, бөтен табигатьтә нечкә тоя. Үз тирәягындагы табигать гүзәллегенә исе китеп, сокланып торганнан соң шагыйрь «Үзе бөхет бит ул» исемле әсәрендә болай ди:

*Юк, түгел бу кошлар җыры гына,*
*Түгел кәккүк авазы гына.*
*Сине җиргә, күккә, тирәлеккә*
*Бәйли торган җепләр сузыла.*

Әнә, күрәсезме, нечкә тойгылы кеше ничек итеп табигый бөтенлекне тойды. Шул табигый гармония, бөтенлек уртасына ничек матур һәм ипле итеп, үзенең кайнар хисләре һәм тирән кичерешләре белән бергә кереп урнашты, шунда ипле яши башлады. Менә шушы күренеш, әнә шундый бөек берлекне, бөек бөтенлекне, олы гармонияне нечкә тою Мөдәррис Әгъләмов поэзиясен гаять камил итә, тәэсирле итә, көчле итә.

Ә «Шигърият» дигән әсәрендә шагыйрь шушы күренешне ничек тоюын болай тасвирлый:

*Тамырлардан актарылып менде,*
*Мине өскә,*
*Өскә әйдәде...*
*Күтәрелим дисәм, җиргә мине*
*ычкынмаслык итеп бәйләде.*

*Яфрак булып яуды иңнәремә,*
*Карлар булып җанга иңде ул...*
*Шуннан бирле шаулый,*
*шаулый,*
*шаулый —*
*Табигатьме?*
*Әллә минме ул?!*

Безнең уйлавыбызча, китаптагы барлык әсәрләрдә диярлек алга сөрелгән бербөтенлек тойгысы — яшәешнең үткәнгә, бүгенгегә һәм киләчәккә бүленмичә каралуы, шулай ук китапка исем итеп куелган төшенчәгә җавап — иң калку һәм иң ачык булып шагыйрьнең «Бары хәтер» шигырендә әйтелә.

Анда М. Әгъләмов башта: «Хәтер һич тә үткән генә түгел, Хәтер — синең киләчәгең дә» дигән поэтик идеяне үткәрә, нигезли дә шуннан соң менә мондый чагыштыру ясый:

*Юккамыни, бишегендә сыман,*
*Орлык ята гөл чәчәгендә.*

Күрәсезме, шагыйрь безнең игътибар үзәгенә «орлык» дигән төшенчәне китереп куйды. Орлык — ул үткәннең нәтиҗәсе. Орлык — ул киләчәкнең башы. Шулай булгач, димәк үткән белән киләчәк бер үк орлыкта очраша, кавыша дигән сүз бит! Алар бер тән, бер җан булып яши дигән сүз!

Ә социаль тормышны, кешеләр яшәешен алсак — анда орлык хәлендә без үзебез түгелме соң?! Һәр яңа буын кешеләре үткән һәм киләчәк өчен әнә шундый орлык, орлыклар кебек бит! Менә шул гаять мөһим мәгънә М. Әгъләмовның яңа китабындагы иң уңышлы әсәрләрдә үткәрелә. Без иләнгән рәвештә өчкә аерып: үткән, бүгенге һәм киләчәк дип йөрткән бүленешне шагыйрь үзенең иҗатына бөтенләй бүтәнчә итеп — бер үк күренешкә, бер үк вакыйгага өч яктан төшкән яктылык кебек итеп файдалана. Әнә шулай өч яктан төшкән яктылык — үткәннән, бүгеннән һәм киләчәктән төшкән яктылык — аңа бик күп күренешләрне, вакыйгаларны, шәхесләрне социаль һәм фәлсәфи яктан тирән, масштаблы яктыртырга, күп төрле бәйләнешләрдә, катлаулы диалектик халәттә һәм торышта күрсәтергә мөмкинлек бирә. Шагыйрьнең уңышлы әсәрләрендәге күренешләр һәм вакыйгалар, үзәккә алынган шәхесләр әнә шуңа күрә зур масштабка һәм киң полифоник эчталеккә ияләр.

...Шагыйрьнең яңа китабы...

Басылып чыккан һәр китабы әдәбият өчен вакыйгага әверелгән шагыйрьләр була. Мөдәррис Әгъләмов та, һичшиксез, безнең поэзиябезнең әнә шундый шагыйре. Кайчандыр күңелебезне кайнаткан уйларны яңадан өскә калкытыйк, искә төше-

рик... 1970 елда басылып чыккан «Кыңгырау» исемле китап дөньяга Мөдәррис Әгъләмов дигән өр-яңа шагыйрь тууын ышанычлы поэтик аһәң белән игълан итте... 1973 тә исә яшь шагыйрьнең «Учак урыннары» басылып чыккан. Ул елларда әдәби җәмәгатьчелек, поэзия сөюче яшьләр арасындагы кайнар-кайнар әңгәмәләр әле һаман да көчле түрендә... 1978 ел — М. Әгъләмовка иң җитди китапларыннан берсен — «Исәнме, йөрәк»не бүләк иткән ел. Шагыйрьнең дөньясы иң тирән һәм иң югары кайнарлыкта ачылган китап! Һәм инде менә 1987 елда — «Киләчәккә кайту»...

Шагыйрь турында Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Нәҗми һ. б. лар үзләренең зур фикерләрен язып чыкканнар. Аларның сүзләрендә олы өмет, олы ышаныч ачык чагыла. Югарыда атап үтелгән китаплар, чыннан да, поэзиянең җитди юлын лаеклы дәвам итүне раслый. М. Әгъләмовның шигъри дәрьясы куәтле агуны күрсәтә.

Ләкин тормышның һәр өлкәсендәге кебек Мөдәррис Әгъләмов поэзиясендә дә еллар узу белән үзгәрешләр бара. Шагыйрьнең китапларын янәшә куеп, яңадан һәм кат-кат укып карау әнә шуны күрсәтә.

Беренче һәм аннан соңрак дөнья күргән китаплар безгә шагыйрь йөрәгеннән ургылып бәреп чыккан хисләр ташкыны турында сөйли. Шул хисләрнең яшәеш күренешләре белән аралашкан кардиограммасын сурәтли. Әнә шул хисләр, шул ялкынлы көчел халәте беренче чор әсәрләренең бөтен асылын һәм эчтәлеген тәшкил итә.

Ә инде безнең кулдагы соңгы китаптагы күпчелек әсәрләрнең эчтәлеген көчел халәте, йөрәк хисләре генә тәшкил итми. Биредә инде тышкы дөнья, олы дөнья — чын һәм зур яшәеш күренешләре тулы көчләренә сөйлиләр, күрсәтеләләр. Ягъни поэтик эчтәлек күбрәк вакыйгалар, реаль күренешләр аша ачыла.

Шагыйрь иҗатында барган бу үзгәреш тенденциясен иң дәлилле итеп китапка кергән поэмалар, балладалар раслый. М. Әгъләмовның моңа кадәр чыккан җыентыкларында бер генә эпик әсәр дә юк иде. Ә бусында шагыйрьнең үзе тарафыннан эпик әсәр дип жанры билгеләп куелганнары гына да дүртәү. Асылда шулай ук эпик характерда булып, махсус билгеләнмәгәннәре дә шактый.

Ләкин «Киләчәккә кайту» китабын укыган вакытта эпиклык көчәю белән бергә икенчерәк төрле үзгәрешләрнең дә урын алуын сизми калу мөмкин түгел. Шуңа күрә менә хәзер, шагыйрьнең поэмалары турында сөйләшүгә күчкәнче, көчелне тырный торган әнә шул үзгәрешләр хакында да уйланып алырга кирәк.

М. Әгъләмовның беренче китапларындагы һәр шигырьдән ташып торган кайнар хис вулканы, кызганычка каршы, биредәге байтак кына әсәрләрдә суына төшкән. Җыентыкны ачып җибәргән беренче бүлектән соң андый шигырьләр китапта укучыга һаман ешрак очрый башлый. Ә инде 65 һәм 66 битләрдә урын алган «Синең экиятең» һәм «Тупыл» шигырьләре, 110 һәм 113 битләргә урнаштырылган «Барыбер» һәм «Әгәр бер кызны яратсаң» әсәрләре бу көчелсез күренеш хакында аеруча ачык итеп сөйлиләр. Менә бер өзек китерик:

*Яңа йортлар булып калка шәһәрдә,*
*Алып чыга океаннарга, галәмгә —*
*Шул мәхәббәт тудырган бер могҗиза*
*Яхшылыкка хезмәт итсә әгәр дә,*

*Чәчәк атар иде дөнья... Кешегә*
*Янәма үлем коралы булып.*
*..Күләгәсе кара булып төшсә дә,*
*Ак булып калыр барыбер ак болыт.*

«Барыбер» дигән шигырьдән китерелгән менә бу юлларны хәтта М. Әгъләмовныкы дип ышанасы да килми. Беренче китаплардагы көчле хисле, бер генә буш юл да бастырмый торган шагыйрь кая китте соң әле? Менә шуның ише шоп-шома һәм безгә, укучыларга, бер генә яңалык та китерми торган юллар ничек итеп килеп кергән аның китабына? Ә бит шигырьдә сүз мәхәббәт турында бара. Кешеләр өчен иң изге, иң кадерле булган хис хакында... Укучыларны зур кичерешләргә ымсындырган мондый җитди мәсьәләләргә шагыйрьнең җиңел карашын, әлбәттә, гафу итүе кыен.

Әйе, кызганычка каршы, йомшак әсәрләр дә байтак кына урын алган бу җыентыкта. Без башта сүз алып барган тирән фикерле шигырьләр янәшәсендә алар, андый әсәрләр, бигрәк тә ачык булып күренәләр. 64 биттә «Урманнарга кереп китә идең...», 72—75 битләрдә «Хәерле юл!», «Җиргә иминлек теләп», «Тукай көне», «Урлар дәшә киләчәккә» дигән шигырьләр бар... Укучы халне дөрес күз алдына китерсен өчен шагыйрьнең «Хәерле юл» дигән шигырен озын булса да тулысынча китерик:

*Керде январь... Илем туфрагына*
*Тәңкә-тәңкә карлар төшкәндә*
*Тик бер теләк: бөтен планетада*
*Икмәк булсын һәрбер өстәлдә.*

*Керде январь... Юк, кайтмасын кеше*
*Таш гасырдан чыккан чагына;*
*Яхшылыкка юллар ачсак әгәр,*
*Яманлыкка юллар ябыла.*

*Керде январь... Ул бит безнең өчен*
*Ак карлары белән кадерле...*
*Алып барсын сугышларсыз чорга,*
*Хәерле юл аңа, хәерле!*

*Керде январь... Ул гадәти сыман,*
*Ул гадәти, әмма асылда —*
*Тагын бер адымга капка ачу*
*Егерме беренче гасырга.*

*Керде январь... Шатлык алып килсен*
*Җир шарында барлык өйләргә;*
*Кешелеккә язсын тагын мең ел*
*Искә алып аны сөйләргә.*

*Керде январь... Дәвам итсен безгә*
*Сугышларсыз яшәр дәверне.*
*Ак канатлы бураннары белән*
*Хәерле юл аңа, хәерле!*

Укучыга шигырь дип тәкъдим ителгән бу язманы мөгаен һәркем һәм әнә шулай бик озак дәвам итә алыр иде. Дәвам итүен итә ала, ләкин һәркем булдыра алган дәрәҗәдәге генә иҗат инде бүген безне канәгатьләндерми. Андый әсәрләр безнең күңелләрдәге көчле рухи ихтыяҗларга җавап бирә алмый. Биредә шагыйрьнең көчле йөрәк хисе юк, күңеленең тулып ташуы юк! Ә алар булмагач — гадәти, тыныч халәттәге кешенең гадәти тыныч сүзләре генә — укучының игътибарын җәлеп итә алмый. Гәрчә анда матур-матур теләкләр белдерелсә дә!

Менә шушындый озын һәм көпшәк шигырьләрне укыганда инде бүтән әсәрләрдәге чын поэзиянең бәясен аңлый башлыйсың. Һәм менә шушындый әсәрләр белән очраша-очраша соңгы елларда ни өчен безнең шигырь китаплары азрак тарала башлавының да серенә төшенәсең... Чыннан да, барыбыз да белеп, аңлап торган элементар нәрсәләрне шигырь рәвешенә генә кертеп, көйгә генә салып сөйләп чыгу кемгә кирәк соң ул?! Аның бит беркемгә дә кирәге юк!

Әйе, танылган шагыйрь китабын рухланып, зур өметләр белән кулына алган укучы, кызганычка каршы, биредә яхшы әсәрләр белән бергә эче буш булган язмаларга да юлыга... Тик менә ни өчен андый әсәрләр Мөдәррис Әгъләмов кебек шагыйрьләр китабына да үтеп керә соң! Бу да безнең поэзиядә талымсызлык көчәюгә бер мисалмы? Соңгы елларда шагыйрьләребез арасында калын китап чыгарырга теләү, зур күләмле поэма язып, аны һичшиксез бастырырга теләү модасы киң таралыш тапты. Әнә шундый калын китап белән озын поэма авторы булу хәзер иҗат җиендәге ниндидер бер дәрәҗә, югары баскыч кебек карала башлады.

Шулай икән шул: озаграк вакыт дәшми торсак — яхшының яхшы икәнен, начарның начар икәнен әйтми яшәсәк — безнең яхшы дигән кайбер шагыйрьләребезнең китапларына да йомшак әсәрләр үтеп керә башлый икән. Таләпчәнлек кимүнең билгеләре китапларда бик тиз күренә.

Шагыйрь М. Әгъләмов үзенең «Урманнарга кереп китә идең» дигән юллардан башланган шигырендә болай дип яза:

*Гөлләр йөгерә, гөлләр кая чаба?*
*Кая таба чаба тугайлар?..*
*Бик күп нәрсә калды җырда гына...*
*Сөйләргә дә ярый...*
*Ни файда?..*

Ә бит табигатьнең әкренләп һәлак булу хакында безнең танылган шагыйребез эчкәрәк кереп, тирәннәнрәк актарып һәм укыган кешенең үзәге өзелерлек итеп яза ала иде. Ул вакытта инде бу шигырь ахырындагы шикелле битараф, тыныч һәм начар тенденция белән килешүне белгерткән «Сөйләргә дә ярый... Ни файда?» дигән сүзләр тормас иде. Андый шигырь язылган очракта ул инде безне тетрәндерер, озак вакыт исебездән чыкмас иде. Ул безнең күп нәрсәгә күзебезне ачар иде! Ә биредә шагыйрь хәтта үзенең битарафлыгы укучыга да күчүдән курыкмыйча, «ни файда?» ди...

Китаптагы кайбер әсәрләр (мисал өчен 115 битттәге «Безнең җыр» шигыре) хәтта бүтән авторларның шигырьләренә дә охшап китәләр:

*Син аны үзеңә диеп*
*Ышанып кабул иттең...*
*Еракка алып киттең дә,*
*Озын гомерле иттең.*

Бу көннәрдә бик еш ишетелә торган бер җыр сүзләрен хәтерләткән мондый юллар инде М. Әгъләмов китабына кермәскә тиешләр иде.

Логика аксап киткән һәм сүзнең, фикернең мәгънәсе чуалып китә торган әсәрләр дә очрый. Китапта әйбәт исем биргән «Киләчәккә кайту» дигән шигырьнең

үзендә дә — шагыйрь әйтергә теләгән поэтик мәгънәнең күп катлылыгын төшеп калдырмаган хәлдә — логик эзлеклелек җитеп бетмәвен әйтергә кирәк. Әсәрдәге эчтәлек тирәнлеген бит буталчык һәм томанлы фикерле юллар түгел, ә ачык шигъри күзаллаулар бәйләнеше тудыра!

«Киләчәккә кайту» китабын укыганда шундый кызыклы бер халәт кичерәсең: гүя бу китапка ике төрле шагыйрьнең шигырьләре, әсәрләре килеп эләккән дә — аларны ни өчендер бергә, аралаштырып биргәннәр. Бүлеп куймаганнар. Әле генә без сүз алып барган байтак кына уңышсыз әсәрләр гүя ниндидер бер билгесез авторныкылар. Тиз-тиз генә һәм шоп-шома иттереп кенә шигырь коеп куя торган шагыйрьнекеләр.

Ә китапның беренче бүлегендәге шигырьләр, аннан соңгы бүлекләрдәге уңышлы әсәрләр һәм балладалар белән поэмалар — болары инде безнең танылган шагыйребез Мөдәррис Әгъләмовныкылар! Аларны инде һичкемнеке белән бутап та, беркемгә биреп тә булмый! Бер китап мәнә шундый ике тойгы уята... Ике төрле шагыйрь белән очраштыра...

Поэмалар... Балладалар... Алар безнең укучыга нинди рухи азык бирә? Бүгенге шигырь сөючене алар нәрсә белән куандыра?

Җыентыкны ачып җибәргән «Онытма, Европа» поэмасы хакында алда сүз булган иде инде. Хәзер «Көтүче малай» дигән әкият-поэмага тукталып узыйк.

*Борын заманнарда түгел,*
*Борын төбендә генә.*
*Аваз салып кара малай*
*Якты дөньяга килә.*

Әкият поэма әнә шулай, чыннан да, халык әкиятләренә охшап: җиңел һәм житез агышта, мавыктыргыч вакыйгалар белән күңелне кызыктыра-кызыктыра башланып китә. Күрәсезме, беренче юлларда ук дөнья белән контраст бирелә — якты дөнья һәм кара малай. Бу инде укучыга кайбер нәрсәләрне әкрен генә сиздереп куя, аның күңелен сагайтып куя... Әсәр шулай әкият рәвешендә бара, ләкин анда бик тә тормышчан эчтәлек ачыла. «Көн үсәсен көн үскән, Ай үсәсен ай үскән» кара малайның язмышы җиңел түгел. Кара малай — ятим малай... «— Кеше булмас, бәхетсез,— ди Түбән очның Фәхриясе.— Ятим артса, бәхет кими,— ди арьякның Нажиясе». Авыл кешеләрендә кара малайга карата әнә шундый караш урнаша. Аның күп кенә балалык шуклыкларын да җиңел генә үткәреп җибәрмиләр әлеге апалар, усал телләре белән нәтиҗә ясап куярга ашыгалар...

Көннәрдән бер көнне авылдагы бу баладан котылыйк дип, кара малайны көтүче итеп куялар. Ул маллар туплап кырга чыга... Ә анда: «Сайрап җибәрмәсенме бер Туган якның сандугачы».

*Шунда үсмер телсез кала,*
*Җиргә бага, күккә бага.*
*Көтелмәгән кодрәт белән*
*Моң бәрелә күкрәгеннән.*

Поэманың менә шушы өлеше игътибарга лаек. Чөнки биредә сүз без исемнәрен яттан белгән бик күп бөек кешеләрнең язмышларындагы мөһим борылыш турында бара. Кечкенәдән үк тормыш авырлыгын татый-татый үскән җаннарның халык өчен бик тә кадерле шәхескә әйләнеп китүләре бу! Халык күңелендә ни барын, андагы моңны, аның рухи халәтен якты йолдыз сыман балкытучы алар. Шагыйрь биредә хезмәтнең иң югары ноктага күтәрелгәнен — иҗади яссылыктагысын ала. Ләкин менә бу җырчы егет язмышында безнең илебезнең бик күп хезмәт каһарманнары да үзләрен — үз язмышларын танырлар. Чөнки шагыйрь яшәү диалектикасын нечкә тоя: зур шәхесләрнең зур каршылыкларны җиңә-җиңә генә зурлыкка ирешүен сәнгать чаралары аша оста тасвирлый.

Әсәрнең ахыры ничек бетә соң дисезме? Авылдашлары — басуга эшкә чыккан әлеге усал телле апалар радиодан кара малайның җырлавын тыңлыйлар — «...Һәммәсен дә рухландырды Шушы җирнең бер бәндәсе».

Тормыш авырлыклары каршында кешенең сынмавы, киресенчә, аларны җиңә барып, үз яшәве аша рухи батырлык, башкаларга якты үрнәк күрсәтүе, кешенең бөеклеген раславы — М. Әгъләмовның башка поэмаларында да шигъри фикер үсеше әнә шул юнәлештә бара. «Көтүче малай» поэмасында без күреп үткән кара малай язмышы «Акмулла арбасы»нда тагын да югарырак баскычка күтәрелә. Биредә шәхеснең көрәше тагын да көчәя, конкретлаша һәм шул ук вакытта аның масштабы да киңәя.

Ләкин бу поэма һич тә бер Акмулла турында гына түгел. Чөнки М. Әгъләмов башта ук эчтәлекне киң һәм ерак тарихи фонда иңли, кузгалып киткәндә үк фи-

кер сөреше зур чорлар фонында бара. Поэманың һәр юлы әнә шул сәбәпле үткәнгә дә, бүгенгә дә карый:

*Шигырь язып Тукай булмакчылар,*
*Акмулла ул, әйе, тикмәгә*
*Үзе белән йорт салырга — корал,*
*Сабак өчен китап йөртмәгән.*

Бүген әдәбият белән шөгыльләнүче бик күпләргә үрнәк булып еллар аша бара, тәгәри бирә Акмулла арбасы... Ул арба өчкә бүленгән: аның беренче бүлегендә шагыйрь үзе утырып йөргән, һәм тагын — «янәшәңдә ике бүлек кирәк Шагыйрь булыр өчен иң элек»:

*Кара эшне сөю — беренчесе,*
*Икенчесе китап — җылы сүз.*

Шундый шигъри тәкъбирләр аша безнең алда халыклар хәтеренә озакка кереп калган зур шәхес образы гәүдәләнә. М. Әгъләмов үзе дә аның белән чын мәгънәсендә рухланган, чын илһам кичереп язган.

М. Әгъләмовның яңа китабындагы поэмалар арасында иң уңышлысы — укучыга иң тирән фәлсәфи һәм әхлакый эчтәлек алып килгәне — «Тукайдан хатлар» поэмасы. Бу әсәр шагыйрьнең олы проблемалар күтәреп, аларны оста, сәнгатьчә югары дәрәҗәдә хәл итә алуын раслый.

Тукай... Соңгы елларда менә шунысы да уйландыра: бүген бу кадерле исемне әйткәндә без һәрчакны да Тукайның гаять тирән мәгънәле тормышын, дөнья караңгылыгы белән кискен рәвештә бәрелешкән тетрәндергеч язмышын исебездә тотабызмы? Без, бүгенге рәхәт тормышта яшәп, әлеге исемне еш кабатлаучылар, Тукай язмышының, Тукай шәхесенең иң асыл, иң төп сыйфатларын онытмадыкмы — аларны хәтердән чыгармадыкмы? Без бүген Тукай юлына, Тукай рухына тугрымы? Һәм инде ахыр килеп: әдәбияттагы хәзерге иҗатчыларны егерме җиде яшендә якты идеал өчен көрәшә-көрәшә һәлак булган яшь-яшь Тукай белән янәшә куеп карау ниндирәк нәтиҗәләр бирер иде икән?

Бүгенге поэзия һәм аның тормыштагы роле турында уйланган саен һәрвакыт диярлек әнә шундый сорауларга килеп чыгасың. М. Әгъләмовның «Тукайдан хатлары» да күп төрле фикерләр кузгата. Төрле чорларны, төрле елларны, төрле шәхесләрне бергә колачлый торган уйлар, хисләр алар.

Поэма өчен реаль җирлек булып Тукайның төрле елларда төрле кешеләргә язган хатлары хезмәт итә. Унөч хаттан алынган унөч өзек поэма бүлекләренә рухи кереш, ачкыч ролен үти.

«Тукайдан хатлар» белән танышканнан соң күңелдә туган иң тәүге тәэсир, иң беренче фикер шундый — әсәр бөек шагыйрь образын аңлауда, күзаллауга алга таба атланган зур бер адым булып тора.

Биредә, бу әсәрдә, моңа кадәр бу темага язылган байтак иҗат җимешләреннән аермалы буларак, Тукай образы бер үк вакытта үз чорының конкрет җирлегендә дә һәм күп чорлар, күп гасырлар өчен хас булган, искерми торган мөнәсәбәтләр — әхлакый һәм фәлсәфи конфликтлар эчендә дә карала. Әсәрдә реаль Тукай образы белән лирик герой образы (ул да шагыйрь) бергә кушылу әнә шундый киң масштаблылык, монументальлек хасил итә.

Төрле чорлар һәм геройлар бергә ялгануның матур нәтиҗәсе буларак, әсәрдә гәүдәләнгән Тукай образы гаять үсә, күтәрелә. Әлбәттә, Тукай үзенең кыска гына гомере белән дә шигъри бөеклекнең гасырлар буена искерми торган үрнәген биреп калдырды. Бу факт үзе М. Әгъләмовка күпмедер дәрәҗәдә булышкан дияргә мөмкин... Ләкин ничек кенә булмасын — поэманың төп уңышы: халык шагыйренең зур һәм җанлы образын тудыруда.

Тагын шунысына да игътибар итик: күп гасырларга халык шагыйре булып калырдай андый образның нигезе өчен дә Тукайның үз сүзләре җирлек хасил итә — «Шат яратса да, җиһанга ят яраткан раббысы». Менә бу юлларда халыкның чын шагыйре булып туган моңлы җанның бар булган бәхете дә һәм реаль тормыштан, бүгенге көннән генә канәгать кала алмыйча гел алга, гел яңа матурлыкка ашкынган — шуңа күрә әле үзен бүгенге җиһанга ят итеп тойган нечкә күңелле трагик язмышлы җан да! Барлык зур шагыйрьләр язмышы өчен диярлек хас шушы үзәкне дөрес тотып алу: Тукай хакында шигъри фикер йөрткәндә аны нигез итү — поэмага уңыш китергән көчләрнең зурысы.

М. Әгъләмов күп кенә олы шагыйрьләрнең әнә шундый мәңгелек бәхетләрен һәм шул бәхет белән бергә үк, янәшә үк, икесе бербөтен булып йөргән мәңгелек трагедияләрен поэмасында реаль тасвирлый.

Әсәр Тукай гомереннән, аның ялкынлы хатларыннан кузгалып китә дә, сәнгатьнең бөек көче ярдәмендә халкыбызның Тукайга хәтле булган уллары язмышын да,

аннан соң яшәгән моңлы җаннар тормышын да бергә колачлый һәм, шуның аркасында, үзәккә, уртага куелган Тукай образының эчтәлеге гаять тирәнәя, киңәя.

*Тукай ераклашкан заманда*
*Азмыни ул көлеп йөрүчеләр*
*Тик шүрәле кытыклаганга.*

Күрүебезчә, поэмада «Тукайдан ераклашу» дигән сүз ул һич тә вакыт узуны, күп еллар үтүне генә белгертми. Бу сүз — чын, олы шагыйрьлекнең үзәк юлыннан читләшү, шуннан ераклашу дигән сүз. Мондый хәлләр һәрбер чорда булырга мөмкин. Әнә шуңа күрә, поэманың багышлау өлешендә үк укучының хәтеренә сеңәрлек итеп болай диелә:

*Тик сорала шигъри матурлыктан*
*Матурлыкта булсын батырлык!*

Бу юллар аша гына да әсәрнең бөтен ялкынын һәм рухи үзәген чамаларга мөмкин. Бер үк вакытта әлеге сүзләр төрле чорларда төрле хәйләләр белән шигъриятнең ялкынлы гражданлыгын киметергә теләүчеләргә карата кискен каршы төшү булып та яңгырый. Тукайлык, аның юлына тугрылык — чын шигърият, көчле шигърият — ул һәрвакыт Матурлык белән Батырлыкның бербөтен булган ялкынлы гармониясе дигән сүз!

Әсәрнең тагын бер зур уңышы шунда: бөек шагыйрьнең бөек батырлыгын ул үз халкының авыр һәм катлаулы көрәше процессында ача. Бу көрәш — самодержавиегә каршы көрәш, социаль гаделлек, чын ирек, рухи яңарыш өчен көрәш. Автор үз әсәрендә халык тормышын шактый киң планда тасвирлый, социаль күренешләрне һәм тенденцияләрне бар катлаулылыгында аңлый:

*Исереге дә шул, аегы да*
*Казаны да шул ук, Җаегы да.*
*Баер өчен җанын фида кылыр*
*Җае гына чыксын,*
*Җае гына...*

Поэманың «Учак сүнеп, тимер калачак» һәм «Җирдә апрель» дип исемләнгән бүлекләре халыкның революцион көрәшен югары шигъри дулкында сурәтләү белән аерылып торалар. Аларда бер яктан: «Ничә гасыр буе агып килгән Чүп тыгылган. Азмы шакшылар?!»— булса, икенче яктан: «Син, агымны туктатырмын димә, Актарылып чыкса, бер бәреп!»— дигән юллар.

Шагыйрь Тукай әнә шул ташкын, әнә шул көрәш эчендә, шуның уртасында булуы белән бөек һәм көчле!

*...Үз дигәнчә бара халык һаман,*
*Үз дигәнчә бара кешелек.*
*Казан өязендә кыссаң аны,*
*Ул Җаектан чыга бүселеп.*

*. . . . . . . . . . . . .*

*Син сөрәсең аны мәсләгеннән,*
*Ә ул урап бөтен җир шарын,*
*Бер гасыр да узмый, кире кайта*
*Эзләп тамырын, эзләп туфрагын.*
*Нишләтергә мөмкин бу халыкны*
*Җылаганда хәтта җырласа?*
*Ул барыбер кайта сөргеннәрдән,*
*Җырда кайта — ни дә булмаса.*

Әйе, М. Әгъләмов менә шундый шигъри юллары белән тагын бер мәртәбә раслый: шагыйрь үз халкының язмышы белән аерылгысыз бергәлектә генә, аның олы көрәше эчендә генә олы шәхес булып өлгерә ала, чын гражданин булып җитлегә ала!

Тукайның апрель аенда — бөек уяну вакытында башланып, апрельдә өзелгән гомере дә тоташтан язгы ташкын! Тормышны, дөньяны чистартучы һәм аны яңартучы, уятучы, сугаручы куәтле язгы ташкын ул Тукай һәм Тукай рухы! Поэма бездә шул ышанычны ныгыта.

«Тукайдан хатлар»... Әсәрнең исеме шулай куелган. Моның да сере, хикмәте бар. Юк, бу поэма шагыйрь хатлары турында гына түгел. Поэмада Тукайның бүгенгә төбәлгән йөрәге, күңеле. Поэма Тукайны бүгенге көнгә кадәр китереп җиткерергә тырышу. Тукай рухын бүгенгә ялгарга, кушып җибәрергә омтылу.

Шулай итеп без шагыйрьнең яңа китабын уку процессында төрле дәрәҗәдәге шигъри әсәрләр белән очрашабыз. Күргәнебезчә, аларның бер ишләре безне мавыктыра, дөнья һәм яшәеш турындагы яңа хис-кичерешләргә алып килә. Ә икенчеләре

исә «урта кул поэзия» дип йөртә торган дәрәҗәдә генә язылганнар. Ягъни артык тир түкми, авырлык күрмичә — җиңелчә, шома гына. Кайчакта «газета шигырьләре» дип тә йөртелә торган югарылыкта гына...

«Синең кулда каләм» дигән шигырьдә М. Әгъләмов үзенең поэтик декларациясен болай белдерә:

*Үз сукмагың!*
*Үзең салдың,*
*Беркем көчләп кертмәгән.*
*Карасы бетсә, каның бар —*
*Халкың тапшырган каләм!*

*Атаң-бабаң беркайчан да*
*Уракка кичекмәгән.*
*Син дә кырда. Синең кулда*
*Халкың тапшырган каләм.*

Менә бу юлларны укыган вакытта без шулай да чын шагыйрь, элекке китаплары аша без белгән шагыйрь Мөдәррис Әгъләмовка ныграк ышанабыз. Чөнки әлеге юллардагы ихласлыкны, фидакарьлекне, үз эшеңә, үз иманыңа тугрылыкны сизмичә, тоймыйча калу мөмкин түгел. Аларда ярсу хис, кайнар йөрәк авазы! Шигъри чагыштырулар да иң җитди халәттә, максимализм дәрәҗәсендә. «Язарга караң бетсә — каның бар», «Атаң-бабаң уракка кичекмәгән, син дә үз кырыңда шулай бул!» Иҗатка мондый караш, билгеле, укучының өметен арттыра.


Ә инде М. Әгъләмовның «Соңгы чиктә» дип исемләнгән һәм китапны ябып куючы шигыре безнең күңелгә тагын да хушрак килә:

*Ахыргача!*
*Ахыргача барам —*
*Юк калмады көчне саклар чама.*
*Чорлар аша хәбәр китерергә*
*Янып егылачак атлар чаба.*
*Яңа гасыр энә капка ача —*
*Ахыргача барам,*
*Ахыргача!*

**Әйе, бу ялкынлы юллар нәкъ менә без белгән шагыйрь юллары! Нәкъ менә Мө**дәррис Әгъләмов кайнарлыгы бу! Шуңа күрә без аның ахыргача барачагына ышанабыз. Хисләрне сүрелдермичә барачагына ышанабыз. Очраклы шигырьләр белән юлдаш булмас дип тә ышанабыз...

Чөнки... Чөнки «синең кулда — халкың тапшырган каләм»!

# Уфада культурабыз истәлекләре



**«Сабах» китап кибете урнашкан бина**

Свердлов һәм К. Маркс урамнары чаты

*А. Тимергалина рәсеме.*

# ТУКАЙ УФАДА

*Уфаларга барып кайтам,*
*Уфа юлы ачылгач.*

Оренбург, Әстерхан, Троицк, Уральск, Касыйм... Менә, Казаннан кала, революциягә кадәрге мәдәният үзәкләре. Моңа Уфаны да кушсак, XX йөз башындагы мул сулы татар мәдәнияте диңгезен әнә шул Җидегән чишмә туендырып торган дип әйтә алырбыз. Казаннан соң икенче урынга күбесе дәгъва итсә дә, ахыр чиктә атаклы «Галия» мәдрәсәсе, «Тормыш» газетасы, «Нур» труппасы һәм башка кайбер культура учаклары белән Уфа алга чыга. Татар төбәге чолганышында утыра торган кала өчен бу табигый хәл, әлбәттә. Агыйделнең һәм аның биек ярына урнашкан Уфаның татар халык җырларында еш телгә алынуы очраклы хәл булмаса кирәк.

Халык улы Тукайның да күңеле Агыйдел буйларына, Уфа якларына тарткан. Әнә бит ул 1912 елның язында, саулыгы начарланып киткәч, дәвалану өчен көньякка — Кырым яисә Кавказга китү мөмкинлеге булса да, Уфа, Троицк якларын сайлый.

Апрель урталары. Тукай, пароходка утырып, Казаннан чыгып китә. Самарада (хәзер — Куйбышев) бер кич кунгач, поезд белән Уфага килеп төшә. Менә ул бер үк вакытта көтепханә булып та хезмәт итә торган «Сабах» китап магазинында. Нияте — магазин мөдире, элеккеге танышы Хәбибрахман Зәбиридән җайлырак номер белешү. Әмма комфорт дигән нәрсәгә исе китми торган шагыйрь, склад хезмәтен үтәүче зур бүлмәнең җылылыгын һәм тынычлыгын ошатып, кунакханә дигән сүзне ишетергә дә теләмичә, шунда торып кала...

Тукай Уфада дигән хәбәр тиз таралып, күрешергә килүчеләр күп була. «Галия» укытучылары һәм матбага хезмәткәрләре дә, приказчиклар һәм кыюрак шәкертләр дә килә. Күп төрле сүз, уен-көлке һәм җыр-музыка. Кечкенә нәрсәдән дә зур мәгънә чыгара белә торган Тукай бу очрашулардан, һичшиксез, шактый мәгънәви азык алган. Гаҗәеп матур тавышлы бер хәлфәнең җырлавын онытылып тыңлаганның соңында ул, мәсәлән, башкорт халкының аянычлы язмышлары һәм киләчәге турында тирән уйларга чумган.

Әмма Тукайның Уфада үткәргән көннәренә ямь биргән төп кеше Мәҗит Гафури була. Түбә астында утырып ялыккач, алар ашыкмый гына, шәһәр урамнарында йөриләр, Губернатор бакчасына кереп утыралар яисә Агыйдел буендагы «Случевский сад»ка барып чыгалар. «Күбрәк сүзләребез,— дип яза М. Гафури,— шигырь вә шагыйрьләр, Казан һәм дә мохитыбыз хакында иде». Ике шагыйрьнең Казан турында, шигърият һәм аның Россия яңа давылларга таба барган чорда нинди эш башкарырга тиешлеге турында сүз алып барулары табигый. Мохит хакындагы сүзне Тукай тулыландыра. «Читтән безне караган кеше, икемезне әле генә хисапсыз каты шаярып, соңра аналары кыйнаган, бер минут элек кенә җылаудан туктаган балаларга охшатыр иде... Русиядә хәзер уйнаган җилләр вә Русия һавасы безнең бөтен коллегаларымызны шул халәте рухиягә китергән».

Уфада өч кич кунгач, Тукай, кымыз вакыты җитмәгәнен искә алып, Петербургка юл тота (аны хат белән чакырган булалар) һәм, анда ике атнага якын вакыт үткәргәч, «Сабах»тагы «резиденциясенә» кайтып егыла. Тагын визитлар, сөйләшеп утыру, музыка-җыр тыңлау. Вакытының күп өлеше тагын Гафури белән үтә башлый. Урамнарда йөриләр, бакчаларга баралар, яшел чирәмгә ятып кымыз эчәләр.

Истәлегендә М. Гафури болай ди: «Уфа Тукайның дәрәҗәсенә мөнасип һичбер хәрәкәт күрсәтә алмады». Үкенеч хәл, әлбәттә. Әмма игътибар үзәгенә эләгергә яратмый торган шагыйрь моңа үзе дә «гаепле» түгел микән? Кистереп әйтергә мөмкин: Тукай Уфага килүеннән канәгать булып киткән. Казах даласы ите, сөте, кымызы һәм саф һавасы белән көтеп торуга карамастан, икенче килүендә атнага якын Уфада калуын бүтәнчә аңлатып булмый.

Кыскасы, Уфа Тукай тормышында матур бер эпизод булган кебек, бөек шагыйрьнең торып китүе шәһәр тарихында әһәмиятле сәхифә итеп саналырга хаклы.

*И. Нуруллин тексты.*

**Яхъя Абдуллин**

# ФИЛОСОФ ҺӘМ ФИКЕР ИЯСЕ

*Чыкты ахыр бездән дә бер бөтен кеше,*
*Яхшы аңлап, тәкъдир иту читен кеше,*
*Татарда да гыйрфан уты кабынганны*
*Күрсәтергә күтәрелгән төтен кеше.*

*Кирәк булса, әйтеп бирим: ул шәп хәзрәт,*
*Тулган ай күк балкып чыккан Шиһаб хәзрәт,*
*Мәгарифкә әүвәл башлап адым салган,*
*Милләт өчен бәһа җитмәс кыйбат хәзрәт.*

Габдулла Тукай

Күренекле галим, тарихчы, фикер иясе һәм философ Шиһабетдин Баһаветдин улы Мәрҗани — татар мәдәнияте һәм мәгърифәтчелек хәрәкәте тарихында тирән эз калдырган олуг шәхес. Татар иҗтимагый фикер тарихының күренекле вәкиле Ш. Мәрҗани Татарстанның хәзерге Арча районы Ябынчы авылында 1818 елның 16 январенда рухани гаиләсендә дөньяга килә. Озак та үтми, Мәрҗанинең атасы Баһаветдин Ташкичү авылына имам булып сайлана һәм шунда ук мәчет каршындагы зур мәдрәсәгә җитәкчелек итә. Бәләкәй Шиһаб шул мәдрәсәдә белем ала. Табигате белән зирәк Мәрҗани балалык чорында ук күпне белергә омтыла, мәдрәсәдәге дәресләр белән генә канәгатьләнмичә, әтисенең һәм бабасының шактый бай китапханәләрендәге барлык китапларын да кабат-кабат укып чыга. Унҗиде яшендә ул әтисенә шәкертләр укытуда ярдәм итә башлый.

Ул заманнардагы гадәт буенча, атасы мәдрәсәсен тәмамлаган Ш. Мәрҗани, белемен арттыру нияте белән, Бохарага юнәлә. Монда ул шәһәрнең иң өлкән һәм могтәбәр мөдәррисләрдән берсе булган Мирза Салих әл-Хоҗәндидән дәрес ала башлый. Моннан тыш, ул Бохараның башка күренекле мөдәррисләренең дә дәресләрен тыңлый. Ләкин Бохара мәдрәсәләрендә уку-укытуның куелышы аның кызыксынучан акылын, белемгә омтылышын һич тә канәгатьләндерми. Шуңа күрә ул күп вакытын китапханәләрдә эшләүгә сарыф итә, мөстәкыйль фикер йөртергә омтылган кешеләр белән аралашырга тырыша. Хөсәен бине Мөхәммәд әл-Кирмани ал-Каргалыйны Ш. Мәрҗани әнә шундыйлардан санаган. Хөсәен бине Мөхәммәд ал-Кирмани рәсми рәвештә мөдәррис дип саналмаган, ләкин ул киң карашлы фикер иясе була, бик бай китапханә туплый; гарәп, фарсы һәм күп кенә төрки телләрне камил үзләштерүе өстенә, шул телләрдә шигъри әсәрләр дә иҗат иткән һәм тарих фәне белән дә тирәнтен кызыксынган. Кайбер галимнәр фикеренчә, Бохара чорында ук Ш. Мәрҗанидә «Вафиятел-әсляф вә тәхиятел-әхляф» исемле җиде томлык

---

ЯХЪЯ ГАБДУЛЛОВИЧ АБДУЛЛИН *(1920) — философия фәннәре докторы, профессор, РСФСРның һәм Татарстан АССРның атказанган фән эшлеклесе. Татарстанда иҗтимагый һәм философик фикер тарихы проблемаларын яктыртуга багышланган «Татар мәгърифәтчелек фикере» (1976) монографиясе һәм күп санлы башка хезмәтләр авторы. Казанда яши.*

китап язу теләге туугa да шул кеше сәбәпче булган. Бохарада ул Низаметдин әл-Илһами кебек күренекле галим белән дә якынлаша. Низаметдин әл-Илһами медицина, астрономия һәм математикадан яхшы мәгълүматлы шәхес була.

Беркаян да матди ярдәм алмаган Ш. Мәрҗани, яшәргә акча табу өчен җирле байларның балаларын укытырга яллана, китап күчереп язу белән шөгыльләнә, ә язларын балалар укыту өчен тирә-юнь авылларга чыгып китә. Әмма тапкан акча иң кирәкле ихтыяҗларны канәгатьләндерергә генә җитә торган була. Соңыннан ул үзенең шәкертләренә: «Бохарада вакытта ялланаякка башмак киеп, һәркөн өч-дүрт чакрым җиргә дәрескә бара идем».— дип сөйләгән (Мәрҗани. Казан. 1915. 44 б.).

Бохарада биш ел яшәгәннән соң, Ш. Мәрҗани ул заманда Урта Азиянең икенче фән үзәге булып саналган Сәмәркандка күчә һәм Шердар мәдрәсәсенә урнаша. С. Айни фикеренчә, ул бу адымны Әмир Насрулла зәэрлекләве нәтиҗәсендә эшләргә мәҗбүр булган. Монда ул казый Әбү-Сәгыйд Габдулла бине Габделхәй әс-Сәмәрканди белән якыннан таныша. Бу галим — теологиядән тыш тарих, математика, астрономия, география һәм фәннең башка тармакларын да тирән үзләштергән шәхес. Мәрҗанигә ул бик сирәк китаплардан торган бай китапханәсеннән файдалану мөмкинлеге биргән. «Ошбу казый Әбү Сәгыйд хәзрәтләренең китапханә вә китаплары минем башлыча мөршидләрем (юл күрсәтүчеләрем) булды. Миңа аң биргән, фикеремне төзәткән шунлардыр».— дип сөйләгән соңыннан Ш. Мәрҗани (Мәрҗани. Казан. 1915, 47 б.). Мәрҗанинең фикерләре үзгәрүдә дини фанатизм һәм схоластиканы ачы һәм үткен тәнкыйтъ утына тоткан күренекле татар галиме Габденнасыйр Курсави хезмәтләрен өйрәнү, тирәнтен үзләштерү дә зур әһәмияткә ия була. Акрынлап ул мөтәкәллимнәр тарафыннан алга сөрелгән тар кыса-формулалардан арына бара, мөселман руханилары тарафыннан гөнаһсыз, изгеләр дип саналган борынгы авторитетларга гади кешеләр итеп карый башлый.

Сәмәркандта ике ел яшәгәч, Мәрҗани яңадан Бохарага кайта һәм ул заманда атаклы саналган Миргарәп мәдрәсәсенә урнаша. Монда Мәрҗани үзлегеннән белем алуын дәвам иттерә, элеккегечә үк татар, үзбәк һәм төрекмән шәкертләренә дәрес биреп, яшәр өчен акча эшли.

Бохара һәм Сәмәркандта яшәү һәм уку дәверендә Ш. Мәрҗани мөселман дине нигезләреннән тыш гарәп һәм фарсы телләрен ныклап өйрәнә, философия, тарих, математика, бигрәк тә геометрия һәм астрономия белән шөгыльләнә. Ул монда әл-Фараби, әл-Бируни, Ибне Сина, Ибне Рөшд, әл-Кинди, әл-Мәгарри, Ибне Халдун кебек философ һәм тарихчылар, Көнчыгышның Сәгъди, Фирдәүси, Хәйям, Низами, Нәваи һәм башка атаклы әдипләрнең иҗатлары белән һәрьяклап тирәнтен таныша.

1849 елда туган якларына кайткач, Ш. Мәрҗани Казандагы беренче мәчетнең имамы һәм мәчет каршындагы мәдрәсәнең мөдәррисе итеп билгеләнә. Монда ул баштанаяк педагогик һәм фәнни эшкә чума, мәдрәсәдә укытуны тәртипкә салу һәм аның эчтәлеген үзгәртү буенча яңалыклар кертә башлый. Казан татарлары арасында тарихта беренчеләрдән булып ул мәдрәсәдә эчке тәртип кагыйдәләре булдырырга ирешә. Мәдрәсә попечительләрен сайлап куюны кертеп, Мәрҗани уку-укыту эшләрен тәкәббер байгураларның тыкшынуларыннан азат итә. Аның дәресләре ул заманнардагы мөселман уку йортлары өчен бөтенләй диярлек хас булмаганча, материалны тирән анализлау, аларның фәнни мәгълүматларга бай булуы белән аерылып торган. Дини уку йортларындагы гадәти предметлар белән бергә ул шәкертләренә тарих, география, математика, астрономия буенча да киң, тирән мәгълүматлар бирә, аларны Көнчыгышның атаклы фикер ияләре һәм шагыйрьләренең әдәби җәүһәрләре, һәм шулай ук татар әдәбияты һәм халык авыз иҗаты әсәрләре белән таныштыра.

Илебезнең университетлы эре фән үзәге булган Казанда яшәү һәм эшләү Ш. Мәрҗани алдында алдынгы рус культурасы һәм иҗтимагый фикере белән танышу мөмкинлеге ачты. Ул көнчыгышны өйрәнүче күренекле галимнәрдән А. К. Казембек, В. В. Радлов, университет профессорлары И. Готвальд һәм башкалар белән иҗади дуслык элемтәләре урнаштыра. Х. Фәезханов аркылы Петербург галиме, академик В. В. Вельяминов-Зернов белән бәйләнешкә керә. Шушы элемтәләр, Казан университеты галимнәре белән даими аралашу аңа рус һәм Көнбатыш Европа фәне ирешкән казанышлар белән якыннан танышу мөмкинлеге тудыра. Казанда ул русча тарихи чыганаклар белән дә таныша башлый. Замандашлары сөйләвенчә, Ш. Мәрҗани китапханәсендә татар, гарәп һәм фарсы телләрендәге томнар белән бәррәттән рус телендәге басмалар да күп булган. Рус галимнәре белән аралашу, рус һәм Көнбатыш Европа фәне һәм культурасы казанышлары белән танышу Ш. Мәрҗанинең мөселман дини тәгълиматының катып калган өйрәтүләреннән арынуында һәм аның мәгърифәтчелек карашлары формалашуында мөһим роль уйный.

Ш. Мәрҗанинең иҗат эшчәнлеге Бохарада башлана һәм Казанда гомеренең

соңгы көннәренә кадәр дәвам итә. Аның беренче хезмәте — Бохара галимнәре арасында хөкем сөргән наданлык һәм фанатизмны тәнкыйть иткән «Игъляме әбнаи әд-дәһер би-әхвяли әһли Мәвараэннәһер» («Урта Азия кешеләре һәм эшләре турында үз чорының уллары мәгълүматлары») исемле китап була. Бу китапта Ш. Мәрҗани яшьләрне Бохарага укырга барудан баш тартырга һәм дөньяви фәннәрне өйрәнергә өнди. Үзеннән алда Бохарада укыган, схоластиканы, дини тәгълиматны, суфизмны тәнкыйтьләп чыккан һәм шуның өчен, динсезлектә гаепләнеп, үлем җәзасына хөкем ителгән күренекле татар галиме Г. Курсави язмышына дучар булмас өчен, Ш. Мәрҗани бу китапны үзе Бохарадан киткәннән соң гына таратуны үтенә. Ул «Тәнбиһе әбнаи әл-гасыр галя тәнзиһе әнбаи Әбу-Насыр» («Әбү-Насыйр юлында гасырның уллары уянуы») исемле китабын да Бохарада чакта яза һәм анда үзенең Курсави идеяләре белән тулысынча килешүен бәян итә. Болардан тыш, ул Урта Азия тарихы һәм географиясенә багышланган хезмәтләр дә яза.

Казанга кайткач, Ш. Мәрҗанинең фәнни-иҗади эшчәнлеге аеруча киң колач җәя. Ул утыздан артык зур фәнни хезмәт яза. Алар арасында фәнни-философик һәм сәнгать фикере, аның күренекле вәкилләренең тормышы һәм эшчәнлеге турында җиде томлык «Вафиятел-әсляф вә тәхиятел-әхляф» («Бабайларның үлеме һәм аларның киләчәк буыннарга васыяте») һәм ике томлык «Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» («Казан һәм Болгар хәлләреннән файдаланылган хәбәрләр») исемле хәзергәчә зур фәнни әһәмиятен югалтмаган хезмәтләре бар.

Ташып торган энергияле Ш. Мәрҗани фәнни-оештыру эшендә дә актив катнаша. Ул, татар галимнәреннән беренче буларак, Казан университеты каршындагы Тарих, этнография һәм археология җәмгыяте әгъзасы итеп кабул ителә һәм җәмгыять эшендә актив катнаша. Профессор Е. Малов әйтүенчә, Ш. Мәрҗанине ак чалмадан һәм яшел чапанда килеш җәмгыять утырышларында бик еш күрергә мөмкин була. 1877 елда Казанда IV Бөтенроссия археология съезды чакырыла. Бу съездга илнең төрле шәһәрләреннән һәм шулай ук чит илләрдән өч йөзгә якын галим килә. Оештыру комитетының әгъзасы сыйфатында, Ш. Мәрҗани съездны оештыруда һәм аның эшендә актив катнаша. Пленар утырышларның берсендә ул Болгар һәм Казан тарихы турында доклад белән чыгыш ясый. Докладны Ш. Мәрҗани үзе татар телендә укый, ә соңыннан В. Радлов тәрҗемәсендә ул русча укыла. Соңрак бу доклад съезд материаллары җыентыгында 1884 елда ике телдә дә дөнья күрә.

Киң карашлы галим буларак, Ш. Мәрҗани фәннең бик күп тармаклары белән кызыксынган. Ул безнең күз алдыбызга киң мәгълүматлы философ, телче, әдәбият белгече, үз халкының һәм күрше халыкларның мәдәниятен һәм тарихын тирәнтен белүче галим булып килеп баса. Мәрҗани философия, археология, этнография, нумизматика, астрономия, география, медицина һәм фармокология тарихы, музыка һәм сәнгатьнең төрле тармаклары тарихы белән кызыксына. Ул татар галәмендә беренчеләрдән булып фәннең югарыда саналган тармаклары буенча төпле, дәлилле һәм файдалы фикерләр әйтеп калдыра.

Ш. Мәрҗанинең мәгърифәтчелек идеяләрен чагылдырган һәм татар иҗтимагый фикер тарихы үсешендә мөһим роль уйнаган фәнни эшчәнлеге үз халкын феодаль-патриархаль мөнәсәбәтләр хакимлегеннән һәм урта гасыр идеологиясеннән азат итү, аны дөнья цивилизациясе казанышларына якынайту идеяләре белән сугарылган иде. «Аның барлык әсәрләре,— дип язды Г. Ибраһимов,— фикердә хөрлек белән, киләчәккә якты карау һәм адәм акылына ихтирам белән сугарылган... Аның әсәрләре баштанаяк адәмнең акылы өстенә салынган богауларны өзү, фикернең искелекләргә кол булуына каршы көрәшүдән гыйбарәт» («Аң», 1915, 1 сан, 14 б.)

Рационалист буларак, Ш. Мәрҗани схоластик баш ватуларга каршы чыга, дини китаплардагы өйрәтүләрнең какшамас дип саналган нигезләрен шик астына ала һәм хөр фикерлелекне яклый. Диннең үзен тулаем инкарь итмәсә дә, ул үзенең хезмәтләрендә дини тәгълимат принципларын тәнкыйть итә. Моның өчен ул кайвакытта изге саналган китаплардан да файдалана, әмма үзенең төп һөҗүмен фанатизм һәм мистицизмга юнәлдерә, дини хезмәтләрдән алынган өземтәләрне аларның позициясен җимерүдә оста файдалана. Ул бигрәк тә мөселман дине тәгълиматы нигезен тәшкил иткән төп принциплардан булган тәкълидкә каршы чыга. Бу принципка таянып, мөселман руханилары замандашларының иҗади эзләнүләргә хакын танымаска тырыштылар, үткән заман авторитетлары фикерләрен берсүзсез ышанып кабул итәргә, борынгыларның сүзләренә һәм традицияләренә сукырларча иярергә өндәделәр. Бу идеянең киң таралуын Ш. Мәрҗани халык өчен зур афәт, фанатизм өчен уңдырышлы җирлек, наданлык һәм катып калганлыкның таянычы дип тәнкыйть итте. «Сәгадәт гасыры», ягъни гомуми гаделлек дәвере, ләззәт һәм бәхет заманнары инде артта калган, торган саен гыйлем нурлары сүрелә, сүнә бара һәм кайчан да булса ул бөтенләй сүнәчәк дигән фикерләрне кире кагып, Мәрҗани: «Кирәк кайу заманда булсын... һәрбер мөэмингә... иҗтиһад юлында булырга лязим-

дыр».— дип язды (Мәрҗани. Казан, 1915, 275 б.). Мөселман дин өйрәтүләре мөҗтәһидләрне, ягъни үткән заманның иҗади фикер йөртергә сәләтле һәм яңа тәгълимат тудырырга хокуклы галимнәре, кешеләргә абсолют белем калдырган хатасыз авторитетлар дип таныта. Ш. Мәрҗани исә бу затларга гади кешеләр дип карады һәм, «мөҗтәһиднең дә хатасы булуы мөмкин», дип язды[1]. Шуңа күрә, алар әйтеп калдырган сүзләрне сукырларча кабатламаска кирәк. «Истидлял (берәр дәлилгә таянып нәтиҗә чыгару) куәсен тәхсил кылырга (булдырырга) иҗтиһад итмәк (тырышу) һәркемгә тиешле», дип яза Ш. Мәрҗани (Мәрҗани. Казан, 1915, 509 б.).

Тәкълид принципларын һәм «иҗтиһад дәвере», ягъни мөстәкыйль фикер йөртеп, иҗади эзләнүләр дәвере үтте инде дигән дини өйрәтүләрне тәнкыйть итү кеше акылына салынган богауларны өзәргә, кешеләрне үле традиция-гадәтләр хакимлегеннән азат итәргә булышты, хакыйкать законнарын эзләргә мөмкинлек тудырды, фәнне дин тәэсиреннән коткару өчен алшартлар хәзерләде. Дин белән фәнне бер-берсеннән аерып карау, бу өлкәдә дин өйрәтмәләреннән аерылу Ш. Мәрҗанигә «хакыйкать һәм табигать законнарын пәйгамбәрләр өйрәтүеннән эзләү урынсыз, аны кеше үз тәҗрибәсе, үз эзләнүе белән табарга тиеш», дип игълан итәргә мөмкинлек бирде[2]. Чөнки пәйгамбәрләр өйрәтүе кешеләрнең иманы, инануы мәсьәләсенә генә карый, табигать законнарының һәм чынбарлыктагы күренешләрнең асыл нигезенә аның катнашы юк. Бу законнар һәм күренешләрнең сәбәпләрен пәйгамбәрләр өйрәтүеннән эзләү урынсыз, аларны ачыклау — кешеләрнең бурычы.

Мәрҗанинең тәкълидка каршы көрәше, кеше акылын урта гасырчылык богауларыннан азат итүгә юнәлтелгән эшчәнлеге әдәби иҗат эшчәнлеген традицияләр һәм дини өйрәтмәләрнең тар кысаларыннан чыгаруга булышлык итеп, каләм әһелләренә ирекле рәвештә яңа әдәби эзләнүләр алып барырга мөмкинлек ачты.

Татарларда мәгърифәтчелекнең формалашуы һәм үсеше, башка халыклардагы кебек үк, буржуаз милләт оешып килгән дәвергә туры килде. Шуңа күрә милләт һәм халыкның тарихи язмышы проблемасының мәгърифәтчеләрдә, шул исәптән Ш. Мәрҗани эшчәнлегендә дә, төп мәсьәләләрнең берсе булуы очраклы хәл түгел иде. Аның фикеренчә, милли үзаңның басылганлыгы, үз халкының тарихи үткәнен һәм аның мәдәни мирасын белмәү социаль һәм милли прогресс юлында җитди киртә булып тора. Шуның өчен милләт уллары ацына халыкның үткәнен, аның матди һәм рухи культурасы тарихын җиткерергә кирәк дип саный ул.

Ш. Мәрҗани хаклы рәвештә татар халкының фәнни тарихына нигез салучы булып хисаплана. Татар культурасының күренекле вәкиле Җ. Вәлиди аны «безнең Геродотыбыз» дип олылады. Аның милли тарихыбызны тикшерүдәге, өйрәнүдәге роленә бирелгән мондый бәя бер дә очраклы түгел, әлбәттә. Элек тарихи хезмәтләр сыйфатында саналып йөртелгән дини-мистик әсәрләрдән аермалы буларак, ул чын мәгънәсендә фәнгә нигезләнгән тарихны барлыкка китерде. Ул татар халкының тарихын беренче дини-мистик уйдырмалардан тыш, ышанычлы тарихи чыганакларны анализлау нигезендә тикшерә. Мәрҗанинең «Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» исемле ике томлык хезмәте һәм «Галәләтез-заман фи тарихи Болгар вә Казан» кебек китаплары әнә шундый рухта язылган хезмәтләр. «Вафиятел-әсләф вә тахиятел-әхләф»та да татар халкының тарихи үткәне турында сөйләүче мәгълүматларга зур урын бирелгән.

Татар халкы тарихын тасвирлаганда, Ш. Мәрҗани гарәп тарихчыларының тикшеренүләренә таянды, көнчыгыш сәяхәтчеләренең истәлек язмаларына һәм русча чыганакларга мөрәҗәгать итте. Шул ук вакытта аның хезмәтләрендә үзәк урынны үзенең мөстәкыйль рәвештә алып барган тикшеренүләре нәтиҗәсендә табылган мәгълүматлар, чыганаклар тәшкил итә. Тарихи дөреслекне торгызу өчен ул бик күп санлы беренче кул чыганакларга мөрәҗәгать итте: борынгы акчалар, ярлыклар, риваятьләр, дәүләт эшлекләләре һәм хосусый кешеләрнең хатлары, кабер ташларындагы һәм борынгы китап читләрендәге язмалар һәм башкалар. Бу чыганакларны җыю өчен ул көн-төн кулъязма китаплар тикшерә, ерак авылларга чыгып, кабер ташларын өйрәнә. Шушы фидакарь эшчәнлек нәтиҗәсендә тупланган чыганакларны ул тәнкыйть күзлегеннән карап бик җентекләп тикшерә.

Тарихи истәлекләрне шулай тәфсилле өйрәнү Ш. Мәрҗанигә татар халкы тарихы турында дәлилләрәк һәм ышанычлырак итеп сүз йөртергә мөмкинлек бирә. Мәсәлән, ул үзенең хезмәтләрендә Идел буе татарларының килеп чыгышы кебек бик мөһим, әмма буталчык мәсьәләне күтәреп чыга. Ул заманнарда татарларның нинди милләттән икәнлеге мәсьәләсе ислам дине идеологиясе белән сугарылган иде. Мөселман руханилары гасырлар буена ислам динендәге халыкларның бердәмлеге

---

[1] Мәрҗани Ш. Әл-хикмәтел балига. Казан, 1888. 145 б.

[2] Шиһабетдин Мәрҗани. Казан, 1968. 20 б.

идеясен алга сөрде һәм аларның аңыннан һәрберсенең мөстәкыйль халык икәнлеге турында карашларны юкка чыгарырга тырышты. Мондый фикерләрне кискен рәвештә кире кагып, Ш. Мәрҗани татарларның мөстәкыйль халык икәнлеге турындагы идеяне пропагандалады.

Татар халкының килеп чыгышы мәсьәләсен тикшергәндә, Ш. Мәрҗани буржуаз милләтчеләр һәм самодержавие идеологлары тарафыннан алга сөрелгән карашларны тәнкыйть итә. Ул татарлар Чыңгыз хан һәм Бату гаскәрләре белән Идел буе далаларына бәреп кергән яулап алучыларның варислары дигән уйдырмаларга каршы чыга. Бу мәсьәләдә Мәрҗани бөек рус революцион демократы Н. Г. Чернышевский позициясендә тора һәм хәзерге казан татарларын борынгыдан ук Идел-Кама төбәгендә яшәгән кабиләләрнең, атап әйткәндә болгарларның, турыдан-туры варислары дип саный һәм бу карашны күп санлы тарихи мәгълүматлар белән нигезли.

Әмма Мәрҗани бу катлаулы проблеманы яктыртуга берьяклы гына якын килми. Ул Идел һәм Урал буе татарларының формалашуында башка этник компонентларның, мәсәлән, кыпчакларның һәм угро-фин кабиләләренең дә катнашуын инкарь итми. Шул ук вакытта ул халыкның формалашу мәсьәләсенең кан кардәшлегенә генә кайтып калмавын да яхшы аңлый. Чөнки бу процесс бер үк вакытта культура үсеше процессы, ягъни этнокультура процессы да иде. Ш. Мәрҗани казан татарларын Идел-Кама болгарларының варислары дип исәпли.

Ш. Мәрҗани тарихка тормыш мәктәбе итеп карады, аның танып-белү һәм тәрбияви әһәмиятен басым ясап күрсәтте, татар халкының тарихи үткәнен һәм әдәби мирасын өйрәнү һәм пропагандалауны халыкның милләт буларак киләчәген тәэмин итүнең зарури бер шарты дип санады. Ул татар халкының бай тарихи үткәне һәм мәдәни мирасы барлыгын икърар итә. «Кыйссаи Йосыф», «Нәһҗел-фәрадис», «Нәсыйхәтес-салихин», «Бәдәвам», «Нәүрүз» һәм «Шәһре Болгар газилары» кебек гүзәл әдәби һәм әхлакый әсәрләрне Мәрҗани бу мирасның мөһим үрнәкләре дип саный. Аларның теле «Болгар шәһәрендә улан ләүхләр (кабер ташлары) язуларына бик мөшабиһ (охшаган). Бу китаплар бу мәмләкәтләрдә басма вә язмалары галәлкәсрәт (бик күп) табыладыр. Гайре мәмләкәтләрдә бер дә күрелгән вә ишетелгәне юк, вә бу китаплар лисаны (теле) госманлы вә чыгтай вә төркмән, вә Казагстан лисаннарына мөбаиндыр (охшамагандыр)[3]». Шулай итеп ул бу әдәби ядкарьләрнең татар халкы мәдәни милке булуын яклап чыга һәм бу фикерне ышанычлы тарихи чыганаклар белән нигезли. Татар халкы тарихын, культура мирасын өйрәнгәндә, халык авыз иҗаты әсәрләренә дә мөрәҗәгать итә, аларның барлыкка килүен борынгы бабаларыбызның гореф-гадәтләре, тормыш шартлары белән бәйләп аңлата.

Шулай итеп, Ш. Мәрҗани — тарих фәненең күренекле вәкиле, татар халкының фәнни тарихына нигез салучы, аны дини риваятьләрдән азат итүче булды. Шуның белән бергә ул күренекле философ, фикер иясе дә иде. «Назурәтел-хак...» («Хакыйкатьне күзаллау...»), «Әл-хикмәтел-балига» («Өлгергән философия»), «Хаккыл-мәгърифәт» («Танып белү хакыйкате...»), урта гасырның теологы Дәванинен «Мелла Җәлал» китабына комментарий рәвешендә язган «Әл-газабелфирәт...» («Сафландыручы су...») кебек китапларында Ш. Мәрҗани дөньяга карашның төп мәсьәләләре буенча мөселман дине әһелләре өйрәтүләрен тәнкыйтьли, чынбарлыкны фәнни-материалистик аңлатуга юл сала. Дөрес, аның дөньяга карашы эзлекле түгел, ул фәлсәфи фикерләвендә мөселман көнчыгышы өчен хас булган традицион формалардан арына алмый әле. Шул ук вакытта Мәрҗани, фикерләрен традицион мөселман дине кабыгына төреп бирүенә карамастан, алланың асылы һәм аның төп билгеләре дөнья һәм аның яралышы, заманның чиклелеге һәм чиксезлеге, барлык һәм юклык кебек ул заман өчен гаять әһәмиятле мәсьәләләр буенча дини тәгълимат вәкилләренең өйрәтмәләрен төрле яктан һәм дәлилле итеп тәнкыйтьли, ул вакытта бәхәс үзәгендә булган «ходус замани» («заманда барлыкка килү») формуласына кискен каршы чыга. Мөселман дине идеологлары, бу аңлатмага таянып, дөньядагы бар нәрсәне, шул исәптән заманның үзен дә, алла яраткан дип игълан иткәннәр. Мәрҗани мондый карашларны нигезсез һәм мәгънәсез дип саный. Бөек галим карашынча, туктаусыз хәрәкәттәге предметлардан башка заман төшенчәсе юк, реаль вакыттан тыш һәм вакытлы нәрсәләрдән башка заман — юк сүз. Шулай булгач, һичнинди реаль нәрсә булмаган заман турында сүз йөртү — мәгънәсезлек. «Заманның хасил булуы» төшенчәсен кире кагуы белән Ш. Мәрҗани мөселман дине кануннарының, алла заманга караганда да алданрак булган, барлык әйберләрне һәм күренешләрне ул үзеннән соң билгеле бер вакытта барлыкка китергән дигән өйрәтүләрен инкарь итә. Шул ук вакытта ул алла идеясен дә кире какмый. Нәтиҗәдә аның философик карашлары формасы буенча объектив — идеалистик булып кала. Чөнки Мәрҗани алла объектив дөнья һәм аның күренешләреннән алда килә дип

[3] Мәрҗани Ш. Мөстәфәдел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. Казан, 1897, 13 б.

саный. Аның фикеренчә, күренешләр дөньясы да алла кебек үк мәңге һәм чиксез: предметларның («мөмкинат») үзлексез һәм мәңге алышынып торуыннан гыйбарәт. Монда максат «үткәндә һәм киләчәктә чиге булмаган вә туктаусыз яңаручан булган җөзьиятнең нәүбәтләнүе нәтиҗәсендә саклана (яши) торган өзлексез бер табигать барлыгын исбат итмәктер. Вә бу өзлексез табигать, үзенең дәвамы һәм өзлексезлеге җәһәтеннән мәңгелек иҗат итүчедән чыга; җөзьият, үзенең үзгәрүчән булуы җәһәтеннән, күренешләрнең барлыкка килүенә башлангыч була, дибез» (Мәрҗани. Казан, 1915. 244-245 бб.). Бу очракта Мәрҗани көнчыгышның бөек фикер ияләре Әл-Фараби, Әбугалисина һәм Ибне Рөшд кебек галимнәр позициясенә баса, табигатьнең дә, алланың да мәңгелек булуы турында алар әйткән фикерләрне алга сөрә. Бу концепция буенча, күренешләр дөньясы, алла кебек үк, мәңге булган һәм булачак. Мәрҗани заманында, дини карашлар өстенлек иткән заманда бу идеяне яклауның әһәмияте бик зур була.

Ш. Мәрҗани алланың асылын да догмаларга ябышып ятучы дин белгечләренчә аңлатмый. Аныңча, алла — күренешләрне үз теләганчә барлыкка китерүче дә, табигатьтән аерылган зат та түгел, ә һәр җирдә һәм һәрвакыт барлык нәрсәләрнең һәм күренешләрнең нигезендә яткан гомум яшәеш принцибы; алла — үткәнне, хәзергене һәм киләчәкне үтеп чыгучы мәңгелек; аның асылы матди һәм рухи күренешләрдә һәр җирдә, һәр нәрсәдә ачыла. Алла табигатен болай аңлату Мәрҗанине пантеистик рухтагы нәтиҗәләргә китергән. Мәгълүм булганча, пантеизмга алланың асылын дөнья күренешләрендә эретү хас. Алла һәм ул барлыкка китергән нәрсәләр турында фикер йөрткәндә, Ш. Мәрҗани дә алла асылын табигатьнең реаль күренешләрендә эретә һәм, ахыр чиктә алланы яңарып торучы табигать белән тиңләштерә.

Ш. Мәрҗанинең философик проблемалар өлкәсендә тоткан позициясен динни-идеалистик карашлардан арыну һәм татар иҗтимагый фикер үсешенә рационализм үтеп керүдә хәлиткеч адым дип бәяләргә мөмкин. Мөселман дине өйрәтүләрен рационалистик тәнкыйтьләү чынбарлыкны фәнни-материалистик аңлатуга илтте.

Дини өйрәтүләрнең дөньяга караш мәсьәләсендәге күрсәтмәләрен тәнкыйть итеп Ш. Мәрҗани шәригать кануннарыннан фәнни белемнең өстенрәк торуын исбатлый һәм мондый фикере белән заманы өчен бик кыю позициягә баса. Әгәр дә шәригатьтә фәнни нигезләнгән фактларга каршылык була икән, ул очракта дөреслеге ачык мәгълүм нәрсәне инкарь итүгә караганда, шәригать күрсәтмәсен үзгәртеп аңлау яхшырак дип саный Мәрҗани.

Ш. Мәрҗани тәкфирнең, ягъни чынбарлыкны фәнни аңлатуга һәрбер омтылышны, ирекле фикер йөртү күренешләрен мөртәтлек дип гаепләү практикасының дошманы иде. Динсезлектә гаепләүнең бу үзенчәлекле формасы күп гасырлар буе теологлар һәм консерватив руханиларның фәнгә һәм философиягә каршы көрәшендә корал сыйфатында хезмәт итте.

Еретик һәм алласыз ярлыгы тагылган кеше законнан һәм җәмәгатьтән тыш калган, читкә тибәрелгән, ул һәртөрле эзәрлекләүләргә дучар булган. Шул сәбәпле тәкфир мөселман дөньясына фәнни белемнәр һәм яңа идеяләр үтеп керү юлында бик зур киртәгә әверелде. Мәрҗани тәкфирне халыкны артка сөйрәүче сәбәпләрнең берсе дип санады һәм аннан кискен рәвештә читләште. Карашларының догматик диничеләрнекеннән төп аермасын ассызыклап, мәгърифәтче болай дип язды: «Без хәкимнәр вә әһле мәгърифәтне, гакыл вә хикмәтне дошман күрмибез. Һәм аларның дәлил илә исбат иткән нәрсәләрене шәрә фанатизм вә дошманлык белән инкарь итмибез. Әһле мәгърифәтне, гакыл вә хикмәтне дошман күрмәк, дәлил белән сабит булган нәрсәләрне шәрә фанатизм белән инкарь итмәк әһле калям [4] вә мөтәфәләсиф (ялган философ) гадәтедер. Әһле калям вә мөтәфәләсиф сүзләре гаять зәгыйфь һәм хаклыктан ерак...» (Мәрҗани. Казан, 1915, 247 б.). Фән белем алу средствосы дип басым ясый Мәрҗани, шуңа күрә аңа дошмани мөнәсәбәт берни белән дә акларга мөмкин түгел. «Гыйлемне зәмм (хурлау) вә инкарь кыйлу мәгърифәтсез вә тәҗрибәсез ләйим (түбән) кешеләр эшедер»,— дип яза бөек мәгърифәтче [5].

Фән һәм философия белән шөгыльләнергә сәләтле кешеләрне Ш. Мәрҗани, диниче-калямчеләрдән аермалы буларак, кешелекнең иң күренекле вәкилләре дип саный. Аның өчен ишан да, дини әсәрләрнең авторлары да чын изгеләр түгел. Чын изгеләргә ул кешеләр алдында чын фәнни белемнәр ишеген ачучы фән һәм философия вәкилләрен кертә.

Фәнни һәм философик белемнәр алу юлында тырышып эшләү аның фикеренчә кеше эшчәнлегенең иң мактаулы һәм хөрмәтле бер сферасы булып тора. Шуңа күрә Ш. Мәрҗани: «Әгәр бер галим тикшерү-эзләү процессында ялгышса, аңа

[4] Әһле калям — мөселман схоластик дин белеме системасы тарафдарлары.
[5] Мәрҗани Ш. Хакк ыл-мәгърифәт. Казан, 1880, 54 б.

бер сәвап (тикшергән өчен), әгәр дәреслекне ачса, ике сәвап (берсе тикшерү, берсе дәреслекне тапкан өчен) була. Галимнең ялгышуы фәннең ялгышлыгын түгел, бәлки тикшерүдәге ялгышлыкны күрсәтә».— дип саный [6].

Милли йомыклыктан арынуда, татар халкын фән һәм культура өлкәсендә башка халыклар ирешкән казанышлар белән таныштыру өчен көрәштә Мәрҗанинең өлеше бик зур. Ул милли һәм дини чикләнгәнлеккә каршы булды. «Үз милләтебезнең яшәргә тырышуы, үз эшен үзе эшли алуы, хаят мәйданында изелеп калмавы өчен,— дип язды Ш. Мәрҗани.— Европаның гыйлем вә мәгарифенә, һөнәр вә сәнагатенә зур ихтыяҗыбыз бар. Европа мәктәпләрендә укымак безнең өчен файдалы. Һөнәр вә мәгариф кайда булса, шунда барып тәхсил итәргә (гыйлем алырга) кирәк. Гыйлем вә мәгарифнең хас ватаннары (аерым ватаны), хас лисаннары (аерым теле) юк» (Мәрҗани. Казан, 1915, 528 б.). Кадимче руханилар, рус культурасы белән танышуга, рус телен өйрәнүгә каршы килеп, аларны иң зур гөнаһ һәм мөртәтлек дип санаган заманда Ш. Мәрҗани киресенчә, бу телне белү татарлар өчен зарури икәнен тәкрар исбатлап килде. «Безнең халкыбызның бөтен кирәк эшләрен булдыру Россия дәүләтенә бәйләнгән, барлык кануннар, хөкемнәр, беркетмәләр шул телдә йөргәнгә күрә, ул телне өйрәнү һәм белү зарури булып кала»,— дип язды ул. Мәрҗани рус теле фән һәм культура хәзинәләрен үзләштерү чарасы булып тора һәм «алтын чыга торган гауны никадәр казыр исәңез, шул кадәр мәгъдән (казылма, руда) хасыйл итәсез. Иштә рус лисаны (теле) боңа мөшабиһдер (охшаштыр)»,— дип язды [7]. Бу фикерләрен Мәрҗани конкрет эшчәнлеге белән дә раслады: Казанда рус-татар укытучылар мәктәбен ачуда ул актив катнашты. Ш. Мәрҗани бу мәктәп ачылуга багышланган тантаналы җыелышта чыгыш ясый, кадимчеләр каргышына карамыйча шунда укыта башлый.

Ш. Мәрҗанинең күпкырлы фәнни һәм мәгърифәтчелек эшчәнлеге, урта гасыр схоластикасына һәм фанатизмга каршы кыю чыгышлары, социаль-экономик, идеология һәм гаилә-көнкүреш мөнәсәбәтләрендәге феодаль калдыкларның авыр мирасын ачыктан-ачык тәнкыйтьләве искелек тарафдарларының яңалыкны куралмаучыларның кискен каршылыгына очрый. Аңа һәртөрле яла ягалар, диннән язган, мөртәт, миссионерлар куштаны, диләр. Мәрҗанинең рус-татар укытучылар мәктәбендә эшләве, университетка йөрүе һәм рус галимнәре белән аралашуы хыянәт дип кабул ителә. Шул хакта, хәтта, мәсхәрәле шигырьләр языла.

Әмма Мәрҗани надан байлар, реакцион динчеләр куйган киртәләргә карамыйча, тоткан юлыннан тайпылмый, шәкертләренә фәнни мәгълүматлар белән баетылган дәресләр бирүен дәвам итә, хезмәтләрендә схоластик йомыклык күренешләрен фаш итә, чыгышлары һәм шәхси әңгәмәләре вакытында да мәгърифәтчелек карашларын пропагандалый. Мәрҗани бик тырышып эшләгән, иҗат иткән, хәтта каты авыру хәлендә дә мәдрәсәдә укытуын туктатмаган, соңыннан, авырып урынга егылгач та, шәкертләренә өендә дәрес биргән. Үләренә ике көн калганда, ул үзенең бер шәкертенә яңа гына язып тәмамлаган «Мөстафадел әхбар...»ына кайбер төзәтүләр әйтеп яздыра.

Замандашларының әйтүенчә, Ш. Мәрҗани үзен бик гади тота, кеше белән аралашканда, ягымлы һәм игътибарлы булуына карамастан, үз позициясен яклаганда, нык һәм принципиаль, искелек тарафдарлары белән көрәштә аяусыз була. Аның өчен дәреслек бар нәрсәдән дә өстен була. Якыннарының фикерләре дә, динче фанатикларның каргышлары да үзе дөрес тапкан максатка ирешү өчен көрәштән аны туктата алмыйлар. Атасының, кешеләрдән аерылмаска һәм купчелекнең фикере белән санашырга кирәк, дип үгетләвенә каршы ул: «Суконныйларда да купчелек бар. Купчелектән бигрәк хакыйкать вә тугрылыкны алда тотарга кирәк»,— дип җавап бирә. (Мәрҗани. Казан, 1915, 176 б.). Сүз дөреслек һәм кешелек дәрәҗәсе турында барганда, Мәрҗани үз заманының иң бай, иң танылган кешеләре белән арасы өзелүдән дә курыкмаган, моның авырлыкларга һәм югалтуларга дучар итүенә, эшендә зур күңелсезлекләргә китерүенә дә карамыйча, үз фикерендә торган.

Көнчыгышны өйрәнүче күренекле рус галиме академик В. В. Бартольд Ш. Мәрҗанине «татарлар арасында прогрессив агымга нигез салучы» дип атады [8].

Ш. Мәрҗанинең фидакарь эшчәнлеге татар халкының фикер үсешендә тирән эз калдырды. Мәрҗани Марксны белми иде, дөньяны аңлауда ул революцион демократ дәрәҗәсенә дә күтәрелә алмады. Әмма татар чынбарлыгы шартларында аның эшчәнлеге тулы бер эпоханы тәшкил итте. Мәгърифәтче үзенең бер әсәрен «Әл-бирак

---

[6] Шиһабетдин Мәрҗани. Казан, 1968, 20 б.

[7] Г. Ибраһимов исемендәге институт архивы, 22 ф., 1 тасв., 20 эш, 157 б.

[8] Бартольд В. В. Сочинения, т. 4. М., 1966, 133 б.

әл-вәмиз фи әр-рәдди галя әл-бәгыйзи әл-мөсимми би-ән-нәкыйз» дип атый, кыскача әйткәндә, дошманнарны юк итүче яшен дигән сүз. Чыннан да, аның чыгышлары татарның караңгы тормышын яктырткан яшен булды.

Ш. Мәрҗани татар иҗтимагый фикере тарихында тәнкыйть юнәлешенә башлап сукмак салучыларның берсе була. Аның искелек калдыкларын фаш итүче чыгышлары бик күпләрне хөр фикерлелеккә китерә, хакыйкатьне эзләү юлына басарга өйрәтә. Шуңа күрә татар халкының асыл егетләре Мәрҗани исемен тирән ихтирам һәм горурлык белән искә алганнар. Г. Ибраһимов аны бөек остаз һәм татар халкының фикри уянуының таң йолдызы дип атады. Татар культурасының Г. Тукай, М. Гафури, Ф. Әмирхан кебек күренекле әһелләре дә аңа югары бәя бирделәр.

Дини фанатикларның һәм реакцион байгураларның Ш. Мәрҗанигә яла ягарга тырышуына карамастан, аның эшчәнлеге гади халык арасында да теләктәшлек таба. Әйтик, 1853 елның 15 декабрендә Ш. Мәрҗанинең указы алынуга һәм мәдрәсәсендә дәрес бирү хокукыннан мәхрүм ителүенә ризасызлык белдереп һәм аны кире эшкә кайтаруны сорап, мәхәллә халкы тарафыннан Диния назарәтенә язылган хатлар, үтенечләр дә шушы хакта сөйлиләр [9].

Ш. Мәрҗанинең күпкырлы фидакарь эшчәнлеге тугандаш халыкларның алдынгы фикер ияләренә дә уңай йогынты ясады. Абай Кунанбаев, Ахан-Сәрин, М. Сералин кебек казах шагыйрьләренә Мәрҗани эшчәнлегенең шифалы йогынты ясавы — тарихта мәгълүм факт. М. Сералинның Ш. Мәрҗанине «халыкка хезмәт иткән кеше» дип бәяләве әнә шул хакта сөйли [10]. Күренекле казах язучысы, академик Мохтар Ауэзов Абай әсәрләренең рус телендә чыккан җыентыгына язган кереш сүздә: «Ул (Абай) шулай ук татарларда мәгърифәтче-новатор булып саналучы Шиһабетдин Мәрҗани әсәрләрен дә белә иде».— дип язган [11]. Мәрҗани эшчәнлегенең Урта Азия халыкларының иҗтимагый фикеренә шифалы йогынтысы турында күренекле таҗик язучысы Садретдин Айни, профессор А. М. Баһаветдинов һәм башкалар да күрсәтеп уздылар.

Ш. Мәрҗани Россиядә генә түгел, ә аннан еракларда да таныла. Аның хезмәтләре, эшчәнлеге белән Көнчыгышта да, Көнбатышта да кызыксыналар. „Zondon Publishina Kompany" 1874 елның 30 мартында аңа махсус хат юллый. Компания Ш. Мәрҗанидән энциклопедия өчен фоторәсемен һәм автобиографиясен җибәрүне сорый. Бу үтенеч канәгатьләндерелә. Аның белән Тунис, Каһирә, Мәдинә, Һиндстан, Төркия һәм башка илләрнең галимнәре дә кызыксына. Ш. Мәрҗани биографларының берсе, күренекле татар язучысы һәм галиме Риза Фәхретдинев Мисыр журналы «Әл-мөктатыйф»тан түбәндәге өзекне китерә: «Берничә еллар үткәннән соң, бездә галим Шиһабетдин бине Баһаветдин бине Сөбхан бине Габделкәрим әл-Мәрҗанинең «Вафиятел-әсляф вә тәхиятел-әхляф» исемле китабы килеп җитте. Ул — Европа Россиясенә буйсындырылган Казан өлкәсе галимнәреннән. 1293 ел хиҗри белән күрсәтелгән китабы безгә килеп җиткәнгә күрә, мин бу ихтирамга лаек кеше әле дә исәндер дип уйлыйм. Аның китабы — сүзләр сайлавының һәм сөйләменең синтаксик төзелеше ягыннан гадилеге, фикеренең тирәнлеге буенча Мисыр, Димәшкъ яки Гыйрак галимнәренең моңа охшаган әсәрләреннән берсеннән дә калышмый» (Мәрҗани. Казан, 1915, 414 б.). Болар барысы да Ш. Мәрҗанинең дөньякүләм танылган галим булуы турында сөйлиләр.

Кеше акылын рухи коллыктан коткаруны тирән аңлаган Ш. Мәрҗани үзенең бөтен гомерен прогресс өчен, кешеләрнең аңын уяту, хәбәрдарлыгын киңәйтү өчен көрәшкә багышлады. Шуңа күрә дә аның эшчәнлеге татар халкының иҗтимагый фикер үсеше тарихында тирән эз калдырды.

---

[9] БАССР УДА, И-295 ф., 3 тасв., 3499 эш, 84 б.

[10] Сералин М. Марҗани.— «Айкап», 1915, 2 сан.

[11] Кунанбаев А. Лирика и поэмы. М., 1940. 26 б.

## Шиһабетдин Мәрҗани

# КАЗАН ҺӘМ БОЛГАР ХӘЛЛӘРЕННӘН ФАЙДАЛАНЫЛГАН ХӘБӘРЛӘР

*Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. Казан, 1897*

1 КИСӘКТӘН ӨЗЕКЛӘР

Бу тарих фәне — барлык миллә̄т һәм кабиләләрнең хәлләрен эченә ала, гыйльми тармакларны һәм фәнни бәхәсләрне тикшерә торган фән. Гади халык һәм белмәүчеләр аны белергә тели. Гыйлем ияләре аны өйрәнүдә тырышлык күрсәтәләр. Тышкы яктан карaганда, ул ханнар турында кимчелекле бер уйдырма һәм әкияткә охшаса да, чынлыкта, төптән караганда, аның һәрбер сүзе мәгълүм бер төшенчәне эченә ала; аның һәрбер җөмләсендә яшерен хикмәтләр, серле фикерләр тулган. Тышкы яктан ул заман һәм дәүләтләр турында хәбәр бирә, эчке яктан, аларның әүвәлге эшләренең һәм хәлләренең хакыйкатен әзли һәм җентекләп тикшерә; яшәешнең барлыкка килү серләреннән хәбәр бирә, аның үзенчәлекләрен һәм тирән сәбәпләрен ачып күрсәтә. Бел, ул — хикмәтләр диңгезенә чумган чын гыйлем һәм башка фәннәрне дә үзара бәйли торган хөрмәткә лаек фән... (3 б.)

Без инде хәбәрдар булганыбыз хәтле Болгар һәм Казан хәлләренә бәйләнешле булган хикәятләр, хәбәрләр, риваятьләр һәм сүзләрне кулыбызга төшкән кадәр китаплардан, язмалардан җыештырып бу китапны төзибез. Чөнки тарихчының вазифасы — үзе хәбәрдар булган һәм игътибарга лаеклы булган сүзләрне, хәбәрләрне арттырмый, киметми, ничек бар шулай китерү, эчтәлегенең төп өлешен төшереп калдырмыйча һәм берәүнең файдасына, яки икенченең зарарына тарафдар булмыйча аңлатып бирү. Булганны яхшымы ул, яманмы, булганынча бәян итү. Әмма берәү үз белдеге белән генә берәүне мактап, берәүне яманлап, берәүнең яхшы, берәүнең начар эшләрен генә сөйләсә, ул кеше гөнаһлы була. (5—6 бб.)

## Болгар дәүләте, аның халкы һәм Болгар шәһәре

Бу Шәһре Болгар — Идел елгасының төньягында, Чулман елгасының[1] Иделгә кушылган почмагына урнашкан. Ул урында экватордан илле биш градус төньяк киңлектә, Канар утрауларыннан алтмыш җиде градус көнчыгыш озынлыкта һәм төшлек ноктасыннан унбиш градус чамасы көнбатыш тарафында тора. Халык телендә моны Искәндәр әл-Макидуни[2] нигез салган дип тә йөртәләр. Гайсаның тууына ике гасырдан артыграк элек төзелеп, зурлыгы уртача гына булса да, утырган урыны — тармаклары күп булган ике зур елганың бер-беренә коя торган ноктасына якын бер урында булганлыктан, төрле яктан һәм чит илләрдән дә зур сәүдәгәрләр килеп катнаша торган мәшһүр һәм зур базарлы бай дәүләтләрдән санала иде. Зур пристане, сәүдәханәсе булган бу төзек шәһәрнең халкы — борынгы вакыттан бирле бай культуралы һәм сәүдәгәрләре булуы белән дә, күп сәфәр һәм сәяхәтләре белән дә мәшһүр булып дөньяга танылган иде. Монда күп төрле ерак илләрдән галимнәр, сәүдәгәрләр, ә гарәпләрдән казыйлар, укытучылар һәм вәгазь сөйләүчеләр килә торган булган.

Шуннан соң, өстенә килгән һәртөрле бәла һәм фетнәләр сәбәпле, (Болгарның) ул яхшы вакытлары узып, (тарихи роле) Казанга күчә башлый һәм ахырда үзе бөтенләй харап булып югарыда әйтелгән мактаулы хәленә Казан варис булып калды.

Шәһре Болгар — җир йөзенең өч яки дүрт кисәгеннән берсе булган

Өзекләрне сайлап алучы һәм хәзерге татар теленә тәрҗемә итеп хәзерләүче СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни хезмәткәре Әнвәр Хәйруллин.

[1] Чулман елгасы — Кама елгасы.
[2] Искәндәр әл-Макидуни — Александр Македонский.

Европа өлешендәге Румия һәм Кастантиния[3] дән кала, беренчеләрдән булып культурага ирешкән һәм Әндәлес[4] мәмләкәтеннән соң, бәлки бер үк гасырда ислам диненә күчкән шәһәрдер...

Бу Болгар халкының мәмләкәте борынгы заманнарда көньягыннан Бабел-әбваб[5], ягъни Дәрбәнд, Тифлис һәм Ширванга, Кавказ таулары, бәхре Хәзәр[6] буена һәм Дагыстан тарафларына, хәтта Әрмәнстан иленә хәтле сузылган булган. Көнбатышта Нократ елгасыннан, Дон, Самар, Сура һәм Ока елгаларының башлары, Көнчыгышта Урал таулары, Харәзм, Сыгнак һәм Шаш, төньякта Россия белән чикләнгән булган. Болгар мәмләкәтендә булган һәр кабилә бер урынга, яки бер су буена урнашып, төрле исемнәр белән исемләнеп йөртелгәннәр. Мәсәлән: «Чирмешән болгарлары», «Нократ болгарлары», «Бәхре Хәзәр болгарлары», «Түбәнге болгарлар», «Тимтүче болгарлар» дип аталганнар. Күп төрле кабилә, нәсел һәм сыйныфлар булып, кабилә, ыруг патшалары үрнәгендә һәркайсының күп санлы хакимнәре булса да, алар тагын олы бер патшага таянып һәм буйсынып яшәгәннәр. Күп исемнәрне эченә алган Сәкалибә, Кыпчак, Хәзәр, Болгар, Җуҗи улусы, Үзбәк иле исемнәре белән, мәмләкәтләре исә төрле вакытта Сәкалибә иле, Дәште Кыпчак, Хәзәр иле, Болгар иле, Татар иле, Җуҗи улусы, Бату урдасы, Бәррийятел-Бәрәкәт һәм Үзбәк иле исемнәре белән аталып йөртелгәннәр. Бу мәмләкәттә булган шәһәрләр: — Олы шәһәр, ягъни Шәһре Болгар, Нократ Болгары, Суар, Сонфар, Биләр, Ашлы, Хизан, Туфҗән, Сабакүл, Кашан, Чылматы, Ибраһим кальга[7], Кызлар, Исбел, Кирмәнчек, Басыф мирза, Керчь, Жукотин (Җукәтау — Ә. Х.), Аклан, Саксын, Фису, Гамикъ, Шабран, Зәнкеран, Сәмәндар, Хәмлиҗ, Бәләнҗәр һәм Бәйда шәһәрләре. Иң әүвәл Кыпчак һәм Хәзәр хаканнары[8] хөкүмәтендә, соңыннан Болгар әмирләре хөкүмәтендә, аннан соң татар ханнары хөкүмәте карамагында булып, Болгар мәмләкәте хәзерге вакытта өч йөз елдан артык инде Россия хөкүмәте идарәсендә. Сәүдәләре: — кол, кәнизәкләр, бал, кеш, сусар, тиен, төлке, балык җилеме, куян, карсак[9], Болгар күне, һәм сәхтиян[10], балык мае, мамонт теше, шәм, кәҗә тиресе, саури[11], чикләвек, куй, сыер, сугыш киеме, кылыч, ук, каен агачы, бүрек, кәләпүш, гәрәбә һәм башка шуның шикелле әйберләр белән булган.

## Болгар халкының килеп чыгышы хакындагы фасыл

Тарихчы мөселман галимнәренең ачык итеп билгеләүләренә һәм башка шуны күрсәтүче хәлләргә, сүзләргә карагандa, болгар халкы — төрек кабиләсеннән[12].

Ибне Фазлан да аларны «төрек» дип әйтә.

Шулай ук Ибне Халдун да, Шәриф Идрисигә ияреп, аларны «төрекләрнең бер тармагыннан»,— дип саный.

Тарихчы галимнәрнең иң олыларыннан Гали бине әл-Хөсәен әл-Мәсгуди ал-Багъдади: «Алар төрекләрнең бер төркеме, алардан һәм аларга һәм кәрваннар йөреп тора; әмма алар бүтән төрек кабиләләреннән өстенрәк»,— ди.

Шәмсетдин әд-Димәшкый әйтә: «Әндәлес иясе аларны, ягъни хәзәр һәм болгарларны төрек халыклары арасында санады»,— ди. Ә икенче урында «Берәү алардан — «Сез нинди халык? Болгарлар кемнәр алар?»— дип сорагач,— «Төрек белән сәкалибә арасында туган халык»— дип җавап бирделәр»,— ди.

«Рисаләтел-интисаб»[13] исемле китапта: «Болгар җире — мөселман төрекләре иле. Алар Габбасилар[14] хөкем сөргән заманда Мәәмүн[15] һәм Васикъ

---

[3] Румия, Канстантиния — Рим, Византия, Константинополь.
[4] Әндәлес — Испаниянең бер өлеше (Андалузия).
[5] Бабел-әбваб — ишекләрнең ишеге. Гәрәпләр Каспий диңгезе белән Кавказ таулары арасындагы тар юлны шулай дип атаганнар.
[6] Бәхре Хәзәр — Каспий диңгезе.
[7] Кальга — кала, крепость.
[8] Хакан — хан.
[9] Карсак — куянның бер төре.
[10] Сәхтиян — кәҗә тиресеннән ясалган югары сыйфатлы болгар күне.
[11] Саури — мөгез.
[12] Төрек кабиләсеннән — биредә Мәрҗани «төрек» сүзен «төрки» мәгънәсендә куллана.
[13] «Рисаләтел-интисаб» — кардәшлекне өйрәнүгә багышланган әсәр.
[14] Габбасилар — Мөхәммәд пәйгамбәрнең агасы Габбасның оныгы Әбел-Габбас төзегән династия.
[15] Мәәмүн хәлифә — 813—817 елларда хакимлек итә.

биллаһ[16] хәлифәлеге вакытында мөселман булдылар; икенче мәртәбә әл-Каим би-Әмериллаһ[17] хәлифәлегендә утыз мең кеше мөселман булды»,— диелә...

Аларның телләре, калдырган әсәрләре, әхлаклары, йолалары, гореф-гадәтләре дә төрки.

Телләре турында Истахри, Ибне Хаукаль һәм Гарнатый: «Болгар теле хәзәр теле кебек», — диләр. Хәзәр теле, әлбәттә, төрки тел.

Шәһәр һәм мәмләкәтләренең исеме «Болгар»— төрки теле белән «болгамак» сүзеннән алынган киләчәк заман фигыль, ә «болгады» сүзе үткән заман фигыль. «Суны болгады», «эшне болгады» диләр. Бу урында исемләштереп, «катнаш» һәм «катыш» мәгънәсендә алынган. Шәһре Болгарда сугылган кайбер тәңкәләрдә вау[18] хәрефе белән «Булгар» дип язылган булуы моны артыгы белән куәтли. Димәшкый язуында да шул мәгънәгә ишарә бар.

Моннан башка тагын патшаларына «хан», «белеквар» дигән исем бирүләре дә төрки булганлыкларын күрсәтә, чөнки «хан» асылда төрки сүзе булып, каф[19] хәрефе белән «кан» дип язылa. «Белеквар» сүзенең кяф[20] хәрефе белән булуы ачык. «Белек» сүзе «белмәк» фигыленнән ясалган исем була һәм ул — «гыйлем» һәм «гакыл» мәгънәсендә кулланыла. «Вар» сүзе — җирле сөйләмдә «бар» рәвешендә «б» хәрефе белән языла, төрләнми торган фигыль. Димәк, «Белеквар» сүзе, «Белекбар» дип ике сүздән кушылып ясалган, ягъни «галим», «акыллы» мәгънәсендә килеп, мактау сыйфаты, мактау исеме булып кулланыла... (8—11 б.).

Болгарларның әсәрләреннән, мәсәлән: «Нәһҗел-фәрадис» «Башла гали», «Йосыф китабы», «Нәсыйхәтес-Салихин», «Бәдәвам» китаплары кебек төрки китаплар, «Нәүруз» бәетләре, «Шәһре Болгар газилары» бәетләре бар. Кайберәүләр күбесенчә бик иске язу белән язылганнар. Бер карашта өч-дүрт йөз ел элек язылган әсәрләр диярго мөмкин, ә язулары — Болгар шәһәрендә табылган кабер ташларындагы язуларга бик охшаганнар. Мондый китаплар бу мәмләкәтләрдә басма һәм язма хәлдә бик күп табыла. Башка мәмләкәтләрдә күрелгәне һәм ишетелгәне юк. Бу китапларның теле госманлы[21], чыгтай[22], төрекмән һәм казакъ телләреннән аерылып тора.

«Нәһҗел-фәрадис»нең башында «бисмиллаһи»дән соң, аллага мактау, пәйгамбәргә сәламнәр әйткәч, болай диелә: «...Гомәр углы Габдулла — пәйгамбәрдән риваять итеп әйтә: бер мөэмин-мөселман минем хәдисләремнән «Кырык хәдис»не ишетмәгән кешеләргә җиткерсә, белмәгәннәргә өйрәтсә, алла ул кешене галимнәр дәрәҗәсеннән исәпләр, кыямәт көнендә шаһитләр[23] җөмләсеннән тергезер. Әгәр дә ул кеше белә торып мин әйтмәгән сүзне пәйгамбәр (алла аңа сәламен күндерсен) әйтте дип ялганласа, үзенә тәмугта урын хәзерләнгән булыр...

Бу китапка «Нәһҗел-фәрадис» дип исем куелды. «Оҗмахларның ачык юлы» дигән мәгънәдә була. Өмет тә шул. Ахырында: «...икенче көнендә, 759 (1357) елда Сарай шәһәрендә язылды. Язучысы галим һәм гыйльме белән гамәл итүче, бөтен кешеләрнең остазы... Мәхмүд бине Гали бине әс-Сараи мәншаән вәл-Болгари мәүлидән вәл-Кәрдари...[24]», дип язылган...

Бу тел аларга Җуҗи һәм Бату урдасыннан кермәгән булса кирәк, чөнки бу — аларның телләреннән аерылып тора һәм алар кул астында мөселманнар бик аз һәм бик күчсез булганнар. Бәрәкәт хан гәрчә 640 (1242) елда ислам диненә кергән булса да, аның халкы арасында ислам дине ныгып урнашып китә алмаган. Күбрәге мөселман динендәге казакълардан булып, мөселман хан гасырында мөселман, ә мөселман булмаган хан булса, аңар ияреп, аныңча яшәгәннәр.

Татар кабиләсендә исә ислам дине — Үзбәк хан һәм аның углы Җанибәк хан заманында куәт тапты һәм ныгып урнашты. Шуңа күрә нугайларда «дин Үзбәктән калды» дигән сүз бар имеш. Аз гына заманда алар шушы мәмләкәттә яшәүче төрле кабиләләргә үз телләрен кертә алмаган-

---

[16] Васикъ биллаһ — 842—847 елларда хакимлек итә.
[17] әл-Каим — 1031—1075 елларда хакимлек итә.
[18] Вау — «у» хәрефенең гарәпчә аталышы.
[19] Каф — калын әйтелешле «к» хәрефенең гарәпчә аталышы.
[20] Кяф — нечкә әйтелешле «к» хәрефенең гарәпчә аталышы.
[21] Госманлы — Төркиядә яшәүче төрекләр.
[22] Чыгтай — борынгы үзбәк халкын шулай атаганнар.
[23] Шаһитләр — сугышта һәлак булган кешеләр, изгеләр.
[24] Болгарда туып, Хәрәзмдәге Кәрдар өлкәсендә булып, Сарайда яшәп иҗат итүче.

нар. Бәс, шулай булгач, бу тел — Болгар халкының үз теле булырга тиеш... (13—14 бб.)

Бу «Бәдәвам» китабы — борынгыдан калган, бик иске китап. Утыз имән авылының Габдеррәхим мелла язган китап, дип йөртү нигезсез... (23 б.)

Әбел-Габбас Әхмәд бине Фазлан бине әл-Габбас бине Рәшид бине Хаммад әл-Багъдади — Болгар иле, аның патшалары һәм халкының хәле турында ачык хәбәрләр белән китап язучы мөселман галимнәрнең беренчесе. Аны — Габбасия хәлифәләреннән әмирел-мөэминин әл-Мокътәдир биллаһ Әбел-Фазыл Җәгъфәр бине әл-Могтәзыйд хәлифә хәзрәтләре — үзенең Сәһсән әр-Расиби һәм Бәдәр әл-Хәрәмиләрдән торган һәм Болгарга җибәрелгән илчеләренә секретарь итеп билгеләгән булган. Яшьлегемдә аның китабының кайбер кисәкләрен күреп, берникадәр нәрсә язып алган идем. Анда Якут әл-Хәмәви һәм башкалар язганнан күп артык сүзләр бар иде. Кызганычка каршы, хәзер дә аны кайда куйганымны белмим. Ибне Фазлан ул рисаләсендә болай ди: — «Сәкалибә патшасы Алмас бине Сәлки Белекварның әмирел-мөэминин хәлифә әл-Мокътәдир биллаһ хәзрәтләренә язган хаты килеп ирешә. Хатында ул хәлифәдән, «иленең барлык шәһәрләрендә һәм төрле якларында торып ислам динен һәм шәригатен өйрәтерлек галимнәр; мәсҗед һәм мөнбәрләр төзеп чит ил патшаларының явыз теләкләреннән саклау өчен шәһәренә кальгалар салу өчен оста эшчеләр җибәрүне»,— сорый. Хәлифә хәзрәтләре аның бу теләкләрен кабул итеп, галимнәр һәм төрле өлкәдә эшли белүче осталар җибәрде. Дәүләт эше буенча вәкил — Бәдәр әл-Хәрәми, ә илче Сәһсән әр-Расиби иде. «Багъдад хәлифәлегенең башкаласы булган Мәдинәтес-сәламнән һиҗрәтнең 309 (921) елында сәфәр аеның унберенче көнендә Болгарга карап юл тоттык».

Хорасан һәм Харәзем аркылы килеп,— юлда күргән һәм ишеткән вакыйгаларны язганнан соң Ибне Фазлан болай дип дәвам итә: «Барырга дип ниятләп чыккан кешебезгә — Сәкалибә патшасына бер көнлек юл калганда, Сәкалибә патшасы безне каршы алырга үзенең хөкүмәтендәге дүрт патшаны һәм үзенең туганнарын һәм балаларын чыгарган иде. Алар безне икмәк, ит, ат азыгы — тарылар белән каршы алып, үзләре дә безнең белән бергә йөрделәр. Шәһре Болгарга ике фәрсәх ара калганда, патша үзе чыгып безне каршы алды. Безгә күзе төшкәч, ходага шөкер итеп сәҗдә кылды. Җиңе эчендә тәңкәләр бар иде, безгә аны чәчте. Без анда 310 (922) ел мөхәррәм аеның уникесендә, якшәмбе көн килеп җиттек. Харәземнең Җөрҗания шәһәреннән анда җиткәнче җитмеш көн вакыт үтте. Безгә чатырлар, киез өйләр утырттылар, без аларга кереп җайлаштык һәм чәршәмбе көнгәчә, ягъни хәлифәнең патшага язган хатын тыңлар өчен үз җирендә булган патшалары, мәшһүр кешеләре җыелып җиткәнче, без шунда тордык.

Пәнҗешәмбе көн төеннәребезне ачып, киемнәребезне чыгардык, җибәрелгән ияр белән атны иярләдек. Габбасия хәлифәлеге билгесе булган махсус кара киемне һәм чалманы патшага кидердек. Мин хәлифәнең Болгар патшасына язган хатын чыгарып укыдым. Патша хөрмәт һәм олылау йөзеннән аякка басып тыңлады. Моннан соң, ул вакытта хәлифәнең вәзире булган Хәмид бине Габбасның хатын укыдым. Бу вакытта да патша аяк өстендә торды. Ул үзе — зур гәүдәле, симез тәнле, авыр бер кеше иде. Аның якыннары безгә тәңкәләр чәчтеләр. Без үзебез алып килгән бүләкләрне чыгарып күрсәттек. Аның хатынына да бүләк кием кидердек, ул иренең янында утырган иде, аларның гадәтләре шулай икән. Шуннан соң патша безне үзенең сараена чакырды. Аның уң ягында патшалар утырган иде, безгә үзенең сул ягына урын тәкъдим итте. Балалары — алдында утырганнар, ул үзе фәкать Рум дибаҗы[25] белән генә капланган бер тәхеткә утырган иде. Боерык бирүе белән табын хәзерләнде, алдына кәбаб[26] китерделәр. Патша аннан өч мәртәбә кисеп алып авыз иткәч, тагын бер кисәк кисеп алып, Сәһсән әр-Расибигә бирде. Шулай итеп һәркемгә аерым ашъяулык килде. Рәсми гадәтләре шулай икән. Патша авыз итмичә торып һичбер кеше ашка кул сузмый. Һәркайсыбыз бер савыттан ялгыз ашап, калганын — тора торган җиребезгә алып кайттык. Ашап туйганнан соң эчемлек — бал сорап алды, аны «сөҗү» диләр, үзе дә эчте, без дә эчтек... (59—60 бб.)

Аларның бик әче яшел алмалары бар, аны кызлар ашап симерәләр.

Ул йортта чикләвек агачыннан күп агач юк, 40 мөрәббәгъ[27] фәрсәх

---

[25] Дибаҗ — ефәктән тукылган пәрдә, җәймә

[26] Кәбаб — кыздырган ит

[27] Мөрәббәгъ — квадрат

чамасы урманнары — шуның белән тулы. Анда мин тагын бер агач күрдем, ләкин нинди агач икәнен белмим. үзе бик биек, буенда яфрагы юк, башы хөрмә агачы башы шикелле, яфраклары башында җыелып тора. Ул агачның бер җиреннән тишеп, астына бер савыт куеп, суын алалар; балдан да тәмлерәк була, кеше күбрәк эчсә исерә. Тәрҗемәче[28] фикеренчә, бу агач каен булмаска кирәк, чөнки каен булган тәкъдирдә аны Ибне Фазлан белеп, «хәдәнҗ» дип аңлаткан булыр иде.

Тагын Ибне Фазлан болай ди: — «Аларның күбрәк ашаган азыклары — тары һәм ат ите. Шулай ук аларда арпа белән бодай да күп. Һәркем иген иксә, уңышын үзе ала, патшалыкка бирелә торган хак юк, ләкин алар һәр йорттан патшага үгез тиресе бирәләр». Тәрҗемәченең фикеренчә, бу үгез тиресе дигәннәре, безнеңчә әйткәндә, иләп эшләнгән һәм «болгари» дип йөртелә торган калын күн булырга кирәк.

«Әгәр патша берәр тарафка, берәр шәһәргә һөҗүм итеп, таларга гаскәр җибәрсә, гаскәр белән бергә аңа да өлеш була,— ди.

Аларда балык маеннан башка май юк, аны зәйтүн мае урынына тоталар, шуның өчен, алар исле булалар. Алар — барысы да башларына бүрек киялəр, патша — үзе генә, ялгыз йөри, әгәр ул базардан үтеп китсә, барлык халык урыныннан торып, башыннан бүреген алып, култык астына кыстыра. Патша узып киткәч, алып киялəр. Патшаның алдына кергән вакытта олысы һәм кечесе булсын, хәтта үз балалары һәм туганнары да, патшаның күзе төшкән вакытта башларыннан бүрекләрен алып култык асларына кыстырып, башлары белән ишарә кылып утыралар һәм патша утырырга кушканчы аягүрә торалар, һәркем утырганда, тез чүгеп утыра. Бүрекне патша алдыннан чыгып китмичә күрсәтмиләр, чыккач кына башларына кияләр.

Аларда яшен яшьнәү бик күп була. Әгәр дә берәүнең йортын яшен сукса, үзе янып беткәнче аңа якын бармыйлар, аны алланың ачуы төшкән җир диләр.

Әгәр аларда берәү гадәттән тыш данлы, мактаулы, бик тырыш һәм зур гыйлем иясе булса, моның хакы — раббебез аллаһы тәгаләгә корбан булу,— дип, тотып муенына бау бәйләп, агачка асып куялар һәм шунда үзе өзелеп төшкәнче асылынып тора.

Мөтәрҗим[29] фәкыйрь әйтә: «Хәзерге заманыбызда әйтелә торган, «күпне белсәң асарлар, юаш булсаң басарлар» дигән әйтем шуннан калган булырга тиеш...

Аларның ирләре дә, хатыннары да ялангач килеш бергә су коеналар, бер-берсеннән бер дә яшеренмиләр. Суга кергәндә хатыннар ирләрдән пәрдәләнсеннәр, яшеренсеннәр дип күпме тырышсам да, теләгемә ирешә алмадым,— ди Ибне Фазлан.

Аларда зина кылу бер дә юк, әгәр дә берәү зина кылса, нинди кеше булуына карамастан, дүрт казык кагып ике кул һәм ике аягын шул казыкларга бәйләп ир һәм хатынны муеныннан ботына кадәр балта белән ярып, һәрбер кисәген бер агачка асалар. Каракка да шундый ук җәза бирәләр...» (61—63 бб).

Болгар халкы батыр йөрәкле, баһадир, курку белмәс, сугышчан, диндар, изгелекле булган. Шуның өчен сугыш коралын олылаганнар, хөрмәт иткәннәр һәм бу сыйфатлары белән мактанганнар да. Хәтта кабер өсләренә куйган ташларында да «сугышчан ир» дигән сүзне аңлата торган «юари», «каракаршы сугыш батыры» дигән сүзне аңлаткан «шуари», «фәхес», шулай ук, «үкеш» һәм «изгелек иясе» шикелле сүзләр язганнар. Аларның кыскача хәлләре Византия һәм Рум халыкларына, аларның патшаларына, милади белән 500 ел ахырында мәгълүм булулары турында хәбәрләр бар. Аларны шул тирәләргә ясаган һөҗүмнәреннән белгәннәр, аларны «һуннар», «утугырлар», «кутугырлар» дип берничә исем белән атаганнар. Аларның юлларын кисү, илләренә ясала торган һөҗүмнәрен туктату өчен император Анастасия озын һәм биек койма койдырса да, туктата алмады. Алар император Юстиниан гасырларында тагын һөҗүм иткәннәр. Икенче елда янә икенче мәртәбә һөҗүм итсәләр дә, бу юлы үзләре җиңелүгә дучар булганнар.

Болгар патшаларыннан Зөбәер хан дигән кеше Идел елгасы буеннан кузгалып, бик зур куәт белән йөреп, славяннарны һәм башка бик күп таифәләрне ияртеп, атлы гаскәрләре белән Дунай суын боз өстеннән үтеп, шул та-

---

[28] Ш. Мәрҗани үзе.
[29] Мөтәрҗим — тәрҗемәче. Бу очракта Ш. Мәрҗани үзе.

рафларда булган мәмләкәтләрне талап, халкын үтереп, үзе Кастантиниядән утыз чакырым җиргә килеп җиткән. Юстиниан кайсар бик каты куркып калтырап, тетрәп, малларын һәм кыйммәтле нәрсәләрен крепосте астына яшереп алып калган һәм башкаласы да чак кына котылып калган.

Моннан соң, Идел елгасының көнчыгыш тарафыннан «Бәян хан» дигән бер кеше чыгып, Болгар халкын һәм башка шул мәмләкәттә яшәүче таифәләрне үзенә буйсындырган. Аннары Болгар хөкемдары Карабат[30] дигән кеше күтәрелеп, аның үзеннән соң өч углы кала. Беренчесе, ягъни олы углы — Батбай, үзенә буйсынучылар белән үз ватанында кала һәм бераз вакыт үткәч Хәзәр хөкемдарына буйсына. Икенчесе Котраг, Дон елгасының көнбатыш ягына үтеп, шул җирне үзенә ватан иткән. Өченчесе — Асбаруг, халкының күбрәге һәм терлек-туары белән Днестр елгасыннан үтеп, кайбер славяннарны үзенә буйсындырып «Берҗан» мәмләкәтендә нигезләнгән. Алар Дунай елгасының тирә-ягын талаганлыктан, Константин кайсар коры җирдә һәм диңгездә зур көчләр туплап гаскәре җиңелеп качкан. Болгарлылар җиңгәннәр дә, кайсарга һәм Дунай буендагы башка мәмләкәтләргә салым салганнар.

Шул заманда, һиҗринең 60 (679) елында болардан бер төркем халык аерылып, Дунай буена нигезләнеп, «Кечек Болгар дәүләте» дигән мөстәкыйль бер хөкүмәт төзегәннәр. Рум халкы аларны «Кечек Болгар» исеме белән, Итеп елгасы буендагы борынгы «Зур Болгар»дан аерып йөрткәннәр. Кайбер тарихчылар Зур Болгарны — «Кара Болгар», кайсылары — «Ак Болгар», яки «Эчке Болгар» дип аералар. «Кара» дип исемләүләре Габбасия хәлифәләренә ияреп, аларның тамгасы булган кара байрак һәм кара киемгә ихтыяр итүләренә бәйләнгән. «Ак» дип, мәдәниятле һәм гыйлем ияләре булганлыктан, ә «Эчке» дип, исламга кергән яки хәлифәлек хөкемендә булганлыктан әйтелгән булыр...

Ибне Хаукаль, Ибне әл-Әсир һәм башкалар болай диләр: «358 (968) елда Россия хөкемдары үз иле һәм күршеләре, кыпчактан бер төркем төрекләр ярдәме белән болгариларны җиңгәч үзара солых ясаганнар, ул сугышта болгариларга бик зур таркаулык китергәннәр. Алар таш суда йөзә башлаганчы, колмак төпкә батканчыга кадәр солыхны сакларга тиеш булганнар. 374 (985) елда Россия хөкемдары Владимир Болгарга килеп, ныклы нигездә чынлап солых ясаган. Ислам динен яхшы дип танып, үзе ислам диненә керергә булган. Моннан соң Суздаль җирендә ачлык булганда, болгарлар россиялеләргә күп икмәк биргәннәр...

Ибне әл-Әсир һәм Ибне Халдун болай дип әйтәләр: «Татарлар Дәрбәнд тарафыннан килеп чыгып, шул тирәдә яшәүче мөселманнарны, кяферләрне, бигрәк тә лан, кыпчак һәм русларны үтереп, бик каты талап, яндырып, бөтенләй харап булу дәрәҗәсенә китергәннәр. Болардан бушангач, 620 (1223) елның ахырында Болгар мәмләкәтенә барырга уйладылар. Болгар халкы бу хәбәрне ишеткәч, алар юлында берничә җирдә дошманнан яшеренеп, посып тору урыннары — бөктермәләр ясап, аларга каршы чыкканнар. Татарлар килеп, посып тору урыннарын әзрәк үткәч тә, болгарилар боларның артларыннан чыгып, һәр яктан урап алып сугыш ачып, аларны үтереп бетергәннәр, бик азы гына качып котылып, Сәкъсин ягына киткәннәр һәм Талкан дигән җирдә үзләренең патшалары — Чыңгыз ханга юлыгып, барлык маҗараларны сөйләп биргәннәр. Бу вакыйгадан соң Дәште Кыпчак татарлардан бушап калган. Юллар тынычланып, сәүдәләр ачылып киткән һәм элеккечә кәрваннар йөри башлаган. Кыпчакларның һәм русларның да сәламәт калганнары илләренә кайтканнар».

633 (1235) елда Бату хан гасырында, татарларның Субутай дигән гаскәр башлыгы белән зур көчләре Болгарга килгәннәр. Болгарлар аларга түбәнчелек һәм итагать күрсәтеп, татар мәмләкәтенең бер өлеше булырга һәм аңа салым түләп торырга риза булганнар. Шулай итеп татарлар аларны бөтенләй үз кулларына алганнар, әмма дәүләтләрен бетермәгәннәр. Болгарлар аларга яраклашып акча сугуда һәм хотбаләрдә үзләрен телгә алсалар да һәм салым түләсәләр дә, кайвакытта аларның кыргыйлыклары һәм эчке дошманлык сәбәпле арада сугыш һәм бәрелешләр дә булып торган. Мәсәлән, Мәнгү Тимер хан бик зур гаскәр белән Болгарга һөҗүм итеп, аны җиңгән һәм солых төзеп кайткан...

---

[30] Болгар хөкемдары Карабат — Сүз VII гасырда Азов диңгезе, Дон, Кубан һәм Дунай елгалары буенда яшәгән болгарларның хөкемдары — Кубрат хан турында бара.

Алмас хан гасырында Болгарның үзендә һәм читтән килүчеләр арасында дин һәм шәригать хөкемнәреннән хәбәрдар булган галимнәр һәм хакимнәр булган дип уйланыла. Шуңа да карамастан ул татарларның иске мәкальләрендә әйтелгәнчә «Олы казанда кайнаган ит чи калмас» дип, Багъдад хәлифәлегенә илчеләр җибәреп, дин һәм ислам әдәпләрен, кием кию һәм тормыш рәвешләрен өйрәнү өчен ислам хәлифәсеннән галимнәр, һәрбер эштә оста булган белгечләр сораган. Әмма үзләреннән махсус, ачык итеп язылган тарих китаплары калмаганлыктан, патшаларның, галимнәрнең һәм башка кешеләрнең күпчелегенең дөрес хәлләре мәгълүм түгел. Болгарның казые булган Ягъкуб бине Ногман әл-Болгари дигән кешенең Болгарга багышланган махсус тарих китабы булганлыгы билгеле булса да, ул китапның нөсхәләре хәзерге заманда табылмый. Хәтта үзебезнең гасырыбызда Аруфи[31] дәүләтләре махсус игъланнар бастырып, зур игътибар белән, төрле ислам мәмләкәтләреннән ул китапны һәм Ибне Фазланның рисаләсен эзләсәләр дә, һичбер җирдә барлыгы мәгълүм булмады.

Әбү Хамид әл-Әндәлеси 529 (1134) елда шәһре Болгарга килгәч, «Болгар тарихы» иясе белән күрешеп, аннан күп сүзләр күчереп сөйли.

Зәкәрия бине Мөхәммәд әл-Казвини аны Әбел-Мәгали Габделмәлик бине Габдулла әл-Җөвәйнең юлдашыннан иде, ди. Бу шәхес 559 (1163) елда вафат булды... (73—78 бб.).

Шәһре Болгарның кайсы заманда Россия кулына керүе, кайчан һәм нинди сәбәпләр белән җимерелүе мәгълүм түгел. Язмыш аркасындамы, берәр дошманлык сәбәплеме — һичберсе ачык түгел. «Тимер харап кылды дигән»,— сүз дөрес булган очракта да, аның аркасында бөтенләе белән җимерелеп, ташландык булып калуы турында уйлау кирәк түгел. Руслар әмир Мөэмин заманында харап кылды дигән сүз дә ышанычлы түгел. Аннан башка тагын «Болгарны 677 (1278) елда татар патшаларыннан Мәңгү Тимер хан харап кылды»,— дигән сүзләр дә бар, ләкин һичкайсында тәмам җимерелгәнлеге турында хәбәр юк. Татар җәмәгатьчелеге телендә «Болгарны Канаш»[32] исемле әскаф[33] харап итте — җимерде»,— дигән сүз дә йөри. Бу сүз дөрес булса, да, үзенең фанатизмы сәбәпле, бәлки берничә бинаны җимерсә җимергәндер. Татар халкы авызында Идел кичү сәбәпле җимерелде»,— дигән сүз дә бар... Хәтта хәзерге гасырыбызга кадәр сакланып калган ике манарасының зурысы егылгач, шуның кайсы елда җимерелеп төшкәнен эзләп, сорап, байтак вакыт үткәннән соң гына бу мәгълүматлар Спасс өязе Олы Чаллы авылының мәрхүм Фазлулла бине Бохарайның язма җыентыгыннан табып алынды. Ул «1260 (1844) һиҗридә сишәмбе көн кичәсендә, рамазан аеның 19 ында, ярты төндә җимерелде»,— дип яза.

Бу шәһре Болгарның мәсҗеде һәм манарасы борынгы төзелешләр икәне ачык, бәлки, Багъдадтан килгән илчеләр җитәкчелегендә булган осталар ярдәме белән салынган булганнар... (91—92 бб.)

## Казан, казан татарлары, аларның гореф-гадәтләре, кием-салымнары

Россия 961 (1552) ел ахырында татарларны җиңеп, Казан шәһәрен һәм аның тирә-юнен яулап алганда, кальга эчендә сигез манаралы бер мәсҗед җамигъ[34], «Таҗик ермагы» дип йөртелгән урында тагын бер мәсҗед һәм мәдрәсә булган. Галимнәрдән, хөрмәткә лаек габбасилардан һәр бөек сәедләрдән[35] күпмедер шәхесләр булып, аларның башында нәкыйбел-әшраф[36] дип танылган мелла Шәриф Кол исемле бер зат торган. Бу ислам ханнары һәм шәһәр халкы алдында ихтирам һәм зур хөрмәткә лаек булган.

Россия князьләре Казан ханнарына илчеләр аша хатлар күндергәндә,

---

31 Аруфи — Европа
32 Канаш — 1740—1755 елларда Казанда епископ булып торган Лука Канашевич турында сүз бара.
33 Әскаф — епископ.
34 Мәсҗед җамигъ — баш мәчет, җомга намазы укыла торган мәчет.
35 Сәед — башлык, җитәкче. Мөхәммәд пәйгамбәр нәселеннән булган кеше.
36 Нәкыйбел-әшраф — бөекләрнең җитәкчесе.

мелла Шәриф Колга да махсус хат һәм бүләкләр җибәрә иделәр,— дип сөйлиләр. Ахырда россиялеләр Казанга һөҗүм иткәндә, ул үзенең иярченнәрен җыеп мәдрәсәгә кергән һәм мәдрәсә түбәсенә чыгып россиялеләр белән бик каты сугышкан. Руслар аны мәдрәсә түбәсеннән чәнчеп төшергәннәр һәм ул — шулай итеп шәһид булган...

Хәзерге кәндә кальга капкасыннан башлап, университетка хәтле сузылган төз һәм киң урам һәм кальга капкасыннан чыгып, ике якка төшеп киткән урамнар — ислам хөкүмәте заманында да шулай булган. Бу заманыбызда борынгы мөселманнардан калган истәлекләрдән бер манара бар. Аны мөселманнар «хан мәсҗеде» дип, руслар «Сөембикә манарасы» дип атыйлар. Кальга эчендә хәзер банк урнашкан бина һәм «дом» дип йөртелә торган губернатор сарае янындагы «Таҗик ермагы» исемле ермакта бер мәсҗед һәм мәдрәсә булган.

Болакның көньягында, хәзерге «Печән базары» дип йөртелгән урында, мөселман каберлеге булган. Руслар Казанны алганда, Шаһгали хан, гаскәр белән килеп, Зөя тамагында Зөя шәһәрен салган һәм шул тирәдә булган чуаш, чирмеш, калмык кебек халыкларны Россия кул астына керткән. Казанга һөҗүм вакытында Шаһгали хан алар (руслар) яклы булып килгән. Казан мөселманнары хәзерге Җиһанша мәсҗеде[37] каршындагы чиркәү урынында булган Нугай капкасыннан чыгып, бик каты сугышканнар. Шуннан соң, Шаһгали хан каберләр өстендәге агачларга яшеренеп Болакны кичкән һәм Арча кыры тарафына үткән. Шәһәрне руслар алганнан соң да мөселманнар бераз вакыт мәетләрен шул каберлеккә күмгәннәр... Рус халкы аларны (татарларны) кимсетү, хурлау рәвешендә татар дип әйтүләреннән кайсыберләре татар булуны бер кимчелек санап, ул исемнән чирканып, «без татар түгел, без мөселман»,— дип тавыш-җәнҗал чыгаручылар да бар. Нинди кызганыч хәл, бу исемнәр (татар белән мөселман) арасында Нил белән Ефрат елгалары арасындагы ераклык кадәр зур аерма бар бит! И мескен! Әгәр синең мөселманнан башка бер исемеңне дин һәм милләтең дошманы белмәсә иде, сине, әлбәттә, «мөселман» дип дошман күрерләр иде. Татар булмасаң, гарәп, таҗик, нугай түгел, кытай, рус, француз һәм немец та түгел, инде кем буласың? Яхшы әле сарт, чирмеш, мукшы, ар халыкларының барлыкларын белмәгәннәр, сине ул исемнәрнең берсе белән атамаганнар. Әгәр дә шулай булган булса, үзеңне чирмеш, я мукшы санап шуңа риза булып йөрер идеңме?.. (2—3 бб.).

Казан һәм аның тирә-ягында яшәүче мөселманнарның күбесендә, гомумән алганда, Казан артында һәм бигрәк тә Алат юлындагыларның гадәт һәм тормышларында, каберлекләргә куелган ташларның язуларында финлык әсәрләре һич беленми. Бу исә аларның асылда төрек, кыпчак яки татар булуларыннан; яки алардагы мөселманчылык куәтеннән; яисә галимнәрнең халыкны ислам хөкемнәре буенча тотарга тырышканлыкларыннан; яисә сәүдә мөнәсәбәтләре аркылы һәм динлелектә алга киткән халыклар белән аралашуларыннан булса кирәк. Хатын-кыз җәмәгатенең бу кадәр динле булуы, намаз һәм башка гыйбадәтләрне үтәүдәге тырышлыклары — бүтән һичбер мәмләкәт халкында күрелгәне һәм ишетелгәне юк. Аларның башларына ураган өрпәкләре, күкрәкләрен каплар өчен кигән күкрәкчәләре, озын җиңле күлмәкләре хатын-кызлар өчен иң муафыйк киемнәр. Ләкин хәзерге заманда калфакны озак вакыт киеп йөрү гадәте керәп, иргә баргач та, хәтта чәчләре агарганчы калфак кия торган булып, өрпәк салу гадәте бетүгә якынлашып бара.

Безнең гасырыбыздан элек хатын-кыз күлмәгендә итәк бер дә булмаган. Безнең гасырыбызда, әүвәлге күлмәкләре асылдан, ефәктән, бурлат[38] яки ситсы булып, күлмәк җиңнәре бик озын һәм бик киң, култык астында, ягъни җиң төбендә икенче төсле нәрсәдән дүрт почмаклап итеп кештәк («хештәк»[39] тән үзгәртелгән — Э. Х.) куя иделәр. Хәтта бер хатынның кештәге бала юрганына җитәрлек булган дип сөйлиләр. Бай хатыннары итәкләренә ике рәт итеп яхшы, кыйммәт бәяле лента тоталар, аның югарыдагысы тар, түбәндәгесе — киң иңле була иде. Урта дәрәҗәдәгеләр яшел, сары яки

---

[37] Җиһанша мәсҗеде — хәзерге Г. Тукай һәм Г. Камал урамнарында урнашкан 15/14 номерлы йорт. Профтехучилище урнашкан бина.

[38] Бурлат — комач.

[39] Хештәк — ялгау.

кызыл төсле, бер, яки ике катлы лента тоталар иде. Фәкыйрьләр һәм гади халык та шулай ук итеп бурлат яки чытны тар гына итеп тоталар иде. Бай хатыннарының башларында ак калфак, аякларында читек-башмак, колакларында көмештән алка, беләкләрендә беләзек, бармакларында йөзек, чәчләрендә толым буенча тезгән һәм алтынчылар суккан тәңкәле, очында көмештән коелган чулпы, муеннарында укадан эшләнгән яка була. Ул якага көмештән биш буйлы, кайберләренең өч буйлы челтәр, фирәзә һәм башка төсле асыл ташлар утыртылган була иде.

Моннан соң инде саф ефәк, яки катнаш ефәк белән аралаш эшләнгән калфаклар чыкты. Алардан соң бүрекләр барлыкка килде. Аны энҗе һәм кыйммәт бәяле якут, зөбәрҗәт, фирүзә, алмаз шикелле ташлар һәм алтын тәңкәләр белән бизәкләп кияләр һәм бер бүрекнең бәясе ике мең сумга һәм артыграк бәягә дә барып төшә иде.

Моннан соң тагын, төрле төстәге хәтфәләрдән юл-юл итеп тегелгән калфаклар кияләр, кайчакта чалма да кияләр иде. Аннан соң энҗе тирәле калфаклар таралды. Инде болар барысы да бетеп, хәзер бик кечкенә хәтфә калфаклар кия башладылар, аңа энҗе тезеп кию бик яхшы кабул ителеп, таралып китте. Күлмәкләрен төрле асыл, йон тукымалардан яки чыттан киң һәм ике катлы итәкле итеп тегеп кияләр, шул ук күлмәкләре белән бер үк төсле тукымадан камзол да тегеп кияләр. Хәзерге тарихтан илле ел элек бик байлар да, чәч тезмәсенә тезәр өчен суккан тәңкә белән генә канәгатьләнгәннәр. Соңыннан инде рус тәңкәләренең утыз, илле тиенлекләрен, тора-бара бер сумлыкларны. Екатерина тәңкәләрен тезәләр иде, аннан соң биш сумлык һәм ун сумлык алтын тәңкәләр дә тезә башладылар. Ике толым буенча ун сумлык тәңкәдән барлыгы 34 данә тәңкә тезеп, авырлыгыннан башлары авырткanлыктан аларны җилкәләренә салып утырып, мәҗлестән кайткач башлары авыртудан зарланалар иде. Хәзер инде болар бетүгә якынлашып баралар һәм җәтмәләп энҗе тезеп толымнары өстенә тагу гадәте чыкты. Хәзер моның да кызыгы бетеп, игътибардан төшеп калды, фәкать чәчләренең очларына һәм төпләренә икешәр алтын тәңкә генә куя башладылар.

Беләкләренә энҗе тезеп тагалар. Кайберләре биш сум, ун сумлык алтын тәңкәләр, кайберләре Истамбулдан алдырып төрек алтын тәңкәсен (маҗидияне) тезеп тагалар, муеннарына берничә катлап тезеп тапас яки мәрҗән яки мәрвәриттән берничә кат итеп тезмә асалар.

Инде, электә мөселман булып та, кайбер сәбәпләр белән исемдә генә христианлыкка кергән мәкруһлар[40] һәм «керәшен» дип йөртелә торган татарлар хәленә килик. Бу таифәнең теле һәм ирләренең киемнәре мөселманнарныкы кебек булып, хатыннарының киемнәре икенче төрле буларының сәбәбе нәрсәдә икән? Әллә мөселманнарның киемнәре дә электә шундый булып, әкренлек белән генә үзгәрү кичереп, керәшен хатын-кызларының киемнәре үзгәрмичә искечә калдымы икән, әллә бу халык асылда төрек булмыйча, фин халкыннан идеме икән?

Казан халкында финнарга охшашлык булмаса да, Казаннан ераграк урыннарга аларның йолалары, гореф-гадәтләре, киемнәре һәм башка яклары белән бер-берсенә охшаулары күп табыла. Мәсәлән, илле еллар чамасы элек Сембер[41] тирәсендәге авылларда хатыннар ак киндер күлмәкне тар гына итеп тегеп, җөй буйларына бер генә илле киңлектә[42] комач тегәләр иде. Җиң һәм җилкәләренә кызыл яки яшел ефәк тегә торганнар иде. Ике-өч бармак киңлегендәге ике кат киндер яки асыл чүпрәк өстенә көмеш акча тезеп, хәмаил[43] итеп киеп, исемен «муен тамыр»дан үзгәртеп, «путемар» дип атаганнар. Аларның өйләренең эчке ягы чуаш өйләре кебек кап-кара, чөнки төтеннәре өй эченә чыга торган булган. Хәер, бу хәмаилне асылда алар башка халыклардан алганнар, чөнки ул гарәп халкында һәм Казан халкында да булган. Казан хатын-кызлары аның исемен үзгәртеп, «әмайли» дип, кайберләре «бөти» дип тә атаганнар. Ләкин алар — алтын тәңкәләр, яки кыйммәтле ташлар, иң кимендә яхшы көмеш әйберләр һәм тәңкәләр белән бизәлгән булганнар... (29—31 бб.)

---

40 Мәкруһлар — начар күрелгәннәр, сөйкемсезләр, ямьсезләр.
41 Сембер — хәзерге Ульяновск шәһәре.
42 Бер илле киңлектә — бер бармак киңлегендә.
43 Хәмаил — хәситәнең бер төре.

**Мирза Шаһиәхмәд бине Мөхәррәм бине Габдеррәшид бине Гали бине Рәскә әл-Казани әш-Шәмәки.** Чыгышы — Тәтеш өязендәге Шәмәк исемле авылдан. Ләкин монда сөйләнгән бабалары һәммәсе — Казан шәһәрендә, Яңа бистәнең төньяк-көнбатыш өлешендә, хәзер Наласа пулаты дигән зур таш йорт урынына яшәп, кайбер җыентыклардан күренгәнчә, карт бабалары — 1147 (1734) елда,— рәбигаль-әүвәл аенда, углы Габдеррәшид 1206 (1791) елда, җомга көн, рамазан аеның егерме өченче көнендә вафат булганнар.

Мирза Шаһиәхмәд Казан шәһәрендә туып, мөселман һәм рус мәктәпләрендә укыган, Казан һәм Уфа шәһәрләрендә хөкүмәт хезмәтләрендә булып, аеруча Казанда шәһәр башлыгы идарәсендә һәртөрле хезмәтләрне башкарып, ахырда полицмейстер киңәшчесе, ә 1254 (1838) елда шәһәр башлыгы урынбасары урынын алып, бик гайрәт һәм тырышлык белән, Казан халкын дер селкетеп торып, идарә эшләрен гаделлек белән башкарды. Бөтен эш моның кулында иде. Егерме ел тоташтан шушы эшне башкарып, «мең башы» дәрәҗәсен алып, 1274 (1857) елда үзенең үтенүе буенча хезмәттән азат ителде. 1292 (1875) елда, мөхәррәм аеның унҗидесендә, якшәмбе көнне вафат булды... Яше җитмешкә якын иде... (342-343 бб.)

**Мелла Мөхәммәд Әмин бине Ярмөхәммәд бине Мәмәш әл-Казани.** Тумышы белән Казаннан. 1154 (1741) елның мәүлед аенда[1] туган. Күңелдән чыгарып язарга оста кеше булганлыгы мәгълүм. Яңа Бистә төзелеше мәсьәләсендә Петербургка сәфәр кылып, гариза биреп дәүләттән рөхсәт алган. Мәликә тарафыннан кабул ителгән, аның тарафыннан үзенә ярдәм күрсәтелә һәм үтенечләре канәгатьләндерелә. Аңа китапханәдән теләгән китапларын алырга рөхсәт ителә. Шуннан файдаланып, ул «Фәтавә-и Казыйхан», «Шәрехен-никая лиш-шәмнә» исемле китапларны һәм теле җиңелрәк булган башка җәүһәрләрне алып кайткан. Әүвәлге икесе варисләры кулында әлегә кадәр сакланалар, үзем күрдем. Үз кулы белән дә гарәп телендә бер китап язган. Бу китап шул бер үк каләм белән «хуҗасы Мөхәммәд Әмин бине Ярмөхәммәд мелла, 1246 (1733) ел дип тәмамланган... (104-105 бб.)

**Мелла Сәлим бине Габдеррәхим әс-Сабави.** Мамадыш өязенең Байлар Сабасы авылыннан. Үз авылында — «Рәхим Сәлими», ә Бохарада булганда — «дамелла Сәлим» дип йөрткәннәр. Үз иле галимнәреннән гыйлем алып югары дәрәҗәгә ирешкән. Пугач фетнәсе вакытында 1187 (1773) елның азагында аңар кушылган. 1188 (1774) елда ул тар-мар ителгәч, Казан шәһәренә керә алмыйча качып китеп, Казакъстанга, ә аннан Бохарага барган. Шунда яшәп 1223 (1808) ел азагында вафат булган.

Фикъһе гыйльмендә яхшы гына галим булган. Кайчагында исерткеч эчемлекләрдән дә авыз иткәләгән. Бервакыт Болгар иленнән Бохарага бара торган сәүдәгәрләр белән казакълар арасында бәрелеш чыгып, казакълардан кайбер кешеләр үтерелгән. Казакълар Бохара мөфтиләренә кат-кат барып, булган хәл турында кәгазьгә теркәтеп, гаризалар калдырсалар да, бу зат аларны бер-бер артлы дәлилләп кире каккан. Ахыр чиктә «Бу казакъларның дәгъвасы нугайларга карата, ә без нугай түгел, без татар кабиләсеннәнбез. Казакъларның дәгъвасы нугайга, безгә түгел икән ләбаса»,— дип дәгъваларын юкка чыгарган. Казакъларга дәгъва кылырга юл тәмам ябылгач, бер кичне Бохара әмире Шаһмурад би Сәлим мелланы есаул җибәреп үз янына алдырган. Бу бик зур куркуга төшеп барса да, әмир тәмам ачылып: «Бәрәкалла, дамелла, фикъһе гыйльмене мондый маһирлыкка һәм мәгърифәткә кайда өйрәндегез»,— дип шаяртып алганнан соң — дөрес, казакъларга дәгъва кылырга инде юл калмады. Ләкин алар бик кара, надан халык, бәрәр фетнәгә сәбәп булмасыннар дип хәвефләнәм. Шуңа күрә, дамелла, Сездән үтенәм, сәүдәгәрләрегездән бераз акча җыеп биреп, алар белән килешсәгез икән дигән. Мелла Сәлим: «Бик хуп, тәкъсир, шулай итәрбез»,— дип кайтып киткән һәм сәүдәгәрләрдән акча җыеп, казакълар белән килешүгә ирешкән... (220-221 бб.)

**Мелла Әбеннасыр Габденнасыйр бине Ибраһим бине Ярмөхәммәд бине Иштирәк әл-Курсави.** Анасы — Миһербан бинте Әмин бине Мансур. Макса башы исемле авылдан чыккан. Мәчкәрәдә мелла Мөхәммәдрәхим ахуннан башлангыч белем алгач, Бохарага сәфәр кылган. Анда бераз вакыт ишан

---

[1] Мәүлед ае — мөселманнарда Мөхәммәд пәйгамбәр туган ай булганга күрә, шуңа ай исемләнгән.

Ниязколый әт-Төрекмәнигә аңгәмәдәш була һәм башка кайбер галимнәр белән дә аралаша. Соңыннан үз ватанына әйләнеп кайтып, Курса авылында имам, хатыйб һәм мөдәррис була. Анда җизнәсе һәм апасының угыллары булышлыгы белән зур мәдрәсәләр салдырып һәм күп шәкерт җыеп, дәрес әйтә.

Имам Газзалинең «Ихъяэл-голум» исемле китабына һәм хаклык эзеннән барган башка борынгылар фикеренә таянып ул җәмәгатьчелеккә туры, дөрес юнәлеш күрсәтеп чыккан. Ахыр килеп соңгы чор галимнәренең һәм кәлям[2] фәне белгечләренең туры юлдан һәм иманнан тайпылуына каршы төшкән.

1223 (1808) елда икенче тапкыр Бохарага барып, анда Бохара халкының иман һәм фикъһе мәсьәләләрендә дөрес юлдан һәм борынгы изгеләр мәзһәбеннән[3] тайпылуларына каршы чыккан, андагы галим-голяма белән зур бәхәсләргә кергән. Ахыр чиктә ул әмир Хәйдәр каршысына чакырылган. Анда да сүз күп була. Бәхәстә катнашкан галимнәрнең күпчелеге я белмәүләре, я тискәрелекләре аркасында, ә кайберләре әмирдән куркып, аның сүзенә колак салмыйлар, мәгънәсез сүз куертып, аның фикеренә җаһиланә каршы төшәләр һәм инкарь итәләр. Үтерү белән куркытып, әйткән сүзләреннән һәм «ялгыш инануларыннан» тәүбә итәргә мәҗбүр итәләр. Яңа инану тексты яздырып, аны яттан укытып, «Минем инануым һәм мәзһәбем шушы»,— дип тәсдыйк иттереп «хаталарын» таныган итеп күрсәтәләр. Булган китаплары яндырыла. Хәтта, «әгәр кемдә дә булса китаплары табылса — ул кеше үтереләчәк»,— дип кешеләрне кисәтеп урам буйлап кычкырып йөрү өчен мөнадилар[4] чакырыла.

Шул вакыйгалардан соң Габденнасыйр Бохарадан чыгып китеп Хивага килә һәм Хаҗитархан аркылы үз иленә кайта. Бераз вакыттан соң хаҗ кылу нияте белән сәфәр чыгып китә һәм 1227 (1812) елның рамазан аенда, солтан йорты Кастантиниягә барып җитә. Шунда ваба авыруы белән вафат була һәм Өскедар шәһәрендә җирләнә.

Бохарада зур шөһрәте булганлыктан Габденнасыйрның исеме хәзерге көндә дә билгеле. Аның белән булган вакыйгалар кеше телендә әле дә сөйләнеп йөри. Кайберәүләр «алланың сыйфатларын танымады», ә кайберәүләр «сыйфатларының күп санлы булуы ваҗиблыгына инанучы» иде дип дөреслеккә каршы торып сөйлиләр. Араларында аның белемендәге өстенлекне изге иманлыгын һәм сүздә турылыгын танучылар да бар. Мелла Мөхәммәд бине Сафар әл-Хөҗәнди («дамелла Хаҗибай» дип тә йөртелә) аның турында белем дәрәҗәсе һәм дөрес инануы белән танылган иде дип сөйли торган булган. Мирза Габдеррәхманның мелла Габденнасыйрны мактап сөйләү һәм аңа булган карашы, мелла Һидиятулла әл-Гөлананиның һәм казый Торсонбакый бине Габдеррәхим әл-Болгариның да аңа яхшы караашта булулары һәм югары бәяләүләре турында хәзергәчә сөйлиләр. Шулай ук мелла Әхмәд бине Сәгыйдь эш-Шырдани — мелла Гайса бине Рәхмәтулла әл-Хоканди мелла Низаметдин бине Сираҗетдин әс-Сәлими казый, мелла Рәхмәтулла бине Габдеррәхим һәм казый Әбү-Сәгыйд әс-Сәмәркандиләр дә мелла Габденнасыйрны гыйлеме һәм белеме, көчле булуы һәм батырлыгы җәһәтеннән искә алалар.

Мелла Әбеннәгыйм мәхдүм Казан халкы арасында таралган төшенчәләрне кулланып «мелла Әбеннасыр — Бохара галимнәренең һәммәсен бер тишеккә тыгып китте»,— дип искә ала иде.

Ул Казан шәһәрендә Апанай Хафиз балаларыннан булган байларның кияүләренә килә торган булган. Әмма гасырында булган Казан галимнәре мелла Әбеннасыр чакырылган мәҗлестән кача торган булганнар. Бервакыт Муса бай мелла Фазылны иртә белән чәйгә алырга җибәргән. Инде килеп җиткәч, мелла Фазыл хадимнән: «Анда кунак яки мәҗлес бармы?»— дип сораган. Тегесе: «Юк, Курса мулласы гына бар»,— дип җавап биргәч, мелла Фазыл арбасыннан төшеп, туктап та тормыйча, җәяүләп Яңа Бистәгә кайтып киткән. Бер мәҗлескә мелла Ибраһим әфәнде һәм аның кияве мелла Таҗетдин әл-Иштирәки мелла Габденнасыйр булганлыктан кабат-кабат чакырылып та бармый калганнар. Мелла Җамалетдин бине Шәмсетдин

---

[2] Кәлям — догматик дини тәгълимат.

[3] Мәзһәб — дини юнәлеш.

[4] Мөнади — Көнчыгышта хөкүматнең карарын яки берәр вакыйга турында хәбәрне урамнарда кычкырып белдереп йөрүче.

эс-Сабавый остазы мелла Сэйфетдин бине Эбүбәкер эс-Сабавыйның шул нәрсәне Бохарада алып кына куймадылар лабаса!» — дигәнен искә ала иде. Атабыз мәрхүм әмир Хәйдәрнең мелла Әбеннасырны үтерми калдыруына үкенеп сөйли иде.

Ниязколый эт-Төрекмәни ишан Бохараның зур мәчетендә хатыйб вазифасын үтәгән. Әмма мелла Ташмөхәммәд эл-Бостани ишан мелла Ниязколый мелла Әбеннасырга инанган дип, аңа иярми торган булган. Кышкар имамы мелла Фаяз аның бертуганы мелла Габид бине Габделгазиз һәм башка кайберәүләр бер мәҗлестә сөйләшеп утырганда мелла Габид тә кыяр-кыймас кына акрын гына сүз башлап карый. Ләкин мелла Әбеннасыр «аяклан, бозау, аяклан»,— дип авызын томалап, сүз әйттермәгән. Башкалар белән мөгамәләсе дә шундыйрак булган.

Бертуганыбыз мелла Садретдин аның хакында яхшы һәм кире яклар турында хөкем йөртеп, «бик зур галим булмаса да, саламәт табигатьле, дөрес фикерле, алдан күрүчән, тәкълидне кире кагучы, әкрен генә, сеңдереп кенә сөйли торган, батыр йөрәкле булып, замандашлары арасында тиңдәшсез булган. Ә гыйлем өлкәсендә чыннан да киң һәм бөтенесен эченә алган кеше түгел»,— дип фикер йөртә. Ләкин гыйлем киңлеге турында сүз алып барганда, аның үз вакытындагы шөһрәтен, замандашлары һәм гасырдашлары белән чагыштырып булмый[5].

Мелла Габделхәбир бине Габделваһһаб эл-Мөслиминең мелла Әбеннасырның «Һәфтияк тәфсирен» мактап язылган мәкаләсен китерәбез:

Азлап кына булса да мисез каләмнән дөнья йөзен ягымлаучы сүзләр барлыкка килә.

Әбеннасыр Габденнасыйр бине Ибраһим эл-Курсави әфәнде хәзрәтләре һиҗри белән 1185 еллар (1771) тирәсендә дөньяга килде. Ул кечкенәдән үк фикер йөртүгә сәләт күрсәтә, каләме белән саф гөлбакча барлыкка китерә, үзен затлылык белән каплый һәм ватаны булган Казан өлкәсендәге Курсаның данын күтәрә. Үзенең төрле фәннәрдән маһирлыгы, бөтен нәрсәләрнең серенә төшенә һәм караңгылыкны җиңә алуы, шөһрәте, һәр нәрсәдән хәбәрдар булуы белән гасырдашлары арасында тиңдәшсез иде.

Ш и г ы р ь: Көнчелектән Йосыфны яшереп чокырга салсалар да,
Аның исемен һичничек оныттыра алмаслар.

Мәгърифәтнең чиксезлеге, иманының куәте, гайрәте, төрле гыйлемнәргә нык бирелгәнлеге, тапкырлыгы, зирәклеге һәм телгә осталыгы белән дан казанды. Ул вакыйгаларны төшендереп бирә алуы һәм алдан күрүчәнлеге белән мактаулы. Аны кечеләргә һәм олыларга бертигез карый алуы, үз-үзен тотышы һәм күркәм булуы да бизи.

Иң әүвәл Казанда ничәмә-ничә укымышлы һәм мөхтәрәм галимнәрдән белем алып, яшьлеге чәчәк атканда Мавәраэннәһергә китә, анда мәшһүр галимнәрдән һәм бөек шәехләрдән гыйлем тәхсыйл итә, һәр өлкәдә югарылыкка ирешә һәм үзенең гасырдашларыннан күпкә өстен була.

Ш и г ы р ь: Дөрес тәрбиянең минем өчен тиңе юк,
Күкәй сала торган тутый кош матур җырлый иде,

дип әйтелгәнчә, аның барлык белеме диярлек — фәкать үзенең изге сәләте һәм бөтен куәтен бирүе нәтиҗәседер. Үз көче белән, бары тик аллаһе тәгаләнең юмартлыгыннан файдаланып, гыйлеме ягыннан үзенең остазларыннан да узып китүе турында гади һәм югары катлам кешеләре арасында да мәгълүм булды. Хаклык һәм намуслылыкны яклап көрәшкәндә, ул үзен хурлаучыларның сүзләренә дә колак салмый уздыра иде.

Ш и г ы р ь: Хак сүзле җыр матурлыкны кылыч йөзеннән ала,
Әгәр хаклы кешедән җиңүче кыюлыгын алсаң,

дип әйтелгәнчә, аның илаһи эзләнүләр юлындагы тырышлыгы һәм гайрәте җиңеп чыкты. Рәхимле һәм шәфкатьле аллаһе тәгаләнең ярдәме белән Хәлилеррәхмандай (Ибраһим пәйгамбәрнең эпитеты) көрәшче булып җитеште һәм нәтиҗәдә аның кискен чыгышы Мавәраэннәһер дәүләтенең фанатик тарафдарлары фикеренчә какшамастай булган тәкълид ныгытмаларын өчен көчле җир тетрәведәй тәэсир итте.

Билгеле булганча, тәкълид заманында белем нигезләренә гомум һөҗүм ясап, халыкны мәгърифәттән аерды һәм мәгърифәтне тылсымлы пәрдә белән каплады.

---

[5] Моннан соңгы Курсавига багышланган язмалар фарсы телендә. Бирегә тәрҗемә бирелә.

Курсави үзенең зирәклек куәте белән мәгърифәт хәзинәсенең тылсымлы йозагын ачты һәм андагы гыйлемнәрне ачып салып, халык алдына кыйммәтле җәүһәрләр чәчте, моңа кадәр буй җитмәстәй тоелган чәчәкләрне һич кызганмыйча, халкына таратты. Ысуле фикъһе һәм иманга караган язмаларны һәр яклап шәрехләп, изге бабаларыбызның максатын бөтен тулылыгы белән аңлатып бирде. Бабаларыбызның рухына теләктәшлек күрсәтеп саф татар телендә ачык итеп ничәмә-ничә китаплар һәм тәфсирләр язды. Гыйлеменең нурлы кояшы иң югары ноктага җиткәч, ул ватаны Курсада шәкертләр тәрбияләп китаплар язды. Яше — якынча кырыкка җиткәндә хаҗга бару теләге белән сәфәр чыгып, Кастантиниядән Өскедарга килгәннән соң аның саф күңеленә: «Җәннәт бакчасы сине йөз күз белән көтә» дигән җыр ирешә һәм шунда ук авырып китте.

Дөньядан аерылу аңа борчу салды һәм 1227 (1812) елда ул гүр иясе булды...

Шигырь: Дөнья беркем өчен дә дәвамлы түгел,
Рәсулулла да анда мәңгелек түгел иде.

Моны язучы кодрәтле алланың рәхмәте алдында фәкыйрь Габделхәбир бине Габделваһһаб әл-Мөслими. 1276 ел (1859).

Бохарада галим исеме күтәреп йөргән, хәзергә кадәр исемнәре искә алына торган җаһил һәм дошман бер төркемнең Курсави турында һичнинди кануннарга сыймаган һәм начар тел белән язылган, дорфа, фәтваларыннан түбәндә өзек китерелә:

...Аның (Г. Курсавиның) тоткан юлы мөселманнар өчен чит нәрсә. Ул яклаган юлны кабул итү — диннең асылын, алланың берлеген һәм сыйфатларын инкяр итүгә кадәр җиткерә. Ул яклаган иманны кабул итү дини өйрәтмәләрнең асылын инкяр итүгә китерә. Киң таралган кәлям һәм фикъһе китапларында да хәзрәте имамның «Зур фикъһе» китабында да «үз-үзеңне күккә чөю һәм масаю — хөкем ителергә тиеш», дип әйтелә. Әгәр кем дә кем көферлектә, дәһрилектә, наданлыкта һәм намаз вакытында имамга иярмәүдә, фетнәдә, дингә ышануы йомшак булуда гаепләнсә һәм тәшвиштә икәнлеге мәгълүм булса, ул зинданга ябылырга яки үлем җәзасына хөкем ителергә тиеш. Шушы гөнаһларда гаепләнгән кеше — изге хөкем һәм галимнәр алдында җавап бирергә тиеш,— дип уналты шәхес мөһер басмыш.

1) Әмир Хәйдәр,
2) Хуҗа Гатаулла,
3) Казый Гыйнаят,
4) Мөфти Әбеннасыр хаҗи,
5) Казый Мирза Фазыл,
6) Казый Мир Габдулла мөфти Җуйбар,
7) Казый Торсонбакый,
8) Казый Мирза Нигъмәтулла мөфти,
9) Казый мирза Шәмсетдин,
10) Мөфти Мөгаллимшаһ,
11) Мөфти Гаваз,
12) Казый Ниязбирде,
13) Мөфти Мирзәйнетдин Мирәк хаҗи мөфти гаскәри,
14) Мөфти Мирза Габдеррәхман Әгълам һәм башкалар.

Бохарадан Болгар галимнәренә язылган фәтваның эчтәлеге:

Казан һәм Каргалы өлкәләре мөселманнарының бөек һәм укымышлы галимнәренә. Тарих 1223 (1808) елда нугайлы мелла Әбеннасыр мактаулы Бохара дәүләтенең гыйлем үзәгендә падишаһ сараена китерелеп, бөек галимнәр һәм мөхтәрәм фәкыйһләр хозурында үзенең әшәке фикерләреннән тәүбә итте. Аллаһе тәгаләнең зарур булган сыйфатларын икърар итеп, аның сыйфатларының күплеген инкяр итте һәм риваятьнең акылдан беренчелеген таныды. Шул турыда игълан итеп, үзенең әшәке фикерләренә таянып бернинди дәлилсез язылган әсәрләрен юкка чыгарды. Имзалар:

Шәйхелислам мәхдүм Гатаулла хуҗа.

Мөфти казый Мирза Шәмсетдин хуҗа.

Мөфти Мирза Габдеррәхман Әгълам.

Фәтваның ахырында өстәмә: Әгәр Габденнасыйр үзенең югарыда аталган фикерләреннән кире кайтып, әмир хәзрәтләре һәм бөек галимнәр хозурында Бохара дәүләтенең падишаһ сараенда, шушы вакытта тәүбә иткәннән соң да, үзенең ялгыш фикерләрендә калса, «мөртәд»,— дип игълан

ителәчәк. Аңа карата мөртәдләргә кулланыла торган чаралар кулланылачак һәм алла сакласын, аңа иярүчеләргә дә шул ук чаралар кулланылачак...

Казый Торсонбакый бине Габдеррәхим әл-Бохари хаты: «Болгар дәүләтенең изге фәкыйһләренә билгеле булсын: Габденнасыйр исемле шәхес тарих 1223 (1808) елда хәерле сәфәр аенда мактаулы Бохара дәүләтенең падишаһ сараена китерелеп, әмир хәзрәтләре, дин галимнәре һәм иминлек саклаучылары хозурында, дәһрилектә, динне танымауда, көферлектә, намаз вакытында имамга иярмәгәнлектә гаепләнеп үлемгә хөкем ителде. Соңыннан үзенең фикерләреннән кире кайтып тәүбә итте. Чынлыкта эш шулай тора.

Үзенең тәкълидтән баш тартырга өндәгән акылсыз рисаләләрен юк итте. Шуннан соң югарыда телгә алынган шәхес әлеге дәүләттән качты. Хәзер ишетелә ки, ул үзенең ялгыш фикерләренә кире кайткан, мөртәд булган. Югарыда телгә алынган дәүләтнең фәкыйһләренең һәм галимнәренең яманатын сата һәм үзен мактый имеш. Үзенең җиңелгәнен һәм түбәнчелеккә төшкәнен әйтмичә, булып үткән вакыйганы киресенчә аңлата. Кайбер сүзләрен безгә бәйле рәвештә дә сөйли имеш. Бу сүзләр чеп-чи ялган, ялагу һәм дәлилсезләр. Аның артыннан иярүче һәркем дөрес юлга кире кайта алмаячак һәм диннән язачак... Сезгә мәңгелек дога һәм сәлам белән... 1225 (1810) ел, җөмадиел-әүвәлнең 22 нче көне.

Мелла Мөхәммәд бине Сафар әл-Хөҗәнди, мелла Һидаятулла әл-Галәни һәм башкалар риваятенә караганда бу хат, фәтва астындагы өстәмә, мирза Габдеррахман Әгъләм һәм шулар кебек башкаларның бу инкярләре һәм кирелекле эшләре — Әмир Хәйдәрдән куркудандыр.

Кыскасы, мелла Әбеннасыйр бу мәмләкәттә булган галим-голямадан һәм гасырындагы башка кешеләрдән гыйлемлерәк, алдан күрүчәнрәк, турылыклырак булган. Алланың барлыгы, аның сыйфатлары мәсьәләләрендә һәм шуңа охшаш башка мәсьәләләрдә хак юлда Мавәраэннәһер һәм Болгар иле әһелләренә ясалган һөҗүмендә дөреслек аның ягында иде. Ул чын мәгънәсендә гыйлем һәм мәгърифәт иясе, ә нотыгы матур һәм нык ышанычлы иде.

Каты холыклы, әче телле булганлыктан, гасырында галим исемен йөрткән бик күпләрнең хәтерен калдырып, аларны үзенең дә һәм фикеренең дә дошманына әйләндерде. Шулай ук аларга ияргән соңгы дәвер әһелләрен дә үзенә каршылыкка төшерде. Боларның һәммәсе аңа дошманлык саклап һәм әйткән сүзләренә каршы барып «кяфер», «юлдан язган»,— дип халык арасында яман атын тараттылар. Әгәр ул ашыкмыйча, мөлаемрак итеп, акыллырак рәвештә, сүзләрен йомшак, матур итеп өйрәтү юлын тота алган булса иде, күпләр хакыйкый хәлнең һәм мәсьәләнең асылына ирешеп, аның йөзендә үзләренә җитәкче табып ялгышу һәм кяферлекләрдән азат була алырлар иде. Әбеннасыйрның тәрҗемәи хәленә караган «Тәнбиһе әбнаэ гасыр галә тәнзиһе әнбаэ Әбеннасыйр» исемендә кыскача рисаләбез бар. Язылган хезмәтләренең исеме ул рисаләдә һәм «Вафиятел-әслаф...»та телгә алына.

Мелла Надир бине Исхак әш-Шөкри, мелла Мөхәммәд Әмин бине Сәйфулла ән-Наласави, мелла Ногман бине Әмир бине Госман әс-Сәмани, мелла Җамалетдин әс-Сабави, мелла Әхмәд бине Сәгыйд әш-Шырдани, аның бертуганнары — мелла Габделвәли, мелла Габделгаффар һәм башка күбәүләр мелла Габденнасыйрның шәкертләреннәндер. Хаҗ сәфәренә киткәндә мәсҗед һәм мәдрәсәсендә ярдәмче булып үзендә укыган мелла Ногман калды... (168—175 бб.)

**Мелла Ибраһим бине Хуҗаш.** Чыгышы буенча Бөгелмә төбәгенең Шарлама исемле авылыннан. Әмма борынгы бабалары мәшһүр Мәчкәрә авылы күршесендәге Янгыл исемле авылдан. Атасы Хуҗашның кабере дә Янгыл авылында булып, хәзергә кадәр билгеле... Ләкин хәзер ул авыл кешеләре барысы да чирмешләр. Ибраһим әфәнде, Мөхәммәдрәхим ахунд белән бергә Кавказ тарафына сәфәр итеп, мелла Гали әфәнде әш-Ширвани һәм гасырының башка укымышлыларыннан белем алган. Мелла Гали хозурында язган китапларыннан «Рисаләи рәбгыль-мөкантарат» (Гөмбәзләре булган бина» язмасы) ахырында гарәпчә болай дип язып куйган: «Бөек алла тарафыннан кимсетелгән Ибраһим бине Хуҗаш әл-Болгари кулы белән шимбә көн иртән, рәҗәб аеның сигезендә, хуҗабыз, башлыгыбыз һәм охшарга тырышучыбыз Гали әфәнде әш-Ширвани йортларында хезмәттә вакытта, 1195 (1780) елда язылып, бу язма тәмам булды». Сүзе шунда тәмам. Шул — 1195 (1780) елда үз иленә кайтып, 1197 (1782) елда Утар карьясендә

аннан соң Яңа Кишет карьясендә имам булып, 1208 (1793) елның зөл-кагъдә аенда Казан шәһәренә килгән. Мелла Әбүбәкердән соң беренче мәсҗет җамигъда имам, хатыйб һәм мөдәррис булуына өстәп, Казанда ахунд булып гомер иткән. Мелла Мөхәммәдҗан мөфтигә якынаеп, хәтта догаларында: «Я рабби, мине мөфтигә якынлыгымнан аерма»,— дип дога кыла икән...

Мөфтигә якынлыгы, бай дөньясы киң булу һәм табигый кыюлыгы җәһәтеннән, Казанда туа башлаган кайбер яңалыкларны булдырмый калды дип сөйлиләр. Ул килгәндә, Казанда туйларда һәм башка мәҗлесләрдә ир һәм хатыннар бергә утыра торган булганнар. Казан кешеләре кара эшләпә, бормалы кара чикмән һәм итек киеп йөргәннәр. Башларына чалма кимәгәннәр. Бу кеше аларны бетерткән, мәчеткә барганда өйдән чалма киеп чыгуны, урамда һәм мәҗлесләрдә чалма киюне керткән. Никях вакытында намаз уку тәртибен, кияүгә намазлык бирү, кыз кияү йортына барганда, комган алып бару йолаларын да бу кеше уйлап чыгарды дип сөйлиләр. Хәтта кара эшләпәдән башка нәрсәсе булмаганлыктан Казан сәүдәгәрләреннән Йосыф бине Исмәгыйль бине Апанай, Йосыф бине Бикбау бине Хытай һәм ат сәүдәгәре Гобәйдулла бине Мортазалар дүрт-биш кеше берләшеп, Мәскәүгә барганнар һәм формага салдырып ак эшләпә эшләтеп кайтканнар. Казан кешеләре арасында ак эшләпә шуннан соң пәйда булган. Дәхи киндердән җиләнгә охшатып бер катлы нәрсә тегеп киеп, исемен «җәва» дип атаганнар. Казанда беренче булып Исхак бине Мостафа бине Мортаза бине Давыд бине Йосыф бер остадан җилән тектереп кигән. Ят нәрсә булуы да һәм нәзакәтлелеге белән шулкадәр күркәм күренгән, хәтта хатыннар җәмәгате дә җыйнаулашып аны күрер өчен барып карап йөргәннәр...

Сүз бара торган мелла Ибраһим әфәнде ир белән хатын арасында низаг булганда хатынны аерып җибәрү тарафдары булган һәм «барлык кешеләрнең дә никяхлары мәңгелек түгел»,— дип, җиңел генә аерып җибәргән. Хәтта үз кызы Мәхбүбәне дә мелла Давыд бине Биккенәдән шул юл белән эш кылып, аерып алган.

Бервакыт Сатыш авылында бер суд эше чыгып Ибраһим әфәнде анда барган. Рамазан исемле бер куштан ярдәмчесе белән әлеге эш буенча хөкем чыгарган булган. Әлеге куштан бер төрле канәгатьләнү белән үзенең акчасын чыгарып, икесенә урталай бүләр өчен Ибраһим әфәндегә биргән. Ләкин Ибраһим әфәнде бер тиен дә бирмичә, барлык акчаны үз кесәсенә салып куйган. Кайтып киткәндә арбага менеп утыргач, Рамазан: «Хәзрәт, барысын да үзләштердегез, безгә һичнәрсә дә булмый кала бит»,— дигәч, Ибраһим әфәнде аңа: «Казан шәһәреннән әфәнде килеп, Рамазан йортына төште» дип әйтү — сиңа зур дан, сиңа шул җитәр, дип җавап биргән дә туктап та тормыйча китеп тә барган. Озак гомер сөреп, 1241 (1825) елда, шәгъбан аенда Казанда вафат булган һәм Яңа каберлектә җирләнгән... (24—26 бб.).

**Мелла Хәмзә бине Мөхәммәд бине Хәсән бине Җиһан Мөхәммәд әл-Казани, әл-Бирәзәви.** Үз илендә укып гыйлем алганнан соң Бохарага һәм Кабулга сәфәр кылган. Кабулда мелла Фәезхан хәзрәтләренә әңгәмәдәш булган. Бохарада бер мәртәбә өч ел, икенче мәртәбә җиде ел яшәгән. Кабул галимнәреннән математика укып, хисап гыйлеменә бик оста булганлыктан, «мелла Хәмзә мөнәҗҗим»[6] дип танылган була. Имамлык һәм мөдәррислек белән эше булмады. Сату эше белән Бохарага кат-кат барган. «Бохарадан мелла Исхак бине Сәгыйд һәм мелла Байморад бине Мөхәррәм кебек тугыз мелланы бу мәмләкәткә алып кайттым»,— дип сөйли торган булган...

Бохарада вакытта әмир Хәйдәр бине Мәгъсүм белән якынлашып, аның мәҗлесләренә кергәнлеге билгеле. Мөндеш авылы имамы — мелла Мостай хаҗи белән араларында дуслыклары көчле була. Математика белән шөгыльләнгәндә энесе мелла Фәйзулла бине Мөхәммәдкол бине Мәмтай бине Тутик шәкерде булган. Бирәзә авылында 1242 (1826) елда вафат булган... (231—232 бб.).

**Мелла Шәмсетдин бине Габдеррәшид әл-Кышкарый.** Тумышы белән Кышкар авылыннан бер ятим бала була. Алагур төбәгендә башлык һәм аксакал булып торучы Ташкичү кешесе Баязид бине Ибраһим бине Әбәк бине Туйхуҗа күп маллы бай бер кеше үзенең баласы булмаганлыктан, бу Шәмсетдинне уллыкка алып тәрбияләгән һәм аны укытып камиллеккә иреш-

---

[6] Мөнәҗҗим — астроном, йолдызлар турындагы фәнне белүче.

торган. Ахырда Бохарага җибәреп белем алдырып кайтарып, Ташкичүдә имам, хатыйб һәм мөдәррис итеп билгеләүгә ирешкән.

Әлеге Баязид бай мелла Шәмсетдин өчен бик киң һәм биек итеп ике кара-каршы бинадан торган зур мәдрәсә салдырган. Мәдрәсәнең уртасында ике тарафка чыга торган бик зиннәтле ике ишеге булган. Мәдрәсәнең түбәсе бик биек итеп эшләнгән, яхшы такта белән ябылган, чормага менә торган баскычларының да яхшы ишекләре булган һәм бикләнә торган тәрәзәләре дә бик зур һәм күп итеп эшләнгән булган. Мәдрәсәнең ишек алды бик киң, ихатасы һәм башка ярдәмче биналары зур байларның йортлары кебек төзелгән, ә капкалары исә бинасы кебек үк бик матур итеп ясалган. Гомумән, бу мәмләкәтебездә моңа кадәр мондаен төзек мәдрәсә күрелмәгән. Мәдрәсәнең эче хөҗрәләргә бүленмеш була. Мелла Шәмсетдин күп шәкерт җыйнап бик зур дан, шөһрәт белән дәрес әйтә һәм соңыннан ул хаҗ кылу теләге белән сәфәр чыгып китә һәм Мисырда чорының мәшһүр кешесе Ибраһим пашага якынлаша, аңа әңгәмәдәш була һәм шундагы университетка фарсы теле укытучысы итеп раслана. Әмма хаҗ кылу теләге тормышка ашмый кала. Ул 1248 (1831) елда Мисырда вафат була. Гали исемле бер углы һәм Ташкичүдә ике кызы кала. Гаять шук, гүзәл холыклы, хуш табигатьле, шул ук вакыт кулына төшкән малны бик җиңел туздыручы кеше була. Бохарада булганда иптәше мелла Хәсән бине Хал әл-Бохариның илле алтынын «бурычка» дип алып, бирмичә киткән булган. Ә әлеге мелла Хәсән «Кяфер Шәмсетдин илле алтынымны урлады»,— дип, гомер буена моннан зарланып йөргән... (129—130 бб.)

**Мелла Фәйзулла бине Мортаза бине Мөхәммәдкол бине Мемтай бине Туйтик әл-Казани әл-Мөндеши.** Галим һәм зур укымышлы булуы өстенә математика һәм астрономия фәненә дә оста иде. Буяучылык һөнәре белән шөгыльләнә, төрле әстырлаб[1] шарлар ясый, бакыр һәм җиздән ясалган төрле буяулар белән гамәл кыла, календарьлар төзи, кояш һәм ай тотылу һәм айның тууы турында хәбәр бирә. Шуңа күрә бу зат «Йолдызчы Фәйзулла мелла»,— дип танылган иде. Хәзерге көндә ул ясаган бер шар һәм бер әстырлаб бездә дә бар. Кайбер календарьлары да басылып таралган. Ул ясаган сәгатьне дә үз күзебез белән күрдек. Мостай хаҗи, Сәйфулла казый, Сәгыйд, Вәлид меллалар моңа бертуган иделәр. Ахыр гомерендә чукрак булып, бик мәшәкать белән генә, бик аз гына ишетә иде.

Математиканы мелла Хәмзә бине Мөхәммәд әл-Бирәзәвидән укыды. Мелла Гатаулла бине Мөхәммәд әл-Курсави аның шәкерде иде. Җитмеш яшьтә чакта 1267 (1850) елда Арча юлындагы Мөндеш карьясендә вафат булды. Углы мелла Гобәйдулла исемле зат Олы Кавалның кече ягында имамдыр... (258—259 бб.)

**Мелла Һибәтулла бине Сәедбаттал әл-Болгари әл-Каргалый Әбү Әхмәд.** Каргалы имамнары җөмләсеннән. Имам, хатыйб һәм мөдәррис, туры сүзле, изге күңелле, укымышлы кеше булып, «Һибәтулла ишан Каргалый» дип йөртәләр иде. «Мәҗмәгыйлләтаиф» һәм «Әдәб» исемле, вәгазь һәм нәсыйхәтне эченә алган, яхшы мәгънәле, дөрес эчтәлекле төрки телендә язылган шигъри әсәрләре бар. Курса һәм Кышкар имамнарыннан — югарыда телгә алынган Дәүләтшаһ ишан мөриде. 1282 (1867) елда Каргалыда вафат булды... (272 б.)

---

[1] Әстырлаб — астролябия — җир үлчи, план төшерә торган корал. XVIII гасырда күк һәм йолдызларны өйрәнү өчен дә файдаланылган.

## Мәрҗанинең шуклыгы

Халыкта баланың азрак шаян һәм шук булуын мактап: «Балаң булса, шук булсын, шук булмаса, юк булсын» дигән атаклы мәкаль бар. Сәламәт табигатьле Мәрҗани дә бала чагында шаяруны, уйнауны, шук уеннарны башлап йөрүне яраткан. Мәрҗанинең шуклыкларыннан түбәндәге вакыйга теркәлеп калган. Ул кәгазьдән битлек ясап карчыкларны куркытып йөри икән. Шулай бервакыт Мәрҗани битенә битлек куеп берәүнең капкасы яныннан үтеп барганда, бер карчык бәләк тотып, киндер чайкау өчен су буена төшәргә дип капкадан чыгып килә икән. Карчык битлек кигән Мәрҗанине җен дип уйлап, куркуыннан кулындагы бәләге белән аның башына кундырган. Мәрҗани бу вакыйганы исенә төшереп: «Күземә утлар күренде. Башым ярылды дип уйладым. Әле дә ярылмаган икән»,— дип көлеп сөйли торган булган. Ләкин авылда чакта башына бәләк төшерткән бу шаяруны Мәрҗани Бохарада укыганда тагын бер тапкыр кабатлый. Әш болай була. Төнлә белән битенә битлек куеп, ул бер шәкертнең хөҗрә (бүлмә) ишеген кага. Шәкерт ишек ачып битлекле Мәрҗанине күргә «Аһ» дип кычкырып ава. Мәрҗани тиз генә үз бүлмәсенә кереп кача. Шуннан соң бу шәкерт, җен күрдем дип, берничә атна авырып ята. Шушы вакыйгадан соң Мәрҗани дә бу шаяртуын ташлаган.

## Мәрҗани һәм... ак тавык

Мәрҗани бала чагында әтәч, каз, күркә, эт, мәче кебек йорт кошлары, хайваннар белән уйнарга, аларны бер-берсе белән сугыштыруны яраткан. Шулай бервакыт аңа йорттагы тавыкларның төрле төстә булуы ошамый башлый. Үзе ак төсне яратканлыктан, тавыкларның да ак булуын тели. Хәтта ул бу теләген тормышка да ашыра башлый: ак төстә булмаган тавыкларның һәм чебешләрнең кайберләренә әтәч койрыклары тагып, йорттагыларга аларны әтәч итеп таныта башлый, ак булмаган тавык-чебешнең күбесен суйдыртып та бетерә. Соңыннан Мәрҗани бу фикеренең хата икәнлеген таный һәм: «Безнең тавыкларны акка алыштыруыбыз җүләрлек булган икән. Төрле төс үзе бер матурлык»,— дип сөйләгән. Мәрҗанинең биографлары бу вакыйганы, аның кечкенәдән үк мөстәкыйль фикер йөртергә яратуына, һәрвакыт башкаларны үз артыннан ияртергә тырышуына мисал итеп китергәннәр.

## Көрәшче Шиһап

Яшь чагында бик таза егет булган Шиһабетдин Мәрҗани тирә-юньдәге авыл сабантуйларында көрәшеп үзен «Көрәшче Шиһап» дип таныта. Авылдашлары — ташкичүлеләр — аның белән бик горурланганнар, күрше авылларда сабан туйлары, җыеннар булганда Баһаветдин хәзрәттән үзләре белән Мәрҗанине дә җибәрүне үтенгәннәр. Бары тик авылның диндар картлары гына «Мужиклар белән көрәшеп, имгәнеп бетә» дип борчылганнар. Әмма Мәрҗани аларны тыңламый, сабантуйларда көрәшүен дәвам итә. Бервакыт ул 19 яшьлек чагында тирә-якта «Ибрай батыр» дип даны таралган мәшһүр көрәшче белән бил алышып, Ибрай батырны җиңүгә ирешә.

Көрәш мәсьәләсендә Мәрҗани үз кагыйдәләрен булдыра. Әйтик, ул егылганнар белән түгел, егучы баһадирлар белән көрәшүне яраткан. Үзеннән бер мәртәбә егылган кеше белән көрәшмәгән. Һәм ул кеше еккан кеше белән дә көрәшмәгән. Һәркемнән өстен, һәр җәһәттән беренче булырга яраткан Мәрҗани батыр кала алмаган сабан туйларында начар кәеф белән йөргән.

# Итагатьле хатын

Бервакыт авыл егетләреннән берәү кияү булып кыз янына барасын уйлап барганда Мәрҗанине очрата һәм: «Хатыным итагатьле булса ярар иде. Шуны ничек белергә кирәк»,— дип сорау бирә. Мәрҗани: «Бу эш бик җиңел. Моны беренче баруда сынап була. Кыз янына баргач, аңа мәшрикъка (көнчыгышка) таба карап намаз укырга боер. Үзең мәгърипкә (көнбатышка) карап намаз укы. Әгәр дә син боерганга итагать итеп, үзе мәшрикъка (көнчыгышка) карап намаз укыса, синең мәгърипкә (көнбатышка) карап намаз укуыңа бәхәс кылмаса, шул хатын итагатьле булыр»,— дип җавап биргән.

# Мәрҗани һәм губернатор

Бервакыт Мәрҗани, ниндидер эше төшеп, губернатор янына барган. Губернатор аның белән бик төчеләнеп, бик зур ихтирам күрсәтеп сөйләшкән. Шуннан кайткач Мәрҗани: «Төче телле түрәдән саклан, дигәннәр. Моннан да сакланырга кирәк»,— дип сөйләгән. Губернатор үзе дә бер мәртәбә Мәрҗанигә бара, ләкин аның йоклаган чагына туры килә. Йорттагы асраулар: «Хәзрәт йоклый»,— дип губернаторны кайтарып җибәрәләр. Йокыдан торгач Мәрҗанигә: «Бер бай урыс килгән иде, кайтарып җибәрдек»,— дип хәбәр иткәннәр. Соңыннан Мәрҗани гафу үтенү йөзеннән губернаторны махсус рәвештә кунакка чакырырга мәҗбүр була.

# Кайчан тәүбә итәргә?

Мәрҗанинең тирән фикерле философ, кырыс, житди тарихчы, ачы һәм үткен тәнкыйтьче булганлыгы киң мәгълүм. Шуңа да карамастан, ул үзенең әсәрләрен кызыклы, укырга күңелле итәр өчен кайбер шәхесләрнең мәзәк яки сәер гадәтләрен дә теркәп калдырган. Мәсәлән, XIX йөз башларында Җәгъфәр исемле бер ишан җәй житкәч, мөритләрен ияртеп, төрле уен коралларын алып чыгып китә, төрле шәһәр-авылларга барып мөритләрен биетеп, музыка уйнап йөри торган булган. Бервакыт ишан үзенең мөритләре белән хаҗга барырга юлга чыга. Диңгездә барганда, давыл куба. Юлчыларның коты очып, тәүбә итәргә тотыналар. Ә Җәгъфәр ишан мөритләрен җыя да музыка уйнатып, җырлатырга, биетергә керешә. Юлчылар аптырап калалар:

— Син кем соң?.. Мөселманмы, әллә кяфер, динсезме? Мондый чакта җырлап, биеп түгел, тәүбә итеп, гыйбадәт кылып үткәрергә кирәк, диләр.

Җәгъфәр ишан аларга каршы:

— Тәүбәне аны артыңа су кергәч итмиләр. Тыныч чакта итәләр, ә хәзер җырлап, биеп күңел ачарга кирәк,— дип җавап бирә.

*«Кызыклы хәлләр»не журнал өчен Ж. Миңнуллин әзерләде.*

*Фәтхи Бурнашның тууына 90 ел*

# КЫЗЫЛ ЧӘЧӘКЛӘР АҢА

Фәтхи Бурнаш! Бу исемне әйтү белән үлемсез гашыйклар Таһир һәм Зөһрә («Таһир-Зөһрә» трагедиясе), яшьлек дәрте бөркеп торган Сәйфулла һәм Хәйретдин («Яшь йөрәкләр» пьесасы), искелекне калкан итәргә тырышып, хурлыкка калган Камали («Камали карт» комедиясе), социалистик күмәк хезмәтнең өстенлекләрен танырга мәҗбүр булган Ярулла («Ялгыз Ярулла» пьесасы), сыйнфый азатлык өчен туган илләреннән һәм сөйгән ярларыннан аерылып чыгып китәргә рухи көч тапкан кызыл сугышчылар («Ак каен», «Әҗәл» поэмалары) искә төшә. Иҗатта өлгерлеге, авылда һәм шәһәрдә кайнаган яңа тормышны тизлек белән сәхнәгә сәнгатьчә күчерүдә осталыгы белән каләмдәшләрен таңга калдырган драматург, Гражданнар сугышы барган авыр һәм киеренке вакытта да 2-3 көн саен бер поэма язып бастырган шагыйрь, кирәк булганда газетаның һәр санында берничәшәр һәм төрле характердагы мәкаләләр белән чыгучы ялкынлы журналист, принципиаль тәнкыйтьче, оста тәрҗемәче һәм, ниһаять, күренекле җәмәгать эшлеклесе — бу исем менә нинди якларны һәм төшенчәләрне берләштерә.

«Ф. Бурнаш дигән әдәби күренешнең иң характерлы яклары нидән гыйбарәт?» дигән сорау куелса, зур табигый талант, хезмәт ияләре белән ныклы һәм даими элемтәдә тору, гаҗәеп актив эшчәнлек, дип җавап бирергә мөмкин. Бөек Октябрь дәверендә мәйданга чыгып, яңа җәмгыять шартларында чын мәгънәсендә чәчәк ата алган бу иҗат — революция тудырган һәр күренеш кебек, әһәмиятле дә, кызыклы һәм катлаулы да... Яңа татар әдәбиятының башында торган Г. Ибраһимов әле 1920 елда ук, әдәбият мәйданына чыккан «яңа исемнәрнең иң көчлесе, шөбһәсез, Фәтхи Бурнаш иде»,— дип язды.

Әдәби шөһрәт аңа чагыштырмача тиз килә. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсеннән киткәннән соң, үзлегеннән хәзерләнеп, «Учительская семинария»дә имтихан тоткан, аттестат алган егет инде 20 яшен дистәләрчә романтик поэмалары, берничә пьесасы, бигрәк тә 1917 елда язган «Таһир-Зөһрә» һәм «Яшь йөрәкләр» белән татар укучысы һәм тамашачысына киң танылган автор, көчле журналист буларак каршылый. Себердә чыга торган большевистик «Көн» («Таң») газетасының редакторы Ф. Бурнаш үзенең агитацион шигырьләре, хикәя-фельетоннары, публицистик мәкаләләре белән, оештыру эшчәнлеге, төрле җыелышларда һәм әдәби кичәләрдә революция дошманнарын фаш иткән ялкынлы чыгышлары белән хезмәт иясенең хөрмәтен казана, дошманнарның нәфрәтенә дучар була. Озакламый контрреволюцион көчләргә моның үчен кайтарырга җай табыла: шәһәрне ак чехлар алгач, яшь редакторны Уфа төрмәсенә ябалар, 3 ай ялгыз камерада тотканнан соң, Себергә озаталар. Тормыш юлын һәм иҗатын сыйнфый азатлык көрәше белән бәйләгән егет өчен әлеге вакыйгалар политик чыныгу һәм җитлегү мәктәбенә әйләнә. Ф. Бурнаш бу чордагы уй-кичерешләрен соңрак «Кан шәүләләре» исемле язмасында тулы яктырта. Себер юлында үлем эшелоныннан качу, фронт сызыгын яшерен үтеп чыгу, газетаны яңадан аякка бастыру, партиягә керү, ул чордагы үзәк газета — «Кызыл Армия»дә редакторлык итү, Үзәк Мөселман Хәрби коллегиясендә матбугат бүлеге җитәкчесе булып эшләү һ. б.— утлы-давыллы елларда Бурнаш узган революцион юлның аерым маяклары шулар.

Язучы гомере буе үз халкына, аның идеалын якынайту эшенә җаны-тәне белән бирелгән иде. Шуңа күрә аның язганнары — пьеса булса — һәр репликасы, шигырь булса — һәр юлы, мәкалә булса — һәр бите хезмәт иясе шатлык-кайгысы белән сугарылган. Бу хис Ф. Бурнаш иҗатының халыкчан рухын билгели. Беренче әсәрләреннән булган «Яшь йөрәкләр»дә үк шул рух ташып тора, шул рух әсәрне тиз арада киң таныта, әле хәзер дә театрлар репертуарларында саклап бара. М. Фәйзинең «Галиябану»ыннан соң, ул сәхнәгә гади крестьяннарны, аларның да инде революционлаша барганнарын алып чыккан, аларны романтик күтәренкелек белән, матурлык рухы белән сугарган икенче пьеса булды; шушы ике әсәр татар драматургиясен халыкның хезмәт иясе катламына йөз белән борды.

Әдәбиятка шундый — халык сукмагыннан атлап килеп кергән Ф. Бурнаш беркайчан да аннан читкә тайпылмады. Аның әсәрләрендә изүчеләргә каршы канлы көрәшкә күтәрелгән, хезмәт ияләре мәнфәгатьләре өчен кулына корал алган каһарман өстенлек итә. Ул каһарманның тоткан юлы туры, аның идеаллары якты. Аның гамәлләренең нигезен иҗтимагый тигезлек максаты нурландыра! Ул бу максатка ирешүдә күп корбаннар биреләсен дә белә. Шуңа да карамастан, барысына да әзер хәлдә, миндидер бер рәхәтлек кичереп, романтик күтәренкелек белән изге көрәшкә ташлана, үзе артыннан башкаларны да ияртә. 1919—21 еллардагы поэмаларындагы һәм шигырьләрендәге «Егет», «Адашкан кыз» драмасында (1920—26) Латиф, «Хөсәен мирза» романтик драмасында (1918—20) Муса, «Лачыннар»да (1932) Сафаров, «Таң» героик драмасында (1936) Таймасов — шундыйлар. Бу әсәрләрендә автор мөһим гомумиләштерүләр, игътибарга лаек сәнгатьчә ачышлар ясый. Мәсәлән, Гражданнар сугышы елларында Урта Азиядә басмачыларга каршы көрәшне тасвирлаган «Лачыннар» исемле романтик драмасы русчага тәрҗемә ителә һәм Мәскәүдә М. Горький инициативасы белән басыла башлаган «Театр народов СССР» альманахының иң 1 нче санында (1934), милли драматургларның иң яхшы әсәрләре рәтеннән дөнья күрә.

Шул ук вакытта драматург тормышта торган саен арта барган яңалыкларга да иҗатында урынны күбрәк бирә. Аның әсәрләре нигезенә яңа конфликтлар, яңа төстәге каршылыклар ята. Социалистик чынбарлыктагы үзгәрешләрне, аерым алганда, гаиләдәге мөнәсәбәтләр үзгәрүен җентекләп өйрәнү нәтиҗәсендә иҗат ителгән 20 нче еллар драматургиясенең күренекле әсәрләреннән берсе дип танылган «Камали карт» комедиясе әнә шундыйлардан.

Совет шартларында яңа кеше туу проблемасына да Ф. Бурнаш беренчеләрдән булып мөрәҗәгать итә. «Мин калдырдым пар казанын» дип аталган, бик тә үзенчәлекле язылган поэмасы (1930 ел), «Хәдичә апа», «Урам кызы (Авыл яшьләре)» (1929), «Тукучы Әсма» (1931) драмалары һәм бигрәк тә «Ялгыз Ярулла» (1939) комедиясе — идея-политик яктан да, сәнгатьчәлек ноктасыннан да әһәмиятле әсәрләр.

Ф. Бурнаш — сәхнә кануннарын яхшы үзләштергән, иҗат практикасында аларны белеп файдаланган драматург. Аның пьесалары фикер куелыгы, динамикалы, кызыклы сюжет, оста индивидуальләштерелгән образлар белән характерлана. Халыкчан, җанлы тел үрнәкләрен бирү ягыннан аның әсәрләре бүгенге яшь язучылар өчен дә өйрәнү мәктәбе булып тора.

Бурнашның иҗаты бик тә иртә, 1939 елда өзелде. Бу вакытта аңар нибары 40 яшь иде. Шәхес культы давылларының кара канаты бу якты иҗатны озак елларга каплапяшереп торды, язучының үзен һәлак итте...

Ләкин гомеренең һәр сәгате көрәш рухы белән сугарылган язучының 20 ел эчендә тудырган мирасы үзенең байлыгы һәм төрлелеге белән гаҗәпләндерә. 22 сәхнә әсәре, 30 дан артык поэма, 200 ләп шигырь, 5 опера либреттосы, 500 ләп публицистик һәм тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләр, хикәя һәм фельетоннар, «Хаҗи Морат», «Аталар һәм балалар», «Икмәк», «Ана», «Корыч ничек чыныкты» исемле романнар һәм повестьларның, күпләгән шигырьләр, бигрәк тә «Евгений Онегин» шигъри романының оста тәрҗемәләре... XX съезд карарлары бу талантның әсәрләрен кабаттан укучыларга кайтарганнан соң, без әлеге мирасның бер өлеше белән таныштык инде: Ф. Бурнашның 2 томлыгы, пьесалар һәм поэзия, әдәбият-сәнгать турында мәкаләләр җыентыклары дөнья күрде, «Казан утлары» битләрендә опера либреттоларының үрнәкләре басылды. Шулай да әле без, әсәрләрен бүгенге укучыга җиткерү җәһәтеннән, язучының якты истәлеге алдында бурычлыбыз. Әгәр дә бу иҗатны тулы белик дисәк, хәзердән үк Ф. Бурнашның 5 томлыгын бастырып чыгару хастәрен күрә башларга тиешбез. Аның бөтенләй дә дөнья күрмәгән, яисә гарәп хәрефләре белән генә басылганга бүгенге киң катлау укучыга килеп җитмәгән, яки үз чорында бик аз вакыт сәхнәдә уйналган әсәрләре шактый. Пьесалар арасында гына да андый әсәрләрнең саны 8 гә җитә («Олы юл белән», «Илһам», «Шатлык», «Хат», «Кызыл чәчәк» һ. б.). Соңгы, үкенечле кеннәрендә дә ул иҗат итмичә түзә алмагандыр. Аларны эзлисе һәм табасы бар.

Журналның бу санында Ф. Бурнашның «Илһам» исемле сатирик комедиясеннән өзекләр укучыларга тәкъдим ителә. Комедия 1929 елда Мәскәү һәм Әстерхан татар театрларында сәхнәгә куелган, Татар дәүләт академия театрының 1930—31 елгы репертуарына кертелгән булган.

**Азат ӘХМӘДУЛЛИН.**

**Фәтхи Бурнаш**

# ИЛҺАМ

ДҮРТ ПӘРДӘЛЕ САТИРИК ПЬЕСАДАН ӨЗЕКЛӘР

ӨЗЕКЛӘРДӘ КАТНАШУЧЫ ПЕРСОНАЖЛАР:

Шәриф Сәгыйди
Гариф Кәрими
Күчәр Тракторов

## Беренче пәрдә

**Уртача җыештырылган зур зал. Каршыда киң пыяла ишек, ишекнең ике ягында да киң тәрәзәләр. Ишеккә дә, тәрәзәләргә дә шторлар корылган. Тәрәзә аша бакча һәм кар өемнәре күренә. Кояш яктырып чыккан. Уң кулда бер ишек, сул кулда ике ишек: берсе, алдагысы, бүлмәгә керә торган, ә арттагысы тышка чыга торган. Уртада зур гына өстәл, урындыклар; сәгать, буфет, диварда рәсемнәр.**

**Пәрдә күтәрелгәндә, Шәриф диванда сузылып ята. Шәриф ялгыз.**

Шәриф *(киерелеп)*. Әх, нинди матур! *(Шторны җыеп куя.)* Яз хәбәрләре дә килә башлады. *(Тора)*. Әх, яратам соң мин язны! *(Карый.)* Әйтерсең лә кояшның сихерле нурлары мине генә иркәләргә телиләр! *(Көйли.)* Язлар да гынай үтәр...

Гариф *(тышта)*. Көзләр җитәр. *(Гариф башлагач, Шәриф тыктый.)*

Шәриф. Тфү! Кайдан искә килеп төште шуның шыңшый торган көе!

Гариф *(тышта)*.

Асыл кошлар китәр борылып,
Газиз гомеркәйләр үтәр, китәр,
Яшь йөрәккәй калыр боегып.

Шәриф *(җыр арасында)*. Тфү! Гариф! Гариф! Кычкырмачы болай койрыгы кысылган кәҗә шикелле! Гариф!

**Гариф сулдан, икенче ишектән гитара күтәреп чыга.**

Гариф *(кереп)*. Нәрсә бар?

Шәриф. Син нәрсә әйләнәсең дә шушы җеназа азаныңны шыңшый башлыйсың әле?

Гариф. Син бит үзең башладың...

Шәриф. Мин болай гына.

Гариф. Мин дә болай гына... Югыйсә, әллә ник эч поша... ямансу.

Шәриф. Кайгырма, Гариф! Әйтәм бит — бер көн килер, мин бөтен татар шигъриятенең йолдызы булырмын. Бөтен татар телендә Шәриф Сәгыйди генә булыр. Шәриф Сәгыйди ул вакыт мисалларда гына йөрер... Шәриф Сәгыйди ул вакыт газет, журнал саен хәер эстәгән төсле 50 тиен, 1 тәңкә гонорар сорап йөрмәс — редакцияләр үзләре 100 әр сумлап гонорарны пакетка салып аның особнягына китереп бирерләр.

Гариф. Синең шулай. Ә минем...

Шәриф. Җүләр! Менә мин генә күтәрелим, аннан соң синең эшең бөтенләй җиңел булачак. Ул вакыт Гариф Кәриминең рәсеме югарыданрак урын алачак... Ә алар әле безгә юл бирмиләр. Бездән көнләшәләр. Бездән куркалар.

Гариф. Синнән куркысыннар да... көнләшсеннәр дә. Ә минем соң нәрсәмнән көнләшергә? Кичә мин идарәгә үземнең «Ялан мәхәббәте» дигән шигыремне илткән идем.

Шәриф. Җә?

Гариф. Әхмәтвәли Кишәли әфәнде карап чыкты да... борынын тартты.

Шәриф. Соң?

Гариф. Шул... ярамый, ди...

Шәриф. Ярамый, ди?

Гариф. Әйе... бу шигырегездән парной сөт исе килә, ди.

Шәриф. Син кайгырма, Гариф! Менә мин күтәрелим дә берәр журналның мөхәррире генә булып алыйм. Синең шигырьләреңне парной сөт түгел, черегән кәбестә исе килсә дә, беренче нәүбәттә җибәрермен.

Гариф *(уйлап)*. Кайчан булыр бит әле ул...

Шәриф. Тизме? Озакмы? Ләкин ул булыр! Мин милләтнең чәчәге булырмын...

Гариф. Син булырсың. Ә мин яфрагы да була алмам.

Шәриф. Ярый, кайгырма! Бар, самавырны керт әле!

Гариф. Хәҗәйкә самавыр бирмәде.

Шәриф. Нигә?

Гариф. Иске самавырымны да эреттең, яңасын бирә алмыйм, ди.

Шәриф *(ачуланып)*. Ә син авызыңны ачып йөрисең!

Гариф. Мин «Ялан мәхәббәте» дигән шигырь турында уйлап су салмый куйганмын да, ул кызган да... ниткән...

Шәриф. Җебегән!

Гариф. Җебемәгән шул — эрегән!

Шәриф. Син үзең эрегән *(ачуланып әйләнеп китә.)*

Гариф *(төшенеп)*. Ә... Шуңар күрә мин чәйнек белән куйган идем дә... чәйнек эремәс тә...

Шәриф. Син дә җебемәссең. Бар, китер! *(Гариф чыга, Шәриф ялгыз кала. Йөренә.)* Тиздән яз килеп җитәр. Җәй булыр. Бакчалар гөлләр белән, күңелләр илһам белән тулар. *(Уйлана.)*

Каршыларга иң садә чак,
Иң матур чак җәйге таң.
Шул вакытта уйла, шагыйрь,
Килде илһам уйласаң. *(Пауза.)*

Нинди матур шигырь... Минем өчен бигрәк тә *(Уйлана.)* Язгы таңның ак нурына бөркәнеп *(блокнот ала, яза)*.

Уйлансам, алга төрле уй килә *(уйлана, эзләнә)*.
Уй килә... туй килә... куй килә...

Җырлый башлыйм җырларымны дәртләнеп,
Тибрәтеп дәрт кылларын зар, моң килә;
Мин көтәм шунда йөрәктән ашкынып...
Кайда дим, бәгърем, бу илһамым килә...

. . . . . . . . . . . . . . . . . .

**Күчәр йөгереп керә.**

Күчәр. Браво, браво! Бик матур җырлыйсыз икән. Мең тәңкәлек!

Гариф *(туктый, гаҗәпләнеп тора)*. Ә?

Күчәр. Исәнмесез? Без таныш түгел бугай. Күчәр Тракторов.

Гариф *(гаҗәпләнә)*. Ә?

Күчәр. Нигә гаҗәпләндегез? Мин шагыйрь Күчәр Тракторов. Имажинист.

Гариф *(гаҗәпләнә)*. Ә? *(Утыра.)*

Күчәр. Мин башта футурист идем. Аннан имажинистлыкка күчтем. Хәер, анысы неважно! Сез аңа гаҗәпләнмәгез!

Гариф. Әйе, гаҗәп түгел... Күчәр... трактор...

Күчәр. Браво, браво! Сез поэзияне аңлыйсыз булырга кирәк. Күчәр Тракторов. Шәп бит?!

Гариф. Әйе, шәп...

Күчәр. Мин аны табар өчен бик күп көч куйдым. Әтиләр миңа Кәүсәр кушканнар. Ә фамилиям Таһиров. Чынлап та, хәзерге көн белән Кәүсәр, Таһирларның нинди мөнәсәбәтләре булырга мөмкин? Мин тормышны яңадан башладым. Исемемне Күчәргә, фамилиямне Тракторовка алмаштырдым, шәп бит?..

Гариф *(аптырап)*. Әйе... билгеле...

Күчәр. Күчәр бөтен нәрсәне әйләндерә, ә трактор бөтен нәрсәне актара... *(Кулларын бутап.)* Трам! Бам! Ш-ш! Пюф! Зрыйй-й!.. Карагыз әле, сез минем шигырьләрне укыйсызмы?

Гариф *(куркып)*. Әйе... мин шигырьләр укыйм.

Күчәр. Юк, минем шигырьләрне, дим.

Гариф. Сез... шигырь дә язасызмы?

Күчәр. Менә кирәк булса! Күчәр Тракторовның шагыйрьлеген белмәгән, аның шигырьләрен хәрефенә кадәр ятламаган кеше кешемени хәзер?!

Гариф. Әлбәттә... мин үзем дә элек заман...

Күчәр *(исе китеп)*. Әллә сез дә шигырь яза идегезме?

Гариф *(аптырап, кулларын кире салып)*. Ә, юк, алла сакласын! Элек укыйдыр идем димәкче идем.

Күчәр. Ә хәзер?

Гариф. Хәзер юк. Вакыт юк. Акча юк.

Күчәр. Җүләр! Әүвәлге шигырь шигырьмени ул? Анда Тукай, Дәрдмәнд, Рәмиевләрнең кафиялəп, иҗекләп, бармак санап, тирләп-пешеп язган гыйшык, мәхәббәт, табигать, хәсрәт сафсаталарыннан башка бернәрсә дә юк анда... Сез Шәриф Сәгыйдине беләсезме? Ул шушы йортта тора бугай...

Гариф *(куркып)*. Әйе...

Күчәр. Элек журналларда еш кына шуның шигырьләре басыла торган иде. Анда бәдәвам, тәкый гаҗәп такмакларыннан башка бер мәгънә юк... Шулай бит?

Гариф *(куркып)*. Ә?

Күчәр. Анысы ярый әле. Аның белән бер вакытларны тагын бер Гариф Кәрими дигәне...

Гариф *(гаять каушап)*. Ә? *(Утыра.)*

Күчәр. Гариф Кәрими дигән бер диванасының шигырьләре басыла торган иде. Сез аны беләсезме?

Гариф. Әйе, ишеткәнем бар. Зинһар сөйләгез, сөйләгез!

Күчәр. Анысының шигырьләре тагын сплошной хандра. Әйтерсең лә ул гомерендә җыламыйча ипи ашый алмаган да, әйтерсең лә әнисе аны карынынннан ук гробка салып, тактасын да үзе үк кадаклап куйган. Сез аның шигырьләрен укыганыгыз бармы?

Гариф *(куркып)*. Әй, юк. Алла сакласын!

Күчәр. Мәсәлән, аның Октябрь алдыннан гына басылган «Ялан мәхәббәте» дигән шигыре...

Гариф *(гаять куркып)*. Ялан мәхәббәте? Я, я. Зинһар өчен!..

Күчәр. Ул шигырь түгел — слякоть, ландрин, тиряк, мәтрүшкә, карабодай өйрәсе!

Гариф *(эчен тотып, кычкырып)*. Ай!

Күчәр. Сезгә нәрсә булды?

Г а р и ф. Юк, болай гына. Өйрә дигәч, эчем авыртып китте.

К ү ч ә р. Ә минем шигырьләрем бөтенләй башка, анда тормыш, анда ритм, анда лавалар, анда — везувийлар!

Г а р и ф. Ә?

К ү ч ә р. Янар тау анда!

Г а р и ф *(куркып)*. У-у-у!

К ү ч ә р. Менә, мәсәлән. *(Укый.)* «Әй, син, җәйге кояшның яшел кикриге! Корчаңгы болытларның ямаулы имчәге. Даешь! Автобусның зодмани тәгәрмәчләренә борыныңны тыгып, аяк бармакларыңны юарсың. Вж-ж-ж-рас! Гөбер-р-р-р! Трах! Ши-и-и, пах!.. Чырый-и-и! Кикрику! Таңның аксак тәкәсе, кычкырма, шиблитымның колак тәлинкәсен яңгыратып. Трах, бер атып, бах, кыйратып, паш! Пропеллер, рас! Бас! Җи-и-ки-җил, трах!» Шәп бит! Мин аны сөйгәнемнең туган көненә багышлап язган идем. Шәпме?

Г а р и ф. У-у! Гаҗәп!

К ү ч ә р. Ләкин без имажинистларны аңламыйлар бу большевиклар... Сез массаны белмисез, масса сезне укымый, диләр... Аларның иреннәреннән һаман әле шул Пушкин, Лермонтов, Тукай, Мәҗитләрнең сөте китмәгән... Әнә син Сәрдәровны кара... Мәшһүр — революционный шагыйрь, имеш! Аны мактыйлар, күтәрәләр. Ә ул нәрсә бирде? Һаман да әлеге символизм исереклеге... Ә Исмәгыйлеве кем? Бөек реалист мөхәррир, имеш! Ә ул бит бүгенге көннең исләнгән действительностеннән узганы юк. Ә безгә бүген — чүп! Без киләчәк шагыйре. Без һәркөнне бер гасыр яшибез. Шулай бит?

Г а р и ф. Әйе... дөрес... бик дөрес...

К ү ч ә р. Алар поэзияне аңламыйлар. Аларга нәсихәт, политграмота, хәлфәлек кирәк... Ярый, аңламасалар аңламасыннар... Мин шәһәрләреннән китәрмен... мин үземнең массамны табармын, шулай бит.

Г а р и ф. Әлбәттә.

К ү ч ә р. Ярый, озак сөйләшеп киткәнбез. Миңа Гакил кирәк иде. Ул шунда тора бит?

Г а р и ф. Әйе, шунда. Ләкин ул әле өйдә юк.

К ү ч ә р. Аһ, жаль! Алайса, менә нәрсә, иптәш! Сез аңа кайткач әйтегез әле. Мин шул арада авылга китәм. Ул миңа керен чыксын әле.

Г а р и ф. Ярый, әйтермен!

## Дүртенче пәрдә, икенче күренештән өзек

**Вакыйга авылда бара.**

К ү ч ә р. Җәмәгать, миннән сезгә сәлам!

Х а л ы к *(тына)*. Бу кем тагын?

К ү ч ә р. Әй, Гакил, Шәһид, сез дә монда, ах, нинди шәп!

И д р и с. Туктагыз әле, сезгә нәрсә кирәк...

К ү ч ә р *(югары мена)*. Җәмәгать, хәзер туктап тора торган заман түгел. Минем килүем каладан. Мин — шагыйрь, футурист идем, хәзер имажинист.

Х а л ы к. Кем, ди?

I к р е с т ь я н. Кукуруз диме, шайтан белсен.

К ү ч ә р. Мин имажинист Күчәр Тракторов булам.

Х а л ы к. Ә...

К ү ч ә р. Мин шундый массага очравыма бик шат. Сәнгать — массага, масса — сәнгатькә. Безне ләкин калада аңламыйлар. Шуңа күрә мин массага килдем, мин имтихан тотарга килдем.

И д р и с. Рәтләп сөйләгез әле сез...

К ү ч ә р. Минем шигырьләрем эчендә массаның йөрәге, аның артерияләры. Шуңа күрә миңа аларның бәя куюлары, аларның сынаулары кирәк. Мин башладым.

Х а л ы к. Бу нинди әкәмәт тагын бу?

I к р е с т ь я н. Тукта, бусы да нәрсәдер башлады...

К ү ч ә р *(шигырь сөйли)*. Тракторга.
Әй, син, тирләгән кырларның аждаһасы!
Халык сиңа каршы!
Чөнки син,
Бер син,
Бар син,
Синең моторлы йөрәгеңдә кайнар кан
уйный!
Ул уйлый.
Трах! Бах!

Х а л ы к. Әй!
Малай!
Анаңны...

К ү ч ә р. Каер да тирләгән күкрәгең
җиреңнең
Яр да корсагын анда үскән инҗиреңнең,
Бораула бораy,
Кычкыр син бер
Мырау-у!
Ничә этләр синең артыңда һау!
Кыйгакакак!
Ах, так!
Үрдәк,
Каз,
Сиңа мин үзем ата каз
Ыҗ, ыҗ
Бак
Майлы балчыктан коймак
Тракторда пычак
Бер кочак,
Чап син алланың бу серле, дәүләтле,
Койрыгыңны аска бутап;
Бүген сиңа хисап —
Трактор килә, һап!
Ят басып һап!
Лап!
Алашаның артын кочаклап...

Х а л ы к. Долой, долой! Кирәкми!

К ү ч ә р. Нигә долой, мин әле бетермәдем!

Х а л ы к. Кирәкми, долой!

# ИЛ КАЙНЫЙ, ФИКЕР КӨРӘШӘ!

*Күренекле прозаик һәм драматург Аяз Гыйләҗевка 60 яшь тулды. Шул уңайдан укучыларыбызга аның белән үткәрелгән әңгәмәне тәкъдим итәбез.*



— Аяз Мирсәетович, укучыларыбызга Сезнең исемегез яхшы таныш. «Урамнар артында яшел болын» романы һәм «Өч аршын җир», «Җомга көн кич белән», «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят», «Урталыкта» кебек повестьлар, «Берәү» белән «Үги ана яфраклары» шикелле хикәяләр, шулай ук бик күп санлы очерклар, тормыш һәм әдәбият мәсьәләләренә багышланган ялкынлы мәкаләләр — барысы да Сезнең күңел җимешләре булып тудылар да замандашыбыз йөрәгенә килеп ирештеләр. Алар безнең чорыбызны тагын да кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү буенча шактый гына эш башкардылар, мөһим рухи вазифа үтәделәр... Хәтта әле алай гына да түгел: «Зәй энҗеләре» повестендагы Гәрәй Шамин кебек, «Әңгер-мәңгер» комедиясендәге Алим кебек геройларыгыз безнең хәзерге яңарыш чоры өчен дә — көн геройлары булып кабул ителә, алар бүген дә иң үткен проблемалар күтәрәләр...

Сез бүген ул әсәрләрегез турында нәрсә әйтә аласыз? Сезнең күргәннәрегез, кичергәннәрегез, уйлаганнарыгыз ул әсәрләрдә ни дәрәҗә чагыла? Ягъни алтмыш яшьлек гомер һәм иҗат ителгән әсәрләр... Аларның эчтәлекләре арасында аерма күпме чыга икән?

— Сезнең сорау мине үткәннәргә алып кайтты әле... Илленә узган елларга... Кырык яшькә...

Кырык яшемне үтә авыр кичердем мин. Һич яшермим, кичен ятканда бер кеше булсам, унҗиденче январь иртәсендә, кырык яшем тулганда, мин бөтенләй бүтән кеше идем. Үзгәреш шул кадәр тирән, катлаулы, чуалчык иде ки, аны бер сүз белән генә аңлатып та булмый... Бөтен дөнья, тирә-як, яшәгән мохитым, мине ураган кешеләр үзгәргән иде. Иң гаҗәбе: үз-үземә мөнәсәбәтем, кылган гамәлләргә карашым, үткәннәремә, язган әсәрләремә бәям башкача иде. Ачыграк дип әйтимме, анығрак, дөресрәк дип раслыйммы, кабатлап әйтәм, үзгәреш кискен һәм тирән иде. Бу хакта мин «Урталыкта» повестен язып, үз-үземне, заманны, кешеләрне аңларга тырышып карадым. «Кырыкка җиткән кешенең хәлен белү өчен үзең дә шул яшькә җитү кирәк... Кырыкка аяк баскан язучының хәлен белү авыр... К ы р ы к я ш е ң н е ң т а р и х н ы ң н и н д и е л л а р ы н а т у р ы к и л ү е м ө һ и м!.. Минем тормышта искитәрлек берни юк, гап-гади көнлекчемен»,— ди ачынып ул әсәрнең герое Сәгыйть... Повесть тулысы белән автобиографик булмаса да, аның эченә минем бик күп йөрәк әрнүләрем яшерелгән. Ачыктан-ачык әйтелгәннәре дә җитәрлек!.. Повесть тәнкыйтьчеләр күзеннән читтә калды, нишлисең, замандаш тәнкыйтьчеләрнең кем булуы да әһәмияткә ия!..

Кырык яшьне авыр кичердем, дидем. Шуңа охшашлы фикерне мин тиңсез акыл иясе, философ, хорват язучысы Меша Мәхмүт Селимовичның атаклы «Дәрвиш һәм үлем» әсәрендә дә очраттым. Әсәр герое Әхмәт Нуретдин исеменнән автор мондый фикер әйтә: «Миңа кырык яшь, начар чак: әле син яшь, теләкләрең сүнмәгән, мәгәр

син карт та, теләкләреңнең һәммәсен тормышка ашырырга мөмкинлегең юк. Дәрт иплән кенә сүнә, син өйрәнгән гадәтләреңә ышыкланып кына яши башлыйсың һәм моннан ары әллә ни майтара алмаслыгыңны ап-ачык аңлыйсың».— ди.

Бу гыйбрәтле тәҗрибәләр авазына өстәп, тагын ни әйтергә була? Соңра, кырык яшен тутыргач, җаныма якын рус шагыйре Евг. Евтушенко шуңар охшашлы фикерен раслап шигырь язып күңел ачты...

Илле яшь... Анысы чагыштырмача җиңелрәк узылды. Кырык яшьтә соңарып ачылган күз үз көчен бәяләгәндә инде ялгышмады! Елларның авырлыгын, әдәбиятның киртә-бусагаларны кичә-кичә абына-сөртенә барганлыгын, сәнгать үсеше юлына аркылы яткан кара ташларның көчен-мәкерен; бушбугазларның, ялагайларның, мөртәтләрнең бер кавымга дилбегәне үз кулларына эләктерүләрен, күпчелекнең ялган белән өстәгеләрнең колагын балавызлап куеп, илне талап, түбәндәгеләрнең рухын сындырып яшәүләрен күреп-белеп яшәсәм дә, бил баглап көрәш мәйданына атылырга көч калмаганлыгын аңладым. Хакыйкатьне, үзеңнең көчсезлегеңне аңлау никадәр авыр булса да, яшәргә, кулдан килгән кадәр хаклыкны халыкка җиткерергә кирәк иде. Җаваплы, сынала торган еллар кичердек. Чын дөреслекне бөтен тамырлары белән ачып салырга көчем җитмәсә дә, ялганга баш бирмәдем дип ышанам.

Алтмыш еллыгым илебездәге революцион үзгәрешләр елына туры килүенә шатланам, әлбәттә, бу еллар карт күңелләрдә дә көчне яңартыр, моңарчы кыяр-кыймас кына чагылып киткән уй-фикерләргә иркенлек, киңлек бирер дип көтәм. Кайчагында рухи яңарышның соңгарак калып килү ихтималы да буладыр ич?!

Әсәрләргә килгәндә исә, аларның дәрәҗәсе тигез түгеллеген күңел сизеп яши... Бүгенге көн ноктасыннан торып караганда (биеклектән түгел, мин үземне ниндидер бер биеклеккә баскан дип күз алдыма китермим, һич!), әсәрләрнең төрлелеген ачыграк сизәсең. Кабатлап әйтәм: язган чакта мин хакыйкатькә, халык язмышына битараф калмаска тырыштым, иманымның сафлыгын кылган гамәлләремдә күрсәтергә омтылдым, ләкин... бер чакта да ялгышмадым дип әйтә алмыйм. Булды, ярарга тырышканны сизми дә калган чаклар булды, әсәрләргә икеле-микеле фикерләр дә саркып керде, бигрәк тә пьесаларда андый очраклар булгалады. Хак, үзем күрмәгәнне, татымаганны, кичермәгәнне бер чакта да яза алмадым. Географик яктан да урын-юлларны, урман-сукмакларны тәгаен белергә, үзем күргәннәрне генә язарга тырыштым. «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикаят»та соңгы бүлекләр сугыш эпизодларын әченә алган иде. Мин сугышта булмадым, яшем кермәде, әсәрдәге сугыш эпизодлары җанымны борчып, күңелемне тырнап яшәде, һәм мин повестьны, русчага тәрҗемә иткәндә, тамырдан үзгәрттем, сугыш эпизодларын алып ташладым, яңача, хакыйкатькә туры китереп тәмамладым... Беләм, хәзер бик күпләр акыллы булып кыланып «без илдә үзгәрешләр зарурлыгын әллә кайчан белә идек... үзгәрешләрне сагыну минем фәлән әсәремдә бар... мин дөньяның астын-өстен ап-ачык күреп килдем!— дип күкрәк кагып, «яңа ракурстан» торып әсәрләр язарга керештеләр кайберәүләр, ашыгып-ашыгып, үткәндәге әсәрләрен заманга яраштырып иплән-сиплән матташалар. Мин үткәннәремнең һәммәсе өчен җаваплы булып калам, бер әсәремне дә үзгәртергә җыенмыйм. Мисалга, Татар академия театры сәхнәсендә бара торган «Өч аршын җир» пьесасына «борылыш кертергә» чакырып язылган мәкаләләр матбугатта күренгәләде инде. Пьеса, иң авыр елларда, 1972 нче елда язылды. Шулай булып калсын. Язучы кылган һәр гамәле өчен, язган һәр сүзе өчен бүген дә, иртәгә дә бердәй җаваплы. «Киек каз юлы» драмасы 1960—1961 елларда язылып, академия театры сәхнәсендә алтмыш бердә куелды. Кемнәр генә тибеп чыкмады мине ул чакта! Газета-журналларда егермегә якын рецензия басылып, замана кешеләре мине эт итте, бер ай уйналгач та спектакльне туктаттылар. Ә ул әсәр — минем йөз аклыгым!.. Бүгенге көндә калку куелган мәсьәлә — җитәкчеләрнең халыктан тәмам аерылу проблемасы ул әсәрдә заманча бөтен кискенлеге белән куелмаганмыни?!

— Сезнең иҗатта «Өч аршын җир» үзәк әсәрләрнең берсе булып тора. Үзегез әйтеп узганча, күптән түгел аның сәхнә варианты да дөнья күрде... Ул Сезгә ни дәрәҗәдә канәгатьлек китерә алды. Бер әсәрнең ике варианты турында фикерләрегез ничек?

— «Өч аршын җир» пьесасы шул исемдәге повесть нигезендә язылды. Мин повесть-хикәяләрне сәхнә әсәре итеп үзгәртүгә нигездә каршы килям, әсәр күңелдә үз «килеш-килбәте» белән туа. Никадәрле повесть, күпме пьесалар язып мин күңелгә иңгән теманың чишелешендә берчакта да икеләнмәдем: пьеса пьеса булып туды, повесть — повесть булып... «Өч аршын җир»не сәхнәләштерү хакында Марсель Сәлимҗановның тәкъдимен ишеткәч, мин көлеп җибәрдем: «Кая ул?.. Нигә?» Аннары, кинәт

кенә уйладым... һәм кыска гына вакыт эчендә яңа пьеса туды... Язылу аралары ун елга якын булганга, пьесада кайбер фикерләрем житлеккәнрәк кебек тоела, повестьта булмаган яңа сәхнәләрдә Мирвәли образы ачыклый торган сызыклар бар. Мәсәлән, тегермәндә барган вакыйгалар, урманчы белән очрашу күренешләре һ. б. Күп мәртәбәләр тыелып та, СССРның халык артисты Марсель Сәлимҗанов «Өч аршын җир»дән баш тартмады, әсәрне ашык-пошык үзгәртергә ашыкмады, мәхәббәте сүрелмәде, ниһаять, ул сәхнә күрде, әсәрнең яңа язмышы башланды. Талантлы, яшь режиссерыбыз Фаил Ибраһимов «Өч аршын җир»не Минзәлә театрында сәхнәләштерде, үз сүзенең югарылыгына ирешә үзенчәлекле спектакль тудырды. Бездә тыелып торганда, «Өч аршын җир»не ерак Нарын каласында кыргыз дусларыбыз күрсәтеп өлгерделәр.

— Безнең яңарыш чоры рухында бер «авыррак» сорау да бирергә рөхсәт итегез. Сезнең сәхнә әсәрләренең гомере бик үк озын түгел... Бу хакта үзегез ничек уйлыйсыз?

— Нигә бу сорау авыр булсын? Хаклы, нигезле һәм бик дөрес сорау! Һәм минем бу хакта кат-кат уйланганым бар... Менә без үзебезнең төп йортыбыз — Татар академия театрын «милли театр, аның милли традицияләре бар» дип, хаклы рәвештә бәялап киләбез. Ә аның миллилеген (ягъни, татарлыгын, татарчалыгын!) ниләр белән раслап була? Театрның нинди асыл сыйфатлары аның милли йөзен билгели? Беренче карашка бик җиңел кебек күренгән бу сорау шактый уйланулар, житди, төпле җавап сорый. Соңгы хөкем чыгаруны үз өстемә ала алмыйм, мәгәр, бер кызыклы күзәтүем белән уртаклашасым килә. Театрыбызның милли йөзен нинди сыйфатлар белән билгеләп була дигән соравыма, тәнкыйтьчеләрдән берәү, истә-оста юк җавап бирде: «Татар театры Чеховны уйнамый, уйный алмый. Аның беренче төсмере шул», диде.

Чыннан да! Горький элек-электән куела, Шекспирны уйныйбыз, бөек Островскийның күпчелек әсәрләре куелып килә, спектакльләр уңыш белән баралар, тамашачы аларны аңлый, кабул итә, җанына азык таба. Ә Чехов куелмый да куелмый... Нигә алай?!. Гомумән, бүгенге көндә Чехов — Англиядә, Японияда иң күп уйнала торган рус драматургы — безнең сәхнәләрдә бүгенге көндә яңгыраш таба алмый? Башкортлар куеп карадылар — уңышка ирешмәделәр. Рус сәхнәләрендә дә Чехов бүгенге көннең алдаларыннан түгел. ВААП отчетларына күз салсаң, сәхнәнең түрендә Константинов-Рацерлар бара... Нигә алай? Соңгы елларда, бигрәк тә XXVII съездга кадәр булган егерме ел эчендә, без халыкның рухын соң дәрәҗәдә тарайттык, аның дәртен сүндердек, уйлау сәләтен киметтек. Картлар да, яшьләр дә стандарт, әзер уйлар белән яши башладылар. Ә Чехов драматургиясе фикерне азакка җиткерүне көтә, уйлый белә алган кешеләрнең генә күңеленә юл сала, ул рухи сафлыкны, чисталыкны, идеалларның ачыклыгын сорый.

Мин кайчандыр Ибсенны, Шоуны, Чехов драматургиясен яратам, дип язып чыккан идем. Язучының кемне дә булса ихлас яратуы искиткеч мөһим роль уйный, ярата икән — аңарда рухи остазын, таянычын, фикердәшен күрә. Юк, юк, мин һич тә үз драматургиямне Чехов әсәрләре югарылыгына куярга җыенмыйм, белгәнегезчә, мин конкрет бер халыкның билгеле бер чорда яшәгән кешеләре турында язам. Алар Чехов геройлары дәрәҗәсенә менеп җитә алалармы, юкмы, аны да онытырга ярамый, әмма минем байтак җитди әсәрләремә Чеховның тәэсире булуын мин бүген, үзем яулап алган ноктадан торып, ачыктан-ачык икърар итә алам. «Хәдичәнең кече улы», «Киек каз юлы», «Эңгер-меңгер», «Җиргә тапшырылган серләр», «Югалган көн» пьесаларында Чехов аһәңнәре юкмыни?..

Турыдан-туры әсәрләрдә чагыла алмаган икән, бу аһәң минем җанымда бар, тере, хәрәкәтчән, көчле һәм кадерле!..

Стандарт фикерләр торгынлыгында яшәгән тамашачы тормыш чынлыгыннан, хакыйкатьтән качып торыр өчен йөрмәдеме театр залларына?.. Илдә барган хаксызлыкны күрмәдеме, туймадымы алар? Үзләренең көчсез, битараф икәнлеген чамаламадымы халык?.. Шуңа күрә театрларда ваемсызлык, җиңеллек, арт сикертеп кылану өстенлек алганда «Җиргә тапшырылган серләр» кебек шактый житди проблемаларны күтәргән әсәрләр, әлбәттә, уңышка ирешә алмады. Рухыма авазлаш режиссер табылмады. Режиссерлар арасыннан «мин мондый әсәрләрне аңламыйм!» дип койрыкны бот арасына кыстыручылар да булды. Нишлисең, дөнья!..

Кайбер пьесаларымның тиз-тиз мәтәлеп төшүен мин бары чорга, театрларга гына кайтарып калдырырга җыенмыйм. Яхшылыкның чиге юк, кайбер пьесаларым сузынкырак (халык ашыгып яши), прозага тартымрак (тамашачы һәмит таләп итә!) булып чыкты, гаеп атта гына түгел, тәртәдә дә бар. Бик яхшы аңлыйм.

— Сәхнә тормышына кагылгач, сүз уңаеннан тагын бер сорау: улыгыз, яшь драматург Мансур Гыйләҗевның Г. Камал исемендәге театр сәхнәсендә куелган беренче әсәренә ничек карыйсыз?

— Мансур пьеса язар дип әлегрәк уйлап та караганым юк иде минем... Гәрчә, мин өч улымны да бик яшьтән татар һәм рус театрларына йөртә башладым. Алар өчесе дә Камал театрын «безнең театр» дип атап үстеләр. Үз халкының җанын, күңелен

аңлатырга теләсәң, балаларыңның туган телне яшьтән үк матур итеп белүләрен теләсәң — балаңны бик яшьтән театрга йөрт!.. Мансур — архитектор, төзелеш институтының мәгълүм факультетын тәмамлады. Тырышып, ифрат зур көч салып укыды. Идел буе шәһәрләре студентлары арасында проектлары икенче урынны алды, диплом эшен үрнәк рәвештә Парижга җибәрделәр... Ул зур өметләр, якты хыяллар белән укып бетереп, өч елга Мәскәүгә эшкә китте. Һәм шунда үз һөнәренең нәтиҗәсез, буш, пүчтәк икәнлеген татыды... Үз эшеннән ризасызлык, каршылык күрсәтергә әле кулыннан килмәү аны драматургиягә китерде. Мәскәүдән ул дүрт пьеса язып кайтты: «Кәгазь шартлау», «Бәбәй арбасы», «Метеорит», «Рәхәт яшибез». Соңгысы академия театрында дөнья күрде. Биографиясе язучыны язучы итә. «Дөнья бирде кирәкне»,— диде шагыйрь һәм бөек сүзләр әйтә алды. Язучылыкка әзерләнгән кешенең язмышы җиңел булса, аның иген кыры уңдырышлы булмый, тиз саега, тиз туза. Мансурның беренче әсәре куелгач, гомере буе газеталарның баш мәкаләләренә генә ярарга тырышкан бер ханым: «Улыгызга бик начар әсәр язып биргәнсез!»— диде. Сөенеп куйдым, кәгазь колларына, тар карашлы таш маңгайларның үзәгенә үтәрлек пьеса язган икән, Мансурның киләчәге бар дигән сүз...

— Фикерне тагын дәвам итик әле... Бүгенге әдәбиятта яшьләр... Аларда Сезгә нинди сыйфатлар ошый? Ә нинди сыйфатлар ошамый?

— Яшьләр, яшьләр... «Рәшә» повестен юкка чыгарып, авторның намусына кагылырлык ямьсез сүзләр тулы мәкалә басылып чыккач, Әмирхан ага Еники белән очраштык... Хафаланган иде, кыйналган иде Әмирхан ага. Шунда мин аны юатырга теләп: «Минә Сезнең яшьтә янымда үзем кебек берәү утырса, мин бик бәхетле булыр идем», дидем... Өлкәннәр янәшәләрендә ныклы, төпле, ышанычлы яшь буын вәкилләрен күрергә телиләр... Бармы бүген безнең күз текәп торган яшьләребез? Юк икән, моңа кем гаепле? Кемнәр алар бүгенге көндә иҗат юлына төшәргә вак-вак сукмаклардан килүчеләр? Нинди чор җимешләре? Кайсы түтәлдә үсеп пешеп җиткәннәр алар?.. Бүген әдәбиятка кем килә?..

Бүген әдәбиятка нәкъ менә югарыда әйтеп киткән катлаулы чорда азыкланган яшьләр керергә омтыла. Алар арасында әрсезләр, бары тик үз мәнфәгатьләрен генә алга сөргән эгоистлар, көмсызлар, дан тагарагыннан зуррак өлеш эләктереп калырга атлыгып торучылар, прагматистлар күбрәк икән — моны, бу фаҗиганы аңларга да була. Әле союзга кереп җитмиләр, шәп-шәп квартиралар таләп итәләр, иҗат йортларына путевкалар кирәк аларга, калын-калын китаплары чыксын... Әле чын йөзләре ачылып та җитмәгән, алар Язучылар союзына алуны таләп итәләр, бераз гына кичектереп торсаң да: «Сезнең өстән кайларга жалоба язып була?»— дип, оятсызларча шалтыраталар, әтиләрен җибәрәләр, кабул ителмәсәләр, әтиләре, җәнҗал чыгарып, төрле тарафка шикаятьләр язып йөри... Азны биреп күпне умырырга ашкынган яшьләр килә безнең арага. Гаеп кемдә? Гаеп, әлбәттә, яшьләрнең шәхсән үзләрендә дә булып, гаеп бездә дә, без корган чорда да бар. Ни күреп үсте безнең яшьләр?.. Оясында ни күрсә, очканда шул булыр дигәңнәр бабайлар. Авыз пешкәч, салкын суны да өреп кабарга маташсак та — авыз пешкән инде, иреннәр уелган, аңкаулар туналган. Комсызлык, социаль күренешләргә битарафлык, сәяси пассивлык бездән балаларга күчмәдеме? Яшьләр арасындагы бозыклык күренешләренә, эчкечелеккә, алкоголизмга, эгоцентризмга моңарчы үзебез ни дәрәҗәдә таләпчән идек тә ни кадәрле игътибарлы булдык?.. Үзебез чәчкәнне урабыз, «өлкәннәр, уяу булыгыз: балалар сезне уйнап күрсәтә!» дигән хак сүзне оныттык...

Язучы — көрәшче ул. Бер чор яшьләре ни өчен, кем өчен көрәшергә икәнен белмичәрәк калды, без аларны аңлы рәвештә сукырайттык. Булды заман, без «яшьләребез ал да гөл, алар чирәм җирләргә китәләр, БАМ төзиләр, диңгезләрне кичәләр», дип чат саен шапырындык. Һәммәсе дә хак!.. Яшьләребез кыю, эшчән, батыр да, матур да... Ә панклар, хиппилар, тимергә табынучылар, наркоманнар, токсикоманнар каян килеп чыкты? Газеталар әледән-әле җинаятьләр хакында хәвефле хәбәрләрне җиткереп тора... Яшьләрнең бу өлеше кайда үскән?.. Булды заман, яшьләребез күңелләренең алласы итеп бөек бардыбыз Вл. Высоцкийны сайлап алгач, без мыек астыннан гына көлеп йөрдек. Онытмыйк, алла юк җирдә шайтан түргә үтә!.. Без яшьләрне, балаларыбызны күрәләтә шайтан тозагына төшермәдекмени?.. Без аларны көрәшергә түгел — ярашырга, яраклашырга, сүзсез буйсынырга күнектердек...

Илебездә бара торган кискен һәм бәрәкәтле үзгәрешләр безнең нигезебезнең ныклыгын раслый. Яңа тормыш шартлары, яңа фикерләү рәвеше, «гласность», үзгәрешләр һәм тизләнеш яшь буынга яңача җан өрер дип ышанам, шуңа өметләнәм, алгы сызыкка «үзе турында түгел, иле турында уйлаучы» буын килер дип көтәм. Һәр чор алгы планга үзенең җаваплы кешеләрен чыгара. Хуҗалык сферасында, сәүдәдә, авыл хуҗалыгында, завод-фабрикаларда рухлары яңача ачылган эшлекле, уйлау сәләтенә ия булган хәрәкәт-

чән кешеләр бар икән, нигә алар әдәбиятта-сәнгатьтә дә булмаска тиеш? Булыр алар. Кол җанлы, сап-салкын канлы халтурачыларга алар ясин чыкмаса, кем чыгар?..

— Татар әдәбиятының бүгенге тормыштагы иҗтимагый абруе... Тукайлар чоры... Ибраһимовлар чоры... Җәлилләр... Безнең абруй кайсы якка таба юл тота икән?..

— Тормышыбызда әдәбиятның урыны... Иҗтимагый абруе... Зур, җитди сораулар болар. Боларга ышандырырлык дәрәҗәдә җавап бирү өчен кулда социологик тикшеренүләрнең йомгагы да булырга тиеш. Иҗтимагый тормышыбызның әчтәлеген бер әдәбият-сәнгать кенә билгели алмаган кебек, алардан башка иҗтимагый тормыш та тулы була алмый. Әмма, зур кызганычка каршы, әдәбият белән халык арасы елдан-ел ераклаша бара. Бердән, замана безнең кешеләрнең тормышын бөтен яктан үзгәртте, берәүләр чиксез баеп киттеләр. Чамасыз байлык хуҗалары — тук күңелле кешеләр, мал артыннан мал куалап, җаннары хакында онытып тордылар. Әлбәттә, халык бай булырга, яхшы яшәргә, теләгәнен ашарга тиеш. Бу туклык, мул тормыш гадел юл белән килгәндә табигый күренеш. Әмма күпчелек соңгы елларда байлык тарафларына кыек юл сайлады. Хәрәм байлык кеше күңелен үзгәртә, каралта, тупаслandыра. Хәрәм байлык хакына кешеләр җаннарын саталар. Андыйларның күңеле бикле, җаны тозакта, аларга телең дә, әдәбиятың да, китапларың да кирәкми... Телебезгә мөнәсәбәтнең үзгәрүен дә ачынып искәртеп узарга кирәк. Туган телендә дөрес сөйләшкән райком секретарьлары күпме генә икән? Колхоз-совхоз җитәкчеләре?.. Югары даирәләрдә утыручы хөрмәтле иптәшләр?.. Татар телен белмәүне өстенлек санап йөрүче хәсрәт җитәкчеләр азмы бездә бүген? Татар культурасының җаваплы кешеләре арасында үз телләреннән чирканган иптәшләр очрамыймы? Ниһаять, татар теле галимнәре, татар язучыларының балалары телебездән читләшмиләрмени?! Рус теленең безнең тормыштагы чиксез олы урынын зирәкләрнең зирәге Утыз Имәнидән башлап бик күп язучыларыбыз раслап килгәннәр. Рус теле арадаш тел генә түгел, ул безнең күңелләргә бәяләп бетерә алмаслык кыйммәтләрне — Пушкин, Толстой, Достоевский иҗат җимешләрен ирештерә торган тел, аны белү дөнья байлыгы. Ләкин туган теленнән йөз чөерү, курәләтә аннан баш тарту — кеше өчен ифрат зур кимлек. Ни өчендер без бу хакта авыз ачып сөйләшергә куркыбрак яшәдек. Ә Чыңгыз Айтматов тотты да шундый гөнаһ шомлыгы булган күренешнең асылын ачып бирде, манкортлыкның нинди нәтиҗәләргә китереп җиткерүен дөнья каршысына чыгып әйтте.

Татар әдәбиятының казанышлары илебез халыкларының уртак хәзинәсе булса да, ул казанышлар, иң беренче чиратта татар халкының байлыгы. Без ул хәзинәдән рациональ файдалана белергә тиеш. Әлбәттә, мәхәббәт бер яклы гына була алмый. Сент-Экзюпери раслаганча: «мәхәббәт ул бер-береңә карап тору түгел, мәхәббәт — икең дә бер юнәлешкә карау!» Әдәбият халкыбызның үсә барган зәвыгын канәгатьләндерергә, әзерлекле укучыга да җан азыгы булырдай әсәрләр тудырырга тиеш. Менә бүген, төрле телләрдә «Арбат балалары», «Алтын болыт куныл китте», «Зубр» романнары йөргәндә, газета-журнал мәкаләләрен ябырылып укып, көтелмәгән информацияләр алганда, без үз халкыбызны орлыгы сугып алынган мәкинә шикелле буш, коры, аңкауга тия торган әсәрләрдән коткара алмасак, әдәбиятыбыз халыктан тагын да ныграк ераклашачак. Халык әдәбиятның төссезләнгән, көчсезләнгән, гарипләнгән берчакта да гафу итми, вакытлы уңышлар, арзанлы мавыгулар безнең күзне буа күрмәссеннәр! Әдәбиятта талантлы чынлык кына яшәргә хаклы!

— Соңгы елларда Сезне куандырган әдәби әсәрләр бармы? Нинди ләр?

— Соңгы елларда әдәбиятыбызда шәхесләр күзгә күренеп кимеде, әдәбият хәрәкәте тарайды, егәребез кечерәйде. Әлерәк кенә арабыздан киткән якты шәхесләрне күз алдына китереп карыйк: Ибраһим Гази, Мирсәй Әмир, Хәсән Туфан, Сибгат Хәкимнәр нинди зур вак-төякләрдән өстен, чиста кешеләр булган икән!.. Ә без хәзер, көтүчесен югалткан сарык көтүе хәлендәрәк калдык шикелле. Үзара хөрмәт кимеде, олылар олы була алмаган кебек, яшьләр дә сөрлегеп, таралып беттеләр. Әдәбиятның маяклары калмады диярлек. Татар язучылары, төссез төркемнәргә бүленеп, бердәй соры, уртакул әсәрләр тәгәрәтеп торалар. Халык күңелен кузгатырлык әсәрләр сирәк, бик сирәк күренеп кала. Алар да кичәгене бүгенгә, бүгенгене иртәгә ялгап өлгерә алмыйлар, татар әдәбияты җанлы, тоташ агым булудан туктады, күлләре кипте, елгалары саекты. Я, нинди әсәрне күтәреп алып халык тормышының кайнап торган уртасына чыгарып салганыбыз бар?.. Мәхмүт Хәсәновның «Язгы ажаган»ы, Мөсәгыйт Хәбибуллинның «Кубрат хан»ы, Марсель Зариповның гамь тулы очерклары, тагын нәрсә?.. Әлгәрерәк М. Мәһдиев, Н. Фәттах, В. Нуруллин... В. Нуруллинның соңгы повесте аның заман ту-

рында җитди уйлануларын, илебездәге үзгәрешләргә битараф түгеллеген күрсәтә. Гариф Ахунов «Идел кызы» романының икенче китабында дөньяны яңачарак күрергә тырышуын раслады. Кызганычка каршы, без, романны кульязма хәлендә укыган кешеләр, аның бу омтылышын аңлап бетермәдек, авторга тиешле ярдәмне заманча биреп бетерә алмадык.

Мин югарыда телгә алган замандашларым талантсыз кешеләрме әллә? Һич юк! М. Мәһдиевның кайбер әсәрләре оста кул белән, вакыйгаларның үзегеннән торып язылганнар. Әмма аларга авторның мөнәсәбәте җитеп бетми, бәһасе, вакыйгаларның юл арасы юк, алар бик турыдан, тапталган сукмаклардан баралар... Замандашларыма да, үземә дә сүзем бер: без бүгенге көннең революцион үзгәрешләренә әзер түгел идек, пассивлыкны, кыюсызлыкны акларга маташып, төрле сәбәпләр табып, тынычланып, юанып йөрдек. Ә рус әдәбияты вәкилләре, башка милләтләр үз араларында чын сугышчан характерлы әдипләр дә тәрбияләп өлгергәннәр икән. Ә безнең хәл бөтәнчәрәк, һаман, чама чамадан артмасын дип, бер-беребезне үткен күзәтәбез. Нинди болгавыр, авыр, чын язучы әрнеп аваз арты аваз салыр еллар кичердек, яшәдек, бер генә әсәребез дә бәхәскә, каршылыкка очрамады диярлек, һәммәсе шома гына шуа барды. Чөнки без ботак-сатаксыз язарга остардык, күзебез аяк астындарак булды, чынлап торып артка да карамадык, алга карауны әйткән дә юк инде анысы, «белми калдык, сизми калдык»... Шулай түгелмени? Иң кызганычы, яшь прозаиклар арасында да кыю, тәвәккәл, әдәбиятка очраклы гына килмәгәнлеген раслап сискәндерерлек авторлар юк диярлек. «Бик сагынган чакларында», Туфан Миңнуллин, «эх, бәхәс кузгата торган берәү килсен иде!»— дип юкка гына әйтәмени?!

Мөнә замандашларымны күз алдымнан үткәреп утырам... Бар аның, үз дәрәҗәләрен белеп, тыйнак кына язып килгән, затлы хезмәт күрсәткән авторларыбыз да бар. Ләкин заман көткән, заман таләп иткән гаҗәеп китап, әдәбиятның таҗы булырлык, укучыларның бөтен катлауларын берләштерерлек, татар халкын бер башка югары күтәргән китапны беребезнең дә язганы юк әле. Шундый китап кирәк. Күктә йолдызлар күп, ләкин әлегә аның кояшы да, ае да юк. Мин бүген драматургия бакчасына кермим, шигърият түтәлләре арасында йөрергә җыенмыйм, сүзем проза, прозаиклар турында гына...


— Сер булмаса, Сезне хәзер нинди уйлар борчый? Бу уйлар язып утыра торган әсәрегезгә керәме?

— Шундый бер риваять бар. Борынгыда бер кабиләдә искиткеч егәрле бер батыр яшәгән. Чукмары белән бер селтәнсә — дошманның бер дистәсен, кылычын бер айкаса, йөзен кырып сала икән теге... Кылычын да, чукмарын да бөтәннәрдән берәү дә күтәрә алмый икән баһадирның... Менә ил чигенә дошманнар басып кергәннәр... Баһадирга хәбәр салганнар. «Ничәү алар, дошманнар?» дип сораган каз боты кимереп, кырын яткан батыр. «Ике дистәләп булыр», дигәннәр аңа. «Һәй!» дигән батыр, ике дистә дошман өчен кузгалып тормыйм әле!» Дошманнар кабиләнең елкыларын куып алып та киткәннәр... Икенче вакыт, берничә еллар үткәч, йөзләп дошман килеп, кабиләнең сарык көтүен әйдәп алып киткән. Икенче юлы ике йөз дошман басып кереп, кабиләнең байтак кешеләрен әсир иткән... Атаклы баһадир үз көченә торырлык дошман килүне еллар буе көткән. Ниһаять, дошман явы кара болыт булып илгә ябырылган... Офыкны иңнән-иңгә басып киләләр икән явызлар. Баһадирга хәбәр салганнар: «Көнең килде, кузгал! Кыр дошманнарны!»... Баһадир сикереп торган, каз ботын читкә бәргән, кылычына тотынган — селти алмый... Чукмарына барып ябыша — күтәрергә көче җитмәгән...

«Язып утыра торган әсәрем шундый-шундый!» дип мактанырсың... Көчең җитмәсә? Егәрең калмаса?.. Талпынып карыйк каравын... Ни барып чыгар... Язарга кирәк кирәген!.. Мөмкинлекләр ачылды, ил кайный, фикерләр көрәшә, халыкларга уйлау сәләте кайта, күздән ал пәрдәләр төшә... Ил буздан җитди сүз көтә. Егәр җитәрме, хәл калганмы — карап карыйк...

# ГЕРОЙЛАРЫ БЕЛӘН КУЛГА-КУЛ

## ШАМИЛ БИКЧУРИНГА 60 ЯШЬ



Үзеңнең каләмдәш дустың турында сүз әйтү, бигрәк тә аның иҗаты турында сөйләү — бик күңелле дә һәм шактый кыен да вазифа. Күңелле шуның өчен, чөнки син каләмдәшең иҗатын кемгә караганда да яхшырак беләсең, аның күп кенә әсәрләре синең күз алдыңда диярлек туа; шуңа кыен — язучы үзенең елмаю-көлүләре, ачулы, моңсу чаклары, уйчан минутлары белән синең каршыңда гына гел басып тора кебек.

Шамил Бикчурин... Бу исем әдәбиятта илленче еллар ахырларында республикабыз нефтьчеләре һәм нефть ягы төзүчеләре турында тормышчан очерклар авторы буларак күренә башлады. Шамил белән безнең очрашуыбыз да нәкъ шул елларда булды.

1959 елның көзе иде. Лениногорск шәһәрендә халыклар дуслыгы бәйрәме үткәрелде. Бәйрәмгә тугандаш Башкортстан, Әзербайҗан нефтьчеләре дә килгән, шулай ук Казаннан язучылар һәм сәнгать эшлеклеләре чакырылган иде.

Бәйрәм тантанасы башланганчы, гостиницага чандыр гына, озын гына буйлы, җиту салам чәчле бер егет килеп керде дә, безне шәһәр белән таныштырып йөрергә алып чыгып китте. Шәһәр турында ул бик яратып сөйли, аннан да бигрәк, нефтьчеләр турында, «кара алтын» байлыгының ничек табылуы турында сөйли башласа, дөньяларын оныта иде. Тагын шунысы хәтергә бик сеңеп калган. Шәһәр урамы буйлап барганда егеткә бик күпләр сәлам биреп уза, кайберләре белән тукталып сөйләшеп тә китәләр, егетебезне шәһәр кешеләре үз итүләре, яратулары әллә кайдан сизелә иде.

Сабыйларча саф һәм көр күңелле Шамил Бикчурин белән беренче очрашу әнә шулай булды. Күренекле язучы Ибраһим Газиның Шамилгә шул вакытта ук кат-кат әйтүе бик истә:

— Синнән, Шамил, нефтьчеләр турында төпле, зур әсәрләр көтәбез,— диде өлкән әдип.— Нефтьчеләр тормышын синнән дә яхшырак белүче арабызда берәү дә юк, бу турыда язмаска хакың юк синең. Кабатлап әйтәм, хакың юк!

Олы язучының яшь каләмдәшенә биргән мондый киңәше, әлбәттә, дөрес иде. Әлмәт районының Миңлебай авылы егете Шамил. Мәгълүм булганча, куәтле Тимәш-Ромашкино нефть ятмаларын үзләштерү нәкъ шушы төбәктә башланды. Шамил «кара алтын» өчен барган бу олы көрәштә читтән күзәтүче булып кына түгел, турыдан-туры катнаша. Әлмәт шәһәренең беренче нигез ташларын салыша ул, соңрак комсомол җитәкчесе, җирле газета, радио, телевидение хезмәткәре буларак та нефтьчеләрнең, төзүчеләрнең борчу-шатлыклары белән янып-көеп яши. Аңа әсәрләре өчен геройлар эзләп, әллә кайларга барып йөрисе юк, алар Шамилнең дуслары, авылдашлары, сабакташлары. Шуңа күрә дә аның соңрак «Ташлы тауда», «Истәлекле таш», «Алтын җирдә ятмый» җыентыкларына тупланган очерклары, хикәяләре гаять тормышчан яңгырый, аларны мавыгып, язучыга ихлас ышанып укыйсың.

Шулай да Ш. Бикчуриннан каләмдәшләре көткән, аерым алганда, И. Гази киңәш биргән нефтьчеләр турындагы киң колачлы күләмле әсәре тиз генә тумады әле. Моның өчен, күрәсең, вакыт сынавын үтү, каләменең тагын да чарлана, ныгый төшүе таләп ителгәндер.

Аның каравы, алтмышынчы елларда Ш. Бикчурин үзенең каләмен драматургия өлкәсендә уңышлы гына сынады. Язучының драматургиягә мөрәҗәгать итүе дә очраклы хәл түгел иде. Бик яшьтән үк «театр җене» кагыла егеткә. Казан театр училищесында да укып йөри, Әлмәт күчмә театрында артист булып та эшли. Әнә шуңа күрәдер, аның «Тальян моңы» дигән беренче музыкаль комедиясе Әлмәт драма театрында уңышлы яңгырады. Шуның артыннан иҗат ителгән «Бергә гомергә» драмасы исә Татар Дәүләт академия театры сәхнәсенә менде.

Ниһаять, 1973 елның язында Ш. Бикчурин Әлмәт язучылар оешмасына бик калын папка күтәреп килде. Бу — без аннан күптән көткән «Каты токым» романының кульъязмасы иде. Әйтергә кирәк, Шамил бу романын тыныч-тын кабинет шартларында, тормышның бар мәшәкатьләреннән читтә торып язмады. Көндезләрен җирле радио һәм күптиражлы газета редакцияләрендә эшли, мәкаләләре һәм чыгышлары өчен материаллар туплап, буровойларда, нефть предприятиеләрендә, төзелешләрдә, колхозларда була, әдәби иҗат өчен аның бары төннәре һәм ял көннәре генә кала иде. Әнә шулай йокысыз төннәр һәм гаять киеренке хезмәт белән туды бу роман. Әсәр Әлмәт язучылары җыелышында, аннары «Казан утлары» редакциясендә тикшерелгәч тә, Шамил аны камилләштерү буенча һич иренмичә эшләде.

Тирне күбрәк түккән саен, хезмәт җимешең тәмлерәк була бара, диләр. Ш. Бикчуринның «Каты токым» романы әнә шундый «татлы җимеш» булып чыкты. Әсәр «Казан утлары» журналында басылып чыгуга, ул укучыларның һәм әдәби тәнкыйтьнең игътибарын җәлеп итте. Аннары роман рус теленә тәрҗемә ителеп, «Москва» журналында басылды, аерым китап булып чыкты. Тормышчан һәм талантлы каләм белән язылган әсәрне башкалабыз тәнкыйтьчеләре дә тиз күреп алды. «Каты токым» турында «Правда», «Известия», «Литературная газета», «Литературная Россия» битләрендә бик җылы сүзләр әйтелде. Әсәр белән тугандаш социалистик илләр дә кызыксынды. Ул Чехословакиядә басылды, үз телләренә тәрҗемә итәргә рөхсәт сорап, башка демократик илләрдән дә авторга хатлар килә башлады. Әсәр эшчеләр сыйныфы темасына язылган иң яхшы әсәрләргә үткәрелгән Бөтенсоюз конкурсында ВЦСПС һәм СССР Язучылар союзының бүләгенә лаек булды.

«Каты токым» романының уңышы нәрсәдә соң?

Әсәрнең эчтәлеге киң укучылар массасына яхшы таныш. Ул — республикада нефтьчеләр коллективы туу, җылы интернациональ дуслык нигезендә коллективның ныгуы, олы һәм куәтле көчкә әверелүе турында. Бу темага рус әдәбиятында да, татар әдәбиятында да әсәр язылмады түгел. Ләкин Ш. Бикчурин бу җаваплы теманы, берәүне дә кабатламыйча, үзенчәлекле итеп күрсәтеп бирә алды. Барыннан да бигрәк, әсәрдә чын хезмәт шигърияте яңгырый, анда татар, рус, казах, әрмән халыклары вәкилләренең образлары һәркайсы индивидуаль сыйфатлар белән укучылар алдына килеп басалар. Романның буеннан-буена ягымлы юмор белән сугарылуы — әсәрне укучы күңеленә тагын да якынайта, укучы роман геройларын үз итеп, яратып өлгерә. Күренә ки, «сер» дигәнебез әллә ни зур түгел: тормышчанлык, җанлы образлар (боларга ирешүдә авторның үз күзәтүләре байлыгын истән чыгармыйк), аннары әсәрнең буеннан-буена ягымлы юмор белән сугарылуы, бигрәк тә халык юморы. Болар һәр иҗат кешесе өчен мәгълүм шартлар, ләкин моңа ирешү кыен. Шамил Бикчурин исә шушы кыенлыкны җиңеп чыга алды.

1980 елда Ш. Бикчурин «Тирән катлам» романын тәгәлләде. Мәгълүм булганча, заманында Татарстан нефтен үзләштерүдә илнең бөтен төбәгеннән килгән осталар ярдәмгә килсә, Себер нефтен үзләштерүдә инде республикабыз нефтьчеләре үзләре остазлар булып шул якларга киттеләр. Шамил үзе атаганча, «каты токым»нан булган нефть осталарыбызны Себернең кырыс табигате дә, шул кырыс шартларда «кара алтын»га беренче булып юл салуның кыенлыклары да куркытмады. Язучының бу романы әнә шул турыда. Ягъни, какшамас халыклар дуслыгының яңа бер матур чагылышын ача автор.

Алдарак мин Шамилгә әсәрләре өчен геройлар эзләп ерак барып йөрисе юк, диген идем. Бу романы өчен ул ерак Себергә — Түмән нефтьчеләре янына озак срокка барып кайтты. Ләкин бу сәфәрендә дә ул... Тукта, бу турыда сүзне Шамилнең үзенә бирү уңайлырак булыр.

— Шулай, килеп төштем моңарчы бөтенләй таныш булмаган, әле яңа гына туып килүче Себер нефтьчеләре каласына. Таң атып килә иде. Кая барыйм, гостиница дигәннәре бармы монда? Берсен дә белмим. Сорашырга әле урамда кешеләр дә күренми. Шул чак таң алды тынлыгын яңгыратып, җыр яңгырады. Өздереп тә безнеңчә, татарча җырлыйлар. Аякларым үзеннән-үзе шул якка таба атлады. Җырчы егетләр янына якынлашсам, күрәм, үзебезнең Лениногорск егетләре ич!

— Әй, диваналар! (Шамилнең якын дусларына яратып әйтә торган сүзе шундый инде. — Р. Т.) Кешеләрне татлы таң йокыларыннан уятып нишләп йөрүегез бу?— дим.

Егетләр җырларыннан туктап, тынып калдылар.

— Шамил абый! Син түгелме соң бу?

— Нинди җилләр ташлады, Шамил абый?

Әй китте кочаклашып күрешүләр, туган Татарстан турында сорашулар. Егетләрнең өй туеннан кайтып килүләре икән, бер иптәшләренә яңа өйдән квартира биргәннәр. Ирексезләп, шунда, яңа квартирага алып киттеләр. Өй хуҗасы да таныш иптәш булып чыкты. Иртәгесен, Себер нефтен үзләштерүчеләр белән якыннанрак танышу өчен, кайсы гына конторга барып кермә, анда да Татарстаннан килгән танышларым белән очрашмый калмадым.

Шулай итеп, Шамилнең бу ерак сәфәре дә дуслары һәм якын танышлары арасында үтә. Иҗат кешесе өчен сер түгел, әсәрең өчен иң төпле һәм уйландырырдай гыйбрәтле тормыш материалын бары тик әнә шулай дусларың һәм якын танышларың белән тыгыз аралашуда, эчкерсез әңгәмәләрдә табасың.

Язучының бу романын да укучылар яратып кабул итте. Ул рус теленә тәрҗемә ителеп, «Волга» журналында басылды (1982) һәм журналның еллык премиясенә лаек булды. Тиздән роман башкаланың «Современник» нәшриятында басылып чыкты.

Шамил Бикчурин хәзер үзенең яңа зур әсәрен иҗат итә. Һәрвакыттагыча, үз геройларының борчу-шатлыклары, тынгысыз уйланулары дөньясында яши. Без аның бу иҗади эзләнүләре дә яңа иҗат шатлыклары алып килер дип нык ышанабыз.

**Рафаил ТӨХФӘТУЛЛИН.**




# ШӘҺРЕ БОЛГАР

*Редакциягә журнал укучылардан борынгы Болгар шәһәрләре турында материаллар бирүне сорап күпсанлы хатлар килә. Шул сорауларны истә тотып, журналның быелгы саннарында Болгар шәһәрләре тарихына багышланган язмалар урнаштырылачак.*

Шәһре Болгар... Бу исем рухи дөньябызга, күңелләребезгә әнкәбез күкрәгенең җылы сөте аша, сабый чагыбызда ул җырлаган җырлар, сөйләгән бәет-дастаннар, риваятьләр белән тирән уелып калган. Менә ни өчен ул гомер буена күңелебезнең иң нечкә кылларын да тибрәтә ала торган моңсу аһәң булып яңгырап тора. Борынгы калабызны үз һәм якын итү, төп нигез — туган йорт буларак табыну, күп еллардан бирле буыннан-буынга бирелгән кайтаваз сыман хәзерге җиребез, туган туфрагыбыз, туган төбәгебез, туган илебезгә карата тирән мәхәббәт хисе булып үрли, какшамас тамырларын җибәрү белән бергә безнең гражданлык позициябезне билгеләргә, тормыштагы кыйблабызны ачыкларга ярдәм итә. Аңлатып та була алмый торган магниттай тарту көченә ия шәһре Болгар... Шуның өчен булса кирәк, ямьле җәйгә чыгу белән, көннәр җылытуга Татарстан районнары авылларыннан әби-бабаларыбыз икешәр, өчәр кеше берләшеп, яисә төркем-төркем булып, ерак бабаларыбыз җире, данлы һәм шанлы шәһре Болгарга юл тоталар. Нигә, ни өчен, ни калган аларга хәрабәләрнең кайберләре генә сакланган бу борынгы шәһәр урынында? Шушындый сорауны мин гомерен Тау ягы төбәгендә, Апас районының Болынбалыкчы авылында эшләп үткәргән, яше хәзер 70 кә җиткән Бибигаян әби Гыймалетдиновага бирдем. Сорауны ишеткән әбкәй яшәреп киткәндәй булды, битендәге җыерчыклар тигезләнгәндәй итте, авырткан аяклары белән кузгалып, янымарак килеп утырды һәм, җавап биреп тормастан, таныш бәет юлларын яттан көйләп китте.

*Сәлам улсын сиңа, Болгар, олуг данлар күтәрдең,*
*Мәдәни шәһәр улдыгың Яурупага күрсәттең.*

*Синең изге балаларың китапларын алдылар,*
*Наданлык вә җәһаләтне аяк аска салдылар.*

*Тимердән вә ташлардан салган биналар вәйран,*
*Ни сәбәптән улды вәйран, белмәүче улыр хәйран.*

*Шәһре Болгар юлларына таш пулатлар салалар,*
*Шәһре Болгар вәлиләре каршы чыгып алалар.*

*Габдрахман коесындан дәвага су алалар,*
*Габдрахман тау башына нәзер корбан чалалар.*

*Шәһре Болгарларга бардым зиярәт кылырмын дип,*
*Рабига күлләрен күргәч, сәламәт булырмын дип.*

Әби үзенең авылдашлары, яшьтәш карчыклары белән бергә шәһре Болгар газизләренә, Габдрахман коесына, Рабига күленә зиярәт кылу максаты белән баруларын һәм юлда булган бер хәлне сөйләде:

— Аякларым озын-озак юл йөрер өчен ярамый, сызлый һәм авырталар. Ләкин, нихәл итмәк кирәк, әби-бабалар хәтере авыртудан кыйммәтрәк бит. Кайтышлый, метеордан төшеп Тәтеш тавын менә башлагач, бара алмас булдым. Юлга утырдым. Иптәшләрем аптырап янымда басып торалар. Шунда артыбыздан килгән ике яшь ир үземне баскычлардан күтәреп алып менде-

лэр һәм автобуска кертеп үк утырттылар. Гомерләре озын, бәхетләре мул булсын, нәүмиз итеп юлда ташлап калдырмадылар, рәхмәт яшьләргә — дип, әби күңеле тулудан чыккан яшьләрен сертеп алды.— Яшьрәк вакытта шәһре Болгарга ел саен бара идек, хәзер инде картлык ягына чыккач, ике елга бер бармый калмыйбыз, дип әбекәй сүзен тәмамлады.

Халкыбызның бу шәһәргә юлы өзелми, анда баруны авыру һәм картлык тоткарлап кала алмый икән. Үткәннәр хәтеренә тап төшерми кадерләп саклый белә торган шушындый сабыр һәм тыйнак ана-әбиләр, ата-бабалар — шәһре Болгар нәселләре, республикабыздагы һәр татар авылының нигез ташын тәшкил итәләр, эшлекле, хезмәт ярата торган алмаш үстерәләр.

Борынгы бабаларыбыз шундый зур таш пулатлары булган калалар төзегәннәр, килгән кадерле кунакларны каршы да чыгып алганнар. Алар киң күңелле, саф фигыльле, эш сөючән, башлы һәм мәнле булганнар.

Урта гасырларда Европа һәм Шәрык илләрендә дан тоткан, халкыбызның хәтереннән, теленнән һәм җырларыннан төшмәгән бу шәһәр. Болгар дәүләте яшәешенең аерым тарихи чорларында аның үзәге — башкаласы хезмәтен дә үтәгән. Болгар исеме урта гасырлардагы гарәп-фарсы, шулай ук татар тарихи чыганакларында, нумизматика һәм эпиграфика материалларында чагылыш таба. Шәһре Болгар, аның даны, матурлыгы, урыны, халкы тормышының мул һәм иркен, өс-аяк киемнәренең күркәмлеге, базарларының кайнап торуы, товарлары күплегеннән киштәләр сыгылуы, кызларның тал чыбыгыдай матур-сылулыгы, ир-егетләренең батыр, курку белмәс йөрәкле булулары һ. б. турында бик күп язылган. X гасырдан башлап, дөнья аренасында Болгар экономик яктан нык үскән, мәктәп-мәдрәсәләре гөрләп торган шәһәр буларак дан тоткан. Аның болай алга китүенә үзендә акчалар сугу да, һичшиксез, зур ярдәм иткән, билгеле. Шәһәрнең кайсы елда салынганы төгәл генә билгеле түгел, ләкин куфи дирһәмнәренә охшатып Болгарда сугылган һәм датасы билгеләнгән беренче акчалар 903—908 елларга карый. Алар болгар ханы Җәгъфәр бине Габдулла исеменнән чыгарылганнар. Болгар халкының абруйлылыгы, тормыш-көнкүрешенең яхшы-иминлеге килгән кешеләрнең күзенә иң беренче чиратта чагылган. 985 елда Киев кнәзе Владимир, абыйсы Добрыня белән, Болгарга яу чаба. Добрыня, болгар сугышчыларының күн итек-читектән иканлекләрен күреп, кнәзьгә, болар безгә ясак түләмәс, әйдә, башка урыннардан чабаталыларны эзлик, дип эшлекле киңәшен бирә. Болгар иле белән Киевнең үзара тыгыз мөнәсәбәте яу чабулардан башка тагын сәүдә торгызып аралашуда да күренә. Мордва һәм бортас җирләре аша, Югары Сор суын аркылап, Болгардан Киевкә сәүдә юлы да үткән. 986 елда Киевкә, Владимир янына, Болгардан илчеләр килә. Алар кнәзьне халкы белән бергә мөселман диненә күчәргә өндиләр. Владимир илчеләрне әйбәт кабул итә. Киләчәктә бу турыда ныклап уйлап карарга ышандыра. Ләкин ахырда аларга уңай җавап бирелмәве мәгълүм.

Шәһре Болгар зур ике су — Идел һәм Кама кушылган урынга утырган, Европа һәм Азия арасындагы су һәм кәрван сәүдә юлларын үз кулына бикләгән, зур сәүдә үзәге буларак билгеле булган. Болгар Рус кнәзьлекләре, Урта Азия, Гарәбстан, Әрмәнстан, Кытай, Византия һәм башка илләр белән сату иткән. Сәүдәнең болай чәчәк атуы болгарларның варислары татар халкының авыз иҗатында да яңгыраш тапкан.

*Болгар-Биләр диясез, Болгарданмы киләсез,*
*Болгар елкыларын һәйдәп, һинд илләрен гизәсез.*

*Җукә ләнгәс-кәрәз балга, җәм-аяклар ачы балга,*
*Энҗе-мәрҗән, гәүһәр-якут агыла шәһре Болгарга.*

Ибне Фазлан язмаларындагы: «Русларның товар төягән кораблары Болгар пристаненә килеп туктыйлар»,— дигән сүзләр сату-алу болгарлар тормышында яшәү чыганагының әһәмиятле бер төре булуын күрсәтә. Болгар сәүдәсе аша ас, төлке, кеш, тиен, сусар, кондыз мехлары, балавыз, уклар, балык, гәрәбә, бал, чикләвекләр, затлы күн, кылыч-көбәләр, каен агачы, куян һәм кәҗә тиреләре, бүрекләр, сарыклар, мөгезле терлек һ. б. үткән. Бу әйберләр читкә дә чыгарылган. Болгарның үз әйберләреннән сусар һәм кондыз мехлары, балык һәм балык тешләре, каен агачы, чикләвек, бал, куян һәм кәҗә тиреләре, уклар, бизәнү әйберләре, бүрекләр, затлы күн һ. б. әйтергә мөмкин. Болгар күненең даны еракларга таралган. Урта Азия

халыклары яхшы көнне болгар көне, болгари дип йөрткәннәр. Ул татар халкы җырларында да сакланып калган.

*Сәхтиян читек лә, ай, бизәүле,*
*Болгарныкы икән олтаны шул,*
*Болгарныкы икән олтаны...*

Болгар сүзе, Болгар белән бәйләнеш шагыйрьләребез һәм язучыларыбыз иҗатында да зур урын алган. Ул шагыйрьләргә илһам, галимнәргә бетмәс-төкәнмәс фидакарьлек биргән. Болгарда татар халкының бөек фикер иясе Ш. Мәрҗани булган, йөрәге түреннән алып аңа шигырь юллары язган һәм татарларның килеп чыгуын болгарлар белән бәйләү өчен күп дәлилләр эзләп тапкан. Татар халык шагыйре Г. Тукай Болгарга мөнәсәбәтен болай белдерә.

*Дөньяда болгарларның бар икәнлегенә ышансыннар;*
*Якты бәхетебезгә башкалар да көнләшсен, омтылсын.*

Шәһре Болгарны монгол яулап алучылары җимерү дә халык авыз иҗатында тирән эз калдырган, халыкта кара кайгы уяткан.

*Тарих җиде йөздә*
*Килде Тимер Болгарга.*
*Габдулла ханның кулындин*
*Болгар шәһрен алдыйа.*

Болгар бабаларыбыз, килгән яуга карап, кул кушырып утырмаганнар, аларга каршы батырларча көрәшкәннәр һәм күбесе һәлак тә булган. Шәһре Болгар көнбатышка юл тота торган яу юлында калкан хезмәтен дә үтәгән. Исән калган халык көче белән Болгар тиз арада яңадан торгызыла. Болгар һәм болгар җирләре 1250 елда төзелгән Алтын Урта дәүләте составына керә. 1250—1350 еллар азагына кадәр шәһре Болгар үзенең чәчәк ату чорын кичерә. Шушы чорда рус елъязмаларында ул Бөек Болгар дип атала башлый. Анда эшләнгән бизәнү әйберләренең даны еракларга таралган. Таш һәм кирпечтән йортлар төзү, керамик әйберләр ясау, күн эшкәртү һөнәре үскән, алга киткән, чуен кою үзләштерелгән. Акча сугу, сәүдә итү тагын да көчәйгән. Ләкин Алтын Урда эчендәге каршылыклар, алып барылган үзара сугышлар Болгар җире һәм шәһре Болгарны бик нык какшаталар. 1431 елда князь Федор Пестрый Болгарны җимерә һәм аны Казан алмаштыра.

Борынгы болгар шәһәренең хәрабәләре хәзерге Куйбышев районы Болгар авылы урыныда һәм аннан көньякта, Идел суының сул ярында урын алган. Элекке шәһәр урынында соңыннан барлыкка килгән рус авылына Болгар исеме бирелгән. Куйбышев ГЭСы төзелү уңае белән, монда элекке Спасс районының үзәге Спасс шәһәре күчереп утыртыла һәм аңа Куйбышев дип исем бирелә. Хәзер бу урында 1969 елдан бирле дәүләтебез тарафыннан Болгар дәүләт тарихи архитектура заповеднигы оештырылган. 1722 елда Иран сугышына узып барышлый шәһре Болгар хәрабәләрен Петр 1 карап йөри. Кече Манара өстенә менә, тирә-якны күзәтә һәм ул шәһәр урынының оста сайланган булуына соклана. Ахырдан аунап яткан кабер ташларын җыеп куярга әмер бирә. Болгар дәүләтен, шәһре Болгар тарихын өйрәнүгә бөтен гомерен Мәскәү профессоры А. П. Смирнов багышлый.

Татарстан картасында шәһре Болгар, кызганычка каршы, хәзер рәсми кулланылмый. Ләкин халык хәтере шәһре Болгарны күңелендә йөртә, онытмый. Ул яклардагы җирле халык район үзәге Куйбышевка барырга кирәк булса, Болгарга барабыз, дип сөйли. Шунысы игътибарга лаек, борынгы шәһәр атамасы рәсми кулланылыштан чыкса да, элекке Болгар дәүләте җирендәге Татарстан районнарында Болгар сүзе белән дистәләгән авыл, елга, күл, тау һ. б. объектлар аталган. Мондый атамалар тагын элекке Болгар дәүләте белән чиктәш яки аның политик һәм экономик йогынтысы астында булган урыннарда да очрый. Ока суы тирәләре, Пермь өлкәсе, Урал буйлары, Төньяк Кавказ һәм Украина җирләрендә болгар сүзе истәлек булып, географик атама буларак ныгып калган.

Шәһре Болгар халык хәтерендә, күңел түрендә, җырларда, бәет һәм дастаннарда. Ул — халкыбызның данлы үткәне, барасы юллар, күтәреләсе үрләр өчен якты маяк, юаныч һәм ышаныч.

**Фирдәүс ГАРИПОВА,**
филология фәннәре кандидаты.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

19 ноябрьдә узган ачык партия җыелышында тәнкыйтьче Мансур Вәлиевнең иҗат отчеты тыңланды.

Җыелышта Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин, тәнкыйтьчеләр И. Нуруллин, Б. Гыйззәт, шагыйрьләр К. Латыйпов, Ә. Рәшитов, М. Галиев, Л. Шакирҗанова, прозаик Р. Хафизова һ. б. Мансур Вәлиевнең иҗатына һәр яклап анализ ясадылар.

Соңыннан тәнкыйтьче бүгенге әдәби процесска караган күп кенә сорауларга җавап бирде, үзенең иҗат планнары белән уртаклашты.

## ТАНТАНАЛЫ ҖЫЕЛЫШ

6 ноябрьдә Татарстан Язучылар союзы оешмасының Бөек Октябрьнең 70 еллыгына багышланган тантаналы җыелышы булып узды. Җыелышта язучы Барлас Камалов доклад сөйләде.

Революция казанышларын корал һәм ялкынлы сүз белән саклауда, аны ныгытуда турыдан-туры катнашкан язучылар Риза Ишморат, Мария Елизарова һәм Мәхмүт Хөсәен чыгышларын һәркем дулкынланып тыңлады. Соңыннан яшьрәк буын әдипләр ветераннарны кайнар котладылар, яңа шигырьләрен укыдылар.

## К. ТИНЧУРИННЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Октябрь-ноябрь айларында республикабыз җәмәгатьчелеге татар әдәбияты классигы, күренекле драматург, режиссер һәм актер Кәрим Тинчуринның тууына 100 ел тулуны киң билгеләп үтте. Авылларда һәм шәһәрләрдә аның иҗатына һәм тормыш юлына багышланган әдәби кичәләр, драматургның замандашлары белән очрашулар уздырылды.

СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты, Татарстан Язучылар союзы һәм РСФСР Театр эшлекләре союзының Татарстан бүлеге белән берлектә, бу юбилейга багышланган фәнни конференция үткәрде. Республикабызда драматургның әсәрләре буенча куелган спектакльләр фестивале барды.

16 ноябрьдә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Кәрим Тинчуринның тууына 100 ел тулуга багышланган тантаналы җыелыш булды.

Президиумда — КПСС өлкә комитетының беренче секретаре Г. И. Усманов, ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе Ш. Ә. Мустаев, ТАССР Министрлар Советы Председателе М. Ш. Шәймиев, КПСС өлкә комитеты, Казан шәһәр комитеты бюролары членнары һәм членлыкка кандидатлар, республикабызның партия, совет, профсоюз, комсомол оешмалары, иҗат союзлары, культура учреждениеләре, хезмәт коллективлары вәкилләре, драматургның тормыш иптәше Заһидә ханым Тинчурина, туганнары.

Тантаналы җыелышны кереш сүз белән КПСС өлкә комитеты секретаре Н. Х. Кадермәтов ачты.

Кәрим Тинчуринның тормышы һәм иҗат юлы турында доклад белән ТАССР Министрлар Советы председателенең беренче урынбасары, К. Тинчуринның юбилеен үткәрү буенча республика комиссиясе председателе М. Х. Хәсәнов чыкты.

Аннары сәнгать осталары катнашында К. Тинчурин әсәрләреннән төзелгән әдәби-музыкаль кичә булды.

## К. ТИНЧУРИННЫҢ ӨЧ ТОМЛЫГЫ

Кәрим Тинчуринның тууына 100 ел тулу уңаеннан Татарстан китап нәшрияты аның әсәрләренең өч томлыгын бастырып чыгарды.

Томнарны төзүче, сүз башы язучы һәм аңлатмалар бирүче — филология фәннәре кандидаты Бәян Гыйззәт.

## ТЫНЫЧЛЫК ХАКЫНА

24 октябрьдә «Тынычлык дулкыны» дип исемләнгән Бөтендөнья акциясе булып узды. Бу чарада республикабызның әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре актив катнашты.

ТАССР Художниклар союзы янында уздырылган митингта әдипләр: Г. Рәхим, Н. Дәүли, Р. Харис, Р. Гатауллин, И. Юзеев, Г. Ахунов, З. Нури, Ә. Баянов, Ф. Гыйззәтуллина, Р. Халиуллина, Р. Мостафин, Ә. Рәшитов, Э. Шәрифуллина, Н. Акмалов, Г. Моратов чыгыш ясадылар.

ТАССР Художниклар союзы оештырган картиналар ярминкәсендә сатудан алынган акча Тынычлык фондына күчерелде. Халыкара конкурслар лауреаты композитор Р. Кәлимуллинның авторлык концертыннан һәм Әлмәт, Бөгелмә, Минзәлә театрлары спектакленнән алынган акча шулай ук Тынычлык фондына күчерелде.

## КҮРГӘЗМӘ ЗАЛЛАРЫНДА

Бөек Октябрьнең 70 еллыгы уңае белән ТАССР сынлы сәнгать музеенда Идел ягы

һәм Урал буе автономияле республикалары рәссамнарының 60 тан артык әсәрен берләштергән күргәзмә оештырылды. Моңа кадәр әлеге әсәрләр Чувашия, Удмуртия, Башкортстан, Мордовия, Мари, Калмык АССРдагы, шулай ук Татарстандагы сәнгать музейлары фондында саклангaн иде.

Күргәзмә залына куелган әсәрләре белән танышу һәр автономияле республиканың милли традицияләрен, гореф-гадәтләрен һәм рәссамнарның иҗат мөмкинлекләрен күзалларга ярдәм итә.

Казанлылар күргәзмә белән танышканнан соң, аны Йошкар-Ола, Ижевск, Чабаксар, Саранск, Элиста шәһәрләрендә яшәүче тамашачылар да карады.

6 ноябрьдә Татарстан Художниклар союзының Күргәзмәләр залында Бөек Октябрь социалистик революциясенең 70 еллыгына һәм Казан студентларының В. И. Ульянов-Ленин катнашындагы сходкасының 100 еллыгына багышланган республика сәнгать күргәзмәсе ачылды. Анда рәсем, скульптура, архитектура, декоратив-гамәли һәм театр-декорация сәнгате осталарының 500 дән артык эше куелган.

Бөек Октябрь социалистик революциясенең 70 еллык юбилеена багышлап Татарстан АССР Художниклар союзының Күргәзмә залында һәвәскәр рәссамнарның һәм декоратив-гамәли сәнгать осталарының республика күргәзмәсе үткәрелгән иде. Анда 200 гә рәссамның һәм останың меңнән артык эше күрсәтелде.

### ФИЛАРМОНИЯ ЮБИЛЕЕНА БАГЫШЛАП

23 ноябрьдә М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең 50 еллыгына багышланган тантаналы кичә булды.

Кичәне ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов ачты.

КПСС өлкә комитеты секретаре Н. Х. Кадерматов котлау сүзе белән чыкты, коллективка РСФСР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасын тапшырды.

Филармониянең иҗат юлы турында ТАССР культура министры М. М. Таишев сөйләде.

Филармония коллективын олы юбилее белән республикабызның иҗат союзлары идарәләре җитәкчеләре, театрлар, хезмәт коллективлары вәкилләре, үзешчән сәнгатьтә катнашучылар котлады.

Аннары филармония артистлары катнашында зур концерт булды.

### ОЕШТЫРУ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

23 октябрьдә Казанның Актерлар йортында Совет культура фонды Татарстан бүлеген оештыру конференциясе булды. Анда партия, совет, профсоюз, комсомол органнары, иҗат союзлары, культура һәм фәнни учреждениеләр, югары уку йортлары, хезмәт коллективлары, җәмәгатьчелек вәкилләре катнашты.

Конференцияне кереш сүз белән ТАССР Министрлар Советы председателенең урынбасары М. Х. Хәсәнов ачты. КПСС-ның XXVII съезды карарлары яктылыгында Совет культура фонды Татарстан бүлегенең бурычлары һәм киләчәк эшчәнлегенең юнәлешләре турында доклад белән ТАССР культура министры М. М. Таишев чыкты. Доклад буенча фикер алышу булды.

Конференциядә Совет культура фонды Татарстан бүлеге идарәсе сайланды.

Оештыру утырышында Совет культура фонды Татарстан бүлеге идарәсе председателе итеп язучы Г. А. Ахунов сайланды.

### АТАКЛЫ ГАЛИМ ИСТӘЛЕГЕНӘ

27 октябрьдә Казан дәүләт педагогия институтының Актлар залында күренекле әдәбият галиме, тәнкыйтьче һәм профессор Галимҗан Нигъмәтинең тууына 90 ел тулуга багышланган юбилей кичәсе үткәрелде. Казан дәүләт педагогия институтының татар әдәбияты кафедрасы доценты Э. Р. Галиева кичәдә Г. Нигъмәтинең тормыш һәм иҗат юлы турында доклад белән чыкты. Юбиляр турында аның шәкертләре филология фәннәре докторы профессор Хатип Госман, филология фәннәре кандидатлары Җамал Вәзиева, Бәян Гыйззәт истәлекләр сөйләделәр.

### ГАЗИЗ ГОБӘЙДУЛЛИН ХӨРМӘТЕНӘ

21 ноябрьдә Мәскәүнең С. М. Зуев исемендәге культура йортында күренекле тарихчы-галим, язучы Газиз Гобәйдуллинның тууына 100 ел тулуга багышланган тантаналы кичә булып узды. Кичәне язучы Миргазыян Юныс ачты һәм алып барды. Галимнең фәнни эшчәнлеге, тормыш юлы турында кереш сүзне язучы Мөхәммәт Мәһдиев сөйләде.

Тарих фәннәре кандидаты С. Х. Алишев, СССР Фәннәр академиясенең Дөнья әдәбияты институты профессоры Р. Ф. Юсуфов, СССР Фәннәр академиясенең Тарих институты өлкән фәнни хезмәткәре Ш. Ф. Мөхәммәдьяров, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институты өлкән фәнни хезмәткәре Л. Р. Гайнанова чыгышлары да тыңлаучыларда зур кызыксыну уятты. Кичәдә әдипнең улы Сәлмән Газизович Гобәйдуллин истәлекләр сөйләде. Шагыйрьләр Ренат Харис, Рәшит Әхмәтҗанов, Нияз Акмалов, әзербәйҗан шагыйре Илһам Бадалбәйле чыгышларын тамашачылар алкышлап каршылады.

Кичәдә күренекле язучы Әмирхан Еники, генерал Рәфгать Вәлиев, филология фәннәре кандидаты Флора Әхмәтова һ. б. катнашты.

Концертта Мәскәү өлкәсе филармониясе җырчылары, сүз осталары, шулай ук Казан дәүләт университетының «Каз канаты» ансамбле, Мәскәү үзешчән татар театры артистлары катнашты.

## «КАЗАН УТЛАРЫ» — МӘСКӘҮДӘ

20 ноябрьдә илебез башкаласының Н. А. Некрасов исемендәге китапханәсендә «Казан утлары» журналы авторлары һәм хезмәткәрләренең Мәскәү әдәбият сөючеләре белән очрашу кичәсе булды.

Кичәдә журналның баш редакторы шагыйрь Ренат Харис бүгенге татар әдәбияты, журналның эше, анда басылган һәм басылачак әсәрләр турында җылы әңгәмә уздырды.

Журналның актив авторлары — атаклы язучы Әмирхан Еники, язучылар Миргазыян Юныс, Мөхәммәт Мәһдиев, журналның бүлек редакторы шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов, шагыйрь Нияз Акмалов һәм китапханәнең бүлек мөдире Т. А. Пышкинаның чыгышларын әдәбият сөючеләр зур кызыксыну белән тыңладылар. Күпсанлы сорауларга җаваплар бирелде.

## ИҖАТ КИЧӘЛӘРЕ

2 октябрьдә Казан шәһәренең Актерлар йортында Рәисә Ишморатовага 70 яшь тулу уңаеннан әдәби-музыкаль кичә булып узды. Язучының тормыш һәм иҗат юлы турында доклад белән Гариф Ахунов чыкты.

Язучыны котларга ТАССРның культура министры М. М. Таишев һәм ТАССР эчке эшләр министрлыгы вәкилләре, күпсанлы якташлары килгән иде. Соңыннан республикабызның күренекле сәнгать осталары концерты булды.

13 ноябрьдә Казанның Актерлар йортында язучы Кояш Тимбикованың иҗат кичәсе булып узды. Кичәдә танылган прозаикның иҗатын хөрмәт итүче әдәбият сөючеләр, язучылар, Татарстан АЭСын төзүчеләр һәм язучының туган авылыннан килгән якташлары катнашты.

К. Тимбикова һәм халык иҗаты әсәрләреннән торган бу әдәби-музыкаль кичәдә республикабызның танылган сәнгать осталары чыгыш ясады.

## ТОПОНИМИК КОМИССИЯ

18 ноябрьдә СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты каршында республика топонимик комиссиясе төзелде. Аның бурычы топонимика проблемаларын өйрәнү һәм тәкъдимнәр эшләүдән гыйбарәт. Комиссия составында тарихчылар, тел белгечләре, язучылар, журналистлар, совет органнары һәм җәмәгать оешмалары вәкилләре кертелде. Комиссиянең председателе — филология фәннәре докторы, Казан дәүләт университеты профессоры Г. Ф. Саттаров.

Комиссиянең беренче утырышында җирле топонимика эшенең торышы һәм анда гамәли тикшеренүләрнең юнәлешләре турында докладлар тыңлап тикшерелде.

## СТУДЕНТЛАР ЯНЫНДА

Шагыйрь Ренат Харис 11 октябрьдә Казан культура институтының «Диксиз» клубында студентлар белән очрашты һәм «Заман һәм бүгенге әдәбият» дигән темага уздырылган әңгәмәдә катнашты. Шагыйрь студентларны үзенең «Борылышта» («На повороте») дигән поэмасының Равил Бохараев тарафыннан эшләнгән русчага тәрҗемәсе белән таныштырды.

## УТ КҮРШЕЛӘРДӘ

Декабрь аенда әдипләребез Г. Ахунов, Р. Гатауллин һәм җырчы-композитор М. Имашев Башкортстанда булдылар. Алар анда башкорт язучысы, тарихи-революцион темага күп әсәрләр, шул исәптән, татар революционерлары М. Вахитов, Х. Мәүлетов һәм генерал Я. Чанышев турында китаплар авторы Вәзих Исхаковның тууына 60 ел тулу кичәләрендә катнаштылар.

Октябрь азагында шагыйрь И. Юзеев үзенең туган ягы Башкортстанда булып кайтты. Танылган башкорт шагыйре һәм драматургы Ә. Атнабаев белән Башкорт дәүләт университетының татар әдәбияты бүлеге студентлары һәм укытучылары белән очраштылар. Бүгенге әдәбиятка кагылышлы күп сорауларга җавап бирделәр, шигырьләр укыдылар.

Шул көннәрдә М. Гафури исемендәге башкорт дәүләт академия театры И. Юзеевның «Сөйгәнемнең туган көне» исемле траги-комедиясе буенча куелган спектакльнең премьерасын күрсәтте. Әсәрне сәхнәгә РСФСРның атказанган артисткасы Гөлли Мөбәрәкова куйды. Элегрәк шул ук театрда И. Юзеевның «Сандугачлар килгән безгә» исемле моңсу комедиясе сәхнәгә куелган иде.

## ӘЛМӘТ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

17 октябрьдә Әлмәт шәһәренең хезмәт ияләре зурлап шәһәр көнен бәйрәм иттеләр. Тукай һәйкәле каршындагы мәйданда оештырылган әдәбият-сәнгать бәйрәмендә шагыйрьләр Ә. Маликов, Э. Мөэминова, К. Булатова, Р. Рәкыйпов, Н. Әхмәдиев, Әлмәттәге «Кызыл каурыйлар» һәм «Графит» әдәбият берләшмәләре членнары Ф. Галиева, Т. Чудинова, В. Герстенбергер һәм Әлмәт драма театры артистлары, үзешчәннәр катнашты һәм чыгыш ясады.

24 октябрьдә Әлмәт шәһәренең Тукай һәйкәле каршындагы мәйданда «Тынычлык дулкыны» акциясе узды. Шәһәр хезмәт ияләре белән бергә фронтовик-шагыйрь Ә. Маликов, шагыйрьләр К. Булатова, Н. Әхмәдиевләр дә катнаштылар һәм тынычлыкка багышланган шигырьләрен укыдылар.

# ТЫЛСЫМЛЫ ТАРТМАЛАР

Сәнгатьчә бизәлеп эшләнгән тышлыклар — кечкенә китап салу өчен тартмалар ювелирлык сәнгатенә дә, китап сәнгатенә дә якын тора. Китапка рухи культура билгесе итеп хөрмәт белән караган татар халкында мондый тартмалар борынгыдан килә. Мәсәлән, хәзер Хельсинкидагы Милли җыелмада саклана торган, затлы нәкышләр белән бизәлгән кыйммәтле тартма Болгар чорына ук карый. ТАССР Сынлы сәнгать музеендагы фирүзә ташлар белән бизәкләп эшләнгән тартма эстерхан чикләвегеннән бераз гына зуррак, тышында гарәп саннарыннан сере әле дә ачылмаган тылсымлы формула язылган. Ул XIV—XV йөздә ясалган булырга тиеш.

Ленинградтагы Халыклар этнографиясе дәүләт музеенда һәм Татарстанның Берләштерелгән Үзәк дәүләт музеенда төрле-төрле зурлыктагы алтын, көмеш, җиз тартмалар саклана, аларын инде XVII-XIX гасыр осталары ясаган. Бизәкләп, иң матур эшләнгәннәре Казан осталарыныкы. Тартмаларда сырлап-бизәп язылган хәрефләрне һәм әлеге осталарның ярымай рәвешендә монограммаларын да күрергә була. Өске капкачы яисә ян ягы ачыла торган тартмада кульязма яки басма китап яткан, алар анда ышанычлы саклаңганнар.

Безнең көннәргә кадәр килеп җиткән китап тартмаларының декоратив бизәү ысулына, орнаментлар системасына һәм төзелешенә карап Болгар һәм Казан ханлыгы чорындагы татар китабының югары профессиональ дәрәҗәсе турында фикер йөртергә мөмкин. Борынгыдан килгән традицияләр соңгырак чорда да дәвам иткән.

Күпчелек классик тартмаларның төп бизәге — капкачындагы язу. Текст бик нечкәләп, борынгы шәрык стилендә, хәрефләрне бергә үреп, бөтеркәләп ясап язылган. Аларда — бабаларыбызның безгә әйтер сүзе, белемнәре, омтылышлары, уй-хыяллары, кабатланмас рухи иҗаты. Тартмаларда иясләренең исеме, багышламалар, саклагыч язулар, теләкләр очрый, кайвакыт кыска гына сүзләр белән тирән мәгънәле фәлсәфи фикер бәян ителә. Коръән тартмаларының күбесендә шулай ук борынгы легендар шәхесләрнең исемнәре язылган. Бу исемнәр тылсым көченә ия, теләкләрне кабул кылдыра, гөнаһларны бетерә, чирләрдән, бәла-казадан саклый дип ышанганнар. Тартмаларга төшерелгән бу сүзләр аларга яңа сыйфат, яңа эчтәлек өсти.

Тартмалардагы текст күбесенчә кабарынкы ысул белән чүкеп ясалган. Батынкы фон да нокталар, сызыклар, сырлар белән бизәкләнгән. Шуның аркасында хәрефләрнең пластик эффекты көчәя, яктылык-шәүлә уены барлыкка килә.

Халык культурасының җәүһәрләре булган китапларны саклау белән бергә бу тылсымлы тартмалар үзләре дә безнең көннәргә элекке осталарның кул җылысын, күңел яктылыгын, рух байлыгын китереп җиткергәннәр.

**Розалина ШАҺИЕВА**,
Татарстан сынлы сәнгать музее
гыйльми хезмәткәре.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Казанда Язучылар йорты (Комлев урамы, 14)

**Юрий ФИЛИМОНОВ** фотолары.

*РСФСР Министрлар Советы*
*карары*

## ӘДӘБИЯТ, СӘНГАТЬ ҺӘМ АРХИТЕКТУРА ӨЛКӘСЕНДӘ РСФСРның 1987 ЕЛГЫ ПРЕМИЯЛӘРЕН БИРҮ ТУРЫНДА

РСФСР Министрлар Советы, РСФСР Дәүләт премияләре буенча РСФСР Министрлар Советы Президиумы комиссиясе тәкъдимнәрен карап, карар бирә:

РСФСРның 1987 елгы Дәүләт премияләрен бирергә:

Әдәбият өлкәсендә — М. Горький исемендәге премия

**Гыйләҗев** Аяз Мирсәетовичка, язучы — «При свете зарниц» («Аҗаган яктысында») дигән повестьлар җыентыгы өчен.

| | |
|---|---|
| **РСФСР Министрлар Советы председателе** | **В. ВОРОТНИКОВ** |
| **РСФСР Министрлар Советы эшләр управляющие** | **И. ЗАРУБИН** |

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)